**Нәбирә Гыйматдинова**

# Мәхәббәттә гонаһ бар

## Повестьлар, хикәятләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2008

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-44
Г92
**Гыйматдинова Н.М.**

Мәхәббәттә гөнаһ бар: повестьлар, хикәятләр / Нәбирә Гыйматдинова. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — 383 б. — 6000 д. — ISBN 978-5-298-01678-0

Дөнья белән бергә бик күп әхлакый төшенчәләр барлыкка килгән. Алар нинди генә дәвердә дә җир йөзеннән югалмый, алар мәңгелек. Бу Нәбирә Гыйматдинованың әсәрләрендә һәрдаим чагылып килә. Язучы, үз кыйбласына тугры калып, Намус, Вөҗдан, Кешелеклелек, Изгелек, Җан һәм Мәхәббәт турында уйлана.

ISBN 978-5-298-01678-0

© Татарстан китап нәшрияты, 2008
**© Гыйматдинова Н.М., 2008**

## Повестьлар

# Җәза

### 1

Тау битенә төшкән ут шәүләсе сикерә-сикерә чирәм арасында уйный. Бүген тагын учак якты... Һай, киребеткән дә икән бу кыз бала! Кычыткан белән чәбәкләрлек кешесе юк шул аның. «Шүрәле очы» дип аталган урамда Нурсөянең йорты гына кукраеп калды. Тавы белән бергә өскә авам-авам дип торган нарат күләгәсендә үлән дә шытмый дип, күрше-күлән бистәгә үк күченде. Урманны җәяү чыксаң — кул сузымында гына ташпулатлар тезелгән. Халык бит ул умарта күче кебек укмашып яшәргә ярата. Бер-берсенә йөрешмәсә дә, аркасын аркага куеп яткан карт белән карчык сыман, сараен — сарайга, мунчасын мунчага терәп сала. Югыйсә сөнчәлеләргә бистәдә эреп таралмасалар да була иде. Аргы урамнар агач-куак ышыгыннан интекми ләбаса. Анда урын да иркен. Каралты-кураларың белән теләсәң — буйга, теләсәң, иңгә табан җәел. Элек авыл бер күлмәк эченә сыя иде, бүген аның күкрәге киңәйде, һәм төймәсе, тамырыннан өзелеп, читкә чәчрәде. Хәер... Сөнчәленең тормыш агачы нык иде, яшьләр дә, дөньясын тарсынып, ягага китми иде. Авылның бәгыренә шырпы кадалды шул. Гыймран малайлары Сөнчәлегә кайтып төпләнде. Кулларын кесәләренә тыгып, җил сызгыртып кайтмадылар, төргәк-төргәк акча белән кайттылар. Моңарчы алар елына ике-өч зыян эшләсә, бу юлысы көн саен халыкны зар елатыр, мөгаен. Байлыклары талап җыелган, диләр. Бәлки, анысы дөрес тә түгелдер, чөнки бер талаган нәфесен тыеп туктый белми ул. Яртылаш бушаган арыш капчыгы кебек янтайган чирләшкә Гыймран, залим уллары Сөнчәлене бүлеп алагаем зур йорт тергезгәч, яңадан зәһәр белән шыплап тулды. Сакаллы сабыйларына ул акыл өйрәтте бугай, ике буш куык, авыл халкын кысрыклый-кысрыклый, кыр хәтле бакчалар сөрдереп, ел саен шунда чүп үстерде. Шуларның кыланмышына түзмәгәннәрдер, тикмәгә генә гаиләсе-гаиләсе белән бистәгә агылмаслар иде. Ә көрәшергә тырышып караучылар?.. Алар ялгыз, ялгыз. Элгәре кемгәдер зарланырга мөмкин иде. Әз-мәз гади кешеләрне яклаучы оешмалар бар иде шикелле. Бүген исә көчленеке замана. Теге чакларда Гыймран ише кансыз берән-сәрән генә булса, бүген аларның чуты юк. Акча дигән шайтанның җилкәсенә атланганнар да адәм башыннан очалар.

Хатын, нәзек сабаклы кылганнарны ера-ера, тауга менде. Караңгы иде. Учакка табан турыласа, йә кунакны өркетер. Хәер, куян йөрәкле кызга охшамаган да ул бала. Юкса, төн ката учак пыскытып, урман авызында туңкаеп утырмас иде. Бистә ягыннан ап-ачык булып нindидер кыргый тавышлар ишетелә. Даң-доң калай кагалар, сызгыралар-акыралар. Көй диләр бугай шуны. Гармун — искелек калдыгы, янәсе. Бистә яшьләре дискотекада бии.

Югарыга менгән саен, нарат исе тынга каба иде. Үзәнлектә дә шул ис, әмма, Хәлидәнең йорты янганнан соң, ул көек белән буталды. Унбиш елдан бирле тамакны әчетә. Бәлки, ис һавага сеңгәндер, ә юшкыны Нурсөянең үпкәләренә сылангандыр?! Юшкын да түгелдер, хатынның гөнаһысыдыр, бәлки?!

Гөнаһ, катлам-катлам гөнаһ... Аңардан арынуы җиңел югыйсә: йортка үзеннән-үзе ут капмады, йортны, ишегенә терәү тери-тери, күз алдында яндырдылар! Әйт шулай дип, Нурсөя, әйт! Бу гөнаһың белән парлашып тагын күпме яшәрсең икән?! Әмма дистә ярым елдан соң сиңа кем ышаныр ди! Аннан, сөйләп ни мәгънә?! Анасы да, баласы да гаип... Тик Хәлидәнең җаны гына тынычлап күкләр катына урнашмады: ул җирдән ычкыналмыйча бимазалана. Җәйнең нәкъ бер вакытында күренә мәрхүмә. Шомырт каралганда... Сабыен җитәкләгән килеш тау өстеннән туп-туры Нурсөяләр йортына текәлә. Эндәшеп тә карады аңа хатын: «Зинһар, мине эзәрлекләмә, күршекәем! Мин болай да тере мәет», — диде. Ә аның рухына кылган догалар! И-и, сәгать саен, минут саен... Быел шомырт бигрәк тә уңды. Әле яшел, әле каралмаган. Каралгач... тау башында кабат Хәлидә сураер инде. Бу юлысы Нурсөя акылдан язачак, мөгаен. Хәзер үк аңа бизгәк сукты: аяк-куллары калтырый, гәүдәсен җебетеп, йөрәге ойый. Җитмәсә, авыртмаган башка тимер тарак дигәндәй, өендә көтелмәгән кунак яши башлады. Бистә байлары өчен дачага әйләнгән Сөнчәледә, бак, Нурсөядән башка да унлап йорт бар икән. Ник берсенең капкасына орынсын! Әнә Гыймранның хан сараенда туксан тугыз бүлмә. Хатынның ни инде, йә? Бәләкәй генә олы як та кысан гына кече як. Әзрәк иелмәсәң, түшәменә баш тия. Ашау-эчүе дә каты-коты, Гыймран шикелле өч хезмәтче яллап, абзар тулы мал-туар асрамый. Әй, ризык тарлыгымыни! Ходайның биргәненә шөкер! Нурсөянең күңеле нур да үтмәслек дәрәҗәдә тарайды шул! Гөнаһысы, яман шеш төсле, зурайган саен зурая. Үз вакытында Аллаһ ярлыкамаса, һай читен икән лә. Бит Нурсөя күршеләрен коткара ала иде!

Хатынның аягы тайды. Ул, тотынырга теләп, кылганнарны учлады. Ашаганы эченә йокмаган ябык гәүдәне, сыңар кылганга ябышса да, үлән чыдатачак иде. Ничек коткарыр икән соң аларны, ничек?!

— Егылдың мәллә, апа?

Көянтә сыман бөгелгән Нурсөя сискәнеп башын күтәрде.

— Ә, син икән. Куркыттың, җүнсез. Әйтми дигәч тә теге.

— Син, апа, юрган астында да куркып яшисең бугай. Суз кулыңны!

— Ярар инде... Бетеп үк егылмадым бит әле. Тагын нәрсә дип учак үрләттең, бала? Батырып тиргим дип менүем иде. Кешедән яхшы түгел. — Кыз урманнан бер өем чыбык-чабык ташыган иде. — Әстәгым! Таңга кадәр шушында чекерәеп утырмактамы исәбең? — диде хатын, чәчрәгән ут чаткысыннан йөзен каплап. — Дөнья изрәп йоклаганда, йә?

— Дөнья беркайчан да йокламый, апа. Нәрсәдер кыштырдый, нәрсәдер кыймылдый анда. Синең кебекләр аңа һич тынгылык бирми, апа. Туры сукмак бар, ә син, үләннәрне таптый-таптый, нигәдер кырыйдан үрмәлисең, апа. Мин сиңа баядан бирле карап торам, апа.

— Апа, апа дип сүз саен тачылама, яме, бала! Усал да сөйләшмә. Әйтми дигәч тә теге. Аннан, бу урында учак та якма. — Нурсөя кулы белән ботак-чатакларны буташтырды. — Авылның битен көйдерә ялкының, әйе. Гыймран малайлары иснәнсә, сөякләреңнән он тарттыра, валлаһи. Бүген Сөнчәлегә алар хуҗа.

— Ә минем нәкъ шушында учак кабызасым килә, — диде кыз, үзсүзләнеп.

Хатын караңгы төшкән урманга шикле караш ташлады. Хәлидәнең җаны наратлар арасында бәргәләнеп йөрми микән? Хәер, шомырт каралырга иртәрәк әле. «Ул баласын җитәкләп шушы төшкә чыгып баса», — дип, киребеткән шәһәр кызына ничек аңлатасың ди! Ә бәлки, Хәлидә уттан шүрләр? Йа Ходаем, шулай булса икән ул!

— Безнең тирәдәге авыллардан ниндидер риваятьләр җыям, дисең. Зур укудан йөкләделәр, дисең. Үзең кыл да кыймылдатмыйсың. Килгәнеңә атнадан артык, — диде хатын, учакка чыбык өстәп. Ут рухларны куадыр, мөгаен. Алайса, як, кыз бала, як! Тик Гыймран этләренә генә юлыга күрмә, ботарлап ташларлар. — Риваять дигәнең ни-нәрсә инде ул?

— Телдән телгә күчкән хәл-вакыйгалар, апа. Чынлап та, мин ялкауландым, ахрысы. Эшкә тотынырга кирәк, иеме? Әйдә, синнән башлыйк, апа. Менә бу тау турында берәр риваять белмисеңме?

Нурсөя, авыр сулап, төн карасын йотты.

— Беләм дип... «Шомырт тавы» диләр аны. Наратлыктан арырак — куе шомыртлык. Зерә күп куагы. Чәчсәң, үрчемәс иде зәхмәт. Кыргыйдан азган инде. Күршеләрнең әбисе һәвәс иде җимешенә. Базарда да сата иде, өшкереп дәвалый да, әфсенле дә иде. Моның кай җире риваять соң, бала?

— Шуннан, апа, шуннан? Беркөнне син, бу калкулыкка баласын ияртеп кемдер чыга, дигән идең.

— Анысын язма! Минем генә күземә күренә бит ул! Нурсөя саташкан дигән яманатымны таратырсың, җүнсез. Ник бер миңа гына беректең әле син, ә? Йөр, авылларда йөр! Әйтми дигәч тә теге.

— Күңелең тар бугай, апа.

Хатын бозлы суга чумгандай туңды-өшеде. Каян сизә бу яшь кемсә? Әйе, әйе, аның күңеле нур да сыймаслык дәрәҗәдә тарайды шул.

— Безнеке безнеңчә инде. Синең үзеңнең дә әллә ни мактанырлыгың юк, бала. Урман аша гына бистә. Анда егете-кызы чутсыз. Әзрәк иш-тиңнәреңә илек. Җырла-бие. Яшь чакта гына көлү-шаяру килешә, картайгач чеметем генә елмайсаң да: «Ыржайма», — диләр. Яулыгыңны салып ат. Карчыклар төсле уралгансың иту. Әйтми дигәч тә теге.

Кыз учакка кочак-кочак коры ботак ыргытты. Һаваны ялмаган ялкын телләренең өтек-төтек шәүләсе кытыршы наратлар кәүсәсендә биеште.

— Киңәшеңә рәхмәт, апа. Минем сәгатьләрем санаулы гына.

— Китәсеңмени?!

Хатынның җанын сөенеч биләде. Шушы сәер кунак аркасында капка келәсе шылдырамый. Хәер, элек тә аңа бик килмәделәр. Бер өмет кенә аның ишеген ача да яба, ача да яба. Гыймран, кансыз, явыз Гыймран, бүре тиресен салып калдырыр да мөлаем, йомшак ир кыяфәтендә Нурсөянең бусагасыннан атлап керер сыман. Ничә ел хатын кысыр өмет белән яшәде! Килми Гыймран... Кунак турында ишеткән, димәк. Ишетмәскә ни! Санасаң, авылда йортлар ике кулдагы ун бармак ласа! Кемнең морҗасында төтен куе да, кемдә сыек — һәркемнең уч төбендә.

— Китмим әле, апа.

Бу кыз тыштан ипле-җайлы гына күренсә дә, эче тулы кирелек иде. Кара син, әллә нинди җиде ят Нурсөянең бәхетенә киртә кора. Китмим, имеш. Гыймран бит ул, чалшайса-кәкрәйсә дә, Гыймран! Уңайга сыпырган хатын илле биш яшьлек ирдән шалкан ясый. Соңгы көннәрдә ул, Нурсөяне очратса, салынган иңбашларын төзәтеп, талпынып кагына һәм төнлә көт дигән ишарә белән калын кашларын сикертә. Бик килер иде, кунак кызы юлына бүрәнә тәгәрәтә.

— Авылдашларың турында сөйлә әле, апа.

— Монысы нәрсәгә инде, бала?

— Риваятьләрегезнең мәгънәсенә төшенер өчен кирәк, апа. Халкы нинди, экияте шундый, диләр.

Хатын чекерәя-чекерәя авылга карады.

— Иң кырый йорт Гыймранныкы инде. Элек-электән терлек үрчетеп сатты инде. Болын ягы бит, иркен. Кыр-басу белән фермасы да якын. Әрәмәлектән йодрык хәтле генә кыр үрдәкләре атып ашады инде. Аның бабасы заманында күгәрченнәрне терелэй утта кыздырган, ди. Шуннан бирле өй кыекларында күгәрченнәр гөрләми, корыткан Сөнчәледә кошларның нәселен Гыймран бабасы. Гыймранның ике малае йә авылда, йә бистәдә. Ике арада иләнәләр. Башкисәр алар. Абзаң — тол. Байтактан инде. Мәрхүмә хатыны Фәһимә яшьләй үлде. Аңа якты көн чырае күрсәтмәделәр инде. Бер беләген каенанасы кара яндырса, икенчесен — хыянәтче... — Тел очына нинди сүз төшкәнен Нурсөя әле дә абайлап өлгерде. Гыймранның тишек-тошыгын күрсәтәм дип, үзенең ертыгын җилгә селки түгелме соң?! — Бирерәк — Әмирҗан бабайлар...

— Чү, апа. Икенчесен хыянәтче дигән идең. Әллә Гыймран берәр хатынны яраттымы?

— Син, кызый, тавык төсле, авыл борынча гайбәт чүпләдеңмени, йә? Ул да риваятьме?

Нурсөянең бәгырен утлы тимер көйдерде. Кайсыныңдыр хәтере бер дә саекмый, ахрысы. Тик Фәһимәнең үлемен аңа сылтамасыннар. Бу гөнаһны да үзенә алалмый ул!

Хатынның күзен яшь әчеттерде. Төтен икән.

— Ник өстәмисең, учагың сүнә, — диде ул, әкрен генә. — Йөрмә бүтән теләсә кемнән сорашып, яме, бала! Аның бит әрем теллесе дә күп. Һәр сүзе үтеңне сыта. Әмирҗаннардан тегендәрәк... — Урманның йөрәген ярып карлыккан тавыш белән кош кычкырды. Йа Рабби, кош микән?.. — Кайтыйк, бала, — диде Нурсөя. — Бәласеннән баш-аяк...

— Без икәү бит, курыкма, апа. Әйдә, Әмирҗаннарны сикереп, үз тирәңә күч. Сул як күршеләрең кемнәр иде?

— Мәрхүм инде алар... Әниле-кызлы иде. Яндылар. Мәетләр турында сорашма, яме. Гүр иясе сиңа берни дә әйталмас, бала.

— Ә син күршеләрең өчен үзең сөйлә, апа. Алар нинди кешеләр иде?

— Кеше кебек кешеләр иде. Ике аяклы, ике куллы. Әйтми дигәч тә теге. — Нурсөянең ачу казаны дөбер-дөбер кайный иде. — Көл катыш туфракларын җыеп, зиратка илтеп күмделәр...

— Нәрсә-ә-ә?! — Кыз, учак аша сикереп, хатынның алдына килеп басты. — Күршеләреңнең кабере дә бармыни?!

— Вәт акылга сай савыт! Үлекләрнең җәсәде җиргә иңдерелә ләбаса! Боларның көле генә инде... Сөякләренә хәтле янып уалгач...

— Исемнәре дә язылганмы?!

— Язылган иде элек. Такта кисәгенә. Ул череде инде. Коймасы да ауды. Пар шомырт куагы гына исән.

— Бар, кайт, апа, — диде кыз, төпченүеннән капыл туктап.

— Кайтмый ни! Нарат бит ул баш түбәсен генә каплаган, шәрә агачның салкыны арканы туңдыра. Әйтми дигәч тә теге.

Нурсөя кызу-кызу таудан төште. Төште дә артына борылды: калкулык иләмсез караңгы иде. Учагын сүндерде... Сөйлә дә сөйлә дип җаныңны ашый бит, ә! Хәлидә иде аның исеме. Кызы Галия иде. Йә, күңелеңнең почмаклары түгәрәкләндеме, бала? Әллә син Нурсөяне, җил капка сыман, теләсә кемгә ачылыр дисеңме?!

Турыларына җиткәндә генә, тыкрыктан машина ыжгырып чыкты. Каты музыка тавышы колакны саңгыраулата иде. Ул да түгел, хатынның аяк астында сыра шешәсе чылтырап ватылды. Гыймранныкылар бистәдәге «шайтан туе»нда кәефләнгән. Алар гел шулай, мыскыллап йә тәмәке төпчеге, йә шешә бәреп китә.

Нурсөя, чүмәшеп капшана-капшана, пыяла кисәкләрен итәгенә тутырды. Кунак кызы ялгыш басмагае тагы. Туфлиемның үкчәсе җиргә бата дип яланаяк йөри. Авылда сиңа көзгедәй шома таш түшәлмәгән шул.

Гыймран малайларының чираттагы «бүләге»н рәшәткә кырыена бушаткач, ул колагын торгызып тыңланды. Койманың теге ягында нәрсәдер кыштырдый иде. Янган йорт нигезендә орлыгын коеп алабута котырып үсә. Хатынның тавыклары ел саен шунда кереп йомырка салды һәм ел саен качып кына чебеш чыгарды. Нурсөя чалгы белән ничәмә-ничә мәртәбә чүп дәрьясын чабып ташларга җыенды, тик, уртадагы рәшәткәләрне каерып, ул тарафларга керергә батырчылык кына итмәде. Чөнки күңеленә шундый уй кагылды исә, мәрхүмә Хәлидә төшендә: «Син һаман минем белән булашасыңмыни?» — дип үпкәли иде.

Кыштырдаган җан иясе тавык-мазардыр, мөгаен. Кайчакта, җилле төннәрдә, алабута дәрьясы аның ишегалдына табан шуыша кебек. Ут та йөгерек иде бит, җил ныграк иссә, аны Нурсөяләр йортына табан куачак иде. Аллаһ кодрәте белән генә Хәлидәләргә кушылып янмады хатын. Йорты исән, ә менә ул үзе... Йә, аның кисәүдән кай җире артык, Раббым?! Нурсөянең хәлләре бишбылтыр ук авыл уртасында басып кычкырырлык иде бит. Адәм баласының рухи дөньясы шыксызланган саен, тышкы кабыгы ялтырый икән. Күр син өйдәге шкафны! Кием белән шыплаған лабаса. Иренмә генә, көненә биш күлмәк алмаштыр. Кулына акча тиде исә, ул бистә кибетләрен айкады. Кибетчеләр аны үзе артында «чүпрәк колы» дигәннәр, имеш. Әй, андый төртмәле сүзләргә авыз турсайтмады хатын. Урамнан матур итәкләреңне җилфердәтеп баруларның ләззәтен татысалар иде бер! Кем өчен киенгәнеңне аңласалар иде...

Өйалды утын кабызырга кирәк. Төнлә дә көндезге кебек якты шәһәрдә үскән кыз бала ничек караңгыдан чирканмый икән? Бәрәч, кунак бигрәк әз чыгымлы! Кайнаган суда гына ботка сыман әйбер болгата, балсыз үлән чәе генә эчә. Кала бикәчләре төшкә кадәр йокы бүскәндә, бу таң белән аяк өстендә. Башта хатын аны кояш сукмасын дип башына яулык бөркәнә дип уйлый иде, ә кыз йоклаганда да яулыгыннан аерылмагач, бик сәерсенде. Кунакның сәерлеге тау өстендә учак ягу, яулык ябыну белән генә чикләнсә икән! Көн саен кичкырын аның кулында уенчыкка охшаган тартмачык була, ул шуны ачып нәрсәдер саный һәм, кемнәндер яшергәндәй, шырпы хәтле генә нечкә ачкыч белән четердәтеп бикли иде. Кеше әйбере, үтереп кытыкланса да, Нурсөя тартмачыкка кагылмады.

Кыз да кайтып ятты. Аның аягы идәнгә тими, ул күбәләктәй очып кына караватка куна бугай. Кунак — Аллаһтан, ди. «Китми» дип авырсынмаска иде дә... Кызны ник гаепләргә инде, йә? Аны авылда кемдер Нурсөяләргә кодалаган бит инде. «Ул хат ташучы, күп күрә, күп ишетә» дигәннәрдер. Әйе, Сөнчәледә аңа һәр гаилә әгъзасы үз туганнары шикелле. Этенә, мәчесенә, тавыгына хәтле таныш, ә бистәдә, аның карамагындагы ике озын урамда, капкага беркетелгән тимер тартмалар телсез. Аларның «ачык авызы»на айга бер мәртәбә соры реклама кәгазьләре каптырганда, Нурсөя биек-биек коймалар артында этләрнең генә ярсып өргәнен ишетә. Хуҗалар белән гәпләшү яки аралашу тәтеми аңа. Алар яшь байлар, аларга пенсиягә иртә. Хәреф танымагач, гәзит-журналлар яздыртмыйлар. Элгәре ул хат ташучыга урын түрдән иде, чөнки авылның бер очындагы хәбәрне икенче очына сумка кырыена гына кыстырып киләсең дә, тәмле-тәмле ризыклар белән сыйлана-сыйлана чәй эчкәндә, хуҗабикәнең бияләй хәтле теленә бушатасың. Шуннан хәбәр, чүпрә сыман күпереп, урамга таша. Әйе, хат ташучы кадерле кеше иде заманында.

Алгы бүлмәдә нәрсәдер дөбердәде. Тәрәзәгә таш бәрделәр мәллә, Ходаем?

Хатын юрганын кырыйга селтәп торды да ишек ярыгыннан бакты. Кунак кызы шәм яктысында тартмачыгына ачкыч яратып маташа иде. Йозагын бозган, ахрысы. Нурсөя йортында сернең дә гомере кыска шул...

## 2

...Иртән кунак ишегалдында таптана иде.

— Таң йолдызы икән син, кем...

— Алия, — диде кыз, яулыгын рәтләп. — Исемемне гел онытасың, апа. Алия мин. Бүген ялым, диден. Мине зиратка алып кер әле.

Нурсөянең кинәт кенә башы әйләнде. Мәетләрдән дә риваять эзлиләр микәнни?!

— Анда ни эшең калган, бала?

— Аларның каберен күрсәтерсең, апа.

— Кемнәрнең ул, Ходаем?

Алия алабуталы нигезгә иягеп чөйде:

— Боларның... Миңа кызык.

— Әстәгъфирулла, кызык өчен генә зираттагы мәетләрне борчыйлар димени?! Гөнаһ бу!

— Бүтән гөнаһларың булмасын, апа.

Кыз без карашы белән хатынны үтәли тишә иде. Әйтерсең аңа ничә еллар капчыкка яшергән һәм бер генә җан иясе дә (Гыймраннан гайре) белми дип уйлаган катлам-катлам гөнаһларның барысы да мәгълүм иде.

— Хәзер алайса, — диде хатын, күндәм генә.

Башка чара юк. Кунак нindидер буйсындыру көченә ия иде. Аның менә шунысы куркыта да инде.

Мәңгелек йорт Гыймраннар очында. Ул капка төбендәге «тере капчык»ны ерактан ук күрде. Матуррак күлмәген дә кимәде, ичмасам. Күнел дигәнең, күпме генә оялтма, һаман очына. Җир шарында бөтен ир затлары кырылды, бердәнбер Гыймран гына исән дисәләр дә, йөзенә төкерерлек шушы чирканчык адәм ничә хатынны тилертте-шаштырды. «Син — кабахәт», — дия-дия яратты аны хатын-кыз. Тик берәү генә аңардан җирәнде, берәү генә...

Гыймран аларның һәр адымын күзе белән үлчәп тора иде.

— Нихәл? — Нурсөя йөрешен акрынайтты. — Терелдеңме?

— Ә кем авырган монда?! — Бакча карачкысы, муенын суза-суза, бөкшәйгән гәүдәсен озынайтты. — Мин таза-сау!

Рас, ир сырхау кеше янәшәсендә биш таҗлы гөл иде. Аңардан хатын-кызны ымсындырган көч-дәрт ургый. Аякланса, тагын себерелер микән? Әнә бистәдә ялгыз хатыннар базары шаулый... Әрсезләр юаш Нурсөянең өлешен умырып тешләрләр инде... Югыйсә иң көчле көндәштән арынганына да байтак ел.

Күзен тасрайткан, Алияне танырга тырыша, явыз! Сүзгә-сүз бәйләмәскә кирәк. Хатын, тизрәк дигәндәй, кызның кулыннан тартты. Ләкин Алия үзе дә «капчык»ка караган, аның йөзе ап-ак, иреннәре кысылган иде. Мөгаен, ирнең ямьсез чыраеннан биһуштыр.

— Әйдә, бала. Гыймран абзаңда риваятьләр юк, — дип пышылдады Нурсөя. — Теле дә агулы, әйдә, дим!

Кыз анысы агуга каршы даруын тиз табар, аның бүтән ягы куркыныч. Кичә ике башкисәр исерек иде. Алай-болай аталары өендә кунмагайлары. Капка төбендәге Алияне тәрәзәдән генә суырып алачаклар, валлаһи.

Сүзсез генә зират сукмагына табан юнәлделәр.

— Син бу абзыйдан җирәндең, ахрысы, — диде Нурсөя. Кызның таш кебек йөзе язылмаган иде. — Биткә адәм ыстырамы инде. Камыр кебек әвәләгәч тавык таптаганмыни, җәлпәк-җәлпәк эз. Тумыштан шундый Гыймран. Ходай тышы гарипнең эчен бизәп күркәмли, ә моның ни эче, ни тышы... Шул карачкыны хатыннар сөя бит әле.

Хатын көлгән итенде. Баксаң, ул үз-үзеннән көлә икән. Гыймранны кемнәр сөйгәнен әйтсәң, кунак кыз ышанмас иде.

Кешеләр якынлашканын өнәмичә, дәррәү каркылдашып, зират өстендә каргалар күтәрелде. Картайган тупыл агачларының кояштан сипкелләнгән чуар яфраклары шып та шып бәргәләгән канат җиленнән ризасыз гына шыбырдаша иде.

— Алар койма читендә, — диде Нурсөя. — Икесенә уртак кабер.

— Алгарак барыйк, апа.

— Ни алга бар, ни ерактан кара инде. Җир белән тигезләнмәсен дип, яз саен туфракларын өскәрәк өештерәм инде. Кабер икәнлеге анык инде анысы. Шомырты да тамга-билге бит. Йә, мәрхүмәләрнең рухына дога кылыйк, бала.

Койма тирәсен зәһәр кычыткан сарган иде. Алия, аягы белән үләннәрне аудара-ега юл салып, каберлеккә якын ук килде. Үрелеп, тармакланып үскән шомырт куагыннан кызгылт җимешен өзде.

— Зираттагы нәрсәләргә тимиләр, бала! — диде Нурсөя, өне алынып.

— Монысы да гөнаһмы, апа?

— Хәрам диләр борынгылар.

— Ник бу түмгәккә нәкъ менә шомырт утырттыгыз?

Хатынның ачуы кабарды.

— Түмгәк түгел, кабер ул! Син, кызый, нигәдер үртәп сөйләшәсең әле.

Кыз, тапталган кычыткannарны аяк очы белән торгыза-торгыза артка чигенгәндә:

— Рәхмәт, күрдем, — диде.

Гыймран һаман урыныннан кузгалмаган иде.

— Әй син, бераз тоткарлан! — диде ир, Нурсөягә эндәшеп.

— Бар, мин кайтмыйча, өйдән борын тыкма! — Хатын кызга боерды. Боермый ни! Азынуы чиктән ашты. Каберлектән шомырт өзә, и Аллам!

Кояш җылытса да, буяулы агач эскәмия салкын иде. Нурсөя үз-үзен кочаклады. Әллә зират суыгы үзгә микән?

— Сиңа ияргән яулыклы чәчби кем ул? — диде Гыймран, ераклашкан Алиягә табан каерылып.

— Кызым. — Нурсөя шаяртты.

— Кысыр сыер бозаулаган ди, ие!

— И Аллам, дорфа да инде син, Гыймран. Студент, Казаннан. Риваятьләр сөйләттерә.

— Зираттагы әрвахларданмы, ахмак!

Хатын эскәмиянең кырыена ук күченде. Ирнең җикеренүе йөрәгенә ярамый иде. Яңадан түл җыя бу явыз. Ә Нурсөя аңардан наз көтә, җылы көтә. Үзгәрмәсә дә үзгәрмәс икән бәндә!

— Хәлидәләрнең каберен карады...

— Ә? — Гыймранның болай да кызыл күзләренә кан сауган иде. — Кемнәрнең-кемнәрнең дисең?

— Хәлидәләрнең, дим. Чит-ят кызыксынмас иде, шул нигезне тигезләттереп, үлән чәчтер, дип күпме ялындым сиңа. Йортыңда тракторың бар. Эшләтергә ялчыларың бар.

Ир юан таягы белән дык-дык җиргә сукты.

— Үзең казып тигезләргә иде, ахмак!

— Моның йөрәге ярылып үлсен дисең мәллә, Гыймран?! Сез бит кабергә ярты чиләк көл генә илтеп күмдегез. Малайларың белән! Мәрхүмәләрнең янган сөяге астарак булгандыр, кисәүләр астындарак. Ха, мин көрәк белән шуларны актарырга тиеш икән!

Юаш Нурсөянең кызып-кызып әрепләшүе Гыймранны шаккатырды. Ул, синме соң бу, ә, дигәндәй, хатынга акайды.

— Әйе, тапканнар бер җүләрне! Әйтмәгән саен теге.

— Ай-яй! Теле чарланган бикәнең! — Ир таягы белән һавага кизәнде. Миңа суга дип куырылган иде Нурсөя, әмма таяк дөп-дөп кече капканы кыйнады. — Уяндыгызмы, үгезләр?!

«Үгезләр» Гыймранның башкисәрләре иде.

— Ник аларны таң зәрәсе уятасың? — диде Нурсөя, баягыдан да ныграк куырылып. — Малайларыңа телемне кисәргә кушасың мәллә?

— Синең черек телеңне эт тә ашамый, ахмак! Кунак кызына теге төнге маҗараларны риваять итеп бытбылдасаң, чын ир анты — телеңне муеның белән бергә мин чабам!

— Әй дорфа да инде син, Гыймран. Кычытмаган җиреңне кашыма, зинһар! Үзем белән кабергә иңәр ул.

— Кара!

— Син дә күзеңне йомма, Гыймран. Малайларың бистәдә кемнәрне генә рәнҗетми. Яшь кызларны әчертеп-исертеп мыскыллыйлар. Әйтмәгән саен теге... Җүнле ата икесен дә каеш белән ярыр иде. Өйләндерсәң дә вакыт инде.

Ул тыелган чикне узган. Малайларына тел-теш тидергән кеше — Гыймранның дошманы. Ә аңа дошман саналу пычагыма кирәкме?! Шундый яшерен өмет белән янганда, йә? Ләкин башкисәрләрнең кансызлыгына чыдарлык түгел! Кичә соң, кичә, үзенә дә сыра шешәсе тондырдылар.

Гыймран ике куллап таягына таянды:

— Минекеләргә ни кылансалар да килешә. «Түбә» бит алар. Өй түбәсе белән бутама, ахмак! «Крыша», диләр андыйларны. Күрәсеңдер, тирә-юнь нефтә баганалары белән чуарланды. Кырыкмаса кырык атадан туган уйнаш оешмалар астан май чөмерә. Минем бөркетләр — шуларның иң кәттәләренең «түбә»се. Берәр бәхәс купса, милиция нәрсә кыйратсын сиңа! Әнә Самара бандитлары, бистәнең нефтәсеннән безгә дә дәү генә кисәк бүлегез, дигәч, минекеләр давай Казаннан үз өерен китертеп боларны утлы табада кыздырырга! Борчак төсле куырганнар! Ха-ха-ха!

Нурсөя сүз көрәштермәде. Ир барыбер өстә калачак иде. Ул — калкавыч, ул батмый. Әйдә башкисәрләр үзара дөмбәсләшсен. Алар мал өчен кан коя. Ә яшь кызларны ник мәсхәрәләргә? Юлны аркылы чыккан карт-корыны, бала-чаганы ник машина белән бәрдертергә?

— Әле үзем дә малайларга булышыр идем. Мылтыктан төз атам, — дип хихылдады Гыймран һәм таягы белән урыныннан калкынган хатынның итәген тибрәтте. — Син әллә мине бетәште дисеңме? Чир китә миннән әкрен генә. Элеккеге гайрәтле чаклар кайта тиздән. Менә-менә аяклар ныгыды, җир катысын тоя. Шулай, Нурсөякәй.

Хатынның тәне чемердәде. Татлы чемердәү иде бу. Гомер көзендә булса да Ходай аны бәхетенә табан турыласын. Бая гына усаллык исәпләп кәпрәйгән әтәчнең, Нурсөякәй, дип, йомшак кына әйтеп куюын күр син.

— Әлләү, яшәрдең, ахры, — диде ул, итәген сыпырып. Аның күңеле качышлы уйнарга әзерләнде. Әмма Гыймранның тавык тәпие чуарлаган йөзендә соры болытлар укмашкан иде.

— Прәс, юлыңда бул, ахмак! Синең белән озаграк тәтелдәшсәм, хәлсезләнәм мин. Көчне суырасың син. Җир җимертеп йөргәндә кинәт егылуым да синең аркада. Сез  хатын-кызлар, дәҗҗал токымы, боздырып, кабергә тыгасыз.

Хәзер генә рәхәт чемердәгән тән бозланды. Нахак сүз ишетүе авыр иде.

— Бәрәч, чирен дә миннән күрә икән! — Нурсөянең күкрәгендә берьюлы мең шырпы сыздылар. — Син бит кеше яндыргач бетәштең, ерткыч!!! Син бит үлгәч тә бәддога иясе!!! Әнә теге студент кызга ничу риваять дияргә, аңа синең кебек бүреләрнең явызлыгы турында язып, ил-көнгә фаш итәргә кирәк!

Ир чытырдатып хатынның ябык беләгеннән кысты:

— Тагын бер кат әйтәм: кара!

— Әйтмәгәең ни! — Нурсөя, аның кулыннан ычкынып, җил-җил үз очларына атлады. Күңелдә өермә иде. Ник яраттырасың бу бәндәне, и Ходай?! Ал йөрәктәге сөюне дә сал шушы урынга җирәнү хисе!..

Ә кунак аңа яңа тетрәнү әзерләгән, ул янган нигездә алабута дәрьясын гизә иде. Нурсөя дырк-дырк рәшәткә селкетте, чөнки аның каушаудан теле аңкавына ябышкан. Йа Алла, кабер таптый! Аста — адәм сөякләре!

Күзләре шарланган хатынның ым-ишарәсен аңламаган Алия дәрьяда йөзде дә йөзде.

— Чык! — диде хатын, ниһаять, телен кыймылдатып. — Чык, дим!

Кыз, алабута очларын кага-кага, ашыкмыйча гына рәшәткә кырыена килде.

— Чирләдең мәллә, апа? Йөзең агарган.

— Чирләмәдем. Өйдә генә утыр, дигән идем, колагыңа да элмисең икән, бала. Башкисәрләр авылда чакта качып торуың хәерлерәк, алар ач ерткычтан да хәтәррәк. Әйдә!

— Шул гынамы, апа?

— Юк! — Каты бәрелмәсә дә, ачу төерле-ташлы иде. — Анда бүтән кермә! Тыйнак кунак кына хуҗага бәхет ул.

Гыймран игезәкләре бөтен куәтенә музыка акыртып узганда, алар икесе дә өйдә иде.

— Сиңа шәһәреңә таярга иде, бала, — диде Нурсөя. — Безнең авылда куркыныч. Ул риваятьләреңне тизрәк тупла инде.

— Сөйлә, туплыйм. — Алия мәче кебек урта ишекне тырнады. Нишләп бу кәефсез әле? Мөгаен, хуҗабикәнең әмер-боерыкларын өнәмидер.

— Миндә гел күңелсез хәлләр генә, бала. Иртәгә бистәдә почта таратам, шунда әби-чәбидән сорашырсың.

Күңелсез хәлләр, имеш. Фаҗига дисә, үз-үзен сатар иде микән? Ә бит чыны-хагы шул: көтелмәгәндә барысы да ут белән очланды. Ут, ут, ут... Йорт та янды, кешеләр дә янды... Шуңа күрә бүгенге көнгә кадәр җанда корым...

## 3

...Туганда Кодрәт иясе аны ап-ак фәрештә итеп яраткан. Әйе, ул керсез-тапсыз кыз бала иде. Күршедә дә аның кебек үк ак төскә манчып туган тиңдәш үсте. Алар иң якын сердәшләр иде. Нурсөя бүген генә, дөнья гаменә уралгач кына, бер хакыйкатькә төшенде: икесенең арасын ни байлык, ни акча бозмады, ә менә уртак ир дуслыкның канатларын сындырды. Дөрес, кызларның һәрберсе үзенчә яратты: Нурсөя — эчтән сызып, бөтен наз-нурын бердәнбер кешесенә бөркергә әзер булып, ә Хәлидә — кыска мәхәббәтенә нәфрәтен кушып, җирәнеп-чирканып. Андый ярату да бар икән шул. Соңра яшьлегендәге юләрлегенә үкенгән Хәлидәнең Гыймранга коры нәфрәте генә калса да, эш эшләнгән: ике сердәшнең дә түшәк җылысын татыган ир уртакка әйләнгән иде. Хәлидә бизде дип кенә Гыймран аңардан араланырга теләмәде. Аның шунысы айга сикертә иде шул: ир отыры Хәлидәне эзәрлекләде. Ә бала тугач... И Ходаем, боларны хәтереннән казып ник уела да киселә икән Нурсөя?! Шомыртлар быел да каралыр, быел да мәрхүмә бәләкәй кызы белән тау өстенә чыгар... Юк, бистәгә күченергә кирәк. Тәрбиягә мохтаҗ ялгыз карчыклар сыендырыр әле. Ә бит Хәлидә чибәр иде... Йә, анысы нәрсәгә инде тагы? Әйе, нәрсәгә? Ләкин ул күз алдында тере килеш чайкала. Бу — хәтернең бер кисәге. Чибәр, чибәр иде сердәше. Дулкын-дулкын озын чәчләре шарлавык сыман иңнәренә агар иде. Гыймранның исә шушы чәчләргә ураласы килде. Хатыны үлгәч уралды... Нибарысы бер мәртәбә! Ир хатын-кыз затын ярата белмәде, ул каты бәгырьле аучы иде, ул аулады гына. Ә тоттырмаган киек-җанвар аучының канын кыздыра. Хәлидә тибәргән саен, Гыймран шашынды гына. Сукыр! Алмагачта иң сусыл, иң баллы алма Нурсөя иде югыйсә. Ә Хәлидә коры иде бит ул! Аннан сәер. Кечкенәдән телсез әбисенә тагылып урманга йөрде. Алар чиләк-чиләк шомырт җыеп яртысын базарда сата, яртысын, киптереп-төеп, иләктән иләп, кышкылыкка саклый иде. Бер елда Сөнчәледә яше-карты эч китүдән җәфаланды. Телсез карчык дәвалады: ул хасталарга киптергән шомырт онының төнәтмәсен эчертте.

Күршедән күрмәк, сатып табыш алмак дигәндәй, Нурсөя дә аргы очтагы әбисен шомырт белән кәсеп иттермәкче иде дә, сәүдәләре уңмады: аларның шомырты вак, ә Хәлидәләрнеке карга күзе хәтле эре, шуңа күрә халык күршеләрнең тауарына ябырылды. Үсмер Нурсөя күз яшьләре белән елагач, сердәше: «Ярар, әби сезне дә ияртер, без бик еракка китеп җыябыз», — диде, ләкин телсез карчык оныгының кул хәрәкәтләренә каршы нәзек иреннәрен генә чапылдатты. Карт чәүкә болай да Нурсөяне өнәми иде.

— Һәй, саран кортка!.. Җен ич ул, — диде кызның әбисе. — Җүнле карчык төннәр буе урман сукмагы таптамый. Шомыртларын да сихерләп кенә эреләтә. Улы белән киленен дә җеннәре ярдәмендә аертты. Килене Үзбәкстанда, улы Себердә үлде әнә.

Бу карчыкларга дошманлашырга бернинди сәбәп тә юк иде. Хәер, телле белән телсез ничек дуслашсын ди. Хатын-кыз бергәләшеп гайбәт чүбеге чәйнәсә генә аралаша. Ә менә Нурсөя белән Хәлидә агылый белән тагылый иде. Хәлидә, медицина училищесын тәмамлап, Сөнчәлегә кайтты, ә Нурсөя укымады, бистәдәге почта бүлекчәсенә урнашты. Тәкъдир аларның икесен дә дөм ятим ясады. Шуннан соң кызлар ике йортны бер итеп яши башлады. Нибарысы сирәк тешле рәшәткә-койма гына араларын урталай бүлә иде. Ни Нурсөя, ни Хәлидә егетләр дип егылмады. Сакал-мыек алардан шүрли иде бугай. Парлы кыз-кыркын куркыныч шул. Аның берсе — шөпшә, икенчесе — бал корты, чаксалар, үрле-кырлы сикертәләр. Кызларны тимер бөгеп турайтырлык көчле егетләр генә буйсындыра ала иде. Һәм андый «батыр» табылды...

...Бик эссе көн иде. Агач-куакларның яфраклары куырылып шәлперәйгән, җир буй-буй ярылган иде. Кызлар Кара Тобага су коенырга төште. Колачлап йөзә-йөзә эчкә үк кергән Нурсөя бөтерчеккә эләкте. Тоба, корбанын өзгәләгән ерткыч кебек, аның арык гәүдәсен зыр-зыр әйләндерде-тулгандырды да төпкә сөйрәде. Хәлидә сердәшенә ярдәмгә ташланды. Әмма бөтерчек, тагын да кызурак әйләндереп, икесен дә аска батырды. Бергә тотынышып үскән кызлар бергә тотынышып үләргә тиеш иде. Шөкер, үлмәделәр. Икесен дә су төбеннән тартып алдылар. Яр буена чыгарып салгач, Хәлидә коткаручысын күреп аңын җуйды, ә Нурсөя дер-дер калтырады гына. Йа Аллам! Каршыларында, тешләрен җемелдәтеп, аждаһа ыржая иде. Гыймран! Сөнчәледә генә түгел, күрше авылларда да аткан-аскан, кискән-тураган җәллад Гыймран! Аны юлымда очраттырма, дип, кем генә Аллаһка ялвармаган икән.

— Танымыйсың мәллә, алтын балык? — диде егет, черт-черт комга төкереп. — Төрмә шулпасы белән тукланган авылдашыгыз мин.

— Ие шул, сине ун елга япканнар иде. Габбас абзыйга аткан өчен дә, бүтәннәр өчен дә... — Нурсөя сердәшенең битеннән сыйпады. Хәлидәнең озын керфекләре дулкынлана иде.

— Ун елны өч елда бөкләдек без, алтын балык. Андагы абзыйлар белән блат зур безнең. Ә сез, ике сөяк-санак, нишләп елгада чупырдашасыз? Кыр үрдәкләрен саташтырып, ә? Сез җәфалар аркасында аталмадым, камышлыкка шылды, каһәрләр.

Егет, аяк астындагы мылтыгын күтәреп, һавага гөрселдәтте. Шартлаган тавыштан яр буе селкенде. Хәлидә яңадан аңын җуйды. Елга читенә шапылдап карга үләксәсе мәтәлде.

— Ник бу кызый минут саен йокыга тала, ә? — Бу юлысы егет мылтыгын Хәлидәгә төзәде.

Нурсөя чәрелдәп сердәшенең өстенә ауды:

— Атма-а!

Гыймран дөнья яңгыратып шаркылдады:

— Вәт тиле! Мондый чибәркәйне атарга без җүләр мәллә! Дустыңа әйт: ул — минеке. Кич белән очрашырбыз.

Минеке дип тамгаланган хатын-кызга егет урман бете кебек кадалды. Бу аяныч хәлләргә көенергә тиеш иде кыз, ә ул керфеген ачар-ачмас тибрәтеп яткан сердәшеннән көнләште. Ничек җиңел генә Гыймранның мәхәббәтен яулады соң әле Хәлидә?

— Олактымы, аждаһа? — Сердәше комга буялган чәчләрен ашыга-ашыга җилкә чокырына төйнәде.

— Шул аждаһа коткарды бит, су төбендә балыкларга ризык буласы идек, — диде Нурсөя, эче тырналып. Гаҗәп, көнләшү узмый иде. «Төрмә чыпчыгы» ни яр, ни пар түгел югыйсә.

— Нишләп ул кәкәйне төрмә сәкесеннән бик тиз шудырганнар?

— Без батканда елгадан сөйрәп чыгарсын дип!

Нурсөя сердәшенә гаҗәпләнде. Акыллы кеше Гыймранның аягын үбә-үбә рәхмәт укыр иде, ә бу борып-борып чеметә.

— Егет төрмә белән гөнаһларын юган, бүтән явызлык эшләмим дип тәүбәләгән. Адәм баласы үзгәрә инде.

— Үзгәрми! Явызлык аның канында бар!

— Әй, төртелмәсәнә, Хәлидә! Гыймран сиңа гашыйк, ахрысы. Кичкә сез күрешәсез...

— Нәрсә-ә?! — Хәлидә кинәт кенә пыр тузды. Аягын селкеде, кулын селкеде, әйтерсең аңа тигәнәк ябышкан иде. — Әллә син мине шул аждаһага ярәштеңме?

— Абау, ник мин сезгә тыкшыныйм ди?! Сине сайлаган икән, сөен: Гыймран кебек баһадирлар юлда аунамый. Өйләнер менә.

Хәлидә кулына ком йомарлады да ачу белән җиргә бәрде һәм:

— Сиңа өйләнсен, яме! — дип, авылга йөгерде.

Әнә шулай, уйламаганда-көтмәгәндә, ике сердәш боз белән тоз кебек булды. Кызлар һәркайсы ялгыз гына кич каршылады. Нурсөянең ян тәрәзәсе Хәлидәләргә карый иде. Гөлләргә су сибәргә иелгән кызның күз очына Хәлидә эләкте. Ул, әбисенең иске тырысын беләгенә асып, арт яктан гына чыгып бара иде. Нәрсә бу?! Карчык үлгәннән бирле сердәшенең урманга аяк басканы юк иде. Хәзер нәкъ шомырт каралган чак... Әстәгым, элеккеге гадәтләрен кумакчы мәллә Хәлидә?!

Нурсөя аңа үпкәләде. Әйдә дип сердәшен дә чакырса икән. Гыймран өчен күперенә инде. Хәлидәнең шәүләсе дә күмелмәде, Гыймран сызгырды. Кыз тиз генә яңа халатын киде дә, изү

сәдәфләрен юри каптырмыйча, урамга атылды. Егет очрашуга әзерләнгән: чәчләрен тараган, аңкытып хушбуй сөртенгән иде. Нурсөянең йөрәге алгысынды. Их, шушы агай-эне белән култыклашып урамнар әйләнсәң икән!

— Күршекәем өйдә юк шул, Гыймран.

— Син аны кисәтмәдеңмени, тукмак борын? — Егет, киң маңгае белән сөзеп, кызга якынлашты. — Кайда Озын чәч?!

Кыз, пыяла сыман зеңгелдәгән тавыш белән:

— Урманда-а, — диде.

Гыймран бүре кебек ырылдап тауга чапты. «Ник телемне тешләмәдем икән? Хәлидәне муеныннан наратка асачак бит!» Төне буе мендәр чылаткан Нурсөя иртән кое янында шомырт юган сердәшен күрде һәм сөенеченнән өч мәртәбә: «Аллага шөкер», — дип кабатлады. Ә көнләшү кимемәгән иде. Гыймран белән вәгъдәләштеләр микән?

Хәлидә, кояштай балкып, аның учына шомырт салды:

— Бик тәмле, аша...

Кое суында тагын да мөлдерәгән җимешләр салкын һәм... эре иде. Әллә әбисе сыман оныгы да әфсенләп зурайта. Гелән-гелән аралашсалар да, күршесенең ярты дөньясы — карурман, җиде сукмакта җиде йозак...

— Сине Гыймран эзләгән иде...

— Мине урманда диден инде, әйеме?

Нурсөя чүт кенә шомырт төшенә йотыкмады.

— И аның ыспайланып, чибәрләнеп килүләре! — диде ул, гаебен аклагандай. — Шакмаклы күлмәктән, кара ботинкадан. Егет кәттәсе, кыскасы.

— Ерткыч сарык тиресе ябынса да ерткыч инде.

Хәлидә бик тәкәббер иде.

— Алай да... куып тоттымы соң?

Нурсөя төпченүен дәвам итте:

— Тоттырдылар ди! Минем койрык кыска, җаным.

— Әйе шул, кыска. Ничә мәртәбә артыгыздан бардым, ә сез әбиең белән җир ярыгына чума идегез! Шомыртларыңны нишләтәсең?

— Бистәдә шәхси хуҗалыклар өчен базар төзегәннәр ич. Бер өлешен сатам, бер өлешен киптереп төям.

Хәйлә иде бу, Хәлидә аны үзеннән читләштерә иде.

Иртәгәсен кичкырын Гыймран тагын килде. Хәлидә әүвәлгечә урманда. Өченче көндә егет дуладыкотырды һәм: «Атам», — дип калкулыкка китте. Кире төшкәндә аның өстеннән пар бөркелә иде. Ул Нурсөяләр турындагы эскәмиягә ауды.

— Шушында сагалыйм! Барыбер ботыннан эләктерәм, — диде.

Кыз аңа тустаган белән су биргән иде, Гыймран савытны җилкә аша чөйде:

— Син дә эчемне пошырма!

Нурсөя егетнең алдына тезләнде.

— Гыймран... Мин чибәр түгелмени? Мине ярат син.... Хәлидә буш ич ул, агач ич ул.

— Ә? — Җир тырмап үкергән ерткыч бермәлне сулышсыз калды. Ә күзләре, тауарның бәясен билгеләгәндәй, аска-өскә тәгәрәде. — Да-а, син ничава! Иреннәр дисеңме, күкрәкләрме. Йә, бөтен буең белән бас! Әһә, аякларың да матур. Кочакларлык җирләрең бар. Тик син ирләр төсле кыркымыш. Миңа толымнарын сүтеп уралырдай озын чәчле кызлар тансык.

— Үстерермен, Гыймран.

— Маташма, синең чәчең үскәндә, безнең сакал агарыр. Ә миңа бүген үк өйләнергә кирәк.

Ярты төнгә хәтле сүгенә-сүгенә көтте егет, ә Хәлидә таң беленгәндә генә кайтты. Тырысы тум-тулы шомырт иде.

— Адаштың мәллә? — диде күз кабаклары шешенгән Нурсөя. — Турыңда Гыймран ухылдаганда йокы юлдашмыни.

— Балачактан ук таныш урманда адашсаң тагы.

— Төнлә кем шомырт чөмли инде?! Әллә нинди син, Хәлидә.

— Ә кем төнлә чөмли әле?! Кичтән үк тутырам мин савытны.

— Аннары нишлисең? Гыймраннан качасыңдыр инде...

— Ул башкисәр йөрер-йөрер дә, суыныр әле.

— Хәлидә, сердәшкәем. — Нурсөя дустын кочаклады. — Чынлап та Гыймраннан араланыйм дисеңме? Чәчеңне кистер! Төптән үк. Ул, озын толымлы кызга гына өйләнәм, ди.

— Ант мәгәр?

— Ант, ант!

Хәлидә дулкын-дулкын чәчләрен бармаклары белән тарады. Их, бер кодрәт белән шуларны Нурсөянең башына беркетсәң иде! Уралсын иде Гыймран, мәңгегә уралсын иде.

— Мә, туракла! — Хәлидә халат кесәсеннән кайчы алды. — Үләннәр кыркырга яраган чәчкә дә ярар.

И туракламыймыни соң инде Нурсөя! Ул, сердәшенең гүзәллеген тамчы да җәлләмичә, кайчысын эшкә җикте. Черт-черт, черт-черт... Тотам-тотам чәч яфрак төсле җиргә төшәлде...

...Кич белән капка төбендә ләчтит сатып утырганда, тыкрык башында кияү егет күренде.

— Килә-ә, — диде Нурсөя, аякларын тыпырдатып. — Мин өйрәткәннәрне онытмадыңмы? Әйдә тор, каршысына атла. Җебемә, яме? Өргән эткә каршы син дә өр.

— Тибеп очырмас микән, Ходаем?

Хәлидә, башындагы яулыгын төшереп, иңнәренә япты.

— Нихәлләр, егет асылы? — Кыз юл уртасына чыкты. — Танымыйсыңмы? Хәлидә мин. Чүп-чар яндырганда аягым таеп учакка егылдым да толымнарымны өттем менә...

— Атаңның кара сакалы-ы! — Гыймранның бәбәкләре шарланып оясына сыймады. — Ничә көн шушы килбәтсез артыннан чаптыммы мин?! Тфү, кыркылган сарык!

Хәлидә тораташ иде. Нурсөя аны этеп-төртеп кенә кузгатты.

— Йә, ник каттың син? Җиле тиде мәллә?

Гыймран тыкрыктан югалган иде инде.

Күзенә яшь бәргән «кыркылган сарык», иреннәрен уймакландырып:

— Яратмаган икән, яратса, кыска чәчемне хурламас иде, — диде.

Әй, кеше күңеле карурман шул. Эчтән генә, яшерен генә Хәлидә дә егеткә өметләнгән, әмма качкан кыланып, эзләттереп, үз бәясен күтәргән. Хатын-кыз җебе — чуалган йомгак бит ул. Энәсе кадый дип тирги тора, кочагына чума тора. Гыймран аптырамады, озын чәчле Фәһимәгә өйләнде. Шуннан соң Хәлидә отыры сәерләнде. Әйтерсең ул телсез әбисенең күчермәсе иде, иртә-кич урманда буталды. Уртак табактан ашаган ике сердәш әкрен генә бер-берсеннән ерагаеп читләште. Дөрес, алар сөйләшә дә, көлешә дә, ләкин ике арадагы элеккеге ихласлык сүрелгән. Беркөнне Хәлидә мунчада кычыткан төнәтмәсе белән чәчен чайкады.

— Яңадан үстерәм! Синең тозсыз киңәшләреңне тыңлап кияүләрдән колак кагасым юк, — диде.

Чәч озынайды, тик нишләптер кияү балакайлар чиратка тезелмәде. «Гыймран әле Хәлидәсе, әле Нурсөясе белән кети-мети уйный» дигән гайбәт, мөгаен, аларның кул-аягын богаулаган иде. Ә утсыз төтен булмый! Төнлә Нурсөя ишеген бикләмәде шул... Хәлидә нишләде икән? Гыймран аудан кайтканда аны да кочагында җылытты микән? Шуны beләсе килеп өтәләнгән Нурсөя төнлә озак-озак ян тәрәзәдән багар иде. Күрше йортта исә тынлык... Тычкан уты да җемелдәми. Чәч үстерә, имеш. Гыймран, ач күз, өйләнеп кенә кызган ташын бастырса икән. Аңа Фәһимә дә, Нурсөя дә кирәкми, ул Хәлидә дип шашына иде. Ә сердәш үзе һаман да аңардан җирәнә бугай. Яраткан кешең турында тешең сызлагандай сөйләшмиләр лә. Бит Хәлидә, Гыймран дисәң, нәфрәтенә буыла иде.

— Корсаклы хатынны тибә-тибә кыйнаган, ерткыч!

— Мылтык түтәсе белән Сафа абзыйның маңгаен тишкән, ерткыч!

— Урамда машинасы белән бәрдереп, сыер имгәткән, ерткыч.

Хәлидәнең телендә «ерткыч» кушаматы йөзгә төрләнер иде.

Берсендә Нурсөя: «Ул «ерткыч» дигәнең иркәләгәндә аю кебек йомшара», — дип әздән генә ычкындырмады. Читен иде, ай читен! Энә очы хәтле серен дә яшермәгән сердәше белән йөрәк хәлләрен уртаклашасы килә иде.

Хәлидә, сизгән сыман:

— Бүтәннәр белән чуала, ди әле тагы, ерткыч, — диде.

«Бүтәннәр» төркемендә, мөгаен, бер Нурсөя генә түгел иде. Гыймран бистәдә дә шаяра икән. Хат ташучының колагына хәбәрләрне җил китереп кенә сылый. Фәлән хатын «минеке» дип мактанган, фәлән хатын «мин — аныкы» дип чытыкланган. Ирнең кочагында май сыман эрегән Нурсөя генә авызына су капты. Чөнки Гыймран: «Әгәр дә мәгәр, йомран төсле, Хәлидәгә сүз ташысаң, үтерәм», — диде.

Фәһимәнең игезәк малайлары туды. Алар бишектә генә фәрештә иде. Аталары камышлыкта гөрес-гөрес үрдәк-каз атса, бот хәтле игезәкләр эт-мәче җәзалап кул шомартты. Бичара хайваннарның үләксәсеннән урамдагы коелар сасыды. Гыймран аларның һәр явызлыгын хуплап, акча белән авызлыкландырды. Тугыз яшьтә Кави белән Бакый бистә кибетендә сыра белән сыйлана иде. Кыйнала-кыйнала сынган сөякләре ялганмаган әниләре бик яшьләй гүргә кереп яткач, малайларның күзеннән ике бөртек яшь таммады. Аталары кебек каты бәгырьле иде Кави белән Бакый. Яшь әнине алар чәйнәп кенә йотачак иде. Шуңа күрә Гыймранның сөяркәләре «мин» дип аның йортына ыргылмады. Ә Нурсөя барысына да түзәргә риза иде. Тол иргә иң кулай хатын ул инде, ул! Аш-суга оста, чиста-пөхтә... Җанында чәчелмәгән-түгелмәгән наз һәм сөю...

Лəкин аның кулын сорап ишек шакымадылар. Гыймран таптап ялтыраткан сукмакларга тузан кунды. Аның каравы Хəлидəлəр тəрəзəсендə ут тиз сүнə иде. Колакка сизгер иде Нурсөя, күршесенең капка келəсе шалтыраса да уяна иде. Ə монда келəдəн алда лас-лос турдан узган аяк тавышы... Кем дип баш ватма: Гыймран! Ул гына борын яфракларын киңəйтеп мыш-мыш сулый. Кая бара дип, табышмакка җавап эзлəмə: урам Хəлидəлəр белəн бетə. Ары табан — тау.

Итəк астында учак ягып, коймак пешерə икəн бу сердəш. Ерткычны күралмыйм диюлəре чеп-чи ялган! Бəлки, күралмыйдыр, бəлки, монысы хактыр. Хəлидə бик гарьчел иде, ул теге чакта — чəче кыркылган чакта — егетнең түкереп китүен гафу итмəде. Шуның өчен үчегүе дə ихтимал. Менə Гыймранны үзенə иялəштерер дə аннары артына тибəр. Нурсөяне елата-елата дөньядагы бердəнбер татлы җимешеннəн аерганын белсə икəн сердəш! Белмəде... Югыйсə, йөрəкне телеп, күлə-күлə төнге маҗараларын сөйлəмəс иде.

— Түкергəн түкереклəрен үзеннəн ялаттым аждаһаның. Дүрт аякта үрмəлəттем. «Чык миңа кияүгə», — ди. Мəйтəм, айны да учлап тотар идең дə, буең кыскарак.

Төннəрен урманда йөри торган гадəтен кабат яңартты күрше. Тəрəзəдə ут кабынмады. Ə Гыймран бикле ишеккə килде дə китте, килде дə китте. Ул ялгыш та Нурсөянең капкасына бəрелмəде. Ир Хəлидə кармагында чəбəлəнə иде. Шулай-шулай хəйлəкəр сердəш, аның канын уйнатып, тилертə-шаштыра иде.

Бервакыт ул күршесенең ишегалдында ят кеше күрде. Көпə-көндез! «Гыймранны көнлəштерер өчен сөяркə тапкан», — дип уйлады Нурсөя. Йомыкый гына Хəлидə дөньяның сыртына атланып чаба: берсен этə, икенчесен тарта... Нурсөя генə, Гыймранга тугрылык саклап, күзлəренə пəрдə корды менə.

— Төзелеш прорабы ич ул. Аягына күгəргəн кадак кадалган да, шуның урыны шешкəн, ярасын чистартып бəйлəдем, — диде Хəлидə, аны беркатлыга санап. Янəсе, бистəдə хастаханə ябык икəн. Мыжлаган чир-сырхау белəн ябалар ди сиңа! Күзгə төтен өрə, төлкебикə. Гаҗəп, ят ир дүрт-биш мəртəбə күренде дə эзен суытты. Ə өч айдан Хəлидəнең җиңелчə генə корсагы кабарды.

— Карбыз йоттың, ахрысы, — диде Нурсөя, киная белəн.

— Йоттым шул. — Хəлидəнең күзендə яшь тамчылары җемелдəде. — Оят, кызый. Сиңа əйтергə дə хурландым.

— Үзең дə инде, ачык авыз! Өч тапкыр очрашкан прорабтан балага узасың, — дип шелтəлəде Нурсөя. — Аягына кадак кадалган, имеш.

Ə үзенең сөенечтəн дөньясы нурланды. Ниһаять, көндəшлəр ярышы тəмам. Хəзер Гыймран, алтынга манчылса да, хыянəтче күбəлəккə өйлəнмəячəк.

Хəлидə күкерт сыман кабынды:

— Син нəрсə! Мин ул прорабның исемен дə сорамадым. Ярасын бəйлəдем дə җибəрдем.

— Җилдəн яралган, алайса, балаң...

— Яралмаган! Аның əтисе — Гыймран.

Нурсөянең умыртка баганасы чатнады.

— Йа Аллам, нишлəдең син?! — диде ул, җан ачысы белəн. — Син, син...

«Син урлап минем иң татлы җимешемне өздең», — дияргə көче җитмəде.

Ə сердəш аны үзенчə аңлады.

— Əйе, əйе, Гыймран — адəм актыгы. Мин дə тиле! Акыллы кеше шул ерткыч белəн төн кунмас иде. Тиргə, орыш, эт итеп сүк, дускаем.

Шуннан соң Нурсөянең хəле җиңелəйсə икəн! Димəк, Гыймранны бала белəн бəйлəмəкче була, сөйрəлчек. Əйе, Хəлидə — сөйрəлчек. Яратмаган ир белəн йоклаган хатынны тагын ничек атыйсың?! Ул да изге түгел, əмма Нурсөя яратып сыенды Гыймран куенына, яратып!

— Нəрсə соң... аңа əйтəсеңме соң бала турында?

— Ашыкмыйм əле. Бераз сабыр итəм.

Хəлидəнең күзлəре хəйлəкəр кысылды. Тик дөнья аңардан да хəйлəкəррəк иде. Беркөнне Атау болынында Гыймран очрады.

— Күршең түгəреклəнə, шулаймы? — диде ул туп-туры. Гыймранның кайчан əдəп кагыйдəлəрен үтəп гəплəшкəне бар!

— Көнлəшəсеңме?

Тел очын елан агуы əчеттерде. Чагып, аның бу ирне айнытасы килə иде.

— Кемнəн? — Гыймран сагайды. — Əллə, атаңны фəлəн...

— Əллə, əллə шул менə. Сиңа сылар əле аягына кадак кадалган прораб баласын. Исемсез төзүче бистəдə вакытлыча эшлəде. Аны мир буйлап эзлəп интекмəс бит инде янында гына син тыпыр-тыпыр биегəндə.

Гыймранның «тавык тəпилəре» белəн бизəлгəн йөзе бер агарды, бер кызарды.

— Мине узгынчы этлəргə алыштырдымыни? Синнəн гайре ирлəрем юк, ди бит, себерке! Урталай сындырам!

Акылга тулы түгел ир «себеркe»не урталай сындырырга өлгермәде: ауда ул, минем биләмәдә үрдәк атасыз, дип, Савруш чуашын сугып үтерде. Гыймранны унөч елга хөкемгә тарттылар, әмма төрмә төтенендә бер ысланган шома балык, биш ел болганчык суда йөзгәч, ирекккә чыкты.

Ике хатын аны ике төрле көтте: Нурсөя һаман да яратып, ә Хәлидә хыянәт итеп. Кызы тугач ул: «Их, бала әтисез үсә», — дип моңланды да кунакчасына чибәр генә балта остасын кундырды. Биш ел алар язылышмыйча гына яшәделәр. Нигә кинәт кенә бозылыштылар? Бу бер хикмәт иде. Хәлидә яшь ирен иртән озатты, ә кич Гыймран кайтты. Монда нindидер очы очка ялганмаган бәйләнеш бар иде. Ник гаҗәпләнә Нурсөя: сердәше сукыр карчыкның оныгы лабаса! Әбисе сыман ерак чакрымнардан тоемлау сәләте аңа да бирелгән иде, күрәсең.

**4**

...Хатын, кулын йодрыклап, кат-кат күзләрен уды. Иртәнге томан белән өретелеп, таудан Хәлидә төшә иде. Ул туп-туры Нурсөяләргә табан атлый. Йа Ходай, моңарчы төнлә генә җанлана иде, ә бүген...

Нурсөя кычкырып-кычкырып догаларын укырга кереште. Ләкин өрәк килә дә килә иде. Чү, хатын саташа түгелме соң? Нинди Хәлидә ди, кунак кызы лабаса бу! Кара-кара, атлап йөрешләре тач Хәлидәнеке!

— Таң әтәчләре дә уянмаган, син аяк өстендә, — дип мыгырданды Нурсөя. — Ишек ачылганын да ишетмәдем.

— Син каты йоклыйсың, апа.

— Йоклар сиңа! Минем ярты гомерем уяу үтте.

— Борчуларың күптер, апа.

— Каян? Җан кыйнарга исерек ирем юк, тәүфыйксыз балам юк, усал каенанам юк, ут үрләтеп талашыр күршем юк.

— Нәрсәдер эчтән кимерә, димәк.

— Анысы синең хәсрәт түгел, бала. Әйтми дигәч тә теге.

— Ачуланма инде, апа.

Алиянең күзләре яшьләнгән иде. Әйтерсең керфекләренә чык бөртеге кунган! Һәркемнең үз уе да үз моңы шул. Моның да күңелендә бер-бер сагыш кошы талпынадыр. Чит җирләр, чит кешеләр. Элеккеге елларда зур укулардан студентларны бәрәңге җыярга җибәрәләр иде, хәзер әллә нинди мода: риваять, әкият, хикәят, фәлән-фәсмәт. Әти-әнисен дә сагынадыр, шәт.

— Әйдә, бистәнең ала каргалары белән дуслаштырам. — Кызгану хисе Нурсөяне йомшартты. — Аларда сүз буа буарлык. Берсенең салам бөртеге хәтле гайбәтеннән икенчесе кибән өя.

Урман аша үтеп, бистә башына кергәндә генә арттан машина кычкыртты. Нурсөянең йөрәге какты: Гыймран башкисәрләре! Кичтән үк шомланган иде хатын. Авылга тагын бер бәхетсезлек агыла сыман. Аның йорты өстендә генә тубал-тубал кара-коңгырт болыт асылынды. Ни яңгыр, ни боз болыты.

Ул, кызны юл кырыена табан кысрыклап, җилкәсе белән ышыклады.

— Тик тор, бала!

Җир тишеп, тычкан чинаткан дәҗҗаллардан якты дөнья йөзләрендә кем качып котылсын ди!

— Әй син, Җен хатыны! Артыңа кемне яшердең? — Машина тәрәзәсеннән игезәк сыңары бүселде. — Җәле, каплама!

— Ни... оланнар, шәһәрдәге туганымның кызы ие.

Авыр йөк күтәрдемени, Нурсөянең аяк буыннары сыгылды.

— Туганыңмыни фәлән... — дип сүгенде сыңар һәм, сикереп төшеп, хатынны читкә йолкып атты. — Каплама дигәч каплама! Оһо, безнең биләмәдә яңа түшкә! Чибәр, каһәр! Ничек безнең кулларда үчтеки сикермәдең икән син, фәләнеңне... Җәле, яулыгыңны сал!

— Кит, хәшәрәт! — Кыз, чебен куган сыман, кулы белән селтәнде.

Хатынның күз аллары караңгыланды. Көпә-көндез дөнья белән хушлашырга язган икән Ходай. Хәзер аны да, Алияне дә сугып җиргә сеңдерә болар.

— Бакый, төш әле, фәлән! Монда бер түшкәсе миңа кизәнә, һа!

Икенче игезәк сыңары машинадан гына ырылдады:

— Хәзер булашмыйк, фәлән! Төнлә яулыгын чиштереп, чәчен тарарбыз. Киттек!

— Дәшмә, зинһар, бала! — дип пышылдады Нурсөя.

Алиянең исә күзләре нәфрәт белән күмерләнеп яна иде.

Машина тәгәрмәченнән пырылдап очкан тузаннан икесе дә каһ-каһ йөткерделәр.

— Менә шулар инде Гыймран малайлары. Алардан милиция дә шүрли. Әйдә кире борылыйк, бала. Риваять кайгысымыни монда. Төнлә әбиз ишегеңне каерып керәчәкләр инде.

Кыз бәхәсләшмәде, җан кадерлерәк иде.

— Син аларның әшәкелеген белсәң иде, бала. Алла суктырыр инде дә бер. Ул көннәрне күрмәбез инде без.

— Күрерсең, апа.

Бигрәк кистереп әйтеп куя бу бала. Милициягә гариза язып илтмәкче, ахрысы. Йа Аллам, хәзер генә зарланды бит хатын, ул башкисәрләрдән милиция үзе дә шүрли, диде.

— Төштән соң үзәккә автобус бара. Башың сау чакта Казаныңа сыптыр, бала. Төнлә әбиз ишекне каерачаклар.

Алия юлдагы таш кисәген тибеп очырды.

— Юк!

— Нәрсә «юк», бала?

— Эшемне төгәлләмичә мин беркая да китмим. Менә шулар инде, диден мәле син?

Хатынның зиһене чуалган иде.

— Кайчан әйттем? Нәрсә әйттем, бала? Ә-ә, Гыймран малайлары, дидем. Син аларның корбаны инде хәзер, бала. Яшь кызларны харап итә, кабахәтләр. Йә, кая яшерим мин сине, бала?!

— Өзгәләнмә, апа. Алар миңа чәнти бармак белән дә кагылмас.

«Их, син игезәкләрнең явызлыгына тармаган шул», — дип әрнеде Нурсөя. Йә, кая яшерергә бу кыз баланы? Печәнлеккәме? Идән астынамы? Дөньяңны актарып табачаклар бит.

Алия бүлмәсендә озак кына утырды. Ачык ишектән аның ярты ягы гына күренә иде. Хуҗабикәнең күзе очлы: теге тартмачык белән уйный. Менә ул, урыныннан торып, дәшми-тынмый гына ишегалдына чыкты. Мөгаен, шайтан коткысыдыр (югыйсә хатынның кеше әйберенә ымсынганы юк иде), ул, бусагадан сикереп кенә үтеп, тартмачыкка иелде. Йа Ходаем, нинди кара орлыклар соң болар? Дүрт бөртек! Әстәгъфирулла, кипшенгән шомыртлар.

Өйалды идәннәре сыгылды. Нурсөя, үкчәсенә ут элгәндәй, кече бүлмәгә атылды. Юк, шайтан алдады, шайтан! Шомырт дип нәрсә күрсәтте икән, мәлгунь?!

Көн чамасыз озын тоелды. Хәерсез кара-коңгырт болытлар, шуышып, Гыймран малайларының йорты кыегына эленде. Аларда чи-чи музыка чинаталар иде. Төнлә «пәри туе» гөрләтерләр, мөгаен. Күпме кыз-кыркынның башын ашадылар шул йортта... Чираттагысы — Нурсөя кунагы. Ә Алия бик тыныч. Көндез беркем дә янап куркытмаган кебек.

— Яле, җылы гына киен дә идән астына чум, — диде Нурсөя, ваемсыз кызга боерып. — Өстеңә сәләмәләр ташлармын. Тапмаслар, нибуч.

— Алар сиңа тияме, апа?

— Тия, дип... Әллә тагы.

Ул монысына төгәл генә җавап бирә алмады. Игезәкләр аталары белән Нурсөя арасындагы гыйшык маҗараларыннан хәбәрдар иде. Шуны белгән тәкъдирдә дә Нурсөяне санламый иде алар. Җен хатыны иде аның кушаматы. Җен хатыны... Нинди ямьсез исем! Гыймран белән кушылсалар, бәлки, үги әниләренә юньләп эндәшерләр иде.

— Ходайдан узып җанымны суырмаслар әле, — диде ул, хисләреннән оялып. И беркатлы кәбестә! Аның ни-нәрсә уйлаганы кызга бик мөһим ди.

— Сүзләрең алтын, апа. Аллаһы Тәгалә тәкъдиреңә язмаса, йөз юлбарыс та куркыныч түгел. Теләсәң, идән астына үзең кач, ә мин эш белән киттем.

— Төнгә каршы ниткән эш ул?!

Кунак көлемсерәп куйды. Аның бу куркак хатынга буйсынырга исәбендә дә юк иде. Ул тартмачыгында казынды-казынды да, корт чаккандай, торып урамга йөгерде. Нурсөя, аның артыннан күзәтергә теләп, тәрәзәгә капланды, әмма кыз караңгылыкта йотылган иде.

Ә өстәлдәге тартмачыкның капкачы ачык иде! Йозагын бозгач, ул аны зур сумкасына тыга иде. Ашыгып онытты бугай. Җен алдамаган: кипкән шомыртлар! Тик алар нишләптер кимегән — өчәү генә. Берсе ярыкка кысылган дисәң, ярыгы да юк. Әй, искә төшсә, йөрәккә кан сава, Хәлидә дә шомырт киптерә иде бит. Осталыкта телсез әбисеннән дә уздырды ул. Бервакыт ярты Сөнчәле эч китү кизүеннән тәгәрәп ятты. Ә сердәшенең шомырт суын ясап эчкән кешеләр, «эһ» тә димичә, кикереп кенә йөрде.

Кинәт даң-доң бикле ишеккә типтеләр. Башкисәрләр! Ялгыз хатынның ишеге җәйге күбәләк инде ул, өф дип өрсәң, канаты каерыла.

Көне буе җыелган курку куырылып бөрешкән иде бугай, хатын алай ук җебемәде, үзенә генә ишетелерлек итеп:

— Кеше кебек түгел инде сез, җимерәсез, — диде. Ул игезәкләрне гомер буе аермады: Кави белән Бакый бер үк төстә, бер үк кыяфәттә иде. — Син кайсысы соң әле?

— Мөгезлесе! — Ирен читләренә буй-буй селәгәе аккан егет, суда йөзгәндәй таза беләкләре белән һава ишеп, алгы бүлмәгә ыргылды. — Кайда кунагың?

— Нинди кунак, улым?

Ай, беренче мәртәбә «улым» диде Нурсөя. Гыймран белән никахланса, аның улларына шулай дәшәр микәнни?

Бүлмәдә өермәдәй бөтерелгән башкисәр, бәләкәй гәүдәле хатынны чебен сыман учында сытарга җыенгандай, бармакларын тырпайтты:

— Кайда чәчбикә?!

— Алияме? Алия... — Нурсөя аркасы белән, сагыз төсле, диварга ябышты. Китте дисә, сумкасы да, яулыгы да урындыкта. — Бистәдә, дусларында. Кунам, апа, диде.

— Безнең вакыт күп, көтәрбез. Кайткач та, үзең җитәкләп китерәсең! Шылдымы, Җен хатыны? Кирегә катсаң, өеңдә бикләп яндырабыз. Тегеләр кебек. — Егет, Хәлидәләр ягына төртеп, бармак шартлатты. — Көпә-көндез утта өтәбез! Безгә суд та, төрмә дә юк!

«Юк, юк, юк...» Чигәләр зеңгелдәп шаулады. Юк шул, сезгә бернинди дә хөкем юк.

Хатын тупсасы ватылган ишеген көч-хәл белән күтәреп япты. Тәне утта пешкәндәй кыза иде. Бу нәсел бәндәләреннән иман җәяү качкан, бу нәсел бәндәләренә чебен ни дә, кеше ни. Гыймран жалу бирсәң дә якламаячак. Игезәкләренә табынган адәмнән мәрхәмәт көтмә инде. И Аллам, күктән аңа коточкыч җәза юлланыр, һәм ул да Хәлидәләр сыман утта куырылыр микән? Гөнаһысы шундый ук кичермәслекмени соң, йа? Фаҗиганең сәбәбен яшерде, әйе, яшерде... Аның телен канатканчы тешләттерделәр һәм менә шул тешләнгән теле белән үзен дә утка атачаклар.

Нурсөя көчсез, тәвәккәл түгел иде. Баш алып качардай урының булса икән. Бәлки... Алия аны вакытлыча гына үзләрендә яшәтер? Кайчандыр ике сердәш шәһәр турында хыялланганнар иде. Матур киенергә яраткан Нурсөя биек үкчәле туфлидан гына тротуардан теркелди, имеш. Сөнчәледә язын-көзен билдән пычрак, аякта гел резин итек. Яшь кызларга ни ямь инде. Китмәделәр... Авыл баткаклыгы суырды...

Хатын, ухылдап, салкын идәнгә егылды. Тәне барыбер суынмады. Ул, ыңгырашып, уңга-сулга чайкалды. Яшь чакта шәһәр сеңдерер иде әле, ә хәзер гомер көзенең сары яфракларын җил кыштырдатканда, кайсы ташпулат бусагасыннан уздырсын ди. Кала урамнарында Нурсөядән башка да чүплек савытында актарынган хәерчеләр күп. Аның язмышы — шушы Сөнчәле. Җәзасы да шушы Сөнчәледә... Әллә четер-четер янганда: «Ник коткармыйсың, сердәш?!» — дип, Хәлидә каргады микән?

## 5

...Җәй буе туфракка бер тамчы яңгыр таммады. Кайчандыр ярыннан тулып-ташып аккан Сөлчә елгасы чыпчыклар коенса сыйрагы күмелмәс дәрәҗәдә саекты да аннан бөтенләй корыды. Ни гаҗәп, шуннан соң елга бөтенләй кысырланды. Бүген төбендә ком... Кәҗә тавы битеннән челтерәп аккан чишмә юлын адаштырган, диделәр. Августта исә уптым илаһи коелардан су качты.

Беркөнне Хәлидә бакчасыннан гына аңа эндәште:

— Урманда аулак чишмә бар. Әбекәйләр заманыннан бирле ага инде ул. Савыт бир, сиңа да чәйлек апкайтам.

— Чү, мин дә барам, урынын да белеп калырмын, — дип, Нурсөя җилкәсенә чиләк-көянтә аскан иде, күршесе туктатты:

— Барма! Минем сукмагым әйләнгеч. Кеше арытып монда!

Нурсөя аңлады: әһә, Гыймранны аулый. Ялгыз гына бала үстерүләре авырдыр. Башта ни уйлаган, җилбәзәк?! Кеше өлешен умырды да, кызын калкан итеп, хокукларын дауламакчы хәзер. Гыймран Нурсөянеке иде, Нурсөянеке! Чәнти бармагыннан тотынып, чәч бөртегенә кадәр аныкы!

Ул да хәйлә капчыгын кысып бәйләде:

— Әй, бармасам да ярый әле. Гыймранның үз чире кузгалган, ди, кисә-тапый, ди. Алла сакласын! Син дә кызың белән күзенә чалынма, — Нурсөя кара буяуны кызганмады. — Бала синеке, дип маңгаең белән таш чүкесәң дә, ышанмаячак Гыймран, чөнки йортыңда чит ир-ат исе чыгардың. Гыймран шуңа җенләнә.

— Кем әле аңа бала аткара?! — Хәлидәнең күзләре усал кысылды. — Минем кызыма ерткыч ата кирәкми. Карале, әй син. — Кинәт сердәше аңа шикләнеп карады. — Әллә шул башкисәргә гашыйкмы син? Бик сайрыйсың бит. Телеңдә гел Гыймран.

Бик уңайлы вакыт иде бу. Кыр да түк шунда күңелеңдәге сер юшкынын! Якын сердәш, терәлеп яшәгән күрше, аннан битәр хатын-кыз. Бер-берсен кичермәсләр идемени! Аһ, юк, малын да, акчасын да, хәтта соңгы телем ипиен дә бүлешә хатын-кыз, әмма ир бирми. Яратмаса да, аңа бүтәннәрне кагылдырмый ул.

Алай да Нурсөя, читтән-читтән генә суктырып:

— Әвен хәтле тап-таза ирне әрәм яткырмаска иде инде, — диде.

— Гыймран бистә хатыннары белән себерелеп туйгач, сабынлап юарсың да түшәгеңә салырсың, — диде Хәлидә, нигәдер турсаеп.

Нурсөя дә ачуын тыялмады.

— Син соң, үзең соң, кем әле ул хәтле?! Сиңа да йортка кергәннәр иде бит.

— Керерләр дә! Мин синең кебек саз бакасы түгел, күлдә генә бакылдап ирләр чакырмыйм, алар үзләре эзләп таба.

Сердәш бәгырьгә берьюлы йөз энә белән чәнчеде. Савыт та алмады ул, пыр-пыр тузынып өенә китте. Күңелеңдәген түк, имеш. Телсез карчык оныгы лабаса ул! Әнә сөйләмәсәң дә, барысын да сизгән.

Икенче көнне Нурсөя кибет каршында Гыймран белән күреште. Эчә-эчә ирнең йөзе камыр кебек кабарынган иде.

— Әйт әле, Җен хатыны, күршеңне нишләтим? Өч төн рәттән килдем, ишеген ачмады, — диде Гыймран, ярылган иреннәрен ялап.

Нурсөя сердәшенең кичәге каһкаһәсен йотып бетермәгән иде.

— Балга сырышкан чебеннәр шикелле инде сез ирләр. Тәки Хәлидә дип үләсез. Кайсыгызга гына ачып өлгерсен инде ул ишеген?!

— Башка сакал-мыекка ача алайса! — Ир тешен шыгырдатты. — Без — сөйкемсез сөяк алайса. Баласы кемгә охшаган?

— Кемгә, дип... Һәрхәлдә, сиңа түгел. Үз атасынадыр, теге прорабка. Кызын да үзе сыман йомыкый урман пәрие итеп тәрбияләде инде.

— Миннән йөз чөергән хатыннарга көн юк, ишет!

Гыймран кулындагы буш шешәсен баскычка томырды. Их, аның ни белән янаганын белсә икән Нурсөя! Гыймранның гайрәтен чигереп, Хәлидәдән биздерәм дип кенә зәһәрләнде бит ул. Ә моның ахыры коточкыч фаҗига белән тәмамланды.

...Соңгы арада (миендә умарта күче жуылдый диярсең) хатын йокысызлыктан җәфалана иде. Төнлә ул, тамагы чатнап, су эчәргә торды. Капка төбеннән өч ир узып китте дә уңга борылды. Нурсөя ян тәрәзәгә бакты. Ай яктысында дөнья ап-ачык күренә иде. Менә «төнге кошлар» Хәлидәләр коймасыннан сикерде. «И Ходаем, сердәшнең азуы чамадан ашты, күч-күч ирләр белән шаяра», — дип уйлаган гына иде хатын, берьюлы өч төштә — келәт, сарай, өй нүешендә ут үрләде һәм Нурсөянең шарайган күзләре белән бергә үсте-зурайды... Ут төрттеләр! Раз-бой! Хатын, агач кебек каткан аякларын сөйрәп, ишеккә ташланды. Әмма өйалдында аны сугып ектылар. Мышнавыннан таныды Нурсөя: Гыймран!

— Шаулама, җен! Үтерәм! — дип ысылдады ир. — Малайлар, живо чоланга качыгыз!

— Нишлисез сез, ерткычлар!!! Кеше яндырасыз бит!!!

Хатын авырткан тез капкачын уа-уа тормакчы иде, Гыймран аягы белән аның җилкәсенә басты:

— Шым бул, дим!

— Сүндере-е-е-гез, — дип чәбәләнде борыны белән идәнгә кадалган Нурсөя. — Баласы-ы-ы ха-кы-на-а...

— Әллә кайчан өй тирәли чатыр чабадыр, шайтан таягы! — дип хихылдады ир.

Чоландагы үсмер малайлар да көлеште:

— Син, эти, аларның ишегенә көрәк терәдең, катырак янсыннар, дидең.

— Шым, дим, әнчекләр! Бар син, чык! — Гыймран аягын алды. — Чык, диләр, чукрак! Комганыңда суың булса, сип!

Бер кашык суга тилмергән авыл халкы утны ничек авызлыкласын ди! Хәер, су да көчсез иде монда. Йокы сөреме белән исергән кеше уянып йөгергәндә, бүрәнәләр кисәүгә әверелгән иде.

— Төн җилсез, бәхетең — ут сиңа авышмады, — диделәр Нурсөягә. Ә ул, акылдан язгандай, Хәлидәне эзләде. Кемдер аны бистәдә кунакта диде. Юк, сердәше өйдә иде. Кичкырын ул бакчасында бәрәңге казыды. Димәк, янды, кызы белән икәүләшеп янды!!!

Бу мәхшәргә Гыймранның мыек очы да селкенмәде.

Ул, йодрыгын хатынның борынына ышкып:

— Иснәдеңме? — диде. — Иснәдең, ыһы. Әгәр исемемне төрләндерсәң, балта белән башыңны чәрдәклим. Үзәктән тикшерсәләр, әйт, кичтән чүп яндырды, диген. Учагын сүндермәгән, диген. Кайнар көлдән дөрләгән ут, диген. Оста гына шик-фәләннәрнең тишек-тошыгын томала.

...Өч көннән милиция «хуҗа гаебе белән» дип, «эш»не япты. Хәлидә бистәдә дигән хәбәр дә расланмады. Көл өемен генә зиратка илтеп күмделәр...

Шушы хәлләрдән соң Нурсөя боекты. Гыймраннан да күңеле сүрелде. «Кеше яндырам дип ут төртмәдек без, — диде ир, берсендә уфтанып. — Сабак бирмәкче идем малайлар белән. Тәкәббер Хәлидә йорт-җирсез калса, бәлкем, миңа кияүгә чыгар, дидем. Баласы белән дә ала идем мин аны. Чибәр ие, су анасы!»

«Кайсы җире чибәр, ә?» Инде Нурсөя мәрхүмәдән дә көнләшә иде. Әлеге фаҗига еллар тузаны белән күмелер дисә...Чү, вакытны ашыктырма икән. Аның үз бизмәне, үз чамасы... Гыймранга яңадан хисләр кайнарланган мәлләр иде. Тегесе дә, эчүен ташлап, хуҗалыгын тергезә, очраганда әллә ничә төрле ишарә белән (ул күз кысулар, ул елмаюлар) уза иде. Әлбәттә, җил котырса (хәтер уянса), тузан өермә ясап һавага күтәрелә һәм көн яктысын (күңелне) каплап шомландыра иде. Янды бит Хәлидә

белән кызы, янды!!! Хатын бер өермәдә тончыгып, бер яктыга үрмәләп яшәгәндә генә мәрхүмәнең рухы эзәрлекләргә тотынды: төннәрдән бер төнне тау өстенә чыгып басты Хәлидә... Нәкъ шомыртлар каралган чак иде. Менә унбиш ел шулай. Нурсөя, аптырагач, бистәдәге белекче карчыкны үзендә кундырды. Икәү, тауга текәлеп, озак баскычта утырдылар.

— Әнә, әнә, — диде хатын, карчыкны җиңеннән йолыккалап. — Кызы белән...

— Кая, кая? — Белекченең күзләре алмаз иде, ул алай да күзлек киде. — Юк бит, бәбкәм, берни дә юк бит. Нарат ботаклары гына тырпаешкан.

— Әнә, әнә! Хәлидәнең кулында чиләк!

— Бисмилләһир-рахманир-рахим... — Карчык, дога укып, Нурсөянең битенә өрде. — Җен алдый, бәбкәм. Чирле син, бәбкәм. Аллаһы Тәгалә сиңа мондый җәзаны никләр тәгаенләде икән соң? Тәүбә, тәүбә!

Аңа белекче дә ярдәм итмәде. Ходай да кичермәслек гөнаһны адәм кулы белән генә юарлык түгел иде шул. Ә гөнаһ, күр, галәмне айкап, кире үзеңә кайта! Җәза булып! Бүген Гыймран малайлары «яндырабыз» дип аңа янады. Бәрәч, ул инде яна! Тәрәзәләр кып-кызыл лабаса! Нурсөянең борыны төтен исен тоймый микәнни?!

Хатын ишеккә табан шуышты. Йа Ходаем, тыштан терәтмәгәннәр! Котыла икән, котыла. Хәлидә дә, ут камагач, ишекне эткәндер. Нурсөягә егерме адым гына иде югыйсә. Коткара ала иде!

Нурсөя туп кебек өйалды баскычыннан мәтәлде. Авырту сизмәде. Аңа ничек тә читкәрәк шуышырга кирәк иде. Төнге салкынча һава айнытып җибәрде. Аның тәрәзәсе кызаргач, димәк, каршы урамда яналар. «Аһ Аллам, кемгә хәсрәт тагы» дип, Нурсөя капкага табан титаклады. Әллә аяк бармагы сынган, әллә каймыккан иде. Ялангач беләкләргә кызу бәрелде. Йа Ходай, Гыймран малайларының алпавыт утары хәтле йорты утка төренгән! Нишләп тып-тын гына яна ул?! Нишләп аны сүндермиләр?! Коеларда мөлдерәмә тулы су. Ә-ә, кеше юк, кеше. Авылда аксак-туксак карт-коры гына.

Бистә ягында янгын машиналары улашты. Күргәннәр булыр. Күрми ни, офыкны өтә лабаса!

Койма буенда кунак кызы белән маңгайга-маңгай бәрелештеләр.

— Кайда идең син, бала?! — Хатын үзалдына калтырый иде. — Башкисәрләр сине таптырып җелегемне киптерде. Йортыңа ут төртәбез, диделәр.

— Сиңа чират тимәс әле, үзләре янып ята бит, — диде кыз, тыныч кына. Әйтерсең салам кибәненә шырпы сызып ыргытканнар! Әй бу яшьләрнең гамьсезлеге.

— Йорты төзелер анысы, Гыймран малайларының акчасы күп. Кеше-фәлән генә эчтә калмасын. Кичтән бик шау-шу иде анда. — Нурсөя баягы соравына җавап ишетмәгән иде. — Кайда идең син, ә?

— Күп белсәң, тиз картаерсың, апа.

— Яшәрүгә табан бармабыз, әйе. Пожар ягыннан кайтышың, ахрысы.

— Шикләнмә, авызымнан ут өрдертергә мин аждаһа түгел.

— Җә, сураеп тормыйк, керик. Бездән ни ярдәм инде.

— Иркенләп янсыннар, әйеме? Сезнең авылда шундый гадәт бар мәллә?

Кыз аның һәр сүзен кирегә сукалый иде.

— Нинди гадәт ул?

— Ерактан гына тамаша кылу.

Нурсөянең күз кабагы тартышты. Аһ Алла! Кыек атып туры тидерә бу тел бистәсе!

— Күбәләк, канаты белән җилпенеп, учак сүндерсә икән, — диде ул. — Син тугарылма, яме? Өй янды дип, алар кара ниятләреннән тайчынмас, бер нәпселәрен сузганнар икән, тагын килерләр. Сиңа риваятьме, башыңмы кыйбат? Бүген тынычлап йокла, таң белән мин сине арканлап олы юл тукталышына илтәм. Әйтми дигәч тә теге.

Тик ул җилгә генә гайрәтләнгән икән, иртән кызның караваты буш иде. Ничек мыштым гына сыза соң ул, йа?

Урамнан шаулаша-шаулаша хатыннар үтте. Бистә гайбәтчеләре янгын карый, имеш. Ә Нурсөя ул якка күз салырга да курка. Кисәү өемедер инде. Кайчандыр үсмер игезәкләр Хәлидәгә ут төрткән иде, ә бүген үзләре янды. Ходай чокыр-чакырны тигезли икән ул.

Хатын нишләргә дип йөдәгәндә, Алия кайтты.

— Син... син, әйтми дигәч тә теге. Кар кебек эрисең, билләһи. Җыен! Бистә аша гына тукталышка озатам.

— Соңгы автобус түгелдер бит, апа. Бар син, Гыймраныңның хәлен белеш.

— Нинди сүз бу? Нишләп минем Гыймран ди әле ул? — Нурсөя шап-шоп алъяпкыч итәген какты.

— Алдашма, апа. Күзләреңдә гел шул ир шәүләсе...

Кыз дыңгылдатып урта ишекне япты. Бу юлысы турдан ир-атлар узды. Гыймранның йөрәге ярылган мәллә? Кайгы күсәге үз капкаңа бик каты ора шул.

...Җирдә ауный-ауный үкергән Гыймран яралы бүрегә охшаган иде. Нурсөя хатыннар арасында басып торды да абына-сөртенә өенә атлады. Йа Ходай, ерткычка да бала кызганыч икән... Аларда да җан дигән нәзберек нәрсә бар икән. Һай, очынып та яшәдең, Гыймран. Менә сиңа да Тобадан да тирәнрәк яра уйдылар. Түз, чыда хәзер.

Хатын баскычтан мүкәләп менде. Ул Гыймран өчен дәртләнеп хәлсезләнгән иде.

— Абау, нишлисең син, апа?! — Алия аны култыклап алды. — Башың әйләнә мәллә, апа? Даруларың кайда?

— Анда бит, анда... — Нурсөянең теле көрмәкләнә иде. — Анда... Гыймран абзаң акылга җиңеләйгән. Игезәк сыңары тәтенгә тончыгып үлгән бит... Юатыр гына идем бичаракаемны, бистә гайбәтчеләре чекерәйгән. Тәмләп-тәмләп чәйнәрләр иде соңыннан...

Кыз бернинди гаҗәпләнү дә белгертмәде.

— Ят син, апа, ят, — диде.

— Гыймранга һай авырдыр. Ата кеше бит. Аның тегесе — икенче игезәге шыр исерек. Кесәсендә аракы шешәсе. Авылыгыз белән утка тотам дип акыра.

Дару да хәл өстәмәде. Алия пешергән үләнле чәй дә тынычландырмады.

— Тыкрык башыннан гына карап кил, бала. Нишлиләр икән?

— Кемнәр, апа?

— Соң... халык инде... Гыймран инде...

Алия, уч төбеннән генә укыгандай:

— Ирләр кабер казый, корымга буялган Гыймран тәмәке көйрәтә, — диде.

«Хәлен сорашасы иде... Битеннән сыйпап бирәр җылы сүз әйтәсе иде... Ник мин гайбәттән куркам соң әле?»

Әмма ул Алиядән кыенсынды. Кыз маңгаена хәтле каплаган яулыгының очын бөтерә-бөтерә аны күзәтә иде.

— Үлмим мин, ана каз бәбкәсен тилгәннән саклаган кебек саклама. Әйтми дигәч тә теге, — диде хатын, җаны кысылып. Әллә нәрсә, дөньясы тар һәм кысан иде.

— Алайса, мин тауда шомырт җыям. Алар каралып тәмлерә башлады. Шуны ашасаң, кәефләнәсең, апа.

Нурсөя авызыннан күбекләр кайнатып аңа кычкырды:

— Мин шомырт яратмыйм!!!

— Мәйлең, апа, — диде кыз, җилкәсен җыерып.

Нурсөя мендәр төя-төя елады. Әйе, яратмый ул, яратмый!

Тик беркем дә аның күз яшьләрен сөртмәде. Алия гаип иде. Ялгызлык кочагында өшегән хатын уе белән Гыймранга сыенды... Әмма туң бәгырьле ир дә салкын иде. Туганда ук боздан катырылган Гыймран ничек бүген генә җылынсын ди! Шушы минутларда нишли икән бичара?

Аягына таш бәйләгәндәй, вакыт бик әкрен кыймылдый. Көндез тамактан ашау үтмәде. Чәй кайнатып, кызны көткән иде, ул исә кайтмады. Шомыртлыкны каян күргән, хәерсез! Тауны аркылыга-буйга гизгәндер инде шулхәтле гомер эчендә. Шәһәр халкы табигать дип үлә, билләһи.

Көн кичкә авышкач, Нурсөя юынып чәчләрен рәтләде һәм, иң матур күлмәген киеп, урам буйлап китте. Күңел ялгышмаган: Гыймран капка төбендә тәмәке пыскыта иде.

— Нихәл син? — диде хатын, йомшак тавыш белән. — Килдем әле менә. Әзрәк кайгыңны җиңеләйтим, дим. Ходай сабырлык арты сабырлык өстәсен инде сиңа, Гыймран.

Ир яңаклары бүлтәйгәнче тәмәкесен пуфылдатты.

— Синең җәлләвеңә кем мохтаҗ, йа?

— Җәйге мунча тиз җитешә, яксам, юынасыңмы? Йөзең корым гына...

Ул Гыймранның чәченнән сыйпамакчы иде, ир башын кыңгырайтты:

— Әнә кәҗә тәкәсен сыйпа!

Әй, булмый икән, булмый! Бу адәмгә тәмле телең әрәм. Аның белән үзе кебек ордым-бәрдем сөйләшергә кирәк икән.

— Малайларыңны артык узындырган идең, Гыймран. Бәндә түзсә дә, Алла түзми шул. Яндырам дип, кичтән мине өркеткән иде кайсыдыр.

— Ничава, Бакыем исән бит, бурычын кайтарыр. Вакытын үзең билгелә, сиңа кайсы төндә җайлырак?

— Хәлидәгә сәгатен куеп килмәдегез бугай. — Нурсөя дә усалланды. — Бусын тый, ичмасам. Сине Ходай кисәтте, Гыймран, кара!

— Карыйм, карыйм, Җен хатыны! Үнда да син, сулда да син.

— Малаең сезнең өйдәме? Бер кызган-кызган, үзем колагына тукыйм.

— Маташма. Ул бистәдә әшнәләре белән кайгысын юа. Мин генә аек монда. Бугаздан төшми.

— Безнеңчә түгел икән, Гыймран, — диде хатын, тагын йомшарып. — Мөселманча түгел. Мәет догага мохтаҗ.

— Син үзеңә укы, яме. Тукта, Бакый кайгысын юдыртсын. Аннан иманыгызны көячәк ул. Кайсыгыз ут төртте, танығыз яхшы чакта!

Ирнең күзендә иман әсәре юк иде.

Өч көн авылда җил дә исмәде. Эчә-эчә мие сыегайган игезәкләр сыңары сөнчәлеләргә «бурыч»ын кайтарырга кереште. Урамнарда кәҗә-сарык тапталды, каз-үрдәк изелде. Нурсөягә иң катысы эләкте: Бакый, машинасы белән сөздереп, капканы аударды, коймаларны иште. Хатын-кыз кулы белән генә каккан-суккан рәшәткәләр чыдам түгел иде шул. Ләкин бу шомланып көткән бәла белән чагыштырганда уен гына иде. Ут кына салмасын берүк!

— Тузыныр-тузыныр да ипләнер әле, картая-картая кешенең каны куера, — диде Нурсөя.

— Җүләр кан үзгәрми, — диде Алия. — Мин икенче атнага китәм, апа.

Хатын шатланды: Гыймранныкылар кунак кызы өчен каныкты лабаса. Бер үк вакытта моңсу да иде: ияләште шушы җан иясенә. Тырт та пырт сөйләшсәләр дә, иптәш иде әле. Сүз алышыр кеше иде...

— Озакламый эшем бетә, апа.

— Бәрәч, риваятеңне язмадың да бугай.

— Мин аны төгәллим инде, апа.

«Төгәллисең, пычагым, — диде Нурсөя, ризасыз гына. — Синең итәгеңә кыңгырау тагасы иде. Кайларда шылдырарсың икән?»

Ник мондый тилемсә уйлар миемне кайната, ә? Кыңгырау тагасы, имеш. Китәм, ди бит әнә. Күңелеңнең тарлыгына үләрсең! Өйдәшеңә күпме сабыр иттең, соңгы мәлдә генә чыгымлама, зинһар. Үз мәшәкатең дә муеннан ашкан: койма-капкаларың җирдә ята.

— Бистәгә балта остасы Гомәргә барам, — диде ул. — Биш ел күршем Хәлидә аны ир итеп асрады. Күрше хакын хаклап, ауган-егылганны төзәтер, бәлки.

Күңел үсмәсә дә, бу хәрабә оясында яшәргә ярамый иде.

Кинәт кыз су тамчысы кебек чәчрәп тамды:

— Юк, юк, син бик хәлсез, апа! Аякларың да сызлый. Гомәр, дисеңме? Мин аны үзем чакырам.

Нурсөя:

— Синең ише бала-чаганы тыңламый ул. Бик кире кеше, — дисә дә, кыз ниятеннән чигенмәде:

— Адресын әйт, апа!

— Таш кибеттән соң өченче йорт.

Бәлки, хатынның бармавы хәерлерәктер дә. Гомәр барыбер булышмас иде. Ир Хәлидәнең үлемен авыр кичерде. Һәм берсендә, Нурсөяне туктатып:

— Авылыгыз белән дәҗҗаллар сез, — диде. — Карап торып кешеләр яндырдыгыз, — диде. Ул бистәдә еш очрый, ләкин беркайчан да исәнләшми иде.

Койма-капка сылтау гына. Нурсөянең ир җанындагы рәнҗешне алып ташлыйсы килә иде. Гомер кыска, фанилыктан бакыйлыкка бер адым. Хатын шушы ярты сүәм аралыкта да гөнаһны артык күп төяде. Әзрәген бушатасы иде, бушатасы... Хәер, теге гөнаһның тары бөртеге хәтлесе дә тәмуг казанында кайнатырга җитәдер.

Нишләптер кыз озаклады. Яшь кешегә ярты сәгатьтә бистәне аркылыга-буйга иңләргә була. Хат ташучы Нурсөя ул чакрымнарны мең кат санаган инде. Эч пошу көчәйгән саен көчәя генә иде. Балта остасы Алия белән сүз боткасы пешермәс. Ул өздереп кенә «юк» дияр. Кунак автобуска юлыгып утырып китмәс: әйберләре монда. Әйбер дигәннән, тартмачык кайда соң әле? Өстәлдә күренми.

Хатын, үз-үзеннән уңайсызланып кына (карак, янәсе), кызның дәү сумкасына тыгылды, тартмачыкны тартып алып капкачын күтәрде. Өч бөртек кипкән шомырт бер почмактан икенче почмакка тәгәрәште...

Ходай кисәткәндер, мөгаен, ашыгып урта ишекне генә япты, атыла-бәрелә Алия кайтып керде.

— Ой, кызык! — диде ул, ясалма көлеп, ә үзенең йөзе ап-ак иде. — Бистәдән хәтле куды...

— Әстәгым! Бүреләр мәллә, бала?!

— Бүредән дә хәтәррәк, апа. Тыкрыкка кадәр ыжгыртты. Таптата иде машинасы белән чокырга мәтәлмәсә.

— Игезәк сыңары Бакыймыни?! Канатып тешлиләр бит, имансызлар. Алла берсен җәзалады инде. — Кинәт Нурсөя йөрәген учлады. — Машинасы белән чокырга кадалды, дисеңме? Без гөл туфрагы өчен казыган чокырдыр инде. Башы бәрелеп үлмәгәндер ич? Монысы да дөмексә, Гыймран, валлаһи, тилерәчәк.

— Исерек ул, апа. Рулен кочаклап гыр-гыр йоклый.

Кыз алгы бүлмәдә йон кофтасын киде. Аннан, ишеккә арты белән басып, сумкасында казынырга кереште.

— Мин тау белән саубуллашам, — диде ул, сәер генә.

Нурсөя шаккатмады. Аның сәерлеген табигый кебек кабул итә башлаган иде. Тауга бакча сукмагыннан гына элдертәсе кеше нигәдер тыкрыкка табан борылды. Гыймран малае уянса, өзгәләп ыргыта бит, Ходаем!

Алия, күрәчәге белән шаярткан төсле, машина янына килеп, тәрәзәсенә муенын сузды... Шуннан соң Гыймраннар очына төшеп китте ул. Нәрсә эзли, нәрсә югалткан?! Хәлидәләрнең йорты янасы кичтә хатынның йөрәге чемердәп оеган иде. Нәрсәдер сизенде Нурсөя. Бүген дә нәкъ шул хәл: йөрәк ойый. Ул, нииндидер фаҗига буласын алдан ук тоеп, туктарга әзерләнә кебек. Аптырагач, хатын өй җыештырырга тотынды. Сәфәр кешесе артыннан идән юарга ярамый, диләр. Кунакның холкы кесәсендә генә: кайтыр да, хуш, апа, дияр.

Нурсөя кызның сибелгән-таралган киемнәрен урындыкка элде. Зур сумканың замогы каптырылмаган иде. Кул үзеннән-үзе тартмачыкка үрелде. Әй Нурсөя, Нурсөя. Озын борыныңны бер кыстырасың инде. Ник шушы шомыртларга эчең кытыклана икән?

Хатынның чәч төпләре кызышты: шомырт берәү генә иде. Учына утлы күмер койдылармыни, ул тартмачыкны сумкага ташлады. Бөтен гәүдәсен көзән җыергандай, кул-аяк тартышты. Димәк, бая икесен алган... Алар белән ни-нәрсә кайнаштыра икән ул?!

Хатын әштер-өштер идәннәрне юды да, ике төймә йокы даруы кабып, түшәккә ауды. Нервысы җөй кебек тартылган, йөрәк кан сугармый иде. Эчтән үзен ашап бетерде шул. Гомер сукмагы кыек сызылды. Яшьтән үк Гыймран белән кавышып, бер оя бала үстерү иде исәбе. Бәндә сөйләр, тәкъдир көләр, ди. Көлмәгән кая! Өмет-хыяллар әнә теге җимерек рәшәткәләр кебек: әз генә күңел җилкенсә, әле берсе, әле икенчесе тыртая... Аңа бәхет турында хыяллану килешми иде.

Уйларында чәбәләнеп ята-ята, йокы даруы тәмам изрәтте. Үлемне дә тоймас дәрәҗәдә тетелеп йоклады ул. Шыгыр-шыгыр көйләгән тавышка уянганда, таң аткан, тәрәзәләргә кояшның алтынсу нурлары сирпелгән иде. Шыгыр-шыгыр... Шыгыр-шыгыр... Шунда гына ул әрле-бирле йөренгән кунак кызын шәйләде.

— Иртүк нишлисең, бала? Әйтми дигәч тә теге.

— Синең уянганыңны көтәм, апа.

— Китәсеңмени? Бүгенге рейс кичкерәк якта бит.

— Беләм, апа. Син йокы белән төнге маҗараларны сизмәдең. Ерак-ерактан уратып тормыйм, апа. Миндә әни холкы: сырлап-бизәкләп мәшәкатьләнмим, турысын әйтәм. Сөнчәледә ике хәбәр бар...

— Ай Аллам! — Нурсөя дарудан миңгерәгән башын учлады. — Бакый рәнҗетте мәллә?! Эләктең мәллә шул бәдбәхет тырнагына?! Син бит миңа туганым кебек якын хәзер. Оныт инде мырлашкан чакларыбызны, бала. Хәтереңдә мине әшәке итеп саклама, яме.

— Ашыкма, апа. Соңрак бәхилләшербез. Хәбәрнең беренчесе: исерек Бакыегыз машинасында үз косыгына тончыгып үлгән. Икенче хәбәр: Гыймраныгызның йорты янган...

Хатын, бугазына бодай бөялгән үрдәк сыман, ыйк-ыйк диде. Көчкә ике сүз сөзеп чыгарды ул:

— Гыймран... исәнме?

— Исән, исән! Бар, сөеклеңне юат!

Алия үксеп-үксеп елый башлады. Нурсөя кызның бу халәтенә игътибар итмәде, аның үзенеке көчле иде. Йа Рабби, Гыймран исән! Хатын өчен моннан да зуррак бәхет бармыни дөньяда! Исән! Ходай җәзаларын шуның белән чикләсен иде. Тик ир әле күрәселәрен күреп бетермәгән кебек... Аңа тагын да коточкычрак әрнү тиеш кебек... Юк, аларның икесенә дә уртак кебек ул...

## 7

Гыймраннар урамы киң иде, һай киң иде... Кибән хәтле ирне култыклаган хатын әле сулга, әле уңга кыйшайды. Ә Гыймран туры гына атламый, аягы чалшая да кырыйга тарта иде. Алар икесе дә аңкы-тиңке.

— Шул-лай, Гыймран, — диде Нурсөя. — Шул-лай, әкрен генә теркелдә инде син. Ай-яй хәсрәтле минутларың. Күрәчәк бу, Гыймран. Аңа каршы бәндәдә чара юк. Ни тырышсаң да. Тәкъдиренә язганны кем сөрткән дә кем төзәткән!

Ир шыңшыды. Ул телсез иде.

— Ызбам тынга иркен, Аллага шөкер. Туйганчы яшә. Кунагым китә. Ияләшкән дә идем инде үзенә. Минем дә кызым шул чама булыр иде. Син, сөйкемсез сөяк дип, читкә тибәрдең бит, өйләнмәдең, Хәлидә дип шаштың. Буйсынмаган хатын-кызларга тигәнәк кебек ябыша идең. Ярату юк иде инде синдә. Яраткан кешеңне терeләй яндыралармыни, йә? — Гыймран каршы дәшмәгәч, хатын тагын да батырайды. Кичәге ерткыч бүредән юаш куян баласына әйләнгән иде ир. — Мәйтәм, игезәкләрнең дуслары бигрәк мәрхәмәтсез икән. Бакыйны җирләделәр дә, кабер дә суынмады, машиналарына төялешеп тайдылар. Хәлеңне сорашсыннар иде, ичмасам. И Алла, нинди начар дөнья!

Тузан туздырып, чалыш-полыш атлаган Гыймранның кайнар сулышы колак яфрагын пешерә иде.

Әй, яңа вакытта кеше киеп туздырган иске чабатаны җилкәгә аскан төсле инде бу. Һавага сугып, йолдыз ваклаган гайрәтле чакларында ир Хәлидә артыннан чапты шул.

— Куян төсле еш-еш сулама әле, Гыймран. Әйтмәгән саен теге. — Нурсөянең беләге талган иде. — Чү, туктыйк чүт кенә. Кемнәргә барганыңны чамалыйсыңдыр инде. Миңа барып ятышың, Гыймран, миңа.

— Әһе, әһе! — Ир кинәт телгә килде. — Ну көч үзеңдә, трактор кебек сөйрисең. — Гыймран шап-шоп чалбар кесәсенә сукты. — Фифируслар да янган, карале...

— Үзең исән калганга шатлан, Гыймран.

Ир, җир сыман каралган «бизәкле» йөзен чытып, тагын мыгырданды:

— Фифируслар да янган, карале...

«Бу акылга зәгыйфьләнгән, ахрысы, — диде Нурсөя, пошынып. — Өенең көле күккә очты, соңгы малае тончыгып үлде, ә ул фифирус дип сөйләнә».

— Әйдә кымшан! — Хатын терсәге белән ирнең аркасына төртте.

Хәлсез Гыймран тышаулаган атка охшаган иде.

— Кызулама, Нурсөя.

— Бәрәч, исемемне онытмаган!

— Оныттырмадың бит, гел күз алдында бөтерелдең, Җен...

— Йә, йә, — дип элеп алды хатын. — Шул кушаматыңны авыз тутырып әйт! Җен хатыны мин, Җен хатыны! Әфсенләрмен әле үзеңне менәтерәк!

Ир лышкылдаган борынын җиң очына сеңгерде.

— Ачуланма, җәме. — диде. — Гадәт буенча ычкынды.

Бауга тагылган бозау кебек күндәм генә ияреп барган Гыймран капка төбенә җиткәч, киреләнеп, ишегалдына кермәде.

— Нишләп йөрим соң әле мин монда, йа? — диде ул.

— Нишләп, нишләп! — Нурсөя, үртәгәндәй, иреннәрен очлайтты. — Әллә син үлем исе белән исерденме? Йортың янды ич! Кемгә кирәк син бүген, ә? Ник үзе дә дөмекмәде, дип шаулашты авыл. Ятып йокларга — караватың, чәй эчәргә өстәлең юу-ук!

Гыймран, күзләрен әйләндереп, йорт тирәсендәге хәрабәләргә карады:

— Җил аудардымы?

— Җил.

— Нык дулаган икән.

Ул, тезен бөгеп, җиргә чүгәләмәкче иде, аркан ауды. Аннан, терсәгенә таянып, мышный-мышный торып утырды. Аның гәүдә авырлыгыннан рәшәткәләр шартлап сынды.

Хатын да, бүкәнне тәгәрәтеп, ир каршына китерде. Сүз юк иде... Көн саен яный-яный йөрәк бозган башкисәрләрне Алла суктырды. Ә бу аюның кайгыдан табаны урталай ярылды: моннан соң адәмнәрне таптамас, дөньясын ишмәс. Шәт, тыныч яшәлер. Тик Ходай җанны тындырыр микән? Уң якта — алабута сарган нигез... Ул мәңге хәтер капкасын яптырмаячак.

— Ы-ы-ы-ы...

Бер иш бәндәләрнең башына хәсрәт ташы соңрак ява икән. Бая гына гамьсез кебек иде Гыймран, ә хәзер тамак төбен гырылдатып ыңгыраша.

— Ы-ы-ы-ы... Мылтыгым кайда, атылам... Ике балам, ике бөркетем юк...

— Икәү генә түгел, өчәү юк, — дип кыстырды Нурсөя. Ниһаять, ул ачылырга тиеш иде. — Унбиш ел элек син үз кызыңны яндырдың.

Тозы эредемени, ирнең бәбәгеннән шау-шау яшь ага иде. Ул, пычрак йодрыгы белән басып, күз төбен корытырга маташты.

— Син... син... Җен хатыны, ни лыгырдыйсың?!

— Лыгырдамыйм, Гыймран. Хәлидә синнән тапкан иде баласын. Мин көнләшеп яшердем, Гыймран. Их, белсәң иде минем ничек яратуымны! — Нурсөя тыелып кына көлде. — Җүләр, билләһи. Иске чабата ертык әнә... Кизәнеп берне сугар идең, әйеме? Кулың камыр шул.

Бик түбәннән генә килбәтсез зур кош очып үтте. Канаты буй-буй ак иде аның. Кош каурые белән яраңны сыйпасаң, тиз төзәлә, имеш. Адәм баласы нинди генә ысуллар белән дәваланмас иде. Менә Нурсөя дә унбиш ел бәгырен телгән гөнаһ газабыннан котылмак була.

— Ы-ы-ы-ы, — диде Гыймран. — Ы-ы-ы-ы...

Күтәренгән-җыенган кунак кызы алларына килеп баскач та, оялмыйча ыңгырашты ул.

— Ы-ы-ы-ы...

Алия иңендәге юл сумкасын җиргә шудырды. Аның кулында бәләкәй тартмачык иде. Нурсөя, коты очып, шуңа текәлде. Менә хәзер кыз тартмачыкны ачар да, аннан җиз елан шуышып чыгып, Гыймран белән икесен буып үтерер сыман. Хәтта сулышка да авырайды.

— Синең... синең тәки риваятьләрең язылмады, бала.

— Язылды, апа. Ахырына бер нокта гына куясы калды. Эчтәлеген сөйлимме?

Алиянең тиктомалга елмаюы сагайта башлады.

— Сөйлим дип... — Хатын Гыймранга ымлады. — Риваять тыңларлыкмыни безнең хәлләр...

— Ә ул бик кыска, апа. Яшәгән, ди, булган, ди, ике туташ. Күршедә генә, ди. Кызларның кыска чәчлесе бер Аждаһага мөкиббән, ди, ә Аждаһа, киресенчә, дулкын-дулкын Озын чәчлесен сайлаган, ди. Аны көчләп гел үзенә буйсындырырга җилкенгән, ди. Дулкын чәч бу кабахәтне яратмаган, әмма, хаталанып, аның белән төн уздырган һәм бала тапкан, ди. Көнләшүеннән зәһәрләнгән Кыска чәч Аждаһага: «Аңа ышанма, бала чит ирдән», — дип алдашкан, ди. Шуннан соң явыз Дулкын чәчтән үч алган, төнлә ике аждаһа малае белән аның йортына авызыннан ут өрдергән, ди.

— Җитте! Бу риваять түгел! — диде Нурсөя һәм урталай сынган Гыймранның дылк-дылк җилкәсеннән селкетте. — Ишеттеңме син, ишеттеңме? И Ходаем, Аждаһасы син бит моның, Кыска чәче — мин! Хәлидә — Дулкын чәч! Син яндырдың дип әйтмәдем мин бу балага, Гыймран. Валлаһи! Гомер буе эчемдә сакладым ул кара серне, Гыймран! Исерек килеш мәрхүм Бакый белән Кави тишкәндер, Гыймран! — Хатын ухылдап яңадан бүкәнгә төртелде. — Абзаң хәсрәтеннән таш күек катты, ахрысы. Җаныбызны актардың, бала.

— Риваятьнең дәвамын тыңлагыз. — Кыз тартмачык капкачында нәфис бармакларын биетте. — Ул айлы төндә Дулкын чәч кызы белән икәүләшеп шомырт җыя. Әбисенең «дәва өчен төнге шомырт кирәк, көн яктысы аның шифасын урлый» дигән әманәте аларны үлемнән коткара. Аналы-кызлы йортның янганын да, Аждаһаларның өчәүләшеп Кыска чәчләрдә яшеренүен дә тау өстеннән тамаша кыла. Менә шулай риваять тәмам.

Кунак кыз яулыгын чиште. Дулкын-дулкын чәч аның иңнәренә таралды...

Гәүдәсе кечерәеп, Нурсөя бөҗәккә әверелде. Күзләре генә галәмне сыйдырырдай булып зурая иде.

— Хәлидә, синме соң бу? — диде ул, яшьлек еллары белән саташып.

Гыймран да сынын турайтты. Ирнең авызы ачык, ияге дерелди иде.

— Мин Хәлидәнең кызы Галия. Чәчләрем нәкъ әнинеке, әйеме? Балта остасы Гомәр абый мине шунда ук таныды. Коймаларыңны рәтлим, диде, апа. Бушлай, диде.

— Йа Рабби, сез... сез... исән икән?! Кайда идегез шул гомер?!

Йөрәктәге бозның чит-читләре кителде. Кичерер микән Хәлидә?! Кичерер микән, йа Ходаем?!

— Аждаһа бер явызлык ниятләсә, уеннан кайтмый, үтерә, дип, әни таудан олы юлга йөгерә. Без шәһәрдә урнаштык. Андагы яшәү яшәү түгел иде инде әни өчен. Ул һаман Сөнчәлесе белән төшләнде. Авыл дия-дия кипте-саргайды. Урманнан әни, яфракка төреп, нибарысы дүрт шомырт алды. Туган як истәлеге дип. Кич саен Гыймран, Кави, Бакый, Нурсөя диеп исемнәрегезне санап елый-елый шуларга нидер пышылдый иде ул. Төшләремдә дә мин аның шомырт белән әвәрә килгәнен күрәм... Ә Сөнчәле таулары әүвәлгечә матур... — Кызның күзләре мөлдерәмә яшь иде. Менә эре-эре тамчылар Галиянең керфегеннән сытылып, яңакларын чылатты. — Биш яшьлек кызчык идем, ә барысы да истә... Һәр агачы, һәр үләне... Наратлар биегәйгән икән... Риваять язам, имеш. Максатым бөтенләй башка иде. Кипкән шомыртларны яшереп кенә ияләренә ташласам, бәлки, мәрхүмә анамның рухы тынычланыр, дидем. Кичерегез, мин бит аларның каргалган шомыртлар икәнен белмәдем. Кичерегез! Менә дүртенчесе... — Кыз тартманы ачты. Соңгы шомыртны бераз учында әвәләгәч, кире савытына салып, хатынның аяк астына куйды. — Синеке иде, Нурсөя апа...

*2007*

## Күкчәчәк

### 1

Җан нигә болай үрсәләнә икән? Кайта дип… Әйдә… кайтсын! Акыллы кеше бу авылга бүтән аяк та басмас иде. Аны зарыгып көтәләр диярсең. Кемгә кирәк ди ул! Әнә хуҗасыз йорты кукраеп утыра, аның пыяла күзгә охшаган тәрәзәләрендә салкын бушлык. Кайчандыр Күкчәчәк йотылып карап узган серле тәрәзәләр иде алар. Хатын гүя аңа гына Ходай тарафыннан язылып та чит-ят бусага төпләрендә адашып калган бәхетен карашы белән суырып алмакчы була, әмма шул мизгелдә ике күзенә әчеттереп яшь тула да, чирәмле капка төбеннән тиз-тиз чабулап үтеп китә иде. Ә бәхет, чынлап та, шушы йорт эчендә иде. Мирсәлим атлы иде ул. Нишләп Күкчәчәк газизенә чытырдап ябышмады икән?! Нишләп аны үзенеке итәр өчен суларда батып, утларда янмады?! Батты да, янды да анысы… Тик… мәхәббәт гөлләр сыман бик кыска гомерле икән: яши-яши дә... сула. Бүген хатынның күңеле кибеп корыган күл шикелле: хисләр сүнде, ярату үлде. Дөрес, кайчакта бәгырьнең бер нүешендә тилереп сөйгән көннәрнең кайтавазы ыңгырашып куя да үлгән йөрәгенә әбелхәят сулары бөркелгәндәй әллә нишләтеп сискәндереп уятып җибәрә. Әгәр шунда Күкчәчәк әз генә үткәннәргә табан талпынса, йомылган сөю күзәнәкләре терелер дә, яшь чаклардагы кебек, яңадан Мирсәлим дип шашыныр сыман иде. Йа Рабби, кайтаваз үзе нинди көчле! Аның сизелер-сизелмәс тоелган нәни генә дулкыны да бөтен җиһанны дерелдәтә иде. Ә элек миллионнарга тапкырланган гарасат иде бит ул! Шуңа ничек түзелгән икән?

Мәхәббәтең хакына төн уртасында төпсез Карасазда адаш, имеш. Хәзер хатын бу юләрлегенә шакката менә. Үз акылындагы адәм баласы сазга якын да килмәс иде. Ата-баба элгәредән үк бу урынны тикмәгә генә койма белән әйләндермәгән ләбаса. Су-мазар эзләп борын тыккан мал-туар аннан кире чыкмый, җир йоткандай югала иде. Ә Күкчәчәк сазга керде… Әй, тәненнән меңәрләгән кырмыска чабыша! Уйларга да куркыныч хәтта. Анда бөтенләй икенче дөнья иде бит…

Кайта, димәк. Төрмә өч ел гомерен ашады. Өч ел азмы, күпме? Мирсәлимнән биздереп суындыргач, аз түгелдер инде. Ә бу пырдымсыз хатынга нәрсә җитми икән? «Кайта» дигән хәбәр ник бәгырьне аркылы-торкылы кисә-телә? Кайтсын, кайтсын, кайтсын! Авыл урамнары тар мәллә?! Лотфуллага атып ни үзгәртте соң ул?! Бүген үзендә төрмә тамгасы, Лотфуллада уч. Ире һаман аңа теш кайрый. Алар нәселендә кичерү һәм гафу итү юк, алар миһербансыз кавем.

…Хатын озак кына Атауга карап торды. Ул тарафларда аңа берни дә кирәкми, аны уйлары җиргә кадаклаган иде. Көтү таралды, ә сыер күренми. Тагын Гөлсемнәр капкасына төртелде микән? Лотфулла үчкә ерактан кереште. Бәс, ул бит Мирсәлим белән беррәттән Күкчәчәкне дә җәзалый иде. Астыртын гына, сүзсез генә. Башта ир «кунаклар өе» дип салдырган ике катлы йортка Гөлсемне күчерде.

— Хуҗалыкка бик еш түрә-мазар килештерә, Гөлсем уңган, аш-суга оста, абзыйларны шунда гына сыйларбыз, сиңа да мәшәкать кимер, — диде.

Ул, күрәсең, хатынын беркатлы тилемсәгә саный иде. Әйе, Күкчәчәк гайбәт тыңламый, аңа — укытучы кешегә — чүп җыю килешми дә иде. Ә йөрәк барысын да сизә! Лотфулла белән Гөлсем арасында уен бар! Әлбәттә, хәйләкәр ир моны ачыктан-ачык танмады. Танган тәкъдирдә, буран кубып, хатын аерылып китәр дип шүрләде бугай. Йә, кем бәхетсезрәк: пары урланган Мирсәлимме, әллә көндәш белән ир бүлешкән Күкчәчәкме? Ир хыянәте әче, билгеле. Ләкин аның әчесеннән алай ук йөз чытылмас. Сер бирмичә яшәргә гадәтләнгән горур хатын әлеге дә баягы авылдашлардан уңайсызлана. Кемнәрдер сине йөз мәртәбә чәйнәп йота. «Хурлыгы-ояты бары шул гына», — дип, монысына да түзәр иде, соңгы көннәрдә Лотфулла аны Гөлсем көндәш белән бер бауга бәйләп тота башлады. «Кунак өе» — тыкрык башында, ә бакчалар — уртада.

Күкчәчәк күренсә, чиләк-көрәк күтәргән Гөлсем дә «җир астыннан» калка һәм:

— Сезнең бәрәңге эре, бүрек кадәр, эме? Өч-дүрт төп казыйм әле кунакларга бәлешкә, — дип, канны боза иде. «Кунак» бердәнбер санда, ул Лотфулла иде, әлбәттә.

Мирсәлим кызганыч, монда хатыны ят ирләр сыйлый. Авыздагы сөяксез тел еландай ысылдый шул. Бервакыт Күкчәчәк ярып салды:

— Нигә читләр өчен янасың? Әүвәл үз хәләлең турында кайгырт син. Төрмәгә барып хәлен белеш, һичьюгы!

— Мин ул бозаудан аерылдым, — диде Гөлсем, чиләгенә шалдыр-шолдыр бәрәңге тутырып. — Җәлләсәң, син бар. Сез бит аның белән теге ниләр…

Көндәш җөмләсен тәгәлләп өлгермәде, Күкчәчәк ыржайган бикәнең авызына вак бәрәңге кыстырды:

— Безнең исемнәрне гайбәткә буяма, яме?!

Чүмәшкән Гөлсем лып итеп артына ауды да бәрәңгене төкерде һәм, туфраклы иреннәрен кулы белән сөртеп:

— Кемнән яшерәсең инде кыеш-мыешларыгызны? Авылда һәммәсе дә беләич, — диде. — Безнең туй кичендә теге… Дөрес түгелмени?

— Синеке дөрес түгел, әйе!

— Кемнеке дөрес соң?

— Бер Аллаһыныкы! Ә сезнеке ялган! Барыгызныкы да чеп-чи ялган!

Әрнеп кычкырды Күкчәчәк. Ник каралталар, ник әллә ниләр гөманлыйлар?! Аларның берсе — саф кыз, икенчесе саф егет иде…

«Бәрәңгене яз чәчәсең, көз казыйсың, кырмавык хатын бүтән көн саен күз алдымда болганмас», — дип тынычланган Күкчәчәк уртак баудан һаман котылмады.

Картаеп сыерлары үлгәч, Лотфулла:

— Гөлсемнекен алабыз, аныкы яшь, матур, — диде.

Кемнең сарыгы бәрәнләгән дә, кайсысы ак, кайсысы кара йонлы булган — шуларга хәтле иренмичә тикшергән-күзәткән елгыр карчык-корчык Гөлсемнең сыерын мактамый иде.

— Ашыкмыйк, башка җирдән сорашыйк, аныкы сөткә кинәндермәячәк, — дип карышкан хатынның сүзен ир колагына да элмәде.

— Ишегалдына шайтанның үзен кайтарып бастырсам да ризалашырсың, — диде.

«Күбекләндереп бер чиләк савам», — дия-дия сатылган сыерның сөте савыт төбен дә күммәде. Моның чираттагы җәза икәнен аңлый иде Күкчәчәк. Менә көннәрдән бер көнне вак җанлы Лотфулла аны битәрләргә тотыначак. «Синең кулың каты, шуңа хайван сөтен качыра», — диячәк. И хатын, үзеңне яклап авыз ач әле! Мирсәлимгә тоташкан әллә нинди «гөнаһларың» су өстендә калкыр.

«Син аның кимчелеген белеп юри алдың», — дип бәхәсләшү файдасыз иде, Кукчәчәк табигатьнең хатасын төзәтү әмәлләрен эзләде. Сөт, ниһаять, тамчылап артты. Язга табан ул чиләген тутыра язды. Ләкин, көтүгә кугач, рәтләнгән-тазарган сыер Гөлсемнәр капка төбенә кайта башлады. Хайваннар да адәмнәр кебек саташа икән! «Әйдә, Акмуен», — дигәч, ул, кыш кышлаткан яңа хуҗабикәсенең назлы тавышын, йомшак кулларын исенә төшереп, күндәм генә арттан иярә иде. Ә иртәгәсен… яңадан шул ук хәл кабатлана! Һай, такылдык көндәш белән очрашудан гарык иде Кукчәчәк! Нишләтә бу хайван, йә?! Ник ул һаман саен шушы ят капкаларга ышкыла соң?! Охшаса да охшар икән мал иясенә! Ә Гөлсем — саңгырау колак — мөгрәгән сыерны тыкрык буйлатып кына озатмый, аңа агач телен юнып, шуны бүрәнә итеп юлга аркылы тәгәрәтергә кирәк. Көндәш ызгыш-талашка сусаган. Дәшмичә генә китеп барасы горур Кукчәчәк исә ирексездән аның «бүрәнәсе»нә абына.

— И Ходайның бәндәсе! Һич тынгы юк! Никләр хайваныгызны минем колак төбендә үкертәсездер. — Гөлсем, авызын кыйшатып кына, черт-черт көнбагыш чиртә иде. — Сөте имчәгеннән җиргә тама ич, сукырлар!

— Рәхмәт яусын, син безгә әйбәт сыер саттың, Гөлсем. Уңдык без, — диде Кукчәчәк, көлемсерәп.

— Уңдык, дип мыскыллыйсың бит син! Нишләттең малкайны, пәри заты?! Нинди догаларың белән әфсенләдең?! — Көндәш учындагы көнбагышын ачу белән сыер өстенә сипте. — Кәҗәдән дә хужы иде бит бу мәхлук! Тәүлегенә ярты стакан сөт саудыра иде! Икенчеләй турымда бакырынса, сәнәк белән корсагына чәнчәм!

Хатын җирдән таяк алып сыерга кизәнгән Гөлсемнең кулын читкә борды.

— Сукма! Бүтән ул синең тирәңдә сырпаланмас.

— Давай ыспурлашабыз, көтүдән туры монда чабачак мүкләк! Мине сагына ул, мине!

— Чапмас. Сиңа ул: «Сөтем ташый, күр», — дип исбатларга теләгән. Хайваннарда да кеше акылы бар. Мин дә аны саташкан дип ялгыштым.

— Саташыр әле, көт. Син әллә кемнәрне дә саташтырырсың. Мирсәлим төнлә исемеңне кычкырып, тирләп уяна иде әнә. Яшәтмәдең син безне татулыкта, әфсеннәрең белән ирне боздырып яттың.

«Сүзгә-сүз ялгама, кит!» — дип, үз-үзенә боерды Кукчәчәк. «Төнлә исемеңне кычкырып уяна…» Нәрсәдер йөрәкне умырып-умырып чеметте. Юк, көл тузгыган учакны яңадан кабызып, хисләрне терелтмиләр. Яшәү бер төстә генә дәвам итә. Ул инде элеккечә Мирсәлимгә багыналмый…

Сыер шул көннән соң Гөлсемнәр капка төбеннән бизде. Әмма азгын хайван, көтүдән качып, иркенләп басуда сыйланырга гадәтләнде. Лотфулла тагын хатынын гаепләде.

— Келәт тулы бодай, база тулы чөгендер, ник шуны иртән дә, кич тә лыкындырмыйсың! Бөтен кырымны таптатасың! Авылыгыз белән миегезгә чүкелдеме сезнең? Мал-туар урамда чирәм дә чемченмәсен диелдеме? Ишет, монда җиргә мин генә хуҗа! Безнеке димәм, теге вакытта ун мөгезне дөмектергән кебек, иген басуында очратсам, монысының да башына гөпелдәтәм.

Иренең янавы җилгә очмаячагы көн кебек ачык иде. Колхоз рәисе чагында ук Лотфулла кыр-басуда адашкан сыер-сарыкны фермага куып яптыра һәм «аяк хакына» штраф түләтмичә хуҗасына бирмәскә куша иде. Карчык-корчык чирек сарык бәясеннән торган «аяк хакы» — акча каян тапсын, авыл советы рәисе Мирсәлимгә елый-елый зарлана. Ә Мирсәлим «тоткыннар»ны азат итәргә фермага ашыга. Шуннан соң Кукчәчәк аркасында бишбылтыр ук дошманнарга әйләнгән ике ир маңгай белән маңгай чәкештерә… Лотфулла күлмәк изүләрен ертып кайтса, хатын сүзсез дә аңлый: Мирсәлим белән «чүкердәшкәннәр», чөнки авылда колхоз рәисе белән пәрмә-пәр сугышырлык гайрәтле кеше ул гына иде.

— Сөенмә, хәерчеләр чабатасының да кабыргаларын санадым, — дип, ир Кукчәчәккә бер генә җөмлә ташлый һәм, туксан тугыз терәү терәп, эченнән генә Мирсәлимне сүгәргә керешә. Дошманы белән хатынының да исемен янәшә куеп төрләндерәсе килсә дә, дөньясын шартлатырга җитәрлек микъдарда җыелган ачу төенчеген әлегә чишми, көчкә тыелып кала иде.

Бөлгенлеккә төшкән колхоз таркалгач, халык сарыклар төсле миңгерәүләнде. Бер яктан авыл советы рәисе Мирсәлим пай җирләрен сатмагыз дип үгетләсә, икенче яктан хәйләкәр Лотфулла, озын телле акчалар вәгъдә итеп, карт-корының нәфсен кыздыра иде. Рәисләрнең кайсысын тыңларга да белмәгән халыкның уңга-сулга борыла-борыла муены кәкрәйде. Ниһаять, авыл кыл урталай бүленде: «Мирсәлимнеке дөрес» диючеләр пай кәгазен сандык төбенә яшерсә, «Лотфулланыкы дөресрәк»ләр, зур акчага өметләнеп, үз өлешен яңа байга илтеп тоттырды. Тик Лотфулла кулыннан саран тиеннәр генә тамды.

— Ник кешеләрне алдадың?! — дип ачынды Кукчәчәк. Чөнки халык: «Ирең бәдбәхет», — дип, аның күзен ачырмый иде.

Лотфулла юанайган корсагын гына сыпырды:

— Үзләре бирде. Беркем дә көчләмәде. Хәерчеләр чабатасы ягына авышканнар да, беркөн каршымда тезләнеп: «Ал пайларны, Лотфулла», — дип ялварачак әле.

Җир хәтле җирне талаганда, Мирсәлим кул кушырып утырмаска тиеш иде… Җебегән түгел иде бит ул. Нишләп ир Лотфулла тозагына эләкмәгән ярты авылдан бер хуҗалык оештырмады икән?

Эчтән генә сызды Күкчәчәк. Әмма, Мирсәлимне очратып: «Тизрәк ертлачның юлына аркылы бас», — дип, Лотфуллага каршы котыртырга базмады. Гәрчә җаны бүтәнгә тартылып яшәсә дә, кеше күзендә ул аның ире иде, ире!

Яз көне Мирсәлим төркеме җирләрен чәчмәде. Кысыр басуларда кинәнә-кинәнә чүп үләне үсте. Җан тәслим кылган күмәк хуҗалыкның машина-тракторларын юнь генә бәягә үзенә саттырган элеккеге рәиснең исә кырларында эш кайнады. Көрәк-сәнәктән гайре коралы булмаган карт-коры хәлсезлеген чамалады да (үзе сабанга җигелсенмени) тасма тел Лотфулланың тәбәсенә аягын кыстырды. Җирен кочаклап уфтанган беркатлыларга: «Үз кишәрлегегездә чәчелгән бодайның яртысы сезнеке», — дигәч, халык кача-поса аның белән килешү төзеде. Бу гамәлен күрше күршедән, туган туганнан яшерде. Янәсе, Лотфулла белән бернинди алыш-биреш тә юк.

Әлеге хәлләрдән соң Мирсәлим көчсезлегеннән үкереп елагандыр, мөгаен. Күкчәчәк аны изелгән-сытылган кыяфәттә күз алдына китерде. Баш иелгән, җилкәләр салынган. Канатлары каерылган бөркет сыман, җирдән сөйрәлеп бара ир… Интегә-кысыла йөрәк түрендә яшәгән кешесен бу сурәттә күрүләре олы әрнүгә әвереләчәк иде. Әмма хатын Мирсәлимне бәяләп бетермәгән икән.

Туфрагыннан коймак пешерерлек басу-кырларны җиңел генә учына йомарлаган «яңа бай»: «Уңышның чыгышы начар», — дип, халыкка яртышар гына капчык бодай таратты. Менә шул көннәрдә гомер капкага орынмаган Мирсәлим аларга керде. Күкчәчәк өйалдында гөлләргә су сибә иде, сулышын эченә кысып, ишегалдында сөйләшкән ирләрне тыңлады.

— Синең азынуың чик-чамасыз икән, Лотфый, — диде рәис. Тавышы мескен түгел, таза-көр иде. — Башта алдап-йолдап хуҗалыкның бөтен милкен үз исемеңә күчердең. Аннары, ялган вәгъдәләр яудырып, пай җирләрен җыештырып алдың.

Лотфулла беркайчан да ахырга кадәр кешенең сүзен тыңламый иде:

— Булдыклылар заманы хәзер, бүректәш. Бура-Киртә кырлары ялт иткән. Чәчәм, урам, сөрәм. Ник тагы чырай сытасыз инде?

— Җирнең чын хуҗасы — халык, Лотфый.

— Кит аннан! Менәтерәк яңалык! — Лотфулла болытларга карап өргән ялкау эт төсле һауылдап көлде. — Пай дигән әкияти нәрсә уйлап чыгардыгыз бит сез, башсызлар! Шуны кәкре-бөкре карчыкка да, аксак-туксак картка да өләштегез. Имана җирләре белән бер үзегенә үткәннәр бит инде ата-бабаның. Ник аны «пай» дигән кушамат чәпәп кабат яңарталар?! Кәҗәсен җигеп сөрсенме ул җирен әби-чәби?! Орлыгын итәгенә салып чәчсенме?! Берсен дә өндәмәдем-үгетләмәдем, үзләре кишәрлекләреннән баш тартты.

— Кешеләрне син ялганлап ышандырдың, Лотфый! Әле икмәк амбардан кузгалмаган, әйдә, гадел генә халык белән исәп-хисап ясa.

Лотфулланың табанына ут элделәр.

— Тукта, тукта, бүректәш! Син бит минем өемә карт-коры өчен кайгыртып килмәдең, — диде ул, тешен шыгырдатып. — Син бит минем хатынны сагындың. Сез яздан тиклем күрешмәдегез, ахрысы, ә? Күкчәчәк! — Ир даң-доң өйалды ишегенә сукты. — Чык монда, Күкчәчәк!

Хатын дулкынлануыннан черт тә черт гөл яфрагы өзә иде. Ничек тыныч кына басып торсын ди ул! Иркә май җиле сыман исеп җан ярасын дәвалаган тавыш иясе ике-өч адымда гына… Хәзер ишекне ача да Күкчәчәк… Һәм нихәтле генә күрсәтмәскә маташса да, яшерә алмаган сөю-наз тулы карашы белән Мирсәлимгә текәлә… Әй, әйтергә генә ансат шул! «Йөрешләреңә кадәр яратам!» — дип кычкырган хатынны ерткыч бүре — Лотфулла — шунда ук мең кисәккә өзгәләп атачак.

Күкчәчәк бөрешеп диварга сөялде. Көнләшүеннән кабарынган Лотфулла йодрык уйнатырга сәбәп эзли иде. Ә хатынның ике арысланны сугыштырасы килми! Соң инде, соң… Нәрсә буләсең ди хәзер…

Шапылдап капка ябылды. Күкчәчәк, тәрәзә пәрдәсен чак кына этәреп, тышка карады. Лотфулла, йомарланган йодрыгы белән һаваның йөзенә төя-төя, ялгызы гына ишегалдында йөренә иде.

Мирсәлим куркыныч давылны үзе белән ияртеп китте, шөкер. Әллә… Күкчәчәкне күрмәс өчен тизрәк баш-аяк алдымы? Кара, болай уйласаң, йөрәккә бик авыр икән лә.

Лотфулла белән Мирсәлим күз буе икмәк өчен тартышты.

«Ул, хәерчеләр чабатасы, җыенда гына тел кашырга мачтыр, болай аның районда да, Казанда да сүзе үтми», — дип кәпрәйгән ирнең «бүректәш»е суд карары белән амбарны бушаттырды. Ат арбасы тәгәрмәчләре, «шыгыр» көенә җырлый-җырлый, авыл халкына бодай ташыды. «Бу җиңелү Лотфуллага сабак», — дип уйлаган хатын ялгышты: ире — явызлыкның бер мисалы, фермадагы яшьләрне куып, күрше авыллардан эшчеләр ялллады.

— Хәерчеләр чабатасы Бура-Киртәне бүкән төсле икегә ярмакчы, — диде Лотфулла, нотыгын хатыны колагына көйләп. Әйтерсең боларны Күкчәчәк түкми-чәчми Мирсәлимгә җиткерәчәк. — Җу-ук, чабаталы агай, бурасы да, киртәсе дә минеке! Революциягә кадәр авылда берәүгә генә бил бөккәннәр. Ул заманалар ялтырап кире кайтты бүген. Кем дә кем әмеремә буйсынмый, ачлыктан тәгәрәп үләчәк. Бакчасын сөрдертмим, печәнен чаптыртмыйм, вәйт. Хәерчеләр чабатасы Мирсәлимгә көн күрсәтмим, кыскасы.

Көрәш кызды. Яз җиткәч, Мирсәлим, ягадан трактор китертеп, хуҗалыкларның бакчасын сөрдертте. Лотфулланың җиңелүе дәвам итә кебек иде. Ләкин алай булмады шул. Яңа гына оя сипләп, балалар үстергән яшь парлар, ни чарадан бичара дигәндәй, йөз суын түгеп, хуҗадан эш сорарга мәҗбүр иде. Шунда Бура-Киртәнең бердәмлеге пыяла кебек чатнады. Мирсәлимне үзәккә — хакимияткә күчәргә кыстадылар. Ник ул ризалашмады, ник адым саен Лотфулла белән чәкәләшер өчен авылда калды икән?! Явыз бүрегә каршы яланкул кем көрәшә ди! Мөгаен, күрәчәге җибәрмәгәндер аны, күрәчәге аяк чалгандыр. Хәзер аңа, өч елдан соң, кабат ут эченә ташланмаска иде! Ул төрмә иләгендә иләнгәндә иркенәйгән Лотфулла тәмам ныгыды: үзен яклардык түрәәшнәләр тапты, алар белән элемтәләрне саклар өчен ау көннәре оештырып, тәм-том белән сыйлады, аулакта кызлар кочтырды. Капкорсаклы, симез кызыл чырайлы «абзыйлар» эчеп исерешкәч гөп тә гөп Карасаз кырыенда очкан кошларны ата иде. Бервакыт Лотфулла өч үрдәк кайтарып ташлады.

— Тиз генә мамыгын йолкып, чистартып бир! Кайнар көлгә күмеп пешергән үрдәк ашаган юк, диләр кунаклар.

Үрдәкләрнең берсе үлмәгән иде. Кош-кортны болай да җәлләгән Күкчәчәк нишләргә дә белмәде. Лотфулла, ярты сәгатьтән кайтып алам, дигән иде. Ул инде кызганмаячак, ул инде кайнар суга манып-манып үзе пешекләячәк. Андый газаплы үлемнәргә тармасын өчен үрдәкне күрше Имам карттан чалдырырга кирәк иде. Тик хатынның моңа да кулы бармады. Бичара кош, тимә, сакла дигәндәй, күзгә карый иде. Ахыр чиктә ул, аны абзарга яшереп, йорт үрдәген суйдырды. Кыргыйның канаты гына яраланган иде. Күкчәчәк шифалы сулышын өреп, атна-ун көн дәвалагач, кош тернәкләнде.

Үзебезнең үрдәкләргә кушсам, Лотфулла сизмәс дигән иде, кая ул, ире, бәбәген алартып:

— Нинди саз үрдәге бу?! — диде. — Кем аны йортка ияләштерде?!

Күкчәчәк алдашты:

— Ишегалдына үзе очып төште.

— Бодай тыгыныр-тыгыныр да кире сазына таяр әле, — дип мыгырданды Лотфулла.

Ә үрдәк беркая да качмады, ул нигәдер шушы йортка беректе. Тик аның күңеле каядыр ашкына сыман. Һәм бу кыргый җан белән хатын арасында икесенә генә мәгълүм уртаклык та бар кебек. Төркем-төркем кошлар тәпи очы белән өй кыегына орынып очып үткәндә, Сорыкай да аларга иярмәк булып канат кага, әмма симергән гәүдәсен җирдән куптаралмый… Менә Күкчәчәк тә яшәүләре тәмугка тиң йорттан арынырга уйлаган иде дә, яшьлеген урлап картайткан еллар тырнагыннан ычкындырмый шул әле.

Әллә үзен кош язмышы белән чагыштырулар башына сукты, әллә монда бер-бер хикмәт яшеренгән иде, өч төн рәттән төшендә үрдәк, адәм теле белән:

— Син мине бәладән коткардың, озакламый мин дә сине коткарырмын, Күкчәчәк, — диде.

Хыялый хатынның мондый төшләр белән саташуы табигый иде анысы… Чөнки ул төшләрендә генә рухтан гыйбарәт якты һәм гүзәл дөньяда яшәп ала иде.

Каз-үрдәк өмәләре якынлашкач, Күкчәчәк Сорыкайны үткен пычактан сакларга ниятләде. Карасаз эчендә зәмһәрир суыкларда да боз катмаган хикмәтле күл бар, һәм анда ел саен ике-өч пар үрдәк кыш кышлый иде. Ул кошны капчыкка төреп үз аймагына табан очыртырга дип капка келәсенә орынганда гына, Лотфулла күлмәк җиңеннән эләктерде:

— Юри сарай читенә посып карап тордым. Нишли бу ахмак хатын, мәйтәм. Кая барышы үрдәк белән икәүләшеп, мәйтәм.

— Саз... сазына илтәм… — Күкчәчәк алдашып туйган иде. — Ул табигатьтә иректә яшәргә яратылган.

— Минем бодайны состыра-состыра симерткәндә ирек турында уйладыңмы соң син?!

— Бер үрдәктән генә бөлмәбез әле, Лотфулла.

— Бүген син — үрдәкне, иртәгә — сыерны, берсекөнгә атны чыгарып ыргытырсың, ахмак хатын! Дәүләтнең хәзинә сандыгын синдәй тиле юмартлар бушата. Калтыранма, хатын! Суймыйм мин бу саз кәрләсен, йортныкы белән парлаштырып, яңа сорт бәбкәләр үрчетербез. Болар тырыш, уңган нәрсәләр, оя-оя бала үстерерләр.

— Ут белән уйнама, Лотфулла! Алар ябулы тормышка күнекмәгән, аларның җаннары үзгә!

— Син дә Бура-Киртәдән очып китәргә маташтың да калдың бит оянда. Минем белән калдың! — Ир кисәк кенә капчыкны тартты: — Моны аерым ябам! Качырсаң, үтерәм!

Кыр үрдәге, язгы үләннәр борынлауга, йомырка салырга кереште. Салды-салды да зур әрҗәгә менеп тә утырды. Ул, бала хәстәре белән мавыгып, үзенең кыргый табигать вәкиле икәнен дә онытты шикелле. «Кошлар да коллыкка риза икән, — диде Күкчәчәк, шаккатып. — Әгәр шулай икән, димәк, тиздән ахырзаман җитә».

Әрҗәдә сары йомгаклар пипелдәгәч, Лотфулла, канәгать елмаеп:

— Җаннары үзгә, дисеңме, хатын? Минем кулга эләккән киек-җанвар йортныкы була да куя ул, — диде.

Ышанмады Күкчәчәк. Үрдәккә ышанмады. Аны табигать барыбер кире чакырачак, һәм ул бөртек сибелгән тук ишегалдын куркыныч, әмма ирек тәме сеңгән татлы тормышка: чумып-чумып йөзгән күл-елгаларына, канат җилпегән һава юлларына, алтын төскә манчылган сагышлы көзләренә алмаштырмаячак иде. Әнә Мирсәлим дә шулай бит: шәһәрдә төпләнмичә, газап чиктергән туган җиренә әйләнеп кайта. Юкка тиргидер ир-егетне Күкчәчәк, юкка…

**2**

Аңа хәтле Бура-Киртә тагын бер кешегә артты. Лотфулланың унике ел элек югалган үги атасы кинәт кенә пәйда булды. Аның кулында иске чемодан иде. Ул бау белән бәйләп аркасына аскан эреле-ваклы байрак-әләмнәрен ишегалдына аударды да, күзләрен челт-челт йомгалап:

— Уф, йончытты, — диде. — Менә безләр, балалар. Саумы-арумы, улым?! Саумы-арумы, килен?! — диде.

— Хи-хи, сәяхәтче бака исән икән әле. Урманнан мунча ягарга утын да төягән.

Лотфулла аке аяклы табылдыкка сөенмәде, әтисе белән салкын гына күреште.

— Мин бака түгел, улым, мин — Лелин, — диде карт. — Утын да түгел бу нәмәләр, изге байрак алар. Безне Бура-Киртәгә рибалютсия ясарга җибәрделәр.

— Кемнәр, Сабирҗан әти?

— Көрәштәшләр, бакчи.

— Кая соң алар?

— Үлделәр инде.

— Революция корбаннары булдылармыни?

— Юк, улым, картаеп гүргә иңделәр.

— Синең, Сабирҗан әти, безнең белән яшәгәндә үк шөрепләрең бушаган иде. Ә хәзер, о-о, сәвсим башыңда җилләр сызгыра! Кругом тишек!

Өч сыйныф белемле Сабирҗан абзый элек авылда партия секретаре иде. Җаны-тәне белән халыкны Ленин юлыннан тайпылмаска өндәгән кызыл коммунист картаеп кына Лотфулланың әнисенә өйләнде. Тол хатын аны бер генә максат белән йортка кертте: башкисәр Лотфулла ир-ат кулында чыжлаган каеш тансыклый иде. Әмма үги ата ун яшьлек малайга чәнти бармак белән дә чиертмәде: ул малайны үз ысулы белән тәрбияләде: ашыйсың киләме, эшләп аша! Менә сиңа Ленинның беренче томыннан фәлән әсәр, укы да тотлыкмыйча гына эчтәлеген сөйлә. Шуннан соң кашыкка үрелерсең. Әһә, киногa акча кирәкме? Революция турында җыр ятла, җырламасаң да шыңшып күрсәтерсең.

Ил-көндәге үзгәрешләр партияне таркаткач, кызыл агай Бура-Киртәдән каядыр китеп барды. Лотфулланың әнисе аңа гашыйк иде. Телендә сандугач биетә, сүгенми-кыйнамый, назлы-ягымлы Сабирҗан коммунист. Авыр тормышта изелгән авыл хатыны өчен бәхет иде бу. Карчык үлгәндә улы белән килененә гозерләп-гозерләп соңгы васыятен әйтте:

— Атагыз йөремсәк кеше, ят җирләр гизеп туйгач, беркөн ишек шакыр. Бусагадан бормагыз, урынын түрдән бирегез, — диде.

Сабирҗан карт баядан бирле өйалды ишегенә карый иде.

— Әнкәгез, дим, нишләп озак мыштырдый, дим? Мине сагынмады микәнни?

— Әнине җирләдек шул, — диде Күкчәчәк.

— Ашыккан икә-ән, — диде карт, еламсырап.

Лотфулла шуңа дөрләп кабынды:

— Кара, турсая берәү! Син анда авыл саен, шәһәр-калалар саен ялгыз хатыннар җылытып йөргәндә, ул үлмичә сине көтсен, имеш!

— Хатыннар җылытмадым мин, улым. Рибалютсия утын сүндермәскә тырыштым. Тик ирек бирмәделәр. Соры кортлар басты илне, капкорсак буржуйлар басты. Лелинга рәт бетте. Ничава, арт сабакларын укытабыз әле. — Сабирҗан карт кыршылган иске фанер чемоданыннан калкынып аягына басты. — Яшәсен каммунислар партиәсе! Лелинга дан!

— Шаулама, прәс! — Ире үги атасын төсе уңган күлмәк чабуыннан тартып урынына чүктерде. — Синең эшләр хана икән, революционер. Башыңа йөгергән икән Ленин томнары. Без үзәктәге картлар йорты директоры белән әшнәләр. Шунда урнаштырырбыз, үз ишләрең янына. Рибалютсиягезнең утын да бергәләп кабызырсыз.

Күкчәчәк кулы белән бөкрәйгән картны каплаган ишарә ясады:

— Тимә инде син аңа. Читкә какма. Мәрхүмә әни, урынын түрдән бирегез, диде. Оныттыңмыни, Лотфулла? Наил хәзрәттән сора, ул да ишетте.

— Нинди васыять?! Аның бит әнә «түбәсе» кыйшайган. Нормаль кеше түгел ул!

— Кыйшаймаган, Лотфулла! Карт үз заманыннан бу чорга күчалмаган гына.

Лотфулла, башын учлап, уңга-сулга чайкады:

— Ну кортка-а! Миңа үчләшеп шундый мәгънәсез васыять әйтеп киттең син! Күкчәчәк җүләрдәше бу. Ну, матри, Сабирҗан эти, революция ясыйм дип, авылда кеше генә көлдер! Бу таякларыңны яшер, күземә күрсәтмә!

Ир әләмнәр бәйләмен тибеп тузгытты. Шул чакта карт, үзенә суккандай, җыерылды-кечерәйде. Менә тагын берәүнең үзе төзегән һәм үз хыялларына инанып яшәгән дөньясын ваталар. Теге елларда алар миллионлаган, иң акыллы, иң зирәк һәм иң дөрес затлар иде. «Коммунистлар җүләр» дип пышылдап кына кара, телеңнән асулары мөмкин. Бүген алар берән-сәрән генә... Хәзер авыз тутырып «ахмак» дип хурла, беркем дә тыймый.

Сабирҗан карт, күндәм генә: «Ие, улым, ие», — дип ияген селкетсә дә, әләмнәрне яндырмады: мунча башына ыргытты. Килен сатмаячак, чөнки ул «җүләрдәш» иде. «Рибалютсия» дип әтәчләнгән картның әзрәк кикриге шиңде. Буржуй дошман кем дә түгел, үзенең үги малае икән ләбаса! Шушы яңалыкларны белгәч, «Лелин бабай» өч көн авырып түшәктә ятты. Әмма «изге» ниятеннән дә чигенмәде.

— Ни киңәш итәсең, килен? Бура-Киртәдә камунис исеменә тугры кешеләр бар микән? Миңа көрәштәшләр төркеме туплыйсы ие, — диде ул.

Һай ерак иде картның беркатлы хыялыннан Күкчәчәк, һай ерак иде! Ул, битарафлыгы белән аны рәнҗетмәс өчен генә:

— Лотфулла бу шөгылеңне яратмас, эти, — диде.

— Аңа кем сызгырган?! Мин чын бәлшәвикләр кебек яшерен оешма төзим, килен.

Лотфулланың үги этисе белән булашырга кәефе юк иде әле. Карт чиратның койрыгына күчеп, алга кинәт кенә Күкчәчәк чыкты. Бүген-иртәгә Мирсәлим кайтырга тиеш, ботак очы туганнары аның йортында тәрәзәләр юа иде. Боз кебек салкын пыялалар җылынмаса да, кояшта ялтырый. Хәзер көтү каршылаганда гел алар турыннан үтәргә туры киләчәк. Хәзер бер аяк басуларың мең газап булачак.

Төшке ашны «кунак өе»ндә генә капкаларга гадәтләнгән Лотфулла үз урамына турылаган иде. Ул машинасы белән капка баганасын сөзеп үк туктады да ажгырып хатыны каршысына атлады. Йөзе җир төсле каралган, күзләре кызарган иде. Сүзенә буылганга күрә, ир бүртенеп берара дәшмәде. Әмма йодрыклары әллә ничә кисәккә сугып ярырга әзер иде. Күкчәчәкнең йөрәк тибеше сүлпәнләнде. Юк, Лотфулла кыйнар дип курыкмады ул. Бу бәндә белән яшәлгән гомердә ничә кат үлде дә ничә кат терелде инде. Мирсәлим кайткан, димәк… Аның шунысы куркыныч иде. Мирсәлим кайтка-а-ан.. И-и, эчтә нидер өзелде, өзелде… Ыңгыраша-ыңгыраша өзелде… Бүтән яратмыйм дип мең дә бер мәртәбә тәкрарлаган иде юкса! Өч ел үзен шуңа әзерләгән иде-е-е! Әй, үртисең дә соң син, язмыш!

Кайнар дулкын аны аяктан егарга теләгәндәй айкалдырды-чайкалдырды.

— Сиңа тимим мин, аңгыра! Хәерчеләр чабатасын гына чүким! — Ирнең гыжлавык сулышы колак яфрагын пешерә иде. — Шуннан соң син үзең үләсең! Саргаеп. Өч елга гына түгел, мәңгелеккә китәчәк сөяркәң.

Сөяркә булалмады шул Мирсәлим. Җаннар кебек тәннәр дә кушылып өлгермәде. Бу ир аны белә, әмма ул иң-иң нечкә җиргә — бәгырьгә пычак белән сызып, мең дә бер мәртәбә әрнетеп тәм таба.

— Хатынын җибәр менә син, Гөлсемне. «Кунак өе»нә икенче хуҗабикә эзлә.

— Сөяркәң өчен кайгырасың, әйеме? — диде Лотфулла, хихылдап. — Бар, җаным дип каршысына чап!

Чапты Күкчәчәк, ничә еллар аның каршысына чапты. Төшләрендә… Нибарысы төшләрендә... Иркәназ татымаган хатын аңа йөгереп килә дә тәнне изрәтерлек кайнар кочагына сеңеп бетә иде… Ә өнендә исә бу хакта уйларга да ярамый шул.

— Ачуыңны миннән алма.

Күкчәчәк бу сүзләренә үзе дә аптырады. Нәрсә ди ул? Әйтерсең бүген генә явыз карга озын томшыгы белән җанын чукый! Шыгырдаган теш, йомарланган йодрык, әрем әчесеннән дә әчерәк тел — аның гомерен бизәүче «кара бизәкләр» иде.

Ир, иреннәрен түгәрәкләп, «ух» дип һавага өрде.

— Атты бит ул миңа, каһәр. Мине үтереп, сиңа өйләнмәкче иде, каһәр!

— Ник һаман моны тискәре ягы белән әйләндереп куясың, Лотфулла! Син аны үзең мәҗбүр иттең! Бүген дә сиңа бөтен авыл нәфрәтләнә. Кырда нишләгәнеңне хәтерлә син!

Ачык капкага карый-карый турдан кешеләр уза иде. Хатын, чиләген эләктереп, ян бакчага кереп китте. Йөрәге дөп тә дөп кага иде. Мирсәлим кайткан, димәк… Әллә ничек, бертөрле генә аккан соры көннәрне яктырган да сыман… Җанда да татлы сыкрау иңри сыман… Барысы да үлде-бетте дигәндә… Яраткан кешең белән яшәү ничек була икән ул? Иртә дә, кич тә син күреп туялмаган нурлы йөз, ишетеп туялмаган тәмле сүз, назланып туялмаган кочак… Мирсәлим белән Күкчәчәк әнә шулай мәңге яратышып яшәргә тиеш иде. Хатынның әле дә күз алдында: кыз чыркылдап көлә, ә егет Карасаз өстендә пырхылдап очкан кыр үрдәкләрен саный.

— Ничә үрдәк, шул көннән безнең туй. Берәү, икәү, өчәү, дүртәү… Унике… Унике көннән! Анда кадәр ничекләр генә сабыр итәргә, Чә-чә-әк!

Бәндә артык шашынганда, бәндә артык очынганда, аһ, сикерәләр, аһ, ялгышалар, дип, фәрештәләр зар елыйдыр, мөгаен. Күк каләмнәре теркәгәннәр белән җирдә язылганнар бик сирәк тәңгәл киләдер. Сирәк кенәме? Бәлки, тоташтыр. Кемгә бакма, баш-аягы белән хатада. Туй бәйрәмен ашыктырып йөргән бәхетле көннәрнең берсендә Күкчәчәккә әллә нинди сәер чир йокты: башта ул мәктәп бакчасында балалар белән чүп утаганда аңын җуеп егылды. Мирсәлимнең әнисе — өлкән яшьтәге укытучы — «эссе сукты» дип, аны бүтән кояшка чыгармады, ләкин ышыкта да шапылдап авулар ешайды. Бу зәхмәтнең бердәнбер шаһиты булачак каенанасы Гөлйөзем апа иде.

— Әни безгә кысыла дип яратмассыз да инде, кызым. Мирсәлим белән киңәшеп, туегызны ике-өч атнага кичерегез, — диде ул. — Син әүвәл терел инде, кызым.

Һәр мизгелен зарыгып көткән никах көнен күчерү яхшы фал түгел иде. Анда ук сизде йөрәк! Күңел салып яраткан пары белән сирәк кешеләр кавыша шу-ул…

— Мирсәлимгә ничек дияргә соң?

Күкчәчәк туйны өзәрлек сәбәп эзләде.

— Авырыйм димә, кәеф юк дип хәйләлә, — диде Гөлйөзем апа.

— Болай алдашу ярамас бит инде.

— Ә син ир-ат сырхау кыз белән никахланырга атлыгып торыр дисеңме?

— Ул, бакага әверелсәм дә, миңа өйләнәчәк, Гөлйөзем апа!

— Ай-һай, кызым! Кайсы ир авызыннан күбек агызып җирдә бәргәләнгән хатын белән кочаклашып ятар икән! Өянәгең кузгалгач син бит бигрәк чиркаңыч буласың. Туры сүзем өчен үпкәләмә тагы.

Йа Алла, Мирсәлим «болын чәчәгем» дип атаган кыз шундый да ямьсез кыяфәткә керәмени?!

Ул елый-елый туй күлмәген җөен җөйгә сүтеп ташлады. «Күлмәгем ямьсез иде, яңасын тегәм», — дигән сылтау егетнең башына сыймады.

— Ник юк мәшәкатьләр белән вакытны сузасың, арыш капчыгы кисәң дә син миңа матур бит, — диде Мирсәлим, күзләре белән сөеп.

Ә Күкчәчәк үзенчә ялынды:

— Ике генә атнага сабыр ит инде, җаным. Ак күлмәксез нинди кәләш ди ул.

Тик бәйләнчек чир кырмавыктан да зәһәррәк иде. Хәзер инде булачак каенана да, үтәр, үтәр, көннәр кызу шул, дип юатмый, ул да пошаманда, ул да борчуда иде.

Беркөнне укытучылар бүлмәсендә икәүдән-икәү генә калгач, Гөлйөзем:

— Күкчәчәк, сиңа сүзем бар, — диде. — Син тәрбияле, белемле яшь мөгаллимә. Син миңа үз балам кебек якын. Мирсәлим белән сез өйләнешергә җыенгач, үлеп шатланган идем. Мәйтәм, улымның бәхет күмәче ишелеп уңды. Тик, сеңлем, син безнең йортка төс түгел бит әле. Ни бит… Сиңа эссе суга дип йөрибез дә икән… Ул ни икән, ни… нәселегез авыруы икән. Нәкъ синең яшеңдә мәрхүмә әбиеңне үз чире тота башлаган, диләр. Күршесе Бибинур абыстайдан белештем. Көненә өчәр егыла иде, ди бичаракаем.

— Мин… мин әбине хәтерләмим. — Күкчәчәк сулаган сулышына пешә иде. — Мин бәләкәй чакта үлгән ул. Тел төбеңне аңламадым, Гөлйөзем апа.

— Тел төбе, дип… Төбе-өсте шул инде, сеңлем, мин улыма чирле хатын алдырмыйм.

— Без бер-беребезне яратабыз, Гөлйөзем апа!

— И-и, яратабыз, имеш. Нәрсә дисез соң ул мәхәббәтне! Куык ич ул, куык! Гаилә коргач, шартлый.

— Юк, безнеке шартламый, шартламый! — дип илерде кыз. — Мин үз хәлләремне үзем Мирсәлимгә сөйлим.

— Сөйләп вакыт әрәм итмә, алдына гына егыл, сеңлем. Бәбәкләрең акайсын, авызыңда күбек кайнасын, кул-аягыңны көзән җыерсын. Менә шул чагыңны күрсәт аңа!

— Мәрхәмәтсез син, Гөлйөзем апа!

— Мин газиз улымның бәхетен яклыйм, сеңлем. Нәсел чире ул анадан балага да күчә. Ә миңа гарип оныклар кирәкми. Их, егылгач та ни тамаша кыланганыңны үзеңә дә күрсәтәсе иде.

Күрде үзен, читтән күрде Күкчәчәк. Тузан эчендә бәргәләнгән сылу гәүдә кызганыч шул. Мирсәлимнең йөзен дә шәйләде кыз. «Гүзәл чәчәгем», — дип, иреннәреннән үпкән егет аңардан җирәнә иде… Әй тәгәрәп кенә үлсәң икән! Ходай Газраилне җиргә юллап, җанын тәннән аерсын иде. Мирсәлимсез яшәү яшәүмени ул?! Дөм караңгы баздагы сукыр тычканга хәтле яктылыкка өметләнгәндә, аның күңел дөньясында беркайчан да чәчрәп кояш кабынмаячак.

— Зинһар, Мирсәлимгә минем чирем турында белгертмә, Гөлйөзем апа.

— Тәки үз телләрең белән әйтәсеңме?

— Юк, әйтмим, Гөлйөзем апа.

— Ялган белән кияүгә барсаң, бәхиллегем юк!

Күз яшенә коенган Күкчәчәк әкрен генә сорады:

— Мирсәлимгә ни диим соң инде?

Кыз сыгнач-сыгылгач, Гөлйөзем укытучы да йомшарган иде.

— Үзеңнән тизрәк биздер, сеңлем. Берәр егыл да…

Юк, юк, яраткан кешесе янында үз чире кузгалудан Алла сакласын! Мирсәлимнең хәтеренә ул гүзәл сыйфат-рәвеш белән уелырга тиеш. Мәңгегә… Гомергә… Болын чәчәге тузанга буяламыни!

— Атна-ун көнгә шәһәргә китәм мин, Гөлйөзем апа.

— Кая, сеңлем? Дусларыңамыни? Җир читеннән дә эзләп табачак ул сине. Кал, дисәң, синең хакка калачак та. Бердәнбер терәгемне ягага сөйрәмә инде, бала-а!

Иртәгәсен мәктәп бакчасына колхоз рәисе керде.

Ул:

— Бер атнага Казанга китешем, ял йорты директорына өч-дүрт баш яшь кәбестә кисеп, машинага ташлагыз, кызлар, — дип боергач, тирләгән муенын сөртә-сөртә куак ышыгына чүмәште. — Уф, эсседә май эри, ахрысы. Күкчәчәк, салкын су эчертер идең.

Тирә-яктагыларның хәрәкәтен дә, тавышын да тоймас дәрәҗәгә җитеп кайгысына чумган кызны Гөлйөзем төрткәләп айнытты:

— Су, ди Лотфулла, су, ди. Әйдә, сеңлем, колонканың тимере каты, икәү агызабыз. — Су алганда карт укытучы, пышылдап кына: — Рәис ял йортына бара, — диде. — Утыр да кит!

— Кая? Нигә?

— Бәрәч, дусларыңа!

— Мин автобус белән барам.

— Юк, син нәкъ менә Лотфуллага утыр!

— Үз акылыңдамы син, Гөлйөзем апа?! Мирсәлимгә ишеттерсәләр, үлгәндә дә гафу итмәячәк бит! Азгын Лотфуллага этен дә ияртеп җибәрми кеше.

Хатын чиләктәге суны чайкалдырып кызның аягына түкте.

— Һаман минем улыма дәртләнәсең икән, үз чирле!

Өтте-куырды нәфрәт катыш сүз Күкчәчәкне! «Үз чирле…» Ачуы килгәндә Мирсәлим дә шулай дип кычкырса? «Үз чирле…»

…Ул рәис машинасына утырганда, укытучылар шаккатып карап торды. Гөлйөзем апа бәхетле иде. Ходай ансат кына «үз чирле килен»нән коткара! Хәзер Мирсәлимгә ниләр генә лепелдәмәс инде ул: «Яңа күлмәк тегәм дип, туй көнен юри күчергән, улым. Лотфулла белән чуала икән, улым. Әнә бергә ял йортына тайдылар, улым. Әни алдаша дисәң, укытучылардан сора, улым…»

Кызның чәчен тузгытып уйнаган җилдән дә көнләшкән Мирсәлим, әлбәттә, ышана. Юк, ышанмый. Егет Күкчәчәкнең аны гына ятратканын белә. Юк, ышана! Чөнки хыянәтчене мәктәптән ун пар күз озаткан!

…Күкчәчәк эче пошып әйләнеп кайтканда, Бура-Киртәдә дөньялар үзгәргән иде инде. Күңелнең бер почмагында: «Мирсәлим барыбер минем белән күрешеп, энәсеннән җебенә кадәр төпченәчәк», — дигән нәни генә өмет уты пыскып янды. Күрешмәде, төпченмәде горур егет! Гөлйөзем апа купайткан гайбәт үз эшен эшләгән иде. Гарьләнгән Мирсәлим: «Ул йөз хатын белән чуалган итәк колын сайлаган икән, мин дә аңардан калышмыйм, йөз ир белән йоклаган җилбәзәк Гөлсемне ярәшәм!» — дигән, имеш. И кодрәтле Алла! Бер-берсе өчен ярaтылган ике сөю тамыры кеше калдыклары белән бәхетләрен җимерергә тиеш идеме соң!

Күрше авылда үләннәр белән дәвалаучы имче бар. Җаны тартмаса да, Күкчәчәк шунда барды. Турда өч хатын таптана иде. Карчыкның җайсыз чагы икән, капкасын бикләп, чаш та чош ишегалды себереп маташа:

— Женнәре котыра, — диде каратутлы. — Бәлки, әзрәктән ипләнер. Синең кай әгъзаларың авырта, үскәнем. Чирең нинди? Духтырлар ни диләр?

Кинәт капканың тимер келәсе шылдырады, һәм ак яулык өстеннән башына ямаулы бүрек кигән карчык, себеркесе белән каратутлы хатынга селтәнгәндәй итеп:

— Төпченмә, марҗа, — диде. — Үзеңнекен генә бел дә тор, — диде. — Нишләп соңардың, бәбкә? — Күкчәчәккә ул йомшак тавыш белән эндәште: — Бетеренгәнсең бит, бәбкә.

— Аны чиратсыз кертмә, Тутыйбикә әбекәй, — диеште хатыннар.

— Көш-көш, шайтан токымы! Ирләрегез белән чәкешеп аракы эчәсез дә, зәхмәтләнгәч, дәвасын сорыйсыз. Әүвәл бирәнегезне тыегыз! — дип, имче тагын бер тапкыр себеркесе белән селтәнде дә кызны үзенә табан тартты. — Уз, бәбкә. Иртә-кич күз яшең кипми икән. Тәкъдирне беребез дә үзгәртмәс, бәбкә. Ходайдан сабырлык сора. Чирең язгы ташулар күек агып китә, бәбкә. Бала вакытыңда елан оясына баскансың. Җиләк аланында. Миеңә курку оялаган. Шул хәзер уянган. Ә куркуны курку белән чөйләргә кирәк. Төнлә, илаһи чибәр тулы ай яктысында, Карасазга кер дә таң атканда гына чык.

Күкчәчәкнең беләгендәге бала йоннары кабарды. Карчык күрәләтә үлемгә этәрә түгелме соң?! Саздан кеше исән чыкмый, саз «эһ» дигәнче аска суыра. Кыз дивардагы кадакларга эленгән бүктәр-бүктәр үлән-тамырларны күздән кичерде. Имче кипкән-корыган болын уртасында тереклек итә сыман иде. Аңа дигән дәва бардыр инде ул. Карчык «саз» дип көлеп кенә үртидер.

— Синең чиреңне үлән генә җиңми, бәбкә. Өрекмә, сакчы фәрештәләрең баскан эзләреңә канатын җәяр, бәбкә. Ныгытып тыңлый гына күр: саз түмгәкләр белән чуарланган. Керә-керешкә ике түмгәкне сикереп, өченчесенә бас. Чыкканда киресенчә, берәүсен генә сикер, бәбкә.

«Карасазга кертеп мине үтермәкче була карчык. Нинди җәзалар белән җәзалыйсың тагы, Ходай?!» — дип, юл буе яшь түкте Күкчәчәк. Ә аннары…

— Килен, кулың коргыры, нишләп син мәк чәчәкләрен сындырасың?!

Хатын сискәнеп башын күтәрде. Кайда ул? Ник чәчәкләр ботарлый? Имче карчыкка рәнҗи-рәнҗи әле генә юлдан йөгерә иде ләбаса.

— Кызыл төс — әләм төсе, килен. — Сабирҗан карт дырык-дырык ян бакча капкасын селкетте. — Партиәгә дан! Яшәсен Лелин!

Урман очыннан күкнең чибәр йөзен буйый-буйый әрсез тузан болыты йөзеп килә иде. Көтү! Нинди эчпошыргыч мәгънәсез тормыш бу. Тамак өчен тереклек итәләр: көн дә бер үк шөгыль, бер үк уй, бер үк юнәлеш… Ә барысын да уймак хәтле генә авыз йота! Ләкин бүгеннән соры һәм күңелсез тормыш үзгәрәчәк… Чөнки Мирсәлим кайткан… Әнә күңел ничек уйный: әле сыкрана, әле очына. Көтмим, яратмыйм, күралмыйм дигән хатынның аңында кайтавазлар ешайган саен ешая…

Күкчәчәк атылып бакчадан чыкты. Көтү каршылаганда кайсы күлмәген кияргә икән? Ул бит Мирсәлимнәр турыннан узачак. Укытучы хатын килеш-килбәте белән башкалардан аерыла иде. Ни кисә дә: «Нишләгән бу?» — димәсләр. Ә менә Күкчәчәк үзеннән-үзе сорый: «Нишлисең син?! Аңа күренеп нәрсә үзгәртмәкче буласың? Давыл чакырып, шуның өермәсендә бөтерелә-бөтерелә кайларда югалырга җыенасың?!»

— Әти, аргы очта көтү каршылыйлар. Эшем күп, син генә барсаң иде безнең сыер артыннан.

— Лелин башым беләнме?! Буклы сыер куаргамы?!

Карт, үпкәләп, балалар төсле авызын турсайтты.

— Халык белән гәпләшер идең, әти.

— Э-э-э, синеке дөрес, килен. Капкадан борын тыкма, аягыңны сындырам, ди Лотфый. Буржуй малайдан шөлләгән ди Лелин. — Сабирҗан карт мунча башыннан озын саплы әләмен суырып алды. — Кызыл байрак тирәсенә берләш, эшче-крәстиән. Партиәгә дан! Ур-ра!

«Халык белән гәпләш» дип ялгыш ычкындырды Күкчәчәк. Балалыгына кайтып төшкән үги атаның хыялый уены зыян-зәүрәт салмаса да, Лотфулла гарьләнәчәк. Тагын Күкчәчәк гаепле…

— Әти, туктале, әти! — Хатын артыннан ташланганда, «Лелин байрагы»н болгый-болгый карт кош кебек оча иде инде. Күкчәчәк тә уе белән генә аргы очтагы йортның капкасына сугылды. Халык җыелгандыр, Мирсәлимнән хәл-әхвәл сорашадыр. Бура-Киртә, гәрчә хатын бу иргә карата күңелен суытырга тырышса да, Мирсәлимне хәтереннән сызмаган, аны юксынып көтте. Ә аның бүтән авылдашларын якларлык кодрәте юк. Аның киң көрәш мәйданы тарая-тарая кысылды: авыл бае — Лотфулла бүген. Җирле үзидарә рәисе — яшь егет — хуҗаның рөхсәтеннән башка шырпы да сызмый иде. Ишегалдыннан гайре белмәсе калмаган Мирсәлим нишләр? Хәзер Күкчәчәк, җаны белән иренә хыянәт итеп, гел Мирсәлим турында уйлар микәнни?! Һәй, әйтерсең элек андый уйлар уйлап уелмаган!

Ирек тәменнән исергән Сабирҗан карт ала-кола сыер куып кайтып керде.

— Мөгезенә асылынып, корсагына байрак сабы белән төрткәләп кенә җиңдем Сөтлебикәңне, килен. Кирегә каера, азгын. Анда халык бии-җырлый. Мирсәлим төрмәдән котылган икән.

— Әти, бу безнең сыер түгел, безнеке аксыл-кызыл.

— Миңа сүз кыстырырга тәки җай чыкмады, килен. Иртәгә нибуч минем кызыл әләмем астында биерләр. Яшәсен партиә! Лелинга дан!

Җаны өзгәләнгән хатын кинәт кенә урамга йөгереп чыкты. Сыер, имеш, сыер… Халык Мирсәлим белән күрешә икән. Иң әүвәл Күкчәчәк тоярга тиеш иде аның кул җылысын. Бөтен тыю-тыелуларны кагып төшереп, ул юл чатында көтәргә тиеш иде. Хис үлде,ярату үлде, дип, үз-үзен алдаган ласа! Әнә офыкта аның сурәте эленгән. Менә ул зурая-зурая Күкчәчәккә табан якынлаша. Менә ул җиһанга сыймас, һәм дөньяның күкрәге сытылып, җиде кисәккә ualыр сыман. Гаҗәп, ә хатынның йодрык хәтле йөрәгендә сурәткә урын табыла!

— Күкчәчәк…

Хатын аңын җуя язды. «Сурәт» җанланып аңа эндәшә иде.

— Күкчәчәк… Танымыйсың мәллә? Мин, Мирсәлим бу.

— Син?!

— Ишетмәдеңмени, мин кайттым бит…

— Ник… ник безнең очта йөрисең әле?

— Сине күрергә килдем, Күкчәчәк. Атап килдем.

— Кит! Лотфуллага ни диярсең?!

— Болын чәчәгемне сагындым, диярмен.

Күкчәчәк артка чигенде.

— Кит! Аның каравы мин сине тамчы да сагынмадым. Кит!

Хатын шапылдатып капканы япты. Йөрәк кыядан атылам дип ачыргаланган кош хәлендә иде. Их, ир бәндәсе, ир бәндәсе! Сагындым, янәсе. Кыюлык түгел, юләрлек бу! Өйгә үк килгән! Лотфулла берьюлы икесен дә атып үтерсен диде микәнни? Ә-әй, күзләренә бер тутырып карамады да, ичмасам. Ә-әй!

Аркасы белән капка баганасына терәлгән Күкчәчәк урталай сыгылды. «Кит» дип куды да… Ә йөрәктән бу кешенең исемен ничекләр сызгалап ташларга, йә?!

Өч елдан соң кан дошманы Бура-Киртәгә аяк баскан сәгатьләрдә Лотфулланың күкрәгендә кырык җен урак урып, кырык чүмәләгә өя иде. Ялагай ялчылары әләкләп өлгергән, күрәсең, башта ул үги этисенә ябырылды:

— Син, кәҗә сакал, төрмә чыпчыгы Мирсәлим белән эшле-мөшле мәллә? Кызыл чүпрәк селки-селки, аның капка төбендә тыпырдагансың икән.

— Кара, кара! Нәстә ди, иеме, килен? Лелин башым белән нишләп чүпрәк селким ди? Чын байрак ул, тити баш! — дип үпкәләде Сабирҗан карт.

— Сине кисәттем бит, кәҗә сакал, авыл көлдереп, урамда теркелдәмә, дидем бит!

— Монда килен мөһим йомыш кушты, улым. Түбән очтан Сөтлебикәне апкайтырга, диде.

Лотфулла ишегалдында җәелгән сыерга акайды. Мәхлук хайван агач кисмәктәге суны шыпыргач, чит йортта икәнен дә онытып, ял итә иде.

Чират Күкчәчәккә җитте.

— Кемнәрнеке белән алмаштырдың?

— Әти безнекен танымаган, шул гына, — диде хатын, җәнҗалның очы нәрсәгә тоташачагын аңлап.

— Ә ник үзең бармадың?

— Эшем күп иде.

— Ә-ә, эшең күпмени?! Хәзер көпә-көндез кеше күз алдында күрешмисезме инде? Ояттыр, әйеме?

— Сыер беләнме, Лотфулла?

— Һо-һо! Әллә дүрт аяклы хайванга әвереллдеме теге хәерчеләр чабатасы. Мин аңа икенче кушамат та тагам әле. Гел «халык та хаклык» дип тәтелдәгән кешегә ничек диләр, беләсеңме? Кызыл авыз!

— Байракны ипи шүрлеге белән бутый, бакчи, тити баш. — Сабирҗан карт үги улына карап мыгырданды. — Син, Лотфый улым, кәпрәймә, җәме? Рибалютсиягә әйдәүче байрак төсе ул кызыл. Яшәсен…

Беркемне дә яшәтмәде үз ишегалдында Лотфулла, картны җилтерәтеп сыерга табан очырды.

— Ку шул мәхлукны урамга! Күп лыгырдасаң, сөргенгә сөрәм мин сине, Сабирҗан эти!

Хуҗа учын учка шапылдатты.

— Мона мин бер табышмак чишәм. Кызыл авызга сигез ел чәписеләр булып та, шуның бишесен киметкәннәр. Бура-Киртәдән аны яклап имзалар сырланган кәгазь илткәннәр, ди, Казанга. Кем кыюланып бу эштә башлап йөргән? Кем, ә? Мин бүлнистә кан эчендә ятканда кайсысы ярлылар чабатасына булышкан? Шуны тиз генә ачыкларга иде. Исемен белсәм, җиде кат тиресен туныйм, билләһи.

Хатынның күз кабагы тартышты. Моңарчы ире бу хакта ләм-мим иде. Ул исем бер калкыр микәнни? «Телебезне тешләдек», — дип ант суы эчкәннәр ике капчык бодайга сатылыр микәнни?

— Авылы белән… авылы белән туныйсыңмы?

— Нинди авыл, аңгыра хатын! Фетнәне берәү генә оештыра. Әнә теге «рибалютсия» дип саташкан җүләр карт ялгыз бит. Мона аңа иярүче тилеләр табылыр әле Бура-Киртәдә. Нәстә кызардың? Син дә ул хатка кул куйдыңмы?

Күкчәчәк икеләнде. Дөресен әйтсә, чынлап та, «фетнәче»не йә алай, йә болай җәзалаячак имансыз ир. Әйтмәсә, алдарга күнекмәгән җанга читен.

Хатын ялганларга мәҗбүр иде.

— Куймадым…

— Шулай, хатын, шулай. Сиңа өйләнмәде бит ул. Исеңдә тот: өйләнмәде-е. Җүләр дип качты.

Әйе, ире хаклы иде: шулхәтле яратып та, Мирсәлим аңа өйләнмәде…

Күкчәчәкнең юашлыгыннан кәефе күтәрелгән Лотфулла җырлый-җырлый сарайга атлады:

Камышлыкта кыр үрдәге
Кычкырадыр, бичара.
Сөйгән ярлар төкерсәләр,
Күз яшеннән ни чара.

— Кая безнең Карасаз илләре кунагы? У-у, ишәйткән бу гаиләсен. Йорт ата казына сан да юк. Молодец, кыр үрдәге! Сабирҗан эти, кил әле, кил!

Карт урам уртасында Имам күрше белән чүкердәшә иде, тавышын сүлпәнәйтеп:

— Ни йомыш? — диде. Теләр-теләмәс кенә, «буржуй» улы янына килеп басты.

— Сабирҗан эти, сиңа хәрби бурыч йөкләнә. Үрдәк сусыз яшәми, сусыз аның тиресе көпшәкләнә, эчәкләре кибә. Ишегалдында зу-ур чокыр казып, су тутырасың. Утыз сигез баш үрдәк баласына күл ясыйсың, кыскасы. Икенче бурыч: син сакчы да. Керфек какмыйча тилгәннән сакла!

— И-и, ыстырам! Лелин башым белән үрдәк сакларгамы инде? Элгәре кош-корт күлдә быкырдый иде.

— Надан! Боларның әнкәсе кыргый. Балаларын канатландыргач Карасазга сыптырса, очты, очты үрдәкләр, дип, авызыңны күккә терәп карап калырсың. Боерыкны үтә, иптәш Ленин!

— Ах, оятсызлар! Өч тиенлек намуслары юк, Лелинга ни кушалар, җә. Син дә, килен, иреңнең хатасын төзәтмисең. Без, камунислар, сезгә — кыз-катыннарга ирек бирдек, хөррият капкаларын ачтык.

— Ул миңа рәхмәт укып яши, мин бит аны, нәкъ тилергән чагында, хурлыктан саклап куеныма сыендырдым, әйеме, Күкчәчәк? — Лотфулла симез ияген мелмерәтеп көлде: — Ха-ха-ха!

Ирнең теш агартуы бәгырьне көйдерә иде.

— Атаудан сыерны караштырам, — диде ул. Бая болынны камаган офыктагы Мирсәлим сурәте әрсезләнеп йөрәккә урнашты инде. Бөтен фаҗига дә шунда шул: мәхәббәт берәүдән дә рөхсәт сорамый. Ходай яраткан хис бит ул. Адәмнәр генә уйлап чыгарса, аны җиңеп тә булыр иде.

Үткәннәр күңел иләгеннән кат-кат иләнде, ә өстә көрпәсе кала да кала.

Әйе, Мирсәлим аңа үз ирке белән өйләнмәде… Бер кичтә гайбәтләрдән үртәлгән-сытылган егет кызны мәктәп тыкрыгында туктатты.

— Күкчәчәк, ахыргы сүзем: мин Гөлсемне алам.

— Ал, — диде кыз, туфли очы белән чирәмне казып.

— Яратмаган хатын алам, дим! — И ярсыды, и ярсыды Мирсәлим. — Син шуңа этәрдең, Күкчәчәк! Син Лотфый белән ял йортларында типтергәндә, мин дә яр сайладым, Күкчәчәк!

— Мин Лотфый белән типтермәдем, Мирсәлим. Бинахакка яла якма.

— Акланма, кызый! Ихахайланып машинасына утырып киткәнеңне укытучылар күргән. Әни дә чуалалар дип ялганламас иде. Алайса, әйдә, иртәгә үк никах укытабыз, иртәгә үк!

Күккә очы белән кадалган ай ярты гына кисәк иде. Хәзер үк Мирсәлимгә иярергә әзер кыз. Шушы минутларда айры-чайры газапланган ике җанның әрнүләре дә бетәчәк. Әгәр имче карчыкны тыңламыйча егет белән кавышса? Һәм… никах укыганда гына өянәге кузгалып егылса? Кул-аяк калтырый, авыздан күбек ага… Йа Алла!

— Тагын бер генә атнага сабыр ит, Мирсәлим!

— Нәрсә-ә?!

— Минем төгәллисе эшләрем бар.

— Чын икән. Син Лотфый белән йоклаган икән. Имеш-мимешләргә ышанмаган идем. Көмәнеңне төшертергә берәр атна вакыт кирәк шул сиңа!

Тыкрык караңгыланды, бөкре ярым ай турайды. Һай, бавырны энә белән чәнчә егет. Сөю тулы ап-ак күңелне каралтырга ничек база ул?!

— Мирсәлим җаным, нишлисең син?! Мине юри пычраталар лабаса!

— Кемнәр? Әниме? Укытучылармы?

— Соңыннан барысын да аңлатырмын, Мирсәлим!

— Болай да аңлашылды. Хуш!

— Мин сиңа хыянәт итмәдем! — дип әрнеп кычкырды кыз. Әмма каты бәгырьле егет ташлап китте. Ташлап… Тик бөтенләйгә түгел. Атна-ун көннән ул өзелгән араларны ялгар өчен «ялгыш» кына тыкрыкта очрар… «Рәнҗеттем, кичер, чәчәгем», — дип, сөйгәненең алдына тезләнер. Ә ул көннәргә хәтле ничек ерак! Ай да тамчылап кына өрелеп кабара. Хәзер инде кыз Карасазга керимме-юкмы дип икеләнмәскә тиеш. Хәзер инде ул Мирсәлимне югалтмас өчен упкынга мәтәлергә дә риза.

Ай тулыша язганда, Күкчәчәк тагын имчегә барды.

— Яраткан кешем белән кавышаммы, әбекәй? — диде.

Карчык:

— Ходай тәкъдиреңне ни белән бизәсә, шуны күрерсең, миннән бернәмә дә төпченмә, бәбкә. Куркуны курку белән чөйлиләр, дидемме, бәбкә, — диде.

Карасазга төбәп карасаң да, ул күз нурын суыра, ә аның тирәсендәге каеннар үсә алмыйча кәрләгә әйләнеп ката иде.

Бу серле һәм куркыныч аймакта ниләр бар? Кыр үрдәкләренә генә мәгълүмдер, алар анда ел саен бала ишәйтте. «Ау, ау» дип шапырынган Лотфулла белән дус-ишләре кырыйда берән-сәрән очкан тәҗрибәсез яшь үрдәкләрне генә каптыра иде. «Йә мин үләм, йә, чиремнән терелеп, Мирсәлим белән кушылам, икесенең берсе», — дип тәвәккәлләде Күкчәчәк. Курку әле табан астына шуып тәнне бозландырды, әле эчне айкап муеныннан буды. Сазга җиткәндә, кыз яртылаш мәет иде инде, имче

карчык төп-төгәл тасвирлаган икән, саз түмгәкләр белән чуарланган, ай яктысында алар, алтын комы сипкәндәй ялтырап, күзне алдый иде.

Кыз беренче түмгәккә басты да чүкечкә әверелеп тук та тук күкрәк читлеген кыйнаган йөрәген көч-хәл белән кысып тыңланды: аста нәрсәдер быгыр-быгыр кайнап маташа. Куркуыннан ул, тиен кебек, өченче түмгәккә сикерде. Аркасына кемдер чукмар белән дык-дык төя сыман иде. Түмгәкләр санын бутаса, аны саз йотачак! Кергәндә — икешәр, чыкканда берәр аша… Ичмасам, күршесе Мәүлия белән дә хушлашмады. Йокысызлыктан зарланган Мәүлия капка төбендә утыра иде бит. «Әй, Күкчәчәк, ярты төн уртасында кая китешең?» — диде хатын. Кыз аңа кул гына селтәде. Чире аркасында ул күрше-күлән белән дә йөрешмәде. Үлсә, тәгәрәп елар туганнары юк авылда… Мирсәлимнән гайре. Егет тә, шәт, артык кайгырмас, бит «хыянәтче» Күкчәчәк аның маңгаена «мөгез» чәпәде.

«Каберем шушында икән» дигән уй баш миен бораулады. Аннары ул көтелмәгән бер могҗизага тап булды: саз уртасында түм-түгәрәк күл җәйрәп ята иде. Тик бу могҗиза куркуны көчәйтте генә, чөнки күл ямьсезлек янәшәсендә коточкыч гүзәл иде. Озын зифа камышлар — аның керфеге, ә төнбоеклар чәчәкле күлмәге төсле. Суда чупылт-чупылт балыклар сикереп уйнады. Менә кайда кыр үрдәкләре нәсел озайта икән…

Күкчәчәк дерелдәгән буыннарын кулы белән сыпырды. Аңа көч җыеп, ничек тә кире борылып чыгарга кирәк. Әгәр таң аттырса, йөрәге ярылачак иде. Карчык дип үлеп булмый лабаса! Ләкин аяклар тыңламый, камыр сыман йомшарып, гәүдәсен сыгылдырды. Шулай ярым бөгелгән килеш торды ул. Аны күл генә җибәрми, ахрысы.

Таң беленгәндә, буыннардан калтырау кимеде, гәүдә дә төзәйде. Карчык кушканнарны төгәл үтәргә кирәк иде. Инде кызны тонык кына гүелдәгән адәми тавышлар әзәрлекли башлады. Йа Алла, әллә элгәре сазга батканнарның җаннары уяндымы? Күл буеннан ераклашып, саз авызындагы кәрлә каеннарга якынлашкан саен, тавышлар көчәя генә иде. Тизрәк авылга йөгер, кызый, тизрәк! Менә соңгы түмгәк, менә… Абау, ни хәл бу?! Күкчәчәк, балалар кебек, күзләрен уды: ауган-сынган койма кырыенда сабантуй хәтле халык җыелган.

— Әнә ул! — Иң беренче Мәүлия сөрән салды. Аннары кызның каршысына атылды. — Йолдызым-күршем, кичә артыңнан махсус күзәттем. Төнлә кая кыяклар икән, дим. Карасазга кердең дә чумдың, атакаем! Үлде дип авыл җыйдым мин, йолдызым-күршем.

Сабантуй гөжләвеннән тынып калды. Һәрберсе Күкчәчәктән сүз көтә иде. Ә ул Мирсәлимне генә күрде. Гаҗәп, баягы күл сыман, егетнең дә кыяфәте шомландырды. Ник ул исерек төсле як-якка авыша? Ник аның йөзе таштан да таш?

— Күкчәчәк! — Мирсәлим аңа табан талпынгандай итте: — Әйдә, өйгә кайт, Күкчәчәк. Син авырыйсың, ахрысы.

— Юк, мин сау-сәламәт, Мирсәлим.

Кыз бәхетле елмайды. Ниһаять, ул яраткан кешесенә бикле серен ачачак.

— Әйдә, өйгә кайт, — дип кабатлады ир.

— Кая кайта?! Кемнәргә кайта?! — Хатыннар белән сөйләшкән Гөлсем очып килеп Мирсәлимнең беләгенә асылынды. — Нигә аны чакырасың, җанашым?

Мирсәлим Гөлсемнең кулын чүп кебек кенә беләгеннән кагып төшерде дә кызга томырылды:

— Әйдә койма аша күтәреп алам, Күкчәчәк!

— Әй син, нәфсе капчыгы! — Сузылган кулларга шап иттереп суктылар. — Икенче хатынга өйләнмисеңдер бит? — Яшь рәис Мирсәлимнең юлын бүлде. Лотфулла шулай истә-сында юк чакта гына җир астыннан калка иде. — Төнә кич — Гөлсем, бүген — Күкчәчәк. Син безгә Бура-Киртәдә кыз да калдырмыйсың, чибәркәйләргә рәттән тамга сугасың, ахрысы.

«Өйләнгән!.. Сазлыкта гына батып үләсе иде, әй! Өйләнгән…»

Мирсәлим иңе белән рәисне этеп юлны ачты да койма аша Күкчәчәккә үрелде.

— Кил, болын чәчәгем!

— Кагылма!

Кызның гәүдәсе бөрешеп җыерылды. Йөзәрләгән пар күз аларга текәлгән иде. Лотфулла исә бу бәхетсезлектән оста файдаланды.

— Кагылма дигәч кагылма, бүректәш. Хатының белән икәү йоклаган түшәгең суынмагандыр әле, кайт та юрган астына чум, бүректәш, — дип, ул, черегән койманы тибеп аударып, Күкчәчәкне култыклады. — Киттек, матурым. Әбзиеңә дә өйләнергә вакыт. Синдәй гүзәлкәйләр җир йөзендә сирәк ул.

Бер-бер артлы икесе дә ялгышты. Башта — Мирсәлим, соңра — Күкчәчәк.

Авыл заманлашып, һәр шәхси хуҗалыкка торбадан су үткәрелсә дә, Бура-Киртәдә кызык кына йола саклана: килен-киленчәк, иңнәренә чиләк-көянтә асып, аръяк болынындагы Зәмзәм чишмәсенә суга бара һәм аның уңганлыгы-булганлыгы мөлдерәмә тулы чиләкләренә карап билгеләнә. Гадәттә, яшь хатыннар, «ялкау икән» дигән бәя куйдыртмас өчен, чишмәдән мамыкка баскандай, сак кына, йомшак кына атлап кайта иде.

…Яшь киленнәр чишмә янында очраштылар.

— Төнә әйтә, әйдә өйгә апкерәм, ди Мирсәлим. Апкер, мәйтәм. Гөлйөзем апа, әй, хәзер әни инде, бәлеш пешергән. Уйнап кына чыгылды инде кияүгә, кызкаем. Сезнең ничегрәк соң анда? Әһем, кочагы кайнармы Лотфулла рәиснең? Минеке тыр-мыр шунда.

Күкчәчәкнең эчен мәчеләр тырнаса да дәшмәде. Җиңел-җилпе Гөлсем белән Мирсәлимне бүлешеп әрләшсенмени! Бүтән ул ир аныкы түгел инде…

Авыл башында такылдык Гөлсем сөрлегеп суны түкте һәм:

— Булдыксыз дип каенанам җелегемне киптерә инде-е-е, — дип үкерергә тотынды. — Иртән дә идән себеркесе дип әрләде-е-е!

Күкчәчәкнең суы мөлдерәмә, тирләгән чиләкләр аскан көянтәсе әкрен генә җилкәсендә тирбәлә, ул илаулаган көндәшен җәлләмәскә тиеш иде. Алла суктырды! Дөнья карасына буялган хатын асыл егетләргә кияүгә чыгып кына агарса икән! Аның бәхетен шушы көя күбәләге генә теткәләде. Чиләгение белән тибеп кенә аударасы иде.

Ә Күкчәчәк җәлләде. Аңарда үзенең ярты кисәгген күрде. Ул да яшь коя, тик бозлы тамчылар тыптып йөрәккә тама иде.

— Йә, улама, — диде Күкчәчәк һәм, чиләген кыйшайтып, Гөлсемгә су өстәде.

## 3

Чир китте… Карасаз төшләрендә әллә ничә тапкыр яңарды да онытылды. Хәзер инде җан авыру, ә монысы, җитмеш җиде әүлия дәваласа да, узмаячак иде. Яшәсен иде Мирсәлим җобага хатын белән, ә менә аңа — Күкчәчәккә — Лотфулла нигә кирәк иде, нигә?! Яратмаган кеше! Салкын кочак, боз каткан йөрәк! Боларны кан дошманыңа да теләмәссең, валлаһи. Лотфулла тупас һәм дорфа иде. Күкчәчәк үзенә боерды: менә син аны шул килеш ир дип санла! Ул сине көчләмәде, син үз ихтыярың белән аның йорт түбәсенә кунган кош. Барысына да Мирсәлим гаепле, Мирсәлим салкын кочакларга ташлады. Үзенең дә җаны сызадыр: куенында сөймәгән-сөйдермәгән сөйкемсез сөяк.

…Ир хакы дип хатын, барча карышуларын җиңә-баса, Лотфулла колы булды. Тик никадәр генә хакы хакланса да, ир бәндәсе бөтенесенә дә җәбер-золым белән түли иде. Холык күлмәк түгел, тузмый шул.

— Мин сине рисвайдан коткардым, — диде Лотфулла, бәгырьне әчетеп. — Син җүләрләнеп Карасазда йөргәндә, мин ул үз акылында дип исбатлар өчен сиңа өйләндем. Шуның өчен син гомерең буе миңа рәхмәт укы!

Бу шау-шулы вакыйгалардан соң яшь хатынның иң курыккан нәрсәсе Мирсәлим белән очрашу иде. Кайда очраша алар: урамдамы, мәктәптәме, кибеттәме — әдәп йөзеннән бер-берсе белән исәнләшергә тиеш. Күкчәчәк «нихәл?» дисә дә, «әйбәт» дисә дә үзен сатачак. Аның тавышы сагыш булып җиргә чәчеләчәк. Ә сер бирәсе, сине читкә тибәргән ир каршында мескен кыяфәттә торасы килми! Әнә шул беренче күрешү калганнарын хәл итәчәк.

Мирсәлим җирле үзидарә рәисе вазифасына сайланган көнне мәктәп укытучылары Мәдәният йортына китте. Ә Күкчәчәк «авырыйм» сылтавы белән өенә юнәлде. Авырмый ул, аңа ярамый. Юк, Лотфулла көнләшеп тел белән кыйнар дип уйламады, аңдагы сакчы минут саен беренче күрешүнең хәтәрлеге турында искәртә иде. Аның каравы Лотфулла җыелыштан кызып кайтты.

— Мин әзерләгән кандидатураны тәгәрәттеләр, шайтаннар. Мирсәлим диде дә мәлҗеде Бура-Киртә. Кай төшен ярата халык бу тәти егетнең, ә? Бәлки, син әйтерсең, ә?

— Белмим, — диде хатын, иренең бозлы карашыннан өшеп.

— Бәрәч, борын заманнарда ул синең ярың түгел идемени?

— Синекеләр олау-олау иде, мин берсен дә санамадым.

«Тартар теленнән табар», — диләр. Күкчәчәккә «белмим» дигәч тә авызын йомарга иде, ә ул болай да дулап чапкан холыксыз айгырны дилбегә кагып тагын да ярсытты.

— Олау-олау дип, мин аларның кайсысын түремә кайтарып утырткан әле! Син бит йортымда хуҗабикә! Мин, Мирсәлим кебек «Аһ, җаным! Яратам!» дип төчеләнеп, берсенең дә башын әйләндермәдем, ә ул синнән адәм көлкесе ясады: артыңнан сөйрәлде-сөйрәлде дә Гөлсемгә өйләнде.

— Аер!

— Кемне?!

— Мине, Лотфулла, мине!

— Менә сиңа мә! Сыптыр, юлыңа ак карлар яусын. Хәзерге заман хатыннары аерыласы килсә, чыга да китә, «аер» дип ялынмый.

— Әгәр мин үз иркем белән китсәм, син үч алачаксың, синдә иман юк бит, Лотфулла.

Ире сикерә-сикерә шаркылдады:

— Ха-ха-ха! Монысы дөрес, мин сине тыныч яшәтмәячәкмен. Алдан синең базга егылып аягың сына, имеш. Аннары, сөякләрең төзәлгәч, сарай түбәсеннән мәтәлеп — кулың. Ул турая гына, башың

ярыла. Гел бәхетсезлек очрагы, әйеме? Инде дә бәла-казалар кимеде дигәндә генә, йортың яна! Ха-ха! Яна, валлаһи! Электр чыбыгы иске, имеш, шуннан бүрәнәләргә ут капкан, имеш. Таныш милиционерлардан шундый нәтиҗә яздырачакмын, зерә генә мин аларны хуҗалыкның итен-маен, балын тыгындыраммыни?! Ә син, ярлы укытучы, өй борынча хәер сорашасың: «Авылдашлар, зинһар, алъяпкыч итәгемә тиеннәр ыргытыгыз!» Әйдә, Лотфулла абзаңның әнә шул тәмуг казанында кайнарга риза икән, аерыл әйдә. Авылдан кыякласаң, егетләр яллап, җир тишегеннән дә таптырам. Хәер, син Бура-Киртәгә тамыр җәйгән инде, синең бит монда сөяркәң бар. Әнә үзенә түрә камыты кигезделәр.

Анысы хак. Мирсәлим белән йорт түбәсе уртак булмаса да, айлы-йолдызлы авыл күге уртак иде. «Минеке түгел» дип лафына Күкчәчәк, «минеке түгел» дип кире кага Күкчәчәк, ә Мирсәлим барыбер якын, барыбер кадерле…

Ниһаять, очраштылар. Берсе — хатынлы ир, икенчесе ир хатыны сыйфатында тәү кат очраштылар…

— Нихәл, Күкчәчәк?!

Яшь хатын күз кырые белән авыл ягына карап куйды. Ул тау битеннән җиләк җыеп кайтып килә иде. Сәламгә сәлам бирмәде, башын гына селкеде.

— Мин печәнлек җирләрен урыйм, чаптырып халыкка өләшергә иде. Яшенә-картына тигезләп дигәндәй. Син нәрсә соң, Күкчәчәк, син…

— … бәхетле, — диде хатын, теле ачылып. — Бик белмәкче икән, бәхетле, яме!

Яшь ир ике кыңгырау чәчәге өзеп, аның тырысына салды:

— Мин дә бу дөньяда син булганга бәхетле…

Күкчәчәк капыл гына йөгереп китеп барды. Үпкә-рәнҗү, таш кебек укмашып, тамакка бөялгән иде. Нинди бәхет турында сөйли, хыянәтче?! Икесе дә өшеп-туңып ятлар белән яшәгәндә, бәхет алардан җәяүләп качты лабаса!

Хатын сусыл җиләкләр өстендә калтыранган зәңгәр кыңгырауларны зәһәрләнеп учында измәкче иде, йөрәгенең ни дәрәҗәдә бозланып катуыннан сискәнеп, чәчәкләрне иренenә тидерде. Боларның ни гаебе, әй.

Шуннан бирле әллә ничек булды бит ул. Ел саен кыңгырау йә китап битләре эченнән, йә укытучылар бүлмәсендәге өстәлдән «үсеп чыга», һичьюгы, иртүк көтү куганда капка тоткасына кыстырылган чәчәк кулга орына…

Йа Рабби, бүген дә болын тулы кыңгырау! Хатын сыер эзли… Мирсәлим төрмәдән кайтты… Өч ел аңа берәү дә чәчәк бүләк итмәде. Ул еллар буш һәм кысыр еллар иде. Нур яктысыннан да яктырак син, мәхәббәт! Болын — гөл-чәчәкләр, ә күңел сөю белән бизәлсә, рәхәт икән лә. Һай азынса азынсын инде бу хайван. Бүген сыерда гамь юк, бүген Күкчәчәкнең иләс-миләс чагы. Ул, сурәт хәтле сурәт сыйдырган йөрәгенең сулкылдавына кушылып, үзе дә сыктый әнә… Аның җан төпкеленнән чыккан ыңгырашуыннан болын да тетрәнә сыман… Төнге йокысына әзерләнеп мендәр кабарткан болытлар да күк гөмбәзенә сыдырылып чыңгылдый сыман… Йа кодрәтле Аллам, хатын күпме генә ялварса да, онытырга теләп тә онытылмаган Мирсәлимнән син һаман араламадың бит!

Болын очына күрше авыл кырлары ялгана иде. Күкчәчәк ызаннан гына үтеп авылга керде. Нигәдер яңа төзелгән йортлар күңелне алгысытты. Моның әдәпсезлек икәнен аңласа да, Күкчәчәк шул йортларның тәрәзәләренә карап уела, гүя хуҗаларның бәхетеннән көнләшә иде. Әйе, әйе, аныңча, андагылар бик-бик бәхетле. Яратышып кавышкан парлардыр… Бер-берсенә йомшак кына эндәшәләрдер… Мөгаен, бала-чагалары аяк астында чуаладыр…

Бу юлысы ул нарат чәере исе аңкыган яңа өйләр каршында тукталмады. Хатын елына бер мәртәбә күптән гүр иясе имче карчыкның каберен зиярәт кыла, ихлас догаларын укый иде. Чөнки Күкчәчәк аңа мәңге бурычлы. Берәүдән чир ук сыман атылып чыга да икенче берәүгә кадала, дисәләр, ул әкият дип көлә иде. Камил акыллы кеше ничек шуңа ышансын ди инде! Ә яшәештә ни аңлап, ни аңлатып булмаган сәер хәлләр күп икән. Ике бит алмасына шәфәкъ кызыллыгы ягылган тупырдык Гөлйөзем апа, кинәт кенә сырхаулап, түшәккә ауды. Гайбәт сүзе бит ул инә төсле: аннан чәнчи, моннан төртә. Килен белән каенана килешеп яшәмиләр, имеш. Йортта көн дә гауга, имеш. Гөлйөзем апаның нервысы чыдамаган, имеш. Гөлсем ишеләрне өнәмәгәндер шул укытучы. Ул бит бердәнбер улына фәрештә яучыламакчы иде. Күкчәчәк холкы, Күкчәчәк чалымнары белән, тик сау-сәламәт килеш. Ә Мирсәлим ак димәде, кара димәде, әнисен шайтаннан азган килен белән «бүләкләде».

Укытучылар хәл белергә баргач, нигәдер Гөлйөзем апа түр якка керттермәгән. Сыза гына ачык ишектән:

— Ачуланмагыз, әлегә базарларда күрсәтерлек чибәр кыяфәттә түгел мин, кызлар, — дигән. Ул Күкчәчәк турында сораган, килсен әле, дигән. Әлбәттә, яшь хатын бармады… Юк, Күкчәчәк аңа үпкә-сапка тотмый иде. Мирсәлим белән аларны аеру өчен Гөлйөзем апа ниләр генә кыланса да, аны дошманнар исемлегенә теркәмәде.

Беркөнне Гөлсем, мул күкрәкләрен сикертеп, мәктәп бакчасына керде.

— Әй, иптәш укытучы, сине безгә чакырдылар, — диде, үзе төтәлдән өзеп кетер-кетер кыяр кимерде. Бура-Киртәдә тавыш тансыклаган ике генә кеше бар: берсе — Лотфулла, икенчесе Гөлсем иде. — Чукрак мәллә син, иптәш укытучы? Анда теге дөньяга олагырга маташкан каенана сине чакыра, дим, җәфа.

Чүп утаган кулларын үлән белән сөртә-сөртә, Гөлйөзем апаларга йөгерде ул. Сулышына кабып, капканы этсә, ишегалдында Мирсәлим утыра иде. Күзләр генә исәнләште… Йөрәк кенә сулкылдады… Бәхет түмен татып, аннары шуңардан баш тарткан кешеләр аерата бәхетсездер. Балдан соң әрем кап инде син. Мирсәлим шундый иде. Ул җиңелгән иде…

Гөлйөзем апада, чынлап та, базарларда күрсәтерлек чибәрлек калмаган, аның күзләре нурсызланып, йөзе көзге яфрак сыман саргайган иде.

— Үзең генәме, кызым? — диде ул, шикләнгәндәй. — Урта ишекне каты итеп яп. Ахыргы сулышларымны сулыйм мин, кызым.

— Тереләсең, Гөлйөзем апа, тереләсең. Кем авырмаган бу дөньяда, — диде Күкчәчәк.

Сырхауның сары суккан йөзеннән яшь тамчылары тәгәрәште.

— Әҗәлдән кем котылган ди. Ничә көн баш очында калкына инде ул. Миңа синең бәхиллегең кирәк, кызым. Бәхиллә мине, зинһар. Мирсәлим белән арагызны мин генә боздым. Мин сине мәкер белән Лотфулла машинасына утыртып җибәрдем дә, иң пычрак гайбәтне үзем уйлап чыгарып, улыма сөйләдем. Лотфулла белән чапты, Лотфулладан көмәнле, дидем, шундый түбәнлекләргә хәтле төштем.

Яраларны кабат-кабат кузгатып, әрнү кичергән йөрәккә авыр иде.

— Барысы да узган инде, Гөлйөзем апа. Кузгатма, яме!

— И-и-и, кузгатмас идем дә… Мирсәлимем бәхетсез бит әнә-ә-ә… Мин кабергә кереп котылырмын, аңа нәрсә-ә-ә…

— Тереләсең син, Гөлйөзем апа.

— Чү, кызым, юатма. Ходай синең чиреңне алды да миңа салды ласа. Ие, ие, салды шул. Гөлйөзем апа җүләрләнгән димә. И-и-и, башларымның шаулаулары-ы-ы…

— Мин сине каргамадым, Гөлйөзем апа. Рәнҗемәдем дә бугай. Терел тизрәк, яме!

Мирсәлим һаман тораташ, ә Гөлсем тавык төсле пыр-пыр кагына иде.

Ул:

— Нәстә бик озак чыркылдаштыгыз, чыпчыклар? — дигәч кенә, ир, кисәткәндәй, усал итеп тамак кырды. — Йә, йә, ир җанашым, авызымда йозак! Кунакны озатыймчы, — дип, хатын, чытлыкланып, Күкчәчәк артыннан урамга чыкты һәм беләккә сыланды: — Нәстә ди йөзем бөртеге? Минем тетмәмне тетәме?

— Ишек ярыгына колагыңны куеп тыңларга иде, Гөлсем.

— Һи, тыңларсың монда! Мирсәлим: «Кер генә, капка аша чүплеккә очыртам», — диде.

Алар әнкәсе белән мине чүпкә саный шул. Без бит, кайбер укытучы иптәшләр төсле, алтынга манчылмаган, кадерсез тутык тимер без.

Гөлйөзем апа савыкмады, өч көннән җир куенына иңде. Юындырып кәфенләгәч, аның саргайган йөзе агарган, ул көлемсерәп яткан, диделәр. Беркемне дә рәнҗетмәгән кешеләр фани дөньялардан елмаеп китәләр, имеш. Аллаһы Тәгалә бәндә аякта чакта үзе төзәтмәгән хата-ялгышларны каләме белән төзәтә, бәндә үзе үлчәргә яратмаган гөнаһларын мизаннарда үлчәп җәзасын юллый, ахрысы. Ә кемнедер алда тәмуг газаплары көтә. Мирсәлимнең әнисе дөньялыкта ук җәзалануына сөенгәндер, мөгаен. Каргамады аны Күкчәчәк, каргамады. Ә рәнҗү синнән торамыни ул! Чык бөртегедәй бер тамчы күз яшенең кая төшкәнен кем күрә?! Аның ташларны да тишәрлек кодрәте бардыр, бәлки.

Күңел өченче тапкыр очрашу эзләми, «барыбер минеке түгел» дигән өметсезлек күз алдына кара пәрдә корган иде. Яшь хатын бер нәрсәне — тартылу көчен исәпкә алмаган икән. Җаныңны тимер кыршау белән кыс, аркан белән уратып бәйлә — әнә шул көч, кыя-тауларны ишеп, дәрьяларны ташытып, яраткан кешең белән тоташтыра. Алдан ук очрашу урыны билгеләмәде Күкчәчәк, алдан ук әйтәсе сүзләрен барламады Күкчәчәк, аның теләк-ихтыярларын ватып-җимереп килде дә ул көч икесен кара-каршы китереп тә бастырды. Кукуруз кырында! Чәкәнләнгән кукурузлар, сакчылар кебек тезелеп, тар сукмакны кеше күзеннән капласа да, хатын җинаять өстендә тотылгандай кызарды.

— Әүвәл син үтеп кит инде, — диде ул, читкә тайпылып.

— Юк, башта син үт. — Мирсәлим, сукмактан чебен очарлык та ара калдырмыйча, колачын җәйде. — Әйдә… ичмасам, бер кочаклармын…

— Азма, яме!

— Азсаң иде әле. Сине уйлый-уйлый тилерәм, ахрысы. Әни үләр алдыннан сөйләде, Күкчәчәк. Кайсыбызда соң хата, ә? Гайбәткә ышанган мин тинтәкме, әллә иң якын кешесеннән чирен яшергән синме? Мин сиңа йөз төрле авыруың белән дә өйләнә идем, бәгырем!

Күкчәчәк сәерсенде: бу ир үкенәме, акланамы? Әллә хатын, кайгырма дип, аның чәченнән сыйпарга тиешме? Шартлап урталай сынган бәхет ансат кына ялганса икән. Әйтерсең Күкчәчәк үткәннәрдәге кәкреләрне бүгенге көнгә сөйрәп кайтарып, турайтырлык кодрәткә ия!

— Өеңдәгеләргә шөкрана кылып яшәргә инде хәзер.

— Син — Лотфыйга, мин — Гөлсемгәме?

— Берсе — минем ирем, берсе синең хатының бит.

Мирсәлим кош канатлары кебек җәйгән кулларын салындырды.

— Исеме генә хатын шул. Ә болай шыксыз шәүлә. Их!

Ахырдан үкенү газабы белән көйдергәнен белсә дә, ник кеше ялгыша соң? «Их», — диде Мирсәлим, йөрәк белән әйтте. Бу аваз әле дә колак төбендә яңгырый. Очрашулар бер, ике, өч саны белән генә чикләнсә икән! Аның һәрберсе элеккесеннән дә тирәнрәк яңа яра иде. Өч ел эчендә әллә ул яралар ямалды дисеңме? Кеше күз алдында йөрмәсә, онытыла, имеш. Онытылыр, көт! Мирсәлим төрмә шулпасы чөмергәндә, хатын сагыш күлендә йөзде… Аңардан башка авыл буш һәм салкын иде.

…Күкчәчәк зираттан туры имче карчыкның нигезенә барды. Тәрәзәләре җиргә баткан иске йорт алдында бер хатын алмаүлән йолкый иде.

— Моның нәрсәдәндер файдасы бардыр әле. — Ул, күптәнге танышлар кебек, Күкчәчәккә елмайды. — Безнең әнкәй йөзләгән төрдә үлән киптерер иде. Аның яныннан иртә очтык, үскәндә берни сорашып калмадык.

— Син кем, апа?

— Бәй, имче әбиеңнең төпчек кызы! Ташкенттан күченеп кайттык. Ә син Бура-Киртәдән, иеме, наным? Синең башыңда, диләр, иеме? Мин сине дәвалыйм, наный! Акчага… Әнкәй безнең синең сыман җүләр иде, бушка өшкерде-төчкерде. Безгә акча кирәк, без йорт җиткерәбез, наным.

— Рәхмәт, мин сау-сәламәт, апа.

— Юк, наным, син сырхау! Акыллы хатын өч чакрым килеп, җиде ят карчыкның каберенә дога укымый ул! Җенле син, җеннәрең тынгы бирми, ары-бире чаптыра. Мужыт шушы үләнне үк кайнатып эчерермен үзеңә. Син анда авылдашларыңа җиткер, хәзер имче әбинең кызы дәвалый икән, диген. Чират икән, алдан ук язылырга икән, диген. Кызы әнкәсеннән дә көчлерәк, диген, наным.

Күкчәчәк моңсу гына иясез йортка карап алды. Мәрхүмә каберендә ничек чыдап ята икән, йа Аллам! Гел шулай, дөнья буталган арада табигыйлек югалып — ясалмалык, хаклык тапталып, ялган өскә калка.

— Бәй, наным, кая ашыгасың?! Чиратка язылганда ук акчасын түлисе, яме! Гөлзифа минем исемем, өченче урамда безнең коттедж!

**4**

Тыкрыкка бала-чагалар җыеп, әләмнәр болгата-болгата «рибалютсия уены» уйнаткан Сабирҗан карт кинәт кенә боегып калды.

— Дөньясы кызык түгел, килен, — диде ул, эчкә баткан яңакларын уып, — дөньясы кызык түгел. Элгәре ач корсакка да уен-көлке белән яши идек, хәзер ашарга да бар, кияргә дә бар, әммәтерәк күңел үсми. Оланнар да икенче. Дәртләре юк. Әзрәк шаулашалар да, тилбизердән баебик күрсәтәләр дип, ызбаларына чабалар. Син карале, килен, ярты метр буйлы оланнарның да аркасында бөкре! Көн-төн тилбизергә чекерәйгәч ничек туры булсын алар.

Тора-бара карт ашаудан да бизде:

— Бугазымнан үтми шул, килен. Элгәре ярты казан бәрәңге белән өч-дүрт телем кара ипине бөкләп салыр идек тә җәяүләп биш аулны урар идек.

Лотфулланың үги атасына талканы коры иде.

Ул:

— Ачтан үлсен сәяхәтче бака. Аның көен көйләмә тагы, — диде.

Ә Күкчәчәкнең картны жәлләп үзәкләре өзелде. Үз чорыннан бүгенгесенә күчалмаган җан иде бит ул. Авылдагы өлкән буын шушы заманга яраклашып беткәндә, «сәяхәтче бака» һаман күкләр гизә иде… Җитмәсә, килен дә аны «яраксыз»га чыгарды. Имам карттан чалдырырга дип бер тавыкның аягын бәйләгәндә, ишегалдында кайнашкан Сабирҗан эти:

— Килен, тавык сатарга җыендың мәллә? — дип сорады.

— Юк, эти. Имам бабайдан суйдырам, — диде хатын. — Шулпа эчсәң, бәлки, хәлләнерсең. Алайса, бигрәкләр дә ябыктың.

— И-и, килен, йортта ир заты барда кем күршегә йөри, китер тавыкны, үзем чалам. — Сабирҗан карт кулын күлмәк чабуына ышкыды. — Китер, китер!

— Сиңа хәрам шул, эти. — Күкчәчәк бик-бик уңайсызланса да, чын дөресен әйтергә мәҗбүр иде. — Син бит, эти… син бисмилласыз кеше бит, эти…

Аһ, ул да Лотфулла сыңары иде. Каты бәгырь! «Кыйблага каратып, бисмилланы укып суй инде, эти», — дисә, укасы коелыр идемени. Бу яшәештә Хак Тәгаләнең кануннар тәртибен бозмас өчен кемнедер рәнҗетергә дә туры килер бугай.

— Шулай дисеңме, килен? Миңа хәрам дисеңме?

Карт, башына тай тибеп миңгерәүләткәндәй, бер урында таптанды.

Үзенең мәнсезлегеннән уңайсызланган Күкчәчәк суелган тавык белән бергә Имам картны да «тота» керде.

— Әйдә, күгәрченнәрдәй гөрләшегез әле, аксакаллар!

Ике кордаш ишегалдындагы утыргычта күңелле генә гәп куерткач, ул Сабирҗан ата алдында, гаебен югандай, җиңел сулады. Башта алар һава торышы турында сөйләштеләр. Гадәттә, өлкәннәрнең сүз җебе шуннан эреләнә башлый. Шушы ят-чит дөньяда аңгәмәдәш табылуына сабыйларча сөенгән Сабирҗан карт тәмам җанланды:

— Карале, кордаш, син дә, мин дә җегәрле халык, кабаттан партиәбезне төзеп, буржуйларның койрыгын кыскартыйк без. Бура-Киртәнең үз Лелиныннан, ягъни миннән файдалансын авылдашлар.

— Шаярмасана, Сабирҗан туган. Ниткән партиә дә, ниткән буржуй ди. Рибалютсиягә кадәрге байлар бүгенгесе белән чагыштырганда пүчтәк кенә. Әнә синең үги малаең бөтенесен дә үзенә көрәде. Көрәсен инде. Барыбер каберенә сыйдырмас. Мин андый ваклыкларга тыныч кына карыйм. Безнең җыр җырланган инде, туган. Аллаһ каршысына нинди йөз-кыяфәт, нинди иман белән тезелербез, шул турыда уйлата хәзер.

— Тиз бирешкәнсең син, кордаш.

— Кемгә, Сабирҗан туган? Картлыккамы?

— Күңелсез уйларга, кордаш. Партиә кешене, дәртләндереп, якты киләчәккә — камунизмга илтә, кордаш.

— Ташла дим шаяртуларыңны, Сабирҗан туган. Иллә дә мәзәк карт син. Теге чуалчык елларда әйбәт җегет идең син, авылга бер зыяның да тимәде, чын мәгәр. Йомшак күңелле идең. Шуның өчен генә мин синең шырдый-бырдый сүзләреңә ачуланмыйча тыңлап утырам. Иту тыңлатырсың Имам картны! Бу саташуларың шайтан галәмәте. Мәчеткә йөр син, туган, эһе. Догалар өйрән. Лелин-Лелин дисең дә, ул да бит Коръән укыган. Аның әнә «Укырга, укырга һәм укырга!» диелгән шигаре кайдан чәлдерелгән дисеңме? Әлбиттә, безнең изге китаптан. Коръән Кәримебез дә бит Аллаһы Тәгаләнең «укы» дигән боерыгы белән иңдерелә. Безне надан димә син, туган. Җәннәтне икенче төрле камунизм дип кенә атый бабаң. Кибетләрдә җаның ни тели — ал да аша, акчасыз гына. Ярлыга-байга бүленеш жук, һәммәсе тигез, һәммәсе дус-тату, янәмәсе. Тилбизердәге тамашалар — үтереш-талашлар жук, зиналар жук, су басулар жук. Тик Лелиныгыз җәннәтне Аллаһтан узып шушы шакшы җир өстендә кормакчы ие, менә аның төп ялгышы шушы ие. Адәм кулы белән, адәм ихтыяры белән оҗмахлар төзелми ул, туган.

— Син, кордаш, Лелинны алай ук хурлама, җәме. Ул халык мәнфәгатен кайгырткан партиә оештырды.

— Ә аның бәлшивикләре нишләде, җә? Асты-кисте! Күпме асыл ирләрне партиә исеменнән аттылар. Примир, мин — гади салдат. Сугышта яраланып плингә төштем, аннан безнең камунислар «хыянәтче» дип мине җәһәннәмгә — лагирга сөрде. Лагирдан соң иллә бер дә тынычлап йокламадым. Төнлә баш очыма итегем белән бүрегемне куеп ятар идем. Кайчан килеп алырлар дип. Плиндәгеләргә икешәр-өчәр кат төрмә исе иснәтәләр иде.

Күкчәчәк картларның бәхәсенә кушылмады. Ул, тавыгын йолкып-юып пешерергә салгач, сарай ишеген ачты. Ябуда сөрсегән кыр үрдәге бәбкәләре ишегалдына сибелде. Тыкрык башындагы «кунак өе»ндә Лотфулла әшнәләре белән типтерә, даң-доң музыка тавышы монда хәтле ишетелә иде. Ир бәндәсе таң атканда гына кайтып авачак. Чөнки кунаклар, авылга гына сыймыйча, урман аланына ташып чыгачак. Ә анда утта яшь бәрән ите кыздырыла. Хатын исә, Лотфулла дөньяның арт ягына тибә-тибә типтергәндә, кыр үрдәгенә ирек бирәчәк. Ишегалды киң, иркен: балаларын очарга өйрәтсен, канатларын ныгытсын. Әллә сизмиме Күкчәчәк, кыр үрдәге Карасаздагы күлен сагына. Бәлки, анда аның пары да калгандыр. Кошларга да сөю-яратулар хас. Әмма аларның мәхәббәте мең өлеш көчлерәк. Кешеләр генә ул бер-берсенә хыянәт итә, бер-берсен рәнҗетә. Әнә Мирсәлим ишеләр… Нәрсә «ишеләр»? Бура-Киртә халкы аны яңадан җирле үзидарә рәислегенә кодалый икән. Кемдер имза җыярга керешкән, ди. Күкчәчәккә эндәшмиләр. Лотфый хатыны дип читләштерәләр, мөгаен. Ә ул теге чакта да Лотфулла хатыны иде ләбаса. Хәзер генә ни үзгәрде соң? Ир белән хатын бер йомгакка чорнала, диләр. Дөрес түгел! Күкчәчәк гомер буе үз дөньясында яшәде. Япа-ялгызы… Лотфулла белән җаннар берләшмәде, берләшә дә алмас иде, чөнки ир коры иде… Йә, кем инде кырда утлаган ун сыерны атып үтерә? Ә Мирсәлим, бу вәхшилеккә түзмәгән ни сабыр Мирсәлим, шушы ук мылтыкны Лотфулланың күкрәгенә төзәде…

Ник дөмектермәгән дип шаулады Бура-Киртә. Заман үзе тудырган җир биләүче күзгә кадалган чүп сыман иде шул. Ул үлсә, авыл коллыктан котылачак. Яраланган Лотфулланы үзәк хастаханәсенә илттеләр.

— Янымнан ни шагу, хатын! — дип үкерде ир, кулын каерып. — Үлсәм, сине дә кабергә сөйрим, көтмә сөеклем белән кавышам дип. Аны төрмәдә череттерәм мин!

Йокы даруы эчергәч, хатын кире авылга чапты. Төне буе ул, йорттан йортка йөреп, имза җыйды. Мирсәлимне яклап… Мирсәлимне аклап… Ә иртән, урыныннан беркая да кузгалмагандай, иренең ятагы кырыенда утырды.

— Нигә кәефең юк? Мин үлмәгәнгә кайгырасыңмы? — Лотфулла кичә боргычлап кара яндырган кулга өрде.

— Юк, синең өчен гарьләнәм, — диде хатын, нәфрәтеннән тулышып. — Гөнаһсыз хайваннарга ничек аттың син, мәрхәмәтсез!

— Икенче юлы гөнаһлы хуҗаларының маңгаена чәпәрмен алайса. Бүтән иген кырын сыер тоягы белән издермәсләр. Киләчәктә сабак булсын аңгыраларга!

— Бигрәк явыз син, Лотфулла!

— Лыгырдама, яме! Духтырдан сораш, нәстә ашарга ярый миңа. Тавык шулпасы дисә, көн дә тавык суйдыр. Мин монда эт кебек айлап-еллап яра ялап, ятакта аунарга уйламыйм, минем кеше үтерүчене төрмәгә тыгасым бар!

Әмма Лотфуллага ярасын озак «яларга» туры килде. Аңа Казанда өстәмә операция ясадылар. Ул терелеп аякка басканда, Мирсәлимгә суд булган иде инде. Өч ел… Халык: «Аллага шөкер, әз срок», — диде. Берәүләргә әз, ә берәүләргә… Күкчәчәк өчен ул мәңгелек кебек иде. Бу еллар, боз кантары сыман, хатынның йөрәге аша шуышты. Иртә дә, кич тә туңдырды, өшетте, калтыратты. Бүген Мирсәлим үз хәлен чамалый микән соң? Яңадан рәислек вазифасына алыну — аждаһа Лотфулла белән канга батышу дигән сүз лә. Хәтәр хәтерле Лотфулла аңа адым саен аяк чалачак.

…Бер кайнарланып, бер суынып бәхәсләшкәч, Имам карт чыгып китте.

Сабирҗан ата, күршесе белән борчагы пешкәнгә шатланып:

— Имам кордаш болай үзе зирәк кеше, — диде. — Тик мона гел үзенең басуын сукалый. Мәчеткә йөр, ди. Лелин башым беләнме, ә, килен?

— Син Лелин түгел, әти.

— Кем соң мин, килен?

— Ап-ак сакаллы, гап-гади Сабирҗан карт син, әти.

Карт көш-көш үрдәк бәбкәләрен куды:

— Тапталасыз, тере йомгакларым, тапталасыз. Чигәләрем кыса, килен. Чүт кенә черем итәм, килен. Шулпаң пешкәч уятырсың, килен. Нәстә диләр, ә? Лелин башың белән монда, эһе…

— Ял ит, әти, ял ит, — диде Күкчәчәк. Ул тагын картны үпкәләтте бугай.

Капканы чебен сыярлык итеп кенә ачып, Гөлсем килеп керде.

— У-у, болар теге кыр үрдәгенең төчкерекләреме? Әйтәм, Лотфулла кунакларга мактана. Көзгә һәрберегез бишәр үрдәк атасыз, ди. Менә кайларда симертәләр икән тамаша корбаннарын!

— Сиңа нәрсә кирәк, Гөлсем?

Такылдык хатын күзе белән үрдәкләргә кадалган иде.

— Бигрәк ябык үзләре, иеме? Ник сулы ләгәнгә бодай сипмисең? Бодай симертә ич!

— Сиңа нәрсә кирәк, Гөлсем?

— Әй, пычагым да кирәкми! Әллә күрше күрше белән йөрешмиме? Кердем әле менә эчем пошып. Лотфулланың ач кунакларын сыйлый-сыйлый аяк табаннарым яна. Ашадылар, эчтеләр, мунчада чабындылар да, машиналарына аслы-өсле төялешеп, урманга сыптырдылар.

— Син сыймадыңмы?

— Һи, монысында абзыкайлар алма күек чибәр кызлар белән иде. Синекенең дә тез башына берсе кунаклады. Лотфый чукынчык миңа «картайдың» дия. Ул яшьләр белән чуала инде. Шәһәр кәнтәйләре белән. Мине асрау итеп кенә кулланмакчы хәзер. Синең белән киңәшим әле, Чәчәк. Мирсәлимемә кире кайтсам кумас инде, эме?

Күкчәчәк чүт кенә «юк» дип кычкырмады. Юк, кайтма, җобага! Мирсәлим аныкы, бары тик аныкы гына!

«Нишлисең син, Күкчәчәк?! Кеше үз иренә әйләнеп кайтырга җыена. Мирсәлим синеке түгел ләбаса! Хыялыңнан җиргә төш, Күкчәчәк!»

— Мирсәлим рәис арбасына җигелсә, мин тәк тә түрә хатыны исәпләнәм инде, эеме?

— Үзегез килешегез, Гөлсем. Мин сезгә кысылмыйм.

— Син Мирсәлимне күрдеңме? Элеккечә мәһабәт ир, ди, чукынчык. Үрдәкләреңне яп та миңа кунак өен чистартыш әле, кызый. Тегеләр дуңгыз кебек мыркылдаша-мыркылдаша ашады-эчте дә идәнгә сөяк бәреп уйнады. Чистый акылсыз бала-чага! Синең иреңнең әшнәләре ич, булыш давай.

Гөлсем такылдаган саен, кыр үрдәге ризасыз тавыш белән бакылдый иде. Бу хатынны кош-корт та өнәми хәтта.

— Гафу ит, Гөлсем, мин кеше пычрагын җыештырмыйм шул. Сау бул.

Күкчәчәк капканы ачты. Мирсәлим кумас диме? Әй Ходай, ничек син шушы мыскылга түзәсең?! Әллә соң ул вакытта Мирсәлимнең акылын томалап торган идеңме? Югыйсә егет солтаны күрәләтә өтек хатын белән язмышын бәйләр идемени!

Сабирҗан карт йокламаган, ул, уйларына чумып, ишек белән түр арасын «үлчи» иде.

— Әни әйтер ие, килен. Бер яхшыга — бер шакшы, бер шакшыга — бер яхшы яки бер шакшыга — бер шакшы, дип адәмнәрне парлаштыра, ди, фәрештәләр. Кайчак ялгыш кына бер яхшыга — бер яхшы, дип тә җибәрәләр, ди. Шулай, килен, Лотфулла — шакшы, син — яхшы.

— Аңламадым, әти.

— Үги малай сиңа тиң түгел, киле-ен. Син яхшыга яхшы бәндә лазем. Урманда кәнтәйләр белән типтерә, ызначит, буржуй калдыгы. Аптырама, теге катын гайбәтен ишеттем мин. Һе-һе, колакның чукраклыгы аркасында. Камунислар партиәсе гүләй-мүләй ясатыр ие, һе. Парткумга дәштереп арт чүмечен кычыткан белән чактырыр иек. Бүген оятсызларны авызлыклаучы җук шул. Аерыл, килен, вәйт сиңа соңгы киңәшем.

Әй, бу хакта Күкчәчәк көн дә уйлый, төн дә уйлый. Күңеленнән генә сәгать саен аерыла. Хыялына чәбәләнеп чуала. Мирсәлим дә ялгыз… Әле аларга өр-яңадан башларга була. Ләкин хыял белән чынбарлык арасында тирән упкын ыржая: Лотфулла! Ирекле баштан хатын аерамыни ул?! Кимсетеп-хурлап яшәсә яшәр, әмма өй җиһазы итеп карарга күнеккән хатынны урыныннан ярты сүәм дә күчермәс. Һай, Мирсәлимдә тәвәккәллек юк шу-ул. Яраткан тәкъдирдә аны урлап, урламаса, күндереп җир читенә качар иде. Бу фани дөньяларда Лотфулланың кулы җитмәслек берәр почмак бардыр лабаса. Их, Мирсәлим, Мирсәлим… Әле бит яңадан рәис булам дип кымырҗый икән. Йа Алла, кан дошманы белән сөзешеп, мөгез сындырулар рәхәт микәнни? Бу юлысы Лотфулла күкрәгенә төзәп аттырмас, өч елда ул усаллык исәпли-исәпли әллә ничә тозак корды. Берсенә капмаса, икенчесенә кабар Мирсәлим.

— Ишетәсеңме, килен? Аерыл! Без сезгә — кыз-катынга — рибалютсия исеменнән ирек дауладыкмы? Дауладык. Сез ирләр белән тигез хокуклы.

— Сез даулаган хокуклар минем өчен язылмаган бит, әти. Лотфулланың үз кануны.

— Борчылма, килен. Буржуй малайны боргычлармын мин. Аңардан мин, э-э... — Сабирҗан карт нигәдер «мин»дә төртелде, гадәттәгечә, «Лелин башым» белән дип ялгап китмәде. — … э-э, теге ни… килен, мин куян түгел аңардан шөлләргә. Ие, куян түгел.

Күкчәчәк көлмәде, чөнки карт җитди иде.

— Аңа телеңне әрәм итмә, әти.

Лотфулла үги атасының сүзләренә җилкә аша гына төкерәчәк иде. Ә шулай да карт күңелне васвасәләтте. Ир — ач күз — хатын-кызга туймады: тәмам туарылып азды-тузды. Аның чүп савытына охшаган күңеле очсыз хатыннар белән тулган, хәзер Күкчәчәк аңа кирәк түгел иде.

Ир төнлә генә кайтты. Тирләп-пешеп ярты болын печән чапкан кешедәй, кое капкачын каерып атып, тимер белән каймаланган чиләкне шалдыр-шолдыр аска ташлады.

— Уф, сусатты. Эчмәдем дә, каһәр. Нәстә йокламадың син? Нәстә ишегалдын саклыйсың? Эт!

Күкчәчәк шәүләсенә карады. Фара яктысында ул канаты көйгән күбәләктәй калтырана иде.

— Син дә хәзер генә урманнан кайттың, бүре!

— Мин — ир кеше. Нәстә дә эшләрмен! Кер, ят! Йокламаган кыз-катынның күз кабаклары шешенә, бит тиресе сәлперәя, ә син миңа матур килеш кирәк. Иртәгә кичкә безгә кунаклар килә. Сарык суйдырам. Бәлеш пешер, мунча як! Мона синең кебек аларның да хатыннары: «Кайда себереләсең?» — дип чәпчи икән. Күрсеннәр чәчбикәләр ирләре бик тату, үрнәк гаиләдә кунак булып йөргәнен, бернинди бозыклык та юк икәнен.

— Гөлсем… Гөлсем хатын роленә бармыймыни инде?

Салкын су белән тамагын юдырган Лотфулла, гыжлап кына:

— Күп сөйләмә, яме! — диде. — Кунаклар алдында да йөземне кызартсаң, кара… — Чиләк киредән кое төбенә очты. — Кара, кичермәм, хатын!

— Мин синнән аерылам, Лотфулла.

— Сиңа бер әйтелгән иде моннан байтак еллар элек. Хәтереңтишек иләк икән. Аерыл, бигайбә! Вәләкин минем тәмуг та бик кайнар: сөяркәң белән кочаклашам дигәндә генә, тәнең чытырдап яначак, үбешәбез дигәндә, иреннәрең көячәк. Ха-ха-ха! Ә Лотфулла не причум! Син кул уйнаткан дип милиция бәйләнмәячәк. Бәс, алар минем ахирләр бит әле. Иртәгә аларның башлыклары да бәлешкә чакырулы.

— Ялгыз яшим мин, Лотфулла.

— Ялгыз?! Синме?! — Ир аны, беләгеннән тотып, фара алдына китереп бастырды. — Япь-яшь килешме? Хет кырык тапкыр тәүбә ит, хет йөрәгеңне амбар йозагы белән биклә, файдасыз. Койма аша сикертер, җирдән шуыштырыр, барыбер шул өтек Мирсәлимнең куенына ташлар. Кем, кем? Табигать, ахмак хатын! Гыйльмия карчыкны котыртмас бит инде ул, аның җыры җырланган.

— Мин сине яратмыйм, Лотфулла.

— Бәс, яратма. Өч тиенемә кирәк синең белән гыйшык-мыйшык уйнау. Яратмаган хатын белән яшәве күңеллерәк тә әле. Син ташла хисләреңне! Ныгытып кунаклар каршыларга әзерлән. Табынны куагында җитлекмичә туган әче әфлисун, мандарин ише әйбер белән тутырма. Алар мужик ашы түгел, алардан эчәкләр бөрешә. Эре-эре бәрәңге, катык, каймак куй. Помидор белән кыярларны пычак белән акыртып суйма, бербөтен торсын.

Лотфулла фараларны сүндерде. Күкчәчәкне караңгылык чолмады. Хатын, абынмас өчен кулларын алга сузып, ачык капкадан урамга чыкты. Кинәт кенә аның төн карасында эреп югаласы килде. Карасаз һаман да куркыныч… Һаман да төпсез… Бәлки, ул шунда гына тынычлык табар. Мәңгегә калса ни! Лотфулланың йорты да саз… Аска суыра, суыра…

Күкчәчәк урам буйлап атлады. Йокысызлыктан интегеп, саран гына җемелдәшкән йолдызлар, күзләрен шарландырып, аңа текәлгән иде. «Кая барасың, әй җүләр хатын? Үз-үзеңне сазга батырып кына котылу булыр, дисеңме?! Гөнаһлы җаның безнең биеклеккә дә менә алмас, җирдә — адәмнәрнең аяк астында тапталыр, тукта-а-а!»

Күкчәчәк туктады. Тик кире борылмады. Югары очтагы бер йортның тәрәзәсендә ут яна иде. Ул шул яктылыкка табан йөгерде. Нәрсәгәдер бәрелеп, тез башын канатты. Ә үзе бер көлде, бер елады. Бу — тилерүнең йә башы, йә ахыры иде: ул бит Мирсәлимнәргә чаба! Теге ут — Мирсәлимнәр уты. Сүндерә күрмә, җаным, сүндерә күрмә. Көч-куәте суырылган хатын, күктән атып төшерелгән кош кебек, тәрәзәгә капланды. Аннан… Әйтерсең җан тәннән аерылды, ул үзен, Мирсәлимнең күкрәгенә башын куеп, сулык-сулык елаган хәлдә күрде. Моңа бик хурланды. Бу хыянәтче ир алдында җебергә тиеш идемени горур болын чәчәге?! Сораулары да сәер иде. Гүя аның теле белән ят хатын сөйләште.

— Чынлап та, авылга минем өчен кайттыңмы, Мирсәлим?

— Синең өчен, Күкчәчәк, синең өчен…

— Һаман яратасыңмы, Мирсәлим?

— Яратам, үлеп яратам, Күкчәчәк.

— Алайса, өеңә чакыр… Бүтән җибәрмә, Мирсәлим. Лотфулладан йолып ал!

— Әз генә сабыр ит, болын чәчәгем. Без угрылар сыман кача-поса кавышмабыз. Син хәзер тынычлан, өеңә кайт. Тик шуны бел: мин сине ул аждаһадан коткарам. Барыбер әмәлен табам.

— Нишлисең, Лотфулланы атып үтерәсеңме?!

— Юк, Күкчәчәк. Ул синә үзе «кит» диячәк.

— Һичнинди янауларсызмы?

— Әйе, болын чәчәгем.

— Тизрәк әмәлен эзлә инде, Мирсәлим! Арыдым мин, Мирсәли-и-им…

## 5

Мирсәлим кулы белән йөрәк читендә кабынган шырпы очы хәтле генә утта җылынып яши башлады ул. Хатын-кызны сөендерер өчен сүзләрне әллә ни бизәргә дә кирәк түгел, ахрысы. «Синең өчен кайттым… Яратам… Әмәлен табам…» Аңа шул да җитә икән. Бу юлысы ир яшьлек хатасын кабатламас. Гайбәт тыңлап Гөлсемгә өйләнгәндә, ул алда нинди сызланулар кичерәсен сизми иде әле. Ә бүген сизә. Шуңа аның вәгъдәсе дә ышандыра. Чарасын табар Мирсәлим, һичшиксез табар. Күкчәчәк аны ашыктырмый, ул, минутларны санап, сабыр гына көтә. Авыл урамында ялгыш кына очрашсалар, җан кинәнә. Икесенең дә күзендә мөлдерәмә сөю… Ташый гына күрмәсен! Юкса Бура-Киртәдә көз сарысы сугып шиңгән чәчәкләр яңадан терелер… Аннан авыл: «Табигать саташкан», — дияр. Монда икәү саташканны белмәсләр.

Күкчәчәкнең бердәнбер сердәше кыр үрдәге иде. Җавап кайтармаса да, киңәш бирмәсә дә, ул аңа сөйләде. Алар икесе дә, Лотфулланың читлеген тарсынып, иркен дөнья турында хыяллана иде.

Беркөнне ир, атсыз бармагы белән һаваны чокый-чокый, хатынын кисәтте:

— Үрдәк бандасын ишегалдына чыгарма! Тагаракка су күп салма, су ябыктыра. Сабирҗан эти казыган чокырны күмдереп дөрес эшләдем әле. Бодай бир, ул яхшы симертә. Кошлар, төп кебек, Карасаздагы кәрлә каеннар арасында утырырга тиеш. Аларга очмаслык авырлык кирәк. Дусларга шәп ау оештырачак абзагыз, һа!

— Киек кош-корт канын койган бәндә хәерле үлем белән үлмәс, дигән борынгылар, — дип, үги малайга үгет-нәсихәт укырга керешкән Сабирҗан картны болай да санламаган Лотфулла аягы белән җиргә сыткан ишарә ясады.

— Әй син, Ленин! Әҗәл белән кочаклашкан идең бит. Бар әле, бар, дәвам ит шул эшеңне, иту тибәрмен дә егармын, — диде ул, ачу белән. — Как хатын белән сүләшәм, килә дә тукмак борынын кыстыра, коммунизм өрәге!

— Моннан ары мин Лелин түгел. — Карт юашланган иде. — Минем чын атым бар, улым.

— Тагын кем инде син, җә?

— Мин гап-гади Сабирҗан, улым.

— Һа! Нинди зур яңалык! Димәк, Ленин бабай пышыйк, димәк, тыкрыкта бот буе бала-чага белән рибалютсия ясаулар пышыйк. Иту безне җимерек ат арбасына төяп, Себер җибәрәсең дип дер калтырап яши идек. Хәзер нишләрсең инде, гамәлдән сызылган юлбашчы? Тагын кемнәр белән җенләнерсең?

Картның ни-нәрсә эшләве Лотфулланы кызыксындырмый, ул аны үрти генә иде.

— Шөгылем бар анысы, улым. Мона син тыңлап бак!

— Синең сафсаталарың белән колак сасытырга вакыт юк, кырда иген яна! Әнә киленеңә сайра, аңа кызыктыр.

Әмма карт Күкчәчәккә ачылмады. Шул көннән ул дәшмәс булды. Ә бүген мунча башындагы байрак-әләмнәрен арт бакчага ташып яндыргач, беркавым таяк белән көл өемен тузгытып утырды да, сөлгесен беләгенә элеп, ашыга-ашыга Имам күршеләргә кереп китте. Иркенлек тойган хатын «тоткыннар»ны ишегалдына таратты. Әй, ни әйтерсең тагы!.. Төшендә ул кыр үрдәге белән янәшә очты. Күк бишегендә ничек рәхәт иде! Йомшак куллы болытлар сиртмәне тирбәтә-тирбәтә… Җирдә күргән җәбер-золым эреп канат очыннан тама… Ирек тәменнән исергән Күкчәчәк кычкырып-кычкырып көлә… Бәхеттән шашынган шушы мәлләрдә генә төш өзелсен иде икән. Офык читендә көткән Мирсәлимгә җитәм дигәндә генә, кемдер хатынның канатларына үткен пычак белән сыза. Күкчәчәк уктай аска мәтәлә. Моны нәрсәгә юрарга инде, йә? Биектә очу ул — яуланган ирек, тик менә бусы да фаҗига түгел! Җан сөймәгән ирдән аралангач, берәү дә Мирсәлим белән Күкчәчәкнең арасын бутамас. Гөлсем санга бар, исәпкә — юк. Мирсәлим белән боткасы пешмәгәч, ул, калдык-постыкка да ризалашып, Лотфулла табынынннан туена. Кинәт кыр үрдәге пырх итеп һавага күтәрелде дә, пәрәвез җебе сыман, баш очында асылынып торды. Ана кош, «әйдәгез, әйдә» дип, астагыларны да дәшә-чакыра кебек иде. Эреле-ваклы үрдәк балалары, канатыннан җил сызгыртып, әнкәләре артыннан югарыга томырылды, әмма аларның көчләре чамалы иде, алар берәм-берәм кире җиргә коелды. Кыр үрдәге дә чирәмгә төшеп кунды. Әле иртәрәк иде, иртәрәк…

Бу тамашаның шаһиты Сабирҗан карт:

— Болар шыпан-шыпан җыена, — диде. Ул сөлгесен чалма рәвешендә башына ураган иде.

— Кая, әти?

Күкчәчәк юри сорады. «Кая?», имеш. Әйтерсең ул сукыр, әйтерсең чукрак.

— Иреккә, килен, иреккә. Кошларда адәм сабырлыгы юк, табигать чакырса, төбе-тамыры белән кубалар. Син теге… Авыз ачып калма, дим. Бер җай кошларыгызны күк суырыр, дим. Үзеңне Лотфулла сугып имгәтер аннары, килен.

— Ни язса, шул булыр, әти. Менә син дә каядыр әзерләнәсең шикелле.

— Ни бит, килен… Сырхаулап ятканда, Имам күрше хәл белергә керештерде бит. Бер-беребезне авыр сүзләр белән үпкәләтмичә генә әйткәләштек тә инде без. «Моннан ары сиңа сәлам дә бирмим» дигән күрше, үпкәсен онытып, тагы керә иде бит, бакчи. Ничек кенә кирегә сукаласам да, Имамныкы дөрес бит, килен. Алла бар, Алла бер, аны йөз Лелин да, йөз рибалютсия дә алыштырмый. Адәмнәр җир кануннарын үзләре төзиләр дә, үзләре үк бозалар, ди күрше. Хак әйтә. Аллаһы Тәгаләнең безне яшәргә өйрәткән китабы мәңгелеккә язылган, аны беркем дә сызалмый-төзәталмый, килен. Ни инде… Имам күрше тәһарәт алырга өйрәтте инде. Мәчеткә — җомга намазына әйдәкли хәзер. Миннән көлмәсләр микән, килен?

— Иман юлына баскан карттан көлсәләр, авызлары чалшаер, әти. Тукта! — Хатын өйдән иске кәләпүш тотып чыкты. — Сөлгеңне чиш, әти. Мә, ки, мәрхүм атамның төсе бу.

— Рәхмәт яусын, килен кызым. Әйдә, кош-кортларны тиз генә җыештырып, урыннарына ябыйк. Ана үрдәк гел күкләр күзли, бакчи, — дип, капка ярыгына кыстырган талчыбыкка үрелгән картка Күкчәчәк, йомшак кына:

— Җомгага соңарасың, әти, — диде.

Күкләр күзләсә ни! Биеклек — канатлылар мәйданы лабаса.

Хатын капканы шар ачты. Аннары, Лотфулланың янауларыннан куырылып, үрдәкләрне сарай ишегенә табан куарга кереште. Саз кошы маңгай терәп карышмады: ул акыллы иде, ул балаларының зур ачышлар өчен зәгыйфьрәк икәнен бүгенге ярым-йорты канат җилпүләрдән үк аңлап өлгергән. Бер үк вакытта ана үрдәк хәйләкәр дә иде. Икенче мәртәбә ул «тере йомгаклары»ның тәпиләрен генә җирдән аертты. Өченчесендә исә араны берничә сүәмгә озайтты.

— Килен, тиздән син боларның соңгы сәламнәрен генә ишетмәгәең, — диде Сабирҗан карт. — Үги малай каты куллы, үзеңне сугып имгәтер, дим. Сак бул.

Ә хатын:

— Ярар, әти, бүтән ишегалдында иркенәймәсләр, — дип ант итә дә, иртәгәсен ниндидер көчкә буйсынып, сарай ишегенең келәсен ычкындыра иде.

Кояш белән бергә уянып кырга киткән, ә төнлә учак төтене исләре, юнь хушбуй исләре сеңдереп түшәгенә кайтып ауган Лотфулла аны-моны сизмәде. Шуңа Күкчәчәк, тәмам тугарылып, кошлар очырды. Үрдәкләргә кушылып аның да җаны югарыга атыла һәм, кояш нурларында җылынып, өмет белән өретелә иде. Бәлки, әлеге минутларда Мирсәлим бер-бер чарасын күргәндер дә инде. Кичә ир, мәктәп кырыеннан узганда, укучылар белән бакчада кайнашкан хатынга күңелле генә каш сикертте. Әй, егет чагындагы гадәте инде бу аның. Нинди булса да сер әйтергә уйласа, кашлары «җанлана». Гауга куптармыйча гына Лотфулладан өзелсәң иде, Раббым! Иренең риза-бәхиллегеннән башка аерылса, тәмугта яначак ич Күкчәчәк. Лотфулла яндырачак аны, Лотфулла.

Беркөнне хатын әздән генә тотылмады. «Төшке ашка көтмәгез» дигән ир күзен-башын акайтып кайтып керде. Күкчәчәк ишегалды уртасындагы ләгәннәргә су тутыргач, сарайга табан өч-дүрт адым гына атлаган иде.

— Бусы нәстәгә?! — дип үкерде Лотфулла. — Әллә үрдәкләр йөздерәсезме?!

Күкчәчәк ис-тын җыйганда, Сабирҗан карт:

— Килен кер чайкый, улым, бакчи, — диде.

Вакчыл Лотфулла бу юлысы: «Кайда керләрең?» — дип бәйләнмәде, аның үзенеке куәтле иде, ахрысы. Ул, кош-корт аулаган төлке сыман, сарайдагы үрдәкләргә ташланды. Әле берсен, әле икенчесен эләктереп кулында үлчәгәндәй иткәч, идәнгә атып-атып бәрде.

— Мыскыл, валлаһи! Күгәрчен хәтле генә бит гәүдәләре. Хурлыкка калдыралар бит, үләксәләр. Ник тазармыйлар икән? Амбар-амбар бодай ашатып бит!

Сабирҗан карт аңа:

— Улым, начар ниятеңнән тыйлык син. Куакка бәйләп үрдәк аткан бәндәнең Алла кулын корытыр, киек кошлар үз үлеме белән үләргә яратылган, — дигән иде, Лотфулла әтисенең башындагы кәләпүшен сугып төшерде:

— Ачу казанымны кайнатып, шушы сәләмә «каз оясы»н чәпәп куя монысы да! Кичә телләрендә Ленин иде, бүген — Алла. Тфү, ике яклы пәкеләр! — Ир җиргә төкергәч, җиң очы белән иренен сөртте. — Күкчәчәк! Сиңа өч көн срок бирелә. Үрдәкләрне хет һава өрдереп симерт. Ау чоры башланды. Яңа гына сызгырдылар, өч көннән Бура-Киртәгә кунаклар килә.

Күкчәчәк үз-үзен тыя алмады, аның бөтен гәүдәсе токка эләккәндәй калтырый иде.

— Кош-кортны җәзалап үтермиләр… Атмыйлар кош-кортка… Хәрам ул…

— Һа, үз бодаемны состырып үстергән үрдәкләр хәраммы?! Соңгы вакытта син зерә телләшәсең, хатын! Шушы ике яклы пәке белән берләшеп, миңа каршы фетнә оештырсагыз, берегезне асам, икенчегезне атам бит, белегез! Әле өченчегез — төрмә чыпчыгы да бар. Аңа аерым җәза. Ә дүртенчесенә — Мирсәлимне яклап имза җыйган кешегә — особый үлем. Нәстә терәлешеп каттыгыз? Сарайдагы мәхлукларны бүксәләре шартлаганчы ашатыгыз.

— Өч көндә генә симермәс алар, улым.

Сабирҗан карт, учына бәрә-бәрә, тузанланган кәләпүшен какты.

— Карале боларга берегез! Гел кирегә сыпырып торалар бит. Төнлә дә йокламагыз, ипи турагыз, — дип ярсыды Лотфулла. — Келәткә китереп аударганны савытка чыгарып салырга иренәләр, эт ялкаулары! Моннан соң сәгать саен кайтып тикшерәм.

Дулаган ир артыннан җил тыну белән, Күкчәчәк:

— Миңа булыш әле, әти! Тиз генә үрдәкләрне су коендырыйк әле, — диде.

— Әй килен, килен, су тагын даябыктыра. Бодай ташыйм, булмаса.

— Ябыксыннар шул, ябыксыннар, әти.

Кая ашкына ул, йә? Ник болай тилерә?! Үлем якынлашканда бәхетсез кошлар очу тәмен, очу ләззәтен тоеп калсын диме? Бу шашынулар хәерлегә түгел бит инде, Ходаем! Нишләп дөнья акылын җыйган Сабирҗан карт «тукта» дип кулына сукмый?! Нишләп ул балалар кебек йөгерә-йөгерә килennнең кушканнарын үти?! И дөнья, нәрсәгә калдың…

Бу юлысы саз кошы, башын кыеш-мыеш боргалап, күккә карады һәм, болай да салынган канатларын җәеп, җиргә чүмәште. Берсен-берсе уздырып бакылдашкан бала үрдәкләр ләгәндә чиратлашып йөзде-чумды, һавага күтәрелмәк булып и талпынды, и җилкенде. Кыргый дәрт аларның канын кыздыра, ерактагы бабаларының болытларга бәрелеп чәчелгән кайтавазы, хәтерне кытыклап, җаннарын кыбырсыта иде. Тик ни гаҗәп, әнкә коштан ым-ишарә юк. Ул әйтерсең тәкъдиренең азагы ничек беткәнен сизенә һәм, шуның белән килешкәндәй, үлем сәгатен көтә иде.

— Бар, оч! — Күкчәчәк аңа яулык белән селтәнде.

Ана үрдәк ярты сүәм генә күчеп утырды. Ул көнне «сарай тоткыннары»н бер яптылар, бер чыгардылар.

Ахыр чиктә Сабирҗан карт:

— Мин кыекка сөялгән баскычта кизү торам, олы юлдан Лотфулланың машинасы авылга җилдерсә, кошларыңны җыярсың, килен, — диде.

Файдасы булмады: үрдәкләр көзнең соңгы саран кояш нурларында канат киптереп ятты. Ә иртәгәсен, суларга да ара калдырмыйча, Лотфулла кайтты-китте. Вакыт кысылган саен кысыла иде. Ана үрдәккә үпкәләде хатын. Күк капкасы бикләнмәгән, күк капкасы ачык, әллә кулдан ашый-ашый моңа да коллык сыйфаты сеңгән микән?

— Тәки очырмак буласың, тәки башыңа маҗара эзлисең, килен. — Сабирҗан карт та шымыйган иде. — Кош-корт тәкъдиргә буйсынадыр, шәт. Азапланма, килен.

Кичкырын ир төргәге белән ефәк бау кайтарып ташлады.

Ул:

— Әй, кайда сез, йорт ияләре? Планнар үзгәрде әле монда. Кунаклар өелешеп бүген үк Бура-Киртәгә килмәкче икән. Миңа үрдәкләрне гатавайлагыз, аякларын бәйләп, өчәр-өчәр итеп капчыкларга тутырыгыз. Шофер Рөстәм белән төнлә килеп алырбыз. Ауны таң алдыннан оештырам. Тегеләр хәмердән кызсын башта. Куакка беркетелгән үрдәкләрне әйле-шәйле генә күрсен. Һа! — дип, ике-өч тапкыр ишегалдында әйләнде.

Хатын кинәт кенә әшнәләрен каршыларга ашыккан Лотфулланың алдына сикерде. Аңа барысын да әйтеп өлгерергә кирәк иде.

— Син көпә-көндез сыер аттың, казларның канатын сындырып җәзаладың, сарыкларны машина белән таптаттың! Беләсеңме авылда синең кушаматың ничек? Җәллад! Җәллад син, Лотфулла! Хәзер үрдәкләрне ядрә белән тишкәләп шаярасыңмы?!

— Вәйт аңгыра! — Ир, гаҗәпләнеп, кулларын як-якка җәйде. — Нәрсә дияргә соң моңа, ә? Укытучы кеше бит үзе! Мин бит, әнә шул түрә-кунакларны җайлый-җайлый процентсыз ссудалар алып, хуҗалык сөйрим. Җүнгә генә ашлама, чәчү орлыгы теләнәм! Ә син монда маңгаема чүкеч белән чүкисең, аңгыра! Сиңа җиңел ул әзер китаптан гына балалар укытуы. Кит, каршымда күперенеп торма!

Лотфулла аны тупас кына этеп җибәрде. Үз көчен чамаламаган Күкчәчәк уң як чигәсе белән капка баганасына бәрелде.

— Эзләгән маҗараңа тәки юлыктың, килен. — Сабирҗан карт кер бавына элгән сөлгене хатынга сузды. — Мә, сөрт әле, кан тибә, бакчи. Бу малайда иман әсәре юк икән. Син исән чакта моңардан качып котыл, килен.

«Качып котыл…» Аның дөньяда бердәнбер теләге шул гына иде. Кайвакыт ул Мирсәлимгә рәнҗи дә. Ир әнә үз тормышын көйли-чөйли: сайлауларда җиңәр өчен аяк баскан урынын ныгыта. Ә Күкчәчәк… Күкчәчәк һаман артка чигерелә. Куактан курка-курка гына җимеш йолкыган малай сыман ул. Умыртып өзалмады инде.

Хатын, бакчага чыгып, озак кына кояш баешына карап утырды. «Кунак йорты»нда гадәттәгечә ыгы-зыгы: Гөлсем тирестә тибенгән тавыкларны куа. Аңа да табын хәстәрләргә әмер бирелгән, күрәсең. Өч-дүрт җирдә ризык төрләндермәсә, Лотфулла кунагының тамагы туямыни!

Гөлсем уфыра-уфыра аның янына килде.

— Синме соң, күршекәем? Ник сагышланасың бу тиклем? Йөзең көл төсле күм-күк. Синең шул эшең әз. Укытучы ласа. Ентилигент кисәге. Синеке, өч тавык тутыр, мунча як, ди. Бу кунаклары энҗе-мәрҗән белән зиннәтләнгән, ахрысы. Җиләк-җимешне Казаннан ук кайтартты. Чистай базарыныкы гына ярамады, каһәр. Күкәй төсле, һәр әфлисунын ак кәгазьгә төргәннәр, кызый. Мараканскимы, тараканскимы сорт, ди. Бинаграт аерым кәрҗиндә. Балыкның ниндие генә юк. Соңынтын керерсең, кызый, ике җәтимә калдык-постык белән сыйланырбыз. Сине дә җәллим, үземне дә җәллим. Бәхетеңә кушаяклап керпе типсә, ятасың инде ялгыз угаланып.

— Кит әле, Гөлсем…

— Әй, китәрмен дә! Нәрсә чыраең караңгыланды? Әбәү, чигәңдә кан укмашкан! Кем сукты, кызый?

— Зинһар, кит, Гөлсем!

— Йә инде, йә, элеккеләр өчен ачуланма, кызый. Лотфулла ни сиңа, ни миңа дигәндәй. Безгә хыянәт итә бит ул, кызый. Итәгендә Казан сөяркәләре аның, күзем чәчрәсен менә! Төнлә юри кер әле, яме. Кара тавыш куптар, өстәлне әйләндереп капла. Сиңа килешә, син — законлы хатыны.

— Зинһар, такылдама, Гөлсем!

— Фу, эченә салам тутырган курчак ич син! Җансыз кеше! Аңа түләүсез акыл өйрәткән мин җүләр. Җә, хуш!

Әллә көн азагында адәм баласына тагын да авыррак микән? Нәрсәдер үлә, бетә, төгәлләнә төсле. И-и, Мирсәлим, Мирсәлим… Умыртып өзмәдең, җаным, өзмәдең!

Сабирҗан карт мытырдый-мытырдый кайчы белән бау тураклый иде.

— Утыз сигез үрдәккә — утыз сигез кисәк. Син, килен, боекма, җәме. Кошлар да язмыштан узалмый, димәк. Караңгылата, сарай утын кабыз. Син тәпиләреннән тотарсың, мин бәйләп капчыкларга салырмын. Ул явыз малай кушканнарны эшләмәсәк, үрдәк урынына үзебезне атмагае. Балачакта ук шәфкатьсез булды Лотфый. Мәче баласын кәтүк җебе белән буа, кигәвеннең артына салам тыгып очырта, баканың сыртына тоз сала иде. Миндә дә гаеп, миндә дә. Лелин әсәрләре укытып, тимердәй нык рибалютсиәнир ясарга уйладым. Динсезлек аркасында бу, килен. Рибалютсиәнирләр дә дөрес юлда булмаган әнә. Шарт-шорт кеше аткан, җимергән, туздырган, төрмәдә асыл ир-җегетләрне череткән. Имам күрше хак әйтә, аңарда ялган юк, килен. Син, килен, мине үз кулларың белән картлар йортына илтеп тапшыр да үз сукмагыңа турыла инде, әйе.

— Миңа син артык түгел, эти. Китсәм, үземнән калдырмам.

— И рәхмәт яугыры, килен кызым.

Баядан бирле эче янган хатын картның колагына иелде:

— Әти… Мирсәлимгә шыпырт кына әйтеп кил әле. Хәзер үк! Карасаз кырыенда сакта торсын. Бәйләтмәсен үрдәкләрне кәрлә каеннарга. Авыл бу хәлне ишетсә, синең белән минем исемне дә төрләндереп каһәрләячәк бит!

— Алла сакласын, килен!

Карт җитез аяк иде, югары очка чапты. Күкчәчәк урам як утын кабызды. Иренеп кенә төн килә, күк йөзен бизәгән тулы ай кара төс җирлегендә сары-кызгылт булып күренә иде. Гамьсез үрдәкләр борынын канат астына төртеп йоклаган инде. Хатын аларны ишегалдына куды. Сарайда бәйлә ни, монда бәйлә ни, барыбер түгелмени.

Йокысыннан бүлгән өчен ризасыз тавыш белән бакылдаган ана үрдәк канат очын тузанга мана-мана шап-шоп кагынды да, әллә нинди озын һәм нәзек аваз чыгарып, балалары арасыннан йөреп үтте. Аналарының җырына бүтәннәр дә кушылды. Ишегалдында мәхшәр купты. Баскыч төбендәге мәче, чатыр-чотыр багана тырнап, өйалды түбәсенә шылды, эт оясына посты. Кинәт «мәхшәр», җирдән кубып, туп сыман өскә атылды. Күкчәчәкнең битенә тузан катыш каурый-мамык бөртекләре сыланды. Гүя кошларны ай суыра иде. Хатын коты очып аларның кире төшеп утырганын көтте. Ләкин үрдәкләр, һавада җеп тарткандай, тыкрыкка табан юл сапты.

— Йа Аллам! — Хатын урамга атылды. — Нишлисез сез, әй?! Туктагыз! Кире борылыгыз! Юк, юк, зинһар, туктамагыз! Очыгыз, оч! — Тыкрык буйлап «җеп»кә ияреп чапкан Күкчәчәк сөрлегеп егылды да, тез башларын уа-уа, аксый-аксый тагын йөгерде. — Борылмагыз, борылма! Хушыгыз, бәгырькәйләрем!

Кошлар, ай нуры яктысында йотыла-йотыла, ноктага әверелде. Хатын кан саркыган тезләренә учлап-учлап туфрак сипте. Хәзер генә дөньяда нидер булды… Ишегалдын тутырып бакылдашкан кыр үрдәкләре дәррәү иреккә очты-ы… Кыргый кан җиңде. Күкчәчәкнең тәне генә җирдә, ә җаны кошлар янәшәсендә — биектә-биектә иде…

Йомышын төп-төгәл йомышлаган Сабирҗан карт шар ачык ишек-капкалардан, буш ишегалдыннан барысын да аңлаган иде, ул, таралган-сибелгән бау кисәкләрен себерке очы белән әләктереп бер өемгә җыйгач, телсез-өнсез хатынга селтәнде:

— Кач, кач! Лотфулланың телендә ни, кулында шул. Имгәтә, бел! Бу башбаштаклыгың аңа ошамас.

Аңа качарга кирәк микәнни? Нигә? Лотфулла барыбер җир астыннан да табачак. Әгәр сиңа җәза тиеш икән, ул инде ычкындырмый, ул чәч бөртегеңә кадәр чытырдап ябыша.

— Килен, килен! Олы юлдан утын яктыртып машина төшә, Лотфулла, ахрысы. Кач инде, кач, — дип үрсәләнде карт.

— Борчылма, әти. Лотфулла бернишләталмас. Акырыр-бакырыр да тынар.

— Ай-һай, килен!.. Дуамал атта акыл юк, диләр. Төтен исе борыныңа бәреләме? Безнең малай, бакчи, авылга үч итеп салам яндыра, ди. Сатмакчы икән дә, халык бәясен күпсенгәч, уттан ялмата, имеш. Бушка өләшәсе нәстә бит ул бу тук заманда.

Лотфулла җеннәре өермәсендә бөтерелә-бөтерелә кайтып керде.

— Капчыкларны машинага ташы, живо! — диде ул шофер егеткә. — Әй, каккан казыклар, сез дә булышыгыз.

Сабирҗан карт белән Күкчәчәк, чынлап та, каккан казык иде.

Шофер егет уңга-сулга каранды.

— Капчыклар кайда соң, Лотфулла Сәфәрович?

— Кайда, кайда? Атаң башында! Сарайда!

Хатын, үги атаны ышыклап, алгарак атлады:

— Үрдәкләр сарайда юк. Алар очты…

Әйтерсең төнге күкнең бер чаты кителеп өскә ишелде: ир бугазы ертылганчы акырды:

— Нәстә-ә-ә?!

— Кем дә гаепле түгел, очтылар шул, улым, очтылар, — дия-дия, бу юлысы Сабирҗан карт Күкчәчәкне ышыклады.

— Мин синнән гарык, тиле бака. Һаман ботыңны тәртәгә кыстырасың! — Лотфулла картны җилкәсеннән умырып тотып, келәткә илтеп бикләде. — Ят шунда тәтелдәп. — Аннан ул хатынны әле бер якка, әле икенче якка җилтерәтте. — Тәки очырдың, ә? Тәки иреңә этлек эшләдең, ә? Мин сине камчы белән ярам, валлаһи. Беләм мин үрдәк сәләмәләренең кайда кунганын. Карасазда алар! Берәм-берәм атып чыкмасам, Лотфулла исемен паспорттан сызсыннар! Йорттагы малларны аякландыручыга аерым җәза тиеш. Әйдәле сарайга!

Ир бау төргәген дә әләктерде. Күкчәчәк карышмады. Әйе, аны җәза читләтеп үтмәячәк иде.

— Саз йотар, эчкә үк кермә, — диде ул, тыныч кына. Аны хәзер ирнең янаулары куркытмый иде инде.

— Йотмас, нибуч! Мирсәлим ташлагач, син хурлыгыңнан билдән саз былчырагы ерып та үлмәдең бит. Миндә синең хәтле генә акыл юк дисеңме, аңгыра. — Лотфулла кысып-кысып аның аяк-кулларын бәйләде. — Хәерчеләр чабатасыннан ярдәм сорап кычкырма, кара, хатын!

Бау белән кырык тапкыр уратып куйсалар да, гарьләнмәс иде Күкчәчәк. Тагын Мирсәлим белән җанны кыйный бу адәм. Шушы минутта үзенең дә йөрәген без белән тишкәлисе иде.

— Мирсәлимнең төрмә срогын киметер өчен имзаларын мин җыйдым…

— Шулаймыни? — Ир бауның очын кискен генә тарткан иде, аяк сөяге пәке белән кискәндәй әрнеде: — Вәт рәхмәт! Минем эзтабарларның эшен җиңеләйттең, ә үзеңнең хәлләреңне мөшкелләндердең бит әле, хатын. Сиңа камчы гына аз, ипи кебек телемнәргә тураклыйм мин сине. Фани дөньялар белән хушлашырга әзерлән.

Ир аны сарай почмагына селтәп атты. Ут сүнде. Ишеккә тыштан амбар йозагы эленде.

Күкчәчәк кычкырып карады:

— Саз суыра, барма-а!

Ләкин таш сарай аның тавышын чыңгылдата-чыңгылдата үзенә йотты. Йа, Алла каргаган нинди көн бу?! Тәүбә, тәүбә! Бәндәсе өчен яратып төзегән көннәрен каргыймыни Алла?! Кеше үзе, аның кануннарын бозып, һәлакәт упкынына ыргыла.

Кул-аягы тышауланган хатын чарасыз иде. Алай да ул өзеп-өзеп тагын кычкырды:

— Бар-ма!..

Таш дивар салкыны туңдыра-өшетә иде. Күкчәчәк гәүдәсен туп кебек тәгәрәтеп алгарак күченде. Шулай күпме яткандыр, кемдер амбар йозагын каерды. Менә ишек ачылды, караңгылыктан сукырайган күзгә кояшның сыңар нуры чәнчелде. Таң ата иде.

— Килен кызым, син мондамы?

— Әти, тизрәк чиш!

— Нишләтте сине имансыз Лотфый?! Исән-әманмы син? Келәттә энә сыярлык та ярык юк, түшәмен сүттем аптырагач. Озаграк маташылды шул. Әй килен, килен! Чөяләп-чөяләп бәйләгән, бакчи.

— Лотфулла, үрдәкләр Карасазда, ди, әти. Шунда китте бугай ул.

— Хафаланма, килен. Үзен бә-әк җәлли, малай актыгы. Эчкә үк кермәгәндер, саз тирәсендә котырынып чапкандыр да эшнә-мәшнәләре белән урман аланында аракы чөмерәдер.

Баудан арынгач та оеган кул-аяк тиз генә язылмады. Гүя тамырларда кан йөреше бозылган иде. «Эчкә үк кермәгәндер… Үзен бә-әк җәлли…» Ярый ла, ярый ла… Саз бит ул — үлем дигән сүз. Хатын аксый-туксый капкага титаклады. Ә анда… анда Лотфулланың машинасы тора, шофер исә, утыргычны артка аударып, изрәп йоклый иде. Күкчәчәкнең йөрәгенә боз катты. Ир эшнәләре белән типтерми, димәк…

Күкчәчәк, тилергән сыман кулларын бутый-бутый, Карасазга табан йөгерде. Саз юлы болын аша иде. Болын өстендә аксыл томан. Кемдер учак ягып төтен тараткан төсле. Күкчәчәк ерактан ук ир-ат гәүдәсен шәйләде. Бозланган йөрәк әз генә җылынды. Аллага шөкер, Лотфулла исән! Әллә үрдәкләр алдына очып төшәр дип көтәме, исәр?! Ләкин күзләр алдана. Томан кояш нуры белән кушылып сыекланган саен, теге ир-атның да төс-кыяфәте аныклана, тик ул бер генә дә Лотфуллага охшамый иде. Ничек онытты икән: Сабирҗан карттан саз янына Мирсәлимне чакырттырган иде ләбаса. Мирсәлим бу, Мирсәлим!

Сулуы капкан хатын башта аңа эндәшмәде. Икесе дә телен йоткан сыман иде.

Аннан соң гына Күкчәчәк:

— Син… син монда күптәнме, Мирсәлим? — диде.

— Ярты төннән бирле, Күкчәчәк.

— Саз тирәсендә Лотфулланы күрмәдеңме?

Ир томырылып хатынга карады. Аның карашында сөенү дә, шик-шөбһә дә бар иде. Беренчесен кабул итмәде күңел. Лотфулла гаип, ә Мирсәлим шуңа эчтән генә сөенә кебек. Карасазга кергән, ахрысы, Лотфулла, кергән…

— Син… Син Лотфулланы күрмәдеңме, дим?

Мирсәлим ияге белән генә кәрлә каеннарга ымлады.

— Ник аны тотмадың?! Ник?! Ник?! — дип, хатын йодрыклары белән ирнең киң күкрәген төйде. — Дөмексен дидеңме?! Син мине Лотфулладан бүтәнчә араларга тиеш идең, җебегән!

Мирсәлим йодрыклардан качмады, ул бу тамашадан югалып калган иде.

— Күкчәчәк, җаным! Лотфый мине тыңларлык хәлдә түгел иде. Мылтык түтәсе белән чүт башымны ярмады менә. Чыгар дип мин аны таңга кадәр көттем. Ирләрчә сөйләшербез дигән идем. Чыкмады… Күрәчәге шулдыр, бәлки.

Авыл очында Имам күршесен иярткән үги ата күренде. Картлар сазга турылаган иде. Күкчәчәк ирнең күкрәген дөмбәсли-дөмбәсли арыган кулларын гәүдәсе буйлап салындырды.

— Күрәчәк, күрәчәк, — диде ул, нәрсәгәдер үртәлгәндәй.

Кәрлә каеннар арасына чумар өчен бер сикерү җитә иде. Әнә җиргә борыны белән кадалган җимерек койма. Мөгаен, ярсыган Лотфулла аны аударып узгандыр. Ир бәндәсенә, гәрчә ул никадәр генә гөнаһлар кылса да, Ходай мондый ук язмыш язмас кебек иде.

— Тукта, мин аның белән күпме гомер иттем бит… Болай ярамас бит… Эзлим әле…

Хатын коймага табан ыргылмакчы иде, көчле куллар иңбашыннан эләктереп алды:

— Хәзер сине сазга җибәрсәм, мин, чынлап та, җебегән булырмын.

Күкчәчәк ычкынырга теләп тартылмады. Аның көче суырылган иде инде. Ул, коточкыч авыр йөктән бушанган ат сыман, гомерендә беренче мәртәбә тугарылды. Ава башласа — артында ышанычлы терәк тә сизде. Җан гына сыкрана иде. Җитмәсә, Мирсәлимнең кул җылысы, йөрәкне камаган бозны эретеп, ике күздән яшь китерә иде. Ничә ел кыен ашап, шуңа түзеп яшәлде… Ничә ел! Димәк, еламаска, еламаска, еламаска… Ай, ир бәндәсенә мондый ук күрәчәк кирәкмәс иде лә! Саз күлендә чупыр-чупыр кыр үрдәкләре коена, ахрысы. Балыклар да сикереп уйный шикелле. Шәрә кәрлә каеннар кәүсәсенә әллә нинди аңлаешсыз сәер авазлар бәрелә иде. Аларга хатынның да әрнүле тавышы өстәлде:

— Йа Ходай, нинди генә явыз булса да, ул бит миңа ир иде-е-е!!!

*2005—2006*

## Мәхәббәттә гөнаһ бар

### 1

«Нишләдең? Нишләдең? Нишләдең?!»

Мин карашымны каләм итеп тәрәзә пыяласына шушы сорауның җавабын язам… Язам да сызам, язам да сызам. Сыңар керфек какмаган төнге шәһәргә минем өзгәләнү-бәргәләнүләрем көлке югыйсә. Монда меңәрләгән адәм баласы сөя-сөеләдер, меңәрләгән адәм баласы йә ярын таба, йә югалтадыр. Әнә күпме таш йорт, күпме фатир… Ә Карасуда мин йөрәге зинданга ябылган бердәнбер мәхәббәт тоткыны идем. Ул авылда минем сыман берәү дә гыйшкыннан тилермәде. Әллә, Ходаем, шуның өчен үчләштеләр микән? Менә ничәнче мәртәбә берәм-берәм югары сыйныф кызларының шәүләсен күз алдыннан уздырам. Тик кемгә генә бармак төртсәм дә шикләндерә. Үзем кулларына сукмагач, гөнаһысыннан куркам, ди. Әмма кызларның кайсыдыр шырпы сызган бит инде! Һай, үз балаларымдай якын күргән үсмерләр миңа нинди явызлык белән түләде. Яшь-җилкенчәк ни-нәрсә аңлый соң?! Бу яратуны үзем ялварып, үзем теләнеп алдыммыни! Барысы да минем ихтыярдан тыш хәл ителде. Мин кырыс язмышымнан разый идем инде: табигать кануннары буенча, соңлаган хисләр белән соңлаган назлар бу елда да мине читләтеп үтәргә тиеш иде. Авылда җиләк сыман тәмле-татлы чибәр-сылулар хисапсыз иде, ләкин әллә капкаларны бутады, әллә күрәчәгем тартты — мәхәббәт нәкъ минем йөрәгемә шакыды…

«Сине авылдан сөрделәр мәллә?» Алдашырга өйрәнмәдем: мин коточкыч зур җинаять кылдым, мин аңнарымны җуеп яраттым. Әмма бу хакта иң якын сердәшләремә дә белгертү юк. Әүвәл үзем ул мәхшәр эчендә өр-яңадан яшәргә тиеш. Әле мин аңкы-миңке хәлдә: барысы да ватылды-уалды, кыскасы, дөньяларның асты өскә бергә укмашты. Тик аның исеменә генә җил-яңгыр тимәде. Аның исеме… Көтелмәгәндә генә кайдан пәйда булдың соң син, әй егет? Минем сукмагымда ялгыш кына эз салдың мәллә? Алай дисәң, адәм баласын язмышлар җитәкләп йөртә. «Син минем сукмагымны таптама, син минем юлымда буталма», — дип, кем кемне битәрли ала. Ә бит минем каядыр ашкынуларым тикмәгә генә булмаган икән! Алда, башлар югалтырлык маҗараларга юлыгасың, дисәләр, бәлки, мин урынымнан да кымшанмас, үземне йөз кадак белән кәнәфиемә кадаклап куяр идем. Ашкынулар хәерлегә түгел инде ул, мин, кырыкта кырыкка ярылган хатын, бу хакыйкатьне танырга тиеш идем. Ләкин бертөрлелек алҗыткан, тормышта нәрсәдер үзгәртәсе килә иде. Әйе, килә иде. Йөрәк кош сыман каядыр очарга талпынды. Кая? Үзе дә аңламады. Ә үзгәреш кирәк иде. Бүген үк кирәк иде. Югыйсә иртәгә яшәүнең бер мәгънәсе дә, бер кызыгы да калмас төсле. Әмма искеләрне яңартыр өчен, дөресрәге, җимереп-ишеп яңадан нигезен өяр өчен сәбәп кенә юк иде. Шушы адымымны, соңыннан үкенмәс өчен, «сәбәп» белән ныгытырга тиеш идем мин. Һәм ул үзе маңгае белән төртелде… Иске Татар бистәсендә сәнгать үрнәге саналган татар баеның агач йортын калын кесәлеләр бульдозер белән иштергәч, безне, өч гаиләне, Казан читенә күчерделәр. Киң такта баскычлардан йөгерә-йөгерә үскән кыз бала өчен шырпы тартмасы хәтле генә фатирда кысан иде, әлбәттә. Җитмәсә, куышым җиденче катта — биектә иде. Гүя аны бауга бәйләп күк белән җир арасына элгәннәр. Мин ул бүлмәне ничек тә сатып, берәр бистәдән агач йорт бөтәйтергә хыялланганда гына, авылдан әтинең апасы Мәүлидә килеп төште. Туп-туры мәктәпкә. Дәрес вакыты иде. Ул, нәкъ авылдагы кебек, рөхсәтсез-нисез генә сыйныф бүлмәсенең ишеген ачты да:

— Чүттин Әхмәдулла бай оныгы Диләрә мондамы? — диде һәм, Әби патша сыман, горур гына башын югары чөеп, өстәлгә табан теркелдәде. — Бак, Иске бистәдәге әбзи ызбасын кая илттегез?! Ник аны туздырдыгыз?! Җөзҗәшәрлек ие кана. Әбзи төсе җукмыни шылай, йа?!

Сорау арты сорау яудырган туганымны нишләтергә дә белмәдем. Сагынуымны белдереп, яратып кочакласам, ул гаепле: тәртип бозды, дәресемне өзде. Ачулансам, без ике иң якын туганнар бишбылтыр күрешмәгән. Ә балаларның әкият иленнән иңгән ак яулыклы, озын күлмәкле «капчыкка»

исләре дә китмәде, алар бу тамашаны тиз генә үз файдасына борды: кемдер кәгазьдән самолет ясап очырды, кемдер кесә телефонын чәрелдәтте, кемдер күршесенең башына китап белән шапылдатты.

Мин кызардым-бүртендем һәм көтелмәгән кунакны җитәкләп коридорга чыктым.

— Дәрес бара, тугани апа. Әз генә көт инде, яме.

— Җук, көтмим! — диде карчык, кистереп. — Мине духтырларга җуллаганнар ие. Бүлнис капкасының келәсенә дә орынмадым мона. Чир өстәтеп җөрмим кана. Үзеңне бактым, хуп. Ызбаң да җук вакыт. Хуш, бәбкәч.

Тугани апаны аяк өсте генә озатсам да, ул үпкәләмәс иде. Әмма нәрсәдер мине аңардан аермаска тырыша: колагыма, туктат, туктат дип, тын белән өрә иде.

— Ашыкмале, тугани апа. Сиңа җитди сүзем бар. Дәрес хәзер тәмамлана ул.

Ни гаҗәп, пырдымсыз Мәүлидә әбием карышмады.

— Иту оланнарның сабагын җәт кенә очлат, — дип боергач, эскәмиягә чүгәләде.

Туганыма нинди мөһим сүз әзерләдем икән? — Табышмак. Бу мизгелдә мин ниндидер бер гайре табигый көчнең теләген үтим сыман. Ә ул үзе аңымда гына яши, аны реаль дөньяга күчерсәң, эреп таралырга тора. Ләкин мин бик нык хаталана идем. Карчыкның шәһәргә килүе дә, мәктәпкә сугылуы да юкка түгел. Мин әнә шулай күрәчәгемдә тамгаланган иң нечкә кыл — күпергә табан якынлаша идем…

Тугани апа фатирымны ошатмады. Төне буе ахылдады-ухылдады да, таң аткач еламсырап:

— Монда тагын ике көн җокласам, үләм, — диде. — Ташкапчык, ватый. Суларга һавасы да җук, — диде. Минем талчыккан йөз-кыяфәтемә күз сирпеп, чиремне дә билгеләде. — Җәп-җәш башыңнан үле-мүле җөрисең, бәбкәч. Дәрт-дәрманың шышы ташкала суыра, ватый, — диде.

— Якын-тирәдәге бистәдә берәр агач йорт сатылыр, бәлки, — дидем.

Мәүлидә карчык ризасыз гына кашларын җыерды:

— Нәстәгә ул җорт сиңа, бәбкәч? Анау аулда хан тирмәсе! Апаеңны бүген-иртәгә Газраил кунакка дәшмәктә. Бакчамны да, мунчамны да, абзар-курамны да, шыл берәмлектән йортын да ай элгәре синең исемгә җаздырттым, бәбкәч. Духтырлар «чиреңалайдыр-болайдыр» дигәч, җәт кенә эшләп аттым кыягазларын.Оланшакка сабак укытырга мәптеге дә өр-җаңа анау.

— Әй, юк-бар такылдама инде, тугани апа! Син тап-таза әле, — дидем.

Әйтерсең туксанны тутырып, йөзенче яшенә үрмәләгән карчыкка үлем турында кузгатырга иртәрәк иде.

— Монау син кайт та мал-мөлкәтне миннән кабул итеп ал, бәбкәч, — диде карчык. — Җат нигез түгел, атаң уйнап үскән җорт.

Туганымны рәнҗетмәс өчен генә «ярар» дидем. Авыл кечкенәдән үк минем дошманым булды. Җәйге елларымда шунда болганмас өчен мин кыш айларында ук мең хәйлә корам, әмма эти бердәнбер иркә кызын, үкертеп елатып, Карасуга илтеп ыргыта, һәм бу әсирлекнең азагы аяк-кул сындырулар, баш ярылулар белән тәмамлана иде. Хак, соңыннан табигатьнең матурлыгы күзгә чалына башлагач, җиләкле аланнар, төрле төсләр белән бизәлгән чуар күбәләкләр, алтын сибелгән арыш-бодай басулары, чишмә буйлары бик-бик сагындыра, күңел яңадан шул манзара-күренешләрнең кабатлануын тели, тик ул теләк теләк булудан ары узмады. Чөнки Карасудан мәңгегә биздергән вакыйганың кайтавазы бөтен истәлек-хатирәләрне күмеп ташлады. Нинди гарьлек, миңа клубтан көн саен чабата Шәпәй малае Илдус тагыла иде. Ничек җөрьәт итте икән, ничек?! Мин — абруйлы университет талибәсе, ә ул — фермада ат караучы. Алай гынамы, авылда Илдус егет мыскылы санала, аңа кызлар исеме белән дә эндәшми, үзенең алдында ук «Ат тизәге» дип үрти иде. Менә шушы «тизәк» иң кәттә шәһәр кызына гыйшык тотсын инде, йә!

Мин аны бер кудым, ике кудым, өч кудым. Бәгыренә кадалырлык иң усал сүзләр белән чәнечтем.

— Фу, синнән ат исе аңкый! Фу, син тирескә буялгансың, ахры, бөтен урам сасыды.

Әй пычак тел, пычак тел! Кисте-телде, кисте-телде, ә моңа — «тизәк»кә — бу мыскыллауларны тыңлау рәхәт булды микән, егет, күктәге йолдызларны маңгае белән сөзеп, тик өскә карап елмая гына иде. Шул хәлләрдән соң Карасудан гайрәтем чикте. Авыл, дисәләр, ул ат исе сеңгән Илдус кыяфәтендә гәүдәләнеп чиркандыра торган булды.

— Илдус исәнме, тугани апа?

— Кайсы Илдус?

— Аның кушаматы Ат тизәге иде бугай.

— А-а, ватый кемне сүлисең икән. Капыл гына аулны ташлады ул олан. Шуннан бер-бер артлы атлары да үлде. Малларны Шәпәй малае күек оста караучы җуктыр ие Карасуда. Атка, бәбкәч, үзгә тәрбия кирәк. Ашату да, кул җомшаклыгы да.

Туганымны авылына озаткач, атна-ун көн аңгыраеп йөрдем. Аның исән килеш йортын миңа яздыртуы башыма сыймый иде. Менә сиңа мәзәк карчык! Сеңлесен Карасуга кайтып яшәр дип өметләнә микән? Бүгенге авыл нинди икән ул? Шәһәр сәгать саен үзгәрә, ә Карасуда нинди яңалыклар бар? Мәктәбе зурмы? Укучы балалар ничәү? Ниһаять, Мәүлидә апамны табиблар нәрсә дип Газраил белән өркетә?

Бу бәйләнчек уйлардан котылу юк иде. Беркөнне ялымда сәяхәткә киттем. Автобус Карасу уртасында туктаса да, басу кырыенда ук төшәсе иттем. Сап-сары бодай кыры мичтә пешкән күмәчне хәтерләтә. Сабагыннан тотып, бер башакны учыма игән идем, яңгыр тамчылары кебек бөртекләр чәчрәде.

Авыл башында йоны сирәкләнгән карт кына эт каршы алды. Һәм, койрыгын моңсу салындырып, артымнан иярде. Беренче урам тып-тын иде. Нигәдер ул миңа бик киң күренде. Элек тар иде, без, бала-чага, качышлы уйнаганда аңа сыймыйча, язгы ташкын төсле, басуга җәелә идек.

Эт белән култыклашып туганымның капка төбенә җиттек. Ул, хуҗа сыман, алгы тәпиләре белән капканы этте. Карчык тыштан өйалды ишеген тоткасы шомарып беткән кәкре таягы белән терәткән иде. Авылда иң ышанычлы «йозак»! Эт, моңсу койрыгын ике-өч мәртәбә болгагач, эшем эшләнде дигәндәй, буе белән җиргә сузылды. Ишегалдында билдән үлән үскән. Әй, исәр дә инде мин: шунда ятып туп кебек тәгәрисем килә! Сиздермичә генә балачак җанымны кытыклый. Авылны яратмаган идем шу-ул… Юньсез Илдус. Ник озаткан ул, йә? Әнә үзе дә шәһәргә олаккан, ди. Кинәт гармун күреге ыңгырашкандай капка шыгырдады. Үлән арасында чыкырдашкан чикерткәләргә ачуланып әле бер, әле икенче колагын шомрайткан эт нигәдер өрмәде, иренеп кенә күзен ачты да кире йомды. Галошларын чыштыр-чыштыр сөйрәтеп ишегалдына кергән карчыкны мин танымадым. Ул карачкы кебек әкәмәт кыяфәттә иде: таяк төсле ябык гәүдәле, баш түбәсенә, бу ябыклыгын тагын да купайтып, каз оясы хәтле бүрек чәпәлгән.

Карчык миннән ятсынмады, хәтта исемем белән эндәшеп, корыган агач ботакларына охшаган бармакларын учыма сонды:

— Арумы, Диләрә бәбкәч? Мәйтәм, Актырнак басуга табан теркелдәде, кыз кайта, мәйтәм, күршекәем этенә кушып калдырды инде сине каршыларга, ватый. — Әби нәкъ туганым кебек көйләп-җырлап сөйли иде. — Ызбага уз, Диләрә бәбкәч. Әмма әрбер үз урынында. Күршекәемнең җортындагы чүп үләненә дә тимәделәр. Аның рухыннан курыкты җәш-җилкенчәк, ватый.

Таякка үрелгән кулымны куырдыларммыни, әллә нишләдем.

— Әллә, тугани апа… әллә? — дидем дә хәлсезләнеп җиргә чүмәштем.

Карчык агач бармаклары белән аркамнан сыйпады.

— Үләргә җаткан төшеннән капыл торып калага җөгерде, мәрхүмә. Диләрә бәбкәчне эзлим, дир, васыятемне әтәм, дир. Шуннан кайтты да әҗәлетдингә тапшырылды, ватый. Урынын җәннәттә әйләсен, Ходай. Җакшы кеше ие. Кая, бәбкәч, син мине төсмерләдеңме суң? Сәрбиназ әбкәең мин, уң җак күршегез. Минем пич ташында тәгәрәткән кәлҗемәләремне җаратадыр иең син. Хәзер газ дигән әкәмәт бездә, бәбкәч. Андаен кәлҗеләр җук.

Газраил, тугани апа, Сәрбиназ әбкәй, кәлҗемә — барысы да башымда буталды. Минем инде кулым гына түгел, йөрәгем дә пешә иде. Исән чагында карт апам белән туганлык җепләрен ялгап, аралашып-күрешеп яшәмәдем мин. Шуңа күрә аның үлеме дә тетрәндермәскә тиеш кебек иде. Ә нигәдер алай булып чыкмады: бу хәбәрдән эчем-тышым елый иде. Ай тугани апа, тугани апа! Мин хәзер генә үземнең дөм ятим икәнемне аңладым. Үзем белән бергә яралган кимчелегемнән дә хурландым: мин — ташкурчак, миндә хис тә, наз да, җылы да юк. Ир-ат халкы, күрәсең, шуларны сизеп миннән тайчынадыр. Кичер, тугани апа, кичер, бәгырем!

Түбәсенә «каз оясы» чәпәгән карчык юатмады. «И Алла, и Алла» дия-дия ботак-бармаклары белән җилкәмнән сыпыргалагач, капкага юнәлде. Ул нәрсәдер әйтте бугай, тик аның соңгы сүзе генә колакка бәрелде.

— Әбкәче вафатыннан шат Актырнак ашамый, бәбкәч.

Юлда капкалармын дип, сумкама тавык казылыгы төреп тыккан идем. Күчтәнәчемне этнең савытына ташладым. Бичара, ят ризыкны өнәмәде, иснәде дә, борыны кытыкланып, өч тапкыр төчкерде. Хуҗабикәсе белән бергә картайган хайван да дөньядан туйган, ул да үләргә җыена кебек. Ә хәзер эт ялгызлыгымны бүлешердәй бердәнбер җан иясе иде. «Актырнакка җүнлерәк әйбер ашатырга кирәк! Ашатырга кирәк!» — Ничектер шушы уй, хәсрәтемне кысрыклап, күңелемә оялады. Йомшарган гәүдәмне сөйрәп өйгә кердем. Монда бөтенесе дә элеккечә иде. Дивар кырыенда күпертелгән мендәрләр өелгән сиртмәле тимер карават, тәрәзә буенда шакмаклы ашъяулык җәелгән өстәл… Тирәсенә аллы-гөлле корама чүпрәкләрдән тегелгән япмалы урындыклар… Тугани апа иртән үк утын ягып утлы күмерендә коймак чыжлаткан ак мич кенә сүтелгән. Эре чәчәкле чаршаулар да асылмалы болын төсле. Ишек башында борынгы «Аятел Көрси». «Җеннәрне куа», — дия иде тугани апа.

Тәрәзәләре урамга баккан алгы бүлемтектә һәммәсе дә балачагымның шаһитлары иде. Дивардагы агач рамнарда минем газизләремнең сурәте: бабай белән әби, әти белән әни һәм иң азакта мин — иркә кызчык… Мин елыйм, ә алар су тамчылары бөркегәндәй җем-җем итә. Тугани апа исәндер кебек. Олы тауда кәҗәсенә үлән чемчендерәдер кебек. Могҗизага өметләнгәндәй, суыткычның ишеген тарттым. Чынлап та, таш савытта тум-тулы кәҗә сөте иде. Өстендә сап-сары каймак. Мин аны Актырнакка чыгарып салдым. Әй, ялмаштырды да борынын янә җиргә төртте. Аның кайгысы минем белән чагыштырганда йөз өлеш куәтлерәк иде. Мин моңарчы тугани апасыз гына яшәдем. Ходай кушса,

тагын яшәрмен, ә хайван, хуҗасына тугры хайван нишләр? Һәм мин аны хәзер кая куйыйм? Сәрбиназ карчыкның капкасына бәйлимме? Йорт васыять ителгән дип бу авылда кем төпләнә әле?! Туганымның ызбасын сатсам — хуш, сатмасам… барыбер хуш. Кичер инде, апам, кичер. Мин үз уйларымда үзем үк чәбәләнеп беттем бугай. Ә мәрхүмәнең хуҗалыгына тел-теш тидерерлек түгел: ул төзек-бөтен иде. Һәр почмактан шук балачагым чыркылдап көлә сыман. Әмма хатирәләрнең гел башына сугам: бергә уйнап үскән кызлар-малайлар, һәм, ниһаять, ат исе аңкыган Илдус миндә — шәһәр иркәсендә — барыбер сагыну хисләре уятмас шикелле. Әллә нинди идем шул мин, әллә нинди сәер зат идем!

Кичкырын Сәрбиназ карчык хәл белеште, ә иртән төне буе йокламаган мин бичараны эт һау-һаулап уятты. Башта кайда икәнемне төшенмәдем, кичәге маҗараларны хәтердән сөрткәндәй, бер мизгелгә онытып тордым. Чү, мин авылда, мин тугани апа өендә… Капкада исә кеше бар. Халатымны гына киеп болдырга чыктым. Ниндидер хатын, эттән өркеп, баганага елышкан иде.

— Тими ул, керегез, — дидем иртәнге салкынча һавадан иснәнеп. — Тик менә тугани апа… Юк бит инде.

— Ә минем синдә иде йомыш, Диләрә. — Хатын эткә кырын карый-карый болдырга менде. — Үз итеп эндәшәм, ачуланма берүк. Мәүлидә абыстай сине зерә ярата иде. Карасуга укытырга кайта бәбкәчем, урын әзерлә, дип тинтерәтте соңгы көннәрдә. Рәхим ит, бездә вакансия…

— Юк, юк! — Мин әрсез кунакны ярты сүздән бүләргә ашыктым. — Минем авыл мәктәбендә укытасым юк! Әллә Сез мәктәп директорымы?

— Үзе идем шул. Сәвия мин. Җәйге лагерьның җитәкчесе кичә генә вакытыннан алдарак бәбиләде. Аңа алмашка укытучы кирәк иде.

Директор хатынның тел төбе аңлашылды.

Мин тагын:

— Юк, — дидем. Бу иртәдә минем дә иңе кәефсез бикәгә «юк» сүзе бик ошый иде.

— Лагерь урман аланында, зерә матур җирдә. Янәшәдә генә күл. Ярдәмгә физкультура укытучысы белән рәсемнеке була. Хет өч көнгә, ә?

Өч көн… Әле мин авыл белән исәп-хисап ясый-ясый бераз тоткарланырмын бугай.

— Ничәнче сыйныф?

— Унынчылар, — диде шатланып. — Гел кызлар гына. Унсигездә. Аланда кунышта, билгеле. Рәхмәт, Диләрә. Чәйләгәч, җыенып мәктәпкә килерсең.

Әйе, әйе, мин әллә нинди сәер зат идем шул. Башта «юк» дип кәкрәйдем дә аннары кинәт кенә турайдым. Өстәвенә мин явыз да идем. Мәктәп директорына изгелек эшлим дип түгел, тугани апамның рухыннан оялып кына ризалаштым. Йортымда өч көн дә яшәмәде, дияр, таш каласына сыптырды, дияр. Ә миңа мәңгелекнең үзе кебек тоелган ул сәгатьләрне ничек тә үткәрәсе иде. Сумка төбенә нибарысы тарак, яулык ише вак-төяк ыргыттым да (урманда кем куна ди) мәктәпкә юнәлдем. Ә анда автобуска төялгән үсмер кызлар мине көтә иде. Сөенеченнән балкыган мәктәп директоры ерактан ук кычкырып исәнләште:

— Саумы, Диләрә әллә кемовна, әтиеңнең исемен оныттым. Ә-ә, Әсәдулловна! — Сәвия автобусның ярым ябык ишеген ике якка каерды. — Балалар! Өч секунд тынлык! Яңа укытучыгыз белән таныштырам. Диләрә Әсәдулловна — сезгә дин сабаклары өйрәткән Мәүлидә абыстайның сеңлесе. Ул вакытлыча Наилә апагызны алмаштырыр.

Менә сиңа яңалык! Тиктормас тугани апа балалар да укыткан.

Мин кызларга елмайдым. Елмаюым ихлас иде. Гомеремне яртылаш кыскартсалар да, балалар ярата идем. Ә алар шәһәрдә дә, авылда да бер.

Кузгалабыз дигәндә генә, автобуска чикерткә сыман яшь кенә туташ сикерде. Аның матур йөзе зәһәрләнеп кыйшайган иде. Ул, сыбызгы сызгырткан әче тавыш белән чинап, шоферга акырды:

— Нишләп мине көтмисең, тинтәк?!

Авызын учы белән томалап хихылдашкан кыз-кыркынга да эләкте:

— Ә сез ыржаймагыз, урмандагы черки корбаннары!

Бәлки, ул юл буе тел тегермәнен әйләндерер, һәрхәлдә, аның ачу ташы тиз генә суынырга охшамаган иде, туташ ят кешене шәйләде һәм, идәндәге төргәкләргә абына-сөртенә, янымдагы буш урынга килеп тә утырды.

— Син яңа укытучы мәллә?

— Юк, иске. — Бу чикерткәне үртәп гел киресен сөйләргә әзерләндем. — Егерме ел мәктәптә укытканнан соң яңартмадылар әле.

— Мин Гаян Наиловна.

— Диләрә.

Без бер-беребезне бәяләп-үлчәп күзгә-күз караштык: «Әгәр мин унсигез-унтугызда кияүгә чыгып, бала тапсам, мөгаен, бүген кызым шушы тел тегермәне яшендә булыр иде». Күңелемнән әнә шундый уй йөгереп үтте. Ә Гаянның бөтен йөзенә: «Мин синнән яшь!» — дигән масаю җәелгән иде. Чү,

очынып болытка үрелмә, кызый! Гомер агачында талпынган соңгы сары яфракның да үз матурлыгы бар…

— Мин үткән елда гына институт тәмамладым. Эп-эсвежи белемле, — диде Гаян, тагын бер өстенлеген сиздереп.

Карасуны дүрт тарафтан да урман чолгаган, без эт төчкергән арада турыдан гына «А» пунктына барып җитәргә тиеш идек, ә юл, офыкларны өч кат әйләнгәндәй, ялыктыргыч озын иде. Ниһаять, автобус, кәрлә куакларны маңгае белән сөзә-сөзә, эчкә керде һәм «байлыгы»н зур гына аланга бушатты. Кызлар, чебешләр сыман, җиргә сибелде. Мин әле төп вазифамны аңлап бетерми идем. Кем мин? Кайда мин? Шунысы гаҗәп: аңлау дәрәҗәм дә түбән иде. Әгәр артымнан этсәләр, барырмын, этмәсәләр, шып туктармын кебек.

Гаян чыркылдык кызларны, бер сафка тезеп, тыштан ат абзарына охшаган бинага табан кумакчы иде.

— Уйнасыннар, ирекләрен чикләмә, — дидем. Бу минем әз генә үз вазифамны үтәргә маташуым иде.

— Мәйлең, син җитәкче укытучы. Берәр этлек эшләсәләр, эти-әниләренә үзең җавап бирәсең. Алдан ук кисәтәм, бел!

Алан таныш түгел иде. Мин монда балачагымны хәтерләткән бер генә чәчәк тә, бер генә үлән дә күрмәдем. Аннан, күңел күзем дә сукрайган иде…

Авызын турсайткан Гаян «абзар»га йөгерде. Кызлар чыр-чуына күмелгән аланда ул бөтенләй артык иде. Битарафлык чире йоктырсам да, җилкәмә аударган йөктән котылу юк шул. Иртәгәсе көннән үк ял тәртибен төзергә кирәк. Бу яшь-җилкенчәккә мин кайсы ягым белән кызыклы була алам икән? Әллә алар яшенә кайтып төшимме? Яшьлегемнән мине нибарысы паспортыма язылган еллар гына аера. Күңел һаман да унҗидедә… Тән картайса да, җан картаймый икән.

Уйлана-уйлана әкрен генә бинага табан атладым. Чаттан борылганда, дәү генә «аю» белән бәрелештек. Әйе, әйе, кыска җиңле йонлач футболка кигән егет нәкъ аю иде. Ул, минем юлымны каплап, култык астына кыстырган тубын кулында сикертергә тотынды. Мөгаен, аңа әдәп кагыйдәләрен өйрәтмәгәннәр иде. Кинәт «урман хуҗасы» шаркылдап көлеп җибәрде.

— Арттырырга дисәң, Гаянга куш! Безгә җитәкче итеп Казан әбисен билгеләделәр, ди. Моның кай төше әби инде? Матур апа ич бу!

Мин бер сүз дә дәшмәдем. Мондый әдәпсез егетләр Казан урамнарында да сирәк очрый иде.

«Аю» кинәт җитдиләнеп китте:

— Гафу итегез! Үпкәләмәдегезме? — диде.

Мин һаман саңгырау идем. Егетне бөтенләй ишетмәмешкә салыштым. Әмма зәңгәргә буялган ишек тоткасына үрелгәндә, капыл гына артыма борылдым. Нигә? Белсәм икән… Егет тә урыныннан кузгалмаган, күзләре белән мине озата иде. Нигә? Белсәм икән…

Лагерь бинасы тыштан гына килбәтсез-котсыз икән, эче бик матур, һәр бүлмә нарат такта белән каймаланган иде.

— Безнең Карасуда туып үскән бай эшмәкәр Исмәгыйль шәһәрдә бозылган «кәбестә кучәне» өчен төзеткән иде моны, — диде Гаян. — Җәй саен хулиган малайны шушында кайтаралар иде. Ике тән сакчысы белән. Тәрбиялиләр, имеш. Хәзер хулиган институтта укый инде. Төзәлгән, ди, ахрысы. Шуннан соң Исмәгыйль йортны мәктәпкә бүләк итте. Лагерьның спонсоры да ул. Син Равил Сәйдәшевичны күрдеңме? Физкультура укытучысын, ә?

— Юк.

Телем йә сөйләми, йә алдаша.

— Күрсәң, үләсең! Шундый чибәр егет. Күрше авылдан. Бездә икенче ел туп типтерә.

Миңа ни Равил, ни агач.

— Кайсы бүлмәгә урнашыйм, Гаян?

— Залда унсигез карават, анда кызлар йоклый. Ә синең куыш — иң соңгысы. Равил белән безнеке… янәшә, яме.

— Төнлә тәрәзәдән кереп урман пәриләре кытыклар дисеңмени?

— Егет бик мут, төнлә кызларны капшамасын, дим. Салам сыйракларның да күзе гел Равилдә. Әнә кара. — Кыз, тәрәзә пәрдәсенең бер читен күтәреп, урамга ымлады. — Равил тегеләрне туп уйната. Кара, кара, аңа юри ышкыналар, канатсыз чебешләр! Әнә теге колга буйлы сикергәк — безнең директорның кызы. Кияү инде. Кызына өйләндертә дә урынына куйдырта, ә үзе өйдән генә безгә фәрман очыртып ята. Тик менә кызы бака төсле: җәлпәк битле, җәлпәк борынлы, Равилнең бәхет савытында шылдырарлык алтын тәңкә түгел.

Гайбәт сөйләгән дә, тыңлаган да икесе тиң гөнаһлы, дияр иде тугани апа. Аның хикмәтле сүзләре ничек исемә төште соң әле?

— Кызларны җыеп килегез, Гаян Наиловна. Күрешик, танышыйк.

Төркем белән таныштым, билгеле. Ләкин бернинди ачыш та ясамадым. Бу кызлар да миллионлаган яшьтәшләре кебек үк көлә, хыяллана. Аларның тәү мәртәбә сөю газабының тамчысын татыган һәм җавапсыз мәхәббәттән канатларын өттереп, шуны зур фаҗигагә санаган иләс чаклары иде. Ә Равил, чынлап та, егет солтаны, һәм ул урманда бердәнбер. Әлбәттә, башы ике булса гына, мәктәп укучылары белән шаярыр. Чүлмәкче малаен алдан ук кыйнаган кебек, мин дә яшь укытучыны кисәтергә уйладым. Тик колак борырга һич җай юк, Гаян гел егет тирәсендә бөтерелә. Ә минем, һич кенә дә өченче кешенең кулына агач кашык тоттырып, гайбәт боткасын ташыта-ташыта болгаттырырга исәбем юк.

Кояш нуры мәтәлчек аткан аланда сәлә генә эңгер таралды. Кич якынлашты. Урманда кунмаска дигән кирелегем көчле иде, Гаянга кызларны тапшырып, җәяү генә авылга җилдердем. Дүрт-биш чакрымдагы Карасу, шәһәр тукталышлары белән исәплəгәндә, кул сузымында гына иде. Урман авызында артымнан кызыл машина куып җитте.

— Утырыгыз, үзем илтәм.

Рульдә Равил иде.

Нигәдер миңа ачу ташкыны китереп сукты. Чыраемны сытып:

— Лагерьдан читтә йөрергә сиңа кем рөхсәт итте?! — дидем. — Син анда сакчы да, егет!

Әйтерсең тирә-якта башкисәрләр мыжлаган, әйтерсең алар менә-менә аландагы кызларга ябырылачак иде.

— Борчылмагыз, бездә бик тыныч. Җил дә исми, яфрак та селкенми, — диде егет, көлемсерәп. — Йә, утырыгыз инде. Биш минутта илтәм дә лагерьга кайтам бит инде. Гаян, авылда кунасыз, ди, имеш.

Ялындыру мәгънәсезлек иде. Синең турында кайгыртканда, керпе сыман энәләреңне тырпайту килешми ул. Аннары, егетнең һаман колагына киртләнмәгән иде.

— Дустым, әгәр дә мәгәр лагерьда кыз-ыркын белән кети-кети уйнасаң, үзеңә үпкәлә.

— Ничек аңларга инде моны? — Равил уң кулын рульдән бушатты. Машина тәгәрмәче эре генә гырдага бәрелде.

— Туры мәгънәсендә аңла!

Мин артык каты бәгырьле идем бугай.

— Кем яманатымны сатты икән? Карасуда бер генә хатын-кызга да нәфесләнгән юк иде. Инде дә чәчби кызларны әйтсәгез… Һи, пешмәгән әче алма ич алар. Тешләсәң, үтең сытылыр. Миңа, беләсезме, кемнәр ошый? — Егетнең күзләре чүлмәктән май ялаган мәченекедәй ялтырады. — Сезнең кебек өлгергән җимеш тәмледер ул. Бәлки, бүген төнлә күрешербез, баг алмасы, ә?

Шунда мин үз-үземне тыялмадым: егетнең яңак төбенә кундырдым. Гомеремдә чебенгә дә сукмаган кулымның сөяге чатнады кебек. Машинадан ничек чыгып, ничек өемә кайтканымны томандай гына хәтерлим. Нәрсә булды соң, йә?! Элек тә ир-ат авызыннан әллә нинди тәкъдимнәр ишетә идем ләса! Кайберләреннән көлеп, колак яныннан гына шудырдым, кайберләренә үртәлеп еладым. Мин дә фәрештә түгел, мин дә адәмнәр төсле хаталар һәм ялгышлар җыелмасы идем. Ләкин бу егет актыгының миңа ымсынырга бернинди хакы да юк иде. Чөнки ул… яшь иде. Шуңа күрә миндә җеннәр өермә тузгытты. Ул яшь иде шул, яшь иде!

Директорга вәгъдә ителгән өч көнемнең берсе әнә шулай үртәлә-гарьләнә гамәлдән сызылды… Төнлә, тәрәзәдән бөркелгән ай яктысыннан сискәнеп уянгач, әлеге күренешне яңадан җанландырып, үземне сыек чыбык белән чыбыкларга керештем. Һай, Диләрә! Ник аңа кизәнеп-кизәнеп суктың?! Кыргый син, кыргый!

Әмма ишегалдындагы иске коедан бер чиләк су тартып, өстемә койгач, үкенүләрем су белән җиргә сеңде. Әле бу башы гына, әле уртасын һәм азагын көт! Мондый әрсез егетләрдән оят җәяү кача, ул сине адым саен ач күзләре белән ашар, ә соңыннан, шәхси фронттагы җиңүләре хакында лыгырдап, дусларына мактаныр. Йа Аллам, мин чамадан тыш күпертәм бугай. Хатын-кыз тарафыннан кире кагылган, өнәлмәгән ир икенче мәртәбә телендә сандугач биетер микән?

Иртәгәсен мин көнозын балалар белән кайнаштым. Без үләннәрнең дәвалау серен өйрәнә-өйрәнә урман айкап хәлдән тайдык. Гаян, башым авырта, дип, бүлмәсендә китап укыды, ә Равил Сәйдәшевич… өердән куылган яралы бүредәй, еракта гына тыңлап-күзәтеп йөрде. Тамак ялгарга утыргач та яныбызга килмәде.

Кич белән, халык арып караватка егылгач, өс-башымны алыштырдым да шыпырт кына куаклыкка чумдым. Уч төбенә сыярлык түгәрәк көзге сыман шома күл көндез күз очыма эләккән иде. Нинди могҗиза, йа! Табигатьнең илаһилыгы рәссам тукымаларында гына чагыла дип уйлаган шәһәр кешесе бигрәк бәхетсез икән! Бу үләннәр, бу чәчәкләр һәм йөзендә нәни генә дулкын да тибрәлмәгән күл ничек шул шаукымга сыйсын ди?!

Су ләззәтен тоярга ашыккан тәнемне юри кымырҗытып әкрен генә чишендем. Ни гаҗәп, моңарчы мыжык карт төсле мыгырданган мин бу мәлдә шушы хәлəтемнән канәгать идем. Тынлык белән без икәүдән-икәү генә идек.

Ләкин күлне иңләп-буйлап рәхәтләнеп йөзәм дигәндә генә, кемдер:

— Эчкә үк кермә, — диде. Гүя тынлык үзе эндәшә иде. Мин ирексездән су төбенә чумаштем. Ярда биленә таянып Равил басып тора иде. — Йөзәргә ярый, эчкә генә кермә, — диде егет, бала-чаганы кисәткәндәй.

Әмма миндә коену дәрте сүрелгән иде инде.

— Нишләп мине эзәрлеклисең, акылсыз?!

Тавышым, дулкынга әверелеп, күл өстенә җәелде.

— Кем акылсыздыр бит әле монда. — Җавап та дорфа иде. — Бөтенләй таныш булмаган күлгә акыллы кеше аягын да тыкмый. Уртада аста салкын чишмә бөтерелә. Шунда батсаң, дөнья белән хушлаштым дип сана.

Камышларга киселә-киселә ашык-пошык киендем. Озын толымнарымнан чупыр-чупыр су акты. Әле миңа дөнья белән хушлашырга иртәрәк иде… Горурлыгымны җиңеп:

— Рәхмәт, егет, — дидем.

Равил җилкәсе белән борылган иде. Кинәт ул ниндидер бер тәвәккәллек белән каршыма атлады:

— Диләрә!

Юк, бу кичәге оятсызлыкның дәвамы иде. Нинди «Диләрә»?! Ичмасам, кызлар кебек «апа» дисә икән!

— Мин сине чишенгән килеш тә күрдем бит, Диләрә. Юри килмәдем бит артыңнан, суга батмасын дип борчылып килдем. Буй-сының да сылу икән синең. Мә, оятсыз дип икенче яңагыма да сук инде.

Егет, алдыма тезләнеп, башын миңа табан янтайтты. Бер-беребезнең карашында йотылдык. Үзем дә сихерләнгәндәй аңа табан авыша башладым. Менә билемнән уратырга җыенгандай, көрәктәй зур кулларын өскә күтәрде. Әз генә алга талпынсам, егет, дулкын сыман, кочагына суырып алачак иде. Томаланган аңым көчкә ачылды. Нишлим мин, йә?! Берьюлы йөзәрләгән бал корты чактымыни, кадала-чәнчелә лагерьга йөгердем. Ирдән аерылганнан бирле берәүдән дә үптермәгән иреннәрем бизгәк суккандай дерелди, аяк-кулларым калтырый иде. Юрганымны башымнан ук бөркәнеп яткан идем, бер пештем, бер туңдым, аннан торып, арлы-бирле бүлмәдә йөрендем. Җаным дуфан иде, аны бастырырлык көч тапмагач, бу халәтемнән хурланып, тып-тын гына еладым… Йә, кем инде мин хәзер? Башта: «Тузан бөртеге дә очырмагыз, мин — ак болыт», — дип кабарындым-күперендем дә, соңыннан алдыма тезләнгәч, егетнең карашыннан җебедем… Ә ул, яшь төлке, тәҗрибәле иде, йомшаруымны сизде. Аңа шул гына кирәк тә. Менә иртәгә әрсезләнеп тагын сүздән бау ишәр. Егет — аучы, кинәт кенә табышына сикерми, аның эзенә баса-баса эзәрлекләп тәм таба. Ә мин корбан идем. И беркатлы җан! Башка хатын-кызлар кебек җиңел генә каптырам дип хыяллана микән?

Тәрәзә төбендә машина кычкыртты. Пәрдәнең читен генә этәреп, тышка карадым: Равил, тәгәрмәчләренә типкәли-типкәли, машина тирәсендә бөтерелә иде. Йөз-кыяфәтендә, атлап йөрешләрендә җиңүчеләргә хас тантана. Имеш, мин аңа утырам да, ул очыртып кына авылга илтә. Ә мин бүлмәмдә бикләндем. Моннан соң ялгыз калырга ярамас, моннан соң, такылдап туйдырса да, Гаянны янымнан җибәрмәскә кирәк. Кызык фикер! Ә нигә мин ялгыз калмаска тиеш әле? Кемнән куркам мин, кемнән? Шушы егет кисәгеннәнме? Кулыңны шаярып утка тыкмасаң, беркем дә мәҗбүр итми. Димәк, димәк… бердәнбер куркыныч зат ул мин үзем идем!

…Төнлә чек тә чек ишеккә чиерттеләр. Лагерь изрәп йоклый иде. Аяк очларына гына басып ишеккә килдем дә сулышымны эчкә кысып тыңландым. «Кем анда?» — дип сорау егетнең әрсезлеген хуплау билгесе иде. Дәшмәгән очракта өстенлек миндә калачак. Ә ул тагын чиертергә базмады. Таң минем өчен атса да атты, атмаса да атты.

Ә икенче көнне Равил, эш планын күрсәткән булып, колагыма пышылдады:

— Нишләп әрекмән төбенә посасың, баг алмасы? Мин сезнең халыкның психологиясен шәп өйрәндем. Сездә түземлелек чамалы. Әйдә, аулакта күрешик инде.

Мин бу тәкъдимне колак читенә дә элмәдем.

— Планыгыз әйбәт, — дидем. Һәм Гаянны чакырдым. — Экскурсиягә син дә барасың, Гаян Наиловна!

— Ә Равил Сәйдәшевич нишли? — Кыз чырае караңгыланган егеткә ымлады.

— Ул бүген лагерьда кизү, — дидем.

— Башы авырта мәллә?

— Әйе, Равил Сәйдәшевич күптән сырхау. Чиренә дәва да юк, ахрысы.

Бусын егет ишетсен өчен кычкырып әйттем.

Ул ишетте һәм миңа сәерсенеп карап куйды. Бая гына масаюдан дөньяга җәелгән егет: «Ник көләсең?» — дип рәнҗи иде. Шуннан соң Равил көнозын күзгә-башка чалынмады.

Кичкырын Гаян бүлмәгә ирле-хатынлы ике ят кеше алып керде.

— Равил Сәйдәшевичның апасы белән җизнәсе ат җигеп килгәннәр, — дип хихылдады кыз. — Энекәшләрен эзлиләр, кыскасы.

— Ә Равил кайда? — Чәч бөртекләремә кадәр кызарды бугай.

— Аныкы кайда? Аныкы айда! Машинасы да юк, — диде Гаян, җилкәсен сикертеп. — Соң ул бит җегет кеше, күрше авылда кызлар аулыйдыр. Хатын-кыз исе иснәмичә яши алмый бит сезнең азгын энекәшегез, Суфия апа.

— Ул андый түгел, — диде хатын, уңайсызланып. — Миңа җитәкче белән икәүдән-икәү генә сөйләшәсе иде. Ислам, син дә чыгып тор әле. Гаян иркәм, ачуланма, син дә, яме?

Суфиядә Равил чалымнары бар иде. Хатын, япмасын кайтарып, караватт читенә утырды.

— Мин Мәүлидә абыстайдан өшкертә ием. Әбиеңнең сулышы шифалы ие. Синдә дә андый сәләт юктыр, Диләрә?

— Сез миңа былтыргы танышым кебек эндәшәсез, Суфия. Без беренче тапкыр очрашабыз бугай.

— Гаепләмә, безнең гел авылча инде. Аннан… — Хатын да үзалдына кызара иде. — Син бит Равилнең теге чактагы «төнге кошлары»ның берседер. Урманга ул чакыргандыр инде сине.

— Нинди «төнге кошы»?!

— Ие, сез якынлыгыгызны яшерәсездер инде. Диләрә, зинһар, энемне аздырма! Өйләнмичә картая бит инде шул галәмәт себерелеп! Үз тиңе кирәк бит инде аңа! Әни әнә кайгыдан тагын урын өстенә егылды.

Бу хатын бутала иде. Һичшиксез, Карасуда Диләрә исемле тагын бер адашым яшидер, һәм Равилнең апасы аның белән гәпләшәм дип ялгышадыр.

— Сезгә икенче Диләрә кирәк, авылдагысы, — дидем.

— Мине җүләр димәгез, мин танып сөйләшәм. — Равилнең апасы еларга ук тотынды. — Мәүлидә абыстай бик йомшак күңелле ие, син дә бәхетсез кешеләрне кызганасыңдыр дип уйладым. Начар нәсел баласы түгел, дидем. Әни авыру бит безнең, бәлки, өч-дүрт атнадан якты дөньялар белән бәхилләшер. Шул гомерендә дә энекәш аны тәмуг утларында яндыра. Исән вакытында өйләндереп, карчыкны сөендермәкче идек, ә ул әнә һаман иске гадәтен куа икән. Хәерсез, ике ел гына тәнәфес ясады да…

Хатынның өтек-төтек сүзләреннән шул мәгълүм иде: мин яшь егетне аздыру нияте белән Карасуга кайткан юньсез Диләрә икән. Элек тә без аның белән мәхәббәт «пешергән» икән. Егеткә өйләнергә кирәк, ә мин, әлеге дә баягы юньсез Диләрә, аны бәйдән ычкындырмыйм икән. Күңелемә җирәнү сыман бер хис тулды. Суфия күз яшен сөртә, ә битендә буй-буй кара эз сызыла. Күрәсең, ул бәрәңге чүпләгән җиреннән капыл гына торып урманга йөгергән, ә безне ике көн эчендә кемдер фаш иткән һәм Равилнең туганнарына шылтыраткан иде. Кем? Гаянда кесә телефоны бар. Директор кызы да муенына бау белән «элемтә» аскан. Аш бүлмәсендә дә телефон. Пешекче кыз белән мин әллә ни аралашмыйм, ул Гаян карамагында. Менюны алар бергәләп төзи. Йә, кайсысына шик белдерим? Ләкин монысы баш ватарлык табышмак — бәла түгел әле. Кызык, Равил нинди «төнге кошлар» аулаган? Ул: «Мин сезнең халыкның психологиясен шәп өйрәндем», — дигәч, мин нишләп сагаймадым икән?

— Суфия, яшермә, барысын да сөйлә!

Ишекне ыграк тартып яптым. Хатын шешенгән күзләрен тасрайтты.

— Сиңа караганда мин күбрәк беләм дисең мәллә, Диләрә?! Казанда соңгы курсларда укыганда, өч бүлмәдәш егете белән энекәш үзләреннән олы бай хатыннарга «гыйшык хезмәте»нә ялланган. Бригада оештырган алар. Заказлар яңгыр төсле яуган. Укуын көчкә-мөчкә ялгап чыкты, җирбит. Төнлә «эштә», көндез арып йоклый ие, ди җизнәсе. Ислам бит, Казанга командировкага баргач, энекәштә куна иде. Түләвен яхшы түләдегез, Диләрә. Кичәге студент авылга яңа машина белән кайтты.

— Энегезнең шөгылендә минем бер катнашым да юк, Суфия. Мәүлидә әбекәем рухы белән ант итәм.

Мәрхүмәне кузгатып, әлбәттә, гөнаһ алдым. Нигә акланам, нигә?!

Хатын әллә нишләде: кара буй белән чуарланган йөзенә курку бәрде. Бернинди сөяркәләр асрамадым дип йөз кат тәкрарласам да, ул ышанмас иде, ә монда бер исем хөкемдар сыман бөтенесенә дә нокта куйды. Суфия тагын илаулап елады.

— Ай Аллам, нахакка сине каргыйм икән лә! Гайбәткә буялдым, йа Аллам! Иманлы нәсел баласы акча түләп җегет-җиләннән сөйдертәмени, тузга язмаганны! Кичер, Диләрә, кичер. Зинһар, Гаянга серемне тишмә. Равилнең маҗараларын күңелеңә биклә, зинһар!

Бу хатынга үпкәләмәдем. Гомер буе ак эт бәласен кара эткә сылтыйлар. Мин дөньяның сәер хәлләренә күптән әзер идем, миңа мондый ачышлар, гәрчә беренче мәртәбә ишетсәм дә, яңалык түгел. Мөгаен, андый чакларда җан шәрифләрем бик карт дәрвиш кыяфәтендә яшәешнең үзгә бер үлчәменә күчәдер. Алайса, нигә миңа кинәт кенә авыр соң әле? Нигә? Гаҗәп бит, әйеме? Нindидер Суфия елый, нindидер Равил бай хатыннар белән чуала. Йә, шуннан? Нишләп мин ятлар кулындагы ташны көчәнә-көчәнә төям, ә? Ватылсын-уалсын, аларга җиңел булсын, имеш.

Кинәт кенә җанымдагы авырлыкны читкә чөеп аттым һәм диварга кадакланган озынча көзге каршында әйләнә-тулгана башладым. Әйе, минем буй-сыным зифа, әйе, билләрем нечкә. Әйе, мин иң матур бакчаның иң сусыл алмасы. Күзләремдә нур да сүнмәгән, тере ут чәчрәп яна. Маңгаемда ике хыянәтче җыерчык кына «без, без» дип шәрран яра иде. Әгәр алар дөньяга каш җыерып караганга күрә тирәнәйгән дисәң, мин әле яшь идем, бик яшь идем. Әнә шулай үз-үземне юаттым-җылыттым. Тик…

бу уйны күпме генә күңелемнән кусам да, ул барыбер кырмавыктай ябышачак иде. Димәк, Равил мине акчалы шәһәр бикәсе дип уйлаган һәм тасма телләнеп яуларга теләгән. Димәк, ул… юри гашыйк булып кылана. Минем өчен бу бик зур кимсетү иде. Ул хәсрәт аучы кайда икән? Шуны битенә бәреп әйтәсе иде. Мин дуамалланып әздән генә аны эзләп китмәдем. Мондый юләрлеккә кем генә базыр иде икән?! Әллә егет, миннән салкын бөркелгәч, чираттагы «акча капчыгы»н аулар өчен Казанга элдерде микән? Бәлки, ул шушы минутларда берәр бай ханымны назлап сөядер? Менә аңа «хезмәте» өчен уч тутырып акча түләрләр. Йа Ходай! Нинди әшәке уй тозагында чәбәләнәм! Кемнәндер көнләшәм мәллә?

Бәйләнчек уйларымнан качып җырлап карадым, ләкин тавышымны үзем дә танымадым. Эчемнән кайнар бәрә, эчем көя, чөнки күл буенда алдыма тезләнгән егет карашы белән бөтен гәүдәмне яндыра иде…

**2**

Иртән без Биләр тавына сәяхәткә җыендык. Урман аша туры юлдан гына тәпиләсәк — анда хәтле җиде чакрым тирәсе иде. Тик холыксыз Гаян киреләнде:

— Җыенабыз хатын-кыз. Безнең урманнар калын, бүреләр ботарламас, ике аяклы җанварлар җитәрлек, — диде һәм, кемнедер югалткандай, күзе белән аланны айкады.

Ә минем күңелем аны таң аткач та эзләгән иде инде. Бу үзенә күрә аклану да иде: лагерьда мин — баш укытучы, ә Равил Сәйдәшевич «түрә» белән санлашмый, каядыр җил куып йөри.

— Син бит нәчәлник кеше, Диләрә, ник ул җегетне тыймыйсың? Аңа ирек бирсәң, атна буе лагерьга килмәс, — дип чәпчеде Гаян. — Ир-ат затыннан башка Биләрегезгә аяк та атламыйм, вәт шул! Директорга шылтыратыйм әле.

— Равилнең әнисе чирләгән. — Мин көпә-көндез кычкыртып алдаштым. — Сорады ул, кичкә кадәр.

Кыз җенләнеп кесә телефонын бәләкәй сумкасына ташлады.

— Сорады, дисеңме? Кайчан? Апасы кичә генә энекәшен таптырды бит.

— Суфия миңа килгән иде.

Нәни ялганга олысы өстәлде.

— Аңа синнән ни кирәк?

Гаянның төпченүе ачуымны кабартты.

— Күп белсәң, тиз картаерсың. Ярты сәгатьтән юлга кузгалабыз.

Кыз һаман үзенекен сукалады.

— Арабызда гайрәт өчен ир-ат булмагач, ничу еракка сәяхәт итәргә, үзебезнең аланда гына болганыйк, — диде.

Гаянның өркәклеге кызларга да йокты, аларның алтысы гына батыраеп миңа иярде. Без бернинди хәвеф-хәтәрсез Биләргә барып җиттек. Ләкин безгә биеклекләр белән хозурланырга язмаган икән, кырмыскалар кебек үрмәләп тау түбәсенә менеп баскач кына һава бозылды: баш очында ямьсез соры болытлар укмашып, көннең якты чырае караңгыланды. Тамак ялгарга дип чирәмгә ашъяулык җәйгән генә идек, күкнең сүрүе ертылгандай, җиргә эре-эре яңгыр тамчылары коелды. Аяклар юештә тайгач, туп сыман аска тәгәрәштек. Табигатьнең көтелмәгән кыланышына шаккаттым: күк гөмбәзе, ни гаҗәп, табигатьнең җәйге кануннарына буйсынмыйча, бозлы яңгыр яудыра иде. Ара ерак, йөгереп кенә үтәрлек түгел, ышыкланырга да урын юк. Кызлар кызык табып, шырык-шырык көлешкән иде дә, юка күлмәкләре тәннәренә ябышып, суык агай борып-борып чеметкәч, боегып-бөрешеп, атлар-атламас булдылар. Ашыгудан ни файда?! Урман барыбер коткармый, ул, киресенчә, комсызланып болытларны үзенә суырды. Кайта-кайта миңа икенче нужа агай тагылды: басканда аягым авырта иде. Күрәсең, таудан тәгәрәгәндә ул каймыккан, ә мин кызулык белән моны сизмәгәнмендер. Әлбәттә, ыңгырашу-зарлану укытучы кешегә килешми иде. Аннары мин үземне иң артка чигердем: берүк шушы яшь чебешләр чирләмәсен. Табигатьне гаепләмәсләр, миңа кырын карарлар. Күк белән җирне тоташтырган яңгыр эченнән «агып» чыккан машинаны мин абайламыйча калдым. Ул кисәк кенә каршыбызда туктады.

— Ур-ра, Равил абый! — дип, кызлар аңа ташландылар.

Егет тиз-тиз ишекләрне ачты.

— Әйдәгез, Диләрә Әсәдулловна! Башта сезне илтәм! Болай һәммәгез дә сыймыйсыз!

— Юк, юк! — Мин берәм-берәм кызларны машина эченә тутырырга керештем. — Бөгәрләнеп булса да утырыгыз! Минем арттан килеп мәшәкатьләнмәгез, Равил Сәйдәшевич! Әкрен генә үзем дә кайтам мин.

Йә, нәрсә лыгырдый бу юләр тел?! Яңгыр чиләкләп-чиләкләп коя, урманга болыт тартылган саен тартыла.

Егет тышка бүселгән кыз-кыркынны этә-этә көчкә ишекне япты һәм гамьсез генә минем тарафка бер сүз ыргытты:

— Ярар…

Гүя мин күлдәвекләр белән агып китсәм дә, аңа барыбер. Хәерсез көн, чыланган өс-баш, авырткан аяк — болар мине җебетмәскә тиеш иде. Мин, горурлыгыма таянган килеш: «Утырмадым шул, егет», — дип масаеп, ничек тә юлдан теркелдәргә тырыштым. Әмма иң карт, иң хәлсез ташбака да миннән җитезрәк кыймылдар иде. Тигез тротуардан гына йөреп өйрәнгән аякларым су белән балчыктан изелгән апара ерырга күнекмәгән. Тездән пычракка баттым. Җитмәсә, таеп та егылдым. Миңа болганчык күлдә чәбәләнгән мескен балык буласы гына калды.

Ә ул әйләнеп килде… Менә шулай, килде. Аңардан пар бөркелә иде.

— Бик каты кудым. Ике төштә тәгәрмәч тайды. Син шундый матур…

«Тасма телләнмә», — димәкче идем, теш арасында ком бөртекләре шыгырдады. Мин күлдәвектән су да эчкән идем.

— Әйдә машинага чум, анда йомшак япма бар, чишенеп шуңа төрен. Иту авырыйсың.

— Рәхмәт, үзем дә кайтам.

— Их сине, шәһәр кызы! — Егет мине капчык кебек кенә күтәрде дә арткы утыргычка утыртты. — Курыкма, сиңа карамыйм, синең чибәрлегең болай да күренә. Мин тышта көтәм.

Миңа калтыравык суккан иде. Коры япма белән урансам да, гәүдәм җылынмый, әйтерсең мин боздан катырылган сын идем.

— Каядыр туктап юынасы иде. Бу хәлдә лагерьга кайтуы уңайсыз, әллә ни уйлarлар, — дидем.

Нихәтле генә телемне йозакка бикләсәм дә, егет белән сөйләшергә мәҗбүр идем. Их, горурлыгымны сындырды яңгыр, сындырды!

— Ә син кешеләр нәрсә генә уйласа да пошынмыйсың бугай, баг алмасы.

«Баг алмасы…» Аһ, шушы төче кушамат (әйе, ул миңа кушамат кебек ишетелә иде) җеннәремне йөз бауга тезеп атындыра иде. Йодрыкларым белән әздән генә егетнең җилкәсенә төймәдем: «Мин баг алмасы түгел, түгел!»

— Алда күксел дивар, берни күренми, бүре юлдан аркылы чыкса, таптала, — диде Равил. — Урманда төн кунмагаек әле. Сине лагерьдагылар Карасуда дип белә, ә мин… Апа кичә синең яныңа килдемени? Гаян әйтте. — Егет җавап көтеп машина маңгаендагы көзгегә текәлде. Арткы утыргычтагы юлдашны шуннан күзәтергә була иде. Мин, әлбәттә, кызганыч кыяфәттә идем. Нинди хурлык. Ниһаять, үрмәкүч тозагына эләктем. — Апаның сиңа йомышы зур идеме? Озак серләшкәнсез, ди. Ник дәшмисең, Диләрә?

Аның төпченүе йөрәгемне ярсыта иде.

— Төшер, җәяү генә кайтам, — дидем.

— Машинада кайтасың, — диде Равил. — Без хатын-кызны япа-ялгыз гына карурманда бастырып калдыра торган егетләр түгел!

— Дөньядагы барча хатыннарга да хезмәт күрсәтеп бетерә алмассың. Минем сиңа түләргә акчам да юк!

Егет нәрсәгә төрттерүемне аңлады. Ул шаркылдап көләргә тиеш кебек иде. Көлмәде. Машинаны кисәк кенә туктатты да газаплы бер ыңгырашу белән рульгә табан авышты.

— Их, апа, апа… Кешенең бәхетен җимерергә дисәң, аңа куш.

— Син минем бәхетем түгел, егет!

— Аның каруы син бәхетле, ахрысы. Без, ирләр, мәгънәсез халык инде. Каушавыбызны яшерер өчен әллә нинди тозсыз сүзләр сөйлибез. Рәнҗемисеңдер бит теге көндәгеләр өчен… Юри телемә салындым мин. Хет ышан, хет ышанма, сине беренче күргән мәлдә үк йөрәкне утта көйдердең, Диләрә.

Йа Аллам, ник син мине чукрак итеп яратмадың?! Ник, ник!!! Мин бу хәтле ясалма һәм төче сүзләр ишетергә тиешмени соң?! Миннән кычкырып көләләр, мине җәберлиләр. Йа Аллам, зинһар, колакларымны томалама!

Егет кул арты белән тирләгән тәрәзә пыяласын сөртте. Ул минем эчтән генә ничек үртәлгәнемне сизми иде.

— Йөз елга ике генә ява ул мондый салкын яңгыр. Табигатькә аптырама, диләр.

Яусын, яусын! Дөньясын су бассын! Монда минем үз хәлем хәл! Чү, нишлим мин? Тәүбә, тәүбә!

— Апага ышанма син, Диләрә…

— Минем сездә эшем юк!

— Апада, бәлки, юктыр, ә миндә бар, Диләрә.

— Мин кемгәдер акча түли-түли назланырга җыенмыйм, егет! Маңгаема «Сөяркә эзлим» дигән белдерү ябыштырмаганнар.

— Борчакны мул сипкән апа. Бүлмәдәш малайлар оештырган төркем юкса. Алар өчесе дә армиядән соң тәҗрибәле, чая егетләр. Хатын-кыз көенә оста бииләр. Мәгълүматлары турында сөйләп көләләр иде. Мин төнлә тимер юлда вагон бушата идем. Әни хакына. Ул ялган шеш авыруы белән чирләгәч, операция ясатырга акча эшләдем. «Байбичәләр белән өстерәлә» дигән дан шуннан таралды. Җизни

алып кайтты ул хәбәрне апага. «Тәгәрмәч»не мин җәйге шабашкада эшләгән акчага юнәттем. Уф, бала-чага кебек акланып утыр инде, әй! Көлке, валлаһи!

Равил машинадан төшеп яңгырга коенды. Мин туңам, ул яна иде… «Җебенәсең, кер», — димәдем. Мин каты бәгырьле идем, мин таш идем. Егетнең хикәяте әллә чын, әллә ялган иде, аермадым. Моның мәгънәсен дә тапмадым. Минем хисләрем белән уйнамасыннар, миңа сүз белән тимәсеннәр, кыскасы, шәхси дөньяма тыкшынмасыннар — бердәнбер таләбем шул иде. Ә гайбәт, кысылып, апа белән энекәшне бозыштырган икән, бигайбә, ике туган араларын үзләре көйләсен.

Мөгаен, егет табигать белән көч сынаша иде. Тәрәзә пыяласын аска шудырып:

— Салкын тидерәсең инде, — дидем.

Тавышым йомшарган иде. Равил кулын уа-уа кереп утырды:

— Боз ява, валлаһи. Юл артык изелгән, көпчәкләр тарталмас, ахрысы. Якынрак авылдан өстерәтергә трактор-фәлән чакырмыйча булмастыр. Син машинада гына торып тор.

— Озак сибәләр микән? — дидем кәефсез генә.

— Күк йөзе көнчыгыштан агара, болытлар итәген җыяр.

— Көзге көннәрдән дә суыграк…

— Әниләр сагынган кояшлы җәйләр сирәк хәзер, Диләрә.

Бак, әле генә бер-беребезгә кадалган энәләр күптәнге ахирәтләр кебек чүкердәшә идек. Әйтерсең баягы «аңлашулар» кайдадыр үзелеп-коелып калды. Бәй, егет акланды да, аңа карашым үзгәрде, димим. Барысы да микъдарына кадәр үлчәүдә үлчәнгән иде инде.

Ул авылга китте, ә мин, һичкемнән тартынмыйча, иркенләп ыңгыраштым: аягымның авыртуына чыдар әмәл юк иде. Ниһаять, урман өстендәге кара-кучкыл болытлар кубарылып офыкка табан шуышты. Күкнең ярты ягы ачылды. Һай, егет кенә озаклады! Аяк сызламаса, мин, бәлки, җәяү генә Карасуга турылар идем. Бездәге кирелек потлап-потлап базарларда сатсаң да кимеми иде. Алай да, калтырануларымны җиңеп, юеш күлмәгемне кидем. Башымда яшендәй уй да ялтырады: таякка таянсам, барам да барам инде мин. Әй, бу кирелеккә дә охшамаган, җаным тоткынлыктан котылырга ашкына иде. Кинәт кенә качасым килә! Качасым, качасым… Нишләдем, йә?! Равилнең үзенә дә, сүзенә дә битараф хатын болай үрсәләнмәскә тиеш югыйсә. Гомер сәгатьләре кайда текелдәсә дә барыбер түгелмени?! Төн белән машина салоны җылынды бугай, гәүдәм изри-ойый башлады. Минем дөньям белән йокы дөньясы уртасында нечкә генә күпер сызылды. Мин йокыдан һәрвакыт куркам: шул чакта яңадан чын халәтемә кайталмам төсле. Ә бу юлысы аң нигәдер карышмый, мамык түшәк җәйгәннәрмени, әкрен генә утыргычка түнәм. Нindидер сихри көч, аягымның да авыртуын оныттырып, үзе кайнар, үзе иркен куенга китереп сала. Мин монысына да карышмыйм, киресенчә, ләззәт һәм рәхәт тоеп, төшемдә елмаям. Саташкан димәгез! Ялгыз хатынның өнендәге мендәре — таш, юрганы — калай шул аның…

Үз-үземне җылытып, бөгәрләнеп озак йокладым, ахрысы, агач яфракларында яңгыр тамчылары кипкән; алар кинәнә-кинәнә җилдә лепердәшә. Ә Равил кем беләндер бәхәсләшә иде.

— Көт дигәч көт инде, абзый. Түлим, дидем бит мин сиңа!

— Көтмәгән кая! Өч сәгать бушка трактор тырылдатам!

— Сәгатен ничәдән?

— Нәстәнең сәгатен?

— Соң, сәгатьләп түләргәдер бит тракторыңа?

— Аңа акча нәстәгә, энем?

— Ярар, абзый, үзеңә ничәдән?

— Җәмгысы мең тәңкә, энем. Ну, уят теге кешеңне, озак йокы бүсә.

— Тимә, абзый, тагы әз генә йокласын.

— Жук, энем, мең тәңкәң дә кирәкми! Калхуз рәисе сугып үтерә мине хәзер.

Бәс, «ызгыш алмасы» мин икән ләбаса! Тырнак очы белән тәрәзә пыяласын кактым. Машинага сөялгән егет:

— Кузгалабыз, абзый, — диде. — Карасу башына хәтле тарттырып илтсәң, мең тәңкә синеке!

Ул — җиңүче, аның күзләреннән тантана очкыннары чәчри иде. Моны үзе дә яшермәде:

— Менә эләктең бит. Сиңа кайчан шулай сокланыр идем. Йоклаганда син тагын да чибәррәк икән, — диде.

Мин иренемне тешләдем. Әлегә вакланырга исәбем юк иде. Ул да бүтән теленә салынмады. Без, пычрак ерып, Карасуга юнәлдек. Апалар турында «рәхмәт» әйтеп Равилнең борын төбендә генә капканы ябам дип уйлаган мин җиргә дә басалмадым. Аяк битем кабарып шешкән иде.

— Нишләдең, Диләрә? Егылдың мәллә? — дип, егет миңа ярдәмгә атылды.

Мин кулым белән аңа киртә ясадым:

— Кагылма! Үзем дә атлыйм!

Бер аякта сикерә-сикерә капка тоткасына үрелгәндә, Равил мине, капчык сыман гына култык астына кыстырып, баскычка утыртты. Аннары чиләктәге яңгыр суында кулын чайкагач, җиңен сызганып куйды:

— Каймыктыргансың син моны. Бераз дәвалыйбыз хәзер.

— Кагылма, дим!

— Ә син кычкырма, яме, шәһәр кызы! Әнә теге куактагы чыпчыкларны өркетерсең.

Күземә яшь тыгылды. Юк, авыртудан түгел, гарьлектән. Бу егет, әрсезләнеп, җаныма үрмәли иде. Моңа сәбәп артыннан сәбәп чыгып торуын кара син! Егет, алдыма чүгәләп, аягыма баскаларга кереште.

— Кай төштәрәк авырта? Сынмаган, димәк, әйбәт. Каймыккан бу нибарысы. — Ул муенымнан ефәк шарфымны суырып алды. — Каты гына кысып бәйлим. Туйга хәтле төзәлер, шәт.

— Нинди туй?

— Безнеке түгел, курыкма. Халыкта шундый әйтем бар.

Хәйләкәр Равил әкрен адымнар белән җаныма якынлаша иде. Өйгә кертмәскә кирәк! Мин аның ни теләгәнен беләм… Әйе, беләм… Аның минем белән уйныйсы, шаярасы һәм ахырдан җиңүе белән мактанасы килә. Студент бүлмәдәшләре кебек ул да бер көнлек мәгълүматларга кызыга. Бәйләп бетергәч, егет аягымны сыйпаган иде, кисәк кенә тибендем. Мондый тупаслык килешми иде, билгеле. Оят, миндә хатын-кызларга хас нәфислек үлгән иде, ахрысы. Хәтта ул да бу тәрбиясезлегемнән уңайсызланды. Капка төбендә исә, миңа табан борылып:

— Теге сүзләр уйнап кына әйтелде, — диде. — Мин сине уятырга җәлләдем, безнең әни дә синең кебек бөгәрләнеп йоклый, шул гына.

Егет минем белән саубуллашмады, ул гүя, «шул гына» дип, араларны шартлатып өзде. Хәер, нинди өзәрлек ара бар соң! Без бер-беребезгә ят идек, чит идек. Равил киткәч, нигәдер мине сагыш басты. Җитмәсә, үч иткәндәй, авылга эңгер иңде, ә ялгыз җаннарга кичләргә керүе бигрәк авыр иде. Төннәрдә тагын да авыррак анысы. Сине мендәреңнән башка берәү дә көтми. Караңгылыкны иш ясап, көчкә таң аттырган чакларың да була.

Сәрбиназ карчык капкадан гына башын тыгып сөйләнде:

— Этеңнең тамагы тук, мин мәет сакларга барам. Сәхибҗамал әбкәчең гүр иясе, ватый, — диде. — Иртәрәк шылды мәрхүмә. Җәш ие әле, җөзен генә ваклаган ие. Мәүлидә күрше үз катына җыя, ватый. Анда да тик җатмый, терекөмеш.

Әбине күңел белән тыңламадым. Мин үз сагышым дөньясында йөзә идем. Офыкка җәелгән кояш кызыллыгы бәгыремне көйдерде. Бөтен булмышымныниндидер сәер тойгы биләде: авылда да тар, шәһәрдә дә тар, җаным Галәм сүрүенә сыймый иде. Аяк битемдә исә әле дә аның кул җылысы… Күр, мин егет белән ничек көрәшәм. Мондый хатын-кыз сирәктер ул. Әллә җаным таштан әвәләнгән микән? Кеше матур сүзләргә юри алданыр иде. И Ходай, моның хәтле акыл бирмәсәң лә. Шул акылга юләрлек кушып әз генә сыеклатсаң, бәлки, хәлләрем җиңеләер. Һәм бүген мин йолдызлар белән чуарланган җиһан уртасында япа-ялгыз каңгырап та утырмас идем. Ялгызлык… Мин аның ни-нәрсә икәнен аңлый башладым шикелле. Чү, тукта! Әгәр мин аңа ышансам? Әйе, әйе, Равил чынлап та гашыйк дип фаразлыйк. Әнә йолдызлар аның сүзләрен җепкә тезә: «Син минем бәхетем, ахрысы… беренче күргән мәлдә үк йөрәгемне утка көйдердең, Диләрә…»

Бу сүзләр өчен мин күккә рәнҗи алмый идем, чөнки хыялым үзе шулай тилертә иде.

…Төнлә шык та шык тәрәзә пыяласын миләш ботагы кыйнады. Ул әче җимешләреннән арыган иде бугай. Ә мин аягымның авыртканын да онытып… Ул килде дип… Күземнән эре-эре тамчылар тәгәрәде. Мин бәхетсез идем. Ялгызлык янәшәсендә шушы кимчелегем дә бар. Нигәдер бөтенесенә дә Илдус гаепле кебек тоелды: мөгаен, мине шул егет кенә каргаган. Нәкъ бүгенге сыман йолдызлы төн иде.

Илдус, әсәренеп:

— Диләрә, миңа кияүгә чыгасың син, ә мин туй бүләге итеп сиңа яңа яуган кардан да аграк акбүз ат бүләк итәм, дөнья читеннән табып, — дигәч, пычак телем:

— Син аңа үзең генә өйлән инде, хәчтерүш, — диде.

Шунда Илдус чәнти бармагымны кысты да:

— Бүләкне үзең эзләп килерсең, кызый, — диде. Хурлау-көлүләргә ни түзгән егет урталай сыгылып елады…

Бүген ул дөньяда микән? Очратсам, бәлки, мин аңардан кичерү сорар идем. Кичер, Илдус.

Таң алдыннан җил тынып, миләш шыкылдавыннан туктады. Тынлыктан колаклар сызлый иде. Мин бу авылдан югалырга тиеш. Кая? Кысан фатирыма, билгеле. Адәм баласы, уе белән дүрт тарафка чәчелсә дә, аяклары бер генә җиргә илтә — үз куышына. Иртәме-соңмы. Ул, адашкан җанын сөйрәп, нигезенә кайтып егыла. Миңа ашыгырга кирәк. Мин үз-үземнән куркам. Миләш шыкылдагач, ул дип алдандым. Димәк, аны көттем. Йа бер Аллам, көттем шул, көттем! Йөрәгемне мең киртә белән уратып, мең сакчы бастырсам да, мәхәббәт дигән үзе явыз, үзе мәрхәмәтсез, үзе өметсез хисләрнең тозагында

чәбәләнеп ятам. Йа Аллам! Маңгаемны ташка орып сиңа ялварам: бүтән очраштырма! Бирмә миңа сөю җәзасы, бирмә!!!

**3**

Авыл тынлыгын шәһәрдә адаштырдым. Казан — зур базар, шаулый-гөрли иде. Мин дә аның ритмына яраклаштым шикелле. Әйтерсең тәүлектән артык йоклап, төшемдә Карасу белән саташып уяндым. Баксаң, алан да юк, Равил дә юк… Озак-озак тауар кибетләрен буйладым. Яңа уку елына киемнәр сайлыйм, имеш. Аннан берәм-берәм ахирәтләремә сугылдым. Ә алар җәйге ялда иде. Кафеда колакны ярган музыка белән узыша-узыша чәй эчтем. Мин көнозын нәрсә беләндер мавыгып чуалган-чәбәләнгән дөньямны тәртипкә салырга тырыштым. Ләкин җанымны алдый алмадым. Ул Карасуда иде, Карасуда! Төнлә төтен белән ысланган күк йөзеннән йолдызлар эзләгәндә һәм эзләп тә тапмаганда, җанның бәргәләнүенә чик-чама булмады. Иртән таң әчесе белән җыендым да авылга киттем. Мин чын-чынлап юләрләнгән идем. «Күпер» тукталышында автобустан төшеп аксый-туксый өч-дүрт адым гына атлаган идем, юл читендә кызыл машина күземә чалынды. Равил! Нишлим мин?! Ник кайтам?! Кичә генә «очраштырма» дип Ходайга инәлгән хатын, чылбырдан ычкынып, егетнең кочагына үзе атыла. Оят, оят, оят!

Равил йокымсыраган иде бугай. Автобус тәгәрмәченең чыжылдаган тавышына уянып, машинадан чыкты. Без, аргы як белән бирге як, бер-беребезгә карашып сүзсез генә басып тордык. Йөрәк сулкылдады, хисләр ташыды…

— Өс… өс-башымны алмаштырып килеш әле. — Ялганласам, тотлыгам икән. — Ә син кемне көтәсең?

— Берәүне… Аягың төзәлдеме?

— Авыртмый…

— Аксыйсың бит. Капка-ишекләрең ачык. Этең дә өрми.

— Казан ерак, тиз генә әйләнәм димә. Ярый, мин туры аланга барам. Син көтәсе кешеңне көт.

— Берәү дигәнем син бит инде ул. Кил, утыр, Диләрә.

Мин йөгәнсез хисләремне тиз генә таш кабыкка төрергә тиеш идем.

Коры гына:

— Рәхмәт, — дидем.

— Әнкәй авырайды, сулышлары киселер, ахрысы. Сине лагерьга илткәч, авылга китсәм рөхсәттер бит, җитәкче апа?

— Үртәмә, зинһар! Алай-болай ярдәм кирәксә, шылтырат.

Егеткә кесә телефоным язылган кәгазь суздым.

Аланда бөтен нәрсә үзгәргән иде. Ничек моңарчы искәрмәдем икән: яфракларына сәлә генә көз сарысы йоккан усаклар нинди төз икән! Аларның түбәсендә кояш нурлары җемелдәшә. Ә каен кызларына аклык болытлардан ягылмады микән? Уенчык чалгы белән чыкырт-чыкырт чикерткәләр үлән чаба… Җирән башлы көяз гөмбәләр, оялчан әбиләр кебек, авызын томалап көлә… Урманда эше төгәлләнмәгән ала кош пыр-пыр куактан куакка очып куна…

Юк, алан түгел, мин үзгәргәнмен. Мәхәббәт, ачкыч ятып, йөрәгемнең бикле ишекләрен ачкан иде. Йа Аллам! Бу чирдән ничек терелергә?! Мин иң куркыныч яшьтә идем. Җиңел-җилпе яшүсмерләрнең акылы җитмәгән юләрлекләрне хатын-кыз кырыктан узгач эшләп ташлый. Табигать йә бәхетле, йә бәхетсез итәр өчен аңа соңгы мөмкинлек биреп карый. Минем очракта исә бәхеткә өметләнү ахмаклык иде. Без тиңнәр түгел идек, түгел идек!

…Егет ярты төн уртасында шылтыратты.

— Миңа син кирәк, чык әле, Диләрә, — диде.

Тавышында хәсрәт бар иде. Ут кабызмыйча гына, ашыга-ашыга киендем. Әйтерсең мин дөньяда баткан бәндәне коткаручы тылсымлы көймә идем. Хатын-кызның тагын бер ялгышы: ир-атның кайгысын да, борчуларын да, йөрәк аша үткәреп, җанына аудара. Ул аның хәсрәтеннән авыруга сабыша.

Мин: «Нәрсә булды?» — дип сорамадым. Барысы да тавышыннан билгеле иде. Без, Галәм өчен ике кара нокта, алан кырыеннан атладык та атладык. Җәй җылысы сүрелгән, җиңелчә генә калтырата иде. Кинәт урманда өзеп-өзеп кемдер ыңгырашты. Куркудан Равилгә табан сикердем.

— Агач ул… — Егет кулымнан тотты. — Корыганда кайрысыннан куба да авыртуга түзалмыйча ыңгыраша. Агачлар аягүрә үлә. Әнкәй китте бит минем…

— Ходай урынын җәннәттән әйләсен. Син… син нык бул инде… Дөньяда без вакытлыча шул…

Равилне юата-юата кулымны бушатмакчы идем, ул ычкындырмады.

— Өйләнәсеңме, диде. Әйе, дидем. Кызың ни атлы, диде. Диләрә, дидем. Мин, алайса, тынычлап үләм, улым, диде.

Аланмы, минме уңга-сулга чайкалдык.

— Синең Диләрә исемле кызың юк!

Бөтен көчемә кулымны тарттым.

— Бар! — Егет караңгылык эченнән кочагына суырып алды. — Мин теге агач хәлендә, кичә төне буе юл буенда ыңгыраштым. Син Казаныңа качтың, әйе. Үзеңне минем йөрәктән каермакчы идең, киребеткән! Паспорттагы яшең белән мактанма, яме! Без дә маңка малайлар түгел, Мәкәрҗә ярминкәсендә кыргый атларны аз биетмәдек.

Аның кайнар сулышы исертә-тилертә иде. Җитмәсә, ярамны кузгатып, Илдус исемә төште. Бу якта ир-ат гайрәт чәчкәндә Мәкәрҗәдә «ат биетә» икән. Янәсе, ат хәтле ат буйсындырып саткан халык алар. Бичара Илдус та шулай сөйләнә иде. Ә аннан ни файда?!

— Диләрә… Син дә хәл эчендә. Юкса кире кайтмас идең, — диде Равил, чәчемнән сыйпап.

Егетнең киң күкрәгенә башымны куйдым.

— И Аллам, бирмә миңа сөю җәзасы…

— Нәрсә дидең син, Диләрә?!

— Юк, болай гына… Мондый кайгылы сәгатьләрдә нишләп йөрисең, егет? Күрше-күләннәрегез ни дияр?

— Син мине таш бәгырь димә! Йөрәгемнең әрнүенә чыдамагач, синең яныңа килдем. Әнкәй бит ул, Диләрә! Өйдә карчыклар төнката дога укый. Әзрәк апаның күзеннән югалып торыйм, дидем. Әнинең өзлегүендә гел мине гаепләде.

— Тиздән таң ата. Кайт инде…

— Сагынуымның яртысын сиңа күчеримме, Диләрә?

— Кайт, яме.

Без нәкъ вакытында аерылдык. Лагерь бинасының өйалдында гөлт итеп ут кабынды. Баскычка киерелә-киерелә күлмәктән генә Гаян чыгып басты.

— А-у, Диләрә-ә-ә! Син кайда?

— Тс-с, шүрәлеләрне өркетәсең? — Мин, үлән ерып, бинага табан чаптым.

— Фу, төн бигрәк салкын! Капыл гына йокым качты, синдә дару юк микән дип бүлмәңне шакысам, урын-җирең тузгыган, киемнәрең чәчелгән, җен урлады мәллә, дим.

— Кем дә урламады. Урман һавасы сулыйм.

— Һи, әкәмәт инде сез, шәһәр кешеләре. Ул һаваны кайсы тишекләргә тутырасыздыр. Әллә сез үлчәмсез инде, тәүбә-әстәгъфирулла. Керәсезме, Диләрә? Бүген сакчыбыз юк, аланда бик хозурланма, бүре абзый ботарламасын. Равилнең әнкәсе каты чирләгән, ди.

— Үлгән… — Мин әз генә тотылмадым. — …Үлгәндер, бәлки.

— Озак интекте, мескенкәем. Энекәй белән апакай тынышалмады. Туганнары өйләндермәкче, ә бусы… Карале, Диләрә. Синдә яучылык сәләте бардыр, иеме? И җайлы җир бу урман, кавыштыр безне Равил Сәйдәшевич белән, җә! Үләм мин шул егет дип саргаеп! Каным кайный, малай.

«Нишли бу җүләр кызый?! Ник ул йөрәгемә пычак белән чәнчә? Әле мин егетнең ут-кочагыннан чыгып суынып та өлгермәдем, әле мин аның сулышына кушылып сулыйм».

Чү, монда мин юләр идем. Кем белән ярышам, ә?! Гаян яшь, Гаян чибәр…

— Кавыштырасыңмы, Диләрә?

— Мин — начар яучы, сеңлем. Үзең егетнең йөрәгенә юл тап.

— Һе, тап, имеш. Өйдә өйрәт. Син ушлы хатын. Директор кызы өчен бик майлы калҗа бит ул Равил!

Һай, ирләр йөрәге мәсьәләсендә мин тәҗрибәсез идем, чөнки элек мәхәббәт учагын кабызыр өчен шырпы да сызып карамадым. Минем бу дөнья өчен бик җайсыз кеше икәнлегем шуннан да беленә иде.

— Чынлап та салкын икән, — дидем. Миңа бәйләнчек Гаяннан арынырга кирәк. Аннан, мин бит бербөтен түгел, кабыгым гына гәүдәмне тотып тора, ә җаным егет белән ияреп киткән иде.

Ул тагын шылтыратты. Мин, баягы хисләрне бастырырмын да Ходай биргән гомеремне элеккечә салкын, битараф дөнья чыраена текәлеп яшәп бетерермен дип, юрган астында бер өшеп, бер туңып ята идем. Телефонга да кагылмадым. Әй, үзеңне алдаудан ни мәгънә?! Әнә, күземне яшькә манчып, күңелемдә сагыну бөреләнә иде. «Сагынуымның яртысын сиңа күчеримме, Диләрә?» Күчте инде, егет, күчте…

Иртәгәсен телефон янә телгә килде. Алмадым… Курку тәнемне куыра иде. Егет, каһкаһә белән көлеп: «Шаярдым», — дисә?

Алан сукмагында ясанган-бизәнгән, бәләкәй сумкасын иңенә аскан Гаян белән маңгайга-маңгай бәрелешә яздык.

— Уф, иртүк һава сулый шәһәр кешеләре. Минем Кәкре Күлгә — Равилләргә йөгереш. Апасына шылтыраткан идем, әнкәй вафат, бүген җирлибез, ди. Менә кайчан егеткә мин кирәк ул! Юатырмын, иркәләрмен, кайгысын бүлешермен. Шәт, син әйткән туры юл йөрәккә шунда салыныр.

Көнләшү дигән әче әрем тәмен татымаган идем. Тамакны өтеп, йөрәкне тырный икән. Юата, иркәли, димәк. Ә миңа егет шылтыратканда «әйе» дип эндәшергә дә горурлыгым кушмый. Һәм мин хәзер генә берничек тә үземне үзгәртә алмыйм.

«Тукта, барма! Минем җаным аның янәшәсендә! Тимә безгә, аерма безне, җилбәзәк кызый!» — Бу минутларда мин булып өзгәләнә-өзгәләнә урман кычкырды, алан кычкырды, кошлар кычкырды…

Ярты көн инә өстендә биедем. Күз алдымда Равил белән Гаян иде. Күр, кочаклашалар, күр. Кыз елан кебек беләкләре белән егетнең муенына урала. Хак, мин куркыныч яшьтә идем. Көнләшүем дә бүтәннәрнекенә охшамаган, үземне эчтән кимерә-кимерә газаплый идем.

Егетнең йөрәгенә юл ярам дип шапырынган чибәркәй борын салындырып кайтты.

— Дорфа, төпсә, тәрбиясез бит ул Сәйдәшләр оныгы. «Җанашым, кайгыңны уртаклашам», — дип кочакламакчы идем, «Синең җанашың — урамдагы багана», — диде. «Нишләп аяк астында буталасың? Диләрәгә булыш әнә», — диде.

— Шулаймыни?!

Урман «уф» дип җиңел сулады, алан кул чәбәкләде, кошлар чыркылдап көлде. Дөньяның караңгы чырае яктырып, җанымны сөенеч биләде. Аһ, бу мәкерле хатын-кыз. Мин шуның берсе идем ләбаса!

Равил икенче көнне кичкырын пәйда булды. Без Гаян белән, сөлгеләр тотып, күлгә төшеп бара идек.

— Әллә су коенасызмы, кызлар? Күкенең тамагы карлыккан бит инде, — диде ул, күңелсез генә. — Аннары, күл белән шаярырга ярамый, дигән идем. Берәүләргә…

«Берәүләр» мин идем, әлбәттә.

— Су пәрие табаныбызны кытыклар дисәң, әйдә, син ярда сакта тор!

Гаян егетнең җилкәсенә сөлге япты.

Мин җиргә әллә бастым, әллә юк. Гәүдәм сукмактан оча. Ул янәшәдә, ул янымда! Аның күңелсез кыяфәте бәгыремне телгәләсә дә һәм мин берничек тә аны юатмасам да, иңнәремдә бәхет канат җилпи. Дөньяны җебеткән яңгырдан соң кинәт кенә эсселәткән иде. Тәннең суда суынасы килә. Тик мин Равил алдында чишенергә оялдым. Ул күлгә карап утырды. Тиз-тиз генә киемнәрен салып ташлаган Гаян юри егет каршында сыргалана-боргалана башлады. Әйе, аның гәүдәсе сылу иде… Мин тагын көнләштем бугай, йөрәк чәнчеде. Егет күзе белән генә чибәркәйне ашый дисәм… Йа Ходай, ул башын тезләренә куйган да мине күзәтә иде. Әйтерсең мәктәп үрмәкүче икебезне тоташтырыр өчен арага җеп үрде. Беркайчан да ирләр карашыннан тетрәнгәнем юк иде. Аның күзләре мине ярату белән коендырды.

— Равил белән аулакта калдыр, яме. Кит, яме. — диде Гаян, колагыма пышылдап.

Кыз, балык сыман, күлгә сикерде.

— Нихәл син?..

Җаным тоташ ут иде.

— Әнкәйне җирләдек. Рөхсәт итсәң, иртәгә апага әйберләр ташыр идем. Коръән мәҗлесенә анысы-монысы кирәк, ди.

— Әй, син тагы! Әлбәттә, бар. Рөхсәт сорап килмәскә иде инде.

— Күрәсем килде, Диләрә. Сине…

Гаян судан башын калкыта да безгә кул болгый, ә аның ишарәсе миңа гына аңлашыла иде.

— Мин… мин теге камышлы тирәсендәрәк йөзәм, — дидем.

Равил дә кузгалды.

— Миңа да вакыт. Апа тиргидер. Төнлә уникедән соң алан очында көтәм, Диләрә.

«Һи, тәки Равил белән кавыштырмадың инде! Терелләй саргайтып үтерәсең инде!» — дип үпкәләгән Гаянга ничек серемне түгим ди?! Ялкыны чәчрәмәсен дия-дия, курка-курка мәхәббәт учагына якынлашканда кеше хәлен уйлыйсыңмыни ул!

…Төнлә яшь кызлар җитезлеге белән тәрәзәдән чыктым. «Алайдыр, болайдыр» дигән икеләнүләрдән узган идем. Алан түшәме бик тәбәнәк, йолдызлар чекерәя-чекерәя миңа карады. Үртәдеме, көлдеме? — Тик үзләренә мәгълүм иде.

…«Алан» миңа куенын ачты. Ул кайнар иде, дәртле иде, чөнки бәгыремнең кочагы иде.

— Сагындырдың, шәһәр кызы, — диде ул.

**4**

Казаннан юксынып дусларым кайтты. Без, гомер сукмагыннан атлаган дүрт җан, холык-фигыльләребез төрле-төрле булса да, бер башак бөртекләре идек. Кызлар башта минем «башбаштаклыгымны» хупламыйча аһ-ваһ итенделәр дә эшкә ябыштылар. Зәрия мунча якты, Гөлия бәлешкә ит-бәрәңге турады, ә Гөлсирә белән без ишегалдында кибеп саргайган үләннәрне йолкып яндырдык. Гөлсирә арабызда бердәнбер ирле хатын иде. Миңа аның белән җиңел дә, рәхәт тә, чөнки ул сөяркәләр белән мактанып саруымны кайнатмый.

— Сине башбаштак дип ачуланды. Кинәт кенә авылда укытырга калуың сәеррәк, Диләрә.

— Тугани апа йорт-җирен минем исемгә яздырган бит.

— Сат! Син — шәһәр кызы, камырын ничек кенә кабартсаң да, авылда ипиең уңмас. Әнә Мәслик, шәп кеше белән таныштырам, ди. Заманында Президент ипподромында чабышкы атлары тәрбияләгән, ди.

Мәслик Гөлсирәнең ире иде.

— Миңа сөяркә кирәкми, сердәш. Ат белән мавыгучылар бигрәк тә.

— Нинди сөяркә! Ялгыз, ди, ул. Хәзер ялда, ди. Караватың кырыена ат бәйләмәс.

Шунда капканың келәсе шылт итте, һәм бер кочак әйбер күтәргән Равил килеп тә керде. Ә мин аны дусларымнан яшермәкче идем… Ул минем иң тирән серем иде.

— Кунакчанда кунаклар икән, Диләрә.

Егет тә уңайсызланды.

— Әйе шул.

— Болар сиңа. — Равил тартмаларны юылган баскычка куйды. — Дәфтәрләр, кәгазьләр, каләмнәр. Йә, хушыгыз, кызлар.

Капка ябылгач та сизгер Гөлсирә:

— Карасуга берегүең аңлашылды хәзер, — диде. — Бу яшь әфәнде сиңа гашыйк!

— Кит әле, сердәш. Хезмәттәш кенә ул. Мәктәптә кирәк-яраклар бүлгәннәр дә, минем өлешне китергән.

Гөлсирә учымдагы үлән валчыкларын кагып төшерде.

— Син үз савытыңа сыймыйсың, Диләрә. Күзләрең сәер яна. Сак бул, яме!

«Сак бул…» Ник?! Нигә?! Минем дә берәр тапкыр яратырга хакым бар лабаса! Тыелмадым түгел, тыелдым. Хисләремне төреп, кыса-кыса бәйләдем, ә төеннәр, әфсен укып өргәндәй, кинәт кенә чишелде-таралды. Лагерьдан соң мин, шәһәргә таясы кеше, директор: «Бездә укытучыларга кытлык, кал», — дигәч, әз генә дә ялындырмадым, киресенчә, күңелемдә шатлык-сөенеч тыпыр-тыпыр биеде. «Ярар», — дип әллә ничә мәртәбә кабатладым бугай. Мин Равил белән араны өзә алмадым! Инде үземне «җүләр» дип әрләүләрдән дә арыдым һәм, тәкъдиремә буйсынып, тып-тын гына яраттым… Авыл көзләре эчпошыргыч күңелсез, яңгыр ява, юл пычрак, кичләре караңгы, диләр. Ә мин шушы елак-мыжык көннәрне, мөгаен, кояшлы җәйләргә дә алмаштырмас идем. Чөнки дөньямны балкыткан кешем гел янәшә иде. Янәшә иде… Ә моның ни дәрәҗәдә авыр сынау икәнен белсәгез икән! Чит-ятлар сизмәсен өчен күзләр генә очраша. Авылда яшерен эш юк, һәммәсе дә уч төбендә ялтырап ята. Ә безгә ничек тә яшерергә кирәк! Коридордан үткәндә, җыелышларда, бәйрәм табыннарында хыялда үрелгән җеп аша гына җаннар бер-берсе белән тоташа. Гүя мин үсмер кыз мәхәббәте кичерәм: үзем егеттән оялам, үзем аңа тартылам. Әмма аулак өй турында хыялланырга да куркыныч иде.

Сәрбиназ карчык:

— Ялгыз хатынга җен ияләшә, — дип, миндә төн куна, ә югары сыйныф кызлары утырмага җыела, Гаян исә минем кулым белән һаман егетне ауларга маташа иде.

— Теге карчыкны биздер, кичкә Равилне чакыр. Аннары үзең өч-дүрт сәгать урамда йөр, сез, шәһәр кешеләре, һава суламаса тончыга, — дип җелегемне киптерде кыз.

Ә мин аның теләген үтәсәм, яраткан кешемнең күңеленә төкерер идем. Әлбәттә, егет ачудан Гаянны тәрәзәдән атачак. Рәхмәт яугыры, Сәрбиназ карчык усал иде.

Ул, кызның мәкерле ниятен сизгәндәй, таягы белән идәнгә кадый-кадый:

— Мин күршем Мәүлидә ызбасында күз дә, колак та, ватый. Миңа кысанланмагыз, оланнар, — диде.

Беркөнне укытучылар бүлмәсендә ничектер Равил белән икәү генә калдык.

Егет:

— Йөз сакчы бастырып кечкенә утрауга япканнар диярсең. Керфегең селкенсә дә сакчы күрә. Былтыр заманнан бирле кулыңны да сыйпаган юк. Син шундый мөнәсәбәтләргә ризамы, Диләрә? Фатир хуҗасы Тимерҗан бабай иртәгә район үзәгендәге кызында куна, ди. Караңгылаткач кил әле…

— Юк, ярамый!

— Нишләп ярамый? Без бер-беребезне яратабыз бит, Диләрә! Мәхәббәттә гөнаһ юк ул.

— Бар. Әгәр ул урланган булса, мәхәббәттә дә гөнаһ бар.

Егет урындыгына сыймады.

— Йә, әйт, без аны кемнән урладык соң? Син дә, мин дә ирекле түгелмени?

Йөрәгемә боз кисәге кадалды. Дөрес, Равил белән мин ирекле. Ләкин без барыбер карак! Без еллардан урлап яратабыз. Егет минем яшь чактагы елларыма кул суза, ә мин аның бүгенгесенә ымсынам. Бездә тиңлек-тигезлек юк!

— Болай гөнаһ дисәң, никах укытабыз!

Нәкъ шул вакытта ишектән Гаян атылып килеп керде.

— Уф, аяк асты лыш измә, итекне суыра. Нәрсә укытабыз дисең, Равил Сәйдәшевич?

— Гаянише наданнар аркасында фәннәрне начар укытабыз, дим. Дәресеңә соңардың, йокы чүлмәге!

Егет бик дорфа, ләкин кызның да тиресе калын иде. Ул хихахайлап көлде дә:

— Киләчәктә, шәт, парлап йокларбыз әле, — диде. Ул яңа ауга әзерләнә иде бугай.

Кичкә табан кыз миңа:

— Бүген өең буш, Сәрбиназ кортканы аргы оч Фатыйма әби кунарга дәшә, — диде. — Син, дускаем, фәлән сәгатькә Равилне үзеңә чакыр.

Мин һаман егетнең тәкъдименнән айнымаган идем. «Никах укытабыз», — дип шаярмады ул. Йа Ходаем, туры юлдамы без? Адашмадыкмы без?!

Бәйләнчек Гаян җиңемнән селкеде:

— Чукрак мәллә син, Диләрә?

— Әзрәк горур бул син, Гаян.

— Нинди горурлык турында сөйлисең, дускаем? Хәзерге егетләрне көчләп үзеңә ябыштырмасаң, алар сакалы агарганда да өйләнми! Син теге заманнар белән чагыштырма, ул чакта чын егетләр олау-олау иде. Бүген яртысын, ирләр чутыннан сызып, чүплеккә генә илтеп түгәрлек. Кайсы зәңгәр, кайсы эчкече, кайсы зәгыйфь! Шушы авылда күзгә кырып салырлык бер Равил бар!

— Ул сине яратмый!

Уйланган кыз бала өчен дәлилем көчле, әмма Гаянның башында җил уйный иде.

— Директор кызын да сөйми Равил. Моңа карап кына директор апабыз өметен өзмәде. Булачак киявем дип әнә, аңа хезмәт дәресләре өстәде.

— Равилне үз өеңдә кабул ит, — дидем.

— Ай-һай, бәгырьсез син, Диләрә. Туктале…

Мин туктамадым, пычрак ерып, Сәрбиназ әбиләргә чаптым.

— Ялгызым гына йокларга куркам, әбекәй, — дидем.

Кунакка җыенган карчык ак шәлләрен чиште.

— Җәсти Патыйма үпкәләмәс, шай, — диде. — Аңа, бакчи, ияләшәсе җен-пәри анук ияләшкәндер.

…Карасуга кыш иртә килде. «Юлларга чана эзе төште», — дип хатлар язган тугани апаны элек аңламый идем. Хәзер моны үзгәртеп: «Машина эзе төште», — дисәң дөресрәк булыр, чөнки авылда атлар юк иде.

— Әйдә, машина белән Казанны урап кайтабыз, фатирыңны угрылар чишендермәгәнме? Тикшерик, — диде егет.

— Фатир исән, анда дус кызым Зәрия яши, — дидем.

— Качарга иде, ә! Утрау сакчыларыннан, дим. Сәрбиназ әби синдә кыш та кышлар микән? Хет капка төбендәге карларны көрисе иде.

Беләм, Равил очрашу көтеп тилмерә иде. Әрсезләнсәм, моның талканы коры, китәр дип пыжымладымы, әллә яратуы сабыр иттерә идеме, бүтән ул «аулак» димәде.

Беркөнне без мәктәп укучылары белән урманда чаңгы шудык. Балалар төркем-төркем агач-куак арасына сибелгәндә, мин тауга үрмәләдем. Равил дә иярде.

— Тотынышып аска очабызмы? — диде ул.

«Очышлар» шома гына үтмәде, чаңгы түмгәккә тиеп, икебез берьюлы көрткә чумдык.

— Кымшанма… — Егетнең кайнар иреннәре карлы битемнән үпте. — Мин сине яратам… Әгәр югалтсам, үләм…

Тау башында кызлар кычкырды:

— Диләрә-ә-ә Әсә-эду-улловна-а!

— Ай, күрделәр! — дидем.

— Күрмәделәр, без кар астында. Әйдә никах көнен билгелик, Диләрә! Кайчан кулыңны сорарга синең?

Кызганыч, җавабым әзер түгел.

Егет — яшел яз, мин — сары көз, ә аңа да, миңа да җайлы уртак ел фасылы табигатьтә юк иде. Ләкин йөрәкнең анда ни эше бар?! Ул яратуыннан шашынып тибә дә тибә. Аннан, нәрсәдер үзгәртергә дип маңгаен ташка орган хатын да мин идем ләбаса! Йә, үзгәрт инде. Бу очракта беркемнән дә киңәш сорама, әнә шул шашынган йөрәгеңне генә тыңла. Чынлап та, мин иректә, дүрт ягымда — дүрт офык. Равил дип авыз суы корыткан Гаян тынычланды шикелле.

— Әй, безнең егеткәебез куркак ич, — диде кыз, җиңелүен аклап. — Армиядән качып, Карасуда сөрседе. Авыл мәктәбендә укыткан яшь белгечләрне солдат хезмәтенә алмыйлар, ди. Срогы тулгач, шәһәргә ычкына инде ул. Директор салам сыйрагын тагын җибәрә инде аңа.

Үлчәү тәлинкәсендә кат-кат үлчәдем дә тәвәккәлләдем. Сырхаулаган Сәрбиназ карчык үзәк хастаханәдә дәваланганда, аулак оештырдым. Үземчә, хәйләләп, мин язмышымны алдамакчы идем: тәрәзәләргә калын пәрдәләр элдем. Янәсе, урамга ут яктысы төшмәсен. Капкаларны терәттем, янәсе, өйдә юк саналам.

…Ул кып-кызыл роза чәчәкләре күтәреп килеп керде.

— Сагындым, — диде. Йөрәк җылымны кушып әзерләгән табыныма борылып та карамады, чалт-чылт уткабызгычларны сүндерде. Егет акылдан язган, егет шашкан иде. Кичә генә: «Көнен билгелибез», — дигән бәндә никах турында кабат сүз кузгатмады. Ә мин… Кемдер, бәлки, «их син!» дип шелтәләр. Кемдер, бәлки, «азгын» дип битемә төкерер. Ләкин үз гомерендә бер тапкыр яраткан кеше һәртөрле әр-битәрдән тыелыр. Әлбәттә, бу гөнаһымны юар өчен дәрья сулары да җитмәячәген белдем мин. Белдем, белдем! Ә үзем аның назыннан эредем-таралдым…

Йокының иң татлы бер җирендә Равил дорфа гына төртеп уятты:

— Диләрә, тор! Без янабыз!

Ничек киенгәнемне дә сизмәдем. Шкафтан документларымны гына алып өлгердем, егет мине ишеккә табан сөйрәде.

— Тиз бул, Диләрә!

Тугани апаның каралты-куралары белән өе уптым дөрләп яна иде.

— Равил! Син кит, яме! Безне бергә күрмәсеннәр!

— Әллә мин куркакмы, Диләрә? Әйдә, күршеләрне чакырып кычкырыйк, әйдә!

— Аннан ни файда?! Өй тоташ ут эчендә бит! Икебез бергә кеше күзенә чалынсак, хурлыкка төшәбез, шул гына. Кит дигәндә, кит син!

Йокы белән исергән тирә-күрше уянып чыкканда, тугани апаның йорты дөнья белән бәхилләшә иде инде. Ир-атлар күмерләнгән нигезгә көрәк белән кар ташладылар да йокы бүсәргә ашыктылар. Үлеп барган авылда бер йортның көлгә әйләнүе алар өчен зур югалту түгел иде. Аргы урамнар исә керфек тибрәтеп тә мәшәкатьләнмәде.

Ни гаҗәп, Гаян янымда бөтерелә иде.

— Әй Аллам! Кемнәр яна дисәм, сез икән лә. Карале, Диләрә, туңгансың ич син. Һай, өстеңдә дә юка икән лә. Әйдәле безгә, малай. Җәтрәк атла, — дип, ул каткан гәүдәмне этә-селкетә башлады.

Кар шыгырдады, йолдызлар салкын нур коеп җемелдәде, айның сипкелле түгәрәк йөзенә болыт итәген сөртте, тик мин боларны аңым белән тоймадым, бу манзара-күренешләр ясап куйгандай күз алдымнан гына шуышып үтте. Гаяннарда кайнар чәй эчеп җылынгач кына нинди фаҗигагә тарыганымны аңладым. Тугани апаның йортын яндырдым! Юк, аны яндырдылар! Кемнәр, йә, кемнәр?! Сарай-абзар түбәсе тулы коры үлән иде. Кәҗә генә асраса да, Мәүлидә карчык ун сыер кышлатырлык печән чапкан…

— Тегеләр төрткән, Диләрә, тегеләр. Бүтән беркемнән дә шикләнмә. Клубтан кайтышлый директор кызы өстергән, — диде Гаян, уйларымны күзләремнән укып. — Апа, апа, итенсәләр дә, синнән көнләшә ич алар. Кһым, үпкәләмә, зинһар. Равил Сәйдәшевичның сиңа сокланып караганын әллә ничә күргәннәрдер инде. Хәзерге яшьләр үчле, кызгану дигән хис юк аларда.

— Җүләр сатма, Гаян! Беренчедән, без Равил белән хезмәттәшләр, икенчедән… — Йа Ходай, ник акланам мин?! — … өй хәтле өйгә ут төртергә кызларның кулы бармас иде.

— Һи, бармас ди! Синдә Равил куна дигәннәрдер. Урамга ялангач кудырып адәм рисвае ясыйк дигәннәрдер.

— Миндә беркем дә кунмады. — Борынымны төтен исе сеңгән җиң очына төрттем. Шунда гына абайладым: тугани апаның җәйге пәлтәсен кидергән Равил. — Ишетәсеңме, Гаян, кунмады! Шулай утырган килеш кенә сездә таң аттырсам, эти-әниеңә комачауламам микән?

— Алар алгы якта йоклый ич. Хәзер сиңа да урын җәям.

Әлеге фаҗигадән умарта оясыдай гөжләгән башыма йокы керсә, мин тинтәк булыр идем. Иртәгәсен Гаяннан кышкы киемнәр сорадым.

— Син кая җыендың? — диде ул. — Мәктәпкә иртә әле.

— Казанга, әйберләреңне посылка белән салырмын, Гаян.

— Казанга?!

— Әйе. Бөтенләйгә.

— Абау, мәктәп белән хушлашмыйсыңмы?

— Юк…

— Абау! Мин нәрсә диим икән? Абау, һич көтмәгәндә бит! Мә, иске тунымны ки, муеныңа иске шарфымны чолма. Казанга еш йөрелә, адресыңны шушы кәгазь кисәгенә сызгала әле, юл хуты үзем сугылырмын.

Тугани апаның йортын яндырган бәгырьсез авылга үпкәләп киттем мин. Кинәт кенә җаным каралды, дөньям каралды. Тик Равилнең генә исеме кар кебек ак иде…

**5**

— Ят инде, Алла колы! Төнката тәрәзәдән кемне күзлисең, ә? — Зәрия күзләрен уа-уа аш бүлмәсенә чыкты. — Ул Карасу дигәннәре бер дә килешмәде сиңа. Тып итеп кинәт кенә кайтып кердең. Әйттек без, авыл сиңа төс түгел, дидек. Син шәһәр кызы ласа! Әле мин авылда тусам да, анда

мәңге аяк басмас идем. Балачакта потлы чиләкләре белән чишмәдән су ташытып, олау-олау печән өйдертеп бөкрәйтте авыл. Ә сине нишләтте инде ул?

«Күрәчәгем белән очраштырды. Күрәчәгем белән… Мин һаман тәнемдә аның кул җылысын тоям — бусы кыска гына бәхетем. Тугани апаның нигезендә көл өеме — бусы озын-озын хәсрәтем».

— Әллә нинди бөек кеше син, Диләрә. Фатирыңда тагын ун-унбиш көн яшәсәм ачуланмассың микән?

— Яшә.

— Мин бит әле, сердәш, бай гына ир каптырдым. Банкрот завод директоры. Банкларда акчасы тау-тау аның, тулы бер заводны чишендергән ләса. Бикәсе белән концертыма килә, ди. Хе-хе!

Зәрия сөяркәләрен гел хатыннары белән чакыра иде. Хәйләкәр иде ул, буаны гел үзенә табан ерды. Ир, билгеле, ирексездән ике хатынны бер-берсе белән чагыштыра. Өйдәгесе сәләмә халаттан, үкчәсе тапталган иске чүәктән, ә сәхнәдә курчак кебек ясанган-бизәнгән чибәр…

Миңа Зәриянең бу гадәте ошамый иде. Әмма нишләтим, күрше белән дус — Ходайдан, диләр.

Зәрия саескан иде, сердәшләремнең һәрберсенә «кайтты» дип чыркылдады. Тик мин генә болыт сарган күк йөзедәй күңелсез. Равил шылтыратмады. Югыйсә телефонга карап күзләрем күгәрә иде. Тәүлек буе — көнен дә, төнен дә — мин аңардан: «Исәнме, Диләрәм?!» — дигән сүз көттем. Аның назларын хәтеремдә яңарта-яңарта саташып беттем. Мин, бәлки, мәхәббәт газабында туктаусыз өтеләтөтелә юләрләнер дә идем, сизгер Гөлсирә, ай-ваема карамыйча, Мәсликнең яңа танышларына әйдәкләде.

— Әзрәк җилдә җилләнерсең. Мунчада себерке белән чабынып, хәсрәтле уйларыңны кудыртырсың, — диде. — Хуҗасы белән таныш димим, танышма. Без әле ул кешенең үзен дә ярты еллап кына беләбез. Мәслик, шәп егет, дия анысы. Элек атлар тәрбияләгәнен әйткән идем бугай. Син чүт кенә язып, алайса, керпе сыман бөтәрләнгәнсең, нервыларыңа суккан, ахрысы, — диде.

Бауга бәйләгән бозау шикелле, теләр-теләмәс кенә дусларыма тагылдым. Без бистәдән ике катлы йорт турысына килеп туктадык. Капка шар ачык иде. Мәслик белән Гөлсирә машина әрҗәсендәге күчтәнәчләрне өйгә ташырга керештеләр, ә мин, телефон элемтәсе эзләп, киң ишегалдында чабулап йөрдем. Әгәр Равил шылтыратса? Ә монда телефон тоташмаса? Йа Ходаем, ник мин үз фатирымда гына утырмыйм икән?! Горурлыгымны изеп-таптап үзем төймәләргә бассам, ә? Үзем, Галәмне сискәндереп: «Сагындым!» — дисәм?

Абзар буенда кемдер шык та шык утын ваклый иде. Мөгаен, хуҗадыр. Борынга мунча исе бәрелде. Нәкъ авылдагы төсле төтене татлы әчкелтем икән…

— Әй, абзый! Монда кесә телефоны кай тирәдәрәк тота икән?

Әйләнеп абзар артына чыктым.

— Өйдән шылтыратыгыз, Гөлсирә, өйдән. Мин хәзер мунчага бер-ике пүлән өстим дә сезнең карамакта булам.

— Гөлсирә өйдә, абзый.

Ир бөгелгән җиреннән тураеп басты. Кинәт аның кулындагы балтасы аяк очына шуды. Ул миңа текәлгән дә шаккаткан иде. Әйтерсең аның алдына күктән нииндидер җан иясе егылып төште. Маңгаена ук батырылган бүрек астында елтыраган күзләрдә нәрсәдәндер шөлләү дә, нәрсәгәдер сөенү дә бар иде.

— Исәнме... сез, Диләрә?! Сез бер дә үзгәрмәгәнсез.

— Ә син... ә сез кем?

Мин ялгыша идем, әлбәттә, ялгыша идем. Бу Илдус түгел, аңарда нибарысы Илдус чалымнары гына шәйләнә иде. Менә хәзер ул бөтенләй бүтән исем әйтәчәк.

— Мин Илдус идем, Диләрә. Карасу егетен хәтерлисезме?

— Юк! — Тавышымда тимер бәрелеп чыңлады. — Сездә элемтә начар икән.

— Ә сез өйдәге телефоннан шылтыратыгыз. Димәк, сез Гөлсирәләрнең дусты инде…

— Юк, мин сезне хәтерләмим! — Эчемдәге явыз җанвар тырный-тешли иде. — Америка белән хәбәрләшәсе иде миңа.

Монысы Илдусны да, үземне дә үртәү иде.

— Рәхим итегез, хет Җир шарының иң соңгы ноктасындагы утрау белән сөйләшегез, Диләрә.

— Рәхмәт, мин шундый утрауларның берсеннән котылдым гына әле, — дидем.

Абзарда ат пошкырган кебек ишетелде. Каядыр соңлагандай, ашыга-ашыга өйгә кердем. Зур залда Гөлсирә белән ире табын хәстәрлиләр иде.

— Син сурәтләр генә кара, без үзебез кыймылдыйбыз, — диде сердәшем һәм итәгемә альбомнар китереп салды. — Кара, кара, Илдус дөньяның кайсы гына кыйтгасында сәяхәт итмәгән. Америкада, Япониядә, Африкада, Франциядә, Италиядә. Бөтен илләрдәге ат ярышларында катнашкан егетебез.

Иңнәренә канатлар тегеп, җиде кат болытлардан очса да, минем өчен Илдус Карасудан гап-гади ат караучысы гына иде.

— Ул — оста балыкчы, — диде Мәслих, көлемсерәп. — Казансу елгасында таныштык без аның белән. Бәке тишкәндә. Кармак белән балыкны шәп эләктерә Илдус, ә хатын-кыз мәсьәләсендә йомшаграк менә. Карт буйдакны үзебез димләп өйләндерсәк кенә инде, әйеме, Гөлсирә иркәм?

Мин, йөрәгемнән кан тамыза-тамыза, энә өстендә бии идем. Мәслихнең төрттерүләре ярамны тагын да тирәнәйтә иде. Ник дәшмисең, Равил?! Карга бата-чума арт бакчадан гына качырганда, йөрәгеңне сакла, дидең. Син бу әрнү-газапларны үзең өстәп торганда, мин ничек йөрәгемә дәва табыйм соң?!

Альбомнарны аннан-моннан гына актардым, чөнки сурәтләрдә гамем юк иде. Хуҗа ачык кеше иде, ул күгәрчендәй гөрли-гөрли дуслары белән исәнләште.

— Мунча нәкъ сез кушкан сәгатькә җитеште, — диде ул, миңа күз сирпеп. Бүрек-фуфайкасын салгач, ир бетереп Илдус иде.

Гөлсирә:

— Танышыгыз, Диләрә, — дигәч, хуҗа, кулын йөрәгенә куеп, мине сәламләде. Абзар артындагы хәл-тамаша гүя булмаган иде.

— Мунчаның иң эссесе — кызларга! — диде Мәслих. — Чибәркәйләр, без сез чыгышка мәтрүшкәле чәй пешерербез, мичтә бәрәңге тәгәрәтербез. Сез ризамы?

Мин кыстатмадым, минем тизрәк Илдус күзеннән югаласым килә иде. Никләр, Ходаем, шулай соң бу?! Син теләмәгәннәр чәчрәп каршыңа чыга, ә син теләгәннәр йөзен яшерә.

Ләүкәдәге агач ләгәндә ике төрле себерке пешекләнгән иде.

— И, күр инде, ир-ат кына димәссең, бөтен төштә чисталык бу Илдусның. Сап-сары идәннәре, утыргычлары. И, шуңа акыллы гына бер хатын…

— …мине димләмә, яме! — Тизрәк Гөлсирәне бүлдердем. — Миңа ир кирәкми!

Ахирәтләрем арасында Гөлсирә иң төплесе иде, ул Зәрия сыман җанымда казынмады, имән себеркесен кайнар суга манып, кызу таш өстендә селкеде дә:

— Эсседә изрә, — диде. — Миче утын белән ягыла, сулышка җиңел. Хәер, син коры парның рәхәтен беләсең инде, тугани апаңның да мунчасы шәп.

Битемә себерке каплап елап җибәрдем. Эчемә тулган хәсрәт таштай катырса да, күз яшьләрем бозланмаган иде.

— Мунча да юк, өй дә юк, ул да юк. Мин гөнаһлы, Гөлсирә. Яраттым мин... Яшь бит ул егет, бик яшь. Акылымны җуйдым, ахрысы, юкса күрәләтә җанымны утта көйдермәс идем. Кемдер, безгә үчегеп, тугани апаның йортын яндырды. Күрмиләр-сизмиләр, дигән идем, серем җиде сандык төбендә, дигән идем. Баксаң, серне җил себерә. Мәхәббәтем гөнаһлы, шуңа ул тиз беленде.

Сердәшем кранны ябарга онытты. Кайнар су аяк табанын пешереп ага да ага иде. Гөлсирә, кулымдагы себеркене йолкып алып, мине чабарга тотынды:

— Мә сиңа! Мә сиңа! Мәхәббәттә нинди гөнаһ ди ул тагы! Яратасың икән — сөен! Димәк, син — тере, димәк, синдә җан бар! — Ахырдан Гөлсирә өстемә салкын су бөркеде. — Ой, Илдусның су савытын шартлатабыз, кран борылмаган!

— Рәхмәт, син дә миңа кушылып еларсың дигән идем.

— Ә син елама! Билгеле, йорт кызганыч.

— Ул шылтыратмый...

— Чынлап яратса шылтыратыр.

— Син «сак бул» дип кисәткән идең.

— Соң?

— Әй, нәрсә мин синең башыңны бутыйм әле! Үзең дә чабын.

— Кайсыбыз яратмаган да, кайсыбыз җан тартканыннан өзелмәгән, Диләрә. Син «сак бул» диюдән узган инде. «Нык бул» диясе кала хәзер.

— Илдус Карасудан бит, Гөлсирә.

— Әйтәм аны, бер-берегезгә сәер генә карашасыз.

— Ул яшь чагында, кунак кызы дип, мине клубтан озата иде.

— Ә-ә, имәндә икән чикләвек! Илдус идәнгә бер басасын өч баса шул.

— Мин аны яратмыйм!

— Яратма, зинһар. Сез бүген очраклы гына күрештегез. Мәслих тә, мин дә сезне танышлар дип һич уйламадык. Язмышның бер хикмәте инде бу. Илдус туган авылында, димәк ки, Карасуда йорт сала, ди. Китсә, коттеджын безгә сатачак. Шәһәр туйдырды, цивилизациядән качып читтәрәк яшисе иде.

«Карасуда йорт сала... Йорт сала... Нинди бәхетле кеше».

Мунчадан соң берникадәр йомшардым бугай, Илдуска дустанә елмайдым. Әйе, ул булдыклы ир, көнкүреше төзек-камил иде. Ә бүтән ягы мине чеметем генә дә кызыксындырмады. «Язмышның бер хикмәте шушы очрашу белән төгәлләнергә тиеш иде. Йөрәген башка кеше биләсә, хатын-кыз, «эһ» тә дими, теләсә кайсы ирнең өметенә балта чаба. Мин дә уем белән Илдусның өметләрен кистем-туракладым. Хушлашканда нигәдер аңа карадым. Юк, юк, бу ир яшьлектәге юаш, кыюсыз егет түгел

иде, бүтән иде, бүтән иде ул! Карашында горур бөркет канат җилпи. «Яратсаң, аягыма егыл», — дисәм, Илдус, мөгаен, кычкырып көләр иде. Ә күзләре барыбер моңсу, моңа, әлбәттә, мин генә гаепле идем.

Фатирда миңа сюрприз әзерләнгән иде. Зәрия, роза чәчәкләре кочаклап, зыр-зыр бүлмә уртасында әйләнде:

— Котлыйм, җегет һуштан яздырыр дәрәҗәдә чибәр. Сине өч сәгать зарыгып көтте.

— Кем?! Равилме?!

— Миннән яшергән идең дә, су төбеннән үзе калыкты әнә.

— Кайда ул?!

— Кайда, кайда, имеш? Айда! Үпкәләдем әле мин сиңа, кызый. Авылда яшь кенә егет белән типтердем, димәдең шунда. Гомер бакый сәер инде син. Йә, йә, кәефсезләнмә, иртәгә тагын сугылам, диде.

Иртәгә хәтле ерак иде. «Ник мунчага бардым икән?» — дип, үз-үземне мең кисәккә өзгәләдем. Төнем шик-шөбһәләр белән буталды. «Никах укытып кушылыйк та, үзеңне рәнҗеткән Карасуга кире кайт», — дисә, нишләрмен? «Нишләрмен?» дип ник өтәләнәм икән?! Мәхәббәте хакына җир читенә китәчәк хатын ла мин!

Әмма егет: «Әйдә, авылга», — дип, миңа ташланмады. Кичә генә «Яратам!» дигән кеше минем белән салкын гына күреште. Һәм яныбызда торган Зәриядән дә уңайсызланмыйча, теле белән камчыларга кереште:

— Нишләп шыпан-шыпан Карасудан качтың?! Бала-чага төсле теге. Син җитди хатын түгел икән. Син эгоист икән! Кемгә үпкәләдең инде, җә? Электр чыбыгы иске, шуннан бүрәнәгә ут капкан. Кайсыбыз гаепле моңа?

— Ә син нишләп шылтыратмадың?

— Ха! Качкыннарга нинди шылтырату ул! Минем сиңа хөрмәтем кимеде, ханым.

— Әй, иптәш! — Зәрия озын буйлы Равилгә үрелеп-үрелеп йодрык селкеде. — Кем соң син шулхәтле, ә? Баядан бирле әтәчләнәсең, кара мыегым. Синдәй дорфа ирләрне без көнбагыш кабыгы кебек пуфылдатып төкерәбез. Бел, яме! Мин урамда һава сулыйм, талашмагыз, тыныч кына чүкердәшегез.

Егет бер кызарды, бер агарды.

— Гафу ит, Диләрә. Нервылар тузган. Чәй эчерәсеңме?

— Түрдән уз, — дидем.

Мөнәсәбәтләр яңадан көйләнсә дә, элеккеге эчкерсезлек үлгән иде. Нәрсәдер кителде… Нәрсәдер… Мин Равилдән: «Хәзер авылга кайтабыз», — дигән сүз көттем. Ә ул тузга язмаган мәзәкләр сөйләп вакыт уздырды, үзе әледән-әле беләгендәге сәгатен капшады.

— Синең бу усал өйдәшең өстебезгә кайтып кермәс бит инде, баг алмасы. Караватың киң, кил, чүт кенә ял итик, — дип, ул мине билемнән кочакламакчы иде, тәнем тартышып, читкә сикердем.

— Кагылма!

— Нишлисең син, Диләрә?! Сагынмадыңмыни?!

— Кайчан никах укытабыз, Равил? Урам аркылы мәчет...

— Никах? Ниемә соң ул? Без бит болай да бергә. Карасуны җенең сөймәсә, атна саен Казанга килермен. Машина кулда. Фатирың иркен.

— Мин Карасуны яратам, яратам, яратам! — Миңа әллә нәрсә булды: күңелем ташып тулды, йөрәгем даң-доң какты, ике күземнән мөлдер-мөлдер яшь акты. — Күлмәгеңнең төймәләрен каптыр… Чишенмә… Бар, кит! Мин Карасуны яратам. Кит, дим!

— Кич бит инде. Төнгә каршы җүнле хуҗа этен дә кумый. Үкенмәссеңме, баг алмасы?

— Әйтмә миңа баг алмасы дип. Әйтмә! — Сүзләрем теш арасында сытылды.

— Миндәй егетләр Казан урамында бер сызгырса, ун хатын муенга ябыша. Шуңа күрә үкенмәсәң генә ку син, әй, кем, Диләрә апасы. Йә, хуш иттек!

Казан урамындагы хатыннар төркемендә Диләрә исемле кеше юк иде шул. Мин — ялгыз горур, яраларым учлап, читтә тора идем.

Җитмәсә, Зәрия дә авырттырып җаныма кагылды:

— Ишек төбендә күрше подъезддагы Зина белән бакылдашканда, синең бу яшь нәстәкәең атылабәрелә чыкты. Зинаны үзең беләсең, һәр чибәр иргә сагыз күек сылана. «Какой ты милый», — дип, шундук моңа сарылды. Озак кеткелдәштеләр кызыл машинага сөялешеп. Иманым камил, төнгә кавыша болар. Дөресен әйткәнгә үпкәләмә, ул җегет бик мут, ахрысы. Мин бит ирләр мәсьәләсендә тәҗрибәле хатын, кешене кешедән аерам. Нәрсә, кара мыекка каты бәрелдең мәллә? Ирләр бүген дефицит, шуны онытма син. «Свиданҗа куйдыгызмы?» — дип, Зинадан сорыйммы соң, сердәш?

— Сорама.

— Мәйлең. Алайса, җегетең өчен сугыш. Яу кырында үзара кыйнашып җиңгән хатын-кыз гына ирен саклый ала. Җиңнәреңне сызган, сердәшкәем! Алга, изге көрәшкә!

Кемдер кыюсыз гына ишек шакыды. Равил! Баягысы төштәге Равил иде, бусы — чын. Әйе, әйе, мин төш күрәм, теге ямьсез сүзләр, ямьсез күренешләр төштә генә кабатлана иде. Менә хәзер егет керә дә: «Җыен, Диләрә! Без авылга кайтабыз», — ди. Ник «юк» дидем соң әле мин: яз белән көз уртасында өр-яңа фасыл бар, ул — мәхәббәт чоры. Әйдә, бәхет өч кенә көнгә, өч кенә айга, өч кенә елга сузылсын, шушы кыска гына мизгелдә бер-береңне сөеп-сөелеп яшәүләргә ни җитә!

Тиз-тиз генә кызарган күз кабакларыма пудра тидердем.

— Үзем каршылыйм, — диде Зәрия.

— Исәнмесез, апа?! Диләрәләр фатирымы?

— Син кем, кызый?

— Гаян мин. Карасудан.

— Бүген карасулар көне бугай, — дип сукранды Зәрия.

Әле генә «Равил» дип очынган күңелемнең сыкрануын басарга тырышып, Гаян белән исәнләштем.

— Тунын юллап йөри димә, Диләрә Әсәдулловна, — диде ул, башын аска иеп. — Илче мин. Директор, кайтсын, ди. Авылда хуҗасыз йортлар күп, ди. Әнә Сәрбиназ әбекәй дә ызбасын сиңа яздыра икән. Балалар сагына сине...

Сәер, Гаян бик боек иде. Башка чакта теле телгә йокмаган кызның берәр шөребе бушаган мәллә?

— Тугани апамның йортын яндырган кызларны ничек укытыйм мин, Гаян!

— Каргыйсыңдыр, иеме?

— Мәүлидә апа: «Әшәкелек кылганнарга Аллаһ хөкемдар», — дия иде.

— Шулайдыр, ие. Диләрә, синнән соң мин зерә авырдым. Йөрәк өянәге белән… Өч көн тоташ. Мәүлидә әбекәй буды…

Без Зәрия белән бер-беребезгә карашып алдык.

— Әй, кызый, синең тән температураң югары, ахрысы. Шәһәрдә грипп, — диде ахирәтем.

— …бармаклары шыр сөяк иде Мәүлидә әбекәйнең. Үзе пыш-пыш ләгънәт укый… Аның кабердәге бәддогасыннан беркем дә котылалмый, ди әнкәй. Үтерә-ә-ә ул! Син гаепле, Диләрә. Син минем юлыма аркылы төштең. Минем өмет Равилдә иде. Сез аның белән беренче көннәрдә үк иснәштегез. Суфия апасын мин китерттем урманга, энең карт хатын белән себерелә, дидем. Аннан соң сезнең арада берни дә юк кебек иде. Ә беркөнне тау астында әүмәкләшә-әүмәкләшә үбештегез. Теге төндә дә Равил белән кундыгы-ы-ыз… Артыгыздан күзәтте-ем… Мин яндырдым өегезне-е-е, мин…

— Аһ, кабахәт! — Зәрия мәче җитезлеге белән Гаянның чәченә тырнак батырды. — Каз түшкәсе йолкыгандай йолкыйм мин сине, тәмуг кисәве! Син аларга ник тыкшынасың?! Көнләштеңмени, кәкре таяк?! Һәр көнләшкән хатын йорт кадәр йортка ут төртсә, авыл-шәһәрләр өч көндә янып бетә безнең!

— Җибәр, Зәрия.

Сердәшемне көчкә Гаяннан аердым.

— Мәүлидә әбекәйнең өрәге мине барыбер буып үтерә-ә, — дип үкерде кыз. — Кичер, Диләрә, кичер, зинһар!

…Дивардагы сәгать туктаган иде. Фатирны җанландырып чың-чың суга иде ул. Хәрәкәтсез оеган угы кыл минем яралы йөрәгем турысында кадалган сыман. Урыныннан кузгалса, вакыт алга тәгәрәр иде… Йөрәккә дә җиңеләер иде… Сәгатьне борсам, тавышка Гаян уяныр. Үлән төнәтмәләре эчереп, аны көчкә тынычландырдым. Кыз, «буылам» дип, идәндә ауный-ауный елады. Һәрбер хатын-кыз — яшьме ул, картмы — яратуга мохтаҗ. Ә мәхәббәт җаннарны йә агарта, йә каралта…

**6**

— Уян инде, йокы чүлмәге! — Зәрия мине, караватымнан торгызып, балконга табан этәрде. — Тегеләрне тәки сагаладым, сердәш. Зина чибәр ирләрне әрәм яткыра димени! Башыңны тәрәзәдән тыгып аска кара әле. Синеке күрше подъездан чыгып бара. Форсаттан файдаланган кара мыек. Угры төсле ялт-йолт тирә-ягына карана үзе.

Зәриянең кулыннан ычкынып балкон ишегенә сөялдем. Йа Ходай, ник бу таң атты икән? Ник мин кара төннәрдә генә батып калмадым икән?

— Әшәке син, Зәрия… Әшәке-е…

— Мин сине коткарам, тиле! Ике кырда ике куян куган ир сәләмәсе нәстәмә сиңа?! Курыкма, Зинага байлар кирәк, укытучының хезмәт хакы гына аз аңа. Ул, күрәсең, моның кесәсен угалаган да, «хәерче икән» дип, әче таңнан артына типкән. Хәзер сөеклең базардан кызыл розалар алып сиңа йөгерәчәк.

— Барыбер син әшәке-е…

Һәр ыңгырашкан саен бәгырь җепселләрем шартлап өзелә иде.

— Ну җегетнең дә авызы пеште. Курыкма, дим, сиңа өйләнәм, диячәк ул менә. Шулай ниятләде инде кара мыек. Аннары гомер буе өстеңнән чабачак. Һи, җанкаем, миңа болар күптән мәгълүм инде. Зәрия апагыз бүген ир-ат холкы буенча Казанда иң зур белгеч.

— Ишекне ачма…

— Мәйлең. Ахырдан терсәгеңне тешләмә. Гашыйк хатын-кыз зерә куркыныч зат бит әле ул. Андый-мондый җүләрлек эшләмә тагы.

— Гаян кайда?

— Иртүк авылына тайды. Беренче автобуска өлгерим, ди. Йортыңның көлен күккә очырган имансызны нишләп гафу иттең син? Бәясен түлә, дияргә иде.

…Ярты сәгатьтән кыңгырау төймәсе чыңлады. «Ач! — диде йөрәк. — Ач, син өч көнлек бәхеткә дә риза идең, әнә ул — бусага төбендә. Минеке бул», — дип, аягыңа ятып ялварачак.

«Ачма! — диде акыл. — Ачма, син горур хатын идең, шул килеш кал».

Кыңгырау чыңы дөбердәтү-шаку белән чиратлашты.

— Диләрә, ник дәшмисең?! Диләрә-ә-ә!

Егетнең илерүе, мөгаен, бөтен подъездга яңгырый иде. Менә кесә телефоным көй уйнарга тотынды. Озак дөбердәтте, озак шакыды, озак шылтыратты Равил. Берзаман дөньяны тынлык басты.

— Китте, — диде посып кына балконнан күзәткән Зәрия. — Җегеткәй яртылаш бөкрәйгән. Иртән зерә туры иде гәүдәсе. Казан хатыннары белән шаярма инде син, кара мыек. Алар бәрәңге генә ашап үсмәгән.

Миңа алга табан да яшәргә, яшәргә иде… Башта сәгатькә «җан» өрдем. Гомеремнең шушы өлешен, зинһар, чаптыртып кына үт, вакыт хисапчысы.

Кышкы киемнәремнең барысы да Карасуда янды, мин шыр ялангач идем. Бәлки, тормышны кибетләрдән башларгадыр? Үзе бер юаныч, үзе бер онытылу… Хәер, кем өчен киенәм инде мин? Кайсы гына ялгыз хатын-кыз шулай уйламыйдыр. Әмма минем өчен Гөлсирә хәл иткән икән инде. Ул: «Кибетләр әйләнәбез, җыен», — дип шылтыраткач, аның әмеренә буйсынып, студент елларында тектергән иске пәлтәмне шкафтан тартып чыгардым. Бусы да ярар иде дә… Кем өчен киенергә соң, йә?! Йорт белән бергә минем күңелдә дә көл бураны тузгый түгелмени?!

Ишекне ачсам… идәндә роза чәчәкләре бәйләме. Берсенең таҗына кәгазь кисәге кыстырылган. «Сине югалтасым килми, Диләрәм. Хәбәр бир! Равилең». Укыдым да, тагын күзем яшьләнде. Минем дә югалтасым килмәгән иде. Килмәгән иде! Ә син, егет, югалдың, югалдың, югалдың… И тәкъдир, мондый әрнүләргә ничек чыдамак кирәк?!

…Юл читендә Гөлсирә кул болгый иде.

— Диләрә-ә!

Учыма йомарлаган кәгазьне, вак-вак кисәкләргә ертып, чүп савытына ташладым.

— Диләрә, нихәл?! Мәслихнең машинасы ватылды, бүген безне Илдус йөртә, — диде сердәшем. — Абау, син нигә күңелсез?

— Матур әйберләргә акчам җитәр микән дип борчылам.

— Спонсорың — Илдус. Ул бик бай кеше. — Гөлсирә, алдашуымны сизсә дә, уенга борды.

Ир, машинасыннан төшеп, миңа кулын сузды.

— Исәнме… сез, Диләрә?

Ул яланбаш иде, чәче ап-ак иде. Әле генә акылларым китеп яраткан кешемнең исә чәчләре дә кара, куллары да кайнар иде… Йа Ходаем, ник мин аларны чагыштырам икән?!

— Кайсы кибеттән башлыйбыз, кызлар? — диде Илдус.

— Үзәк универмагтан, — дидем, чөнки ул якын иде. Нигәдер чигәм кысып, тыным буылды. Гүя Гаянның каһәр чире миңа да йоккан. Шәһәрдәге ыгы-зыгы, тәртипсез хәрәкәт, тызбыз чабышкан ят кешеләр миемне кайната иде. Кичер, Казаным, синнән биздем бугай. Сулык-сулык әрнегән җаным, тән кабыгыннан кубып, рәнҗеткән-елаткан Карасуына очмак була. Анда җил дә йомшак, болытлар да ак, йолдызлар да эре… Анда… Юк, бу исемне мин хәтердән сыздым. Югалды ла ул, югалды!

Сатучы кыз туннар сайлаганда, Гөлсирә:

— Мәслихнең машинасы ватык диюем ялган. Син акчам җитәр микән дигән төсле инде. Илдус бит… Соңгы мәртәбә Диләрәгә багыйм инде, ди. Шуны оныталмыйча үләрмен, ахрысы, ди. Китә данлыклы ат караучы…

— Кая?!

— Карасуына. Йорт төзеттерергә урын караштырам, ди. Төп нигезләрендә читләр икән.

— Әнә тугани апаның бакчасында салсын. Миннән рөхсәт.

— Әйт шулай дип. Илдус гаҗәеп җайлы кеше. Аның бер генә сәерлеге аптырата, ди Мәслих. Гомере буе кемгәдер бүләккә дип бала кебек тәрбияләп нәселле акбүз ат асраган, ди.

— Әкият! Алайса, нишләп шул бүләк иясен эзләмәгән ул?

— Буе җитмәгәндер, тегесе бит айда кунаклаган, ди. Аның кем икәнен үзең дә беләсеңдер, тәкәббер кыз!

Туннарны, «килешми» дип, сатучының кочагына томырдым. Җир шарын аркылыга-буйга гизгән ир, күккә җиде баскыч терәп, айдагы тәкәббер янына менәргә тиеш иде. Мөгаен, агачтан чокылган

акбүз ат абзар нүешендә череп ятадыр. «Бүләкне үзең эзләп килерсең, кызый», — дип язмышлар юраган әүлиядән тагын ни көтәсең. Матур әкият, билгеле.

«Башым авырта» сылтавы белән фатирыма кайтып аудым. Җанда зилзилә купкан иде. Ирләр шундый төрле-төрле микәнни соң? Берсе «яратам» дия-дия хыянәт итә, ә икенчесе, яшьлектәге хыялына тугрылык саклап, ялгыз картая…

Кич белән автобус мине бистәгә илтеп куйды. Ике катлы таныш йортның эчендә-тышында утлар гөлтләгән: ишегалдына энә төшсә, ялтырап күренә иде. Әкрен генә абзарга атладым. Күңел һаман әкияткә ышанмый иде. Ә әкиятләр чынбарлыктан да көчлерәк икән. Яп-якты аран уртасында тышауланган акбүз ат басып тора иде. Менә ул муенын бу якка табан борды һәм төсе уңган ялларын тузгытып кешнәп җибәрде. Аның да күзләре, хуҗасыныкы кебек, моңсу иде…

*2006—2007*

## Каракош

Йорт янып бетте. Сүндерә алмадылар. Кыйбладан кузгалган җил котырды да котырды, аның кояш баеганда да тынар исәбе күренми, ул, дәһшәтле сулышын өрә-өрә, күмерле кисәү башларында ут үрләтеп маташа иде.

Рәхимҗан утын түмәренә төртелде дә катып калды. Эче-тышы көйде егетнең, тамырларыннан шаулап аккан каны төерчекләнде, йөрәге туктагандай булды. Өченче йорт... Әйе, өченче йорт көлгә әйләнде. Ир-улакның бер генә йорт салырлык куәте бар, ә Рәхимҗан өчкә нигез казыгы какты, өч урын алмаштырды. Кулыннан балта төшмәде, аның сабы бармакларына берегеп үскән кебек иде. Арыган иде бит инде ул, туйган иде, агач каезлый-каезлый буыннары гарипләнә башлаган иде.

Соңгысын егет урманнар артындагы чит авылда төзеде. Иркенләп-җәелеп төзеде. Ике катлы булып чыкты өе. Авыл халкы шаккатты: искиткеч матур карлыгач оясы иде бу. Ул каралты-кура, ул келәт, ул мунча... Яшәмә, сокланып кына тор! Монысы — мәңгелек, балаларның балаларына калачак байлык дип тырышты шул. Юкка беләген талдырган икән. Ут монда да аны эзләп тапты. Кем аңа үчегә дә, кем төртә икән, ә?! Шул хәсиснең башын өзеп этләргә ташлар иде Рәхимҗан. Әллә яшен сугамы? Ап-аяз көннеме?! Малай-шалай шыртлаткан чыбыркы очыннан чәчрәмидер бит ул алай-болай? Әллә ниме... Теге сүз дөресме? Тфү, чәнчелгере, син дә ир башың белән шуңа ышанып утыр тагы.

...Иң беренче йортын Рәхимҗан иске өйләреннән әз генә читтәрәк салды. Ата нигезе муртайган, идән-сайгаклар череп, түшәм аска бөгелгән иде, яңасына куана-куана күченделәр. Ә дүрт көннән, кышкы зәмһәрир суык төннәрнең берсендә, өйне ут чолмады.

Кече йомышы белән ишегалдында булашкан әнкә карчык комганын ыргытып өйгә йөгереп керде дә:

— Каракош, — диде һәм, һуштан язып, идән уртасына егылды. Аны тышка шул килеш сөйрәп кенә чыгардылар: дөньясын ут чорнаган иде. Алмашка кияргә күлмәк тә эләкмәде хәтта, яну-пешүдән көчкә котылып, бер кат киемнән сәләмә йорт бусагасына кайтып аудылар.

Рәхимҗанның өйләнергә йөргән чагы иде. Кыз соралган, туй көне билгеләнгән, ә монда... хәсрәтнең хәсрәте! Җитмәсә, болай да җиңел-җилпе анасы тәмам исәрләнде, ул, көннәр буе тимер караватта тирбәлә-тирбәлә, авызында күбекләр кайнатып:

— Каракош оча, Каракош ут сала, — дип кабатлап утыра башлады.

Килен төшерер алдыннан гына аның чире көчәеп китү егетнең җелеген киптерде. Кыз, булачак каенанасын бу хәлдә күрсә, ике дә уйламыйча тәртәгә тибәчәк иде.

— Саташыр-саташыр да туктар, — диде атасы. — Һашияләр бакчасында гөжләгән карга тавышы миен бораулый аның. Туктар.

Карт ник кайгырсын, аның дөньясы күптән көйләнгән, алай гынамы, ул шул көйле дөньясының алдына да, артына да тибеп, аласын алган, бирәсен биргән, балда-майда йөзгән, аңа хәзер зират ягына таба караштырырга вакыт җиткән иде. Ә егетнең — кыз-кыркын куркытырлык яшькә үрмәләгән, утызның арт ягына аяк салындырган карт буйдакның — хатын-кыз исе дә иснәгәне юк.

Ул чакта Рәхимҗан ачуын тилемсә анасына түгел, атасына бөркеде. Картны савыттагы май кебек туглады.

— Әнкәне бастыр, — диде. — Көйлә-чөйлә, акылына китер. Бәрия ишетсә, безгә аяк та басмый, бел шуны! Кыз күтенләсен генә, сакалыңнан асам, карун тәре.

— Бәрәкалла, малай, — диде ата, гаҗәпләнеп. — Кыязлыда кыз бетмәс, бүтәне табылыр.

Үтерде, билләһи, үтерде карт шайтанның шушы сүзе! Табылмасын белеп юри шулай нәзек җиргә энә төртә бит ул, Рәхимҗанны кылый, саңгырау, аксак Гөлмия дә ир итмәячәген аңлап, теленнән зәһәр агу сиптерә. Нинди камырдан әвәләгән җан булды соң ул, авылда иң ямьсез дигән кыз да аны — Сибгатулланың бердәнбер малаен сөймәде. Сөйкемсез сөяк булды Рәхимҗан. Әгәр егет клубтан иярә кайтса, чәчби халкы шыпан-шыпан качу ягын карый, ярты сүәм дә озаттырмый иде. Әй кимсенде дә

соң егет! Анықын кисеп ташлаганнар да урынына бармак тегеп куйганнар диярсең. Югыйсә буй дисәң — буй, кыяфәт дисәң — кыяфәт бар, килмәгән җире юк. Әнә кәтәнә генә егетләр-кызлар кочаклап шаяралар. Нишләп Рәхимҗанны өнәмиләр, нишләп аңардан җирәнәләр, ә? Бу сорау ашаганда да, йоклаганда да, эшләгәндә дә күңелне тырный иде. Нишләп, нишләп, нишләп?! Моңа төгәл генә җавап бирсәләр иде. Бәлки, аның теге кара төндә кылган эшен күргәннәрдер? Һәм таралгандыр ул авыл буенча. Юк, юк, аңа шайтан белән ата гына шаһит.

Рәхимҗанны кире какмаган бердәнбер кыз Бәрия иде. Чиләк белән капкач бер-берсенә соң гына юлыктылар. Кыз Рәхимҗан кебекләрдән бодай суктырып, кибән өйгән, сөю өлкәсендә тәҗрибә туплаган кемсә иде. Үзе күрше авыл кибетендә сату-алу итте. Гайбәтен йөз авыз ирештерде, хәер, аның белән йоклады, моның белән төн кунды, диделәр. Рәхимҗан ничек өйләнмәс борын сөйрәлчекнең арт сабагын укытсын ди, йә? Шикәр төсле кителергә генә тора лабаса Бәрия, аннан кем әле сиңа кияүгә барам, кочагыңны җәй, дип сырпаланган ди, шул кибетчегә өмет тот та, тишегеңне кысып түз инде туйга кадәр. Туйлар узгач, хатын ясагач, камчы белән биетерсең, егет, моңа гына башың эшләр, шәт.

Ә Бәриянең үзенә күрә бәясе югары иде, ул «мин — кеше калдыгы» дип әз генә дә уңайсызланмады, алдан:

— Йортыгыз — чүплек башы, анда тирескә күмелеп, сасып ятасым юк, яңасын төзе, — дип шарт куйды, аннары, бөтенләй оятсызланып: — Әнкәң зерә авыша, диделәр әле, алай акылын бәрәңге боламыгына кушып ашаса, чыкмыйм сиңа. Тилемсә белән бер куышта яшәргә кем дип уйлыйсың мине! — дип кәҗәләнеп, егетне чүт аяктан екмады.

— Ул үз акылында, Бәрия. Йорттагы бар эшне дә эшли, — дип көчкә ышандырган иде аны Рәхимҗан.

Әнә күр, әнкәсе ниндидер Каракош белән саташа. Бәрия ишетсәме!

— Анаңның телен үзең кис, мин ник аның белән ми черетим, — дип, Сибгатулла карт җиңел генә котылмакчы иде, егет, чынлап та асарга чамалагандай, атасының сакалын учлап тотты, акайган бәбәген маңгаена хәтле тәгәрәтеп менгезеп:

— Түбәсенә төя-төя әнкәне син дивана ясадың, хәзер акылын кайтар, — дип акырды. — Йодрыгыңнан куәт ташыганда кыйный идең син аны, хатыннар белән чапканда нахакка дөмбәсли идең.

Җаена ничек төшкәндер карт, Рәхимҗан күрмәде, ишетмәде, бермәлне Минҗамал карчык Каракошны теленнән җуйды. Егетнең үз эше куәтле, ул картлар янына ашарга гына кайта, куна-төнә яңа йорт нигезе корып ята иде. Бу юлысы ул, кыр өлешенә кереп, теләнә-теләнә, авыл кырыеннан җир алды. Дүрт якта да җил генә уйный, күрше-фәлән юк, тәгәрәп гомер кичер! Кеше белән орынып яшәүдән Алла сакласын! Егет беренче йортының ни сәбәптән януын чамалый иде: күрше Сафия кул сузымы арада гына ич. Карга Һашия кызы ул. Бер аның гына кызымы икән? Моны ни йөрәкле Рәхимҗан да таныргa курка иде. Ихтимал, утны кыз төрткәндер. Җан бирер алдыннан Һашия серен аңа тишкән, мөгаен. Шулай икән, шикләнергә урын калмый: Сафия кулы. Шушы йомыкый гына, чи утыннан кабызган учактагы пыскак ут төсле сүрән генә нәмәстәкәйдә үч алырлык явызлык бар микәнни? Һы, тычкы кабыгы нәзек дип карама син, Рәхимҗан, эченә бак: эчендә Сибгатулла җене утырса, ни хәл итәрсең. Карт хәзер генә мескен бит ул, ә заманында адәм башыннан йөргән аждаһа иде. Хәзер генә мескен, әйе.

Икенче йорт төсе-сыны белән беренчесеннән һич кайтыш түгел, киресенчә, кыр-басуларның бәйсез җиле сеңгәнгәме, зуррак та, калкурак та чыгачак, ярдәмгә чакырган күрше авыл чуашлары бүрәнәләрнең иң эреләрен генә сайлап ташый иде. Туйга дип җыйган шактый акча, әнә шул бүрәнә ярыкларына чумгандай, берәм-берәм югала барды. Төннәрен, ай яктысында, кулы балтадан арынып торган арада, Рәхимҗан чуашларга бурычын түләде: трактор белән аларның җирен сөрде, урманнан утын кайтарышты, тирес түкте. Батрак хәленә төшүенә гарьләнсә дә түзде, йорт, аңа яшәүдән битәр, өйләнеп, ишәер өчен кирәк иде. Аны артында эте-бете Сибгатулланың печкән тәкәсе дип күп үртәде. Күрсәтәчәк ул аларга печкән тәкәне! Ел саен җилбәзәк Бәриягә орлык тәгәрәтеп бала белән өйне тутырачак, әгәр ул, бүтән тапмыйм, дисә, көмәнен алдырырга ниятләсә, эт кебек тугыз айга чылбырга бәйләп куячак. Яратмый Рәхимҗан маңка балаларны, үлеп яратмый, потлары бер тиен, ул моны фәкать үзенең көчле һәм гайрәтле икәнен раслау, ирлеген таныту өчен генә эшләячәк.

Шуларны төптән уйлагач, чуашларга бил бөгүнең гарьлеге кими, бәгырьне кискәләп интектерми башлый, карт егет яңа дәрт, яңа көч белән балтасына ябыша иде.

Тәүлегенә ике-өч кенә сәгать йоклап, каты-коты гына кимереп өлгерткән бу йорт Рәхимҗанга никтер аеруча якын иде. Аның әчесе бавырга ук тамды шул. Учны кытыклаган туй акчалары очты, кесәләр саекты, егет үзе дә шыр сөяккә калды. Тәндә чыкмас җан да, өстә, карачкыга элгәннәр диярсең, җилфер-җилфер килгән күлмәк кенә. Хет ела, хет көл, абзый. Атасының яшереп кенә җыйган акчасы бар, менә ул әйләнешкә кереп китмәде әле, менә ул күңелне әз-мәз җылытып, өмет учагын сүндермичә тота. Карт шайтан аны былтырның былтырында ук чүлмәккә тутырып нигез төбенә күмде. Өйләнгәндә бирмим итенмәс. Рәхимҗанның җиде тиресе салынганын күрде бит, хәрам малын мәете белән бергә каберенә илтеп салдырмас.

Яңа йортка күчеп атна-ун көн яшәгәч, шушы акча «ике тәкә»не бик каты сөзештерде.

— Атай, — диде карт егет, — туй турында уйларга кирәк.

— Уйла, уйла, син өйләнәсе кана, — диде Сибгатулла, сүзнең кайсы тыкрыкка борыласын алдан ук сизгән төсле.

— Ник мин генә уйларга тиеш әле! Син соң, син?! Тиененә кадәр йортка тыктым, хет кесәмне әйләндереп капла. Давай теге яшергән сәмәннәреңне.

— Тыксаң, үз тишегеңә тыктың. Анаң белән безнең гумергә иске йорт та җитә иде. Картларның садака акчасына борыныңны сузма, оял, малай.

— Садака акчасы?! Ну, карт мөртәтнең мөртәте дә бит син, Сибгатулла! Урлап җыйган колхоз акчасы, диң! Әллә мине аңгыра сарыкка чутлыйсыңмы? Син бүредән туган бүре баласы мин. Иртәгә чүлмәк өстәлдә булсын, тиз казып ал!

Сибгатулла карт байлыгы белән хушлашырга өлгермәде, «тәкәләр» мөгез сындыра-сындыра сөзешкән төндә, күк гөмбәзенә очкыннар чәчрәтә-чәчрәтә, яңа йорт янып бетте... Капыл янды. Әйтерсең кемдер өйнең нүеше саен шырпы сызып ташлаган иде. Тикшерүче өч көн авылда буталды, сорады, төпченде, ләкин «син» дип бармак төртерлек бер генә гаепле кешене дә тапмады. Әгәр Сафия кала шифаханәсендә дәваланып ятмаса, Рәхимҗан барысын да аңа сылтаячак иде. Бәхете, авырып котылды.

Тикшерүче:

— Кемнән шикләнәсез? — дип сорагач, хуҗа уфырып башын гына иде.

Кемнән, кемнән, имеш. Ут төртүченең исемен белсә, син хәчтерүшкә эш чыгарып та тормас иде Рәхимҗан, үзе хөкем итәр иде...

Аның каравы анасы шашып-шашып кычкырды:

— Каракош ут сала, Каракош, балалар, сакланыгыз, саклан!

Карчыкның кулын бутый-бутый кычкыруыннан уңайсызланган егет:

— Безнең әнкә тәмам акылга җиңеләйде, аны тыңлый күрмәгез, — диде.

Ни дәлил, ни шаһит юк иде, эш шуның белән йомылды. Анасы кебек Рәхимҗанга да ычкынырга гына калды. Җитмәсә, янган йөрәкне яндырып, Бәрия мыгырдый:

— Мин сезнең ул черегән тавык кетәклегенә бармыйм, атаң белән анаңның аяк очында йоклыйсым килми, — ди.

Анысы дөрес инде: иске өйдә тар, кысан, җайсыз. Өч кеше сыйса, дүртенчесенә тәрәзәдән генә башын тыгып торырлык. Нәрсә карагандыр яшь чагында карун ата, ник бер юньлерәк йорт бөтәйтмәгәндер. Акча дип кадалган ул, акча дип! Каберенә җыя бугай. Тәмуг капкасыннан керткәндә ярты тиен дә түләттермиләр югыйсә, бушлай тиресен туныйлар.

Күзенә ул-бу күренмичә йөргән көннәрнең берсендә өй салышкан чепи күзле чуаш агае, егетне туктатып:

— Бу аулда синга тупрак ут өрәдер, тупрак ялкыныннан нигезең өтеләдер, китеп читтә сал, шәт, унгарсын, — диде.

Рәхимҗан чуаштан көлде.

— Ырым-шырымнарыңны эпиеңә кушып аша, абзыкай, миңа атай өчен үчегәләр, ул бит заманында блач иде, Кыязлыны камчы белән сыйлый иде, — диде. — Элеккеге фил-түрәләргә кырмыскалар тибә хәзер, аздылар мыжгаклар.

Абзый авызындагы челемен теле белән ирен читенә этәрде.

— Җок, — диде, — түрә авыл саен бар, берсенә дә кызыл этәч җиппәрмиләр, синганын бетендә гаебе.

Төкеренеп китеп барды егет. Ләкин абзыйның бер сүзе колак эчендә чебен кебек жуылдады да жуылдады: «Читтә сал, читтә сал, читтә сал». Шәп киңәш бирде түгелме соң Чтапаныч абзыең! Чынлап та, бер Кыязлы гынамыни Җир йөзендә, йөз алар, миллион алар. Читтәрәк тамыр җибәрүнең авырлыгы юк, әнә урман аша сикереп чыктың исә буп-буш авыллар сибелеп ята, чакрымнарга суз каланчаңны, артык җир умырасың, агай-эне, дип чуртым да тыймый, кулга сукмый. Тик Бәрия генә ризалашсын, ул гына чәпчемәсен. Ә ата белән әнкәгә әйтеп тел дә әрәм итәсе түгел, ике бетәшкән җан кая барып баш төртсен ди. Саплаган җеп энә артыннан иярә дә иярә инде ул. «Синең бүтәндә гаебең» диме чуаш тәресе. Нинди гаебе бар икән соң Рәхимҗанның авыл каршысында? Кемнекен урлаган да кемнекен кабып йоткан әле ул? Ә теге төн... юк, бетте, эреде теге төн, аны бүтән искә алу юк. Зур нокта аның артында. Кара Карга каберендә череп ята, күмер төсле күзләре белән чукып, сүзсез генә каргыш яудырмый. Каргышын әйтер идең... «Дөмек, бет, кадал» дигәндер, ә шуның кайсысы чынга ашкан ди әле. Рәхимҗан һаман исән-имин, һаман төп-төз басып йөри. Эчкән суы белән чәйнәгән ризыгы да тамагыннан үтә.

Авылдан таярга дигән карар искәрмәстән генә җанга беректе дә куйды. Бәрия биш чакрым ераклыктагы авылда эшли, гадәттә, эңгер-меңгер төшкәч кайту юлына чыга, аның кулында һәрвакыт авыр сумка була иде. Рәхимҗанның шул йөкне илтешеп тә куйганы бар. Ирекле бәяләр кызны тәмам

азындырды, ул кибеттә ничек теләсә, шулай сата, ә артып калган тауарын зур сумкасына шудыра иде. Мондый мал җанлы хатын — үзе бер бәхет.

Карт егет «күз алмасын» әрәмәлек буенда көтеп торды. Менә аның «алмасы» алдына ук тәгәрәп килеп басты.

— Уф, арыдым, кулым өзелә, писүк тутырганыем, — диде, йөген лапылдатып егетнең аяк турысына куйды. — Күтәреш, нәрсә уклау йоткан кеше кебек үрә каттың.

Кызның ару-талчыгу ташыган күзләрендә ят шәүләләр биешкәндәй булды. Бу гел шулай иде: кайчан гына карама, Бәриянең йөзендә мыек-сакал эзе бар сыман. Сатып кына йончырлык зат түгел син, кәнтәй. Икенче «эшең» дә куәтле: кибет эчендәге аулак почмакта «алыш-биреш» ясап, эт хәленә төшәсең. Мәңге туймас ач тән син. Көнләшә, моны яшерми дә Рәхимҗан, көнләшүеннән иреннәрен чәйнәп өзәргә җитә, тик нишләсен соң, арбаңа җикми торып, ул бияне минеке дип санама.

— Сабыр ит, писүгең эремәс тә, качмас та. Сөйләшик печтек кенә, — диде егет һәм кызны әрәмәлек эченә таба тарткалый башлады.

Бәрия ике аягын түмгәккә терәп карышты.

— Кымтырыкларгамы? Бушлыймы? Ват хәйләкәр төлке!

— Тимим мин сиңа, чәрелдәмә. Сөйләшәбез генә, кыз-мыз.

Тияргә иде бер, бик-бик тияргә иде дә, кул кыска. Аның бит әлегә кадәр яратуы үбешә белмәгән килеш лач-лоч ирен суырудан һәм кабыргасыннан җайсыз тотып кочаклаудан гына гыйбарәт иде. Инде болар гына аз, болар гына җитми, күңел башкасын да тели... Аяк чалып егасы да... үз кисәген умырасы... Бүтәннәргә мулдан өләшә бит, кәнтәй, аңа менә жәлли, аны читкә тибәрә. Өйләнмичә тотынсаң, сау бул, хуш, янәсе. Төкерәсе иде шушы юеш бакага, юк шул, юк, капка төбендә матур-матур түтәйләр «ал мине кияүгә, җаным» дип тезелешеп утырмый. Хет аяк чал, хет бәреп ек, юк һәм бетте. Селәгәеңне йотып җибәр, Рәхимҗан. Өйләнгәч чыгарырсың ачуыңны, билгеле. Ике-өч бала таптырып койрыгын бозга катырсаң, икенче төрле сайрар ул. Егет Бәриядән кулын ычкындырды, үпкәләгән төсле:

— Синең уеңда гел бер нәрсә, кибетеңдә шуны гына «үлчәтәләр», ахрысы, — диде.

— Гайбәт чүбеге чәйнәгәнче, әнә йортың турында уйла, йөрәк маем, өйләнәсе кеше тизрәк кейләнә ул. Яндым дип, башын сулы мичкәгә тыкмый.

— Шуны сөйләшик, дим бит баядан бирле!

— Кузгатма да, яме. Бармыйм тавык кетәклегегезгә.

— Сине анда кыстамыйлар, әүвәл тыңла.

— Шәһәргә кыяклыйк, дисеңме? Аллам сакласын, ике аягымның берсен атламыйм таш калага, мин аулны яратам, — дип, һаман үзенекен сукалаган Бәрияне Рәхимҗан сумкасы өстенә төртеп аударды.

— Өрмә, көчек, ләң дә ләң, сүз әйтергә ирек бир! Яңа йортны урман артында салсам, ни диярсең? Риза булырсыңмы?

— Әстәгъфирулла! Әллә сезне Кыязлыдан сөрәләрме?

Егетнең кулы кесәсендә иде, йомарланган йодрыктан чалбар балагы бүлтәйде. «Тамызсаң инде моңа» диде ул, мыскыллап хихылдаган кызны күзе белән үтәли тишеп. Ярый, ачуы теленә күчте:

— Сөрмиләр, ыржайма. Безнең нәселгә кемнең көче җитсен ди.

— Шулайдыр шул, җитмидер. Ике йортыңнан да көл өеме өймәсләр иде.

— Мин синең белән киңәш-табыш итәм, ә син һаман телең белән аркан ишәсең, кызый. Бергә яшисе бит безгә.

Риза булмас, тагын тыртаер дип сагайган иде Рәхимҗан, юк, Бәрия бу хәбәргә шатланды да бугай әле.

— И, җәһәннәм чите түгел лә. Бер үк һава, бер үк су. Кызыктыр ул урманга сырт терәп яшәүләр. Төзе, сал, йөрәк маем.

Менә шушы сүз генә кирәк иде аңа, ә калганы пүчтәк иде.

Карт урлап җыйган акчасын сыкрана-сыкрана өстәлгә чәчте. Утырып санадылар, һай, яши димәк егет, дөбердәтеп яши! Атасының акчасы ул өмет иткәннән дә күбрәк булган икән ләбаса. Тизрәк таралмас-таркалмас җиргә урнаштырырга сәмәннәрне. Өй инде ул иң зур байлык, өй, өй! Әнә кешеләр сөйли, тиздән акчалар алышына, имеш, тиенеңне дә сакламаска, тауарга әйләндерергә, имеш. Булыр, булыр, бу хөкүмәт абзыкайга бер дә ышаныч юк. Сәгате-минуты белән дөньясын үзгәртеп куя. Йөр аннары, төн чыкканчы, йон чыккан, дип.

Имеш-мимешләр атасын да шикләндергән әнә. Акчаның бәрәкәте бетә, дигәч кенә чүлмәген казып алды карун, юкса кич «әйе» дип, иртән «юк» дияргә бик оста ул.

Урманга арка куеп яшәсәләр дә, тирә-як авыллар өчен өйлек бүрәнә юнәтү олы хәсрәт иде. Усак агачы тиз чери, каен, имән вак-тояккә генә ярый, ә сагыз исе аңкыган нарат еракта — җәһәннәм читендә иде. Рәхимҗан бүтән агачларга тотынмады да, аңа нарат, фәкать нарат кына бата иде. Нәфсесе зур иде егетнең, һәм ул иренмәде, чакрымнар урап нарат эзләде. Тапты. Ике атна эчендә аударып, эшкәрттереп, булачак нигезенә ташытты. Айлы төннәрдә дә балта тавышы тынмады. Ул ни яллаган

осталарына, ни үзенә ял бирмәде. Өйнең түбәсен япкач, арыган, хәлсезләнгән ирләр, калганын үзең эшлә, дип, тиешле акчаларын учлап һәм Рәхимҗанны эт итеп сүгеп, таярга мәҗбүр булдылар. Мин сезне симерергә чакырмадым, дип калды егет. Аның үзенең дә җаны бугазына терәлгән иде. Ул котсыз ябыкты, йөзе, бавыры шешкән тавык кебек, агарып катты, күзләре эчкә батып, яңак сөякләре очлаеп бүлтәйде. Төс җуярсың да шул: хатын-кыз тәрбиясе җитми бит. Әнкә карчык аш-суы белән кинәндерми хәзер, картайды, аның үзен, баланы ашаткан кебек, кашыктан ашата күрше хатыннары. Карун ата, чәй кайнат, дисәң, сусыз самавыр куя. Ә Бәрия йорт ягына ялгыш та күз салмый, әзергә бәзер килергә җыена иде.

Беркөнне егет, кыек такталарын буяп маташканда, яңа йортка якынлашып баручы әнкәсен күреп шаккатты. Минҗамал карчык кәкре-бөкре таякка таянган, оекчан гына, юл тузанын пыр-пыр китереп, ашыга-ашыга теркелди иде.

— Нишләп сине атай чыгарып җибәрде, әнкә?! Адашсаң ни, — дип тиргәп каршылады Рәхимҗан. Урман аша үтүләре бер дә ансат түгел, сукмаклар, ватылган сөяк кебек, уңга да, сулга да, алга да, артка да чәчрәгән иде.

— Миңа Ходай туры юл күрсәтте, улым, — диде әнкәсе, кулы белән чүп-чарны сыпыра-сыпыра баскычка утырды. — Йә, дога кылыйк.

— Догаңны караватыңда кылырга ие, әнкә! Синнән сорыйлар: нишләп аяк астында чуаласың?

— Качып котылмассың, улым, урманы да пәрдә кормас. Каракош монда да ут апкилер. Көчеңне бушка исраф итәсең кана. Шуны искәртим дип ашыктым. Тиле, дисез дә авызын каплыйсыз анагызның. Әлегә кадәр атаң якты көн чырае күрсәтмәде, хәзер син — баласы...

Карчык авызын учы белән ябып тыенкы гына үкседе. Рәхимҗан нәрсә дияргә дә белмәде. Анысы хак инде: Сибгатулла хатынын зар елатып, кыйнап-таптап тәмугта яшәтте. Малайдан да уңмады әнкә. Җир йөзендәге барча хатынкыз җенесен күралмаган малай-егет шуларның берсен, гәрчә ул аны тудырса да, бакса-үстерсә дә, аерып кына ничек яратсын ди. Күңелдә үксегән бичара әнкәсен әз генә кызгану хисе кабынды, әмма ул тиз сүнде, чөнки «Каракош» дигән сүз аны чыгырыннан чыгарган иде.

— Җүләрләнүеңнең дә бер чиге буладыр бит, шайтан таягы!

— Мин үз акылымда, улым. Кайчак башым әйләнгәләп, күз алдымда соры-мыры таплар гына биешкәли. Каракош Һашияләр тирәсеннән чыга. Мәрхүмә күк кап-карадыр гынам. Төннәрен, йокысызлыктан җәфаланып, гел тышка йөренәсең, гадәткә керә бу. Шунда күренә ул кош. И оча, и оча, сөбханалла, машалла, куәт тә соң үзендә, күкләр томалана, ике канатын җәйсә.

— Синең Һашияң карга тизәгенә коенып яшәде, бакчаларының һәр тупылында карга оясы, син шулар белән җенләнәсең, әнкә. Бар, кайтып кит, йөрмә эч пошырып. Синең исәрләнүең генә җитмәгән иде монда. Шуны лыгырдар өчен җан-фәрман чаптыңмы!

— Бүген үк тәүбәгә керешергә дә гөнаһларыңны ярлыкау сорап Ходайга ялварырга, алга таба явызлыкка бармаска кирәк, улым. Ни кылдыңдыр, Каракош каныга сиңа әнәтерәк.

Рәхимҗан карчыкны җилтерәтеп баскычтан торгызды.

— Бар, дидем бит, яхшы чакта кайтып кит, дидем. Шул кош телеңне чукысын иде синең, юк-бар пытырдамас идең хет.

— Чү, улым, сабыр. Сүзем очланмады, ахырын тыңлап бак, — дип өзгәләнгән әнкәсенә егет йөрәгеннән кан коеп җикеренде:

— Сыптыр Кыязлыга! Юкса әнкә димәм, берне ямармын да юеш таракан ясармын!

Карчык киткәч тә ярсуы тиз генә басылмады Рәхимҗанның. Кара син, ә! Юри бәла-каза чакыра тиле әнкә. Казаны тел белән дә тартып китерергә була. Телгә килгән алга килә, ди. Әгәр бик күп сөйләнеп йөрсәң, аягыңа да урала, ди ул. Аңа ник тынычлап кына яшәргә язмаган икән? Көн саен турларында күмердәй күзләре белән каршы алып озатып калган Карга Һашиясеннән котылгач, дөньяларында сулыш иркенәйгән иде. Инде әнкәсе бәйләнергә кереште. Ник ялварсын ди кичәге партком секретаре малае Рәхимҗан Ходайга?! Юк ул Ходай, ялган ул, кешеләрне куркытыр өчен генә уйлап табылган әкият ул! Егетнең йолдызсыз төндәге кыңгыр эшен Ходаең да, модаең да белми, моны белсә, Сибгатулла карт кына белә. Ә аны Рәхимҗан изге итә алмый, изге сын күреп: «Гөнаһымны кичер», — дип, алдына тезләнә алмый, чөнки карт үзе дә муеннан әшәке сазлыкка баткан. Аның гөнаһларын ун авыл тавыгы да чүпләп бетермәс иде.

Озак тынычланмады егет. Баскычка менеп, күктә уйнаклап очкан кошларны күзәтте. Әнкәсен саташтырган зәхмәт — Каракош — канатларын шап-шоп бәргәләп баш очында бөтерелми микән? Ха-ха-ха! Тәпиеннән генә эләктереп җиргә сылар иде Рәхимҗан. Тфү, карчыкның юләрлеге аңа да йога бугай инде.

Ә кичкырын ул тиктомалдан шомланып өй тирәли әйләнде, кайсыдыр нуештә куркыныч сагалый сыман иде. Әнкәсенең җеннәре калды, ахры, алар күңелгә коткы салып бимазалый. Йокысы да йокы булмады: әллә ничә мәртәбә бастырылды. Өскә ябырылучы шайтан Һашия кыяфәтендә иде. Һашия аның җилкәсенә менеп атлана да тезләре белән муенны кыса, буа иде. «Көш-ш, үләксә карга», — дип, гәүдәсен кыймылдата Рәхимҗан, күзен ача һәм... чытырдатып кире йома. Саткыры, ир башыңнан бала

йоннарың кабарыр: хатынның кулы юк, иңбашында ике канат... «Син идең, син, син, син...» дип каркылдаган тавыш колак пәрдәсен ерта...

Төшләнү-бастырылулар һәр төн саен кабатлана башлагач, Рәхимҗан бөтенләй бетәште. Аякларын көчкә сөйрәп атлады. Өн белән төш арасында буталган кара дәҗҗал, ни Һашия, ни кош, аның канын суыра иде. Нигезе шаукымлы, ахрысы, юньле кеше ярым ташландык урыс авылында бура күтәрәмени?! Җен-пәри мыжлаган урын бу, валлаһи. Алланы танымаса да, җеннәрдән өркә иде егет, ни хикмәттер. Аңа бигрәк әрсезе бәйләнә бугай, һич туктамый, каһәр.

Бертөнне аптыраган-йөдәгән Рәхимҗан ишегалдындагы такталар өстенә урын җәеп ятты. Авыл — утсыз, җиһан — йолдызсыз, тышта дөм караңгы иде. Тәмле-тансык йокы керфекләрне аралап күзгә тулып барганда, колакка «кар-р» дигән тавыш ишетелде. Егет тактага сеңде. Урманнан төн карасыннан да караpак бер кош очып чыгып килә иде. Менә ул канатларын Рәхимҗанның өенә табан турылады. «Кар-р, кар-р...» Уктай түбән атылды һәм томшыгы белән чык та чык тәрәзә пыяласын чукырга тотынды. «Көш, көш» диде атылып торып утырган егет, әйтерсең тавык куа иде. «Көш, көш!» Әмма аның көшелдәве үзенә дә ишетелми, яргаланган иреннәренә ягылып кала иде. Күкрәген ярып тук-тук бәргән йөрәге аны кире ятагына аударды. Хәлсез егетнең бармак селкетерлек тә рәте юк иде. Терсәгенә таянып янә торса, коштан җилләр искән! «Авырыйм, ызба салу мигә сукты, күземә әллә нинди әкәмәтләр күренә, духтырлардан дару яздырып алырга кирәк, болай саташтырса, тәпиеңне дә сузарсың. Калыр йортың этләргә», — дип үз-үзен юатып, таң аттырды ул. Ә иртән күзе ялгыш кына ян тәрәзәгә төште. Күлмәк сәдәфе кадәр ике тишек! Ни-нәрсә бу?!

Рәхимҗан, аякларын җирдән шудырып кына, тәрәзәгә якынлашты. Чәнчелеп китсен, томшык эзе, томшык! Димәк, төнге маҗаралар чын булган, күзгә генә күренмәгән. Әле бер кошның да тәрәзәгә кунып пыяла хәтле пыяла чокыганы юк иде. Әллә урыс урманнарына канатлы дәҗҗаллар иялэш-кәнме?! Сөйләсәң, адәм ышанмас, Сибгатулла малаеның башына тай типкән, диярләр. Аңа хәзер духтыр түгел, биш чакрымдагы багучы удмурт карчыгы кирәк. Җеннәр ахирәте ни такылдар менә. Аныкы гел дөрескә чыга, имеш. Теге кара төннән соң алар тарантаслы атта шушы багучыга барганнар иде. Карчык түм-түгәрәк битле хатын иде әле. Ул ата белән улны капка тоткасына да орындырмады, куып җибәрде. Ә артларыннан:

— Кешегез кайта, исән ул, мөртәтләр! — дип кычкырып калды.

Сибгатулла инде икенче ай шик белән яши, төшендә Карганы тере итеп күрә, шуңа ул багучыдан нәрсәдер белмәк булган иде.

— Ишеттеңме, малай, кайтачак, ди. — Атасының кызыл борынына хәтле агарган иде. — Чиста эшләмәгәнсең, дуңгыз! Ни урталай, ни пырталай!

— Кайтмый, — диде малай. — Удмурт карчыгы чуртымны беләмени! Карга дөмекте, валлаһи, дим.

Ә бит багучы алдашмаган иде. Аның сүзләре вакыт аша саркып барыбер расланды шул. Анда инде пычагым да кыралмыйсың, бөтен юллар бикләнгән иде.

Карганың исән икәнен сизенгән багучы нишләп егетнең маҗараларын гына белмәсен ди. Белә булыр, белә булыр.

Карт егет карчык яшәгән авылга юл тотты. Аңарда гына сер түгел икән, багучының капка төбенә халык җыелган, яртылаш бөкрәйгән озын буйлы бер карт, таягы белән төртә-төртә, кешеләрне чиратка салып маташа иде.

— Син өченче, син дүртенче, син алтынчы... — дип саный-саный, ул Рәхимҗанга җитте. — Син, олан, егерменче, иң актыккы.

— Мин — беренче, — диде егет, кулы белән халыкны як-якка этәреп түргә узды. Капкадан да очып кына үтмәкче иде, ләкин ул эчтән терәтеп куелган икән.

Хатын-кыз пырдымсыз Рәхимҗанга әр-битәр яудырганда, чыелдап өйалды ишеге ачылды. Карчык йокыдан гына уянган, кәефсез иде бугай, үзалдына ачулы мыгырдана-мыгырдана капкадан терәүне алды. Аның шадра йөзе күренүгә, урамдагылар дәррәү артка чигенде.

— Барың да каралыр, тибенмә, тибешмә, — диде җен сыңары һәм күзләре белән төркемне бораyларга кереште. Кинәт ул кәкре бармагын егетнең күкрәгенә кадады. — Монау бәндәдән гайре барың да керер.

Рәхимҗан исен-акылын җыеп өлгергәнче, халык ташкыны аны гайрәтләнеп коймага таба кысрыклады һәм чирәмле ишегалдына ыргылды. Егет тә аларга кушылмакчы иде, карчык дөньяны дерелдәтеп үкерде:

— Кермәң, каргышлы бәндә! Мин сингар берлән сүләшеп тә бакмыйм!

Бая чиратка тезгән карт, көлемсерәп, ашыга-ашыга борын төбендә үк капканы япты...

Егет йодрыклары белән ярсып-ярсып капкага сукты да карчыкны бетереп сүгә-сүгә китеп барды. Аждаһа тәре, суксаң, арык гәүдәсеннән сихер-михере шыбырдап коела инде, кеше күп шул, аулак җир түгел, һи, Рәхимҗан болай гына җиңелми әле ул, шөлләде дип кукрайма, карчык, җаныңны, таракан кебек, үкчәңә качырачак, көт. Аннан соң каз муеныңнан бора-бора сихереңне костырачак. Сөйләрсең, егет ни сораса, шуны сөйләрсең, шайтан бозыгы!

Күкрәгендә айгыр дулатып, Рәхимҗан өенә кайтты. Капка баганасы утыртырга дип казыган чокыр туфрагын бер дуңгыз баласы борыны белән актара иде, аңа да ачуыннан өлеш чыгарды, дыңкылдатып майлы корсагына типте. Дуңгыз чиный-чиный сыртына тәгәрәде.

— Сасы тәре, элдерт моннан, терелəй тиреңне туныйм! — диде ул, тагын типмәкче иде, ызба читеннән Бәрия калыкты.

— Хайванның эчәген агызасың бит, имансыз! Исемеңне Рәхимсезҗан дип кушарга иде атаңнарга.

Егет кызлар кебек авызын турсайтты.

— Таң тишегеннән нишлисең монда?

— Эшкә барышлый сугылдым, йортыңны карарга. Ә менә син кайда сөйрәләсең?

— Урмандагы аударасы агачларны тамгаладым.

— Әллә маржа биленә тамга суктыңмы, дим. Атаңа охшасаң, көт синнән! Нәселегез белән азгын сез.

— Телеңне теш арасында кысыбрак тот, Бәрия. Мин көн-төн йорт дип чиләнәм, синең сымак кибеттә ирләр белән кети-мети уйнап ятмыйм.

— Абау, абау, шикләнсәң, өйләнмәссең... Ялынучылар без түгел.

— Җә, күперенмә. Өй ничек соң, ошыймы?

— Үлепләр ошый. Остардың син сала-сала.

— Акча оста, ул салдыра. Бер тәрәзә пыяласын нәрсәдер тишкән әле, — диде Рәхимҗан. — Кош чукыган, ахры.

— Кит, дивана, кош пыяла чукый димени?! Малай-шалай чуерташ бәргәндер. Кая тишек? Ян тәрәзәдәме? Абау, ялтыравык боз кебек шоп-шома ич ул.

Чекерәя-чекерәя ерактан гына караган кызны егет этеп җибәрде.

— Якыннан кара, сукыр ябалак. Шар күзеңне зуррак ач та.

— Син үзең сукыр ябалак! Минем ун чакрымнан күрә күзләрем. Пыяла шоп-шома, хи-хи!

Рәхимҗанның җаны үртәлә башлады. Аңардан эте-бете көлә, хурланып үләрсең.

— Әйдә әле, әйдә, — диде ул, Бәриянең касыгына төртә-төртә һәм ян тәрәзәгә таба куалады. — Тишек бар, дим, тишек монда, дим, сиңа ыржая, дим.

Коты алынган Бәрия, тарткалаша-тарткалаша аның кулыннан ычкынып, урамга йөгерде. Шактый йөгергәч, борылып:

— Духтырга бар, ми күзәнәкләрең зарарланган, күзеңә шайтан тишеге күренә, — диде.

«Үтерәм» дип, кызга таш кисәге томырганда, күз янә тәрәзәгә төште, һәм баш түбәсендәге чәч үрә торды: тишекләр юк иде... Кая киткән алар, йә?! Ничек капыл гына томаланган?! Күрде ич, күрде Рәхимҗан, карандаш очы сыярлык тишекләрне теп-тере күзләре белән күрде. Ул багучы янында киләп сарганда, пыяланы кемдер алмаштырмагандыр ла! Юк, юк, бу үзе кискән пыяла, әнә чәпәк-чәпәк бармак эзләренә хәтле анык. Нишли дөньясы, җә? Нинди әкәмәтләре белән егетнең башын катыра ул? Бар иде бит ике тишек! Аягүрә төшләнә мәллә Рәхимҗан? Мөгаен, җеннәр саташтыра аны. Каракошы да, пыяла тишеге дә шулар шаукымы, ахрысы.

Егет тынычланып кыекка таба сузган баскычка үрмәләде, тик эшкә керешә алмады, юлдан тагын әнкәсе килеп ята иде. Хәерсез кортка, кул-аякны бәйләп йөри бит, ә! Сырхау дип жәллә аны, көн дә бәбәген терәп монда чаба. Әй бу картларны, үзләреннән алдан сине кабергә илтеп тыгалар, валлаһ.

Карчык, йөзе каралган улына күз дә салмыйча, баскычка төртелде һәм кулындагы төенчеген чишеп җибәрде.

— Бисмиллаһир-рахмәнир-рахим. Шулпа апкилдем, улым. Йөрәгеңә яткырып кына аша әле. Төнәгенәк атаңның мәчеткә китүен генә көттем дә, Фәтхетдин абзаңнан тавык суйдырдым. Атаң тавык-чебешкә тимәскә куша бит, санап кына тора.

Каты-коты чәйнәп егетнең ашказаны бозыла башлаган иде, ул, тәмләп кенә тавык ботын кимерә-кимерә, шулпа чөмерде.

— Атай мәчеттә нишли?

— Җомга намазына йөри.

— Һы. Шул сакаллы тәрене ничек мәчет бусагасыннан атлаталар икән соң?

— Кяферләнеп атаңа тел-теш тидермә, улым. Сиңа да гөнаһлардан арынырга вакыттыр, ирләр яше куасың бакчи.

— Миңа вәгазь укыма, әнкә! Яратмыйм акыл өйрәтүләрегезне, минем үземдә дә баш бар.

— Теге көнне сүземне бүлдереп кудың, улым. Тыңлап бетер. Төшлек салдырганием, изгеләрдән шул килеп иреште. Пакьләнеп-аруланып, «кылган кара эшемә тәүбә итәм, йа Аллаһы Тәгалә, истигъфар кыл» дип, җитмеш мәртәбә кабатласын. Шунда Каракош тынычланыр, аңа каныкмас, бу нигезеңә дә ут китермәс, диделәр.

— Уф, тагын Каракош! Шулпа хәйләсе белән син тиле сүзләреңне сөйләргә килгәнсең икән. — Рәхимҗан буш савытны җан ачысы белән җиргә бәрде, тавык сөяген тезенә сугып сындырды. — Гарык

мин сездән, әнкә! Газраил ник атай белән сине онытты икән, ә?! Таптап-таптап күмәр идем, валлаһ! Күздән сыңар тамчы яшь сытылмас иде!

— Җир күтәрмәс гөнаһ белән ничек яшәмәк кирәк, бала! — дия-дия, әнкәсе яньчелеп туфракка буялган савытны алып төенчеккә төйнәде, бүтән бәхәсләшмәде, гөлт итеп кабынган Рәхимҗаннан шүрләде бугай, тиз генә табан ялтыратты.

Әнкәсенең сүзләре бер колактан кергән, икенчесеннән чыккан иде, тук егет ишегалдын яңгыратып кикереп калды. Тәмле шулпа ашказанын тыгызлый иде. Үзе гөнаһ сөйли, үзе тавык урлый, юләр генә димәссең әнкәйне. Пешерүен Фәтхетдин хатыны пешергәндер инде. Кая тиле карчыкка аш-су тирәсендә кайнашу!

Әнкәсе аны тагын бер кыланышы белән үтереп ташлады. Яңа йортка күченгәндә, «монда калам, китмим» дип, киресенә катты. Әүвәлгеләрендә ул болай карышмаган иде. Мич арасына поскан карчыкка төрлечә ялындылар, тыңламый гына бит. Ахыр чиктә егет камчы тотып керде. Атасы беләгенә асылынмаса, үз-үзен белештермичә тетә иде ул.

— Кулың черер, анаңа суксаң, — дип мышкылдаган картка акайды гына Рәхимҗан.

— Фу, дуңгыз. Син яшьрәк чагында күпме кыйнадың аны, ник һаман кулың исән соң, ник череми?!

— Ул миңа хатын, сиңа газиз әнкә.

— Ярар алайса, хатыныңны тартып ал аралыктан, түлке тиз кыймылда, ишек-тәрәзәләргә такта кагам.

Шулай ызгыш-талаш белән күченде алар. Егет, басу капкасын чыкканда, авыл ягына борылып лач иттереп төкерде.

— Бодай-арышларыңны боз суктырсын, кешеләреңне мур кырсын, албасты Кыязлысы, — диде.

Ә атасы белән әнкәсенең күзендә мөлдерәмә яшь иде... Имеш, картаймыш көннәрендә изге җирләреннән куптылар. Имеш, әби-бабалар күмелгән зират рәнҗеп кала.

Картларның күңел дөньясына да төкерде яңа йорт хуҗасы. Иләшерләр, урыс авылы да авыл. Аның үзенеке куәтлерәк иде әле. Бәрия аңардан сүрелгән кебек тоела. Тизрәк араны җайлап, туйга хәстәрлек башларга иде бит. Ул сикергәк кәҗә бәтиенә кәбестәнең тәмлерәген каптырсаң, үпкә-сапкаларын онытыр иде инде. Сибгатулла акчалар белән бергә чүлмәккә хатынының көмеш әйберләрен дә яшергән иде, хәзер ул алка-беләзекләр Фәтхетдин хатыны биргән иске сандык төбендә ята. Әби төсе дип, әнкәсе шуларны алып-алып карый да кире сала иде. Бәриягә менә дигән бүләк ләбаса көмешләр!

Карчык сизмәсен дип, ул бушаган чүпрәк янчыкка калай кисәкләре салды.

Рәхимҗан ялгышмады, бүләкләрне күргәч, кызның күзләре ялтырады.

— Абау! Чын көмеш! Бигрәк матур! Каян чәлдердең?

— Нишләп чәлдерим ди. Сиңа атап базардан алдым.

— Ялганлама, яме. Мондый борынгы нәстәкәйләрне кала музейларында гына саклыйлар. Атаң теге елларда берәр җанкисәкнең колак-бармакларыннан салдырмагандыр, шәт.

— Җә, беләк буе телеңне сайратма, тагып йөр. Биргәннең битенә төкермиләр. Туй бүләге бу сиңа.

— Туй бүләге?! Әллә көләсең инде? Тавык канатын сындырып биргән төсле генә чыга бит бу, йөрәк маем. Әнә бүтәннәргә...

Егет киң учы белән Бәриянең авызын томалады.

— Ашыкма, яши-яши алтынга күмәм мин сине, валлаһ. Тагын бер бүләк әзер. Яңа йорт.

Кыз аның кулын читкә этәрде.

— Япма әле, минем авызга капкач кирәк түгел. Йортың шәп анысы. Кибеттә ир-атлар сөйләде, Кыязлының карун Сибгат малае ике ятажлы клуб чәпәгән, дип. Әкәмәт зур, дип.

Бу мактау Рәхимҗанның ачлыктан киселгән йөрәгенә сары май булып сыланды. «Менә шул клубны син — ана дуңгыз тутырасың инде, ел саен итәк астыңнан бала тәгәрәтеп» дип, эченнән генә уйлап, астыртын елмайды. Ике-өч атнадан Бәрия куенга керәчәк, аннан тәмугка күчәчәк, егет аны бик-бик «татлы тормыш»та яшәтәчәк иде. Атналарны өч көнгә калдырып кыскартырга да була, тик әлегә бурыч тулысынча түләнмәгән, ул идән такталары өчен урманчы Ранаска диләнке чистартырга тиеш, башта ук шулай кул сугышканнар иде. Йорт дия-дия сандыкта хәзинәң бушый, беләктә көчең кими икән. Барып җен урынына эшләп бурычын каплап кайтса, бүтән ватылмас иде ул, адәмчә тереклек итәр иде.

Ләкин урманга дип җыенган егет тоткарланды, һаман шул әнкәсе гаепле иде. Ул үлә-үлә саташа, төне буе тәрәзә төбендә утыра, тыныч кына утырса бер хәл, «Каракош килә, Каракош ут сала» дип бакырып йоклатмый иде. Аптырагач, Рәхимҗан аны озын аркан белән уратып-уратып караватка бәйләде.

— Мәңге ычкынмассың хәзер, чәбәләнмә дә, җен, — диде. — Мин кайтканчы ят. Атай чишсә, икегезне дә үтерәм! Бирәм мин сиңа Каракошыңны!

Карчыкка дәшмичә генә ятасы да бит, юк шул, аның теле кычытты бугай:

— Көмешләремне урладың, син — угры, — дип еламсырап, үпкәне кабартты. Әнкәсенең тешсез авызына чүпрәкне йомарлап ничек тыкканын да белештермәде егет...

Өй дөрләп янганда, ярты юлга җиткән иде ул. Әй кире борылып чапты, әй чапты, каршы искән җил калкан булып күкрәккә бәрелә, тынны кыса, аяктан ега иде...

Утны сүндерә алмадылар. Хәер, берән-сәрән йортлы авылда юньле кешесе бармыни аның. Булганы да аксак-туксак, китек-петек җан ияләре. Ялкын бугазны көйдереп эчкә үрләде бугай: йөрәк-бавыр өтелә. Их-ма, бер-бер артлы өч йорт! Кайгыңнан үзең дә тәгәрәп китеп янарсың. Кайсы ләгънәт сукканы ут тубалы белән кизәнә аңа, йә, кайсысы? Нишләп нәкъ менә Рәхимҗанга үчегә ул?! Нишләп, нишләп, нишләп?!

Киеменнән төтен исе аңкытып янына атасы килеп басты, тузан бөртеген каккан сыман гына улының җилкәсенә сукты:

— Хана, малай, ызбаңның өч көнлек рәхәтен күрмәдең.

— Кем төртте?

— Шайтан төртсенме! Ул аска икенче атаждан сикерде.

— Ишегалдында ике мичкә су иде, ник сипмәдең, карт хөрәсән?!

— Сиңа әйтүе җиңел, малай. Сүндергәннәр ди җил тудыйм-судыйм бутаган утны мичкәдәге ярты уч суыңны өфелдәтеп. Әнкәңне көч-хәлгә караватыннан чиштем, акырып тереләй яна иде. Куркудан телсез ята әнәтерәк Начталарда.

— Икегезне бергә бәйләп калдырасы иде аны, — диде Рәхимҗан, тешләрен шыгырдатып.

Карт килеште.

— Син, имансыз, булдырырсың моны, — диде. — Ярар, маңка агызып ничу утырырга, үз нигезебезгә кайтыйк.

— Нинди нигезгә?

— Кыязлыдагы төп йортка. Синең уең кая бармакта соң? Төкерсәң дә, шунда җан асрыйсы, малай.

— Бар, әнкәне сыртыңа сал да, таегыз!

— Син нишлисең? Әңгер иңгәнне көтәсеңме? Халыктан ояласыңмы якты күздә кайтырга?

— Телең белән чеметмә, атай, үкенерсең. Төкергәннәр ди синең Кыязлы халкыңа! Элек аларны миңгерәү сарыклар дип сүгә идең, халык дисеңме хәзер үзләрен, яхшатланасыңмы?

— Шыпырт, малай, ярсыма. Сакаллы урыслар көлә. Лутчы әйдә кайт, Начта ире ат җикте, илтешәм, ди. Әнкәң арбада. Монда көлгә борын төртеп шыңшуның файдасын күрмим.

Рәхимҗан аларга иярмәде. Кыязлыга якты күздә кайттың ни, караңгыда ни, барыбер иде. Оялмый ул халыктан, атасы тик акыл сатсын шунда. Аңа Бәрия тынгы бирми иде бу минутларда. Кызый күкне биләп янган йорт турында ишеткәндер, авыл белән авыл арасында хәбәр очып кына йөри. Кибеткә кергән һәр кеше әлеге янгын турында әйтмичә калмагандыр. Бүген-иртәгә хатының буласы кыз кибетен бикләп җәяү йөгерер, кайгыңны уртаклашыр, җылы сүз белән юатыр иде. Ә Бәрия күренмәде. Ташның ташы икән хәерче көтүче сәләмәсе! Әйдә, яныңа сугылмасын ди. Моңа гына түзә әле егет, ә менә йортсызлыкны сылтау итеп, сиңа чыкмыйм, дисә, нишләр ул? Яңадан дүртенче казык кагарлык рәт бетте: шыр ялангач Рәхимҗан. Акча җыя торыйм дисә, еллар уза, сакал билгә җитә, кәләш ятларга ычкына.

Хәзер аңа, бернәрсәгә дә карамыйча, Бәрияне үзенә ябыштырырга кирәк. Моның өчен иң әйбәте — башны юләргә салып, кызга йортка керү.

Әйе, әйе, йортка керү. Башка чара юк. Ата нигезенә аның борылып төкерәсе дә килми. Ул тирес өеменнән гарык! Җитмәсә, теге хатын... каргага әверелеп гел агач ботагында тирбәләдер кебек. «Кар-р, кар-р...» Үлмәгәндер карга тәресе, валлаһ. Үлсә дә, кызы исән ич, суйган да каплаган Карга: чем-кара чәч, чем-кара күз...

Нигә аларны уйлый әле Рәхимҗан? Нигә үткәннәргә бәке уеп, карлы-бозлы суына чума? Чукынсын каргалар! Аңа алдагысы мөһимрәк хәзер. Йортка кергән тәкъдирдә йомгакны кая таба тәгәрәтәсен белер иде ул. Бәриянең атасы — Сибгатулла сыңары, гомер ыштан балагына акча җыйды. Терлек үрчетте, терлек сатты. Башыңдагы шөрепләрең тутыкмаса, бабайны рәхәтләнеп саварга мөмкин. Авылда бот чабып көләрләр, әлбәттә. Йортка керү ир-егеткә хурлык санала. Әйдә көлсеннәр. Тормыш арбасын гел ат кебек җигелеп кенә тартмыйлар, аның тәгәрмәчен келдерәтер өчен хәйлә-мәйлә дә коралар. Җене өзелгәнче тырышты бит инде Рәхимҗан, йә, ни майтарды? Беренче өе яну белән, аңа Бәрияләр ягына аварга кирәк булган. Икенче йорт бабай акчасына төзелер иде.

Марҗа карчыклары бәлагә тарган күршеләрен арбаларына ипи-сөт куеп озатып җибәргәндә дә егет урыныннан селкенмәде, бүкәнгә береккәндәй утырды. Телдән язган әнкәсе кул изәп инәлә-инәлә чакырды аны, ә ул күтәрелеп тә бакмады, дөньясына ачуы көчле иде.

Төнгә каршы күзеңне тасрайтып Бәрияләргә бару килешмәс, аннан, кичке акыл иртәгесе көнгә ярамый дип, егет кисәүләре пыскыган нигез кырыена иске-москыдан урын җәйде. Агач ботакларын сындыра-сындыра дулаган җил тынып, авыл өстендә бер уч болыт әсәре калдырмаган, офык читенә илтеп өйгән, күк йөзе зәп-зәңгәр, җирдән саркыган караңгылык аның төсен күмә алмыйча азаплана иде. Рәхимҗан авызын зур ачып төтен сеңгән һаваны йотты. Әкрен генә көй көйләде, моңсыз тавышы борыны тыгылган кешенең ыңгырашуына тартым иде. Их, бәхетеңне керпе ашагач, шул инде ул.

Ятасың сәләмгә төренеп, куккә карап. Янында, ичмасам, күңел өчен генә бер эт ышкынса икән. Ни хәлдер, этләре дә аны яратмады, каршы килсәң, койрыкларын бот арасына кыстырып шыла иде. Эт эт инде, мәхлук хайван төркеменнән. Ә кешеләр нәрсә? Егет алар өчен өрәктән дә куркынычрак зат түгелмени? Атасы аркасында шулай бу. Ул заманында Кыязлының канечкеч түрәсе, ә Рәхимҗанның горурлыгы иде. Кем гайрәтле атасы белән масаеп, түш киереп йөрмәс икән, ә?! Йөрде малай, йөрде.

Сибгатулла Бикмуллин склад мөдире иде. Ул складка ниләр кергәнен һәм ниләр чыгып киткәнен Кәҗә кушаматлы колхоз рәисе Газизулла да аңышмады хәтта. Ял саен, пардан ат җигеп, Сибгатулла урланган мал-мөлкәтен сатар өчен җиде чакрымдагы базарга ашыга иде. Сыкты дөнья маен мөдир! Кикергәнче ашап, күз кабагы шешенгәнче эчеп, тормышның эчен актарып яшәде. Склад белән генә чикләнсә икән Сибгатулла, авылга да тулаем ул баш иде. Кәҗәне сакалыннан тотып, теләсә уңга, теләсә сулга борды, тегесе дә юаш иде, карышмады, гел аның җырын җырлады.

Ә мәктәптә, урамда Рәхимҗан патшалык итте. Атасыннан кимен куйсынмыни малай! Теләсә, иптәшләрен суктырды, теләсә, баш идерде, яшьтиләр аның кул катысын татымас өчен ничек тә ярарга тырыша иде. Тик менә кыз-кыркын... Теше үтмәде бит шуларга Рәхимҗанның, үтмәде! Чәчби халкы аңардан шөлләми, ул күренүгә, йөзләренә үтеңне сытарлык җирәнгеч кыяфәт чыгара, әрем тәме сеңгән беләк буе телләре исә елан агуына тиң иде. Шуңа күрә малай мәктәптә укыганда ук салам сыйракларга кул тидерергә базмады. Кыскасы, шүрләде. Тыштан гайрәт чәчсә дә, йөрәгендә дер-дер калтырап куян утыра иде бит аның. Каһәр суккан чәчбиләр моны абайламый дисеңме әллә? Үсә-үсә ул кызлардан тагын да ераклашты. Бу аңлаешсыз, сәер халык таш кебек аның бавырына төшеп утырган иде. Ә әнкәсе? Бит ул да алар кавеменнән иде. Бик очыныр, бик кәпрәер иде Минҗамал, атасы дилбегәне нык тотты, һәм бүген менә ачыкланды: Сибгатулла арттырыбрак җибәргән, йодрык ашаган әнкәсе шыр диванага сабышты әнә. Өендә Минҗамалының тетмәсен тетсә дә, бүтән хатыннар янында алай ук шәбәймәде карун. Базардан ул кунмыйча кайтмый, аның төнне кемнәр кочагында уздыруы да сер түгел: калын марҗалар, ягылган мич кебек, һәрвакыт кайнар булыр, Сибгатулланы май кебек эретер иде. Яратмыйча ярата иде ул, котырган нәфесен басар өчен генә хатын-кыз кочты. Ни атага, ни улына мәхәббәт тәтемәде шул. Ирнең азгынлыгы әнкәсен җилгә элеп киптерде. Бер юанычы бар иде хатынның: менә улы буй тартсын әле, күрсәтер сиңа, урам эте! Менә буй гына тартсын... Ә Рәхимҗан үскән саен әнкәсеннән читләшә барды. Кая ул үкерә-үкерә хатынын тукмаган атаның кулына сугу, өйдә кара тавыш тынганчы, багана хәтле гәүдәсе белән тыштa йөри иде малай. Әнкәсенең күз яшьләренә аның кылы да селкенмәде. Әнкәсеннән ни файда әле аңа? Атасына ныграк сыенырга кирәк: ул кием бөтәйтә, ул сораган әйберләреңне юнәтә. Малайларның төшенә дә кермәгән фифирус дигәнне авылда кем тарта? — Рәхимҗан тарта. «Начар» димәде бит атасы, «мә, рәхәтлән, бетсә, тагын сора» диде. Атасы улы белән бик сирәк гәпләшә иде. Ә беркөнне ул ундүрт яшьлек малаена беренче тапкыр серен ачты.

— Минем абруйны үстерерлек эш муенын сузып тора бит әле, малай. Ниткән эшме? Дәрәҗәле, малай, дәрәҗәле. Биш хуҗалыкка бер башлангыч партоешма укмаштырмакчылар. Беренче чикритар үзе килде Кыязлыга шул мәсьәләдә. Авылларда коммунистлар күбәйде, даваегыз, ди, җитәкче сайлагыз, ди. Мин Газизулланы читкә апкитеп сакалыннан тарадым, мәйтәм, мине сайлатасың. Иту кәҗә маеңны агызам.

— Нәрсәгә ул сиңа секретарь дилбегәсе йөгәне, атай?

— Һи, тишек борын, блач бит ул, үзе акчалы блач. Вызнусын исемлеккә киметеп язасың да шалт кесәңә чумырасың.

— Ярамаган ди склад мөдире булуың гына.

— Алай димә, малай. Чикритар әйтә, кем сайлана, шуңар арбалы матай бирәбез, ди.

Рәхимҗан колагын шомрайтты.

— Матай, дисеңме?! Сиңамы?!

— Кәнкрит миңа димим, кем сайлана, шуңар, дим. Бу урынга кызыгучылар байтак.

Матай, матай! Рәхимҗанны ымсындырган матай. Юк, атасы алдыйдыр, валлаһ.

— Бирерләр шул, — дип сөйләнде Сибгатулла. — Чикритар башың белән биш авылны җәяү әйләнмәссең. Блач кешесенә сан бар ул, малай, шаярма син.

— Алайса, ничек тә тырыш инде, атай. Үзең яклы кешеләр җый. Матай безгә эләксен иде.

— Әһә, күзең кыздымы матай дигәч, тишек борын! Атланып чабар идең, көнозын җил белән узышыр идең, ә?! Икебезгә дә җитә ул тимер айгыр, тик мона... — Шунда атасы шиген дә белдерде: — Тик мона берәрсе хатын-кызга хирыс дип чикритарга жалу язмас микән? Анда шул якны яратмыйлар икән, шайтан алгыры.

— Марҗалар әләк сырлар дисеңме?

— Юк ла!

— Әнкәме?

— Хи, әнкәңә тагы. Сарыкның сарыгы ул.

— Соң, атай, маржа сасысын иснәмичә тор әзрәк. Ике атнадан Ходай үзеңә фәрештә таныклыгы бирер.

Сибгатулла:

— Хихылдама, малай! Йөрмим мин алар янына, туктадым, чиста атаң бүген, — дип шапырынса да, ниндидер сер яшерә, бу сер газап булып аның симез йөзенә җәелгән.

Сере белән шайтаныма олаксын, нәрсәгә ул Рәхимҗанга, тизрәк матай ишегалдына керсен иде. Их, яшьтиләрнең эчен яндырып выжылдап узар иде малай урамнан! Татлы хыялдан Рәхимҗанның ирен читләренә селәгәе агып чыкты. Ул бөтен җаны белән атасының «блач» сәндерәсендә аяк бөкләп утыруын теләде.

Ә Сибгатулла көннән-көн басылды, кечерәйде, әйтерсең авыр хәсрәт йота иде. Өйдә һич көтелмәгән тынлык, мышный-мышный хатын кыйнау да юк, акыру-җикеренү дә юк, аты-юлы белән сүгенү дә юк, атасы коеп куйган фәрештә! Әнкәсенә дә ул «әй син, ана эт» дип мыскыллап эндәшмәде, «Минҗамал» дия башлады. «Кара бу атасын, «блач» башына атлану өчен яңадан туарга әзер бит, — дип шаккатты малай. — Тырыша-тырыша яңа тормышка көйләнә, хәйләкәр».

Мөдирнең склад саклыйм сылтавы белән ярты төнгә кадәр югалуы гына сәер иде. Элек ник сакламаган икән?

Беркөнне Рәхимҗан шыпырт кына Сибгатулла артыннан күзәтте. Ул мунча кырыеннан иелә-бөгелә килде дә койма башыннан гына күршеләр ишегалдына сикерде. Малайның күзе акайды, Һашияләрдә ни югалткан атасы?! Авылда карунның бәбәген чукырлык бердәнбер кыю хатын-кыз — ирдәүкә Һашия генә, аның кушаматы да Кара Карга иде. Сибгатуллалар белән Каргалар бер-берсен өнәмәде, йомышка да йөрешмәде, дошманнар кебек яшәде. Качып-посып кына нишли аларда ул?

Рәхимҗанны кызыксынуы җиңде, ул сынык рәшәткә ярыгыннан сыдырыла-сыдырыла эчкә керде. Әнә шыгырдап Карганың ишеге ачылды һәм Сибгатулла, шәүләсен ияртеп, өйалдына чумды. Аяк очына гына басып килгән малай ишеккә колагын терәгәндә, Һашия белән атасы ярым пышылдашып әрләшәләр иде.

— Тагын ялынырга кердеңме, Сибгатулла? Бушка җөрмә, зинһар. Күтемне бирсәм дә, сүземне бирмим, шундый холыклы хатын мин. Кушылыйк, дидемме, кушылыйк. Ташла Минҗамалыңны. Алты айдан бала тудырасы миңа, син әтмәлләгән баланы.

— Һашия, дим, төшерт корсагыңны. Күпме сорасаң да бирәм.

— Кит, бер тиен өчен чукынасың бит син. Ялганлап көмәнемне салдырттырыр идең дә шымытырыңны тоттырыр идең! Җөрмә, дим бит блач дия-дия кәпрәеп. Көндез йолдыз күрмәгән кебек күрмәссең син блачыңны, секретарь итеп сайлаттырмыйм мин сине, корсагымны бүлтәйтәм дә керәм беренчегә, җәям дә салам гөнаһыңны. Себерелгән хатыннарың чутсыз, авыл саен өчәр маржа. Партия кешесе азгынланып чит хатыннар түтәленә орлык чәчми.

— Хәзерге вакытта хатын аерырга ярамаганны беләсең бит, Һашия. Андыйларны чикритар итмиләр дә итмиләр инде ул, — дип, борынын лыш-лыш суырган атасын танымады малай. Авылны дер селкеткән аждаһа шулай мескенләнәме? Кем алдында диң син! Үләксә Карга алдында. Учына кысып кына сытасы юкса...

— Үзеңә дә хурлык бит, Һашия, уйнаштан тапкан бала ни инде...

— Хурлыгы-ние бәби белән бергә үтәр, Алла кушса. Миңа бала кирәк.

— Мужыт бездә камсамул оешмасы да ясарлар. Анда чикритарлыкка сине куярбыз. Партия сүзе берәгәйле сүз, ди, ул.

— Көлдермә, күрше, мин нинди комсомол оешмасының башлыгы ди. Яшем кырыкта, бала табып, кан алмаштырып яшәрсәм генә. Сиңа да яшь әти исеме килешер.

— Тилермәсәнә, Һашия. Бушатсана корсагыңны! Мужыт соңрак кушылып китәрбез. Дөнья җайлангач.

— Хи-хи, ышандылар ди синең әкиятеңә. Баладан котылсаң төкермисең дә син, абзыкаем. Йә, чык. Өч көннән урман буена килерсең. Караңгылаткач. Уйлап кил. Йә син, үзең әйтмешли, «чикритар», йә һаман шул складның карак мөдире, ха-ха!

Һашиянең ихахайлап көлүе Рәхимҗанны чүт кенә һуштан яздырмады. Үтүт матай, кулдан ычкына матай! Үтүт урамнан тузан туздырып выжлап очулар. Ахмак ата! Кем белән бәйләнеп буялды бит! Гыйшкыннан башы әйләнеп акылын җуйган дияр идең, аңа тагы ярату! Җаны агач, үзе агач. Азгынлыгы әнә кая илтеп терәде. Тот хәзер «блач»ыңны учлап!

Иртән ул ачуыннан, билгеле инде, матай тәтемәү ачуыннан, атасына төрттерде:

— Карга белән пешергән боткагыз көймәдеме, иптәш «чикритар»?

— Маңка, сиңа ничу иснәнергә, — диде малайның артыннан күзәтүен сизенгән Сибгатулла. — Башың яшь. Пычагым аңлыйсыңмы син?!

Ата кайгыра, яну-көюләре күзеннән ташый иде. Шулкадәр түрә буласы килер икән адәмнең. Юкса Сибгатулла белеме дүрт сыйныфтан артмаган шыр надан. Партиягә алганнары өчен рәхмәт кенә укып утырасы иде аңа, блачка кызыкмыйсы иде. Мин-минлек котыртты атаны, ул котыргач, малай да

котырды: Сибгатуллага — абруй, аңа матай кирәк. Ләкин икесенең дә хыял канатларын кисеп, уртага Карга Һашия баскан. Ул, «мә» дип, йодрыгын әле атага, әле малайга күрсәтә, ихахайлап көлә...

Сер төенен атасы үзе чишмәс кебек. Димәк, Рәхимҗанга аның белән сорашмый-төпченми генә берләшергә кала.

— Чәнчелдер син аны, атай!

Әллә икесенең дә уйлары бер тирәдә бөтерелә иде, Сибгатулла, ашыгып:

— Ничек? — диде.

Рәхимҗан иңбашын сикертте:

— Бусы — синең хәсрәт. Теләсәң — ас, теләсәң — кис, үз ихтыярыңда. Карга белән түшәк бүлешкәндә «ничек?» димәдең, киңәш сорамадың.

— Булмый, малай. Кеше үтералмыйм. Яхшылык белән ризалатырга Карганы. Өн-тын чыгарттырмаска, шул. Син кысылма, яме. Икенчеләй шыпиун кебек иснәнеп йөрсәң, башыңны сугып ярам!

Һәй җүләр ата, синең янавыңнан Рәхимҗанның коты ботына төшкән ди.

Өч көннән Сибгатулла урманга — Һашия белән күрешергә чапты. Малай да яшеренеп кенә аның итәгенә тагылды. Үлән-яфракларны кыштырдатмас өчен, үкчәсенә сарык йоны бәйләде. Төн айсыз-йолдызсыз, дөм караңгы иде. Сибгатулла белән Карга, аякланган агачлар сыман селкенеп, егерме-утыз адым алдан атладылар, аларны күздән югалтмаска тырышып, тыңлана-тыңлана, Рәхимҗан теркелдәде. Һашия күзеннән очкыннар чәчрәткән гайрәтле атасын камыр кебек изеп, җебек, мескен ир итеп әвәләгән, аңа авыз да ачтырмый:

— Миңа үләнәсеңме, иптәш «чикритар»? — дип, юри «секретарь» сүзенә басым ясап үрти-көлә иде.

«Буып ташла, — дип шашынды Рәхимҗан. — Җебемә, тәре бугаз. Матайсыз калдырасың бит!»

Өметен өзгән атасы имән төбенә чүгәләде.

— Уф, — диде. Уфыруыннан йокымсыраган яфраклар шыбырдашып куйды. — Адәм җанын ашаучы икән син, Һашия. Әллә мине үләндертеп рәхәттә яшәрмен дип уйлыйсыңмы? Ярты җанвалит әнәтек Минҗамал. Кул каты минем.

— Мин синең Минҗамал ише кол булмам, иптәш «чикритар». Колагыңны өзеп кулыңа тоттырырмын, тырнак белән генә чиерт. Кыйнашып үлсә үлә безнең Карга нәселе хатыннары, ну иреннән тукматмый.

— Шуңар ир заты сиңа якын бармады. Мин, ахмак баш, кул яктым.

— Яктың икән, хәзер үкенмә, күрше.

— Һашия, җә инде, араны көйлик, бозылышмыйк.

— Син, Сибгатулла, күрәм, өздереп сүз әйтер өчен килмәгәнсең. Уйлап бетермәгәнсең, димәк. Уйла, мин киттем.

Һашия чынлап та кырт кына кыр ягындагы ташландык үләт базына таба борылды. Моннан авылга якын — нибарысы бер генә чакрым иде. Әзрәк баргач, баз кырыеннан тар гына кәҗә сукмагы сузыла иде, йөрәкле икән Карга, чокырга егылырмын дими, йөгерә генә.

Хатынны Рәхимҗан нәкъ баз турысында куып тотты. Куып та тотты, чәч үрмәсеннән эләктереп, баз авызына таба сөйри дә башлады. Көтелмәгән һөҗүмнән каушаса да, Карга бирешмәде, үз чиратында малайның күлмәк якасына ябышты. Әгәр яка шытырдап ертылмаса, чокыр төбенә икәү очасы иде алар. Яка җөеннән умырылды да, Һашия, җан ачысы белән акырып, аска мәтәлде. Төптән яңгыраган ачы аваз колак пәрдәсен дерелдәтте...

Шул мәлдә Рәхимҗанга калтырау сукты. Дер-дер килеп артына утырган иде, чалбар төбен чылатып балактан юеш акты... Әле генә нишләде соң ул? Ник исәп-хисап бирмичә Карганы базга томырды. Әгәр тырмаша-тырмаша үрмәләп чыкса? Бетте бит баш, мәңгегә төрмәдә черетәчәк бит ул. Юк, юк, өскә менә алмас Һашия, баз тирән, аны казыганда озын-озын баскычлар куеп төшкәннәр, имеш. Тора-бара бу гуҗ чокыр астан су белән ашалып тирәнәйгән, төпсезгә әйләнгән, һәм адашкан күпме терлекне йоткан, диләр.

Әгәр берәрсе тавыш-мазар ишетеп коткарса? Һә, кем йөрсен бу җенле үләт базы тирәсендә. Аннан, төпкә кадалганчы ук, җаны күккә очкандыр инде ул Карганың.

Малай исен-аңын җыеп торып басты. Авызын каплап чайкала-чайкала кире урман эченә атлады. Күңел болгана һәм укшыта иде...

Кара төндәге этлеген ул атасына сөйләргә ашыкмады. Әнә Сибгатулла Һашиянең капыл югалуына ничек борчыла: тәмам пошаманга калды, ашавы ашау, йоклавы йоклау түгел. Ничә көн кырынмый, тиресе бөрешкән йөзен төк басты: шүрәле сыман ямьсезләнде ул. Әйдә, газаплансын әле. Кысылма, башыңны сугып ярам, янәсе. Малаеңа бүген түләп бетергесез бурычлы син, карун. Сереңнән күбенеп йөрмә, ачыл Рәхимҗанга, ачыл. Ачылмыйсыңмы? Алайса чукынып кадал.

Сибгатулла чыдамады, беркөнне эчендәгесе тышка бүселде:

— Кил әле, малай. Тс-с, әнкәң ишетмәсен. Теге районга өстемнән жалу бирергә киткән, ахры, ишегендә ничә көн амбар йозагы. Иртә карыйм — күренми, кич карыйм — күренми.

— Тәмугта каты яндыралар, дип, Алласына жалу язса гына инде.
— Туктале, малай, куй шаяртуыңны. Синең белән олылар сөйләшә.
— Һи, синең олылыгың, минем кечелегем. Олы булсаң, Карга Һашияне капшамас идең, әзмени марҗа-калҗа.
— Ялгыштым, малай. Сырт күрше бит, ил-көн сасытмас, дидем.
— Тезләнеп миңа рәхмәт укы, атай. Тәмугта четер-четер яна Каргаң.
— Ә?! — диде Сибгатулла, күзен шарландырып.
— Мә! — диде малай, телен күрсәтеп. — Бетердем мин аны, үләт базына олактырдым. Этем дә өрмәде.
Атаның ирен читеннән саркыган елмаюы табак битенә җәелде.
— Вич мин инде син, малай, — диде ул, улының маңгаена чиертеп. — Яши белерсең син болай булгач, шушы яшьтән башың эшләгәч. Чупылт дисеңме Карганы базга? Маладис! Матай синеке, көпчәге тузганчы чабарсың.
Мактаганга бик эремәде Рәхимҗан, сүз көрәштерде:
— Үзең белән чагыштырма, атай. Мин синең сымак куркак түгел, — диде. — Бер үләксә Карганың канатларын сындыра алмадың. Эшеңне мин эшләдем.
Сибгатулла сөенечле хәбәрдән соң кеше кыяфәтенә кереп бара иде, малайны тиз бастырды.
— Кеше үтереп батырайган берәү! Кәпрәймә, маңка, тыныңны кыс! — диде.
Әйе, ата куркак, һәм аның бу өркәклеге Рәхимҗанны куркыта иде. Сибгатулла барыр да Карганы үләт базыннан өстерәп чыгарыр, җан кыеп үз өстемә гөнаһ алмыйм, дияр. Ә Карга Һашия чыксамы... ул чыкса, хуш, якты дөнья, хуш, арбалы матай! Явыз хатын аны, артына типтерә-типтерә, төрмәгә озаттырачак. Кулында күлмәк якасы... Үзе бер шаһит.
Малай ялгышты. Сибгатулла Һашияне упкыннан араларга җыенмый, утка басып, сайлауга әзерләнде. Авылда ирдәүкәнең югалуын бик тиз сизделәр. Хисапчы иде шул Карга, каш өстендәге күз иде. Кияүдәге сеңлесе көн саен аның йортын бер килеп әйләнә, көн саен:
— Апаны күрмәдегезме, кайтмадымы ул? — дип, Рәхимҗаннарны тинтерәтә иде.
Тавык-чебеш ишегалдына керсә дә, чәр-чәр кычкырышкан күршесенә әнкәсе ярдәмгә ташланды, әз генә бушады исә аның терлек-туарын ашатты, идәнен юды, казан астында ут үрләтте. Авыл кинәт гаип булган Карганың ләчтитен сатып шаулап алды да тынды, ә бу уйламый да, ике йорт арасында чаба бирә! Әлбәттә, Сибгатулла моны өнәмәде. Атасының бүтән тәүфыйклы песи ролен башкарасы юк, ул башлангыч партия оешмасы секретаре итеп сайланган, хәзер үзенең элеккеге Сибгатлегенә кучеп ята, вакытлыча гына бушаткан зәһәрен кире эченә төйи иде.
— Җөрмә анда, ана эт, тукта, — диде ир, хатынына җикеренеп. — Каргаң мужыт мәеттер инде.
Әнкәсе, ничектер тыныч кына:
— Исән лә ул, — диде. Һәм шушы сүзе белән иренең йөрәгенә хәнҗәр белән сызды.
Исән?! Рәхимҗан белән Сибгатулла бер-берсенә караштылар. Икесенең дә күзендә шом иде.
— Кем әйтте исән дип? — Атасы көчкә телен әйләндереп сорады.
Соңгы вакытта бер ноктага карап оеп китә башлаган Минҗамалның карашы нүештә иде.
— Әнә күләгәсе сузыла, — диде ул, шул якка ымлап.
— Фу, дивана, — диде моңа каршы Сибгатулла.
Ә үзенең шуннан соң төн йокысы качты, бәгырен шик корты кимерергә тотынды. Удмурт карчыгы, әнкәсенең сүзен раслагандай, «кешегез исән» дип тырылдатып куып җибәргәч, чәче дә яртылаш агарды...
Рәхимҗан гына тимер кебек нык иде. Егет дөньясын онытып матайда җилдерде. Кайтмый Карга, үләт базында әҗәлен тапты ул. Җил иссә дә калтырама, карун, күкрәк киереп яшә.
Ике ай үтте, өч ай үтте, дүрт ай үтте, исән Карга канат җилпемәде. «Чикритар» тынычланды. Менә кайтыр Һашия, менә кайтыр дип куркып яшәү аны ябыктырган иде: корсагына янә катлам-катлам май түшәлде, ике ияк чыгып, тамак асты салынды. Кичләрен ул счет төймәсендә чалт та чолт взнос керемен саный, карандаш белән тутырган исемлекне сыза-боза, төзәтә һәм канәгать елмая иде...
Малай матайдан тиз туйды. Бала-чага уенчыгы икән ул. Яшьтиләр көнләшер дип көткән иде, көнләшмәделәр. Әллә «тимер ат»ка, әллә чыбыкка атланып чапты Рәхимҗан, берсенең дә исе китмәде. Машина заманы җитеп килә, авылларда сирәк-мирәк кенә «Жигули»лар борын төртә, һәм егет рәвешен алып барган үсмер малайны зур акчалы эшләргә ымсындыра иде. Ул укуын ташлап чуашларга шабашкага ялланды. Ә аларның ат кертеп биетерлек зур-зур өйләрен күргәч, машина арткы планга күчеп, алга шәп кенә йорт салу уе калкып чыкты. У-у, моның өчен мая туплый-туплый биш-алты ел тиреңне агызырга кирәк иде шул. Карун ата нигез яңарту турында уйламый, ул надан «блач» дип этәчләнеп йөрергә дә хатын-кыз кымтырыкларга гына оста иде. Балтачы һөнәренә җиңел өйрәнде Рәхимҗан, кинәнеп эшлә дә эшлә генә иде. Ә беркөнне... беркөнне бәләкәй генә буйлы хатын Карганың җил капкасын этте. Аның кулында озынча төргәк иде. Хатын ишеккә аркылы кадакланган тактаны

шатыр-шотыр каерганда, төргәк җанланды. Алабута баскан ишегалдына «уа-уа» дигән бала авазы таралды. Уа-уа, уа-уа... Бу кыска-кыска авазлар Сибгатуллаларга да ап-ачык ишетелде.

Ата белән ул, тәрәзәне киң тутырып ачып, тирли-пешә бәрәңге боламыгы сыпыралар иде, капкан ризыклары бугазларына төртелеп калды.

...Болай да караңгы төннең отыры каралуыннан дерт итеп уянды Рәхимҗан. Баш очында ниндидер кош күк яктылыгын томалаган да тәпиләрен салындырып эленеп тора, аңардан тәнне пешерерлек кайнарлык бөркелде. Менә ул уктай аның өстенә атылды, мәгәр шул мәлдә егет йөзен кулы белән капламаса, күзне чукып алачак иде. Кан эчеп туенучы бәдбәхет бугай, аны үлек дигәндер. Кемнәрне генә асрамый бу чытырманлы урман. Тотса, канатын канатка, ботын ботка аера иде инде, өркүеннән әзрәк каушады Рәхимҗан.

Ул әле йокысыннан айнымаган иде, ә йокы тәмам качып, башына аң кайткач, әллә нишләп китте. Бу бит Каракош! Ул төшләнми, ул уяу, бу — Каракош! Битенә тигән канат җиленә хәтле анык!

Егет җан-фәрманга Кыязлы юлына таба йөгерде. Әйтерсең коштан качып кына котылып була иде. Басу капкасы төбендә таң аттырды ул, аннан Кызыл чишмәгә төшеп юынды. Халык көтү куганда, кулын чалбар кесәсенә тыккан хәсрәт кияү, як-ягына ялт-йолт карана-карана, Барыйлар тыкрыгына төшеп бара иде. Йөрәкне чемердәткән курку бетмәгән әле. Җенле урыс нигезенә оя корды бугай Рәхимҗан. Шунда ләгънәт кош җәфаларга тотынды лабаса. Йә тәрәзә пыяласы чукып өнне ала, йә бугаздан буа, йә бүгенге сыман өскә ташлана. Әгәр ул әнкәсе саташкан Каракош булса?! Һай, анықын чынга алсаң! Исәр карчыкның күзенә ни күренмәс.

Бәриянең атасы турларыннан узган көтүгә сыерын кушып маташа иде, булачак кияүне өнәмәгән төсле, ачылып китмичә генә сәламләде. Өйгә кер дип кыстамады, капка төбендәге буяулары чатнаган эскәмиягә артын төртте. Рәхимҗан да аның янәшәсенә утырды.

— Ишеттек, — диде карт, ачу китерерлек дәрәҗәдә тыныч тавыш белән сүз башлап. Сибгатуллаларның иске бәдрәфе генә янган диярсең, йөзендә ник бер борчылу галәмәте чагылсын! — Ишеттек. Әллә ниткән әкәмәтләр сез.

— Тел төбеңне аңламадым, бабай?

Бабай, дигәч, карт таягын дык иттереп җиргә кадады. Яратмады.

— Әй, Мөслих абзый, — дип төзәтте егет.

— Түшәгән бер гүрничәң дөрли, олан. Ышту әйтерең тагы, әкәмәтләр дими. Ни тәмәке төпчеге ыргытмыйлар, ни...

— Ярар, Мөслих абзый, ярага тоз сибеп утырмале син. Минем йомыш икенче иде. Кызың белән безнең башлар исән-сау бит әле.

— Муеныгыздадыр башыгыз, муеныгызда. Шуннан?

— Озын сүзнең кыскасы, мин килдем.

— Кая килдең? — диде Мөслих, аптырап.

— Соң... Бәрия янына, бергә-бергә яшәргә. Өегез болын хәтле, иркен, киң.

— Бездә яшәргә килдем дисеңме? — дип сорады миңгерәгән карт.

— Шулайрак дим, Мөслих абзый.

— Синме, олан? Пәртәйни сикритар Сибгатулла малае көтүче Мөслихкә йортка керәме?! Хурланмыйчамы? Атаң заманында чыбыркы түтәсе белән сугып авыз-борынымны канга манчыган иде, көтүне начар саклыйсың, хәерче бете, сыерлар уҗым таптый, дип. Шушы хәерченең кызына үләнгән генә җитмәгән, инде түреннән җылы урын капшыйлар.

— Нишлим инде, Мөслих абзый. Бәрия, сәләмә, ди, атай йортына бармый.

— Жук! Теләсә кайда яшәгез! Ялгызак карчыклар авыл тулы, өйдәш итсен берәрсе. Әй Хода бәндәсе, ансы да батмый икән, чөнки дә син булган җирдә ут-күз чыга, олан. Зәхмәтле син.

Картның тешсез авызыннан «без-без» авазлары чыгарып аны хурлап утыруы егетнең үпкәсен күпертте.

— Безелдәмә, ичмасам, кукшаңгы*! Йөз белән сөйрәлгән кызыңа өйләнгәнгә рәхмәт укы. Этләр аны иснәми дә, пес кенә итә.

Карт гарьләнер, тузыныр дигән иде ул, тик Мөслихнең йөзе дә чытылмады.

— Әй, олан, мең белән сөйрәлсә дә, безнең кыз артык сиңа, убыр карчыгына үләнсәң генә, — диде.

Ачуыннан тиресенә сыешалмаган Рәхимҗан картның таягын тибеп очырды.

— Атай белеп танауыңны җимергән, кукшаңгы! Бар, Бәрияне уят, итуса дөньягызны ишеп бер чүмәләгә өям.

Тамызса, каты тамызыр бу дип шүрләп, карт пышан-пышан гына капкага юнәлде. Озакламый өйдән, йокылы күзләрен уа-уа, иңенә шәл бөркәнгән Бәрия чыкты.

— Ник таң тишегеннән шаулашасыз? — диде ул, ризасыз гына. — Әтине дә үпкәләткәнсең.

— Ишеттеңме?

— Нәрсәне?

— Кичә йорт янды.

— Сөйләделәр инде кибеттә.

— Сөйләделәр, имеш! Җаның бармы синең? Килеп әйләнер идең хет. Хатын булырга җыена тагы!

— Карале, Рәхимҗан, синең янган йортыңда минем ни катнашым бар, һич аңламыйм. Йокымны өздең менә. Керәм дә ятам. Сүзең булса, кич әрәмәлектә көт, — диде кыз, егетнең кайгысын туп кебек баш аркылы гына чөеп.

Рәхимҗан төнтәеп өйләренә атлады. Дөньясы салкын һәм шыксыз иде. Нишләп кинәт кенә тормышның рәте-чираты китте соң, ә? Кинәт дип... Кинәт тә түгел бугай инде. Шул хатын гына яртылаш сулап, яртылаш йоклап, яртылаш көн күреп яшәргә мәҗбүр итте түгелме соң? Әйе, әйе, үлгәнгә чутлаган Карга кайтты да түм-түгәрәк, туп-тулы дөньяны яртылашка калдырды. Шуннан китте, китте, китте...

Сибгатулла җансыз йортка сулыш өреп азаплана, тупсасы каерылган капканы төзәтә иде.

— Әнкә кая? — диде егет.

— Әһә, кайтмыйм дигән үгез капка баганасын сөзә. Кудымы хәерче Мөслих? Мин бит аларга табан юыртканыңны күрдем, малай. Әз генә дә горурлык юк икән синдә, субакы.

— Әнкә кая? — дип кабатлады Рәхимҗан.

— Авырый. Ник ул сиңа?

— Күп белсәң, тиз картаерсың, — дип, егет өйгә ыргылды.

Кулындагы чүкечен ташлап, атасы аның артыннан иярде һәм шыр ялангач ызбадагы иске тимер караватта керпе сыман бөгәрләнеп яткан карчыгын гәүдәсе белән ышыклап басты.

— Тия дисең мәллә, карун? Тимим, сорыйм гына, — дип ярсынды Рәхимҗан. — Әнкә, ач әле күзеңне. Сине саташтырган кош нindирәк ул?

Карчык:

— Ка-ка, — диде.

— Синең тавык кебек какылдавыңнан ни мәгънә, әнкә, авыз тутырып әйт.

— Караватка бәйләп телдән яздырдың да, инде сөйләтәсең килә, — диде атасы. — Каракош димәк була ул.

— Каракошмы? Дөресме, әнкә?

Әнкәсе, пыялаланган күзләре акайганчы көчәнеп, тагын «ка-ка» диде.

— Ие, Каракош шул, — дип җөпләде Сибгатулла. — Син, малай, кызмале, суын. Мин дә бит йортың янар алдыннан гына кыекка кунган бер килбәтсез зур кош күрдем. Кып-кызыл күзле кош. Тәһарәт аладыр ием, бу тора канатлары белән кояшны томалап. Әнкәң белеп тыкылдаган, ахрысы.

— Син дә ычкынасың, картлач, сез ике пар тиленәр.

Рәхимҗан бакчага чыгып китте. Уртак койманың баганасы черегән, ул Сибгатуллалар алмагачына таба кыйшайган иде. Егет шуның бер ягын җилкәсе белән күтәреп турайтты. Карга Һашия кызы ишегалдында бәбкәләр ашата иде.

— Әй, тупый танау! Сине бүлнистә кәкрәйгән, диделәр бит, — дип, койма аша гына сүз очырды Рәхимҗан.

Сафия, күлмәк итәген сыпыра-сыпыра:

— Терелдем инде, — диде. — Сез өченче кат яндыгызмыни?

— Янмадык, безнең өйгә кояш мәтәлде.

— Тәүбә диң. Әнкәгез дә хаста икән.

— Хаста, хаста, — диде егет, күзе белән берәм-берәм бәбкәләрне буып. Әрҗәсе белән сарайларына куйса, төнлә бу сары йомгакларны «тәгәрәтергә» кирәк. Әнкәсенә ике тамчы су кебек охшаган кызыйга үчегәсе килә иде. Карга да карга, монысы да карга!

Рәхимҗан алмагач төбенә сузылды.

— Чык, малай, булыш, — дип эндәште атасы.

Егет бугазы ертылганчы үкерде:

— Саруымны кайнатма! Сиңа рәхәт, карун. Синең бер аягың кабердә, яңа йорт дип дәртләнмисең. Иске-москыңны төкерегең белән ябыштырып та яшәрсең, ә Рәхимҗан кая барыр, кем куышына баш куяр?! Аңа йортка да керергә ярамый, имеш! Горурлыгыңнан бөкләп-бөкләп аркан иш, надан «чикритар»! Сиңа карыйлар ди, көт. Син — кол, Рәхимҗан — хаким. Бәрия йортка кертергә ризалашмаса, быел сезне улыгыз сарайда кышлатачак. Ызба — киленегезгә! Син үзең гаепле, атай. Һашияләр белән чуалмасаң, бүген бердәнберең урам этедәй шыңшып йөрмәс иде. Бөтен бәхетсезлек синең азгынлыктан башланды.

...Бәрәңге боламыгын Рәхимҗан су белән юдырды.

— Һашияләрдә кемдер бар, атай!

— Ке-кем? — диде Сибгатулла, буыла-буыла йөткереп. Бәрәңге кисәге тын юлына эләккән иде.

Малай дык-дык аның аркасын кыйнады.

— Шудымы, атай?

— Сукма, кабырганы сындырасың! Әй, Минҗамал, кем ул Каргаларда, белеш.

— Ниндидер балалы хатын, хәерче чегән, ахры. Алар хуҗасыз йортларны басарга мачтыр.

Ата белән малайның йөзе кәгазь сыман агарган иде. Икесенең дә күзендә шик күләгәсе чайкалды.

Әнкәсе күршеләреннән бәхет кошы тоткандай елмая-елмая йөгереп тә чыкты.

Ул:

— И-и, танымадыгызмы? Һашия кана! Әйттем лә, исән, дидем лә. Сеңлесеннән сөенеч алыйм, булмаса, — дип гөрләде, өстәл янындагы ике тораташны күрмәде. Ә алар чынлап та таш иде.

Хатыны ишекне япкач кына, Сибгатулла авыз эчендәге телен кыймылдата алды:

— Бет-тек...

Атасы әйтмәсә дә, Рәхимҗан бетеп ята: чалбар төбе юешләнгән, тәнне калтырау биләгән иде.

— Ми-мин а-тай, ка-качам, — диде ул, урындыгыннан аска шуып.

— Өстәл астынамы, күсәк?! Ерак җыенгансың! Безгә хәзер уйлашырга кирәк. Ничек баз төбеннән калыккан ул, җә?! Монда ми кайный. Берәрсе коткарганмы?

— Базда бәбиләде микән?

— Кайда бәбиләгәнен милисиядә белгертерләр, күсәк. Сөйләр Карга энәсеннән җебенә кадәр.

— Юк, мин милициядән тоттырмыйм! — дип еламсырады үсмер егет.

Һәм шул көннән чормада качып ята башлады. Гаҗәп, Һашияләр тарафыннан җил дә исми иде. Җанбәгырьгә чәнчеп бер атна үтте — эзләп килмәделәр, ике атна үтте — һаман юк. Кайчан төрмәгә ябар икән дип көтә-көтә болар тере мәеткә әверелсен, ди микән Карга. Рәхимҗанның таза йөрәге бер җепселдә генә эләгеп торса, картаю ягына авышкан «чикритар» ата тәмам изрәде. Моңарчы чәче яртылаш кына агарса, хәзер ул тузганак төсле ап-ак башлы булды.

Малай бер утыра, бер баса. Көннәр буе чорма тишегеннән Һашияләрне күзләде. Карга тышка сирәк чыга, күбрәк ишегалдында аның сеңлесе кайнаша: бауда бала чүпрәкләре киптерә, су ташый, тавыкчебешкә җим сибә иде.

Туйды, ялыкты иңе-буе тишектән артмаган дөньядан Рәхимҗан.

— Бүтән мин чормада сөрсемим, — диде ул атасына. — Без юкка койрыкны кыстык, Һашия базга кем мәтәлдергәнен абайламаган ул. Караңгы иде бит.

— Күлмәк якасы нәрсә?

— Фи, авылда бөтен малай шундый күлмәк кия иде. Әнкә Каргаларга керештерә, ниләр каркылдый ди тегең.

— Чирли, ди, яман. Аяксызланган, ди. Йомык, ди, ләм-мим, ди. Баласын да сеңлесе генә тәрбия кыла икән.

Малай атаның нурсыз йөзенә карап ыржайды:

— Кызы кемгә охшаган икән соң, иптәш «чикритар»?

Сибгатулла тиз сөялгә басты.

— Иртә теш агартасың, малай. Хәлләнгәч, милисиягә җәвит итә сине Һашия, — диде.

— Безнең синең белән кендекләр береккән, атай. Партияңнән себерке белән кумаслар димә, яме.

Ә беркатлы әнкәсе аларның куырылып яшәвен сизми, Һашия йортындагы хәбәрләрне өйгә ташый, иренең суктырып-суктырып сорашуларына түкми-чәчми җавап бирә иде.

— Карале, Минҗамал, күрше бу гумер кайда себерелгән?

— Ирсез корсак күтәргән хатын кайда себерелсен, каладагы туганнарында яткандыр.

— Карале, Минҗамал, сиңа гүпчим серен ачмыймы Карга?

— Зерә сүзсез Һашия. Телен кистергән диярсең, Аллам.

— Карале, Минҗамал, Карганың аяклары нык зәгыйфьләнгәнме соң?

— Чире хакында сүз кузгатмый шул, яшерә.

Аның һәр җавабыннан соң ата белән ул серләрен тагын да эчкәрәк йотып, иркен сулап куя иде. Әмма беркөнне икесенең дә сулышы кысылып, эченә шөр йөгерде.

— Һашия райунга җыена, духтырга, юллык акча бир, ди.

Минҗамал сандыгы янәшәсенә тезләнгән иде, Рәхимҗан ыжгырып аңа ябырылды:

— Бирмә! Җәяү тәпиләсен!

— Эһе, малай хак, — дип ата да кушылды. — Бирмә, юк акчабыз, диң.

Доктор бер сылтау гына, көч җыйган Карга аларны милициягә әләкләргә бара икән, ниһаять!

— Алладан куркыгыз, — диде ул. — Кешенең аяклары шешкән, ничек җәяү унбиш чакрым тәпиләсен бахырым. Сезгә аның ни начарлыгы тиде соң? Дөнья булгач, әрләшеп-талашып та алгалыйсың. Атагызны суймаган ла ул анук дошман күрергә!

Сибгатулла җеннәре дулап бәргәләп ташламаса, әнкәсе Каргага тәки акча бирәсе иде...

Бу юлысы бәладән шулай арындылар. Тик торган саен зурая барган куркынычның авызын йодрык тыгып кына капларга мөмкин түгел иде. Нидер кылырга, нидер...

Егет көн-төн усал уй белән йөрде-йөрде дә шундый карарга килде: авыл ишелеп йоклагач кына ишеген тыштан терәтергә дә ут салырга Һашиягә! Баласы белән икәү чиный-чиный янсыннар әйдә. Ул инде бакчада җир казыган булып Каргаларга кай тишектән керергә, кай җирдә бензинга манчылган

чүпрәккә шырпы сызарга икәнен дә чамалап куймакчы иде, шунда уртак койма буенда кыштырдау ишетте. Якынрак барды һәм... чүт аркан аумады. Тезләнгән Карга койма кырыеннан үрмәли иде. Менә ул, башын күтәреп, чем-кара күзләрен Рәхимҗанга текәде. Хәзер чәрелдәп кешеләр җыя бу дип шүрләгән төстә егет як-якка каранды, әмма Һашия кычкырмады, ике күзе белән тигәнәк кебек кадалды да калды. Рәхимҗан әсәренде, карашын читкә алырга тырышты, алалмады, күзләр аны үзенә суыра иде... Ләкин куркуыңны сиздерергә ярамый. Ул көрәк сабына ныграк таянды да:

— Нәрсә чекерәйдең, үләксә? — диде.

Кинәт алмагач ботагына кунган карга йөрәкне тибүеннән туктата язып шар ярды:

— Кар-р, кар-р!

— Әнә, — диде егет. — Ишкушын көтә, бар, аның белән оч!

Кошка төртеп күрсәткән арада, Һашия ярыкка чумгандай юкка чыккан иде... Рәхимҗан төксәрде һәм абына-сөртенә бакчадан чыгып качты.

Шабашкага киткәч кенә аның куркуы басылды. Әмма йөрәккә оялаганы һаман авызын купайтып тора иде әле. Таң атса да, кояш баеса да, күңелгә тынычлык иңмәде, эзгә бастырып милиция килер сыман иде.

Чуашларга бура бурап, көмешкә чөмереп кайтып барган кичтә Рәхимҗан капка төпләрендә туңкайган Һашияне күрде. Алай якты дөньяга чыкканы юк иде әле Карганың. Әнә ул ерактан ук егеткә күз угын очырды. Кара, ничек тез буыннары калтырый. Йә, күпмегә сузылыр бу куян мескенлеге?!

— Әй син, Карга, — диде Рәхимҗан. — Шыпырт кына каргыйсыңмы? Дөмек, дисеңме? Синең ишеләрнең каргышына төкердек без. — Ул батыраеп якын ук килде. — Тө-кер-дек, — диде. Һәм төкерде, әмма лайлалы төкереге үзенең күлмәк изүенә сыланды.

Һашия берни дә дәшмәде... Күзен дә яшермәде...

Сибгатулла, улының башбаштаклыгын өнәмичә:

— Их, малай, бәладән котылып барабыз бит, тишегеңне кысып кына йөр инде, ачуын китермә Карганың, — дип орыша башлаган иде, егет беренче мәртәбә күкрәгән йолкый-йолкый улап елады:

— Ярты җан белән яшә-ә-этте! Юк-ка! Базга мәтәлдерүченең мин икәнен белми у-ул!..

— Белә, — диде атасы, өздереп. — Белгәнгә шулай күз белән җәзалый, Һашия усал-унтагай хатын. Безне калтыратудан тәм таба ул.

— Юк, белми! — дип бәхәсләште Рәхимҗан. — Күптән төрмәгә тыгар иде. Карга нәселе үчле халык бит. Давай, атай, онытыйк, кешечә аяк сузып яшик.

— Онытырсың, пычагым. Шундук исеңә төшерер.

Һәм төшерде Кара Карга. Ертылган күлмәк якасын уртак койманың казыгына чыгарып элде... Өч көн җилфердәде чүпрәк.

Рәхимҗан тагын кара кайгыга батты.

— Өшкерттерә милициядән, — диде.

— Үзең гаепле. Салмыш баштан әтәчләнеп төкерендең, — диде атай. — Тишегеңне кыс, дидемме, җә?

Аһа-һай, бу дөньяның сәерлеге! Вакыт та сүтмәслек җөйләр бар икән бит, ә! Һашиянең кызы үсте, Рәхимҗан киң җилкәле әзмәвергә әверелде, партия таркалып, «чикритар» Сибгатулла «блач»тан сөрелде, картайды, ә ике йорт арасында һаман суык җил исте. Бу хакта ачыктан-ачык игълан ителмәсә дә, Рәхимҗан өчен иң хәтәр дошман Карга Һашия, Һашия өчен, һичшиксез, Рәхимҗан булды. Дөрес, Кара Карга корбанын бүтән күз белән ауламый, ул әҗәлен көтеп үлем түшәгендә ята иде. Кызы су гына эчереп тора, ди. Көннәре санаулы, ди. Аталы-уллы шат иде. Бигрәк тә Рәхимҗан сөенде: Карганың дөмегүе аңа тәҗел кирәк, ул куян йөрәге белән яшәүдән гарык иде.

Кышкы айларның берсендә Һашия җан тәслим кылды. Аның җеназасын зиратка озатканда, егет: «Рәхәтен күрмәм, Карга төрмәдә башымны черетер», — дип, күңеле тартмыйча гына төзегән яңа йортында учак тергезде. Шатлык-сөенечнең иге-чиге юк иде. Ниһаять, ниһаять! Ул тимер кыршаудан мәңгегә азат! Менә өйләнер һәм бер кайгысыз бәхетле көннәр башланыр.

Ата белән ул Каргадан котылу шатлыгын утырып юдылар. Сибгатулла карт исерде һәм өстәлгә янтаеп пышылдады:

— Мин бит... малай, Һашияне яраткан ием, — диде, чепи күзеннән мөлдер-мөлдер яшь акты. — Алдамыйм, чын мәгәр, яраткан ием. Базга ыргытып яшьләй имгәтмәсәң, чәчәк кебек хатын ие ул...

— Шыттырма, атай. Бездә синең белән мыскал да хатын-кыз ярату юк. Алар да безне сөйми. Әллә Бәрия миннән биһуш дисеңме? Аның кадәр гыйшкыңнан тилергәч, баздан ник чыгармадың, йә? Ха-ха-ха! Син аны түгел, «блач» яраттың, иптәш «чикритар». «Блач» Һашияңнән тәмлерәк иде. Сафия кызыңдыр бит, чакыр, мин синең атаң, дип, итәгенә тозлы күз яшеңне түк.

Атасы кул гына селтәде.

— Һашия хәйләсе. Бүтән орлыктан ул бала, мин аңа ниткән ата ди. Безнең нәселгә дә тартмаган кыз, чат кара, — диде.

...Алар җан тынычлыгына тиенеп өч кенә көн яшәделәр. Дүртенче көндә ут, төпсез күккә телен суза-суза, яңа йортны «ашады». «Инде!» дигәндә генә тормыш арбасы шылтырап кире таудан аска тәгәрәде...

Шуннан бирле Рәхимҗанның хыялдагы бәхет алмасына корт тешен батырды. Әнә агачтан җиргә тишекле-челтәрле алмалар коела, ә тазасы алсуланып ботагында тирбәлә. Ул көзгә хәтле тамыр суы белән туеныр, йомшак җилдән иркәләнер, кояш нурыннан балланыр-кызарыр. Рәхимҗанга да, Каргадан арынгач, язмыш тап-таза бәхет алмасы сузган иде. Ә ул нигәдер туфракта ауный, аны корт кимергән...

Бакча рәшәткәсеннән муенын сузган атасы:

— Малай, чык, булыш, — дип ялвара иде. Ул күкрәгенә тып итеп төшкән бер черек алманы аңа томырды.

— Мөгрәмә, капкаң белән чукынып бет, — диде. Һәм эңгер җәелгәнче кузгалмады, аннары торып коедан су тартып эчте дә яхшы ат тизлегендә әрәмәлеккә юыртты.

Киләм, дигән Бәриянең эзе дә юк иде. Гарьләнде егет, чүмәшеп тезенә йодрыгын бәрә-бәрә ыңгырашты. Шулай инде, шулай, йорт-җирсез ир кемгә хаҗәт. У-ух, хәерче көтүче чыбыркылары! Сытып, эчәкләрегезне саварга иде бер! Саварга иде...

Ачуыннан бүртенгән егет, җил-җил атлап, Бәриярләргә китте. Мөслихләр зур бүлмәдә кунак мәҗлесе җыйган, җырлап-көлеп күңел ачалар иде, борын сызгыртып мышнаган әзмәверне күргәч, һәммәсе дә шымаеп авызын япты. Бәрия иң түрдә балкып утыра иде, егет аны урындыгыннан йолкып кына торгызды.

— Әйдә, әнчек!

Мәҗлес исәйгәнче, ул кызны, йодрыгы белән аркасына кадый-кадый, ян бакчага куалап керткән иде инде.

— Рәхим, дим, Рәхим, нишләвең бу? Апалар читтән кайтты, алардан оял, — дип чинады Бәрия, Рәхимҗанның келәшчә төсле кыстырган бармакларыннан ычкынырга уйлап әле уңга, әле сулга тартылды.

— Патшалар кайтсын, миңа димәгәе! Ник вәгъдәңне боздың? Кич сөйләшербез, диюче бит син!

Ул, шалдыр-шолдыр агачтан чикләвек коямыни, ике куллап кызны селкетергә кереште. Кинәт ачуын үпкә-рәнҗү алмаштырды. Күр, аның берәүгә дә кирәге юк. Шушы күшеккән җанына хет өч кенә тамчы җылы тамызсалар иде! Җәлләсәләр иде аны, юатсалар иде.

— Бастырып суярга да каберстанга озатырга сине, кызый!

— Һи, мине каберстанга, тек сине туп-туры төрмәстанга инде, алайса, — дип телләште Бәрия, һәм шушы янавы белән бәгырьгә чәнечте. «Төрмә» сүзе ничә еллар буе аның котын очырды бит.

— Йә инде, — диде егет, капыл йомшарып. — Уен белән чынны аермыйсың, ахры.

— Сүзеңне үлчәп сөйләсәң, аерырбыз. Йортка керәм, дип, иртән этине җенләндергәнсең икән. Синең үкчәгә ут ияреп йөри, безне дә яндырмак буласыңмы? Җә, кысма беләгемнән, шаяртам гына. Әти йортында миңа да урын тарайды, йөрәк маем. Апалар төянеп Себердән кайтты әнә, бөтенләйгә, өч бала белән. Лутчы тагын йорт салырга кереш.

— Бетемне сатыпмы?

— Һи, сездә акча — бер букча. Атаң ике яклап талады халыкны: колхоз малын сатты, взностан чәлдерде.

Сүз төгәлләнмәде, кызның туганнары ишегалдына ишелгән, сеңелләрен эзли иде, егет бакча артыннан гына тыкрыкка шылды.

Көрсенә-көрсенә Сибгатулла карт улына болай диде:

— Удмурт багучысына барып егыл син, малай. Нилектән пажар чыкканын сорарсың. Өч тапкыр бит, өч. Ул дөресен әйтер. Мә, пинсәдән ун мең, баккан өчен карчыкка бирерсең.

Рәхимҗан атасының җәлли-җәлли биргән акчасына җирәнеп кенә карады.

— Аның телен синең ун тиенең түгел, менә бу нәрсә чишәр, — дип, ишек башындагы терлек чала торган пычакны алып картның борын төбендә уйнаткач, чалбар каешына кыстырды.

Тузганакка кинәт җил бәргәндәй, Сибгатулла чайкалды.

— Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла! Ни сүз бу! Багучы белән иплəп сөйләш. Янап-нитеп каһәренә эләкмәгәең, малай.

— Эләкмәбез, — диде егет. — Карчык белән безнең очрашкан бар, атай.

Кояш әле уянмаган, ә карчыкның капка төбендә халык мыжлаган иде. Монысында Рәхимҗан тәҗрибәле иде, капкага якын да бармады, бәрәңге бакчасыннан иелә-бөгелә ишегалдына элдерде. Хәзер ыштын-пыштын гына йодрык белән суксаң таралачак өйалды ишеген ачарга кирәк иде. Ул теше белән тупсаның күгәргән кадагын суырды.

...Багучы идән уртасындагы сулы ләгәндә балалар кебек каурый йөздерә иде, бугазына терәгән пычактан керфеген дә селкетмәде.

— Мингар килеп ятуын төнә үк мәгълүм, — диде. — Эчеңдә явызлык болдырый. Болдыр-болдыр, болдыр-болдыр...

— Болдыратам хәзер, шайтан әшнәсе. Бик белдеклеләнгәч әйт: ник килдем мин? Суям әйтмәсәң!

Кулның җегәре китеп маташа иде, ул пычак сабын катырак кысты, әмма пычак, елан кебек шуып, ләгәнгә чумды, идәнгә су тамчылары чәчрәде.

Карчык яулык очы белән битен сөртте дә:

— Ни күреш суда? — диде.

— Син, — диде Рәхимҗан, әллә карчыкка, әллә ләгәнгә тибәргә белмичә. — Уйнап утырма монда. Йортларыма кем ут төртте, шуны тап!

— Ыһы, каурый аша бактым. — Карчык аның әмерен колагына да элмәде, үзенекен такылдады. — Кап-кара чокыр... Төбе җәһәннәм түбәсенә тиклүк йиткән, аһ тирән! Бакчы, бак. Анда катын җылый... Яуызлыгыңны үлчәргә бизмән җитмәс. Син төртеп төшергән бичара шышыдыр... Атаң берлән тәү катыма килдең — сүләшмәдем, ялгызак килдең — кудым, чөнкиләр сез тәмуг кисәүләре, сезгә багу — гөнаһның гөнаһы...

— Тукта, җен, юкса ипи шүрлегеңне ватам. Исән чагында Һашия үзе зарландымы?

— Мин ангыр гумер күрмәем, мона суда шәүләсен тәү шәйлим, — диде карчык. — Айгырның утлы җаны кәзер кошта... Сингарның ызба кыегына куна да уты чәчелә җанынннан. Каракош ут сала, кап-кара кош.

Рәхимҗан, үртәп, авызын чалшайтты:

— Ник ул башкалар йортын яндырмый?!

— Чөнкиләр сингарда хатын ләгънәте, ангарга ут йоттыручы син. Хәзер мин утны сүндерәем, тик сингар сүз каты: кара төстәге кошларга тимә, аларны эзәрлекләмә. Катын җаны шунда тынар, үч алмас бүтәнли, үз җае берлән күк катына ашар. Амин, нокта.

Егет янды-пеште, маңгаена бөрчек-бөрчек тир бәрде. Ни ди, ә? Кош ут сала, ди. Әнкәсенең дә Каракош дия-дия акылы зәгыйфьләнде. Аны балага санап, әкият сата болар. Мөгаен, сүз берләшкәннәрдер. Җәзадан куркып, шыр җибәреп яшәсен, дигәннәрдер. Моннан соң күктә карганың әсәрен дә күрмәссез! Каргасын да, Каракошны да меңгә чәрдәкләп каурый яңгыры яудырачак ул.

— Мин сиңа ышанмыйм, чепи күзле әбекәй. Җаны кошка күчкән хатын җәһәннәм упкынынннан ничек өскә үрмәләгән?

Карчык:

— Монысын кандаш туганыңнан төпчен, — дигәч, Рәхимҗан ирексездән телен шартлатты. Кандаш туган?! Анасын саткыры, Сафия аның сеңлесе булып чыгамы? Атасы шапырынды бит әле, Һашия хәйләсе, бүтән орлыктан ул бала, мин аңа ниткән ата, диде. Аһ, хәйләкәр карун, аһ, сакаллы аңгыра!

Юл буе атасын әрләде егет. Һәм бөтен бәхетсезлегенең башын аңардан күрде.

Карт һаман йорттагы тишек-тошыкны ямый иде.

— Нәрсә, малай? Ни диде багучы?

— Атаң шакшы җан, диде.

Сибгатулла ничектер кечерәеп китте, тузганак башы җилкәсенә батты.

— Заманасы дөрес яшәтмәде бит аның, малай. Бездән гыйбрәт ал да, син туры юлга бас инде, хаталанмыйча, гөнаһ кылмыйча тереклек ит. Ходайдан кичерү сорап ялварсаң, шәт, иншалла, ул ишетер.

— Һи, карун, син, миннән уздырып, дөньяны дер селкетеп, айгыр кебек кешнәр идең, көч-дәрманың кимеде шул. Адәм, көче бетә башлагач, Алла, дия, тәүбә, дия инде. Булды, минем белән бәхәсләшмә! Күпме генә Алла димә, чабуыңдагы гөнаһларыңны кояр өчен күпме генә мәчеткә йөрмә, намаз укыма, шайтаннар сиңа тәмугта урын әзерләгән... Әнкә йоклыймы?

— Аны Сафия мунча юындыра.

— Ә-ә, Сафияме? Мин шул кызың турында әйтеп әнкәне сөендерим дигән идем. Сибгатулланың күршедә генә газиз балакае яшәгәнен белсен әле ул.

— Малай! — Карт аңа инәлде. — Әнкәңнең йөрәге моңар чыдамас. Ни усал Һашия дә аны кызганды, серен ачмады.

— Ә мин ачам, атай. Сиңа үч итеп ачам. Сафия минеке түгел, дип, ник алдадың?

— Үз гөнаһым — үземә, әнкәңне кызган, малай.

— Бер шартым бар, яме. Мылтык тапсаң, дәшмәм.

— Бәй, ник ул сиңа?! — Гаҗәпләнүдән Сибгатулланың йөзендәге җыерчык сырлары тирәнәйде.

— Хәтерлисеңме, атай, сез Кәҗә Газизулласы белән әрәмәлектә мылтык атыш уйный идегез. Паф та паф, паф та паф чыпчык чүпләдегез. Хәзер минем чират. Әнә! — Егет Сафияләр бакчасындагы тупыл агачларына ымлады. — Бүктәр-бүктәр карга оясы. Мин аларның нәселен корытам.

— Карга затының ахырзаманда да бетәсе юк, малай, бала-чагаланма. Әйдә, нигезгә туфрак ташы. Кышка кирәселәребез бар, бөтен җирдән җил өрә. Кошларның сиңа ни зыяны тигән ди әле.

— Шуларның берсендә Һашия җаны, имеш, атай. Ха-ха-ха! Матур әкият, әйеме? Син, карун, моңа ышанасыңмы?

— Әй, бу көннәрдә барыбыз да тилердек бугай. Курыкканга куш күренер, ди. Каракош дигәннәре дә шул куркудан туган галәмәттер. Йорт-җир тирәсендә нинди генә кош очмас, ашарга эзли күбесе, тавыкка сипкән бодайга да төшә. Әнкәң чире синең дә башыңа йөгермәгәндер лә?

— Син, картлач, боргалама, яме. Мылтык, диләр сиңа, мылтык. Сора Кәҗәдән, куян ата малай, диң.

Сибгатулла карт сукранып кына Газизуллаларга китте. Сафия белән Минҗамал култыклашып мунчадан чыгалар иде, ызба нүешенә сөялгән Рәхимҗан кызның йөз-кыяфәтеннән атасының чалымнарын эзләде. Җир — кара, Сафия җирдән кара иде. «Чегән арбасыннан төшеп калган нәстәкәй» диде егет, үзалдына ачуы кабарып. «Әнкәсе янында тикмәгә генә сырпаланмыйдыр бу. Тәки тындырмадылар бит җанны, башта анасы, аннары баласы...»

Сафия баскычка җиткәнче аны күзе белән чәнчеде ул. Һәм, шелтәләп:

— Көпә-көндез кем мунча керә, йә? — диде.

— Минҗамал апага атап якканыем, кичкә таба хәлсезләнә ул, — диде кыз, гаепле кеше сыман. — Чабынырга себерке генә булмады менә.

— Бер себеркеңне җәлләмәскә иде.

— Себеркеләр чормада. Әнкәй үлгәннән бирле анда ниндидер кош пырхылдый. Менәргә куркам шул.

Кинәт Минҗамал карчык, күзләрен шарландырып:

— Ка-ка, — диде, кулын бутый-бутый нәрсәдер аңлатырга азапланды. Ул әле һаман ипкә килмәгән иде.

— Какылдамасана, тавык! Бар, кереп ят, — диде егет, карчыкны өйгә куалады. — Нәрсә дидең син, кызый? Кем пырхылдый дидең?

— Кош, дидем. Абау, нишләде битең, Рәхимҗан абый?! Кып-кызыл!

Кош, кош! Әһә, димәк... чормага оялаган. Багучы аңа тимә, диде. Ух-ух, мылтык кына юнәтсен Рәхимҗан, бәдбәхетнең йонын пырылдатачак.

— Ник һавага терәлдең, тай! — диде ул кызга һәм шаулап кан аккан бит очын уарга кереште.

Сафия:

— Бетми, иягеңнән муеныңа ага, — дип, аңа төртә-төртә капкага таба чигенде...

Ә Рәхимҗан котырган үгез халәтендә иде, аның күзенә ак-кара күренми, бар уен Каракош биләгән, тизрәк Сибгатулла кайтсын да мылтык кына тоттырсын, ул җәза сәгатен шунда ук билгеләячәк.

Мылтык алып кайтты атасы. Күзен кан баскан улына әсәренеп карады.

— Төсләрең әллә нинди, — диде. — Хәерлегә түгелдер бу, бала. Гөнаһыңа гөнаһ өстәп кошлар үтермә, ниятеңнән тыйлык. Каргалар бала чыгара, балаларын очыргач туздырырсың ояларын, инде бик тәкатең корыса.

— Миңа акыл сатканчы, үзеңне тикшер, атай. Син түгелмени ул шакшыга буялып яшәүче? Әле дә синнән марҗа исе аңкый. Хәзер генә бит Аллаң исеңә төште, хәзер генә тәүбә дип җиргә баш орасың. Бозык Сибгаттән кем яралсын? — Рәхим яралган!

Ул картка иң кызык хәбәрен әйтмәде, яшерде. Каракош бар, Каракош әкият түгел, ул чормада яши. Багучы ялганлады дияр идең, хәзер генә Сафия дә шуны раслап торды. Кошта чынлап та Һашия җаны микән? Рәхимҗанны үлгәнче тинтерәтер өчен күчергәнме аны Карга хатын?! Юк, үләксә, син ике аяклы Һашия килеш тә егетне җиңмәдең, җиңәрлек көчең калмаган иде, Каракошка әверелеп кенә әллә ни узынмассың: ядрә утында канатларың бик тиз өтелер.

Сафия эшкә китү белән, егет аларның өй чормасына менде.

Актарынды-казынды, һәр тишеккә кул тыкты, тик кош юк, юк кынамы, аның барлыгын искәрткән чәнти бармак хәтле эз дә табылмады. Ул утырып нәтиҗә ясады: көндез тупылдагы каргалар белән бутала, бәдбәхет. Мөгаен, әллә ни зур да түгелдер үзе, карга чамасыдыр. Атай әйтмешли, курыкканга куш күренә ул.

Егет, чын хуҗа сыман, Сафияләр бакчасында йөренде, башын артка чөеп әледән-әле тупылларны караштыргач, туфлиларын аягыннан кагып кына төшереп, беренче агачка үрмәләде. Адәмнән яманлык киләсен сизеп, каргалар пыр-пыр һавага күтәрелде, тирә-як колак тондыргыч каркылдау авазы белән тулды. Мәхшәр куптарып, ояларны ул берәм-берәм җиргә томырды. Карга көтүе инде каркылдамый, юк ителгән балаларын җәлләп, тамак төбе белән генә каркылдый иде...

Бакчага атылып Сафия керде. Бер күкне айкап очкан кошларга, бер җир тулы карга баласына карады.

— Нишлисең син, абый?! Ник бу гөнаһсызларны үтерәсең?!

Рәхимҗан, чирканып:

— Ямьсезләр бит. Ни матурлыклары бар соң?! — диде.

— Ходайның рәхмәте киң, ямьсезгә дә, матурга да урын җитә.

— Һи, тиле кыз, колагың тынычланыр. Болай иртә — кар-р, кич — кар-р.

— Мин тиздән кияүгә чыгам, күрше авылга. Безнең өй нык, таза, атаң белән әнкәң монда кышлар.

— Кияүгә?! Шыттырма, кызый! Син җен калдыгын да алалармы?

— Алалар, Ходайга шөкер. Хурлама мине, яме. Әйтсәм әйтим, үкенечкә калмасын: мин — синең сеңлең.

Егет ишетмәгән кыланды, койма буенда күз ялтыраткан мәчегә, ботыннан эләктереп, карга баласы үләксәсен ыргытты.

— Мә, авыз ит, мәче туган.

— Син миңа абый тиешле кеше, — диде кыз.

Тапты шаккатырырлык яңалык! Беләләр, җанкисәк, беләләр, әмма Рәхимҗан кебек акыллы башлар телне аркылы тешлиләр.

— Сине әнкәң ягадан апкайтты, атайның сезгә катышы юк, — диде ул.

— Әнкәй мине тудырганчы чуаш карчыгында торган. Аяклары имгәнгән булган аның, соңра да тубыктан гел шешә иде. Аны бит корсаклы килеш үләт базына төртәләр. Урман кисүчеләр аркан белән генә чыгарды, юкса шунда үләсе идем, дия иде, мескенем.

— Кем төрткән базга?!

Рәхимҗанның эчтән кайнап бәрелгән сулышы иренен пешерде.

— Ипидер, әйтмәде. Ул кеше бу дөньяда рәхәт күрмәс кенә, диде.

— Кызык, кем икәнен белгәч, нигә милициядән аның кулына богау салдырмады? Ник шыпырт кына теге дөньяга олакты икән Карга әнкәң?

— Үз җәзамны үзем хәстәрләрмен, диде.

— Һе, Алласыннан өч көнгә үз хисабына түләүсез ял сорап кайтып, җәзалар микән базга этүче кешене?! Ха-ха-ха! Боларны ул сиңа юри лыгырдаган, юри. Акланыр өчен, үзен фәрештә итеп күрсәтер өчен. Чынлыкта әнкәң себерке иде, чуашлар белән себерелде. Чуаш орлыгыннан яралган бала син, миңа гүпчим дә сеңел түгел.

Сафия Рәхимҗанны шаккатырып җиңел сулап куйды.

— Лутчы чуаштан ярал, сездән яралганчы. Синең кебек ерткыч белән туганлашырга Ходай язмасын, — диде.

...Оялары туздырылса да, каргалар бакчадан китми, йә дәррәү тупыл ботакларын сырып ала, йә җиргә канат очын тидереп-тидереп астан оча иде.

Сибгатулла карт:

— Әй, үзәкне өзеп елый да соң бит кошлар, — дисә, әнкәсе «ка-ка»сын да кабатламый, үзалдына йомылып, телсезгә әйләнеп бара иде.

Ә Рәхимҗан көн туды исә гөрс-гөрс карга атарга тотынгач, карт белән карчык тәмам бөрешеп почмакка елыштылар.

— Мин — каргалар Газраиле, күрегез, тышта каурый яңгыры ява, — дип, ул аларның өнен алды. Рәхимҗан карга чүпләү белән шулкадәр мавыкты ки, өйләнү хәсрәте дә, Бәрия дә онытылды. Әйтерсең йортлары да янмаган, әйтерсең йөрәкне авырттырып-чәнчеп кайгы да кискәләмәгән.

Һәр гөпелдәткән карга аңа чамасыз ләззәт бирә иде. Койма буенда тау хәтле кош үләксәсе өелде.

— Атай, — диде егет, — үләт базына ташы бу чиркангычларны. Бакчаны чистарттым.

— Дөньядагы барча карганы чүпләмәссең, малай, куанма.

— Берсе ычкынды, атай. Ну барыбер каптырам мин аны, Һашияләр кыегына шылды, мөртәт.

Төнлә ул Сафияләр чормасын кармаларга уйлады. Кесәсенә фонарен тыкты. Каракош, һичшиксез, шунда поскан иде. Уртак коймадан теге якка сикерәм дигәндә генә, күзе ишегалды уртасында тыпырчынган кап-кара әйбергә төште. Менә әйбер, җанланып, тәпиләренә басты һәм сыңар канатын шапылдатты. Каракош!!!

Егет, койманы дөбер-шатыр аударып, аңа ташланды, тик кош ике-өч сүәм биеклектә өскә күтәрелеп өлгергән иде, егет сикерә-сикерә аңа үрелмәкче булды, буе җитмәде. Аннан кош бакча артыннан гына кырга таба очты. Бик түбән очты. «Әһә, — диде Рәхимҗан, сөенеп. — Сыңар канат белән җилпенәсеңме? Берсен ядрә тиштеме? Ерак чаптырмассың, алайса, безне, җанкисәк, җиргә мәтәлерсең».

Алар куыша-куыша урман авызына җиттеләр. Кинәт Каракош иң биек агач ботагына кунды да тибенә-тибенә:

— Кар-р, кар-р, — диде. Аның күзе ут кебек кып-кызыл иде...

— Әле син ял итәсеңме, ух-ух, — дия-дия, егет аңа гырда белән бәрде.

Кош өркеп агачтан аерылды. Аны ничек кенә булса да яңадан кырга таба куаларга кирәк, анда канат ялы бирердәй куак-мазар юк иде. Рәхимҗанның теләгенә буйсынгандай, «уткүз» кырга борылды. Ул хәзер сыңар канат кагып әлсерәгән, егетнең алдыннан җир ягалый гына оча, ике-өч талпынсаң, кулга эләгәчәк иде.

Егет, «үтерәм!» дип үз-үзен кыздыра-кыздыра, соңгы көчен җыеп, Каракош өстенә сикерде... Шул мәлдә аның аяк астындагы җир каядыр шуышып китте, һәм ул, корбанын кочаклаган килеш, упкынга мәтәлде. Үләт базы дигән җәһәннәм аны күптән көтә иде...

*1995*

## Ак торна каргышы

### 1

Төн шундый яктырды, шундый яктырды, әйтерсең күктәге ай алма кебек шып итеп авыл өстенә өзелеп төште. Күзгә кадалган яктылыктан качарга теләп йөзен капларга үрелгәндә, ул хәлсез бармакларының кан тамырлары аша үтәли саркып чыккан алсу-зәңгәр төстәге нурларга хәтле күреп өлгерде. «Ник яна бу төн?» дип уйлады хатын, бүленгән төшен кызганды. Бүген ул тагын өн белән төш арасында яшәде. Юк, яшәмәде, яшәү ул тулы бер гомер була, хатын чеметем генә тереклек итеп карады. Ә төшләр бик сәер иде. Озын буйлы, шома йөзле, сыерчык канатыдай коңгырт күзле ир заты бусагадан атлый да туктап кала, атлый да туктап кала... Кем ул? Кем? Мондый буй-сынлы ирне авылда күргәне дә, очратканы да булмады. Каратайда аның сынган канатларын төзәтеп дәвалардай кеше юк иде. Әллә Шамил микән? Кара бөдрә чәчләре тураеп, күзләренең зәңгәр төсе уңып шул кыяфәткә кергәнме? Ләкин ул төшләр белән җәзаларга тиеш түгел. Үзе ташлап китте ләбаса, бөтенләйгә, мәңгегә ташлап китте. Кызганмады, миннән башка ничек яшәр бу, димәде. Үлмәскә дә була иде бит.

Аһ, бүген ул аңа үпкәләп ята! Тиле хатын! Үлмәскә дә була, имеш. Газраил баш очыңда кагынсын әле, бар, котылып кара.

Нигә дөрли соң бу төн? Җиһанга ут капкан мәллә? Инде яктылык иске мүк арасына кадәр тулды, инде бүрәнәләрдә кызыл шәүләләр биешә. Торып тәрәзәгә багасы иде, зәгыйфь аяклар тыңламый. Хатын көнозын кузгалмыйча урын өстендә аунады. Ара-тирә ишегалдына алып чыгып һава сулаткан күрше Сәрия бүген кунакта иде, хатын таңнан бирле кояш чырае күрмәде, тәгам ризык капмады, су эчмәде. Ул кеше кулына калган бичара иде.

Кинәт урам яктан, төннең йөрәген калтыратып, әче тавыш белән кычкырдылар:

— Пожар!!! Пожар!!!

«Йа Ходай, — диде хатын, коты очып терсәкләренә таянды. — Өйгә ут капкан! Бу бит мин янып ятам, мин дөрли-дөрли янам! Сәрия, мөгаен, тыштан ишеккә йозак салгандыр, мине берәү дә өйдә дип белмидер. Мин... мин үлеп барам! Әнә ничек агач чертли, ничек әче төтен тынны кыса...»

Ул кычкырырга маташты, тик сүзләре бугазына тереләде... Хатын лапылдап кире урынына ауды, күзен йомды. Аны беркем дә коткармаячак, ул беркемгә дә кирәкми. Шәһәрдән җыр укытырга кайткан авыру укытучыны авыл әллә кайчан исемлектән сызып аткан, яшиме ул, яшәмиме — аңа барыбер: күрми дә, ишетми дә.

Күзеннән яшь тамчысы сытылып, яңагына тәгәрәде. «Үлгәндә елыйлармыни? — диде ул, гаҗәпләнеп. — Үлем исен сизгәч, адәм баласы акылыннан шашып үрсәләнергә, чәбәләнергә тиеш түгелмени?!»

Ызба тирәсендә акырыш-бакырыш башланды. Ярты төндә йокысыннан уянып аңгырайган халык, бер-берсен уздырып, тамак ерта иде:

— Су, су ташыгыз!

— Сибегез түбәсенә! Кем өскә менә!

— Сипсәң дә җук монда! Җил бу якка куа! Булмый, ут күчә!

— Кайда пажар хөрәсәннәре?! Авыл белән янабыз хәзер, раз-буй!

— Арыслан килә-ә! Җул бирегез. Арыслан килә! Электр чыбыкларын киссен, чыбыкларны!

«Мин үлеп барам, алар дөньясы белән минем дөньяны ут аерды. Ичмасам, «хуш» дип әйтергә, бәхиллек сорарга берәр якын кешем дә юк... Шамил, Шамил, син генә аласың бугай мине. Үлгән чакта: «Калдырмас идем үземнән», — дидең. Шулай ярыймыни, ә? Фәрештәләрнең «амин» дигән сәгатенә туры килгән ич. Менә ал... Кочагыңны җәеп көт...»

Хатын соңгы мәртәбә суларга дип авызын ачты. Шунда ишеккә китереп типтеләр. Ишек шапылдап идәнгә ауды, тузан бөркелде.

— Кайда син, әй? — диде бусага төбендә таптанган берәү, күзе белән өй эчен айкап.

Хатын әз генә күтәрелә төште һәм... тәне чемердәп, әкрен генә артка авышты. Бусагада Ул — төшендә күрешкән озын буйлы ир басып тора иде. Ниһаять, тавыш иясе аны тапты, ажгырып караватянына килде.

— Ахмакбикә! Терелләй янасың бит! Тор, чык! Пожар бит, күршең яна. Әллә сукырмы, әллә чукракмы син?! — дип, ямьсез итеп акырырга тотынды. Үзе, чөеп атардай булып, бер кулы белән караватны селкетте.

— Янучы мин түгелмени? — диде хатын, аптырап.

— Күршең, дим! Тор, тәмләп-иркенләп янарга ниятлисеңме әллә?!

— Син кем? — диде хатын, аның җикеренүләрен бөтенләй ишетмәгән төсле. Хәзер инде ул үлмәячәген беләү, үзен шушы ир коткарачагына ышана, шуңа күрә тыныч кына сөйләшергә тырыша иде.

— Мине танымыйсың син, — диде ир, караватны селкетүдән туктап. — Авылга кайтуыма өч кенә көн әле.

— Син дә минем хәлне аңламыйсың, — дип көлемсерәде хатын. — Юкса «тор да тор» дип тинтерәтмәс идең. Аяклар йөрми, аяксыз мин... Әгәр авырсынмасаң, күтәреп кенә чык...

— Шулай диләр аны. Аягың йөрмәсә, телең бар. Кычкырырга иде кеше ишетерлек итеп. Өйдә юк, дип маташалар бит әнә, Сәрияләрдә, диләр. Мин нәстә аңлыйм монда. Кил!

Сүзләре дорфа булса да, хәрәкәтләре ипле иде ирнең, ул аны җайлап кына беләгенә салды, аннан үлчәүгә куярга җыенган кебек тирбәтеп алды.

— Каз мамыгы, валлаһи!

Урамның икенче ягына — чирәмлеккә илтеп утыртты ир. Сул күрше Фәрдәнәнең йорты янып бетеп килә, халыкның бер өлеше — күмерләнгән нигезгә, бер өлеше хатынның җиргә янтая башлаган иске ызбасына су сибә, урам кырмыска оясын хәтерләтә иде.

Бая өзелеп калган сулышын күкрәк читләрен авырттырганчы тутырып сулады хатын һәм үзалдына елмайды. Озынча нәзек бармакларын, пианино клавишлары өстеннән йөгертеп узгандай, чирәмгә тидерде. Әнә тегендә генә, каршыда гына халык тилерә-тилерә ут сүндерә, бала-чага чабыша, ирләр сүгенә, ә ул көй уйнарга тели. Чөнки аңа яшәү кайтты, яшәү озын буйлы ир кыяфәтендә аның өенә атылып керде... Көчле беләкләренә салды һәм күк гөмбәзе астына чыгарып куйды. Әнә тулган ай, аның исән калуына сөенгән сыман, баш очында тулгана... Әнә таң йолдызы Чулпан күз кыса... Йа Раббым! Юкса бу гариплегең белән яшәмәсәң дә ярый ла. Дөнья имгәге бит ул. Бүтән беркайчан да, беркайчан да, әйе, беркайчан да аякларының рәтләнәсе юк. Тамырлары кипкән, кан качкан, һәм аның бу хәлдә берәүгә дә якын буласы юк... Балалар кечкенә, аңардан читтә-еракта, иренең әнкәсе кулында үсәләр. Ире күптән онытты. Бәлки, өйләнгәндер дә. Барып чыкмады ич тормышлары. Ул аны гаепләми дә. Кайсы ирнең чирле хатын иркәлисе килсен. Ирләргә тупырдап торган таза, сау-сәламәт хатын кирәк. Алар, җаныңнан битәр, тәнеңне ярата. Чү, соңгы төшендә ул атлап китте. Әйе, әйе, теге ир аңа кулын сузды.

— Сара, — диде, ап-ачык итеп, исеме белән эндәште хәтта. — Безгә сөйләшергә иде, Сара, — диде.

— Мин җыр язам! — дип җавап бирде хатын.

Шунда давыл өермәсе аларны ике якка аерды. Нәрсә турында сөйләшергә тиеш алар? Икесенең дә тавышы моңсу иде...

Чирәмгә сеңә язган гарип сынны күрделәр дә, күрмәделәр дә. Аңа шаккатмадылар. Хатын, ара-тирә башын күтәреп, шау-шулы төркем арасыннан коткаручысын эзләде. Тапкач, яшертен генә аны күзәтте. Исеме Арыслан икән. Бите-башы корымга буялган, манма су булган ак күлмәге аркасына сыланган. Кырыенда корсаклы хатын-кыз бөтерелә, җиңеннән тарта, каядыр әйди. Ир аны ипләп кенә читкә этәрә дә ялкын эченнән кисәүләрне сөйри. Инде куркыныч артка чигенде, ут үз эшен эшләде дә, халык күңеленә шом оялатып, өйләренә таратты. Корсаклы хатын да чайкала-чайкала өенә таба атлады. Офыкта таң беленә башлаган иде. Арыслан башкалар кебек китәргә ашыкмый, сүнгән кисәүләрне төя... Ичмасам, күз кырые белән генә Сара тарафларына караса иде! Филтәсез сукыр лампа сыман урам уртасында ялгыз гына чеңкәеп калды ич хатын. Аңа бик уңайсыз, чөнки гариплеген беренче мәртәбә кешеләргә күрсәтте. Моңарчы аның дөньясы ызба да ишегалды белән генә чикләнә иде. Хәзер ишегалды да юк, уртадагы коймага хәтле ут ашады, хәзер йорт тирәсе шып-шыр.

Фәрдәнәне хатыннар юатып маташа иде, берара ул күздән югалды, аннан тагын пәйда булды. Аякларын сөйрәп кенә Арыслан янына килеп басты, башын артка чөеп, биленә таянды.

— Калхуз салыр әле яңасын, мин нәстә, ызба дип үлимме хәзер, — дип шар ярып кычкырды. — Төрттеләр миңа ут, әнәтерәк шәһәрдән кайткан шалапай малайлар шырпы ташлады.

Шулчак исән калган сарайдан Фәрдәнәнең абыйсы Илһам атылып чыкты да төтенләгән кисәүне сеңлесенә томырды.

— Азгын ана эт! Синең белән өстерәлгән көчекләр кулы бу, алар тәмәке төпчеген ыргытканнар. Ниемә анда кеше башы катырасың? Придме әллә ул сиңа! Көчекләрең салдырыр ызба!

— Каян килгән пыркарур, тыкшынма, яме. Отпускың үтүт, тай Чаллыңа.

— Йә, халык, кеше көлдермә, җитте, — диде Арыслан, туганнарны тыеп. Һәм ялгыш кына Сарага күз төшерде. Күз төшерде дә, кулын чалбарына ышкый-сөртә, аңа таба атлады. — Гафу, онытып та җибәргәнмен, гафу. Хәзер өеңә кертәм. Бар да тәртиптә. Ызбаң исән-сау, Аллага шөкер, — диде ир, хатынны кулына күтәрде.

Фәрдәнәгә кызык иде, ул шаркылдап көләргә тотынды:

— Кара, кара, күтәрттереп йөриләрме назлы бикәләр. Шәһәрнеке, имеш. Үрмәләп тә керерсең, җан имгәге.

— Прес, — дип, сеңлесен сарайга куалады Илһам. — Бәйләнмә кешегә!

— Тыңлама, — диде ир дә. — Усал сүз йөрәккә чәнчеп кадала инде ул. Бигрәк тә сиңа. Ну нишләтәсең, авылда халык бозылган, элеккеләре каядыр, шайтан белсен.

Хатынны ятагына кертеп салгач та Арыслан китмәде.

— Кызык, синең хакта ишетмәгән идем, — диде. — Исемең Сара диделәр бугай?

— Сара. — Хатын күзләрен яшерде. Ят ир-ат алдында бөтен буең белән сузылып ятуы бик уңайсыз иде. — Кала кешесе мин. Каратайга җыр укытырга җибәргәннәр иде. Үземнең теләк белән, билгеле.

— Консерватория тәмамлаган белгечнең караңгы авылны сайлавы сәер инде.

— Минем тамагым ач, — диде хатын, сүзне икенчегә борып.

— Ә, гафу, нәрсә бирим? — Ир тирә-ягына каранды. — Сиңа берәрсе ризык-фәлән әзерлиме соң, туганкай? Өстәлең буп-буш.

— Сәрия булыша иде, ул кунакта, ахрысы. Шкафта киптергән ипи бардыр, су белән чылат шуны.

— Юк, Сара туганкай, каты-коты белән син каз мамыгына ит кунмас. Мин күз йомган арада әйләнеп киләм, көт. Без синнән ерак тормыйбыз, өч йорт аша гына.

Корымга чумган ир учын шапылдатып чыгып китте. Аның китүе булды, авызын ерган Фәрдәнә ишектән башын тыкты.

— Күрше, дим, әй, күрше! Нанка таптыңмы? Үзе күтәрә, үзе төшерә, ват кыран. Вагыйзә апаның калада адашкан төпчек малае ул, укытучы сыңары. Әлегә электрик, көзгә мәктәпкә укытырга бара, имеш. Авылда төпләнмәкче икән. Ике баласы, корсагы борынына менгән хатыны бар. Калада ачка кипкәндер алар, анда асфальтка бәрәңге чәчалмыйсың шул.

«Нигә, әйләнеп киләм, диде ул. Ашарга китерәме? Ир башы беләнме? Каратай халкына көлеп сөйләргә бер мәзәк булыр инде. Авылда сине дүртәр-алтышар пар күз йотлыгып күзәтә, һәр адымыңны тикшерә, бәя бирә...»

— Син, дим, чукрак астай, ишетәсеңме мине? — Фәрдәнә, түземсезләнеп, ишек яңагын шакылдатты.

— Ишетәм, — диде хатын. — Нишләп кеше чәйнисең? Үз хәсрәтең башыңнан ашкан.

— Әй, барыгыз да хәсрәт дип лыкырдамагыз әле! Атаң малы жәл түгел шул, диләр. Юри үзем яндырдыммыни. Арысланны яманламыйм мин, астаем, яратып кына сөйлим. Мәрхүм әтиләр ярата иде аны. Син белеп торсын дип кенә әйтүем. Кеше иренә кызыкма дип кенә... Ансы сиңа кем инде кыз-катынга караган кебек хисләнеп карасын. Вагыйзә балалары алар һәммәсе дә гарип-горабаны кызгана. Олы малае Әнәс кулсыз катынны өч ел кашыктан ашатты. Катын җанлы Вагыйзәнекеләр. Ярар, була икән сездә хәлләр.

Фәрдәнә, кетер-кетер көлеп, ишек артына чумды. Ул арада, чәчәкле савыт белән кайнар шулпа күтәреп, Арыслан килеп керде.

— Менә әнкәй тиз генә җылытты. Яле, мендәреңә сөял. Тартынма, оялма, без бит коллегалар. Әгәр рөхсәт итсәң, шушы калын китапны тез өстеңә куяр идем, өстәл ролен үтәр иде ул. Җайлымы сиңа?

— Рәхмәт, тик... нигәдер кулым калтырый, кашык тоталмыйм. Син бар, чык инде. Җаем белән әкрен генә ашармын.

— Ә, юк, болай килешмәдек без. Йә өстеңә түгәрсең. Үзем каптырам. Син мине ир заты дип санама. Әйтик, дустың ди мин, яки абыең ди, яисә энекәшең ди. Чын мәгәр! Ризамы?

Хатын исе китеп Арысланны тыңлады. Үзенә шаккатты: ул берсүзсез аңа буйсынды. Нинди дер илаһи көч бар иде бу ирдә. Аны аңлап та, аңлатып та булмый иде.

— Йә, йә, ач авызыңны, вәт молодец, вәт тырыш, — дия-дия, Арыслан савытның төбен ялтыраттырды. — Хәзер инде бая өзелгән сүзебезне дәвам итик, Сара. Тамак туйгач, сөйләшүе дә күңелле, әйе бит? Мәктәптә озак укыттыңмы?

— Ярты ел.

— Димәк, февральгә тиклем. Шуннан бирле урын өстендә, әйеме? Дүрт айлап икән, алайса. Мәктәптән булышалармы?

Нәрсә дип җавап бирсен Сара? Бая Арыслан үзе үк әйтте ләбаса, авыл үзгәрде, халык үзгәрде, диде. Мәктәп ничек булышсын? Аны директор белән завуч беренче көнне үк өнәмәде. Сара Каратайга пианиносы белән килеп төште. Пианино дәү иде, мәктәп ишегеннән сыймады, яңакларын каерып алып кына эчкә керттеләр. Җимерек ишек директорга ошамады, ә завучка — уйналган көйләр. Ул, җае чыккан саен, авыл баласы гармун уйнап үсә, дип чемette.

Пианино белән Сара ни чарадан бичара сөйкемсез сәяккә әверелде. Ишек тә, «колакка ятышсыз көйләр» дә гаепсез иде, билгеле, бәйләнүнең сәбәбе бүтән иде. Моны бу иргә ничек аңлатасың?!

Хатын эндәшмәде. Тамак төбенә утлы төер бөялгән иде.

## 2

Ерак Себердә ул җан тартмыйча егерме ел яшәде. Иртән торып салкын асфальтка аяк басу белән, табаннарына суык йөгерә дә, күңел ирексездән яшел чирәмле урамнары белән төшләргә кереп саташтырган авылга талпына, җылы эзли. Атау болыннарына, Сөлчә ярларына ашкына, һәр капка төбенә тукталып, авылдашлары белән күрешә иде. Күз алдында Каратай гел бер сурәттә тора: әнә кич җитә, урам тутырып көтү кайта, тояк тузанына кушылган мөгрәү тавышы авылга тарала. Әнә мал-туарлар абзарларга ябылган, чәйләр эчелгән, күрше-күлән капка төбенә җыела. Оста телләр сандугач сайрата, бала-чага колак шомартып тыңлый... Әнә яшь-җилкенчәк гармун уйный. Тальян моңы төн йоклаган кошларны сискәндереп уята...

Арыслан шундый авылны сагынды, туган җир аның хәтерендә шул рәвешле уелып калган иде. Һәм ул төянде дә, Себер белән хушлашып, авылына тәвәккәлләде. Яңгырлы көн иде, авыл башындагы чокырлы юлда машинасы батты. Ярый әле Каратай башыннан трактор чыгып килә иде, ир кулын изәп туктатты. Кабинага өч егет кысрыкланган иде.

— Бөркетләр, булышыгыз әле, зинһар.

Егетләрнең рульдә утырганы, тәрәзәдән генә муенын сузып:

— Бер «чистай малае», абзый, яме? — диде.

— Кем, кем? — диде Арыслан, аңламыйча.

Егетләр шаркылдап көлде:

— Бер ярты, абзый, бер ярты! Ату келтерефүн арбаңны этеп тә тору юк. Бушка тир агызмыйлар бездә. Әллә айдан сикердеңме син?

Тракторчының йөз-кыяфәте таныш тоелды Арысланга. Мәктәптә бергә укып, бергә Атау болыннарында тәгәрәп үскән Шаһиәхмәт малае түгелме соң? Бервакыт алар Шаһиәхмәт белән Сабирҗан мулланың биш олау утынын өч чакрым урманнан кул арбасына төяп ташыганнар иде.

Шунда Шаһи болай диде:

— Малай, Сабир мулла акча-фәлән бирсә, әйдә алмыйбыз, икебезгә дә дога кылдырабыз.

Арысланның исе-акылы китте. Унбиш яшьлек дусты мөәзин малаенда акыл да, иман да хәтсез икән лә! Хәер, ул чакта әбиләр «Бер дога бар дөнья малыннан артык» дип өйрәтәләр иде шул...

— Син Шаһиәхмәт малаемы?

— Иртән аныкы идем, көндез атакайны җен алмаштырмаса әгәренки.

— Ярар, юлыгызда булыгыз, җегетләр!

— Саранланма инде, абзый. Яртыңны җәлләмәсәң, машинаңны сөйрәтеп, авылның теләсә кайсы очына илтәбез. Без мировой солдатлар, иеме, Габдел?

Шаһи малае иптәшләренә күз кысты.

— Яртым юк, — диде Арыслан. Чынлап та, ул «чистай малае»н тыкмаган, дөресрәге, дөньяның бу ягын уйлап бетермәгән, әгәр инде тагын да күңелен ачса, авыл ярты теләнеп каршы алыр, бәлагә юлыкканда, әҗер сорар дип башына да китермәгән иде. Эче актарылып, бәгыре көйде ирнең. Әмма гарьләнүен сиздермәде. Бүтән ялынмады да. Көпчәк чумган чокырга таш кисәкләре ыргыта башлады.

Ә трактор, аның йөзенә пычрак валчыклары чәчрәтә-чәчрәтә, күтәртмә юлга ыргылды.

Кичен әнисе табын янында авыл хәлләрен сөйләде:

— Мәчет салалар, улым. Нигезе зәһәр тавышлы булды. Әүвәл урын өчен даулашты халык. Берәүсе, искесе янәшәсенә салдырыйк, ди, икенче берәүсе, авыл уртасына, ди. Үзара ызгышып-талашып, бер-берсен каргашып, кара дошманнарга әйләнештеләр. Рушаниянең капкасына бозык йомырка бәргәннәр, имештер, анысы исә, коймама терәп мәчет куймагыз, дигән. Ник алай дисен инде ул мескен карчык, киресенчә, кинәнә, иман йорты белән янәшә яшим, дип. Бу тирәдә эчеп сүгенүчеләр йөренмәс, дип. Әнәтерәк Шаһиәхмәт малайлары манара калае ташыдылар трактор белән. Сүгенә-сүгенә бушаттылар да мәчет турына, баскычына утырып аракы чөмерделәр. Шешәсен идәненә бәреп ватканнар. Җыеш-тыручы Миңнеруй елый-елый җыйды пыяла ватыкларын. Син, улым, берәр яшник акны апкайтмадыңмы? Коймалар ауган, мунча ләүкәсе черек, осталар чакыртып рәтләтәсе иде ауган-егылганны. Аракысыз бит берсе дә эшләми.

— Нәрсә булды соң бу авылга, әнкәй? — диде Арыслан, теше сызлагандай чыраен газаплы чытып.

— Ничек «нәрсә булды», улым?

Анасы, Шаһиәхмәт малае кебек үк, аңа сәерсенеп карады.

— Нәрсәгә генә тотынма, сүзне каян гына башлама, аракыга килеп терәлә бит, әнкәй!

— Син, улым, бүген генә дөньяга туган төсле кылынып утырма инде. Себердән җибәргән акчаларың кая тузган дисең соң, шул зәхмәт суына бит, шуңа. Кое бурасын алмаштырдым, биш бүтилкә сорадылар, өстәвенә өч бүтилкәне бер черек бүрәнә чыккан саен капкалап бардылар Габделхак белән Нәҗибулла. Арт капка ауган ие, икене куйдым, келәт башы өчен гүпчим акча алмадылар, бүтилкәләтә генә түләттерделәр.

— Әнкәй, әнкәй! — Арыслан, хатыныннан уңайсызланып, анасын исәп-хисаптан туктатты. — Син намаз карчыгы, шушы хәрәм нәстәкәйне ник йортыңа кертәсең? Әби аны урыс авылы кибетенең киштәсендә күрсә дә: «Кичер, Ходаем, күзем гөнаһлы әйбергә бакты», — дия иде.

— И улым, сиңа мине битәрләве җиңел ул. Менә яшәп кара әле, дөнья куып кара, аракысыз сыңар салам да селкетмәгәннәрен үзең дә күрерсең. Бездә ялгыз карчык-корчык пинсә акчасына икенче көнне үк аракы юнәтә. Аракы — баш, аракы — муен хәзер авылда.

Анасы белән бәхәсләшү мәгънәсезлек иде. Авыл юлында нишләттеләр әнә, аракым юк, дигәч, сәлам дә бирмәделәр. Тик беркатлы күңел ышанмый. Моннан егерме ел элек шундый авыл калдымыни Арысланнарны озатып, ә? Каратайда исерекләрнең әсәре дә юк иде. Бер Гафил атлы бәндә салгалады, әмма мәчет картлары аны яман гадәтеннән бик тиз тыйлыктырды: яңгыр яумыймы, агач-куакны яшен сугамы, чишмә корыймы — барысы өчен дә Гафилне гаепләде. Бөтен гөнаһ-гаепне үз өстенә җыеп, авылдашларының нәләт-каргышына коенып яшәү, күрәсең, Гафилгә читен булгандыр, ул капыл шайтан суыннан бизде, хәтта эчкән урыслардан җирәнә башлады.

...Кайтуының икенче көнендә үк Арысланны хуҗалык рәисе кәнсәләргә чакыртты, гозерен белдерде:

— Арыслан абзый, һөнәрең укытучы икәне дә ызнамы безгә, пәнимайты. Алай да көзгә тиклем электрик сыйфатында эшләп тормассыңмы? Ярты авыл утсыз интегә, пәнимайты. Барый, пычагыма ярый, исерек килеш баганага үрмәләгән дә аска мәтәлгән, муены сынган, пәнимайты палажиниены. Зарплат тучны бирәм, зерналата да бирәм, риза бул.

Электр рәтен белә иде Арыслан. Армиягә кадәр Каратайда ут чыбыклары да сузып йөрде.

— Тырышырбыз инде, энекәш. Кирәксә, хәзер үк эшкә керешәбез. Кемнән башлыйк? — диде ул, рәисне сөендереп.

— Шаһиәхмәтләр йортыннан. Ярты ел инде җил аларның багана чыбыгын өзгәнгә, пәнимайты.

Балачак дустым белән күрешәм дип шатланып, Арыслан түбән очка ашыкты. Шаһи пыр тузып ишегалдында тавык куа иде. Ике яшьти, ике хыялый дус, бермәлне кул бирешергә дә онытып, бер-берсенә карашып тордылар. Шаһиәхмәт арык гәүдәсенә каралып җир төсенә кергән сәләмә майка белән балагын яртылаш бозау чәйнәгән чалбар элгән, йөзе куркыныч: чәчләре мич пумаласыдай тырпайган, яңагын саргылт төк баскан иде.

Өй эченнән ниндидер хатын-кыз кычкырмаса, алар тиз генә аңга килмәсләр иде әле.

— Исерек бугаз! Тоттыңмы, суйдыңмы тавыкны?

— Кәзер, кәзер тотам, — диде Шаһиәхмәт, ул «х» хәрефен бала чагыннан ук әйтә белми иде. — Агын тотыймы, карасынмы, катын?

— Агын, дидем, картрагын, исерек бугаз! Мисез тавык!

— Шаһи, туктале, мин дә булышыйм әле, — дип, дустына кушылып Арыслан да тавык куарга керешә. Ниһаять, берсен абзар читенә кысрыклап тоттылар.

— Малайның ташы кызган, — диде Шаһиәхмәт, черт-черт җиргә төкереп. — Үләнәм, ди. Сине, яшьти, танымассың да.

— Сине дә, — диде Арыслан, күрешергә кулын сузып. — Йә, нихәл?!

Шаһи ялкау гына кул бирде дә пышылдауга күчте:

— Баш чатный, букчаңда нәстә ул, күчтәнәч ләртымы? Әдә карлыган куагы төбенә, катыннан качып кына юл тузаннарыңны юыйк, малай.

— Юк, яшьти, сумкада ут кирәк-яраклары ул. Караңгыда яшисез икән бит.

— Авызны кашык таба ла анысы. — Шаһи калтыранган бармаклары белән шатыр-шотыр корсагын кашыды. Өметсез генә кул селтәде. — Җук кәсрәт кайгыртасың икән.

«Шаһиәхмәтме соң бу? — дип шикләнеп куйды Арыслан. — Мин йортларны бутамадыммы?»

— Ничек «җук хәсрәт»? Утсыз яшәп буламы?

— Миңа ни! Кайттым-яттым, тордым-киттем. Ордым яктысын, ордым караңгысын.

— Эчкәнгә шулай ул, яшьти. Малаең да, борын асты кипмәгән, салырга ярата икән.

— Акыл сатма, җәме, эчсә — эшләп эчә, кешенекен ырламый. Мона син — саран, Себереңнән бер ярты апкайтмагансың. Дусларны көрмәт итмисең, ызначит.

— Ташла, Шаһи. Атаңның рухын рәнҗетәсең бит. Син — мөәзин малае...

— Чур, братун! Ми капкасын каерма. Күзләр чәчри монда баш сызлап. Әдә тиз-тиз генә ут керт, мужытса, катын куйган бүтилкәдән миңа да өлеш чыгарырсың, үзең генә чөмермәссең. Катынның яшергәне бар аның, дәҗҗал, итәк астында саклый. Барыйга эчерәм дигәние, ул сыбулыч муенын сындырган. Катын, катын! Ал үләксә тавыгыңны, бугазладым.

Өйдән, камырлы кулларын керле алъяпкычына сөртә-сөртә, умарта корты кебек безелдәп, Шаһиәхмәтнең хатыны чыкты, күз угын Арысланга кадады:

— Бусы ниткән алкашлар әртиленнән тагы? Тыгынырга гына җыелалар. Шаһи йортында аракы елгасы ага диярсең.

— Катын, чәпчемә әле, Арыслан кордаш бу. Ут чыбыгын ялгыйм, ди. Себердән кайтып җүнле эш белән җөри дисеңме әллә? — дип сукранды Шаһи.

Хатын күз угын җәлт кенә иренә күчерде.

— Сиңа аракы чөмерү генә җүнле эш шул, сасы көзән! Ташы келәттән чыбыкларны! Туйга хәтле ут ясасалар бик сөенерсең. — «Умарта корты»ның тавышы йомшарган иде инде. Ул Арысланга ялагайлана башлады: — Җанкисәгем, эшлә генә, зинһар. Шушы бирәннән саклаган яртым әзер, җә бездә эчәрсең, җә кесәңә тыгып кына китәрсең. Себердә салкынмы соң үзе?

— Киенсәң, җылы, — диде Арыслан, кәефсез генә. Шаһиәхмәтнең тормышын ул болай булыр дип күз алдына да китермәгән иде. Дусты шигырьләр яза, укырга хыялланган иде. Хыял канатларын кем көйдерде икән, ә?

Бу йорттан ул тәмам изелеп чыкты. Ут кабынудан айга сикергән шапшак хатын чебен сырган ипи кисәге белән мүкләнгән кәбестә янына бер шешә чыгарып утырткач, Шаһиәхмәт бизгәк тоткандай калтырана, ә күзе май ялаган мәченеке кебек ялтырый иде.

— Малай, миңа да тамыз, җәме? Малай, үлгәндә дә онытмам, малай. Каберемдә дә дога укырмын үзеңә. Миннән алдарак үлсәң, кабер төбеңә мамык җәярмен.

Шунда Арыслан яшьтиен каты җәзалады. Ахырдан бу этлеге өчен үкенеп туялмады, төне буе йокламыйча уфтанды, уфырды.

Кырлы стаканга тутырып аракы койды да ул:

— Синең өлешең, — дип, идәнгә түкте. Янәсе, шулай дөрес эшли, дустын хәмердән биздерә. Янәсе, моннан соң Шаһи гомерендә дә авызына капмый.

Шаһиәхмәт бу хәлдән әллә нишләде. Әүвәл, бугазына таш тыгылган әтәч кебек, муенын өскә сузды, маңгаена кадәр менгезеп күзен акайтты, аннан, биленә суккан төсле, капыл урталай сынып төште һәм мүкәли-мүкәли идәндәге аракыны яларга кереште. Аракы балчыкланып каткан шакшы идән ярыкларына тулган, аска тиз генә акмый иде. Ир, телен чыгарып, лач-лач китереп ялады да ялады. Үзе эт кебек ырылдый иде. Түзмәде Арыслан, укшып тышка йөгерде. Дөньяның байтак әшәке күренешенә юлыкканы бар, әмма болай тетрәнгәне юк иде, чөнки бу җирәнгеч сурәттә җан дустының шәүләсе чагыла иде.

— Эчеп кайттыңмы әллә, улым? — диде әнисе, аның капкадан алпан-тилпән атлап керүен күреп.

Ана карчык моны бер дә хафаланмыйча гына сораган кебек тоелды.

— Ник алай дисең, әнкәй?

— Соң... диям инде, диям. Эштән кайтуың лабаса!

— Эштән кайтканда эчәргә тиешме кеше?

— Ярар, улым, эчкәнсең икән, ыспурлашма, кер дә ят. Килен борчылыр.

— Их, әнкәй! Нинди сүз бу?! Шыр айнык мин, шыр айнык. Нишләдегез соң сез, ә?! Аракыны Алла урынына күрәсез бит! Карчыкларга хәтле шуны теленнән куймый.

Ул төн Арыслан өчен коточкыч газаплы булды. Икенче төн дә аңа мәхшәр әзерләгән иде: кайчандыр гөрләп торган Әманулла абзыйлар йорты янды. Мәрхүм Әманулла аны, чуаш урманыннан нарат бүрәнә ташып, оныкларына калырлык итеп салган иде. Тырыш кеше иде ул, барысын да хәләл көч белән тапты, ә кызы бер сәгать эчендә аның мал-мөлкәтеннән көл өеме өйде. «Исерек ирләр җыеп ята, — дип шаулашты халык, — шулар гына төпчек ташлаган. Кем аңа ут төртсен ди. Алла каргады...»

«Алла каргады» диде дә Каратай, утны сүндерергә ашыкмады. Теленә салынып, карап торып яндырды. Югыйсә йорт саен кое, кое саен чиләк. Элек авылда мунчага ут капса да, яше-карты егылабәрелә су ташый иде. Ә бүген беркем дә кымшанмады.

Монысына бер шаклар катса, икенче бер җансызлыкка өнсез калды Арыслан. Ян күршедәге Нәгыймә карчыкның иске ызбасында авыру укытучы хатын яши икән. Һәммәсе дә акыра-кычкыра, ләкин ызбага якын килергә базмый. Аны да тамаша кыла-кыла яндырырга исәпләре. Җитмәсә, кайсыдыр «укытучы өендә түгел, Сәрияләрдә» дип бәхәсләшә.

«Юк, юк, егерме ел эчендә авылның бу тиклем бәгыре катмас. Болай ук үзгәрмәс Каратай».

Арыслан күңелендә туган шик-шөбһәләрне куарга тырышты, үз-үзен юатты. Өметкә шайтан төкермәгән иде әле...

## 3

Ике йорт арасындагы койма янгач, Сараның тормышы ирексезләп Фәрдәнәләр белән кушылып китте. Җилбәзәк хатын вак-төяк әйберләрен, табак-савытын аңа кертеп тутырды.

— Син, апаем, без яңа йорт тергезгәнче түзәрсең инде, сарайда ашап булмый ич, — диде Фәрдәнә. — Йоклавын печәнлектә йокларбыз да ул.

— Яшә, Фәрдәнә, — дип ризалашты Сара. — Тик сиңа бер үтенечем бар. Күп сөйләмә, яме?

— Җә телемә күгәргән йозак эләрсең, — диде хатын, үртәп.

— Без — каратайлар — сөйләнә-сөйләнә ясалган халык, авыз йомсак, шундук эчебезгә кату чыга. Миннән дә хутлырак өйдәшне көндез чыра яндырып эзләсәң дә тапмассың. Мин хөсетсез, эчемдәге тышымда. Сине тәрбия кылган сазан тәре, Сәрияне әйтәм, ул менә хәйләкәр төлке, анадан тума чишендерде бит үзеңне, бөтен киемеңне сатып эчеп бетерде. Шәт, кияреңә ыштаның да калмагандыр.

— Мин аңа артык киемнәремне үзем бирәм.

— Бирми хәлең юк, апаем. Шуңа алданып кына айга бер идәнеңне юа, ашарга пешерә. Итүсә бушка эшләр сиңа, сасы балык.

— Алай кушаматлар белән кешене мыскыллама, Фәрдәнә.

— Әй, апаем, харап ентилегент бит син, авылда гел кушамат инде ул. Сасы тек сасы менәтерәк. Эчсә, үз катысына үзе буялып сасый инде.

— Кем сасый, кем?! — Ачык ишектән сиздермичә генә кергән Сәрия идән уртасына басып сайраган Фәрдәнәнең чәч үрмәсеннән умырып тотты. — Син нәстә минем гайбәтне сатасың?!

— Кызлар, зинһар, тавышланмагыз, — дип ялварды Сара. — Узган-барган ни уйламас.

Тик ике хатынның «мунча ташы» кызган, сүз саен «пар» чыжлый иде.

— Кисәүле нигезеңдә улап утырмыйча ник монда ышкынасың? — дип үкерде Сәрия.

— Әлкәш тәре, үзең соң, сырхауны ташлап, ике көн кайда сөйрәләсең? — дип чинады Фәрдәнә. — Укытучының соңгы пар туфлиен саткан акчага чуаш көмешкәсе тыгындыңмы? Степка түти белән икегезнең исерешеп дуңгызлар аранында аунаганын кешеләр күреп кайтты!

— Ә син, кәнтәй, кеше тикшермә. Ирләрнең чутын язып барган амбар кенәгәң дә яндымы, шуны әйт башта.

— Көнләшәсеңме? Үзеңә ирләр күзе төшмәгәнгә тишегең әрниме? Син сазаган әлкәшкә кем карасын ди! Кешедән качып эчәсең, шешәңне тирескә күмеп. Кабымлыгың да тирес кортыдыр әле.

— Кызлар, кызлар! — дип өзгәләнде Сара, ике кулы белән караваты тимерен төйде. — Җитте, туктагыз!

Ләкин тегеләр ташка су өсти торды.

— Син шешә башы имгәндә, мин ирләр кочаклап йоклыйм, ичмасам. Кара кыяфәтеңә, көмешкә тыгына-тыгына борының зәңгәрләнгән.

— Синең, ирләр атландыра-атландыра, аякларың чалшайган, корсагың ботыңа салынган.

«Йа Раббым, әгәр канатлар үссә, мин бу ызбадан очып чыгар идем дә зәңгәр кыңгыраулы аланга төшәр идем. Торна булыр идем мин, ап-ак торна... Кичә кыек турысыннан ике торна тезелешеп китте. Аларны тәрәзәдән күрдем дә, күзләрем яшьләнде. Очасы иде, әй!»

Хатынның уй челтәрен тагын зәңгәрле-күкле тавышлар ертып керде:

— Ирләр сиңа чиратка языла, төн буе капкагыз ябылмый!

— Махмырдан тәгәрәгән төннәрдә безне саклыйсыңмы? Беләбез, әлкәш кисәге, беләбез, айга карап улаганың ишетелә иде шул.

Кинәт калын гына ир-ат тавышы ызгыш-талашны урталай кисте:

— Хәерле кич! Нигә кычкырышасыз, күршеләр?

Ике хатын авызларына су капкандай шым булдылар.

— Менә, авыл хәбәрләрен чүпләп, Сара укытучының күңелен юатабыз, — диде Фәрдәнә, кеткелдәп.

— Ие, — диде Сәрия. — Өчәүләшеп көлешә идек әле. Уз, Арыслан, түргә уз. Сарага йомышың төште мәллә?

Арыслан, укытучы ягына күз салмыйча гына, тәрәзә буендагы урындыкка барып утырды.

— Хәл белергә дип кенә керүем, йомышым юк, Сәрия ханым, — диде ир.

— Туташ, — дип төзәтте Сәрия, һәм Фәрдәнә тарафына агулы ук очырды. — Мин кул тимәгән саф кыз бала. Кайберәүләр кебек ирләр җыеп түшәгемдә кундырмыйм.

— Һәй, оялмый да, кырык яшендә кызлыгы белән мактана берәү. Димәк, караучы юк, — дип, укны кире Сәриягә борды тегесе.

Сараның чигәсенә шаулап кан йөгерде: яңадан чәкәләшәләр, ахрысы! Арысланнан оят. Ут үрләтеп талашсалар, бу ир нәрсә дияр аның йорты турында, Раббым?! Гайбәт оясы икән дип уйлар, мөгаен.

Арыслан:

— Күршеләр, сезнең хәбәрләр Сарага кызык түгел, — дигәч кенә, хатыннар ишеккә таба борылды.

— Иртәгә районнан табиб чакыртырбыз, — диде ир, икәү генә калгач. — Ул дарулар язар.

— Рәхмәт, Арыслан. Миңа табиб та, дару да ярдәм итә алмый. Карадылар инде, нервылардан, диләр, берәр көн аякка басарсың, диләр. Вакыт кына төзәтер барысын да. Сиңа кайгыртуың өчен тагын бер кат рәхмәт. Кереп йөрмә, авылда сүз тиз тарала, хатыныңа ишеттерерләр, тынычлыгыңны бозарлар. Каратайда халык күпертеп, булмаганны бар дип сөйли.

Сара, уңайсызланып, чәч толымының очын бөтерде.

— Их, Сара, Сара! Сүздән куркып бәлагә тарган кешенең йортын өч чакрым уратып узаргамы хәзер! Сиңа кемдер булышырга тиештер бит!

— Мин бу авыл өчен ят та түгел шикелле инде. Нәгыймә карчыкның оныгы. Каратайны мин мәрхүм әтинең сөйләве буенча белә идем. Иң авыр чагымда, кая барып сыеныйм дигәндә, нигәдер шушы авыл коткаручым булып тоелды. Әти Каратайны гел мактый, авылдашларым искиткеч мәрхәмәтле, дип сөйли иде.

— Алайса, син Фәрит абзый кызы икән! Оста гармунчы иде ул, урам җыеп биетә иде. Без, бала-чага, «уйна да уйна» дип, аның теңкәсен корыта идек. Соңрак ул ак бантиклы кызчык белән авылга да кайтты, аннан югалды. Яшьли үлгән, мескен. Ә теге кызчык син идеңме?

Сара хәтерләми иде.

— Без анда бәләкәй идек шул, — диде ир. — Авыл да бүтәнчә иде. Әтиең дөрес сөйләгән: халык миһербанлы, тәүфыйклы, ак йөзле иде без үскәндә. Тик заманалар гел үзгәреп тора. Алай да өметсезләнмик, коллега. Дөнья изге бәндәләргә корымас. Ә теге вакыт дигән сәгатьнең телен алга күчерәбез: син тереләчәк көннәр тизрәк якынаерлар. Әүвәл боек күңел капкаларын ачыйк. Урман буенда безнең бик матур сазлы күлебез бар. Анда быел ике торна төште. Кешеләрдән дә курыкмыйлар, кулга ияләшкәннәр. Барып карыйбызмы?

— Син... син, Арыслан, үртисеңме әллә?

Ирнең йөзе җитдиләнде.

— Шаяртулар икенче төрле була ул, — диде. — Өй эчендә бикләнеп ята-ята син тәмам боекказсың, ә күңел төшенкелеге — иң яман авыру. Әткәй ясаган кабыклы кул арбасы тузмаган әле, үзе шакмак тәгәрмәчле, үзе җайлы.

— Кеше көлдермик, Арыслан.

— Без, мулла абзый аяксызлангач, аны мәчеткә җомга намазына кул арбасына утыртып илтә идек. Абый-апалар, бу изгелегегез мең өлеш булып үзегезгә кайтсын, дип, рәхмәтләр укып кала, беркем дә авыз ермый иде.

— Юк, барыбер кирәкми, син ир кеше, әнә Сәриядән үтенеп сора, ул алып барсын, — дип карышты Сара. — Чынлап та, минем торналарны күрәсем килә.

Сәрия ишегалдында һаман Фәрдәнә белән тарткалаша иде, Арыслан чакыргач, йөгереп өйгә керде.

— Уф Аллам, өч борынга җыелабызмы? Баскыч төбендә кабыклы арба да тора. Төяп кенә килештән мәллә «җемелдек күзләр»не?

— Сәрия, — диде ир, аның сүзләрен колак яныннан уздырып. — Шул арбага Сараны утыртып, торналар карарга төш әле. Ат җигәр идең, сукмагы тар.

— Нәстәгә?! Торнага?! Башыңа тай типтеме әллә?! Шәһәрнекеләр чак-чак тиле-миле инде ансы.

— Сиңа арба тартып баруы читен булырмы? — диде Сара, хыялының чынга ашмавыннан куркып.

— Һи, син дә йөк тагы! — Карт кыз комарланып ызба эченә карашын ташлады. Аның нәрсә эзләгәнен сизенеп, укытучы авыр сулап куйды.

— Эзләмә, Сәрия, син барсын да сатып бетердең...

— Әлсә бармыйм! — дип кырт кисте кыз. — Тәк тә сине карый-карый үләм инде. Сезгә кирәк җүләр торналар. Юл хакын түләгез. Тапканнар ишәк!

— Күпме? — Арыслан кесәсеннән акча чыгарды. Ул бит кайчандыр шушы кызны яраткан иде. Беренче мәхәббәте иде Сәрия... Нишләгән ул? Мәчене рәнҗетсәләр дә җәлләп елаган Сәрия нишләгән?! — Мә, ал, юл хакы...

Карт кыз акчага үрелде дә кире кулын тартып алды.

— Әйем, акчаның пачуты юк Каратайда. Ике бүтилкә аракы бир лутчы.

— Аракы?! Нәрсәгә?

— Әй, белмәгән булып кыланма инде, Арыслан дус. Әнкәң әллә кайчан сөягемнән он тарттыргандыр. Эчәм бит мин, дөньяның артына тибә-тибә эчәм. Мәһишә әбидән көмешкә сатып ал бу акчаңа. Миңа бирми ул, иске бурычларым түләнмәгән.

— Мәһишә әбидән, дисеңме? Кайсы Мәһишә ул?

— Безнең авылда икенче Мәһишә тумаган әле, шул Мәһишә, абыстай Мәһишә! Көндез ашка йөри, дога укый, төнлә көмешкә кудыра.

— Алдашма, гөнаһсыз карчыкка кара якма, кит, Сәрия, чыгып кит, күземә күренмә! — дип дулаган ирне Сара йомшак тавыш белән бастырды:

— Сәрия ялганламый, Арыслан. Мәһишә астай көмешкә белән сату итә. Өч малае да эшләми аның, шуларның тамагын туйдыра.

— Хатын-кыз эчә, абыстайлар сата. — Арыслан гаҗәпләнеп тел шартлатты. — Шәһәрнекеләр эчәләр, анда күз дә, колак та юк, ә монда, авылда... бер-берсен беләләр бит, аналарын корт чаккыры! Гафу, Сара, сүгенмәс җиреңнән сүгенерсең.

— Син үзең гафу ит, Арыслан. Минем аркада кәефең бозылды.

— Ә без барыбер торналар күрергә тиеш!

Ир урыныннан сикереп торды. Шат кыяфәтле булырга тырышып елмайды һәм, Сараның ризалыгын да көтмичә, күтәреп алып чыгып арбага утыртты. Хатын теләсә кая күчереп йөртерлек курчак хәлендә иде.

Тыкрыкка таба тәгәрәгән арба артыннан Фәрдәнә урам яңгыратып кычкырып калды:

— Кешеләр, кешеләр! Карагыз әле, берәүләрне карагыз! Вагыйзәттәйнең Себердән кайткан тиле Арысланы ат булып җигелгән, Сарасы чыбыркы шартлатып аны куа. Ха-ха-ха!

Сараның чәч төпләренә хәтле кызарды, колак яфрагы кызышты, йөрәге леп-леп типте. Ул, арба төбенә сеңә язып, гәүдәсен җыйды. Фәрдәнә алмый-куймый һаман кычкыра иде... Болай җиңел генә йөгәнне бушата торган гадәте юк иде аның, җиде кат уйлап, бер кат кисә иде ул. Нишләдең соң син, Сара, нишләдең? Торналар кызыктырдымы, әллә шушы ирнең, күңеленнең бикле капкаларын ачабыз, дигән сүзләре канатландырдымы? Яшәргә кирәк, ди Арыслан. Яшәргә, яшәргә... Дөньяның үги баласына кагылып-сугылып яшәүнең ни яме дә, ни тәме?! Яшәргә, яшәргә... Яшәп булыр микән, йа Раббым?!

Күңелсез уйлар тәгәрмәч тузанына сеңеп югалды: күз алдында әкияти манзара җәйрәп ята иде. Калкулыкның иң югары җиренә алып менде дә Арыслан, күк йөзе кебек зәңгәрсу күлгә ымлады:

— Матурлык дөньясына ашыгып керергә ярамый, бүген еракта гына карыйк. Әнә, күрәсеңме, торна. Анасы сазлыктагы берәр түмгәктә йомырка саладыр, мөгаен, бусы үзе генә суда йөзә. Менә синең киләчәктә язылачак «Торна» сонатасына кереш өлеш.

Хатын, суларга да онытып, тирә-якны күзәтте. Дүрт дивар эчендә ятып, тоткынлык газапларын кичергән җаны үзалдына сулкылдый иде. Ничә айлар инде ул дөньядан аерылып гомер чигә, ә дөнья искиткеч матур: аның һавасы, урман-болыннары бер бәләкәй генә ызбага сыймаган, офыклардан ташып, чиксезлеккә сузылган иде. Тагын шул тар, кысрык ызбага ничек кайтып керәсе?!

— Нигә күңелсезләндең, Сара?

— Куркам, Арыслан. Кайтып янә ятакка авасы бит.

— Ә син аума!

— Ничек?!

— Йөрергә өйрән. Нигә шаккаттың? Яле, җилкәмә таянып, үкчәләреңә бас.

Арыслан баягы кебек рөхсәт сорап та маташмады, Сараны биленнән кысып тотып, җилтерәтеп җирдән ике-өч сүәм күтәрде дә, сабый баланы өйрәткәндәй:

— Уң аягыңның табанын чирәмгә тидер, — диде. Сара, кычкырып җибәрмәс өчен, аскы иренен тешләде: бозланган кан тамырларына кисәк кенә балта белән чапкан кебек, сөякләргә хәтле авырту төште. — Үзеңне кызганма, — диде ир, куәтләп.

— Булмый, Арыслан, аякларым язылмый.

— Юк, була, коллега. Бас, бас, дим!

Хатын күзен йомып уң аягын чирәмгә тидерде. Баягы авырту көчәеп, тез капкачын куптарып аткандай булды...

— Инде сулын кымшандыр. — Арыслан әз генә бер кулын билдән бушатты. — Ачуланма, табигать күрсәтергә дип алып чыктым да җәллад сымак җәзалыйм. Арысаң, башыңны күкрәгемә куй, ял ит.

Сул аякның сөяге алай ук чатнамады, интектермичә генә турайды. Моны Арыслан да сизде.

— Сара! Сул як безнең тәртиптә түгелме соң? Син аңа куркудан гына басмыйсың бугай. Яле, йә?

Чынлап та, сул аякта авырту кимегән иде. Шатлыктан Сараның тыны кысылды.

— Син үзеңне йөрмим дип артык ышандыргансың, коллега. Шулай ярыймыни?! Ярар, бүгенгә җитәр. Ял ит, мин торналарга җим сибеп киләм.

Арыслан эре-эре адымнар белән атлап күл буена китте. Әз генә талпынса, Сара да аның артыннан куып тотар сыман, җан-тән ниндидер рәхәт җиңеллек кичерә иде. Әллә бозланган кан тамырларын кыздырып яшәү кайта микән? Әнә торна ирнең учыннан җим чүпли. Сараның бер дә кош-корт ашатканы юк, ул да кулын сузар, ул да томшык очын тояр иде. Нинди сәер теләк!.. Тизрәк тереләсе иде...

— Сездән бөтен авыл бот чабып көлде, — диде кич белән Сәрия, хатынның йөзенә иелеп. — Абау, нишләдең син, малай? Күзеңнән очкын сибелә.

— Һава суладым. — Сара бүтән ачылмады. Сәрия сер уртаклашырлык кеше түгел иде. — Көлделәр, дисеңме? Нишләгәнбез ул хәтле?

— Оялмыйча сорый тагы. Арыслан кая аппарды соң, күкәй баш?!

— Торна карарга алып барды, ә моның ни ояты бар? Сиңа үзеңнән оялырга иде, Сәрия. Көн-төн эчүдән дә әшәке нәрсә юк бит!

— Хәзер барысы да эчә, ире, хатыны уптым илаһи эчә. Йорт саен әлкәш. Ә монда, Каратайда, моңарчы кабык арбада кукраеп, җитмәсә, ирләрдән сөйрәтеп йөрткән кыз-катын булмады әле.

— Гайбәтчеләр сүзен сөйлисең, Сәрия.

— Авыл белән чәйниләр, җанкисәгем. Сыер печән чәйнәгән төсле.

Сараның кәефе кырылды. Көндез җанына нур булып җыелган яктылыкны кара шәүлә каплады. Ул үзе өчен көенми иде. Аның: «Ник сине хурлыйлар?» — дип тетелеп янар кешесе дә, гарьлегеннән җир ярыгына чумарлык туган-тумачасы да юк, ул ялгыз иде. Арыслан нишләр, Арыслан?.. Ирнең әнкәсе дә, хатыны да, балалары да бар, аңа читен, аңа кыен...

**4**

— Улым, кил әле.

Таң йокысыннан уятып ишегалдына чакырган ана карчыкның борчылуы йөзенә чыккан иде. Арыслан шомланып куйды: каратайлар тагын берәр бәла-казага тарган микән?

— Улым, килен ишетмәсен, бакчага керик.

— Нинди сер ул, әнкәй. Гөлфия безнең гаилә кешесе, яшермә, бергә сөйләшик.

— Әй, бала! — Анасы өзгәләнеп әйтте бу сүзне. — Килен колагы өчен катырак шул сүзем. Бүген көтү куганда күземне ачырмадылар, гарип укытучы белән икегезне борчак кебек утлы табада биеттеләр. Каушаудан зиһенем чуалып, сыерымны көтүгә дә кушалмадым. Ир башың белән адәм көлдермәсәң, улым.

— Аң-ла-шыл-ды-ы. — Арыслан кулы белән чигәсен кысты. — Уты юк, ә төтен чыккан.

— Авыл у-у килә, улым, ят хәбәр бит, адәм өчен моңарчы ишетелмәгән хәбәр.

— Их, әнкәй, әнкәй. Әнә яшьтине малае кыйнаган. Эчәкләренә хәтле изгән, ди. Төнлә больницага илткәннәр Шаһины. Аны сөйләмиләр, әйеме? Чөнки бу Каратай өчен гадәти вакыйга. Эчеп исерү, сүгенү, кеше үтерү, талау-мыскыллау, бер-береңне рәнҗетү — болар пүчтәк хәбәрләр, шулаймы?

— Кыз-кыркынны кул арбасына төяп йөрү ир-атка килешми, диләр инде, улым. Хурлык, диләр.

— Алайса, миһербанлык кылу хурлык эш санала хәзер, ә? Мин бит Сараны кызык өчен арбага утыртмадым, терелсен дип, изге ният белән эшләдем моны, әнкәй! Хет син аңла! Чирне чакырып китермиләр, иртәгә без дә егылырга мөмкин. Шунда бер кашык суга тилмереп ятсак, хәл-әхвәлләребезне белүче кеше булмаса нишләрбез?

— Авылда элеккеге ата-баба гадәтләре бетеп бара, улым. Күрше хәлен күрше белми, һәркем үз көнен үзе күрә, үз кайгысын үзе йота. Авыл очындагы ялгызак Гатаулла бабаң үлеп атнадан артык ызбасында яткан. Пучты кыз пинсә акчасын бирергә кермәсә, череп бетәсе икән. Син генә ала карга булалмассың Каратайда, кеше ничек яшәсә, шул рәвештә яшәрсең. Мөгаллимә катынны бүтәннәр тәрбияләр, Алла кушып.

— Юк инде, әнкәй. Бүтәннәр аны оныткан. Сара безгә кала. Син үзең, ярдәмчел булыгыз, дип үстердең түгелме соң?

— Ватык-җимерек дөньяны без генә төзәталмабыз, улым. Кешедән аерылып яшәргә тырышма. Сараны ризыктан өзмәм, сүземне аяк астына салып таптамасаң әгәр. Йөрмә ул катын йортына, гайбәттән саклан!

— Булды, әнкәй, бәхәсләшмик. Гайбәттән өркеп, синең ләгънәт-каргышларыңнан куркып, Сараны ярдәмнән ташлыйсым юк. Ул да кемнеңдер газиз баласы.

— Кечкенәдән үк үзсүзле, киребеткән идең, әле дә бу гадәтеңнән бизмәгәнсең икән, улым.

...Көндез ул мәктәпкә сугылды. «Мәктәптән булышалармы?» дигән сорауга Сара җавап бирмәде, һәм бу бик сәер иде.

Коридорның түр башыннан ук аны берсе:

— О, Арыслан Хабибуллович! Төкле аякларың белән! — дип сәламләп каршы алды. Караңгы иде, башта Арыслан тавыш иясен танымады. Мөгаен, аның кергәнен тәрәзәдән күргәннәрдер. Таныгач та гаҗәпләнмәде: Зифа — мәктәп директоры. Зифа — классташ. Зифа — кайчандыр Арысланга гыйшык тотып йөргән кыз... Укыганда бик чытлык иде, астыртын явыз иде. Бөтен класс алдында көлә-көлә егетнең Сәриягә багышлап язган шигырен укыды, аның иң яшерен хисләрен дөньяга чәчеп, оятлы итте. Ул Сәрияне күралмый иде. Шунда Арыслан Зифаны тотып яңаклады.

Алар мәңгегә дошманлашып калган кебек иде.

— Ишеттем, ишеттем, роно мөдире хәбәр итте, безгә укытырга киләсең икән, — дип, Зифа, балкый-елмая, Арысланга кулын сузды. — Хәтерлисеңме, син миңа суккан идең?

— Хәтерлим, әшәкелек җәза белән түләнә.

Ханымның йөзенә кызыл тимгел бәреп чыкты, юка иреннәре бөрешеп кысылды.

— Йә, син ни оттың инде шул Сәриягә багынып? Барып чыккан алкаш бит җанкисәгең!

— Минеке генә түгел, безнең Сәриябез, Зифа. Каратай Сәриясе уртак хәсрәт ул авыл өчен.

— Каратайның яманатын саткан Сәрияңне чүплеккә генә себереп түгәсе инде!

— Түксәң, авылы белән түгәргә монда. Тик минем йомыш ул түгел, Сара Сәфәрова язмышы өчен борчылып керү. Сез аны үги иткәнсез бугай, дүрт айда бер генә укытучы да аның хәлен белешмәгән.

Зифа ирен чите белән генә хәйләкәр елмайды.

— Ой, өлгер дә инде абзаң! Анда да җитешкән! Белешмәгәннәр икән, димәк, Сәфәрова үзе гаепле.

— Сүз бит кунакка бару турында бармый, Зифа ханым! Кеше үлеп, сүнеп ята, ни җаныгыз белән шуның капка төбеннән үтеп-сүтеп йөрисез? Йөрәгегезгә мүк үскәндер, ахрысы.

Ярсыды Арыслан, тавышы тәрәзә пыялаларын зеңгелдәтте.

— Чү, чү, Хабибулыч, — диде Зифа, еламсырап. — Талашалар, дияр халык, кычкырма алай. Ниндидер килмешәк Сара өчен тәмсезләнмик. Ул тинтәк чүт кенә безнең коллективның йөзенә юынтык су түкмәде. Нишләде, дисеңме? Укытучылар көнен бәйрәм иткәндә аракы эчмәде. Әртистләр кебек кыланып утырды. Имеш, укытучы кешегә хәмер кабу — җинаять. Әле роно мөдире Гатауллинга әләкләргә җыенды. Әләклим димәде, билгеле, ну без моны кыланышыннан сизендек һәм, Гатауллин килгәч, Сараны тоттык та лабораториягә кертеп бикләдек. Тәки төн кундырдык шунда. Мәйтәбез, кайнар башын суытсын, ниткән кешедән аерылу ул. Рас син коллективта эшлисең икән, рәхим итеп аның сулышын сула: эчәләр икән — эч, җырлыйлар икән — җырла. — Сагаеп тыңлаган Арысланны үз ягыма авыштырдым дип уйлаган Зифа ашыгып-ашыгып сөйләде: — Ә Хәлимә апаның туган көнендә ничек мыскыллады ул! Пианинода уйна әле, без кушылып җырлыйбыз, дигәч, исерекләр өчен уйный торган көем юк, диде. Икенче көнне Хәлимә апаны класска дәрес бирергә кертмәгән, авызыңнан хәмер исе аңкый, балалардан оял, дигән. Укытучыны бизиме инде мондый сыйфатлар, йә? Шуннан соң да син аның хәлен белергә кушасыңмы?

Бу хатын белән аңлашу-сөйләшү, кайда хаклык, кайда ялган — исбатлау-дәлилләү мәгънәсез иде, ир ишеккә борылды. Менә Сараны ни өчен яратмыйлар икән... Ул аларга охшамаган икән. Әле Арысланга да көзгә хәтле ике нәрсәне ачыклыйсы кала: ул мәктәпкә укытырга барамы, әллә көрәшергәме? Аның хыялы бөтенләй бүтән иде: шәһәрдә колакка чалынмаган «абый» сүзен балалар авызыннан ишетергә, алар белән чын күңелдән якынаеп, мәктәп өчен янып-көеп яшәргә теләгән иде ул. Ай-һай, булыр микән? Сарага кадалган пычак аның да бәгырен уеп-телеп төшермәс микән? Чынлап та, көчкуәт гайбәт сүз белән көрәшеп әрәмгә түгелмәсме? Аракы, хәмер ише азгын зат үтеп кергәч, бу изге йорт мәктәп дип аталырга хаклымы соң?

Арысланның эчендә әллә нәрсә шартлап сынды. Киң урамнар тарайды, шул тарлыкта җан да авыртып кысылды.

— Әссәламегаләйкем, мөгаллим абый!

Иске мәчет турыннан уйланып барган укытучыны кемдер сәламләде. Арыслан башын күтәрде. Мәчет капка төбендә чалма ураган яшь кенә мулла басып тора иде.

— Вәгаләйкемәссәлам, энем! Танымыйм, син кем баласы?

— Асса Сәмигулла улгы Габдулла мин, Арыслан абый. Сез авылдан чыгып киткәндә, без бик бәләкәй идек. Үткән ел Бохара мәдрәсәсен тәмамлап кайтып Каратайда муллалыкка керешкән идем дә... булмас, ахры.

— Тукта әле, мулла энем, ник булмас? Әйдә, аяк өсте гәпләшмик, утырышыйк.

Яшь мулла белән укытучы мәчет ишегалдына уздылар. Эскәмиядә комганнар тезелешеп тора, рәшәткәгә чуклы сөлгеләр эленгән.

— Картларга тәһарәт алырга әзерләп куйган идем, — диде егет, Арысланның сораулы карашын тоеп. — Тик җомга намазын үзем генә укыдым, йөрмиләр хәзер мәчеткә. Юкса көне дә аяз, юллар такыр.

— Йөрмиләр?! Алайса, яңа мәчетне нигә төзиләр?

Аксыл чырайлы мулла түш кесәсеннән дисбесен тартып чыгарды да кире тыкты.

— Уңайсызланма, мулла, дөресен әйт, — диде Арыслан.

— Аллаһы Тәгалә кичерсен, вәләкин мин эчемдәге зарымны бушатырга тиеш, мөгаллим абый. Күрше авыллардан көнләшеп торгызалар иман йортын каратайлылар. Бу мәчетебез дә, әлхәмделиллаһи, нык безнең, салынганына өч кенә ел. Мәчетебезне түгел, иманыбызны савыктырырга иде әүвәле. Шул ният белән Бохарадан тиклем юл сабуым иде. Угрыны угрылыктан, хөсетне хөсетлегеннән, явызны явызлыгыннан биздермәктә иде уем, гайбәттән тыярга, имансызлыктан арындырырга иде теләгем. Иренмәдем, йорт саен кереп вәгазь укырга керештем, Ходайның хак сүзләрен һәр күңелгә салырга тырыштым, хәлбуки ишекләр ачык булса да, түрдә миңа урын кысан иде, түрдә баш кунак — шайтан суы аракы, күңел мөнбәрендә байлык кайгысы, адәм дөнья куа, мал җыя. Казан калаларыннан капчык-капчык ташыган изге китапларыма кул тидерер вакыт тапмый. Иң яманы — битарафлык афәте халыкта. Каратайны мин генә денгә кертә алмамдыр, мөгаллим абый, китәрмен, ахры.

— Ашыкма, мулла. Ни йөрәк белән авылны ташламак кирәк?! Бу бит безнең кендек каны тамган җир! — Арыслан, баягы уй-хәсрәтен онытып, егетне үгетли башлады. — Читтә дә рәхәт түгел, тамакны туйдырырсың анысы, ә менә җанга азык юк. Авыл сагындыра, картайган саен, ул сагыш көчәя, яшь чакта гына диңгез тубыктан кебек, энем. Егерме елдан соң кайтты абыең Каратаена әйләнеп.

— Синең күңелең бозылмаган, мөгаллим абый. Синдәйләр авылда әз шул. Хаста мөгаллимәгә шәфкать күрсәтүең дә зур савап. Кыз-катынны җәлләгән бәндә — мәңгелек дога иясе ул. Андый затның үлгәч тә урыны җәннәттә.

— Рәхмәт, мулла. Аңлавың өчен рәхмәт. Без синең белән фикердәшләр икән. Иншалла, икәү тотынсак, каратайлыларны әз-мәз иман юлына таба турыларбыз. Авыл элеккеге матур гореф-гадәтләре белән яшәргә тиеш.

— Кайчакта, мөгаллим абый, ышанычлар киселеп-киселеп куя. Гомереңне заяга уздырып, томанадан галим ясарга кирәкми, җәһәннәм кисәүләре бит алар, дисең дә, тагын нәрсәгәдер өметләнәсең. Әнә бүген кич белән клубка артистлар килә икән. Каратай кәмит ярата, кеше күп җыелачак. Мәйтәм, концерт алдыннан халыкка өч-дүрт кенә үтемле сүз әйтеп төшәр идем. Атна-ун көннән уразага керәбез. Онытканы бардыр моны, хәтереннән җуйганы.

— Шәп бит бу, энем! Мин дә барам, кичкә көт. Сүз генә әйтмә син анда, вәгазь сөйлә, вәгазь.

Кич җитәргә өч-дүрт сәгать вакыт бар иде. Ир Сараның ишеген какты. Бусагадан ук шаулап-гөрләп:

— Хәлләр ничек, коллега?! Әйдә җыен, торналар сагынгандыр, — диде.

Әйтерсең лә укытучы хатын аны беренче мәртәбә күрә, беренче мәртәбә тавышын ишетә иде, сискәнеп китте, кулындагы китабы ирексездән шапылдап ябылды.

— Син?! — диде Сара, күзләрен зур ачып. — Син?! Юк, юк!

**5**

Көндез Арысланның әнкәсе ике тапкыр аш белән сыйлады. Сүзсез карчыкның икенче керүендә теле чишелде:

— Тамагың тук, идән-сәкең, кер-мазарың юылган булыр, балам, хәлемдә чакта тәрбия кылырмын үзеңне, син Арысланны гына биздер, йөртмә яныңа, — диде ул, — икегез дә кеше кешеләре, буйдак-фәлән түгел. Ил авызына иләк капламассың, тыкрык саен гайбәтегезне саталар.

— Без бит дуслар гына, әбекәй, — диде юрган астында куырылып яткан хатын. Ул шушы оялчан карчыктан үзе дә тартына иде.

— Сезнең дуслыкны икенчерәк иттереп сөйлиләр шул, балам.

— Арысланны «кер» дип чакырганым да юк, әбекәй.

— Безнекеләр әллә нинди халык инде, чакырмаган җиргә дә абына-сөртенә чабалар. Үзләрен дөнья кендеге дип саныйлар, Ходай бәндәсе. Каты гына әйтсәң, кермә, дисәң, пыжымлар ул, куып кына җибәрә күр! Минем хакка, балалары хакына! Син килерсең дә китәрсең, чит-ят ил баласы, аңа монда гомер итәсе бар. Синең аркада бөтенесе белән дә әчелешле булып бетсә, ничекләр торыр ул. Ир-ат илкөн белән бау ишә, диләр.

Арысланның әнкәсе чыккач та, хатын хәрәкәтсез калып озак кына түшәмгә текәлеп ятты. Кичтән ул уң аягын, кымшандыра-селкетә, караватчитенә салындырып ике-өч секунд тоткан, шул шатлыгыннан төнен изрәп йоклаган һәм иртән өмет белән уянган иде, йомшара башлаган бу аяк карчык сүзләреннән соң тагын шыкырдап катты. Ир бүтән килмәячәк, соңгы сүзен дә әнкәсе аша әйттергән кебек тоелды аңа. Һәм Сара үлде.

Бар өметләрен сүндереп үлде. Ул Арысланга шулай тиз ияләшермен дип уйламаган иде. Кешеләр, нигә сез шулай мәрхәмәтсез соң?! Бит Сара бары тик шушы иргә генә ышана, шушы иргә генә таяна, аның тизрәк тереләсе, сезнең сыман ук атлап йөрисе килә, моның ни гөнаһысы бар, йә?!

Хатынның күзенә мөлдерәмә яшь тулды. Ә тормыш, аның хәсрәтенә кул селтәп, җай гына ага иде. Сәрия керде, исәнләшеп тә тормыйча, карават астыннан чемодан сөйрәп чыгарды, капкачын бер ачты, бер япты.

— Алла, таракан да чапмый эчендә, буп-буш.

— Әнәдән җебенә кадәр сатып эчтең инде, Сәрия, алмашка сыңар күлмәгем дә калмады.

— Күлмәк, күлмәк! Аңлат менә шуны минем авырткан башыма! Махмырдан йөрәгем яна-а!

Карт кыз, кулын йозакка бикләп, ишекле-түрле йөренде. Аның күзләре аларган, чәче укмашып-укмашып иңенә сибелгән иде.

— Сәрия, сиңа кияүгә чыгасы иде, — диде Сара, аны кызганып. — Ялгызлыктан да эчүгә сабыша кеше.

— Кияүгә?! — Сәрхуш күкерт сыман дөрләде. — Башыма тай типкән мәллә минем?! Нәстәгә миңа ир, ни пычагыма?! Көчкә-мөчкә юнәткән яртымны бүлешеп эчәргәме? Аннары җилкәмә атланып дөмбәсләргәме? Кара син, авылда кайсы йортта җүнле ир бар?! Өч ел кочаклатып, өч кәлимә җылы сүз ишетмәссең. Шешәне мин ул имгәкләрдән башка да шәп бөгәм. Ух, баш мең кыйпылчыкка ярыла-а! Әйтмә миңа авыр сүз, телеңә тилчә чыккыры. Үзең чык иргә! Әнәтерәк Арыслан янында бөтерелә: күтәрә, төшерә дигәндәй.

— Ул ирнең исемен буяма, Сәрия.

— Абау ла, хараплар икән! Әллә синең Арысланың ап-ак оекбаштан гына болытлардан сикергән фәрештәме? Нибуч, тирәндә ниндидер өметләр белән буталадыр әле. Терелсә, тотып бер ... диядер. Ирләрнең һәммәсе дә бер чыбыктан сөрелгән, сары маем Сара.

— Махмырың көчәйгәндә, син артык зәһәрләнәсең, күрше. Бу чемодан күн тышлы, затлы әйбер, сатып җибәр дә башыңны төзәт. Салгач, синнән миһербанлы кеше юк бит ул.

— Чынлап та, сары май, чумадан кәттә, тиресе кыршылмаган, биге ватылмаган. Бет бете Сафагәрәй катыныннан аерылганда ыштан-трусик салырга гел чумадан эзли, шуңар сатыйм, булмаса. Әй, синнән дә шәп кыз-катын юк, Саракаем, валлаһи, җир йотсын!

Сәрия чемоданны өстерәп чыгып чапты. Тагын шомлы тынлык биләде хатынны. Ул, янә үз хәле, үз язмышы белән килешеп, китапка кадалды. Инде уку да туйдырган-ялыктырган, авыру җанга сүз тәме, сүз ләззәте барып җитә алмый, аның күзләре генә аңсыз рәвештә интегеп-азапланып хәреф чүпли иде. Хәзер аңа дөньяда бер юаныч та юк сыман. Соңгы көннәрдә генә могҗиза булып бусагадан атлап узган бәхетенең канатлары көйде. Аһ, ул аңа ничек ышанды. Юк, ышанмады, беркатлы юләр кешедәй алданды! Арыслан аны караңгы чоңгылдан күтәреп чыгар кебек иде. Ничек алданды, ничек алданды!

Бик күп өмет итте шул. Терелэм, диде, шул ир генә мине аякка бастыра, диде. Ә киртәләрне күрмәде. Күңелне алгысыткан төшләр, күл буендагы торналар йөрәген җилкетте, акылын алды, хисләрен чайпалдырды. Шунсыз терелүе дә мөмкин түгел иде! Нишләргә соң инде хәзер, и Раббым, нишләргә? Алга табан ничек яшәргә?! Ул кермәс микәнни бүтән, гайбәтләрдән шүрләр микәнни?

— «Юк» дигән сүз бездә юк, — диде Арыслан, йөзенә җәелгән елмаюын саклап. — Нигә шаккаттың син? Беренче тапкыр күргән шикелле. Әйдә җыен!

— Мин... мин сине көтмәгән идем, Арыслан.

— Ә син көт, көн туды исә, көт. Менә күрше керер дә, торналар карарга барырбыз, дип шатлан. Якты уй кәефне күтәрә, кан йөрешен тизләтә, гомерне озынайта. Күңел төшенкелеге кабергә сөйри. — Ир сөйләнә-сөйләнә хатынның юрганын аска шудырды. Сараның оялу-тартынуларын сизмәгән дә шикелле, бармаклары белән аяк балтырларына баскалады. Тәрәзә пәрдәләре кырыйга тартып куелган, урамнан өй эче күренеп тора, мөгаен, үткән-сүткән бу якка күз ташлап китәдер. Хатын кызарды, чүт кенә Арысланны этеп җибәрмәде. — Яле, йә, аякларыңны хәрәкәтләндер. Караваттан төшер. Мин булышмыйм, үзең тырыш, кызый.

— Кичә шулай эшләп карадым инде.

— Вәт молодец!

— Бүген... катты алар.

— Нигә? — диде Арыслан, сагаеп. — Безнең эшне ярты юлда бүлә торган гадәт юк. Әллә миңа ышанмыйсыңмы? Хәзер мин шуңа җәза итеп сине өйдән үк атлатып чыгам.

Сара, күз яше аша елмаеп, гәүдәсен караваттан күтәрде дә аягын сузды.

— Тамчы да авыртмады, — диде ул, сөенеп.

— Инде табаныңны идәнгә тидер һәм минем җилкәмә таян. — Ир чүгәләде. — Без икәү берьюлы басарга тиеш.

— Ай, егылам!

— Егыла башласаң, миңа ябышырсың, курыкма! — дип дәртләндерде Арыслан.

— Бу җәзаңны кире ал, Арыслан!

— Бусына икенчесен дә өстим, бел. Миңа ышанмаган өчен булыр.

— Син каты бәгырьле. Син...

— Әйе, мин вәхши, кансыз, миһербансыз, — дип тезде ир, — чутсыз-исәпсез начар сыйфатларга ия зат.

Хәлсез бармаклар теләр-теләмәс кенә иңбашка орынды, әмма Арыслан тураеп баскан саен, алар чытырдап ябыша, мөгаен, Сара ычкынып китеп егылудан курка иде. «Әгәр аңа булышам дип биленнән тотсам, ул гел ярдәм генә көтеп торачак, — дип уйлады ир. — Болай да, гарипләндем дия-дия, ятакка береккән, юкса ике аягы да сау-сәламәт, тыпырдап биерлек. Адәм баласы күңеленә «үләм» дигән уй кертсә, чирләмәгән килеш тә тәгәрәп үлә икән шул».

— Арыслан, тәрәзәдән күрсәләр, болар кочаклаша, диярләр.

— Сөйләшмә, көчеңне телеңә сарыф итмә, аякларыңа күчер.

Хатын кыска буйлы иде. Арыслан исәпләвенчә, ул җилкәдәге кулын, буена чамалап, йә күкрәккә шудырырга, йә беләккә тотынырга тиеш. Ул хәзер барысын да үзе уйларга тиеш. Яшәргә омтылган кеше коткаручысына теше-тырнагы белән ябыша.

Сара әйтерсең аның уйларын укыды, чытырдатып ирнең беләген кысты. Менә Арыслан бөтенләй торып басты. Хатын да аннан калышмады. Аның мышык-мышык елаганын тыңлавы рәхәт иде. Тез буыннарын дерелдәтеп тора бит, тора, рәхмәт яу-гыры!

— Молодец, Сара! Батыр кеше син, Сара! Йә, җитәр, утыр. Аягыңа көч килер.

— Тагын әз генә, Арыслан. Тәмам ышаныйм инде. Нинди бәхетле мин! Бәхетемнән елыйм, тыелып булмый. Рәхмәт сиңа!

Сараның күзләре очкынланып яна иде. Соңгы тапкыр кемне шулай бәхетле итте соң ир? Кем аңа ихлас рәхмәтен укыды? Хатынымы, әни карчыкмы, дус-ишләреме? Аңа һәммәсе дә, бу тиле, ахрысы, дигәндәй, сәерсенеп карый, берсенең дә йөзендә бәхет әсәре күренми. Ә бит яшәүдән дә татлы,

исәнлектән дә кадерле әйбер дөньясында юк! Бу хатын шуны тоя, ичмасам, тоя да, сөенечен күзеннән ташытып, оялмый-нитми елый, көлә, елмая...

— Әүвәлгесе — актыккысы, кызкай. Сиңа тәпи-тәпи йөрергә вакыт, — дип, бармак яный-яный, Сараны кул арбасына чыгарып утыртты ул.

— Торнаны син ашатасың бүген... Синең чират...

...Сазлык күл буенда искиткеч матур иде. Көнозын кыздырган җылы кояш нурыннан тагын да кабарган күпертек чирәм келәм кебек йоп-йомшак, хатын, гәүдәсенең тигезлеген югалтудан әз генә чайкалып, аягын җиргә тидерде. Карашын әле унга, әле сулга күчерде, гүя табигатьнең бар ямен, бар төсен күзләренә җыеп бетерергә тели иде.

Аннан ул күкрәк тутырып сулады да:

— Минем бик-бик яшисем килә, — диде. Тавышы моң белән өретелгән иде. — Гомернең һәр минутын, һәр секундын иң зур бүләк дип яшәр дә яшәр идем. Көн саен пианинода уйнап, яңа көйләр язар идем. Ул көйләр сагышлы булыр, әмма берәүнең дә кәефен кырмас, чөнки сагышы бары тик минем җаныма гына сыланыр, ә тыңлаган кешенең колагын тылсымлы авазлар иркәләр. Мин үземне-үзем генә чиргә сабыштырдым. Яраткан кешем үлде минем. Бөтен тормышыма кара пәрдә ябып, күңелемнең ишек-тәрәзәләрен бикләп китте ул. Ник аның белән янәшә кабергә кереп ятмадым, дия-дия яшәдем мин. Яшәмәдем, билгеле, җирдән генә сөйрәлдем. Җан тәнгә түгел, кабыкка гына төренгән иде. Тамырлардан кан түгел, бозлы су акты. Син югалтуның нәрсә икәнен беләсеңме, Арыслан? О, юк, белмә, белә күрмә! Иң әүвәл, үзеңнән алда, дим, яраткан кешеңә исәнлек белән гомер теләргә кирәк икән ул.

— Йә, тынычлан, Сара. Син кайчандыр яраткансың, сине дә яратканнар. Бу — зур бәхет. Аның рухын рәнҗетмим дисәң, тизрәк савык, ул бит синең чирләвеңне бер дә килештермәс иде. Ә-әнә торна сиңа таба теркелде. Каршысына бар әле. Мә, ипи кисәге.

Сара җиргә береккәндәй кузгалмады. Ул җилдә чайкалган зәгыйфь үләнгә охшаган иде.

— Гөпелдәп барып төшсәм... мәңге торалмам.

— Өч кенә адым атла.

— Юк, Арыслан. Иртәгә, яме? — дип ялварган хатынны ир җитәкләде дә күл кырыена әйдәде. — Бер, ике, өч, — дип санады үзе. Аннары: — Дүрт, биш, — дип дәвам итте хатын. — Алты, җиде... Хәзер үзем, җибәр!

Яңа гына тәпи баскан бала сыман, Сара атлады да атлады. Күл өстенә аның чыркылдык тавышы таралды:

— Йөри-и-им! Күрегез, йөри-и-им!

Хатынның терелүенә Арыслан да торна гына шаһит иде. Гомернең бер көне бушка узмады бугай. Ипи валчыгы чүпләгән кош белән Сарага карагач, ирнең йөрәге җылынды. Шушы ике җан бу мәлдә табигатьнеңербөтен затына әверелгән иде.

...Кич белән ул клубка ашыкты. Чалма-чапанын киеп, яшь мулла да килеп җитте. Икәүләшеп директор бүлмәсенә керделәр. Тар гына бүлмәдә балта эләрлек булып куе тәмәке болыты асылынган, өстәл артында чүңкәешкән өч ирне көчкә генә шәйләрлек иде. Борынны ярган хәмер исеннән мулла егет төчкереп җибәрде.

— Нәстә кирәк? — дип кычкырды йөзен сакал-мыек баскан ир. Һәм җәлт кенә шешәдән кырлы стаканнарга аракы койды да Арыслан белән муллага сузды. — Мәгез, чөмерегез дә үкчәгезне ялтыратыгыз! Йөрмәгез монда иснәнеп.

— Тукта әле, энем, син безне танымадың бугай, — диде Арыслан, мулла егетне киң җилкәсе белән ышыклап. — Мин — мөгаллим абыең, бусы — хәзрәтебез.

— Тфү, абзыкай, танымадым шул. Иснәнеп йөрүчеләр дип торам. Кәнсирткә килдегезме? Мона артсыз эскәмия, алыгыз да сәхнәгә якынрак урнашыгыз.

— Мәшәкатьләнмә, энем, безгә урын-фәлән кирәкми. Халыкка муллабызның әйтер сүзе бар иде.

— Абзый, моны мин хәл итмим, мин прастуй директор гына. Прид баш бездә, аңа баш иегез, ул сәхнә артындадыр, артистлар янында.

Сүгенә-сүгенә шар тәгәрәткән яшьләр төркемен аралап залга үткәндә, Арысланның кәефе төшеп бара, күңел нигәдер пырдымсызлана иде. Клуб шыгрым тулы, кеше күп иде.

— Мөгаллим абый, — дип пышылдады мулла. — Кемнеңдер рөхсәтен сорап вакыт уздырмыйк, сүземне тиз генә әйтеп төшим.

Очып кына сәхнәгә менгән егетне бермәлне халык кул чаба-чаба, аяк тибә-тибә куарга кереште. Клубта мәхшәр купты.

— Без артистлар тыңларга килдек!

— Без акча түләп кәнсирт карарга җыелдык!

— Төш, артистлар чыксын!

— Мәчеттә акыл сат! — дип үкерде халык.

Яшь мулла «бисмилла» дип авызын ачкан килеш кинәт катты да калды.

Арыслан аңа ярдәмгә ташланды, бугазы ертылганчы кычкырды:

— Авылдашлар, нишлисез сез?! Оятыгыз бармы, юкмы?!

Клуб кызып өлгергән иде, берсен-берсе бүлә-бүлә укытучы өстенә сүз ташы яудырды:

— Синнән сорамыйлар, Себер хәерчесе!

— Хәбибулла малае да акыл чәчмәкче!

— Гарип укытучы белән өстерәлүеңне бел! — дип бәгырьне актарганда, пәрдәне як-якка этеп, сәхнәгә рәис чыгып басты.

— Нәстә акырасыз, хайван көтүе?! Пажармы әллә авылда?! Ә сез нәстә кукраештыгыз? — Бусы мулла белән Арысланга әйтелде. — Халыкның дуңгыз икәнен пәнимайтыдыр бит. Аларга кәмит тансык. Акча бирдем, биш ай алмаган палучкыны, бер машина әрҗәсе аракы китереп саттырдым, ирекатыны эчеп бук булды бүген, пәнимайты? Лык алар, авызларыннан ага. Ну, уборкада су да эчертмим, хайван тәреләр. Быел урожай шәп, убират итәбез мамент. Биш комбайн, два «Дон», десяткы машина, мамент убират итәбез. Олыгыз-кечегез кырга, никакуй өйдә яту. Кәнсәләргә шаг та атлатмыйм итү, ярты уч зерна яздыртмыйм. Вчю минем сүз. Башла кәмитне!

Үзе дә лык рәис, мендәр хәтле корсагын чайпалдырып, идәнгә сикерде. Чарасыз калган Арыслан белән мулла ишеккә юнәлделәр.

— Бу кайсы авыл, мөгаллим абый?! — диде мулла, караңгы урамга чыккач, сыкранып.

Арыслан авыр көрсенде.

— Безнең авыл, энем, безнеке...

— Борынга шәп тондырдылар, мөгаллим абый. Ул клубка ерткыч-җанварлар җыелгандыр, мөгаен.

— Җанварларда тәртип бар, энем. Алар табигать кануннарына буйсына.

— Ялгыштык без, авыл дип ялгыштык. Ходай сабырлыклар бирсен! Хуш, мөгаллим абый.

— Хуш, энем.

Төнге һава дымлы иде, җиһанны чуарлаган йолдызлардан да салкын бөркелә, җан-тән өши, туңа иде. Клубтагы күренеш Арысланны соң дәрәҗәдә тетрәндергәнгә күрә, уй бернәрсәгә дә күчми, гел шунда агыла иде...

**6**

Сара караватына ятсынып карады да, аркасын мичкә терәп, идәнгә утырды. Хәл юк, баш әйләнә, күз алдында соры таплар биешә иде. Хатын табанының кадап-кадап чәнчүеннән йөзен җыерды. Авырту яңадан тәнгә иңә кебек иде. И Раббым, сөяк-санагыңны җыя алмыйча, идәндә аунап ятсаң! Арыслан янында гына могҗиза филтәсе кабынып, ул гаип булуга, барысы да өф иткәндәй сүнсә?!

Чемоданны кире өстерәп, Сәрия кайтты.

— Алмады Бет бете! Планда катын белән аерылышу каралмаган, ди. Терсәктән күлмәк җиңен сызганып кер юа! Уф, башым ярыла-а!

Бичара сәрхуш Сара өстеннән атлап чыкты да гөрс итеп караватка ауды, сиртмә шыгырдап урталай бөгелде.

— Сәрия, — диде Сара. — Өйдәге үзгәрешне сизмисеңме әллә? Мин йөри башладым.

— Йөрсәң ни, — диде карт кыз, гамьсез генә. — Синең йөрүеңә караганда, минем баш мөһимрәк. Белмисең син баш хәлләрен! Чумаданыңны Бет бете алмады, дим ич! Үләм мин хәзер, йөз грамм капмасам, йөрәгем туктый. Ул, йөрим, ди, кеше үлә дими.

Фәрдәнә, ишекне сыза гына ачып, борынын тыкты.

— Әлләү-бәлләү, болар урыннарын алмашкан түгелме соң?! И яталар матур гына.

— Әй син, ана көчек, туры бармак, кәкре сыйрак, яп ишекне, торма сайрап, —дип үкерде Сәрия. Һәм мендәрне Фәрдәнәгә томырды.

— Фу, сасы аракы кисмәге дулый. Бүген каптырмаганнар, ахры, сиңа.

— Кызлар, җитте сезгә! Талашмагыз, үртәшмәгез, — диде Сара, — хет шатлыгымны уртаклашыгыз. Мин терелдем!

— И-и, моны юарга кирәк! — дип, Фәрдәнә сарайга йөгерде һәм култык астына ярты кыстырып кереп тә җитте.

Шешә күргәч, үләргә җыенган Сәрия кымшанды, караваттан шуып төште дә:

— Изге кеше син, Фәрдәнә күрше, — дип ялагайланып, идән уртасына бастырып куйган шешәгә үрелде. — Авылның иң чибәр катыны да син. Сал әле шул хөрмәткә йөз грамм, деңкик әле, малай.

— Оста барда кулың тый, кисмәккәем, Сараның тәпиләнүе хөрмәтенә бу, ул бүлсен.

Ике «ахирәт», аяк бөкләп, шешә янына урнаштылар.

— Мин эчмим, — диде Сара. — Кыстамагыз, күршеләр.

— Әйем, ялынма, Фәрдәнә малай, киребеткән бит ул. — Иңенә бәхет кошы кунган Сәрия бөкене теше белән каерды. — Үзебез дә яхшы сыпыртырбыз зәмзәм суын.

Кемнәр сине уйлап тапкан,
Аракы дигән явыз?

Шул явызны эчәр өчен
Шапылдап тора авыз.

Әйдә, төбенә хәтле корытыйк!

Хатыннар голт-голт стаканнарын бушатты, икесе дә кәефләнде.

— Бер уйласаң, синең аяклануың иллә әйбәт түгел, Сара, — диде Фәрдәнә. — Ирләремне чәлдермәгәең.

Кабымлык урынына күлмәк итәген иснәштергән Сәрия аны тынычландырды:

— Һи, кысыр хәсрәт, хәсрәтләнмә, Фәрдәнәкәй. Арыслан белән сазлы күлдә торна ашата алар, аннары тал төбендә көй сызгырта.

— Әдә сызгыртсыннар, синең ни эшең бар, әлкәшбикә, — дип, укытучыны якларга кереште Фәрдәнә. Башка вакытта Сәрия «әлкәшбикә»сен танытыр иде, хәзер ярамый — шешә бушамаган, аның хуҗасы — «ана көчек» — нәрсә генә ырласа да түзәргә кирәк. — Сара да кыз-катын өммәтеннән, утын пүләне түгел. Пәйгамбәр барган, ди, бит әнә Ходай катына. Нишләтим, катыннар азды, гүләйт итәләр, дигән, ди. Ходай әйткән ди, үрчесеннәр, дип.

Сара янды-пеште. Хатыннар гайбәте яндырмый иде, күңелдә оялу хисе уянды. Нигәдер Арыслан турында ешрак уйлый башлады ул. Дөньяда Шамилгә охшаган ир заты тумаган дип саный иде, баксаң... ялгышкан икән. Аны күрер өчен чакрымнар үтеп Каратайга килергә насыйп булган икән. Тик чакрымнар мәхәббәткә таба илтми, аңа юл ябык, мәңгегә ябык... Яратуны йөрәк аша бер кичерде хатын, нинди көчле иде ул гыйшык! Нинди кайнар, нинди тирән иде. Кемгә тәтегән ди мондый мәхәббәт! Бүтән ир чырае күрмичә ялгыз гына гомерен очласа да үкенми Сара: белде, күрде, татыды ул яратуны, тәнендәге һәр күзәнәгенә кадәр кереп тулды сөю, тамырларыннан шаулап акты. Шушы мәхәббәтенә хыянәт кылмаска тиеш хатын, башкалар хакында уйлап бәргәләнмәскә тиеш. Төшләр — юләрлек, теге сыерчык канатыдай коңгырт күзле ир дә — буш хыял...

Хатыннар шешәне бушаткач, икенчесенә тотындылар. Теле бәйләнгән Фәрдәнә Сәрияне кемгәдер кодалый, тегесе һаман карыша иде:

— Чуртыма синең Сабир каенишең, күршекәем. Таныштырма да, кавыштырма да. Син лутчы ярты бир миңа, мужикларың шайтаныма олаксын! Эчсәмме... эчсәм, дөнҗа минеке була да куя ул.

— Теге дөнҗаңа кыз килеш барсаң, кызган тимер белән тишәләр, ди, әлкәшбикә, тәмуг җыеп бакырасыларың бар әле.

— Син лутчы сал. Минекен тишәрләр, синекен ямарлар, белерләр анда.

Күршеләр исерешеп идәнгә тәгәрәште, Сара караватына якынаерга базмады, мичкә сөялеп йоклады. Җәй төне кыска, күзгә йокы эленмәде, хатын торып титаклый-титаклый сазлы күлгә китте. Урман-кырлар, ерактагы офык аңа каршы йөгергән кебек иде. Яр буенда канат җилпегән озын торыклы кош тирә-якны яңгыратып аваз салды! Бу аның иртәнге кунакны сәламләве иде, күрәсең.

— Исәнме, ак торна! Көзгә хәтле мин сезнең хәл-әхвәлләрегезне сорашып торырмын. Аннан хәерле сәфәрләр теләп озатып калырмын. Сез китәрсез, ак торна... Кире әйләнеп кайтыр өчен чит җирләргә китәрсез. Хәзер сез минем бердәнбер юанычым. Ияләштем мин сезгә. Терелүемә дә күпмедер дәрәҗәдә сез сәбәпче. Тәрәзәдән күрендегез дә кызыктырдыгыз. Ә сез Арыслан атлы ирнең нинди изге зат икәнен беләсез микән?

Кинәт ана торна, төлкедән өркегәндәй, сазлыкка ыргылды. Күл буеннан иңнәренә кәтмәннәрен асып шаулаша-шаулаша бер төркем хатын-кызлар килә иде. Алар, Сараны күргәч, дәррәү авызларын йомдылар һәм кырын карый-карый узып киттеләр.

Кич белән мәктәп директоры Зифа ишек шакыды. Сара мич аклый иде, идән-урындыкка акшар чәчрәгән, кунакны утыртырга урын да юк, караватта Сәрия йоклый иде. Директор хатын җирәнгән кыяфәт белән өй эченә күз йөртеп чыкты, түргә узмыйча гына ишек янагына сөялде.

— Хатыннар күл янында күргәннәр сине, аягыңда басып тора, диләр. Ышанмадым, тукта, мәйтәм, керим, күрим. Бәлки, син җүри-марый гына яткансыңдыр. Пенсия ясатыр өчен. Гарип-горабага күп түли хәзер хөкүмәт.

— Зифа ханым...

— Җә, җә, турсайма. Мин сине тикшерергә кермәдем. Мәктәпкә ун гектар чөгендер басуы бүлеп бирделәр. Иртәгедән барча укытучыны да басуга куам. Сиңа да кагыла бу, Сара. Авыл укытучысына җәйге ял юк, җанашым.

— Нәстә-ә? — Бөгәрләнеп яткан Сәрия күзен-башын акайтып торып утырды. — Нәстә ди? Чөгендергә кушамы? Әй син, күсе борын, Сара кичә генә аякка басты, хәлсез әле ул, аңа ниткән басу, ниткән эш?! Нинди бәгырьсез халык соң сез, тәре җаннар, туң күчәннәр!

— Фу, бәхетсез алкашка! Кысылма безнең сүзгә, эчсәң, буеңа сеңдер.

— Ә син — Күсе Борын! Класста малайлар шундый кушамат такты сиңа, хәтерлисеңме? Берәү дә яратмый иде үзеңне, син әләкче идең.

— Хурлама мине, сасы дуңгыз!

Сараның йөрәге туктый язды. Тагын аның йортында тавыш-гауга! Ул өр-яңадан тормыш башларга җыенган иде. Өен юып-чистартып, пакьләнеп-сафланып, ниһаять, җан тынычлыгына ирешеп. Булмас микәнни соң...

Ишек төбендә Арыслан тамак кырды.

**7**

Ир кәефсез. Пырылдап өйдән чыккан Зифага да, аны «иртәгә Сара өчен чөгендергә үзем барам, Күсе Борын» дип кычкыра-кычкыра озатып калган Сәриягә дә мыек очын селкетмәде, аның үз кайгысы көчле иде. Яшь мулла гарьлегеннән җыенган да авылдан киткән. Арыслан аңа күпме өмет баглаган иде!

Имеш, бергәләшеп Каратайны иманга китерәләр... Түзмәде егет, сынды.

— Юлыннан кире борыйк, машина белән артыннан куып тотыйк, — дип, кәнсәләргә барган укытучыга рәис кара көйде.

— Җук белән баш катырасың, пәнимайты, изге урын буш тормас, алмашка Бугаз Гәрәй бар, — диде. — Минем мулладан гайре дә эш муеннан. Терлекләр ач, сыерлар саумаган, халык һаман баш төзәтә, айнымый, пәнимайты.

— Җүнле җитәкче халыкны аракы кисмәгенә чумырмый. Ник авылга шул зәхмәтне кертәсең? Тый!

— Ил белән лыкыналар, Каратай гына әүлиялар утравы түгел сиңа. Ничу акыл өйрәтергә! Кибетендә саттырмасаң, карчык-корчык биш бәягә итәк астыннан шудыра.

— Сез үзегез дә халыкның гайрәтен чигерерлек эшләр эшлисез бит, рәис туган. Мулланы авыл картлары җыелышып сайласын иде. Гәрәй абзыйның әхлаксыз бәндә икәнен беләсең.

— Безнең Каратайга Гәрәй кебек аждаһалар бик тә таман ул, кулы каты аның, пәнимайты.

— Хикмәт кулдамыни? Хикмәт — иманда.

— Бар, аждаһа белән үзең гәпләш, Арыслан абзый. Минем җилкәдә ит, малака, зерна, техника, пәнимайты. Иманыгызны үзегез карагыз.

Мунчадан чыккан Гәрәй «мулла» тирләп-пешеп чәй эчә иде. Ишек катындагы таныш тартмага чүт абынмады Арыслан. Кайсыдыр елда, авылга кунакка кайткач, клуб мөдире аңардан ашыктырып шушы тартманы ясаттырган иде. Сайлау өчен кирәк иде ул. Арыслан, буяу җитмәгәнгә күрә, бер ягын — зәңгәргә, икенче ягын акка буяган иде.

— Кем, энем, бик аптырама шул савытка карап. Садака җыя торган нәмәстәкәй ул. Бисмилланы әйтеп сал шунда акчаңны. Кич белән ата-анаң рухына белгәннәремне укыштырырмын, — диде Гәрәй, чәен шопыра-шопыра.

— Мин әле хәтерлим, Гәрәй абый, син парторг идең. Намазлык өстендәге әбине, типкәләп торгызып, ашлык чистартырга кудың, ә ишек башындагы «Аятел Көрси»не чыбыркы сабы белән сугып төшердең дә: «Динегезне, денегезне черетим», — дип сүгенә-сүгенә таптадың. Шул чактагы иманың белән генә яшәсәң, мин сине хөрмәт итәр идем.

Күрәсең, Гәрәй аны танып өлгермәгән иде, исе китеп:

— Һә-һә, Жандар Хәбибулла малае ла бу, — диде. — Ишеттем, ишеттем. Каратайны бутап, кешеләрне котыртып, әллә ниткән зиначы мөгаллимәләр белән чуалучы бәндә син. Инде миңа чиратың җиттеме? Инде мин гөнаһсызның йортына кереп мазаларгамы ниятең?

— Юк, Гәрәй абзый, сиңа бер генә гозеремне әйтәм: кеше бул, баш тарт муллалыктан. Заманында авылны кан елаткан адәм калдыгы бит син!

— Энем, теге чактагы эшем белән бусының һич аермасын күрмим: элек взнос җыя идем, хәзер — садака. Йөрмә бушка чабулап. Карты-яше үзе мине сорады. Каты кул кирәк, диделәр әммәсе дә, каты кул. Сыртларын чыбыркы белән каезлаган заманнарны сагыналар. Тәртип урнаштыр, диләр, һәк-һәк-һәк. Күрсәтәм әле мин аларга күрмәгәннәрен, иншалла. — Гәрәй боргычлап тоткан сөлгесе белән ләззәтләнеп муенын ышкыды. — Һәк-һәк-һәк...

«Карты-яше сорады, карты-яше...» Арысланның мие түнде. Сукырмы әллә халык, әллә аларны җен-пәриләр алмаштырганмы? Әнисе әйтмешли, хәерлегә генә булсын...

— Арыслан! — Сәрия аңа эндәшә икән, ир өметсез карашын аңа төбәде. Бер генә секунд эчендә Каратай шушы сәрхуш кызның йөзендә чагылып үткәндәй тоелды. — Арыслан,niләр уйлыйсың син, тыңла әле мине дә. Зифага, дим, укытучы башы белән талашып йөрү килешәме инде, ә? Ярый безгә, надан Фәрдәнә белән миңа.

— Берегезгә дә килешми. Сара сездән Каф тавы артына таяр әле.

— Һи, таяр сиңа! Авылда бөтенләйгә калырга исәбе: юа-җыя, мичләр аклый.

— Өзлекмәсен, савыгып җитсен, өлгерер.

— Чөгендергә куа әле Зифа! Үзем барам, иртүк аракы тапмасам, чифир ясап баш төзәтермен. Бер пачка чәйне ярты литр суга салып кайнатасың да, шул була чифир. Куыра инде кан тамырларын, малай гынам, айга сикертә.

— Ташла эчүеңне, Сәрия. Авылның бәрәкәтен качырасың, диләр, картлар тирги.

— Каратайда бәрәкәт качыручылар бер мин генәме?! Кайсы гына йортның капкасын шакыма, һәркемдә бозык, ялган, хәсрәт, мәкер. Ә ул моны күрми, кеше чәйни, кешедән көлә, кеше хурлый. Гайбәт оясы бу авыл, билләһи газыйм! Никләр Себереңнән кайттың, бахыр? Син карга көтүендәге ак күгәрчен төсле бездә. Син дә, Сара да. Тырышмагыз да, денгә кертә алмыйсыз халыкны!

— Сәрия, син йомшак күңелле, акыллы кыз идең, эчмә бүтән, тый нәфесеңне. Менә көз аенда яшьлекне яңартып концертлар куя башларбыз, син дә катнашырсың.

— Чынлапмы, Арыслан? — Сәрия тузгыган чәчләрен җыйнаштырып куйды, бөгәрләнгән күлмәген сыпырды. — Мин акыллы идемме?

— Акыллы идең, хәзер дә акыллы син, Сәрия.

— Җырлаганымны да ошата идеңме?

— Рәхәтләнеп тыңлый идем, чишмә буйларында икәү йөргәндә, син гел җырлый идең бит.

— Ие шул, Арыслан... Кара, онытмагансың икән. Әгәр... әгәр эчүдән туктасам, үз арагызга аласызмы соң? — дип шикләнеп кенә сорады кыз.

— Вәгъдә, Сәрия! Клубта синең кебек оештыру сәләтенә ия кеше кирәк, ул мәсьәләне дә кузгатырбыз.

— Ай Аллам! Җылы сүзләрең өчен рәхмәт, Арыслан. Болай мактап үсендергәннәре юк иде әле.

— Сара, Сара, үтергеч хәбәр. Арыслан ни ди... — Сәрия очып кына ызбага кереп китте, Арыслан да өенә юнәлде.

Дөньяны тәртипкә салырга кирәк иде. Балтаң суга төшкәндәй, баш иеп, борын салындырып йөрсәң, көймәң комга терәләчәк. Кемдер упкын читендә торган Каратайга иман нуры сеңдерергә тиеш. Укулар башлангач, Арыслан балалар белән бергә авылның тарихын өйрәнергә керешер, үткәненә төкергән адәм бүгенгесен дә, киләчәген дә санламый. Әйе, ул җиң сызганып керешер. Тамчыдан күл җыяр. Күңелләреннән җыр-моң качкан авылдашлар, һичшиксез, үзгәрер, рухлары савыгыр, җаннары сафланыр.

Икенче көнне өмет-хыяллар белән булашып кичкә хәтле ишегалдында такта шомарткан Арыслан Сараның хәлен белергә керде. Аның тизрәк якты уйлары турында укытучы хатынга сөйлисе, аны үзенең теләктәше итәсе килә иде.

— Мин җыр язам, Арыслан! —дип сөенеченнән балкып каршылаган Сараны ул чүт кенә кочаклап үпмәде. — Менә сүзләрен дә үзем уйлап таптым, балалар өчен бу, «Торна җыры» дип атала. Хор оештырырга уйлыйм, син моны хуплыйсыңмы, юкмы?

— Бишкуллап, Сара! Безнең әле алда эшлисе эшләр, безнең... — Арысланның сүзе бүленде, ишектә йөзе шикәр сыман агарган Сәрия күренде. Ул сөйрәлеп кенә бусагадан үтте дә капчыктай идәнгә ишелде.

— Мин... айнык, шыр айнык. Мин... тәүбәләгән идем иртән, бетте, вчү дип, эчмим дип... Әбинең Коръәнен үбеп тәүбәләгән идем... Арысланның ышанычын акларга иде исәбем... Ул бит мактады... Эчмә, диде... Ә алар... үтерде. Чөгендерче катыннар кәтмән белән кыйнап үтерде... Чирәм өсте гел кан...

— И Алла, синең миеңә кояш суккан бугай! — Сара, гаепле кеше сыман, иргә карады. — Ни... Арыслан, ул минем өчен чөгендер сирәкләргә барган иде. Көне дә кызу булды, ичмасам. Нишләтик инде, ә? Табибка илтикме?

— Юк, Сара, аңа кояш сукмаган. — Арыслан карт кызның йөзенә иелде. — Сәрия, кемне үтерделәр?

— Ике өстерәлчекнең мәхәббәт кошы, диделәр дә көлә-көлә ана торнаны кыйнап үтерделәр... Атасы котылды... Әй әйләнә баш очында әче тавыш белән кычкырып, әй әйләнә, бахыр... Жук, Арыслан, сөйли алмыйм, йөрәгемә кан укмашты... Жәллим, жәллим дә! Жук, чыгып эчәм лутчы, бастырам лутчы бу хәсрәтне аракы белән!

Мизгел эчендә Сараның күзләре түгәрәкләнеп зурайды. Ир аны тотарга өлгермәде, хатын аңын җуеп егылды...

## 8

...Давыл төн уртасында башланды. Өй кыекларында сызгырып, сәлам генә биреп үтәрдәй тоелган җил отыры көчәя, кул-бармаклар үстергән дәҗҗал кебек, ишек-капкаларны, тәрәзә яңакларын йолкый-тарта. Торна хәбәреннән җан тынычлыгын җуйган Арыслан уяу иде, торып әнисен, хатыны белән балаларын уятты.

— Нәрсәгәдер шомланам, әнкәй. Нидер булыр төсле. Сез тиз генә мендәр-ястык алып базга төшегез әле. Баз идәне чиста, салам җәйгән. Анда ышык та, куркынычсызрак та.

— Хәерлегә генә булсын инде, улым. Җил бигрәк котыра. Әйдәгез, балалар, әйдә, килен. Сакланып атла, корсагың да бигрәк дәү.

Өйдәгеләрне урнаштыргач, кылт итеп Сара искә төште. Хәер, ул хәтердән бер дә чыкмый иде. Хатын егылып маңгаен тиште, исенә килгәч тә әрнеп, такмаклап елады:

— Минем аркада бу, Арыслан, китәргә кирәк миңа, китмәсәм, тагын әллә нинди бәла-казаларга тарырбыз, — диде.

Әнисенең ай-ваена карамыйча, Сәрияләргә йөгерде ир. Эчеп төтен булган карт кыз күзен дә ача алмый иде. Арыслан, аны күреп, Сараларга ашыкты. Сара ут элгән, йокламый иде.

— Фәрдәнәне уят та, өчәүләшеп аның базына яшеренегез, — диде ир, кыска-кыска әмерләр биреп. — Зилзилә тынмыйча кымшанмагыз.

Капка төбенә җиткәндә, җил-давыл аяктан егарга маташа, җирдән тузан-туфрак күтәрелеп күзне каплый, авызга тула иде. Теш арасында шыгырдаган балчыкны төкереп, Арыслан баганага ябышты. «Авылны уятырга иде бит», — дип үрсәләнде ул. Өермә ташкыны ут чәчрәтеп электр чыбыкларын өзде, бәйләме белән аның өстенә ыргытты. Ярый ул башын читкә борып өлгерде, югыйсә дөрләп янaчак иде. Утлар сүнгәч, авылны караңгылык йотты. Кинәт күрше йортның шатыр-шотыр каерылган калай түбәсе очып барып юлга капланды, шиферлар меңгә теткәләнеп ярылды, тәрәзә пыялалары челтерәп коелды. Әйтерсең дөньяны кемдер зур кәйлә белән бәрә-кыйный, изә-вата иде. Халык уянды бугай, җиһанның астын өскә китергән давыл эченнән өзек-төтек тавышлар ишетелде: кемдер чинады, кемдер үзәк өзгеч итеп акырды... Арыслан шуыша-үрмәли ишегалдына керде, артыннан гөрс итеп багана авып калды. Кармалана-капшана гына баз капкачын тапты ул, үзенең көчсезлегеннән, мескенлегеннән гарьләнде. Нишләтәсең, әлеге дәһшәт белән көрәшерлек әмәл юк иде.

— Хәлләр начар, әнкәй, — диде ир, тузанлы битен сыпырып.

Ана карчык шәм кабызып куйган иде, тонык ут яктысында улының газаптан җыерылган йөзен күрде һәм, куркынып:

— Ахырзаман мәллә, балам?! — диде.

— Шуңа охшаган, әнкәй. Каратай аша зәһәр давыл уза.

— И Ходаем, нинди гөнаһлары өчен җәзалыйсың бәндәңне?! Ни гомер яшәп булган хәл түгел.

Сәгать телләре санап атты таң. Өстә котырды, дулады, бәрде, сындырды аждаһа һәм керфек селкетерлек тә җил әсәре калдырмыйча югалды. Арыслан башын бер калкытты баздан, бер чумды: авыл... юк. Юк иде авыл, тирә-юньдә бүрәнә, такта, калай өемнәре генә иде. Төбе-тамыры белән йолкынган агач-куаклар бәгырьне чәнечте, күзләр яшьләнде, ир бугазына төелгән төерне йота алмыйча торды. Аңа еларга ярамый. Еларга да ярамый, хәл бетеп аварга да ярамый: алда эш күп булачак, бүген исән-имин ир-заты кулы кабарганчы кабер генә казыячак иде...

Берәм-берәм кешеләр күренде. Елау-сыкрау авазы хәрабәләр өстенә таралды.

— Күршеләреңне барла, — дип кычкыра-кычкыра, Арыслан абына-сөртенә урамсыз авыл буйлап атлады. — Ишетәсеңме, халык? Күршеләреңне барла!

Кинәт, күк-җирне сискәндереп, бер хатын акырды. Аның тавышы җансыз авылны урталай телде.

— Ак торна каргышы бу-у-у!!!

Ир артына борылды. Иң зур такта-агач өеменә менеп баскан да талпына-кагына Сәрия акыра иде. Кызның чәче-башы тузган, күлмәге кадакка эләгеп ертылган, күзендә шашкын халәт. Арыслан йөгереп килеп аны аска тартып төшерде.

— Сара кайда?! Сиңа әйтәләр, Сара кайда?!

— Китте... Син дә кит. Торна каны бу авылда. Кит, кач!

— Кая китте?!

Сәрия аны ишетмәде. Тиле сыман һаман бер сүзләрне кабатлады:

— Торна рәнҗеше, торна каргышы... Әй, кешеләр! Әй, кансызлар! Әй-й-й!

Әй-й-й...

*Карасу авылы*
*Август, 1995*

## Тамга

### 1

Аның мондый коточкыч хәлне күргәне юк иде. Хәер, кырык яшенә кадәр башыннан ниләр генә кичермәде, ләкин бу — шуларның берсе белән дә чагыштырырлык түгел, бу — акыл һич кенә дә кабул итәргә теләмәгән кыргыйлык иде.

Ир, чүмәшеп, кулын көрткә батырды. Кайнар дулкын күкрәк читлегенә бәрелеп вата-җимерә иде: учына йомарлаган кар белән битен ышкыды. Мөгаен, күзләре ялгышадыр. Ничә төн рәттән йокламагач, арылды. Әгәр Озын толым терелмәсә, дөньяның кызыгы бетәчәк. Әле бит Нурихан, гәрчә өмете шырпы очы кадәр кечерәйсә дә, шуңа таянып яши иде. Ир-атны көчле зат диләр. Рух көче сүнсә, беләктәге көч нәрсә соң ул! Шәрифәгә бүре ташланган икән, монда бары тик Нурихан гына гаепле. Дөрес, авылда

«син» дип бармак белән төртмиләр, ә ир тоя-сизә: хатын нәкъ менә аңа рәнҗи. Сүзсез генә, эчтән генә рәнҗи... Ярасы ниндидер тагы. Ерткыч тырнагы муенын ярып төшергән, ди. «Хәлең ничек, җаным?» дип, чәнти бармагының очына гына кагыласы иде дә... Кизү табиб Нуриханны хастаханә ишеге төбеннән үк кире борды шул. Ирнең юнмаган тупас агач теле харап итте.

— Син авыруга кем тиеш, агай-эне? — диде табиб. — Иреме, энесеме, җизнәсеме?

— Анда синең ни эшең бар? — диде Нурихан. — Мин просто кеше.

Ак халат аның дорфа сөйләшүен өнәмәде:

— Ишекне урам яктан яп, — диде.

Авылдашы, дисә, бәлки, табиб йомшарыр иде, ә ул кирелеген җиңә алмады.

— Кертмисең инде алайса, фәрештә туган. Ичмасам, әйт: тереләме, үләме?

— Анысы Ходай ихтыярында, — диде ак халат.

Шуннан соң ир, кар димәде, буран димәде, көн саен җиде чакрымдагы хастаханә юлын таптады. Әмма теге табиб аны барыбер эчкә уздырмады.

— Авыру әлегә аңсыз, без аны күзәтәбез, син, агай-эне, тавышланма, яме, — диде.

Инде хәзер хәлләнә башлаган Шәрифә үзе Нурихannan кача кебек. Югыйсә, җаныннан җиде кыл өзеп, ярасын бәйләргә дә әзер ул. Бәйләр иде, әйе. Озын толымны бер тапкыр үлемнән коткарган иде бит. Бакча башында учлап-учлап тилебәрән үләне орлыгы ашаган Шәрифә. Башта үз-үзен белештермичә шарык-шорык көлгән, аннары авызыннан ап-ак күбек кайнап чыккан, күзләре дә аларган һәм кыз... үлгән. Монысы хак, Нурихан аны кулына күтәргәндә, Шәрифә суламый иде инде...

...Ир, каткан аяк буыннары язылсын дип, ызба нигезенә сөялеп утырды. Хәзер күкрәкне кайнар дулкын бәреп кыйнамый, киресенчә, салкын үтеп калтырата. Хәтта йөзен ышкыганда изүенә аккан кар суы да, сөңге-бозга әйләнеп, йөрәкне чәнчә сыман. Гайбәткә ышанып, төнката чит хатынның тәрәзә төбен сагала менә. Имеш, чирләшкә бала Нуриханнан, ди. Мәрхүм әтисе — аучы Миннехан — исән чагында моны ишетсә, йөрәге ярылыр иде. Алар нәселендә төчкергән ир-ат та булмады. Имән орлыгыннан имән генә ярала... Ә монда чирләшкә бала! Ниһаять, колакка гел-гел суктырган гайбәттән туеп, бүген ул Сафриналәргә килде. Аумакай хатынның телен кыскартырга кирәк. Түзде, озак түзде ир, ә «синеке» дигән үртәү тынарга уйламый. Хәзер Шәрифәгә таба ике адым атлаганда, хәзер бәхет капкасы ачылам дигән мизгелдә, җил тараткан артык сүз пычаксыз суячак бит. Нуриханның «минеке түгел» дип расларлык бер катгый дәлиле бар барын. Шуңа күрә ул, ишекне тибеп кенә кереп, малайның колак артын тикшермәкче булды, ә өйгә якынлашканда, нәзек тавыш белән улаган эт тавышы ишетеп, уклау йоткандай, баскычта катып калды. Керфеген дә селкетмичә тыңлады ир. Авыл күк гөмбәзен чуарлаган йолдызларга төренеп йоклый, тирә-якта тынлык. Бу зәмһәрир суыкта кемнең эте урамда болгана икән? Соңгы вакытта алар да адәм акылына иреште: Наратлыкны бүреләр камаса, койрык кысып, ояларына шылалар. Һәр җан иясенең яшисе килә. Яшәүдән битәр — нәсел саклыйсы...

Улау кыйшайган тәбәнәк ызбаның бүрәнә ярыгыннан сузылып чыга кебек тоелды. Нурихан, баскычтан төшеп, ватык пыяласы камыр белән сыланган сыңар тәрәзәдән өй эченә карады. Чебен пычратудан каралган лампочка, түшәм тәбәнәк булгач, идәнне генә яктырта, ә анда... анда дүрт аякланган ыштансыз малай эт имә, ә тегесе кымшанмый да, шулай тиеш дигән төсле, күзләрен йомып ята бирә иде. Екты да салды Нуриханны бу тамаша! Инде яңадан аякланып тәрәзәгә багарга шүрләтә иде. Ир башы белән җебеп тора менә. Черки белән сугышырга өркегән аюны хәтерләтә ул. Җебеми дә бугай. Күзләре саташып тагын әллә ниләр күрер төсле. Эчә-эчә мие сыекланган сәрхушләр генә җен-пәри дип шашынмый, аек кешеләр дә тилерә икән. Шәрифә аны тәмам акылдан яздырган, ахрысы. Ызба нигезеннән билгә салкын үрмәли иде, ул калкынып торып басты. Гайбәт куып, юкны бушка аударып йөргән ирне каеш чыбыркы белән суктырсаң да таман гына иде. Наратлыкта хатын-кыз итәгеннән тәгәрәгән һәр баланы Нуриханга сылтасаң, Солтанбәк нәселе күптән авыл урамнарын чыр-чу белән күмәр иде. Ә алар күмалмады шул. Аларның соңгы бөртеге дә иске чиләк кебек төпсез иде...

Нурихан борылган уңайга янә тәрәзәгә күз ташлады. Ике мәртәбә саташмыйлар. Җен-пәри дә бер үк күренешне ике тапкыр кабатламый. Эт чын бар, ыштансыз малай чын бар, һәм боларны чагылдырган рәхимсез тормыш та чын иде. Ул, ярсуын йодрыгына кушып, бөтен көче белән этәргә җыенган өйалды ишеге «өф» дип өргән сулыштан да ачылып китте. Караңгы иде, алай да ызба ишеген капшанып бик тиз тапты. Аягына уралган кышкы төнге суыкны ияртеп бусагадан үткәндә, «Нишлисең, ахмак?!» дигән уй миен бораулап алды. Нишлисең, ахмак?! Җилбәзәк Сафрина сиңа уйнаштан туган баласын аткарырга җыена, ә син күрәләтә аның хәйлә кармагына кабасың. Дөрес, өч ел элек бер төн Сафрина белән кундыгыз. Озын толым читкә тибәргәч, аңа ачу итеп эшләдең бу гөнаһны. Ул көнләшер дә кочагыңа атылыр дип өметләнгән идең. Тик бәгъзеләр көнләшмәде, сине, аяк астында аунаган кирәксез әйбер кебек, тагын да ераккарак күчереп кенә куйды...

Ни гаҗәп, ят кешегә эт өрмәде, киресенчә, юаш холыклы хайван икәнлеген белгерткәндәй, яшьле күзләрен Нуриханга төбәде. Ә ыштансыз малай, авызында ниндидер авазлар әвәләп, эткә елышты. Ир карашы белән өй эчен айкады. Агач караватта, сәләмәләргә төренеп, хуҗабикә йоклый иде. Ул, күрәсең, хәмер парында мәлҗерәгән һәм ишек шыгырдавын да, аяк тавышларын да ишетер дәрәҗәдән узган

иде. Авылның бәгыренә чәнечкән шайтан таягы! Нәсел-нәсәп тамыры безнең туфрактан яралса, бабаларының кабере белән оялтыр идең, «бу бит килмешәк» дип, карт-коры тиргәгәндә, Сафринә кызармый иде. «Аның каравы мин иң асыл ирегезне сайлап, үзем тамыр җәям», — дип шаркылдаган хатын әнә җәйгән. Өйдә генә биклəп асралган чирләшкә малай, йә, кемнеке, кайсы асыл ирнеке?! Солтанбәкләрнең ир-угланнары буыннан буынга Ходай тарафыннан сәер тамга белән тамгаланган: һәрберсенең колак яфрагы артында миң үскән. Хәзер аңа юри генә кыргый малайны да тикшерергә кирәк иде. Ул, иелеп, әкрен генә ыштансызны җилкә чокырыннан кытыклады.

— Әй, җегет, качма син, качма. Мин Нурихан исемле абыең. Яле, күрешергә кулыңны суз!

Малай, кырмавык сыман, йонлач дустына ябышты. Тавышка әнисе уянса уяныр дип, ир баланы, биленнән эләктереп, эт корсагыннан куптарды һәм, үзенә каратып, тезләренә утыртты.

— Бәс, син бөтенләй бозлангансың бит, җегет. Ызбагыз ягылмаганмыни? Туңып үләсең бит. — Нурихан, иягеннән тотып, малайның башын күтәрде. — Ни атлы син? Авызыңа су каптың мәллә?

Бала дәшмәде. Төн карасына манчылган күзләрдә поскан курку бәләкәчне тәмам кыршаулаган, ул ни кычкырмый, ни ычкынырга маташып чәбәләнми, җансыз сын төсле селкенмичә генә утыра иде.

— Сиңа ничә яшь, җегет? Икеме, өчме?

Нурихан өч ел элек авылга кайтып төпләнгән иде. Кхым, димәк, икеләр тирәсе... Нәрсә ди ахмак балык?! Нәрсә саный ул?! Малай кисәге аныкы түгел! Йөз белән чуалган Сафринә ничек аңа шушы имгәкне төртә әле?!

Ир, куырылган баланы кая куярга да белмичә аптырап, тезен тезгә бәргәләде. Юаш эт тә аралыкка үрмәләгән иде.

— Исемеңне тәки әйтмәдең син, җегет. Сиңа Мирзабәк дип кушканнар, имеш. Безнең җиденче буын бабай да Мирзабәк, җегет. Фәсыйлә карчык коткысына бирелгән Кәрим мулла эше бу. Аларның безнекеләрне кузгатырга хакы юк иде. Солтанбәк морзадан килгән борынгы нәсел без, җегет. Әйдә, әниең янында җылыдыр, чум юрган эченә, җегет.

Нурихан, малайны култык астыннан гына тотып, караватка күчермәкче иде, озынаеп баланың күзенә төшә башлаган чәч учмасы тун сәдәбенә чорналды. Таягы белән дөнья күпме генә дөмбәсләсә дә, күңелдә кызгану хисе корымаган иде, ир, авырттырмас өчен үксезне йомшак кына күкрәгенә кысып, чәч бөртекләрен ычкындырды һәм, кулы ялгыш аның нәни колак яфракчыгына тиеп, бу нарасыйда тикшерергә лаек бик мөһим әйбер барлыгын искә төшерде. «Малай минеке түгел», — дип, эче-тышы белән бергә ярсыганга күрә ул аны онытып та җибәргән иде. Баланың чәбәләнгән чәчләрен араласа... Миңтамга!

Ирнең дык-дык бәргән каты йөрәк тибешеннән малай да сискәнде. Әмма куркудан күз алмасы никадәр генә зурайса да, ят абый кулыннан ычкынырга маташмады. Киресенчә, нәни куллары белән чытырдап тун якасына ябышты. Баланың эт исе сеңгән шакшы күлмәгеннән аңкыган ис борынны әчеттерә иде. «Нәсел тамгасы! — диде ир, шаккатып. — Билләһи, безнең тамга-билге! Бала минеке, алайса! Минеке!»

Үзенең кан атасы икәнен сабый да сизәдер, әнә бит һаман аңа сыена.

Нурихан, калтырап-дерелдәп, нүештәге караватка акырды:

— Тор! Мин сине үтерәм, сасы көзән! Син безнең нәселне хурладың! Син минем малайны эт имчәге ялатып үстергәнсең! Тор, диләр!

Сафринә кымшанмады да. Ир, баланы күтәргән килеш, сәрхушкә ташланды.

— Уян, мәгънәсез!

Сәләмәләрне бутап-бутап ыргытса да, хатын табылмады. Биләмче Сафринә өйдә юк иде. Бу хәлгә тагын бер гарьләнде Нурихан. Малай ягылмаган ызбада төнлә дә ялгыз гына кунган икән! Кайнарланган ир мич кашагасында шырпы тартмасы күрде. Бу өйгә ут төртергә кирәк! Авыл изрәп-таралып йоклаганда, күкләрне колачлап янсын! Хәер, йокламасалар да, кем сүндерер икән: җыенысы таяклы карткоры, тәрәзәдән генә зиратка озаясы көннәрен көтәләр. Ут үрләтергә дә малай белән Наратлыктан җәһәннәм читенә таярга! Әле соң түгел, әле Мирзабәккә ике генә яшь. Яланкул бүре аулаган Солтанбәк ирләрен эт дәрәҗәсенә төшерергә бердүнең дә хакы юк! Нурихан югалса, халык үлеп сөенәчәк, чөнки аларны элек-электән өнәмәделәр. Мескеннәр горурларны күралмый шул.

Ул аралыкта бөгәрләнгән юаш этне итек очы белән кадый-төртә урамга куды.

— Пшал, хайван. Син гаепсез, мәхлук.

Ләкин сәләмәләргә шырпы сызып ташларга җыенган кулын акыл туктатып өлгерде: «Китәм, дисең... Ә Шәрифә кемнәргә кала?» Кич ятса, иртән торса гелән-гелән күз алдында бөтерелгән Озын толым, чынлап та, кемгә калыр? Нуриханга тагылып олы юлга кадәр дә бармаячак ул киребеткән. Ике елда ике кәлимә җылы сүз әйтмәгәнне, сиңа иярер ди, көт! Юк, Нуриханга Шәрифәдән аерылу үлемгә тиң. Дөрес, хатын, турларыннан Нурихан узганда, шытырдатып капкасын бикли. Ерак тота ул аны, бик ерак тота! Ләкин рәхәт: бер авыл һавасын сулыйлар, бер сандугач сайравын ишетәләр. Яңгыр да, икесенең тәрәзәсенә шакып, бер үк көнне, бер үк төрле ява. Буран да икесенең капка төбенә бер үк карны өя...

— Әйдә, улым, үзебезгә кайтабыз, — диде Нурихан, тун сәдәпләрен чишеп. — Кил миңа.

Җан тартмаса, кан тарта икән, ыштансыз малай ык та итмәде, тун эченә чумды. Авыл күзсез-колаксыз, Сафринәнең ян күршесе Фәсыйлә карчык та бүген йокы симертә, уты сүнеп, тәбәнәк өе караңгылыкка баткан иде, үз гомерендә беренче мәртәбә бала кочаклаган ир, тар сукмакны киң итеп, иркенләп-җәелеп атлады. Идәндә шуышып арт чүмече бозланган бала тиз җылынды, хәзер бу җылы, рәхәт булып, янган йөрәкне дәвалый иде.

Солтанбәкләр нәселе егылып бала яратты... Комсыз ярату белән яратты. Әүвәлге никахтагы хатыны өч кенә бөртек белән чикләнгәч, бабасы икенчегә, аннары өченчегә, дүртенчегә өйләнә. Яраткан нәрсәне Ходай әз-әзләп кенә тамыза икән: ул бичәләрдән туган балалар берәм-берәм кызамык чиреннән тәгәри...

— Җәйләр җиткәч, без синең белән урманнар айкарбыз, улым. Мин сине поши малайлары белән таныштырырмын, улым. Ачуланма, улым, әллә кайчан сине үземә тәрбияләргә иде дә... Ышанмадым мин ул лыгырдыкка. Анаң — мир хатыны. Бетте ул бүгеннән синең өчен, улым. Синең анаң Шәрифә булырга тиеш иде. Үскәч аң бул, улым. Яраткан кешеңә үчләшеп, бүтәннәр белән бәйләнмә. Үрмәкүч акылы кирәк без ир-атларга. Ул әнә, дошманына пәрәвез корса да, үз капкынына үзе эләкми. Кыз-хатын хәйләкәр үрмәкүч сыңары, валлаһи. Безне әсир итә, ә үзе иректә йөри.

Нурихан кар ерып урамнан атлаганда шулай сөйләнде. Менә ул шып туктап калды. Тагын кемдер аның белән төн бүлешә иде. Бүре! Артына борылмады ир, борын канатларын киереп, салкын һава сулады. Юк, бүрегә охшамаган. Эт исе килә. Баягы йонлач эт исе. Нурихан уң аягы белән җиргә типте:

— Пшал, аңгыра!

Әмма эт аңгыра түгел, ул адәмнән дә акыллырак иде. Хайван баланы кая алып барганнарын белергә тели. Аның моңа тулы хакы бар! Ул әни вазифасын үтәгән, ул аны ачлыктан һәм суыктан саклаган.

Төптәнрәк уйласаң, тәннәр чемерди, Солтанбәкләр оныгын эт имезеп үлемнән йолган.

— Рәхмәт, хайван, — диде ир, йомшарып. — Син бел дә, мин бел бу гыйбрәтне, яме? Ярый син телсез әле. Бар, кайт инде. Урманнан бүреләр чыкмагае. Кечкенә Мирзабәк өчен борчылма, ул — минем улым. Солтанбәкләр үз баласыннан ваз кичми.

Тун эчендә йоклаган малай өйгә керү белән уянды. Аны караватка илтеп салгач, чишенеп тә тормыйча, тәрәзә пәрдәләрен тартты хуҗа.

— Вәйт, улым, син үз өеңдә. Бу — Солтанбәкләр нәселе нигезе. Җиде буын бабаңнар, ызбасын ипли-сипли, шушында гомер чиккән.

Бала, нәни йодрыгы белән күзләрен уа-уа, шыңшып елап җибәрде. Нурихан, аны куәтләп:

— Җыла, улым, җыла! — диде. — Ызба бүрәнәләренең яшь бала җылаганын ишетмәгәненә бишбылтыр! Әйдә, диварларны селкет, улым! Яле, улым!

Ул малайны көчле кулларына күтәреп түшәмгә чөйде. Шыр сөяк, күбәләк төсле югарыда пырхылдап, кире учына төшкән мәлдә өйдә кояш балкый иде. Бала нуры, бала яктысы! Комсызланып бала сөйгән Солтанбәк нәселенең чылбыры Нуриханда өзелми, дәвам итә!

Малай елаудан туктады һәм, иренен очлайтып, эт сыман уларга керешде.

— Әһә, тамагың ач. — Ир, мич авызындагы чүлмәктән тары өйрәсе салып, Мирзабәкнең алдына куйды. — Мә, улым, аша. Суынмаган. Кашыкны тәти кулыңа тот. Хәзер ипи кисәбез. Җегет кеше умыртып ашый, җир җимертеп эшли, улым.

Бала кашыкны, артык әйбергә санап, идәнгә атып бәрде дә йөзе белән савытка тыгылды. Ул лач та лоч теле белән шулпа ялый иде. Күкрәгенә терәгән ипиен кисмичә, шаккатып малайның кыланышын күзәтте ир. Ай-һай, монда хәлләр хәтәр икән. Бөкрене турайтканда шактый чиләнерсең, ахры, Нурихан. Кыргыйланган малай бик озакка кул-аягыңны бәйләр, мөгаен. Ә бакча? Быел язгы айларда корыган йөз төп алмагачка алмашка яңа үсентеләр утыртырга хыялланган идең син.

— Җә, уңган җегет, тукландыңмы? Безнең яккан мунча да бар бит. Эссесе сүрелсә дә, суы кайнардыр әле. Без кайбер эшләрне, кеше күзенә чалынмыйча, төнлә кайнаштырыйк, — диде Нурихан, иң беренче чиратта Фәсыйлә кортканы уйлап. Һәр сүзне энәгә җеп итеп саплаган карчык истә-тында юк чакта гына капка дөбердәтә иде.

Үзен әвеш-тәвеш китергән дәү абыйдан ятсынмады малай, юрганга күндәм генә сузылып ятты, аяк-кулларын турайтып, төрергә дә рөхсәт бирде. Нуриханның гына ташып аккан аталык хисе ярларына кайтып саега башлаган кебек иде. Бу бәләкәчнең мәшәкате, ай-һай, болытларга ашкан тау хәтле икән лә. Әнкәсе итәгенә юеш борынын сөртеп йөрер яшьтә генә бит әле ул. Хатын-кыз ярдәменнән башка моны ничек карап бетермәк кирәк! Әзрәк ялгышты шикелле Нурихан...

Ләкин ләүкәдә малайның ат ялына әйләнгән чәчен кыркыганда тагын колак очындагы таныш миңгә кагылгач, тоныкланган-саеккан хисләр яңадан ярыннан ташыды. Җанның һәр почмагын шатлык-сөенеч биләде. Моннан соң зар да юк, уфтану-үкенү дә юк. Ул Солтанбәк нәселе кыйпылчыгын һич авырсынмыйча үстерергә тиеш иде. Нурихан: «Хатын белән килешмәдек», — дип, балаларын ташлаган ирләрне беркайчан да акламый иде. Атага әманәт — бала, балага әманәт — ата, бу хакыйкать борын заманнардан ук ташка чокылган иде.

— Бак, улым, нинди чибәр халык без, ә! — дип тел шартлатты әти кеше. — Яле, йә, мунчаланы сабынлап, аркаларыңны юыйк. Шапшакның өч табигый күлмәге бар, ди, синдә алар ничәү икән? Туганнан бирле тәнең пакьләнмәгән, ахры, синең, улым.

Бер савыт өйрә чөмергән малай болай да авырайган иде, мунча да өстәлгәч, тәмам изрәде бугай, коендырганда ул яртылаш йоклый иде инде. Кайтарып, үзе белән янәшә түшәккә салгач, битләре алсуланган балага сокланып һәм горурланып карап торды Нурихан. «Читен дип... башта читен булыр, әлбәттә. Авыл ни сөйләр тагы. Ил авызына иләк капламассың: телләре кычыта икән — сөйләсеннәр. Шәрифә нәрсә дияр менә. Һәй, Шәрифә, имеш! Әйтерсең моңарчы ике пар күгәрчендәй уртак ояда парлашып яшәделәр. Озын толым, Нуриханны күрмәс өчен, ак көннәрне кара төнгә алмаштырыр иде. Барыбер Шәрифә ни дияр икән? Тыштан битараф кыланса да, эче ут янар, бәлки? Ир бит аны алдады, алдады! Сафринә белән гыйшык уйнамадым, дип, ант сулары эчкән Нурихан көннәрдән бер көнне балалы этигә әйләнсен инде, йә! Күктән иңгән малайны кемнеке дип әйтергә соң хәзер?!

Нуриханның йомшак мендәре ташка әверелде, уйдан кабарган баш чүмече чатнап-чатнап сызлый иде. Шәрифәсез яшәү яшәүмени ул... Ярата аны ир. Хатын бәгыренә кырык усал шырпы кадаса да, ярасыннан арынырга теләмичә ярата. Һәр күзәнәгенә нәфрәт тулган Шәрифә дә ирне ярата. Тик әлеге нәфрәтен генә җиңә алмый. Аның шунысы куркыныч икән: бер үк вакытта яратасың да, бер үк вакытта нәфрәттән дә газапланасың. Кодрәтеннән килсә, Шәрифә Солтанбәк оныгын Каф тауларына олактырыр иде. Нурихан кан дошманыннан да артыграк иде бугай. Югыйсә алар бер-берсенә насыйп яр иде. Кем аяк чалды да, кем, йөрәкләрне елатып, ике якка аерды соң? Кемгә йодрык янарга тиеш Нурихан? Урмандагы капкынгамы? Азгын Сафринә белән «кавышкан» хәерсез төнгәме?

Ир бармакларын чәченә батырды. Сызлый баш, сызлый! Әллә үзе, бары тик үзе генә гаепле микән? Адәм баласы, гадәттә, хаталарның җеп очын бүтәннәрдән эзли. Йөз кешегә йөз гаепләү ярлыгы тага да, фәрештә сыйфатлары белән бизәп, үзен сөттән ак, судан пакь ясый. Моңарчы Нурихан да кешедән күрде. Түгәрәк бәхетенең кырыен кемдер кимереп алган төсле иде. Кем? Менә син шуңа җавап тап хәзер!

Ир, малайның юрганын рәтләп, утны сүндереп килде. Пәрдәләрне кырыйга шудырды. Салкын йолдыз нурында җемелдәгән кар яктысы диварларга буй-буй ак эз сызды. Сәер, бу төн тыныч уза. Кичә генә авылга көтүе белән бүре төшкән иде. Эт җенесе оясында гына ырылдады. Тирәүле капкалар, тишектошыгы чүпрәк белән томаланган сәләмә абзар-куралар ерткыч өчен киртә түгел. Егерме хуҗалыкка калган Наратлыкта мал-туарның исеме дә онытылган, карт-коры кәҗә дә асрамый. Ә бүре азык сорый. Аларны бу якларга тамак нужасы куып китерде. Көнбатышта урманнар тунала, биләмәләр кечерәя, элеккеге урыс авылларының нигезендә җил уйный. Ачлыкка киселгән бүре нишләсен, кешеләргә ташлана. Үткәннәр яңадан кабатлана, ахрысы. Чү, бүреләр өлеше генә кабатлана. Чөнки аучы Миннеханны каберennән кузгатып терелтерлек кодрәт иясе җирдә юк. Иртә күзен йомды ата. Аның гомерен рәнҗеш кыскартты микәнни? Яшь чагында «рәнҗү» дигән сүздән, «әбиләр әкияте» дип, Нурихан кычкырып көлә иде. Яшьлектә бөтен нәрсәне дә көлкегә борасың шул. Бүген исә икенче төрле уйландыра. Бер канаты белән Нуриханга да орынды бит ул рәнҗү! Тикмәгә генә чит җирләрдә каңгырамады ир, тикмәгә генә җылы кочаклардан мәхрүм булмады. Тик менә кем күбрәк Солтанбәкләр нәселен каргады икән? Тере килеш тиресе туналган бүреләрме? Әллә...

Нурихан колагын сагайтты. Кемдер шатыр-шотыр өйалды ишеген тырный иде. Исереп кайткан Сафринә, өендә баласын күрмәгәч, монда чапты микән? Бу сиңа бүре генә түгел, атам да котылам димә. «Малайны урлады», — дип, бөтен авылны җыячак. Ә тавыш Нурихан өчен соңгы нокта: шул минутта ук ул Шәрифәне югалтачак. Йоклаган сабыйны кулына тоттырып җибәрергә мәллә? Аннан сыналган саклану чарасына күчәсең: «Бала минеке түгел».

Ир улының өстенә иелде. Мирзабәкнең бәрхет сулышы кытыршы яңакны иркәләде. Юк, малай аныкы! Сулышына хәтле якын хәтта!

«Буып үтерәм мин сине, хәшәрәт хатын, — диде ул, иңенә тунын ташлап. — Баланы имгәтүең генә җитмәгән, Нуриханның да тормышын чатнатасың».

Ул бар куәтенә тышкы ишекне эткән иде, эт чинап карга тәгәрәде.

— Фу, хайван, син икән, — диде Нурихан. — Ни пычагыма ишектә тырнагыңны үткенлисең, ә? Мирзабәк минеке, бар, өеңә элдер!

Эт түше белән аңа табан шуышты да өч тапкыр ләң-ләң өрде.

— Әһә, аңладым, хайван. — Хуҗа урман буенда селкенгән кара тапларны шәйләп өлгергән иде инде. — Бу юлысы болар санаусыз. Син миннән ярдәм сорыйсыңмы? Көчле дисеңме Нуриханны? Җүләр мылтык шартлатыр анысы. Тик миңа атарга ярамый, туган. Җә, курыксаң, өйалдына кереп ят. Безнең йортка борын тыкмый алар. Солтанбәк нәселе белән бәрелешсәң, эш харап икәнен чамалыйлар. Бүре хәтере буыннан буынга күчә.

Нурихан ишек ачылмасын өчен келәсен шудырды. Дөньяның пеләш маңгаена төкереп, җылы өйдә малай йоклый. Иртәгәсе хәлләр турында уйламаска тырышып, ир дә баш төртте. Ә мендәр һаман таш, уйлар һаман бәйләнчек иде.

## 2

...1970 елда дүрт яктан да урман белән уратылган Наратлыкка бүре ияләште. Авыл тыкрык саен туктап ял итәрлек дәрәҗәдә әкәмәт зур иде. Халыкны урман туендырды. Күрше базарларда кемнәр чиләк-чиләк гөлҗимеш, балан, шомырт, җиләк, капчык-капчык чикләвек сата — Наратлык хатыннары. Капка төбе саен кемдә сап-сары сатлык бура — Наратлык ирләрендә. Иң оста үләнчеләр кайда — тагын Наратлыкта. Шушы гөрләп барган тормышны каяндыр пәйда булган явыз бүре өере пыран-заран китерде. Башта күмәк хуҗалыкның мең баш сарыгын бугазлады алар. Ә беркөнне күзе-башы акайган көтүче Нуретдин авылга кайтып егылды. Аны коедан тарткан салкын су сибеп кенә айныттылар.

— Кырдылар, барысын да кырдылар! Сыңар сыер да калмады. Мин нишләтим, чыбыркы атмый бит, җәмәгать! — дип үкерде ул.

Наратлыкта йорт саен өчәр баш сыер иде. Халык зар елады. Ирләр, балта-сәнәк белән коралланып, өч көн урманны тарады. Әмма бүре өере җир йоткандай юкка чыккан иде.

Ул көннәрдә аучы Миннехан туктаусыз тәмәке төтәтте. Аның мылтыгы ничә ел келәттә тузан йотып, тутыгып ята иде. Борын тишегеннән бөркелгән әче төтен аучының йөзенә сара, гүя Миннехан үзе дә утсыз-ялкынсыз гына пыскып яна иде. Атаның авылдагы мәхшәргә пошынмавы ундүрт яшьлек үсмергә һич кенә дә аңлашылмый иде. Җиңсә, Миннехан аучы гына ерткычларны җиңәчәк, чөнки ул гына бүре аулауның хикмәтләрен белә, аннан күрмәк Нурихан да ау серләренә төшенеп килә иде. Бүре оясына тыгылып, йомры йомгакларны капчыкка тутыру нинди кызык шөгыль иде! Ә ана бүрене ээзәрлекли-эзәрлекли көн-төн чапкач, бичараның тәмам йончып авуы, һәм этисенең аны яланкул тотуы малайның әле дә күз алдыннан китми.

— Әти, кешеләр бүреләрне тапмый икән. Тегеләр искәртмәстән һөҗүм итә дә урман авызында ук эри икән, — диде үсмер төтенләгән атасына.

— Һе, бүре хәйләкәр зат, улым.

— Син аларны качырмас идең, иеме, әти?

— Мин бүредән хәйләкәррәк бит, улым.

— Алайса, ник юл күрсәтмисең, әти? Абзыйларга булышсаң, рәхмәт яудырырлар иде.

— Хәтерлисеңме, шул абзыйларың өченче ел атаңны бүредән дә яман өзгәләде. Урман каравылчысы Билалетдин җыенда: «Миннеханны авылдан куарга кирәк», — дигән фәрман укыды. Без, имеш, нәселебез белән кан койдык, без — җәллад, Наратлыкта, имеш, безгә урын юк! Ник берсе шунда мине якласын! Кууын кумадылар, вәләкин өч ел капкабызга кеше орынмады, бездән йөз чөерделәр. Моңа күңел бә-әк әрни, улым. Юкса бүрегә ирек бирергә ярамый, ул чүп үләне төсле әрсез, ара-тирә йолкымасаң, урман-кырларны баса. «Син бүреләрнең тамырын корытасың», — диде Билалетдин. Корытмыйм, иту, бүресез урман — көлмәксез катын ул. Әрсез тамырның көчен какшатам мин. Әле дә ерткычларның өер башын гына чүпләдем. Башсыз өер авыл ягына карап иснәнми дә, улым.

— Әти, урманда бөрлегән кызарган, ди. Кыз-кыркын барырга шүрли. Бүре мыжлаган, диләр.

— Быел Наратлык хатыннары базарда күкрәк киереп саталмый икән, — диде төтенләгән ата.

— Әти! Эләктер инде шул өер башын! Кызлар... кызлар сиңа әйтергә кушты, әти! — дип өзгәләнде үсмер.

«Кызлар», билгеле, күплек санда, бергә калдырсаң, ул Озын толым иде. Авылда иң җитез җиләкче Шәрифә иде бит. Дөрес, Озын толым Нуриханга зар түкми, коңгырт күзеннән нур сирпеп, елмаеп кына карап ала. Икәү төнге күктән йолдыз санаганда да, урманчы кызы сызлануларын яшерә. Кем-кем, ә Шәрифә урмансыз кибә-сула. Кырыс Билалетдин абзый кызын нигәдер үзе белән йөртми. Аның күрше авылда сөяркәсе бар, имеш. Ярты гомере аның йортында уза, имеш.

Җиләк-бөрлегәннән тыш Шәрифә дару үләннәре белән мавыга, кыш-яз тирә-яклардан, сырхавына дәва эзләп, кыз янына авырулар агыла, Билалетдиннарның капка төбеннән үк бөтнек, мәтрүшкә, юкә чәчәге исе аңкып тора иде. Шәрифәгә урмансыз яшәү, ә үсмер егеткә аның керфек каккан саен моң түгелгән сагышлы күзләрен күрү авыр, бик авыр иде.

Ата тәмәке төпчеген кытыршы учына басып сүндерде.

— Бүре синең хәсрәт түгел, улым. Тамагың тук, өстең бөтен, кеше кайгысы кайгыртма.

— Әти, бир мылтыкны, мин үзем өерне туздырам, — диде Нурихан.

Аучы Миннехан, зәһәр карашы белән аны яндырып-көйдереп:

— Әтәчләнмә, малай! Син бүре хәйләсен үрәнмәдең әле! — диде.

— Соң... соң үзең бар әлсә. Рас мактаулы бүрече икән син, — дип чәпчеде үсмер.

— Ник мин үземне мыскыллаган халыкка хезмәт итим ди, малай актыгы! Җыенда бугаз ярдылар ничек, җә! Миннехан аталарын үтергәнмени!

— Син... син... әти, бүреләрнең тиресен туный идең.

— Һи, башсыз! — Миннехан черт итеп җиргә төкерде. — Башсыз малай. Акча бит ул. Сезнең тамакны туйдырырлык акча! Мин бит базарда җиләк сатарга катын-кыз түгел. Солтанбәк ирләре, алдырса, эредән алдыра, колагыңа киртлә моны, малай актыгы!

Ә бер кичне аучы озак-озак мылтыгын чистартты.

— Атмаса да көйле торсын, — диде.

Әмма ата исәптә-уйда иде. Бүреләр көннән-көн оятсызлана: авылдагы этләр сафы да сирәгәя. Шул төндә этисе өйдә йокламады. Нурихан печәнлекне тикшерде — ата анда да юк иде. Үсмер келәткә йөгерде — мылтык элгән зур кадак та буш иде... «Бүре эзләргә киткән», — диде Нурихан. Күзенә яшь тыгылды. Малай өер башлыгы белән көрәшергә әзер, атаның ым кагуын гына көтә иде. Алмады, алмады... Нурихан Озын толым каршында ике сүәм үсәчәк иде ләбаса! Батыр егетләрне кызлар «кит» дип кумый. Әнә Шәрифә, аны малайсытып, «аяк астында чуалма» итенә.

Нурихан, кая барып бәрелергә белмичә йөргәндә, ике кызның бакча буенда гәпләшеп утырганын абайлады. Берсе — Шәрифә, икенчесе сары чәчле Сафринә иде. Зимагур Шакирның сабый килеш карт әнкәсенә кайтарып ташлаган үги кызы ул. Озын толым бу шаркылдык белән ни-нәрсә турында сөйләшә икән? Моңарчы алар бер-берсен өнәмиләр иде бит.

Абзар читенә посып, үсмер «сердәшләр»не күзәтте. Чү, Шәрифә кинәт аркан ауды. Ә Сафринәсе, бот чабып көлә-көлә, аның авызына нидер тутыра. Җәядәге ук кебек бакча башына очты егет. Аны күргәч, сары чәч шыпан-шыпан артка чигенде.

— Ул үзе тилебәрән ашады, үзе! — дип чыркылдады кыз. — Мин өстәдем генә!

Җансыз гәүдәне күтәреп, Фәсыйләләргә чапты Нурихан. Табанын нәрсәдер кисте, нәрсәдер кадалды, ә ул чапты да чапты. Бәхетенә, кендек әбисе — имче Фәсыйлә өйдә иде.

— Яшәүдән бизгән мәллә Билалетдин кызы? — дип әрли-әрли, ул Шәрифәне караватка яткырды. — Син, җегетем, минем идәнемне кан белән таплама. Мә чүпрәк, аягыңны юып бәйлә.

Баскычка чүмәшеп аягын караса, Нуриханның күзе шакмакланды. Табанын зур гына пыяла кисәге ярып кергән иде. Аны тартып алгач, кан сиптерде. Егет, сыңар аякта гына сикергәләп, бәрәңге бакчасына чыкты да ярасына учлап-учлап туфрак сипте. «Туйга кадәр төзәлә», — диләр картлар. Шәрифә генә терелсен иде! Тилебәрән орлыгының агу икәнен үләнче кыз белмәде микәнни?!

Имче Фәсыйлә титаклый-титаклый ишегалдын әйләнгән Нуриханга тәрәзәдән башын тыгып боерды:

— Ата каз сымак чирәмемне таптама, өеңә тай! Билалетдин кызы үлми, монак күзен ачтырдым, — диде.

Егет яралы аягын сөйрәтеп кенә Сафринәләр турыннан узганда, биязәй хәтле авызын ерган чая кыз капкаларына сөялгән иде.

— Нәстә ыржаясың, маржа чәч! — диде Нурихан, җенләнеп.

— Теге имгәкне күмеп үк кайтышың мәллә, аксак карга? — дип телләште Сафринә.

Нурихан җирдән таш эзләде. Шаркылдыкның ерык авызын ямасаң, бәлки, бүтән сайрамас иде.

— Әй күтәрде дә чапты тегене! Ха-ха-ха.

Ачуы кабарган үсмер, йодрыгын төйнәп, Сафринәгә ыргылды. Кыз качмады, капкага ныграк терәлеп басты.

— Кил, кил, иркәм. — Аның күзеннән дәртле очкыннар чәчри иде. — Кил... Мин синнән ике яшькә олырак. Миңа быел уналты. Синең беләкләрең таза да, матур да, билемнән уратып кочаклачы, иркәм.

Нурихан бу тәкъдимнән югалып калды. Йодрыкка укмашкан бармаклар үзеннән-үзе язылды. Шәрифәнең күлмәк җиңенә кул тидерергә ярамаганда, күр, бу маржа чәч «кочакла» ди!

— Яле, иркәм, тотып кара, минем йомрыларым нинди зур, нинди тыгыз, — дип, күкрәген калкыткан кызны Нурихан җирәнеп этеп җибәрде:

— Фу, синнән сасы ис килә!

Сафринә үпкәләмәде, коймага эленгән идән чүпрәге белән култык астын сөртә-сөртә:

— Җитлекмәгән икән әле син, аучы малае, — диде. — Тәккә ымсындым сиңа. Ничава, соңрак яратышырбыз. Әбекәй туңкайса, ишекне бикләмәм.

Кызык, Сафринәнең чытлыкланып сөйләшүләре дә, килеш-килбәте дә күрше Орловка авылы марҗаларыныкына охшаган. Наратлык кызлары үзләре әдәпле, үзләре тыйнак. Егетләргә башлап сүз катарга да ояла алар.

Ләкин, үпкәләмәсә дә, чая кыз — кара елан — йөрәккә каты чакты:

— Син, аучы малае, салам сыйрак Шәрфә дип саргайма, җәме? Аның сине җене сөйми. Күтәреп чаптың чабуын, иркәм. Мин тилебәрән белән тыгындырдым аны, мин! Нурихан җүнсез аркасында үләсем килә, дигәч, үлсен, мәйтәм. Авыл урамнары сулышка иркенәер.

Нурихан аксый-туксый китеп барды.

Күңелсез хәбәр иде бу. Ни өчен Шәрифә аны күралмый икән? Ни өчен? Нишләгән ул кадәр Нурихан?

...Аучы Миннехан өч көннән әйләнеп кайтты. Киеме ертылган, куллары тырналып беткән иде.

— Кая, су бирегез! — диде ул, тамак төбен гырылдатып.

Изүенә агыза-агыза ярты тустаган су эчкәч, ата, канәгать елмаеп:

— Каптырдым, — диде. — Миннән калмады. Читәндә алар, улым, — диде.

Нурихан урамга атылды. Басу капкасы янында җыелган халык читәнгә атландырган ике симез бүрене тамаша кыла иде:

— Гайрәтле инде Миннехан!

— Ничек авылга кадәр өстерәгән боларны? Көч үзендә, ә!

— Ай-һай таза бүреләр!

— Катыннар, иртән урманга барабыз!

Шәрифә дә килгән иде. Ул, башын иеп егет яныннан үткәндә, «рәхмәт» дип пышылдады. Нәрсәгә «рәхмәт» ди Озын толым?! Юньсез Нурихан ниндидер билгесез сәбәпләр белән аны үлемгә этәргән ди бит! Үсмер андый ук җебегән түгел иде. Тыкрыкта Шәрифәне куып тотып, беләгеннән кысты:

— Ник тилебәрән орлыгы ашадың, Шәрифә?

— Апа, диген, мәнсез! Мин вчүтеки синнән ике яшькә зуррак, — диде кыз, кулын йолыккалап. — Җибәр, синең бармакларың тимер кебек каты.

— Минем өчен үлмәкче идеңмени, Шәрифә?

— Кем әйтә? Уф, менә хәзер мин егылып үләрмен бугай. Сафринә саескан очырдымы? Ул алдакчыга ышансаң, кәкре каенга терәтер. — Шәрифәнең аксыл йөзен тимгел-тимгел бизәкләр чуарлады. — Нәстә миңа бәбәгеңне тасрайттың?! Тилебәрәннең тәмен татыдым, вәйт шул! Кичке уенда: «Әйдә биибез», — дип эндәш кенә, үтерәм! Хуш, энекәш!

Озын толым, аккош муенын сузып, тыкрыктан «йөзеп» китте. Җенең сөймәү шушыдыр, мөгаен. Олы егетләр белән болай дорфа сөйләшми кызлар. Могҗиза иясе: «Яшеңне арттырыйммы?» — дисә, Нурихан бишкуллап ризалашыр иде. Югыйсә буй да озын, басудагы сирәк уҗым кебек мыек та төрткән...

Бәрәкәтле урманга юл әрчелгән иде, хатын-кызлар, кояш белән бергә уянып, табигать нигъмәтләренә ашыкты. Тиздән тирә-як базарларны Наратлык бичәләре яулаячак иде.

Миннехан аучы, урман тарафларына күз ташлап:

— Хуп, — диде. — Хуп.

Әтисенә рәнҗегән үсмер эченнән генә: «Әйе, сиңа хуп», — дип мыгырдады. Ауга ияртмәде кирәбеткән ата! Бүген авыл Нуриханны тетеп мактар, бүген Шәрифә аның белән биер өчен иң матур күлмәген кияр иде.

— Ат җик әле, улым, — диде Миннехан. — Алатыр почмагына дәү капкын беркеткән идем. Бүрегә дип. Кирәге дә чыкмады үзе. Аулагын аулак, ул тирәләрдә кеше-фәлән дә болганмас, шулай да барып алыйм. Саклanganны саклармын, дигән Ходай.

Үсмернең ике күзе ут янды.

— Аңа да бүре эләксә?!

Батырлык эшләргә беркайчан да соң түгел. Нурихан бүре тоткан, диячәкләр бит!

— Ерткыч көтүе белән чуаш урманнарына олакты, улым, — диде аучы, горурланып. — Билалетдин миңа теш кайрыйдыр. Ул бүкәнгә урман тапталмасын, агач туралмасын. Наратлык баяры!

Әтисе белән Билалетдин арасыннан йөгергән кара мәченең эзләре тирәнәя иде. Миннехан көндәшенең җыендагы галәмәтләрен мыек очына чорнаган, һаман шуны әрнеп-сызланып искә төшерә иде. Ә алга таба хәлләр тагын да катлауланды. Монысын инде берничек тә төзәтеп булмый, монысы дошманнарны маңгайга-маңгай чәкештерде. Капкын барыбер корбан сораган: Билалетдин аңа аягын кыстырган иде. Кирәк бит Алатыр почмагындагы чытырманлыкта буталып йөрергә!

— Арбага яткызып кайттым. Киреләнде, бүлнискә илттермәде, — диде әтисе. — Каны күп аккан. Их, корт чаккыры, кешесе туры килүен күр син!

Кешесе кеше түгел иде шул. Билалетдин кич белән хәл белергә кергән әтисен бусагасыннан да атлатмаган:

— Терелсәм, мин сине авылдан сөрәм, ерткычлар газраиле, — дигән.

Миннехан аучы, Наратлыктан куылудан битәр, бүре капкынына кеше эләгүенә борчыла һәм моны ачыктан-ачык сиздереп:

— Их, корт чаккыры, ничекләр ялгыштым соң! — дип, бармагы белән маңгаена чүки иде.

Ә Нурихан эчтән сызды: ул әнә Шәрифәне югалтты... Кыз күралмауның соңгы дәрәҗәсенә җитте бугай, кичке уеннан да бизде. Сафринә исә, форсаттан файдаланып, тилгән кебек егетне сагалый иде. Ул төнге урамның кайсыдыр тыкрыгыннан тып итеп каршыга чыга да калку күкрәген егеткә китереп тери:

— Кочакла инде, аучы малае! Тилмертмә инде...

Нурихан сүзсез генә Сафринәне юл кырыена бастыра да эре-эре адымнар белән караңгылык эченә томырыла. Ә артыннан барыбер үзәк өзгеч сүзләр куып җитә:

— Шәрфә сине яратмы-ый!

Энә күзе хәтле бәла, зурая-зурая, дөя хәтле хәсрәткә әверелә икән: Билалетдин чиреннән мантымыйча үлеп китте. Кабер казырга барган атаны ирләр зиратка кертмәде:

— Син Билалетдин белән гадел исәп-хисап ясамадың, хәрәмләштең! — диде мулла. Әйтерсең капкын ниндидер мәкер белән нәкъ менә урманчыга атап куелган иде.

Миннехан аучы акланмады, күрәген улына сузып:

— Абзаңнарга булыш, — диде.

Көнозын үсмернең колак төбендә мулланың кисәтүе яңгырады: «Гадел исәп-хисап ясамадың, хәрәмләштең!» Атаның урманчы белән сату-алуларда катнашканы да, уртак мал табып, үзара бүлешкәне дә юк иде.

— Әти, мулла бабай нәрсәгә төрттерде ул? — диде егет.

Миннехан черек утын яккан мич төсле төтенли иде, илтифатсыз гына:

— Яшьлектәге йөрәк эшенә эчләре поша, улым, — диде.

— Нинди «йөрәк эше», әти?

— Аптыратма, улым. Бу авылда яшәрлек рәт юк икән безгә.

— Мин Наратлыктан беркая да күченмим, әти.

— Сиңа кем күченәбез ди, малай актыгы! Зиратның ярты ягында Солтанбәк нәселе!

Карт-коры: «Билалетдин әҗәл таягын кайсыбызга ыргытты икән?» — дип кыбырсыды. Авылда бүген-иртәгә үлем көтеп, хәл эчендә ятучылар байтак иде, ә таяк... таяк шапылдамыйча гына Нуриханнар йортына төште. Баскан саен аяк астында җир калтыраткан сау-сәламәт ата, «йөрәк пешә» дип, өч көн ятакта аунады һәм бер сәер гадәте белән өнне алды. Төннәрен ул саташып бүре булып улый, бу улау җәйге авылның котын очыра иде.

Үләр алдыннан Миннехан улына дәште:

— Нурихан... Бүреләргә тимә... Ерткыч аулау миңа Ходайдан бирелгән җәза ие... Безнең нәсел каядыр каргалгандыр... Җүнле адәм кәсеп итеп таба малны... Наратлыкта яшәмә, еракка кит... Минем җәсәд зиратта Солтанбәкләрнең соңгысы булсын... Теге йөрәк эше дигәнем... Йөрәк эше... Улым, син Билалетдин кызын сүмә, син бит...

Миннехан аучының кинәт кенә сулышы киселде. Нәрсә әйтергә теләде ата? Алар безнең дошман, дидеме? Син кыздан яшьрәк, дидеме? Хикмәт яшьтә идемени? Ярату өчен дөньяда бернинди киртәләр юк. Атаның үлеме дә хисләрне сүндермәде. Ул кайгылы күз яшьләренә коенган мизгелләрдә дә Озын толым турында уйлады.

### 3

...Мирзабәк елмаеп уянды. Яхшы фал иде бу, яхшы фал. Димәк, йорт иясе нарасыйны ят итмәде. Бала үзе дә ата кулына бик тиз ияләшергә охшап тора. Җан тартмаса, кан тарта, ә монда тамгалы малайның җаны да җиңел генә нәсел җебенә ялганыр шикелле. Тик аның кайсы туфракта шытканын уйласаң гына укшыта башлый. Йөз белән чуалган хатынга ул якынаерга да тиеш түгел иде. Тагын бер тапкыр үкенечле ялгыш белән бәрелешмәс өчен нишләргә соң хәзер? Солтанбәк ирләренә генә хас кирелекне ничек сындырырга? «Малай минеке түгел!» дип инкяр иткән Нурихан, сүзен таптап, «юк, минеке икән» дисә, нинди фаҗига! Әһә, Солтанбәк оныгы очсыз хатыннар белән мәшгуль, диячәкләр. Яратмасалар да, әле Наратлыкта аның дәрәҗәсе югары иде. Ул гаярь аучы төпчеге ләса.

Ниһаять, Шәрифә... Гомер алмагачының бердәнбер һәм соңгы багалмасы... Үрелә, үрелә Нурихан, ә багалма иң биектә, менә өзәм, менә өзәм дигәндә генә, ботак, кулдан ычкынып, һавага атыла...

— Әйдә, улым, битеңне юабыз да ботка ашыйбыз, — диде әти кеше, малайны кочаклап. — Син яламасын өчен мин аны куе итеп пешердем.

Бала, иренен бөрештереп:

— Ау, ау, — диде.

— Өйдәш йонлачны сорыйсыңмы, улым? Ул бездә төн кунды. Аның үз дөньясы, синең үз дөньяң, улым. Ә, юк, савытка борын тыкма, төз утыр, туры утыр. Мә кашык. Сине адәми сыйфатларга күнектерәсе бар шул, кыргый. Җәле, ач авызыңны. Җә, чәйнә, улым. Вәт маладис! Сиңа кием бөтәйтәсе иде, улым. Әтисе күлмәгенә уранып үсми инде тәти егетләр. Бер-ике сәгать уйнасаң, күрше авыл кибетеннән сиңа ярардай күлмәк-ыштан җыеп кайта инде әтиең анысы. Хәзер уенчыклар кертәм.

«Уенчыклар» бер тартма ядрә иде. Нурихан бу байлыкны пәрәвез сарган тузанлы иске келәттән тапты. Утыз ел хуҗасыз картайган йортта энәгә дә кагылмаганнар, ни азгын малай-шалайны да аучы йорты кызыктырмаган иде.

— Олысы-кечесе сезнең йорттан шикләнде, олан, —диде Фәсыйлә карчык. Наратлыкта Нурихан белән ул гына ачылып сөйләшә иде. — Нигезегез җенле ие, олан. Төннәрен ялгыз бүре җылый ие анда.

— Сез, урман астында яшәп, акылдан язгансыз, — диде ир.

— Язырсың да, олан. Авылда адәм заты әзәя, зират зурайган саен зурая, — дип уфтанды кендек әбисе.

Малай, ни хикмәт, «уенчыклар»ны күргәч, сөенечле авазлар чыгарып бытылдарга кереште. Күр инде син! Нәни чагында Нурихан да ядрәләр белән уйнарга ярата иде.

— Син тимерләр белән юан, улым, — диде ир, киенә-киенә. — Бабаң боларның рәхәтен күрмәде. Әҗәл комачаулады, әҗәл...

...Нурихан кар күмгән юлдан атын атлатып кына барды. Сафриналәр турында бер карачкы чайкала иде, менә ул абына-сөртенә каршыга килде.

— Тр-р, малкаеңны туктат, Нурихан!

Башына мамыгы коелган шәл бәйләгән, өстенә ямаулы сәләмә фуфайка кигән Сафринә иде бу. Ирнең дилбегә чорнаган кулы калтырады. Белә! Баланың аңарда икәнен белә! Күзсез-колаксыз авыл диген син. Нишләргә? Юлын дәвам итәргәме? Кире борылыргамы? Хатын малайны эзли калса, капка белән ишек бикләнгән. Тәрәзәләр дә томаланган. Ядрәләр белән мавыккан Мирзабәк тавыш-тын чыгармас, шәт.

— Тукта, диләр, Нурихан! Синдә әзрәк баш төзәтергә юкмы? Шешәсе белән димим, күгәрчен тәпие чылатырлык кына. Төнката Орловка марҗалары белән гөрләшкән идек.

Башка вакытта Нурихан сүгенер иде, бу юлысы, тотылудан курыккандай:

— Эчмим бит, миндә нинди аракы ди, Сафринә, — диде.

— Һи, беренче тапкыр исемем белән дәштең әле. Азгынбикә, дия идең гел, — дип кеткелдәде тешсез хатын. — Хет узышлый тәрәзәгә чиертер идең, җүнсез. Минем кочакта назланган сәгатьләреңне сагынмыйсыңмыни? Миндә бүгеннән аулак өй, иркәм.

Нурихан бөтен буе белән чанага сеңде. Нинди аулак өй?! Хатын аны юри сыный. «Бала миндә шул» дип танармы, янәсе.

— Орловкадан кайтарсалар — ишегалдында милиун эз! Ишек шыр ачык! Безнең чирләшкә җәфаны бүреләр апкиткән.

Сафринә чыркылдап көлде. Олыгайса да, хатын-кызның көлүе үзгәрми икән.

— Син әллә җүләрләндеңме?! — Ана дип саналган хатыннан мондый ук тупаслык көтмәгән иде ир.

— Ышанмасаң, Фәсыйлә түтидән сораш. Дәү генә бүре күтәргән иде, ди. Шәрфә сылукай терелдеме әле? Минем сиңа иркенләп бер сер тишәсем бар, иркәм. Кичкырын кил...

— Юк, Сафринә!

— Һи, җансыз курчак! Сернең ахыры күңелсез тәмамлана: син Шәрфәгә өйләнә алмыйсың!

— Тапталма, — диде Нурихан, дилбегәсен кагып.

Аңа Фәсыйлә карчыкның кылын тартырга кирәк иде. Кортка төнлә күргән кешесен таныды микән?

Тик ни ул, ни әби кыек бүкәнне туры ярмады.

— Нәстә диим соң инде итәген җилгә селкегән катынга, олан? Карамады баланы. Кешедән оят, эт имгәләде малай. Хайван да җәлли ие сабыйны. Өчәр көн өендә кунмас, Арлуфка ирләре белән типтерер ие. Жуклы-барлы пинсәмә ашаттым ашатуын Мирзабәк угланны. Тамагын ач итмәдем, Ходай риза булсын. Ие, эзләмәсен дип, бүре апкитте, дидем, ие.

Нурихан, дулкынлануын яшереп, учына йөткерде:

— Расмы соң бу... бу хәл, — диде. Калтыравык тавыш барыбер сата иде.

Карчык иргә үтәли тишеп карап торды.

— Һай ла, олан, һай ла! Сафринә акылга саеккан, ә син таза-сау, камил бәндә. Ниткән бүре ди? Аллага шөкер, бала исән, аның кайгыртучысы бар. Чәй эчәсеңме?

— Рәхмәт, Фәсыйлә әби. Ашыга идем.

— Хәлемне белгәләп тор, олан. Заманында аул катыннарының әммәсен дә мин бәбиләттем, мин чирдән арындырдым. Үлсәм, садакаларыгыздан минем рухыма да өлеш чыгарыгыз. Синең дә кендек әбиең мин. Тәннәрегезнең кай төшендә нинди миң-төртке бар — хәтерлим. Кашки нәсел тамгаларын да, ие, олан.

Нурихан хәйләкәр карчыкның кая табан суктырганын чамалый иде. «Әйе, малай минем өйдә, малайны мин — этисе үстерәм», — дип, ирдән үз теле белән әйттерергә маташа. Ә Нурихан чарасыз: нәсел тамгасыннан да көчлерәк кирелек өскә калка... Инде кием кайгысы чүпкә әйләнде. Төнге вакыйгаларның көтелмәгән борылыш алуы ир файдасына түгел иде.

Мирзабәк ядрәләрне идәнгә тараткан, дөньясын онытып уйный иде.

— Улым, без синең белән кунакка барабыз, — диде Нурихан. Ул кинәт кенә башына суккан уен тормышка ашырырга тиеш иде.

Фәсыйлә — җир корты, җиде кат туфракны казып тикшермәсә, тынычланмый. Мөгаен, кичкә, мең сәбәп табып, ул Нуриханнарга сугылыр. Ә күрше авылда карчыгы белән генә Миннехан аучының яшьлек дусты яши иде. Өйләре җылы, үзләре ачык чырайлы. Нурихан базарга барышлый гел аларда туктала иде. Ике-өч атнага баланы сыендырырлар, бәлки. Ә аннары күз күрер тагы. Иң мөһиме — бүген авылда гайбәт чүпрәсен күпертмәү. Шәрифәгә «эһ» дигән аваз да ишетелмәсен!

Боз шыгырдап туңган баскыч төбендә йонлач эт койрык болгый иде.

— Һоп, сикер чанага, хайван, — диде Нурихан. — Бабаңнарның күңеле иркен, син дә сыярсың.

**4**

Ул гомер буе үз-үзен аңламаган икән. Күңел дәфтәре бер генә битле, азапланмыйча гына укы да чык дип санаган ир шаккатты: дәфтәр калын дәфтәрләрдән дә калынрак икән. Аның икенче, өченче, дүртенче һәм каядыр, бәлки, мең саны сугылган битләре дә бардыр. Мирзабәкне әтисенең дуслары: «Без картларга юаныч», — дип сөенә-сөенә алып калды. Дөрес эшләдем, диде Нурихан, малай белән хушлашканда. Ә хәзер ул, читлектә бәргәләнгән тиен кебек, ишекле-түрле йөренә. Ул да түгел, ятып-ятып, бала йоклаган мендәрне исни. Туганнан бирле Мирзабәкне кочагында тирбәткәнмени! Ничәдер сәгатьтән бәләкәчне юксынасың, дисәләр, илтеп тә мәшәкатьләнмәс иде. Әнә эт тугры, Мирзабәк кайда, ул шунда. Юк, аерылышулар вакытлыча гына бит инде. Малай шушы ишегалдында мәтәлчек атып үсәчәк.

...«Кунак» бик сабырсыз иде, тоягы белән дөп тә дөп ишекне кыйнады.

— Бикләнмәдеңме, олан? Уты элгән, мәйтәм. Көчкә-мөчкә үрмәләдем. Миңа, жук-жук та, өч елдан йөз яшь туласы, олан. Аяклар кәкрәя, аяклар менәтерәк, — дип сукрана-сукрана, Фәсыйлә карчык түргә үк узды. — Үзең генәме соң? Әллә ничә рәт урам кары пырылдаттың дигәндәй. Кая җөрештерәсеңдер.

— Тиздән яз җитә, әби. Сортлы алмагач үсентесе эзлим.

Сагышыннан китеп торыр өчен кортканың килеп керүе бик әйбәт иде әле. Ләкин Нурихан алданиләр ишетәсен белсә икән!

— Аулда алмагачлар бәндә балалары сымак җүнсезләнде: алмалары әче, авызны бөрештерә.

— Минекеләр корый, әби.

— Һе, кемнеңдер зәхмәте тигәндер, олан.

Карчык муенын селкетмичә генә күзе белән өй эчен айкады. Өстәлдәге савытта ботка иде, аңа бәйләнде:

— Ир башың белән сабыйлар ризыгына хирысландыңмы, олан?

— Тамак шеште, — дип алдашты Нурихан.

— Син чирләшкә булып тумаган иең, олан. Сине беләккә салгач, беләк сыгылган ие, — диде кендек әбисе һәм, капыл гына кузгалып, аралыкка башын тыкты. — Нәрсәдер кыштырдаган сымак. Тычканфәлән сымак.

— Нигезләр черегән, җил жуылдый, — диде хуҗа, көлемсерәп.

— Ызбаңның исе дә үзгәргән, олан. Бүрәнәләргә кемнеңдер сулышы ягылган сымак.

— Буйдак иргә җен ияләшмәде микән, Фәсыйлә әби?

— И-и, мин бит нигезгә дога кылмадым, олан. Бисмилләәһир-рахмәнир-рахим...

Нурихан да карчык белән бергә кулын күтәрде.

— Җен, дисеңме, олан? Ул бәдбәхет ияләнсә, гөнаһысы үзеңә, олан. Гарип-горабамы син, сукыр-пукырмы, ник үләнмисең? Мин сиңа Кармәттән каенсеңлемнең оныкасын димлим, бакчи. Соңгы пәйгамбәребез, парсызларны парлы итү лязим, димеш.

— Әүвәл күршеңне кара, Фәсыйлә әби.

— Сафринә катынныммы? — дип гаҗәпләнде карчык. — Миндә аңа таман ишләр-тиңнәр жук шул, олан. Ул безнең кавем халкыннан яралмаган. Сафринә — чи марҗа, аның чын аты — Сирафимә, олан. Зимагур Шакир анасы — мыштым Гөлбикә — үзенә яраклаштырып бозды исемен. Татар түгел ул барыбер, олан. Зерә яшерде моны Гөлбикә. Миңа ягадан авылга нинди чебен очып кергәне дә мәгълүмдер, олан. Бак, безнең Наратлык катыннарының күкрәге иягенә тиклем биек түгел, баш чөеп тә атламый алар. Безнекеләр туксан ир белән дә җокламый. Чөнки безнекеләр Аллаһтан курка. Шәрифә мескенем әнә, иреннән аерылгач, ябылуда яши.

Нуриханны башына сугып һәм селкенмәслек иттереп урынына кадаклап, карчык тел тегермәнен зырылдатты:

— Мин гайбәт чүбенә буялмадым. Итәгемә берәмтекләп җыйдым, әмма кушучлап ил йөзенә сипмәдем. Сафринәнең чын атын сиңа гына белгерттем. Син, олан, авызыңа су кап, җәме? Безнең аулда кеше әз, әзе дә таркау. Наратлыкта бозык үрчи дигән яманат күршеләргә ишетелмәсен! Кибетләрендә әйбер саттырмаслар, урамнарыннан узганда эттән талаттырырлар. Элгәре елларда катыннарыбыз базар шаулатты, уңган исеменнән гайре начар кушамат ябыштырмады. Әл дә сер бирмик, олан.

Карчык көйдереп-көйдереп ирнең йөрәгенә агу тамыза иде. Калку күкрәкле, сары чәчле Сафринә — Серафима... Димәк, малайның анасы — марҗа. Солтанбәк нәселе бу хурлыктан каберендә йөзтүбән әйләнер иде.

— Китим, олан, — диде Фәсыйлә карчык, шәлен урап. — Моңарчы чәй-шикәрдән өзмәдең, алга таба да ташлама, олан. — Ул бусага төбендә бераз таптанды да: — Мирзабәк углан безнеке, шөкер, — диде. — Сафринәне үзем бәбиләттем, шөкер. Бисмилла әйтеп кендеген үзем кистем, — диде.

— Исемен дә син куштыңмы, Фәсыйлә әби?

Бу мәгънәсез сорау иде. Ир беркатлы карак кебек тотыла язды. Ләкин карчык әллә чукрак иде, әллә артык тирәнгә кереп Нуриханны куркытырга теләмәде:

— Хуш, олан, — диде.

Үтмәс чалгы белән чапты хәйләкәр кортка, үтмәс чалгы белән! Ухылдап караватка ауды Нурихан. Ничек алай, ничек?! Солтанбәк нәселе, ике гасыр урыс авыллары белән аркага арка терәшеп яшәсә дә, кан катыштырмаган. Һәр милләтнең үз җыры, үз көе! Нечкә кылына саксыз кагылсаң — өзелә. Ә Нурихан берәү дә бозарга кыймаган шул көйнең уптым илаһи бөтен кылларын умырып ташлады. «Ялгыштым!» дип, җан ачысы белән кычкырасы иде. Тик кычкырып ни файда?! Чөнки төзәлмәслек ялгышлар да бар. Әгәр ул төнне Шәрифә «кил» дип алдамаса, бәлки, ир йөрәген уып утырмас та иде. «Кил» диде Шәрифә... Карчыкка серен үзе белән кабергә алып китсә ярамас иде микән... Хәер, сер вакыт дәрьясында барыбер батмый инде ул. Артык күп җыелды түгелме соң әле монда? Тамгалы малай, марҗа чәч Серафима... Шәрифәне югалтыр өчен боларның чиреге дә җитәчәк иде.

...Миннехан аучы үлгәч, ятим үсмер урта мәктәпне күрше авылда тәмамлады. Анда укучы балаларга интернат төзегәннәр, ул Нуриханга бик кулай иде. Тик егет монда урнашмас өчен җан тартышты.

Солтанбәкләр нәселенең бер ботагы Тимерхан карт, колактан борып:

— Ызбагызның ишек-тәрәзәсен кадаклыйм. Атаң һөнәре сиңа һөнәр түгел, атаң юлы сиңа юл түгел, зур укуларда укып кеше бул! — диде.

Көнаралаш Нурихан сигез чакрымдагы Наратлыкка килә иде. Кышын чаңгыда, карлар эрегәч — җәяү. «Бүре чәйнәгән» дип, егетне ун тапкыр «үтереп», ун тапкыр «терелттеләр». Ә ул, карурманны турыдан гына кисеп, Озын толымны күрергә ашкынды. Кыз гүя нәфрәт җебеннән тукылган, «кит» дип, матур йөзен генә чыта иде.

Сафринә аны кат-кат үгетләде:

— Йөрмә шуның артыннан, иркәм. Атаемны Миннехан аучы капкын куеп юри үтерде, ди ич матуркаең. Минем Шәрфәдән кай җирем ким? Менә билем, менә күкрәгем. Аның нәстәсен кочаклыйсың син? Алды — куна такта, арты — куна такта ич.

Бер кичне, клубта кичә беткәч кенә, буран кузгалды. Йөзләрен пәлтә якасы белән каплый-каплый алдан кызлар йөгереште, ә артта авыз-борыннарына кар тулган Нурихан ялварды:

— Ике генә минутка тукта инде, Шәрифә, ике генә минутка! Мин кырда адашып туңсам, үкенерсең әле.

Сафринә:

— Ник аңа ялынасың? Миндә кун, әбекәй зиратта бит минем, — диде.

Эчендә җан асраган кеше көнләшер иде, ә Шәрифә, Марҗа чәчне егеткә табан очыртып:

— Кунмагаегыз ни, хәчтерүшләр! — диде.

Аягы шуып карга егылган Сафринә Озын толымны үчекләп шаркылдады:

— Ха-ха-ха! Сине миңа саттылар, иеме, иркәм? Син, Шәрфә, үзең Чыңгыз малаена гашыйк бит, иеме?

— Ялган! — диде Шәрифә һәм Нуриханның каршысына ук килеп басты. Кызның кайнар сулышы кар сарган ияк очларын җылытты хәтта.

— Нурихан... Нурихан, мин...

— Әү! — диде егет, канатланып. Ләкин Шәрифәнең кулын тотам дигәндә генә көрткә мәтәлде. Сафринә аңа аяк чалган иде.

— Әй лә! — диде Озын толым.

Нурихан торганда, кыз каядыр гаип тә булган иде. Ул әнә шул «әй лә»се белән җавапсыз мәхәббәткә соңгы нокта төртте кебек.

Чыгарылыш кичәсендә егетләр бакчада качып кына бер ярты сындырды. Моңарчы шайтан суы капмаган Нурихан кара төннең агарып, ә күңелендәге сөю сагышының яктырып китүен тойды. Ул, велосипедка атланып, Наратлыкка җилдерде. Шәрифәләр утларын сүндереп йоклый иде инде. Авылда чикерткәләр генә «көй» сыздыра. Егет, койма аша сикереп, ян бакчага төште һәм тәрәзәгә якынлашты. Көндезләрен бу тәрәзә тутырып ук ачылыр да, яран гөлләре урамны күзләр иде... Ә хәзер тәрәзә ябылган, ак пәрдәләр тартылган. Пәке белән каермакчы иде, рамнар бирешмәде. Ә түзәрлек чама юк! Егет бармакларын пыялада биетте.

— Шәрифә, чык, сиңа сүзем бар!

Өй эчендәгеләр уянды бугай, сиртмә карават шыгырдады.

— Мин сине яратам бит, Шәрифә! Үлеп яратам! Җә, чык инде, Шәрифә! — Ялыну үзеннән-үзе еламсырау белән алмашынды: — Шәрифә... багалмам... Ник син мине сөймисең?.. Шәрифә багалмам, ник син миннән көләсең?.. Уйларымда гел син бит... Чын ярату белән яратам бит, багалмам...

Үзе сөйләде, үзе күз яшьләре белән елады егет. Тимерхан карт якасыннан умырып торгызганда, Нурихан бизгәк авыруы эләктергәндәй калтырана иде. Ул тузынган арада, кызның әнисе бакча артыннан гына Тимерханнарга йөгергән икән.

— Әйдә, олан, — диде карт. — Әйдә! Миндә сине каеш белән ярырлык кына көч бар!

Әмма карт аңа кул тидермәде. Камырланган гәүдәне чоландагы сәкегә иплә кенә аударгач:

— Йокла, олан, — диде.

Иртәгесен Нуриханга зур гына төенчек бирделәр.

— Карчык сиңа юлга ризык төйнәде, — диде карт. — Хәзер ентернатыңа кайт, мәптегеңнән язуларыңны ал, кояш батышында артыңнан калхуз машинасы керер. Калага барышы аның. Зур укуларда укы, олан! Бүтән авылга эз дә басма! Син Солтанбәк ыруын ике кат хурладың, тол катынның тәрәзә төбендә акырып тынычсызлаган бәндә — бер яман. Авызын сасы көмешкә белән пычраткан бәндә — ике яман. Тагын да өченчесен искәртәм. Асыл ир-ат катын-кыздан җәлләтеп сыктамас, олан.

Нуриханның үзенә дә оят иде. Авылдан битен каплап чыгып китәрдәй булды ул. Ичмасам, велосипед тәгәрмәчләре дә тиз-тиз әйләнми. Әллә аяклары хәлсез, әллә йөрәкнең көче суырылган. Шуңа күрә, эзләренә үк бастырып, әрәмәлектә аны Сафринә куып тотты.

— Тимерхан бабайлар тыкрыгында күрдем дә... — диде кыз, мышнап. — Нишләп йөрешең, иркәм?

Әһә, Маржа чәч төнге маҗаралардан бихәбәр икән. Димәк, авылда беркем дә бу хурлыкны белми.

— Велосипедың иске, теләсәң — алыштырыйк. Минеке өр-яңа, — диде егет.

— Үзең ни белән йөрмәкче, иркәм?

— Миңа аның кирәге юк. Бүген калага сыптырам. Зур укуларга.

— Күзем чәчрәп аксын, диген, иркәм!

— Акмасын, күз миңа укырга кирәк.

— Әлсә, саубуллашу хөрмәтенә мине кочаклап үп инде, иркәм.

Гәүдәсен янтайткан кызны Нурихан этеп турайтты:

— Аума, Сафринә.

— И, бигрәк инсафлы син, иркәм. Кемгәдер ялкынлы сәламнәреңне күндеримме соң?

«Кемгәдер», әлбәттә, Шәрифә иде. Капчык-капчык сагыну сәламнәре юллар иде Нурихан. Тик аларны каты бәгырьле кыз кабул итәр микән?

— Кирәкмәс, Сафринә, — диде егет.

Урман авызында ул озак кына Наратлыкка карап торды. Көтте. Чү, өч кенә минут сулыш алыйм, дип, үз-үзен алдый-алдый көтте. Өч минуттан соң тагын көтте. Түзмәс Шәрифә, хушлашырга килер кебек иде. Әле егет интернатта да көтте. Нуриханның гомере тоташ көтүләрдән гыйбарәт иде...

Карендәше «бүтән аяк басма» дисә дә, студент егет өч елдан Наратлыкка кайтты. Тимерхан карт каеннар төбендә ята, каеш белән өркетерлек якын кешесе юк иде. Ул ишек-тәрәзәдәге такталарны куптармады, йорт тирәсен әйләнгәч, Фәсыйлә карчыкларга юнәлде. Кендек әбисенең яңалыклары кыска иде.

— Шәрифә кияүдә, олан. Чыңгыз малаенда. Ире, мәлгунь, эчә, сугыша. Арурак җегет белән кушылмады Шәрифә. Сафринәдән дә уңмады авыл. Ирләр белән азына. Ишекне эчтән бикләдем менәтерәк. Сине күрсә, күзен-башын тондырып керәчәк затсыз бичә.

Карчык мич күмерендә коймак чыжлатып та өлгермәде, ишек дөбердәттеләр.

— Әнә иснәнә теге затсыз, — диде кортка һәм аяк очларына гына басып килде дә колагын кеңә турысына куйды. — Кайсыгыз ызбамны ишә?

Тыштан исерек тавыш ишетелде:

— Фәсыйлә әби, синдә нинди ир-ат ул? Нурихан кебегрәк төсмерләдем.

— Күзеңне җен алдый, Сафринә. Миңа кем сугылсын, — диде карчык.

Чәйләгәч, ул аны абзар артыннан озатты.

— Ачуланма, олан. Бозык Сафринә белән күрештермим. Синдәй асыл җегетне көя тапамасын. Җәйләрдә мәрхүм атаңның дустында яшә. Наратлык дип көенмә.

Эшләр көенүдән узган иде шул. Шәрифә кияүдә... Ире җәберли... Шундый бәхет тансык идеме аңа? Исерек йодрыгына сусап, Нуриханнан йөз чөердеме ул?

## 5

Аучы дустының карчыгы Мирзабәккә таман гына күлмәк тексә дә, Нурихан базардан кочагы белән бала әйберләре җыйды. Ике яшенә хәтле итек, тун, башлык кимәгән малай киендергәндә көйсезләнә башлады. Аның, күрәсең, тыгыз киемгә җаны кысыла иде. Нурихан, нәни «аю баласы»н ишегалдына бастырып, аучы картның кыш буе өелгән карын көрәде. Ә малай каккан казык кебек селкенми иде.

— Өшисең, улым, хәрәкәтлән, — диде әти кеше. Тышауланган Мирзабәк шыңшырга тотынгач, аны агач көрәккә яткырып тартып йөрде, карга салып аунатты. Алар янында койрыгын болгый-болгый йонлач эт тә бөтерелде. «Кемнән туса да, улым — минеке» дигән уй белән җылынып, ир Наратлыкка кузгалды. Ат чанасы табаны сызган тар гына юлдан бөкрәеп-янтаеп бер хатын атлый иде, Нурихан, танымаса да, көр тавыш белән аңа эндәште:

— Утыр, апа!

«Апа» шәл белән томаланган йөзен ачты. Нурихан ничек җиргә сикергәнен дә, ничек хатынны биленнән эләктереп чанага утыртканын да сизмәде.

— Ник җәяү кайтасың, Шәрифә?! Өзлегерсең бит, Шәрифә!

Хатын, аның бу кыюлыгын өнәмәгәндәй:

— Һава суларга кирәк бит инде, бүлнистә тынчу, — диде.

— Врачлар, яраң тирән, диделәр. Уңайландыңмы соң, Шәрифә?
— Алар гел куркыта, — диде Шәрифә.
«Ничә тапкыр хәл белергә килдем. Ник чыкмадың?» дип мескенләнү килешми иде. Һай, тилерткән-саташтырган Озын толым үзе аның янәшәсендә утырып кайта, бу бәхет түгелмени, йә?! Озын толым... Шәлен сүтәсе иде, толымнары һаман үкчәләренә тия микән?
— Сафринәнең малаен бүре ашаган, диләр. Дөресме соң?
— Ә?
— Бүлнистә ишеттем. Начар хәбәр тиз аяклана.
— Шулайрак, ахрысы, — диде Нурихан, айнып. Күңел хис дулкынында йөзә һәм, бу ләззәттән арынып, тормыш күңелсезлекләренә батарга теләми иде.
— Бездә милиция Наратлыкка гүпчим төкерә. Авылың белән егылып үл!
— Сиңа да сакланырга кирәк, Шәрифә.
— Миңамы? Әй лә!
Үтерә шуның «әй лә»се! Нәкъ кыз чагындагы кебек өздереп әйтүен кара син. Нигә Наратлык белән күрше авыл арасы кинәт кенә әллә ничә чакрымнарга озынаймый икән? Инде басу капкасына җитәләр...
— Өең салкындыр, Шәрифә. Кем дә мичең якмаган... Минем ызбада май эри. Әйдә безгә, — диде Нурихан, батыраеп.
— Рәхмәт, Нурихан. Фәсыйлә әби кундырыр әле. Мине урам буйлатып аппарма, төшер. Хуш, яме?
— Исәнлектә яшә, Шәрифә.
Болытларны аралап, бәхет кояшы елмайган көн иде бу. Керпе сыман энәләрен тырпайткан Шәрифә йомшарган. Чана төбендә кендек әбисенә дигән тәм-том бар иде, Нурихан аны юри хатынга бирмәде, аңарда өр-яңа хәйлә борынлап маташа иде. Күчтәнәчен керткән булып, ул тагын бер мәртәбә Шәрифәне күрәчәк! Бәлки, шулай әкрен генә аралар да җайланыр.
Нурихан атын тугарып, юынып-кырынып ике сәгать чамасы вакыт уздыргандыр, ни гаҗәп, Фәсыйлә карчык өендә ялгызы гына йон эрли, ә Шәрифә юк иде. Чанада бергә утырып кайтулар әллә төш, әллә өн.
— Утыр дияр идем, олан, мин кортка белән ни гәпләшерсең икән? — диде әби. — Синең алма бакчаң ел да корыймәле, олан?
— Корый, әби, — диде ир, күңелсез генә.
Алмагач өчен кайгырмый иде ул. «Фәсыйлә әби кундырыр» дигән кеше хатын-кыз кыяфәтендәге өрәк иде мәллә? Карчык та аны-моны әйтмәде.
— Син куакларыңны язга Йосыф аланында төплә, олан. Эш башлаганда картлар белән киңәшләшү мәслихәт ие, олан. Сез яшь токым, үзбаш кыланасыз.
— Туфрак кайда да туфрак инде, Фәсыйлә әби.
— Һе, сүләдең сүз, олан! Син бакча җәелдерәсе урында элгәре безнең бабайларны чукынырга өндәгән поп җан биргән. Авылдан куганда яндырганнар аны. Ул зәхмәтле төштә икмәк тә бармак буыны тиңентен генә үсеп ката ие, олан.
— Ярар, Фәсыйлә әби, миңа да Йосыф аланы ошый. Язга кадәр уйларбыз. Мин чыгыйм, булмаса.
— Ходай тыныч төннәр әйләсен, олан.
Баскыч төбендә Нурихан шыгыр-шыгыр кар изде. Кайда бу Шәрифә, кайда? Карчыкның җил капкасыннан кереп киткән иде бит... Менә сиңа башваткыч! Әмма аңа бәхет кояшы һаман елмая икән: кара мунча тәрәзәсендә ут җемелди иде. Ир төлке җитезлеге белән шул якка ыргылды. Мунчада шап-шоп бәрә-бәрә чабынган тавыш ишетелә. Шәрифә! Тишек-тошыклардан бөркелгән пар борынны кытыклый. Фәсыйлә карчыкка бөдрә каен себеркесен Нурихан әзерләгән иде... Шул каен яфраклары, Нурихан куллары булып, хатынны сыйпый-иркәли... «Моннан да җайлырак форсатны кайчан табасың, аягүрә йоклама, кыюрак бул! — диде ир, үз-үзен кыздырып. — Бәлки, кара мунча сезне кавыштырып та куяр».
Нурихан ишекне төртте. Келә кадакка гына эләктерелгән, таза-таза бүреләрне җилкә аша чөйгән аучы малаена ул киртә түгел, каты гына селкетсә, тупсасы да төптән үк каерылачак иде. Ләкин ир мондый тупаслык эшләргә базмады. Көч белән яуланган мәхәббәтнең гомере кыска.
Юл уртасында Сафринә тыпырдый иде.
— Аякларым туңа, — диде ул, чытлыкланып. — Җылытыр идең, Нурихан. Кортка йортына бал сөрткәннәрмени, иртә-кич яланасың.
— Бар, өеңә кер, җәфа.
— Мин Орловкадан атлы көтәем. Утырмага чакырганнар ие.
— Иваннармы?
— Ибанмы, Чтапанмы — безнең күңел хуш, ашатсыннар-эчертсеннәр, чөнки кесә буш, — дип такмаклады хатын. — Син әл дә Шәрфә дип саргаясыңмы, иркәм? Теге серне чылбырдан ычкындырсам, ник Наратлыкта туганыңа үкенәсең инде син, иркәм.

«Малайның әнисе — марҗа» дигән уй корт кебек вакыт-вакыт йөрәкне кимерә, ә Сафринә белән очрашкач, ул үзен тагын да ныграк сиздерә иде, шуңа Нурихан сүз куертмады, «әй» дип кул гына селтәде. Сереңне бау итеп муеныңа так, сары чәч!

...Нурихан бөтенләйгә дип авылына кайтканда, Наратлык картайган иде. Яшь-җилкенчәк шәһәргә агылган, хәллерәк гаиләләр, каралты-курасын сүтеп, үзәккә күченгәч, ат чабышлары уздырырлык озын урамнарда өйләр берән-сәрән генә калган, «һай» дип кычкырсаң, илле-алтмыш бөртек җан иясе җыелыр иде. Ир якты хыяллар белән кайтты. Беренче исәбе — алма бакчасы үстерү, икенчесе — Шәрифә иде. Хатын иреннән аерылган, хәзер атасы йортында яши. Ялгызлык татлы бал түгел, ялгызлыкта әрем тәмнәре бар. Әлбәттә, Озын толым, ул тәкъдим ясаса, ризалашыр кебек иде. Юллар кисешкәндә, Шәрифә ягымлы йөзен балкытып исәнләшеп үтә башлады. Хәл-әхвәл сорашсаң, матур күзләрен зур ачып: «Духтыр түгелдерсең лә!» — дип шаяртып та куйгалый. Хатын һаман шифалы үләннәр белән мавыга, шуларны җыеп-киптереп, йә базарда сата, йә даруханәләргә тапшыра икән.

Беркөнне уйнап кына:

— Киләм, — дигәч, Шәрифә, һич ялындырмыйча:

— Кил, — диде. — Ут алгач, яме? Ишеккә өч тапкыр шакы.

«Бу күрешү туй белән тәгәлләнер, — диде Нурихан. — Ниһаять, мин яраткан киребеткәнемә өйләнәм! Авыл хатыннары кырык яшьтә дөбердәтеп бала таба. Әле соң түгел. Әле Солтанбәкләрнең нәсел тамыры куәтле...»

Җәйге көннәр эчпошыргыч озын иде, кояш та дөнья төн карасына манчылгач кына байый. Караңгы иңгәнен көтә-көтә күз күгәрде. Кияү егетләредәй костюмнар киеп, галстуклар такты ир. Тик «кил» дигән хатын йөз мәртәбә шакып та ишеген ачмады. Икенче көнне ул:

— Шакуыңны ишетмәдем, арып йокланылган, — диде.

— Уяу тор, бүген киләм, — диде Нурихан.

— Кил, — диде Шәрифә.

Бу юлы да ишек саңгырау иде. Өченче тапкыр бәхетен сынаган ир тагын уңышсызлыкка юлыкты. Гарьләндеме Нурихан? Юк! Хатын-кызга үпкәләгән ир-атның базарда поты бер тиен, дияр иде әтисе. Әмма йөрәккә үткен пычак чәнчелгән иде. Ул, күлмәк-чалбарын да салмыйча, караватка егылды. Ә бүген шул каһәр суккан төн турында уйласа, тамырлардагы кан бозлана. Өч чакрымнан куянны — сулышыннан, төлкене исеннән таныган аучы малае ничек кеше аермады икән?

Ишекләр тутырып ачык иде. «Кхым» диде өйалдында берәү. Нурихан атылып тормады. Нурихан сабыр гына көтте. Үзе килсен... Хәзер аның чираты... Вөҗданың газаплыймыни, Озын толым? Җандагы сөенечнең күләмен Җир шарындагы иң дәү үлчәү-мыскаллар белән дә үлчәп бетерерлек түгел иде. Ул, рәхәтенә чыдаша алмыйча, чытырдатып күзләрен йомды. «Төнге кош» очып кына аның күкрәгенә «кунды».

— Кайтуыңа өч ай, ник бармак селкетмисең? Син турдан үткәндә, дәртем кузгала ич, иркәм... Менә үзем килдем.

— Фу, син кем?! — дип борынын җыерды Нурихан. Сорамаса да билгеле иде: Сафринә. Шул ис, һаман шул ис! Хет бауга элеп җиллә т.

— Мин синең юатучың, иркәм. Шәрфә дип күенәсең, иеме? Төкер, ул — салкын катын.

— Кит, сансыз!

— Кума. Синең тугрылыгың кемгә хаҗәт? Ни кадер күрдең аңардан?

Сафринә хаклы иде.

— Аны бераз көнләштерергә кирәк, иркәм.

— Көнләштерик соң, — диде ир...

Гүя шуннан соң Шәрифә аның муенына асылыначак иде. Беркатлы Нурихан! Ул Озын толымдагы горурлык биеклеген бөтенләй үлчәмәгән икән.

Иске мәктәп бакчасында бригадир Фазыл халыкны җыйган иде. Җыелышка соңлаган Нурихан кеше-мазар күрмәгәндә генә бер карлыган куагы төбенә чүмәште. Төнге маҗаралардан баш авыртып укшыта, мөгаен, ул аю куркытырлык ямьсез кыяфәттә иде. Ир үзен рәхимсез рәвештә сүз белән талады. Чүпрәк! Җебегән! Мәми авыз! Сафринә коткысына бирелеп, сазга буялды. Кеше күзенә туры карарга кыймассың, валлаһи. «Миннехан малае бозык хатыннар белән күңел ача», — дип көләрләр сыман.

Бригадир учын учка шапылдатты.

— Игътибар, Наратлык! Сездә кибет юк, почта юк, клуб юк, утның сыйфаты начар, телевизор эшләми, газ кертелмәгән, интегеп мич ягасыз.

— Урман өскә ишелгәндә, утынга җәдәмибез, — диеште картлар.

— Үзәктә егерме йорт буш, тәвәккәлләп кем күченә? Совхоз Наратлык хуҗалыгы бүлекчәсен гамәлдән сызды. Фермадагы терлекләрне үзәккә кудык, — диде бригадир, үгетләвен дәвам итеп. — Сөткә дә тилмерәчәксез.

— Кәҗә асрарбыз, — диде карчыклар.

— Җәмәгать! Бүреләрне нишләтәсез? Уңда — урман, сулда — урман, ә, җәмәгать?

— Сез гаепле. Чарасын күрмисез, Миннехан аларның акылын тарый иде, — дип гөрләште карт-коры, — әнә мәрхүмнең малае Наратлыкта төпләнеп маташа, шәп кенә түләсәгез, ерткычларны берәмтекләп чүпләр!

Бригадир тагын учын шапылдатып халыкны бастырды:

— Нурихан абый мәсьәләсендә болай: ул җир алды, алма үстерәчәк.

— Көндез — алма, төнлә — бүре, — дип кычкырды берсе.

— Сездә ди аның кайгысы, җәмәгать! Алма сатып баерга хыялланган комсыз сезнең арык сыер-сарыкларыгызны саклар ди! Аның бакчасына ни зыян, бүре алма кимерми.

Шунда, шаккатырып, Шәрифә аваз салды:

— Ник син кеше турында шулай начар фикер таратасың, энем?

— Кем «кеше»? Нуриханмы? Ул синең кан дошманың бит, Шәрифә апа, — диде Фазыл. — Атаң, аучы Миннехан капкынына кысылмаса, йөз ел яшәр иде.

— Тонык суны болгатма, яме, энем! Яп җыелышыңны! Без Наратлыктан беркая да күченмибез, — диде Шәрифә.

Халык мыгыр-мыгыр сөйләнеп таралды. Шәрифәнең кулында талчыбыгыннан үргән тырыс иде. Менә ул, ялгызы гына калып, карлыган яфраклары өзәргә кереште. Нуриханга качып яту уңайсыз иде, ир урыныннан күтәрелде. «Җирдән үскән» пәһлеван хатынны сискәндереп җибәрде:

— Абау, котсыз!

— Булышыйммы? Минем куакта яфраклар ямь-яшел, — диде Нурихан.

Шәрифә аңа зәһәр караш ташлады:

— Кит юлымнан, кит! Мин сине күралмыйм!

— Үткән-беткән бит инде, Шәрифә. Икебезнең дә әтиләр мәрхүм.

— Нәрсә?! Кем сине үткәннәр белән битәрли?!

— Алайса, ник миңа нәфрәтләнәсең? Кичә генә «кил» дип чакырган идең үзең...

— Нигә вәгъдәңне үтәмәдең? Нигә килмәдең соң? — диде хатын.

Нурихан аптырады.

— Кызык син, Шәрифә! Ишеген эчтән җиде кат йозак белән бикләгән дә!

— Ә син тәрәзәне каерып керер идең! Яраткан кеше ничек тә җаен таба ул! — диде Шәрифә һәм, тырысын җиргә бәреп, елый-елый ике кулы белән Нуриханның күкрәген төйде. — Син... син хыянәтче! Син бүген төнлә Сафринә белән идең! Мин сине күралмыйм, җаным-тәнем белән күралмыйм!

Тырыс янтаеп, үләннәр арасына яфраклар сибелде. Кызыл чәчәкле күлмәк кигән иде Шәрифә. Офыкка да шәфәкъ кызылы җәелгән иде. Хатын йөгереп китеп барды. Китмәде, шул кызыл офык белән бергә кушылды...

Ә дүрт айдан Сафринә, түгәрәкләнгән корсагын сыйпап: «Авылның иң асыл җегетеннән күчтәнәч», — дип мактанган. Наратлыкта исә хатын-кыз «тилерткән» асыл егет берәү генә. Кем дип баш ватасы да түгел, ул — Нурихан. Шуңа күрә гайбәтчеләр «күчтәнәч иясе»н дөнья актарып эзләп тә маташмадылар, телләре белән Нурихан капкасына төртелделәр. Ә ир куерган гайбәт боткасын су белән сыегайтты: «Бала минеке түгел!»

Наратлык тел бистәләре шаулаганда, Шәрифә ниләр кичергәндер, анысы Нуриханга караңгы иде. Хатын шул хәлләрдән соң, менә минем җавап дигәндәй, яңадан ире белән кушылды да, исерекнең тукмауларына түзалмыйча, яңадан аерылды. Ике елда Шәрифәгә ике мәртәбә бүре һөҗүм итте. Ул: «Болардан безне Нурихан гына коткара», — дигән, имеш. Арада адашкан сүзләр генә йөри иде шул. Сафринә бәбиләгәч, Озын толым Нуриханнан бөтенләй суынды, ахрысы. Хатын тарафыннан һичьюгы бер уч җылы өметләнгән очракта, иргә, мылтык асып, урман иңләргә кирәк иде. Әмма колак төбендә яңгыраган аучы ата васыяте кулны йозаклый иде. Аның черки дә тешләмәгән килеш үлеп китүе табышмак булды. Бу, чынлап та, Аллаһтан бирелгән җәзадыр, бәлки. Миннехан ерткыч канын күп койды. Әгәр бүген Нурихан алмагач бакчасы тәгаенләп, дөньяны ямьләргә, шул бакчаның җимеше белән авылдашларын сыйларга тели икән, моның ни гаебе?!

Ләкин ир ике ут ялкынында өтелде. Бер якта — васыять, икенче якта — Шәрифә... Җан сөйгәнен ул бәла-казадан сакларга тиеш иде. Кышкы айларда Озын толым үзәк базарда дару үләннәре сата. Берничә мәртәбә Нурихан аны урман аша озатып та куйды. Тик Шәрифәгә, горур Шәрифәгә, ирнең кайгыртуы ошамады:

— Син нәрсә катыннар итәгенә тагыласың? Синнән башка да юлны беләләр. — Ачуланганда аның күзләре зураеп, алдында торган кешене йотардай була иде.

— Их, Шәрифә, Шәрифә, — диде Нурихан, — нишләп һаман мине күралмыйсың син, ә?

Аңгыра! Бу сорау белән ул хатынны бөтенләй ярсытты:

— Мин сине чакырмыйм, мин сине эзәрлекләмим! Үзең кулыңны утка тыгасың! Пешсәң, миңа үпкәләмә!

— Кая кул, йөрәгемне утка тыгам, — дип төзәтте ир.

— Синдә йөрәк юк! Сафринә белән йоклаган бәндә агач бүкәне ул!

— Хаталандым, Шәрифә, кичер, бәгырем...
— Миңа ни... Хата, имеш! Йөрәк дигәннән генә...
Соңгы очрашуда алар әнә шулай пыр тузышкан иде. Бүре хәйләкәр, хатынның иртә-кич ялгыз юл сабуын бик тиз сизде: өченче һөҗүмнән яраланган Шәрифә хастаханәгә үк эләкте. Алга табан аны берүзен генә йөртергә ярамый иде. Өч ул — кисәтү саны, дүртенчесе белән шаярмыйлар. Сандугачны нинди җимнәр сибеп эләктерергә икән? Әйе, ул бүген чанага утырды. Юк, Нурихан күтәреп утыртканда карышмады. Әйбәт, бик әйбәт! Җилле буран күк белән җирне тоташтырып дулаганнан соң, ялтырап кояш чыкмас, билгеле. Сафринәнең бала табулары, малай Нуриханныкы дигән гайбәтләр... Эһе-һе, кайсы хатын урталай сыгылмас. Инде буран әкренләп тына бугай. Арада сәбәп итәрлек бүтән киртә дә юк. Кавышыйк, дисә, Шәрифә ни-нәрсә белән дәлилләп баш тартыр икән?
Ә малай? «Минеке түгел», — дип, бөтен авылны ышандырган малай?

**6**

Фазыл, күшеккән бармакларын угалап:
— Көн салкын, кул өшеде, — диде. — Нишләп бу егет миңа килде әле дип гаҗәпләнмә, Нурихан абый. Баштарак мин сине өнәмәдем. Син кайттың да безгә мишәйт иттең. Наратлыктагы калдык-постык хуҗалыклар үзәккә күченергә тулаем ризалашкан иде инде.
— Шуннан? — диде Нурихан.
— Шуннанмы? Халык бит ул бал корты төсле, ана корт көчле икән, таза икән — таркалмый. Наратлыклар да синең гайрәтеңә таяна.
— Мин беркемне дә үземә бәйләмәдем, энем.
— Бәйләдең, бик бәйләдең, Нурихан абый! Алар авылда хуҗа бар дип гайрәтләнә. Әгәр син моннан кузгалсаң, иртәгә үк нигезләреннән кубачаклар.
— Юк, энем, үгетләмә. Алла кушса, минем монда картаеп үләргә исәп. Солтанбәк нәселенә чит туфрак килешми.
— Синең гомер шәһәрдә үткән, Нурихан абый! Бөтен шартлар тудырылган фатирда. Ә авылда нәстә, йә? Сукыр лампа, кара мунча, чокыр-чакыр юл... Үзәктә без сиңа таш йорттан бүлмә хутлыйбыз. Син төзелеш инженеры, иеме? Һо, мәктәпләр, клублар төзеттерерсең.
— Бүген адәм баласы цивилизация шаукымыннан гарык, энем. Ул таш фатирлардан, газ сауналарыннан туйды. Табигыйлек кайчандыр бар ясалмалыкны кысрыклый инде. Кыскасы, син мине таш өемнәре белән кызыктырма. Нараттан бурап ызба салуларга, төтенләтеп кара мунча ягуларга ни җитә!
Фазыл баш түбәсен кашып алды.
— Үзәктә әзер-бәзер алма бакчасы бар бит әле безнең тагы. Йорты да, мунчасы да агач. Түшәмгә төкереп кенә ят.
— Төкерергә калгач — үләргә вакыт инде ул, энем. Минем үз кулларым белән бакча ясыйсым килә.
— Кире чабата икән син, Нурихан абый.
— Әйтмә дә инде, энем.
— Аптыраш, хакимияттә безне сүгәләр, Наратлык ташландык, ник карамыйсыз, диләр. Авылларны берләштерсәк, чыгымнар кимер иде. Ерткыч оясында кырылып бетәрсез әле берзаман. Шәрифә апаның муенын чак кына чәйнәмәде бүре. Әнә теге аумакай Сафринәгезнең чирләшкә баласын бүреләр күтәреп киткән, ди. Ерткычны, хөкемгә тартып, төрмәгә ябалмыйсың. Безне миңгерәтә бу Наратлык. Ярар, мин йорт саен кереп халыкны күчәргә өндим, ә син, Нурихан абый, уйла, ныгытып уйла.
Уйлады Нурихан. Рух баганасы какшаса, авыл бетә. Адәм, таяныр ноктасын җуеп, бушлыкка мәтәлә. Димәк, авылдашлар, гәрчә аны яратмаса да, ят итми, аңа өмет баглый икән. Ай-һай, аңарда ул өметләрне акларлык абруй бар микән соң? Элек картлар урамнан узганда, тузан бөртеге дә очмас, чөнки аксакал, таягын җиргә йомшак кына кадап, үз дәрәҗәсен белеп, салмак адымнар белән генә атлар, ни шук оланшак та аның каршында шаярмас, бер минутка уеныннан туктап, озатып калыр иде. Теле белән генә түгел, күз карашы белән дә тәрбияләр иде авыл карты. Алардагы олпатлык, алардагы сабырлык Нуриханда да кабатланса икән! Мирзабәк кем үрнәгендә үсәр менә.
Ир аралыктагы сәндерәдән киндер капчыкка төрелгән ау мылтыгын алды. Ата истәлеге... Ут коралын чистарта башласа, Миннеханның ике каш арасына җыерчык буразнасы сузыла иде. Җитдиләнә иде ул. Ау дип яшәде ата, ау дип үлде.
Бригадир Фазыл яңадан әйләнеп керде.
— Минем өй борынча кытаклап йөрүемнән ни мәгънә?! Җәмәгать сиңа аркаланып батырая, Нурихан абый, — диде егет. — Син, кем, ауга җыенасыңмы?
— Юк, чистартып кына куям, эти төсе бит, — диде Нурихан.
— Да-а, Миннехан абзый бүре холкын белә иде! Ну нәстә, уйладыңмы, Нурихан абый?
— Ике сөйләттермә инде, энем.
— Ялгызыңа гына кыендыр, Нурихан абый. Үзәктә хатын-кызның нинди генә төре юк. Кара чәчлесе, коңгырт чәчлесе. Үзеңне өйләндерер идек. Син аерылган кешеме? Балаларың ничәү иде?

— Мин буйдак, — диде Нурихан, кәефе кырылып. Егет аның бәгыренә ком булып коела иде. Дөньясы белән бергә ир-ат та үзгәрде: сөйләшүләре вак һәм төче.

— Син заман койрыгында гына сөйрәләсең икән, Нурихан абый. Мин өченчегә аш төрләндердем. Беренчесе бәрәңге боткасын шыр тоз итеп пешерә иде, икенчесе, кояш битен кыздырганчы йоклап, сыерны саумыйча гына көтүгә куды. Әле өченчесе белән дә чәкәләшәбез. Ялкаурак. Уңмадым мин хатыннардан.

— Авыш йортның моржасы да авыш, энем.

— Минем морҗа туры, Нурихан абый.

— Төтене генә нигәдер кыек, энем.

— Мыскыллама, Нурихан абый.

— Ә син хатын-кыз чәйнәмә, тешеңне сындырырсың, энем.

— Әй, җә мылтык түтәсе белән сыртны каезларсың, таям мин, — диде Фазыл. — Шәрифә апа да көтә-көтә көтек булгандыр.

Өч көн җанына урын тапмаган иде Нурихан. Хатынның морҗасыннан төтен күтәрелми, тәрәзәләре, «менә елыйм, менә елыйм» дигәндәй, бозлы күзләрен мөлдерәтеп, урамга карый иде. «Ире йортында ята бугай» дип көнләшкән Нурихан өчен бу хәбәр йөрәккә сыланган сары май иде.

— Шәрифә сине кайда көтә, энем?

— Фәсыйләттәйләр турында. Бүлнискә бәйләвечен алыштырырга бара.

— Тукта, энем, син аны утыртма! Апаңны үзем илтәм, яме!

Нурихан ашыга-ашыга киенде.

— Әйтүен әйтермен дә, үзе ни дияр бит, — диде Фазыл. — Һе-һе, әллә апай белән мәхәббәт куертасызмы? Булды, шаярттым гына, Нурихан абый.

Атын бик тиз җикте ул, капкасын да бик тиз ачты. Әмма Озын толым Нуриханны көтмәгән иде. Кунагын озата чыккан Фәсыйлә карчык:

— Бригат Фазыл белән китте ул, олан, — диде. — Синең дә үзәктә йомышың барыемы?

Их, кортка, кортка! Ичмасам, син хәйләкәр сорауларың белән йөрәкне көйдермә. Беләсең син Нуриханның кемне яратканын, беләсең! Күптән аларны кавыштыру чарасын күрергә иде сиңа! Әллә картайгач кешенең йөрәге мүкләнә микән?

— Синдәмени әле Шәрифә? — диде ул, ризасыз тавыш белән.

— Ишегалдын муен тиңентен кар күмгән, олан. Аны көрәргә ир-ат куәте кирәк. Ярасы төзәлмичә балакаема себерке белән селтәнергә дә кушмаган врачлар. Мәйтәм, яз ызбаңа сукмак әрчелер, мәйтәм, миндә кышла.

— Наратлыкта биләмче хатыннар болай да күп, үз өендә яшәсен, — диде Нурихан. Әйтерсең ул Шәрифәнең хуҗасы иде. — Миннән ярдәм сораса ни була? Безне үзәк җитәкчеләре авылдан сөрергә маташа. Безгә хәзер бер йортны да ябулы итәргә ярамый. Болар тере, болар җанлы, дисеннәр.

Чынлап та, кар Шәрифәнең капкасын томалап, юлын япкан иде. Агач көрәгенә таянган ир, сихерләнгән төсле, бозланган тәрәзәләргә карап торды. Бервакыт ул (аңа ун-унбер яшьләр иде), Шәрифәне сагалап, аларның турларында таптанды. Күлмәк эчендә нәни кыр куяны баласы иде, шуны күрсәтеп, кызны биетмәкче иде ул. Ачылмалы тәрәзәдән Билалетдин урманчының хатынына җикергәне ишетелде:

— Син төпсез чиләк! Син Миннеханнан калдың!

Ул да түгел, капкадан Озын толым атылып чыкты.

— Нәстә тыңланасың, шалкан колак! — диде кыз, беләктән чеметеп. — Авыл ирләренең һәркайсы хатыннарыннан көнләшә. Синең атаң да шундый.

— Юк, безнең эти көнләшми, — диде малай.

— Синең анаң ир тапканны ашап өйдә генә утыра, ә минем әни хат ташучы! Ул гел кеше арасында!

— Өйдә утырса ни! Безнең әти әнине бер дә нахак сүз белән талкымый, — дип бәхәсләште Нурихан. — Кыз-катын фәрештәгә тиң зат, дия әти. Мин дә катынымны рәнҗетмәячәкмен.

— Хәчтерүш! Сиңа дигән хатыннар тумыйча үлгән, ди. Сикеренмә, яме, син ялгыз муртаясың.

Нәкъ өстенә баскан икән Шәрифә. Менә ул бозлы тәрәзәне сулышы белән өретеп күләдер сыман:

— Язмышыңны дөрес юрадым, әйеме, хәчтерүш!

Тик Нурихан малай чактагы кебек авызын турсайтмый, бүген аның да җавабы әзер:

— Минем язмыш — син, Шәрифә. Ә муртаюга килгәндә, ялгыштың, бездә аллы-артлы дүрт аю асып йөрерлек көч-гайрәт бар.

Кулда көрәк уйный, һавада кар бураны оча иде. Нурихан эчтән генә хатынга боерды: «Өеңдә кун, Озын толым! Өеңдә кун!»

Күкрәккә төелгән сулышын иркенәйтергә дип билен турайткач, ул тагын бозлы ятим тәрәзәләргә бакты. Тупас иде Билалетдин абзый. Табигать белән аралашкан урманчының югыйсә күңеле дә, хисләре дә кылдай нечкә булырга тиеш иде. Матурлык белән өртергә тиеш иде аны Ходай. Икенче тапкыр

үсмер егет үз «өлешен» татыды. Билалетдин, урам яңгыратып кызын сүккәндә, Нуриханның да тетмәсен теткән иде.

— Кем өчен бизәнәсең, сыгылмалы көянтә? Уеннан Миннехан көчеге озатамыни? Ул малай — атасы сыңары: кыз-катынга хирыс. Тик аңа катынның сәләмәсе дә тәтемәячәк. Чөнки алар нәселе белән җүләр, гыйшык-мыйшык дип күзләре сукырая. Сукыр ул кайчандыр тигез җирдә дә бер абына.

«Һай-һай!» дип, өскә болытлар ишелеп төшәрлек итеп кычкырасы килде. Билалетдин урманчы әллә күрәзәче иде, әллә кыек атып туры тидерде: Нуриханга хатыннарның «сәләмәсе» дә тәтемәде. Ул, чынлап та, сукырайган, Шәрифә-элпә аның күзен каплаган иде.

Кар тавын як-якка ярып, ир капкадан үтте.

— Билалетдинның бит ишегалдына арык сыер да сыймый, өч ат ятып аунамагач, ниемә ди уч төбе хәтле ишегалды? Күңел тарлыгының билгесе инде, — дия иде әтисе.

Көри-көри баскычка җитте Нурихан. Ишеккә бөкре агач терәү генә хуҗа иде. Теге елларда ул шушы өйгә керергә күпме хыялланды. Шәрифәнең нинди караватта йоклаганын күрәсе килә иде. Кызлар матур йоклыйдыр ул... Толымнарын мендәргә таратып саладыр...

Нурихан тук-тук ишек шакылдатты:

— Ни хәлләрдә сез? Рөхсәтме?

Җәйне хәтерләтеп мәтрүшкә, бөтнек исләре аңкыды: өйалды диварындагы кадакларга бәйләм-бәйләм дару үләннәре эленгән иде. Ике пар ката, Шәрифәнең йомшак тәпиләрен сагынып, бусага кырыенда «яшь түгә». Урта ишекне дә ачты Нурихан. Ләкин дым тарткан бүлмәдән балачакта күрергә тилмергән караватны эзләмәде. Түрдә, усал күзләре белән үтәли тишеп, Билалетдин абзый карап утырадыр кебек иде. Ул, аралыкка ташланган бер кочак каен утынын мичкә тутырып, шырпы сызды. Аннан ишегалдына чыкты, морҗадан сузылган сыек төтенне карашы белән болытларга табан кугач, кереп, янә мичкә өстәде. Шәрифә җылы өендә йоклар... Кызык та соң син, әй язмыш! Касәңдәге мөлдерәмә суны йотлыктыра-йотлыктыра тамчысына кадәр эчертеп бетермичә туктамыйсың. Аның әчесеннән бәгырь көя, ә сиңа барыбер, синдә кызгану юк...

Шылдырап күмер төште, мич ябылгычлары томаланды. Инде тәрәзәләр елый-елый бозлы күзен юар... Эшен төгәлләгән Нуриханга ямансу иде. Кайтып ата мылтыгын чистарту да коткармады. Шәрифә аңардан юри кача... Бу качышлы уеннарының ахыры-азагы бар микән?

Урамнан кемдер:

— Нурихан! — дип кычкырды.

Ир, аягына да кимичә, оекчан гына ишегалдына чыкты. Башыннан шәле шуган Шәрифә капкага сөялгән, үзе еш-еш сулый иде.

— Мине... мине тагын куды... Шул ук бүре... Маңгаенда йоны күперенке. Авыл башында Гарәфетдин карт сәнәк белән араламаса... Чәйни иде... Качты урманга... Сул урманга... Аларның өннәре шунда, ди... Син безне ник якламыйсың, Нурихан? Син бит аучы малае...

Суыкта да ирнең чигәсенә тир бәрде.

— Ялгыз йөрмә, дидем бит, Шәрифә...

— Миңа хәзер сакчы ялларгамыни?!

— Тынычлан, Шәрифә...

— Сиңа рәхәт, алар сиңа тими. Безнең кебек көчсез хатыннарга гына ташлана. Гайнан тәүбәләде, бүтән эчмим, ди. Әйдә, үзәккә күчик, ди. Мин ирем белән кушылам...

Нуриханның йөрәген үткен хәнҗәр белән мең кисәккә тураклады хатын.

— Бар, өең җылы, мичең кайнар, — диде ул, башын аска игән килеш. Күтәрелеп Шәрифәгә карамады. Чөнки йөзе газап белән җыерылган иде. Касәнең соңгы тамчысы агу иде бугай, агу иде...

...Аның мылтык асып уңъяк урманга юнәлгәнен авыл күрмәде. Наратлыкка караңгылык иңгән, күктәге ай гына, утырмага җыенган көяз кызлардай, битенә кершән буяган иде. Нишләде бу табигать, ә? Илдәге тәртипсезлек бүреләргә дә мәгълүм, ахрысы. Тәмам аздылар. Элек ерткычларның эзе дә бәләкәй генә иде, ә хәзер бүрек хәтле, эре-эре. Кичер, ата! Нурихан синең васыятеңне үтәмәде. Аңла син, ата, аңла! Яраткан кешесе дүрт тапкыр бүре азыгы була язды, моңа ничек Нурихан битараф калсын ди! Аның Шәрифәсенә җил дә саксыз кагылырга тиеш түгел! «Аның Шәрифәсе»? Аныкымы соң ул?! Китсәң кит инде, Озын толым...

...Каршыда бүре улады. Тавышы җырчыныкы кебек бер көчәя, бер әкренәя иде. Ялгыз... Ялгызлык шулай күкрәкне яндыра. Нурихан да, учы белән авызын каплап, шундый ук сагыш, шундый ук чарасызлык белән улады. Иш ишен ерактан ук сизә: ерткыч та аңа җавап кайтарды. Ир юан имән артына посты. Кар өстендә кара шәүлә — бүре шәүләсе. Яланкул аласы булыр...

## 7

Ә яшәү чылбыры әкрен генә бала белән тоташа иде. Баксаң, Нурихан туганнан бирле икенче бер җан иясе өчен яшәгән. Атасы үлгәч калага китүләр, буйдак тормыш, кире авыл туфрагына аяк басулар,

хәтта Шәрифәнең яшьтән үк өнәмәүләре гел малай файдасына икән. Хәзер алар икәү: чәче чаларган ир һәм «әттә» дип тәтелдәгән Мирзабәк.

— Улың тач син, — дип сөендерә картлар. — Бу җегет нәселегезгә асыл өстәмә.

Яңаклары суырылып эчкә баткан малай, үсеп-тазарып, буй калкытты. Нурихан килгән саен, карт белән карчык исәп-хисап тоталар иде:

— Кашык белән ашый...

— Эт кебек шыңшымый...

— Мунча ярата...

— Аш түгелсә, күлмәген юдырта...

— Рәсемле китаплар «укый»...

— Телевизордан әкиятләр карый...

— «Әттә» сүзен еш әйтә...

— Сине сагына, Нурихан...

Сагынадыр, ул бит аның этисе. Кыш үз җырын җырлады, алда сандугачлары белән яз моңлана. Малайны өйгә алып кайтырга вакыт. Быел Нурихан алмагач үсентеләрен Йосыф аланына утыртты. Ике ир-ат — берсе озын, берсе кыска — бакчада кайнашырлар. Әйе, алып кайтырга вакыт. Шәрифә дип очына-очына яралы канатларны җилписе түгел инде. Ул ире белән үзәктә көн итә. Ә авыл халкы иң биек таудан гайбәт чанасына утырып шусын! Аңа кемнән куркасы әле. «Бүреләр урлаган малай» Сафринәнең исендә дә юк. Сәрхуш хатын Мирзабәкне күргән очракта да танымас иде. Ә Нурихан, аталап, аны Сафринә белән мәңге күрештермәячәк. Ходай да иргә булыша: хатын менә-менә үзәккә күченәчәк, ди. Димәк, чуалган төен үзеннән-үзе чишелә. Әгәр сәрхуш түти баланы әз-мәз төсмерләп шик белдерә икән, зарар юк. Авылда аракы колының «авышкан» дигән аты-чаты бар. Аңа беркем ышанмаячак.

Уйларына чумган ир Сафринәнең бүрәнә өстенә килеп утырганын сизмичә калды.

— Кем белән сөйләшәсең, иркәм? Иреннәрең кыймылдый, — диде хатын, күлмәк итәген тезенә кадәр сыпырып.

— Үзем белән, — диде Нурихан.

— Менәтерәк мәзәк! Нишләп алай, иркәм?

— Акыллы кеше белән сөйләшүе рәхәт.

Сафринә тешсез авызын ерып кеткелдәде:

— Җенләнмәгәнсең икән әле, иркәм.

— Итәгеңне төшер, Сафринә. Синең җүн тауар кызыксындырмый.

— И, тәүфыйклы песи дә инде син, иркәм. Сиңа зарланыйм дим бераз, иркәм. Авылда мине санламыйлар, минем белән беркем дә исәнләшми. Рәхмәт, син, йөзеңне чытып булса да, бер-ике кәлимә әйтәсең.

— Кайчан күченәсең, Сафринә?

— Бригат Фазыл, иртәгә дә иртәгә, дия. Әйберләремне җыйдым, көтәм мона, иркәм. Ул үзәккә аягым да тартмый мона.

Сәрхуш ни сабын, ни тарак күрмичә майланып укмашкан сары чәчен бармаклары белән аралады.

— Ирексез баштан кучмә, — диде ир, сүз юктан сүз ясап. Һай, киңәшен теш арасында гына кысып калдырса икән!

— Үзәктән Орловка якын шул, иркәм. Анда минем чын дуслар, иркәм. Питыр, Лексей, Машалар анда. Нишләптер, ул аулда чиркәү чаңы какканда, күңелем тулып җылыйм мин, иркәм. Үксепләр-үксепләр җылыйм. Татар башым белән, иркәм! — дип мышкылдаган хатын, үзенең маржа икәнен искәртеп, Нуриханның баш түбәсенә чүкеч белән кыйный иде. — Син, иркәм, көлмә, яме! Абау, чыраең караңгыланды! Миннән җирәнәсең, ахры, иркәм? Тәки миңа күз атмадың, җегет. Ә мин сине өзелепләр сөйдем. Хәзер дә сөям, иркәм. Мона син настояшный ир хет. Буй дисәң — буй, көч дисәң — көч. Кочагыма каен утыннары ягып иркәләр идем. Хәтерлисеңме, теге төндә без...

Нуриханның ачудан муен тамырлары чатнады.

— Авызыңны яп! — диде ул. — Авызыңны яп!

— Ярар, ярар, иркәм. — Сафринә читкәрәк этелде. — Син бүтәнне сөйдең шул. Әле ишеттеңме соң, Шәрфә Наратлыкта ич. Ире белән тынышмаганнар, ди. И ызбасын чистарта, и чистарта. Гайнанга ул наз күрсәтмәде, шуңа ире эчте дә аның. Җә, иркәм, бригат Фазыл килмәде микән?

Нурихан бу яңалыкка исе китмәгән кыяфәт чыгарды. Кыштан бирле ул Шәрифә белән күрешмәгән иде. Эрегән тәрәзәләр тагын бозланды, капка төбен тагын кар күмде. Йөрәктә дә боз дәрьясы иде. Ичмасам, өзеп-кисеп: «Мин сине яратмыйм», — дисә икән!

Йөздә — ис китмәү, ә күңелдә өермә иде. Менә ул Нуриханны бөтереп алды да күкләргә кадәр очырды. Ә болытлар йом-йомшак. Шәрифә куллары шикелле бугай... Озын толымның аны беркайчан да иркәләп сыйпаганы юк... Ире белән тынышмаган алайса.

...Йосыф аланында кодрәт Шәрифә белән кабат очраштырды. Сукмак тар, бер-береңә бәрелмәс өчен, кемдер юл бирергә тиеш. Нурихан җитди, ә Озын толым елмая...

— Нихәл, Нурихан?
— Аллага шөкер, — диде ир.
— Алма бакчаң бигрәк матур...
Акыл «оныт» дип язган карарны йөрәк бер минут эчендә аркылы-торкылы сызды.
— Урманда нишләп йөреш, Шәрифә?
Хатын кулындагы бәләкәй киндер капчыгына ымлады:
— Минем шул инде, дару үләннәре. Май ахырында барча үлән дәва, дияр иде әбекәй.
— Кая, миңа дигәне юкмы?
— Сиңа нәрсәдән кирәк соң? Кай төшең авырта?
— Миңамы? — Нурихан бармагын күкрәгенә табан бөкте. — Йөрәк минем...
— Духтырлар сәбәбен әйттеләрме соң?
— Алар белми. Яратуны бастыра торган хикмәтле үлән кирәк миңа...
Каушаган Шәрифә капчык бавын бер чиште, бер бәйләде.
— Син нәрсә, Нурихан... Андый үлән дөньясында юк. Мин дә... мин дә синең сыман ышанган идем. Сафринә тилебәрән орлыгы ашаткан иде. Бездәрә ул, яратуны бетерә, дип. Син мине, ярым үле хәлемдә күтәреп, Фәсыйлә әбиләргә чапкансың...
Ир хатынның дерелдәгән иңнәреннән кочты.
— Йә, кемнән бизмәкче идең инде син?
Озын толым ике арага капчыгын кыстырды:
— Артык якынаясың, Нурихан.
— Бүре түгел, тешләмәм, Шәрифә.
— Бүре дигәннән, аларны тәки урманнан кудың син. Алланың рәхмәте яусын!
Шәрифә шома гына баягы сораудан кача иде.
— Җә, җавап бир, киребеткән.
— Зинһар, җөдәтмә, Нурихан! Синнән, бик төпченсәң, синнән!
— Нигә, Шәрифә?
Хатынның йөзе боекты.
— Кем белгән аны... Сиңа гел киреләнәсем килеп тора иде. Сафринә миннән чибәррәк, ул тутырган тавык төсле тулы гәүдәле, ә мин ябык чебеш идем. Янәсе, ник әле син миңа кызыгасың.
— Йөрәк эше бит бу, Шәрифә! Минем өчен авылда иң чибәр кыз син идең.
— Аннары... аннары әти дә гел каршы иде. Солтанбәк кавемен җир йотсын, дия иде.
— Алай икән...
— Язмыштан узмыш юк, Нурихан. Безнең сәгать сукмагандыр. Иртәгә кил... Кичкырын кил. Яшь карлыган яфрагы белән чәй эчәрбез.
— Киләбез, — диде Нурихан, һич кыстатмыйча. Ул күкрәгенә терәлгән капчыкны алмакчы булды, әмма Шәрифә аны кысып тоткан иде. — Шәт, чәй белән генә чикләнмәбез, ә? Мин бит буш китмәм, бирнәләреңне әзерләп куй.
Әллә моңарчы урман телсез-моңсыз иде микән, һәр агачның һәр ботагында тирбәлеп кошлар сайрый башлады. Юк, кошлар гына түгел, күңел җырлый иде. Ә ир-ат күңелендәге җыру бөтенләй үзгә ул!
Шәрифә куаклар эченә кереп күмелгәнче урыныннан селкенмәде Нурихан, аны күз нурлары белән коендырып, иркәләп-сөеп озатып җибәрде. «Иртәгә кичкырын кил...» Мәхәббәтнең башы, азагы юк. Алар һаман бер-берсен ярата. «Иртәгә кичкырын кил...» — «Киләбез». Нурихан ике ир-егет исеменнән вәгъдә бирде. Дулкынланган хатын, мөгаен, «без»неңниләр аңлатканын уена да китермәгәндер. Ихлас яратса, берьюлы икесенә дә наз-җылысын өләшер. Яратмаса?.. Көндәш — әрем әчесе, ә көндәш баласы — икеләтә әрем әчесе, диләр. Шәрифәдә сабырлык һәм миһербанлык ни чамадыр бит.
Тыкрыктагы бүрәнәләр өеменә тагын Сафринә менеп кунаклаган иде.
— Зарыгып-зарыгып сине көтәм, иркәм, — диде ул, мутланып. — Күзләрем талды мона.
— Ни йомыш, Сафринә?
— Иртәгә тучны апкитә Фазыл.
— Хуп, — диде Нурихан, туктамыйча гына.
Бу хатынның җанында ниндидер астыртын мәкер бөреләнә кебек иде.
— Кабаланма, чү, иркәм! — Хатын туп төсле аның алдына сикерде. — Кабаланма, мин сиңа теге серне тишәм. Китә-нитә калсам, ишет мона.
— Нинди сер?! Башымны әйләндермә, Сафринә.
— Тишек сер, иркәм! Әйдә ызбаңа. — Сәрхуш аның беләгенә сарылды. — Әйдә, иркәм. Аерылышу хөрмәтенә соңгы тапкыр назларымын үзеңне. Аһ, иркәм, никләр сөймәдең син мине?
— Узынма, — диде Нурихан. — Ачуымны китерсәң...
— Нишләтерсең, иркәм? Сөякләремне шыгырдатып бер кочакларсыңмы? — дип ыржайды Сафринә. — Сукмыйсың син. Сезнекеләр кыз-катынга йомшак халык. Шуңа бәхетсез дә сезнекеләр. Мона син Шәрфәгә өйләнә алмыйсың. Шулай дигән идемме элгәрерәк? Исеңдәме? Бу сер мәрхүмә әбекәй бе-

лән миндә генә. Әбекәй, берәүгә дә әйтмә, итуса, сине Миннеханның малае атып үтерә, диде үлгәндә. Атасың, пычагым!

Салмыш хатын егылмас өчен бүрәнә башына таянды.

— Тыңла, иркәм. Борын-борын заманда, кәҗә команда, сарык... әй, экият түгел бит әле, кызганыч бәян. Кыскасы, иркәм, моннан фәлән-фәлән еллар элек, әле дөнҗада син дә юк, мин дә юк, Наратлык урманында егет белән кыз төн куна. Безнең әбекәй иртүк каен себеркесе кисәргә бара да күрә боларның кочаклашып имән төбендә йоклаганын. Әбекәй инде ах та вах. Җегет, билгеле, кайнар, әбекәйнең чигәсенә мылтык тери. Әгәр дә мәгәр авылда кыңгырау шылтыратсаң, бүре урынына атып дөмектерәм, ди. Әбекәй, авызыма йозак салам, дип ант итә. Озакламый кыз икенче җегеткә кияүгә чыга. Урман пәриләренең исемнәрен әйтимме? Җегет — синең атаң, кыз — Шәрифәнең анасы.

Хатын-кыз гайбәтен тыңлап торган ир чүпрәк инде ул. Билалетдин абзый хатыныннан кара көнләшү белән көнләшә иде. Имәндә икән чикләвек! Ләкин үпкән-кочкан — җилгә очкан. Яшь чакта кем кемгә гыйшык тотмас.

— Тукта, мыскыллап елмайма, сернең төбе бик тирән, иркәм. Кыз иренә көмәне белән килә. Урмандагы кыеш-мыешлар эзсез узмый. Кыскасы, шул, иркәм: Шәрифә — Миннехан кызы! Шәрифә — синең апаң! Сез — туганнар!

## 8

Ишегалдына кибәргә дип тараткан ике олау чи утынны ярды да ярды ул. Эңгердә күз бәйләнеп, Нурихан кая сукканын, нәрсәгә тидергәнен дә тоймады: балта әллә түмәргә, әллә агачка эләгә иде. Аннан атасы кебек махра төрде дә күз яшен әче төтенгә кушып тартып җибәрде. Әйтәм аны, язмыш гел кирегә сукалады... Әйтәм аны, этеп-төртеп бер-берсеннән ерагайтты. Ул аңа апа, димәк. Сафринәнең әбисе күрше-күлән белән дә аралашмаган төмсә карчык иде. «Атам!» дип өркетмәсәң дә, ул дөньяга гайбәт орлыгы чәчмәс иде. Ник бүтән кеше юлыкмаган аларга урманда?! Авыл шаулар-шаулар да тынар иде. Аның каруы бүген җан газаплары кичермәс иде Нурихан. Көтелмәгәндә табылган малай, көтелмәгәндә табылган кыз туган... Тик күңел ышанып бетми. Әйе, әйе, язмыш аларны бергә бәйләмәс өчен нинди генә киртәләр кормады. Шуннан чыгып та бу хәлләр дөрес дип нәтиҗә ясарга мөмкин. Ходай аларны бу тиклем җәзаларга тиеш түгел иде. Шәрифә бу сызлавыкка ничек чыдар менә. Әллә аңа болар күптән мәгълүм микән? Ана белән кызның серләре килешә. Әнисе бер ачылмаса, бер ачылыр иде. Мәче белән эт туганлыгы гына түгел бит. Алар кеше, аларның аталары уртак! Юк, Озын толым да билгесезлек белән каймалангандыр. Ул мондый утны эчендә йомып сакламас, мәхәббәттән шашкан ирне әллә кайчан оялтып, үзеннән биздерер иде.

Ир, этисе кебек, төпчеген учына басып сүндерде дә төрлесе төрле якка сибелгән пүләннәр өстеннән атлады. Ишегалдына чи утын исе таралды. Ачык капканы ябаргамы икән дип икеләнде ул. Япмаса, аның кая барасы мәгълүм иде. Япса, төнката уйлап баш катачак.

Нурихан җимерек коймалар буйлап кына Шәрифәләр урамына төште. Авыл тып-тын иде. Кершән яккан ай тәмам тулышкан, йөзе белән болыт читенә бәрелеп, урталай ярылыр төсле. Ирнең дә йөрәге әлеге борчулардан вак-вак кисәкләргә теткәләнер сыман.

Шәрифәнең тәрәзәсендә ут сүнмәгән иде. «Нихәл, апа?» — дип кил дә кер, әйдә! Юк, юк, күңел аны туганым дип кабул итәргә теләми, Озын толым аңа яр буларак кирәк иде. Нурихан җансыз багана кебек сураеп торды. Соңлап ишетелгән гайбәт кычытканнан да хәтәррәк чага икән. Шаһитларның барысы да гүр иясе. Кемнән сорыйсы хәзер... Кинәт ирнең күз аллары яктырды. Фәсыйлә карчык исән ләбаса! Бөтен авыл хатынын бәбиләткән кендек әбисе чыш-пышларны ишетмичә каламыни? Туганнар икән, нәсел тамгасы Шәрифәдә дә булырга тиеш.

Тавыклар белән бергә йокларга яткан карчык сукрана-сукрана ишек келәсен ычкындырды:

— Кайсыгыз мине бимазалый? Кайсыгызның вакытлы-вакытсыз тулгагы башланды?

— Ачуланма инде, Фәсыйлә әби. Бу мин — Нурихан.

— Җәйге төн ярты сүәм, таң атканны көтәргә тәкатең корыдымыни, олан? Аулда үлем-китем юктыр ла.

— Бар шул, — диде ир, баскычка чыккан кортканың иңенә костюмын ябып. — Туңма тагы, әбекәй. Монда гына утырып сөйләшик.

— Мине онытып Газраил кемне бәхетле итте, олан?

— Шаярттым гына, Фәсыйлә әби. Мин менә үлдем... Өрәк мин, валлаһи.

Карчык сөякле бармаклары белән аның битен капшады:

— Өрәкнең җисми гәүдәсе юк, олан. Җаның үлгәндер синең. Үлмәсә, моңарчы үләнер иең.

— Сиңа салкын түгелме, Фәсыйлә әби?

— Кәчтүмең җылыта кана. Тәү кат күрешкәндә, мәрхүм Салихҗан бабаң да җилкәмә бишмәтен салган ие. Май ае ие, шомырт салкыннары җелекне катыра ие. Бишмәт иске, сиңайтим, уң җиңендә ямау да күкрәк турысында ямау. Әнкәсе типчегән, эре генә инә белән. «Беренче эсбидәнҗе бу безнең, Фә-

сыйлә», — дия Салихҗан. Нәстә соң ул эсбидәнҗе, дип сорарга кыймадым, олан. Бабаң грамыт кеше, Герман сугышларыннан кайткан ие.

«Моның хәтере сокланырлык бит! — дип сөенде Нурихан. — Ул теге хәлләрне онытмаган, валлаһи».

— Кыһым, Фәсыйлә әби. Ниме соң... Син байтак балаларны дөньяга китерткәнсең. Ниме... һәммәсен дә хәтерлисеңдер, әйеме?

— Һи, дивана! Минем баш иләк мәллә сезгә! Мисалга, син тугач та еламадың. Таза иең чөнкәй. Сулышың кысылган ие. Әнкәң салам кибәне күек йөрде синең. Солтанбәк нәселе гәүдәле халык. Арт чүмечеңә берне чәпелдәткәч кенә тавыш куптардың, эһе.

Карчык берәм-берәм сабыйларының исемнәрен санады. Тик Шәрифә турында гына ләм-мим. Әйтерсең Нуриханның сабырлыгы төкәнгәнен көтә. Ә ир, чынлап та, төн карасын ертып кычкырырга әзер: «Шәрифә нинди иде?!»

— Син, олан, нигәдер борчулы, — диде кендек әбисе. — Җә, йомышың ни?

Нурихан күкрәк тутырып салкын һава сулады.

— Шәрифәнең анасы белән безнең әти яратышкан, ди. Шул дөресме, Фәсыйлә әби?

— Берсенең җегет, берсенең кыз чаклары, моның нәстәсе гаҗәп, — диде карчык.

— Гаҗәп кенә түгел, адәм хуры, алар урманда бергә йоклаган, Фәсыйлә әби!

— Алладан курык, нахак сүз сөйләмә, олан. Шәрифәнең анасы ятимә иде. Ирләр белән тиң печән чапты, ирләр белән тиң урман кисте. Агач аударганда, аягы имгәнә балакаемның, төнлә аны ярый ла аучы Миннехан очрата. Иртән ат табып авылга кайтарды ул Шәрифәне. Минем кулыма тапшырды, Фәсыйлә астай, сауыктыр, зинһар, дип. Кайсы явызы сине гүрдәге атаңа каршы өстерә, олан?

— Кешеләр сөйли бит, — дип акланды Нурихан.

— Һы, кешеләр, янәмәсе! Урмандагылар Гөлбикәгә генә мәгълүм иде. Кара син, телен аркылы тешләмәгән кана, кемгәдер гайбәтен чәчкән. Кара син!

Нурихан барыбер тынычланмады. Карчыкның дәлилләре артык беркатлы иде. Яшьләрнең ничек төн уздырганына урман гына шаһит, шуңа күрә дә шик таралмый иде.

— Син... син Шәрифәнең дә кендек әбисе бит инде, Фәсыйлә әби?

— Булдым ди аныкы да. Шуннан ни, олан?

— Аңарда безнең тамганы шәйләмәдеңме соң?

— Билалетдин кызына каян килсен ул?! Солтанбәк нәселенә ни катышы бар аның? Бур Гарифҗан тамырының җепселе кана алар.

Ир шатлыгыннан сикереп тормакчы иде, кортка сул колагыннан умырып тотты:

— Менәтерәк Сафринә малаенда ул тамга ба-ар. Нәкъ синеке күек тамга-а. Җүнсез! Ник миннән Мирзабәкне яшерәсең? Синең углан кана ул. Теге кичтә ызбаңда бала исе ие. Картайсам да, минем борын тоя, олан. Күрше авылдагы атаң дусларында асрыйсың бәбкәчемне. Фәсыйлә белмәгән сер юк Наратлыкта!

— Катырак тарт, әби, катырак тарт! — диде Нурихан, көлеп.

— Мирзабәкне читләрдә тилмертмә, апкайт, җүнле җүнсез! — диде карчык.

...Шәрифәнең тәрәзәләре дөм караңгы иде инде. Күңеле белән ир ызбага үтеп, хатынның мамык юрганын рәтләде: «Өшемә, бәгырь кисәк!» Күңеле белән аның колагына гомер буе эчендә йотып сакланган сүзләрен пышылдады: «Мин сине яраттым, Озын толым...» Икенче бүлмәдә тагын берәү бар иде. Өченче кеше иде ул. Нурихан күңеле белән аны да йоклатырга урын эзләде. Чит балага, җитмәсә, көндәш баласына Шәрифәдә тар булмас микән? Булмастыр, булмастыр, малай Нуриханның ярты өлеше бит. Их, аныкы гына шул. Ә Озын толым өчен Мирзабәк чаттагы җиденче багана иде.

Авыр сулады ир. Баягы шатлык-сөенеч язгы кар кебек эреп акты. Шәрифә һәм Мирзабәк... Кайсысын сайлыйсың, дисәләр, җавап юк, чөнки икесе дә йөрәккә якын.

Тыкрык башында ул Фазыл белән очрашты. Атка атланган бригадир, сызгыра-сызгыра, Сафринәләр очыннан менеп килә иде.

— О-о, Нурихан абый! Әллә син каравылдамы? Наратлыкны күтәреп китмәсеннәр дисең бугай.

— Син дә безгә ешладың, энем.

— Сафринә түтәйнең туганын озатыштым.

— Нинди туганын?

— Сакаллы абзый шунда. Наратлыкка юл кая, дигәч, илтеп үк куйдым инде. Әйдә, бездән булсын изгелек! Иртәгә ат җибәртермен, күчәсең, җыен, дип калдырдым түтигә.

— Нишләп... нишләп йөри туганы?

— Алла белсен! Урыс, ахры, ул кеше. Татарча аңламый да. Сүзгә дә бик саран. Сафринәгез күченсә, мужыт, бүтәннәр дә кымшаныр, ә, Нурихан абый?

Көтелмәгән «туган» Нуриханның бөтен халәтен биләгән иде, ул, тукран сыман, һаман үз агачының кайрысын тукыды:

— Туганны кем чакырган икән?

— Зимагур Шакир исәндер, картаймыш көннәрендә үги кызы исенә төшкәндер.

Ирнең йөрәк турысында кан оешты. Һай бу язмыш! Кәкрәйгән ботакны турайтам дигәндә генә шартлап сына. «Туган» Сафринә ышанган әкияткә төкерәчәк. «Туган» баланы ике аяклылар арасыннан эзләттерәчәк. Кайтуының максаты да шул! «Качам, — диде ул, — Мирзабәкне кыстырам да җир читенә үк олагам!»

Бу уе күңеленә берегеп, ныгып та өлгермәде, икенчесе баш калкытты: «Ә Шәрифә сылу нишли?»

— Күзне йокы әчеттерә. Хуш, абый, — диде Фазыл.

Нурихан ат тезгененә ябышты:

— Сиңа бер сорау барые, энем. Әз генә сабыр ит. Аерган хатыннарыңдагы балаларың җәлме?

— Хи-хи, көлдермә, Нурихан абый. Аларны кем үстерсә дә, миңа барыбер.

— Ә нәсел тамыры? — дип бәйләнде Нурихан.

— Сафсата! — диде бригадир. — Кем кем белән йокламаган да, кем кем белән чуалмаган, эзлә син шуннан үз нәселең тамырын!

— Ялгышасың, энем.

— Минем үз фәлсәфәм, Нурихан абый.

— Алай икән...

Ә менә аңа Мирзабәкне кем үстерсә дә барыбер түгел шул. Малай аныкы, аның дәвамы! Солтанбәк нәселе ирләре күке булмады һәм булмаячак та.

Таңны ул этә-төртә көчкә аттырды. Ат җигәм дип абзарга керсә — аран буш иде. Малкай тау битендә утлыйдыр. Анда үлән куе һәм сусыл. Ир, йөгәнен беләгенә элеп, шунда китте. Кояш нуры тауга чәчелгән, күз камаша. Нуриханның әллә акылы зәгыйфьләнгән, әллә күзенә күренә: сукмактан, иңнәрендә пар чиләкләрен җырлатып, Шәрифә килә иде. Нурихан, саташам дип, чытырдатып күзләрен йомды. Ачты... Ә хатын һаман килә дә килә иде... Ул әнә аңа карап көлемсерәгән, аптырамый.

Өч-дүрт адым кала икесе дә туктадылар.

— Пәри кызы микән соң, дим?

— Һи, Нурихан, җен-пәри әтәчләр кычкыргач йөрми ич инде, — диде Шәрифә, кызарып. Бит очлары алсуланган хатын дөньяның бер чибәре иде.

— Чиләкләрең авыр, бир миңа, Шәрифә.

— Әй лә! — Шәрифә ярты сүәм читкә тайпылды. — Үтәсеңме?

— Юк, сукмак тар, сыймам.

— Әй лә, таза Мортаза!

— Коең саекты мәллә? Ерактан су ташыйсың?

— Бу чишмә суы, Нурихан. Болганып куерганчы йөгердем әле.

— Кем болгатыр икән тау чишмәсен? — диде ир.

— Сандугачлар коена анда, — диде хатын. Аның кәефе әйбәт иде. Их, ничәдер сәгатьтән ул Нуриханның саубуллашмыйча гына авылдан табан ялтыратачагын белсә икән!

— Чишмә суы тәмледер, — диде ир, ничек тә җебемәскә тырышып. Төнлә Нурихан «йә Шәрифә, йә Мирзабәк» дип сайлый-сайлый бербөтен булып йөрәк түренә урнашкан ике кадерле кешесенең кайсына да өстенлек бирә алмады. Озын толымны ярату хисе белән улын ярату хисе тигезләшкән иде. Ичмасам, берсе инә очы кадәр генә ким үлчәнсә икән! Ахырдан ул шобага тотты: өстә Мирзабәк иде...

— Тәмле, зерә тәмле, Нурихан. Чәйгә дип апкайтам әле. Бүген кич сине көтәм мин, Нурихан... Килерсең бит?

Ир, тезләнеп, хатынның уң чиләгеннән чишмә суы капты. Яшьлектәге хыялларның чынга ашар көннәре дә бар икән... Наратлык кызлары тау сукмагында «ялгыш» очраган егетләргә су эчертә иде. И көнләшә иде шулардан Нурихан. Аның да Шәрифәнең тылсымлы чиләкләренә иренен тидерәсе килә иде. Ә тәкәббер кызның талканы коры: әз генә якынлашсаң да, карашы белән утлы табада кыздыра...

Хатын уйлары белән еллар төпкеленә чумганын белми, йотылып җавап көтә: «Килерсең бит?» Ә Нурихан элекке чаклардагы кебек дөрләп кабынмый инде, аның дәшмәвеннән һәм басынкы кыяфәтеннән сизгер Шәрифә, әлбәттә, бу кичен дә, алдагы кичләрен дә ялгыз уздырачагын аңлый.

— Әй лә! Оедым тәмам, — диде Озын толым. — Атыңны эзләсәң — тау сыртында.

Сиңа ялына-ялварамы соң бу горур хатын! Ратуыннан тәгәрәп үлгәндә дә хисләрен буып тотачак бит ул. Әнә суының тамчысын да түкмичә йөгерә... Алар шулай аерылырга тиеш микәнни?!

— Шәрифә!

Хатын сөрлегеп туктады, әмма артына борылмады.

— Кичкә көт, яме? Көт! — диде ир.

— Көтәм, Нурихан җаным... — диде сулкылдаган Шәрифә. — Кил, кил...

Яратып туялмаган кешеңне газаплау гөнаһтыр ул. Нурихан үзе кичергәннәрне дошманына да теләмәс иде. Озын толым гомер буе аны тилмертеп яшәтте. Хәер, ирдә дә гаеп бар иде: ул Сафринә атлы бер ялгышы белән мәхәббәт дөньясын караллты... Шуннан соң кем сине җиңел генә гафу итәр икән... Әйе, чишмә сулары тәмледер, әйе, парлашып чәй эчүләр бәхеттер. Йә, нишлисең, Нурихан? Син Шәри-

фәгә «көт» дидең. Ә вәгъдә — иман. Улыңны да йөрәгеңнән каерып ыргыта алмыйсың: малай — ярты җаның.

«Миңа бит аларның икесе дә кирәк, — диде ир, яңа гына ачыш ясагандай. — Ник мин кадерлеләрем өчен көрәшмим әле. Сафринәнең туганы Мирзабәкне кулыңда күрә икән, чатнатып: «Бу — Солтанбәкләр оныгы», — дип әйт. Әгәр ул һаман балага дәгъва белдерә икән, мылтык теле белән сөйләш».

Нурихан мылтыгын чорма башына ук ташлаган иде. Кыекка баскыч сөяп, соңгы теләкәне менгәч, ул бер мәлгә төртелеп торды. Сафринәләр капка төбендәге җигүле ат арбасына сакаллы бер ир искемоскылар ташый. Кара, болар тавыш-тынсыз гына авылдан сыза! Йөрәгенә бала хәсрәте суккан кеше моңарчы җир астын казып төшәр иде. Туганы да Сафринә сыңары бугай. Ул очракта өн-тын чыгармау гадәти хәл. «Бүре ашаган», вәссәлам.

Күкрәкне изгән зынҗыр өзелеп, сулышлар иркенәйде. Алда куркыныч упкын юк иде инде. Кичкә табан Нурихан улын алырга барыр, һәм алар, ике ир-егет, туп-туры авылның иң чибәр кызын димләргә китәр. Ә ишегалдында яшь килен аяк басарлык түгел: утын да утын. Хуҗа җиң сызганып шуларны җыештырырга керешге. Ул үзе дә бакча карачкысы иде. Кырынмаган килеш Шәрифәгә күренде. Аның эчке дөньясында да, абынсаң, кул-аяк сынарлык тәртипсезлек иде. Нибарысы мәхәббәте генә үзгәрми, үз төсендә саклана...

## 9

...Басу капкасыннан ике кеше калыкты. Нурихан урман авызында иде, аларны еракган танымады. Кемнәр кичләтеп кенә үзәккә теркелди икән? Наратлыкта һәммәсе дә таяклы карт-коры иде. Ни чүпрәк сатучылар, ни теләнчеләр бу яклардан уратмый, авыл бит урман белән күмелгән иде. Берсе хатын-кыз, берсе ир-ат шикелле. Әллә ат каты чабулый, әллә парлылар еш-еш атлый, аралар бик тиз кыскара иде.

Дилбегәгә тотынып атны әйдәкләгән Мирзабәкне ул култык астына этәрде:

— Улым, кач, күренмә...

Башын артка чөеп атлаган хатын Сафринәгә охшаган иде. Юктыр, күз алданадыр, валлаһи! Иртән алар әйберләрен олауга төйиләр иде. Наратлыкта ике Сафринә яшәми ләбаса! Әмма сакаллы ир култыклаган хатын — Сары чәч иде шул. Нурихан юлчылар кырыеннан чаптырып узып китмәкче иде, малай шыңшыды:

— Әти-и, айгырны үзем куа-ам.

Ир каушавыннан дилбегәне кискен генә үзенә табан тартты.

Нуриханны күргәч, Сафринә:

— Атпусти, Ләксәй, — дип, ят ирнең кулын читкә селтәп атты. — Атпусти, диләр! Нурихан иркәм, — диде хатын, еламсырап. — Мин бит Наратлыктан китеп ятам. Мәңгегә бит, Нурихан иркәм. Мона бу Ләксәй минем абзый, имеш. Әнкә карчык исән, имеш.

Нуриханның бөтен хәсрәте — Мирзабәк, ул аны киң җилкәсе белән каплаган иде. Язмышның китек чит-читләрен түгәрәкләр өчен күпме чиләнде, ә, бер мизгел хәзер барысын да вак-вак кисәкләргә уачак. Кул сузымында гына — малай... Хәзер Сафринә үрелә дә ала... Йөзен сакал-мыек баскан усал Ләксәй абзый аңа ярдәмгә атыла...

Киеренкелек өстәгән тынлыкны озакка сузарга ярамый иде.

— Сез иртүк үзәккә җыендыгыз кебек иде, Сафринә.

— Әйберләрне Питырларга аткардым. Рәхәтләнсен дуслар. Мин Рязаньга ук кыяклыйм, Нурихан иркәм. Әнкә карчык үлем түшәгендә, бәхилләшергә чакыра, имеш.

— Хәерле сәфәр, — дип мыгырданды Нурихан. Тагын нәрсә дисен?! Аңа тизрәк болардан котылырга кирәк иде.

Тик хатын Рязаньга ашкынмый иде. Ул кулын бөжра ясап түгәрәкләде дә авызына куйды:

— Миндә коточкыч сер бар, иркәм. Ләксәй әйтә, ни дия Ләксәй мона, син, дия, марҗа... Ишет тә тораташ бул, әйеме? Тораташ бул! Мин — марҗа кызы, иркәм!

— Пошли, Серафима, пошли, — диде усал Ләксәй, сеңлесен җилтерәтеп.

— Бәйләнмә, — диде хатын, чинап. — Син нәстә аңлыйсың, карт сарык. Мәхәббәт кошым белән җүнләп саубуллашам мона. Ие, мин марҗа кызы, имеш, Нурихан иркәм. Соңгы тапкыр синең белән рәхәтләнеп чүкердәшик мона.

— Мин ашыгам шул, Сафринә.

— Ашыгасыңдыр, ие. Кияү егете кебек киенгәнсең-ясангансың ич. Мин бит мәңгегә югалам авылдан. Начарлык белән искә алма, җәме, Нурихан! Хуш, җанкисә-ә-әк!

— Хуш, Сафринә, — диде ир. Аңа баланы ышыклаган хәлдә атын куалап китәргә дә була, Мирзабәк тә, әтисен сатмыйм дигәндәй, шым гына аркасына терәлеп утыра иде. Ә ул басу иңрәтеп елаган хатынны кызганды. Нигәдер ялган белән калуы да җиңел түгел иде. Нурихан, арбадан төшеп, керпе сыман йомарланган малайны кулына күтәрде:

— Таныйсыңмы, Сафринә?

Хатын хәмердән тонықланган яшьле күзләрен җиң очы белән сөртте:

— Кем бәбкәче бу?

— Син... синеке, — диде ир, гәүдәсе куырылып.

Бәбәген чекерәйткән Сафринә хәзер ерткыч төсле аңа ташланачак... Карт урыс белән икәүләшеп баланы йолкыячак алар. Авызыннан хәмер исе бөркелгән хатыннан җирәнгәндәй, Мирзабәк йөзен әтисенең күкрәгенә яшерде. Юк, Нурихан үлсә дә улын ятларга бирмәячәк. Мылтык арбада, ә ул атса, бергәйле ата...

Ләкин, ни гаҗәп, Сафринәнең күзендәге битарафлык пәрдәсе ертылмады. Баядан бирле «китәбез» дип борсаланган төмсә чырайлы туганның да малайда гаме юк иде.

— Һе, шаяртырга мачтыр инде син, Нурихан. Минекен бүреләр урлады ич, — диде салмыш хатын һәм терсәк очы белән абзасының касыгына төртте: — Пашли, Ләксәй, пашли!

Нурихан, малаен күкрәгенә кыскан Нурихан, арбага кире утырмады. Әле генә тәмуг утында чытырдап янган иргә тымызык кыр җилендә суынырга кирәк иде.

Ә аяклар тыңламый, авылга таба сөйри. Анда зарыгып бәхет көтә. Әгәр соңласаң, аның капкасы гомерлеккә ябылыр сыман...

*2004*

## Сер

### 1

Соңгы тапкыр… Ишетәсеңме, соңгы тапкыр! Моннан соң ул мәңге урман төсен күрмәскә тиеш. Әйе, Гөлфия гаепле, бик гаепле, әмма бу гаепне, тау хәтле гөнаһка әйләндереп, саклап йөртерлек көч калмады. Рәнҗемә дә, үпкәләмә дә, Нияз. Төшләргә дә кереп җәфалама. Гәүдәң авырлыгыннан урталай бөгелгән яшь карама быел яфрак ярмады… Кыз биш ел буе шул ябык агачны кочаклап ыңгырашты, әрнүенә түзә алмаган чакларда, хәтта ки тырный-тырный кайрысына хәтле куптара иде. Аның тамырлары Гөлфиянең сагышыннан гына корыды бугай. Фани дөньялардан дөрес күчмичә, син дә гөнаһ кылдың, Нияз! Ахмак! Кем үз куллары белән гомер җебен кисә ди! «Ирләр җир йөзенә көрәшер өчен туа», — дип мактанган егетнең шул идеме җиңүе?! Әгәр син моны, бу кызый гомере буе сызланып яшәсен дип эшләсәң, ялгышасың: бүген ул соңгы тапкыр килде. Соңгы тапкыр!

…Гөлфия тар сукмактан кызу-кызу атлый, үзенең ялгыш юлга кергәнен дә сизә, дымсу абагалар биегәйгәннән-биегәя, күләгәдә үскән агач-куакларның зәгыйфь җете яшел яфраклары арасыннан саркыган кояш нурлары тонықланган саен тонықланып, урманга көпә-көндез төн иңә, ләкин аяклар туктамый, уй өермәсенә буйсынып бара да бара иде. Кинәт алагаем зур гәүдәле ерткыч җанвар сукмакны «бикләде». Шәл чугын аска салындырган кәрлә куак артында иде ул, авызында таш әвәлимени, тешләрен шыгырдата иде. Бу ямьсез шыгырдау, үкчәне җиргә кадаклап, бөтен гәүдәне катырды. Селкенәм дисәң, селкеттерми, артка чигенәм дисәң, аяклар ябышкан. «Минем гомер бигрәк кыска икән»,— диде кыз, коточкыч күренешне күз алдыннан уздырып. Адәм баласы күрәчәгенә каршы ашкына, дисәләр, ышанмас иде, менә ышанды… Чынлап та, хак икән: соңгы тапкыр килгән…

— Бор-рыл,— дип ырылдады «җанвар». Аңгырайган башка ул «ыр-ыр» булып ишетелде.— Бор-рыл!

— Бәрәч, син кеше затыннан түгелме соң? — Гөлфия, куркуын җиңеп, шәл чугын аралады. Куак төбенә ерткычтан да ямьсезрәк кыяфәтле бер адәм посып ята. Йөзен сакал-мыек баскан, сыңар күзе утлы күмер кебек дөрләп яна. Кыз аңа текәлде, танырга тырышты. Танымады, күргән-белгәннәр арасында сыңар күзлеләр юк иде.

— Бор-ры-ыл! — дип үкерде «җанвар», баягыдан да битәр катырак ырылдап.

— Мин бит сине тешләмим, урман шүрәлесе, бәйләнмә.— Гөлфия кырыйга тайпылган гына иде, Сыңар күз сөякле, йонлач кулын аның биленә батырды. Көчле иде ул, кызны уч төбенә генә салып, өскә күтәрде. Гөлфия кычкырмакчы иде, кабыргалары кысылып, тыны буылды. Хәзер агачка сылый!

— Тимә! — диде шул чакта кемдер. Әйтерсең урман җанланды, әйтерсең төн уртасында чәчәк атарга хыялланган йомыкый абагаларның теле ачылды. — Тимә! Хатын-кыз синең энекәшеңә нинди зыян салсын ди, Алабай. Ачуланмагыз, ханым-туташ, шундый инде безнең абзыкай, аның биләмәсендә куян да рөхсәтсез чапмаска тиеш.

Сыңар күз корбанын дык иттереп җиргә төшереп бастырды.

— Киттек, Алабай, — дип боерды теге тавыш.

Чү, тукта, бу кемнең сөйләшүен хәтерләтә соң әле? Бу бит, бу… «Күрен миңа, зинһар, күрен! Мин сине ничә ел эзләдем!» — дип әйтмәкче иде кыз, өне чыкмады, тын юлы һаман ябык иде. Ник каршысында сураеп басып тора икән урман шүрәлесе?! Гөлфия ачу белән аның корсагына төртте, корсак селкенмәде, ул таш кебек каты иде. Сыңар күз аңа акаеп кына бер карагач, тиен җитезлеге белән хуҗасы

артыннан сикерде. Ә кыз, буш капчык сыман, сукмакка ишелде. Саташты микән әллә? Юу-ук, Гөлфия үз аңында иде. Кәефе күтәрелгәндә, көйләп-җырлап, каш-күз җимерелгәндә, тавышын тимер күк чыңлатып бары тик Ул гына сөйләшә иде. «Мәрхүм» дип гомер дәфтәреннән сызганнар иде ләбаса! Гайбәт оясы Казанга ике генә сүз очырасы иде хәзер: Кеше исән! Тик шунысы сәер: нишләп Ул ниндидер хәшәрәтләр ияртеп ташландык урманда йөри икән? Салабаш урманы, чынлап та, күптән кыргыйланды. Авыл халкы таш йортларга тиенгәч, кайчандыр үзен җылыткан агачлар иленнән йөз чөерде. Мунчасын да газ белән яга, җиләген дә, кырын ятып кына, тау битләреннән чүпли иде. Балта-пычкы тими, машина, арба тәгәрмәчләре изми — чытырман. Үрмәкүч, гайрәтләнеп, урманны пәрәвез белән чуарлады. Гөлфия адаштырган сукмактагы очрашу табышмак иде. Димәк, аяклы бәндәләр эз суытмый икән. Бүретөлке аулыймы болар? Алай дисәң, ау сезоны башланырга иртә. Аңа бу якларда ни калган, йә? Дөрес, Ул Күл-Елга егете иде. Ә Күмер Таудан «аккан» яшел дәрья бер очы белән ут-күршеләргә барып тоташа. Үлгән дигәннәр иде бит…

Кыз елан сыман бөгәрләнгән серле сукмакка бармагындагы көмеш йөзеген ташлады. Йөзек, бүлтәйгән агач тамырына бәрелеп, тонык кына зеңгелдәде. Әле тагын киләселәр бар иде…

## 2

Яңгырга чыланып кайтты ул. Анда ук абагалар дым тарткан иде шул. Гел кәгазь кыштырдаган бинада тынлык, бүлмәләрнең ишеге шар ачылган, ә бүлек мөхәррирләре юк иде. Һәммәсе дә, дәррәү эшләрен ташлап, кая киттеләр икән дип гаҗәпләнеп бүлмәсенә кергән иде, маңгаена мылтык көпшәсе терәделәр.

— Әйдә аска, подвалга, иту атам! — дип әмер бирде мылтыклы.

Гөлфия салкын тимер тию белән чытырдатып күзен йомган иде, әкрен генә керфеген күтәрде. Бүген аны икенче мәртәбә үтерергә җыеналар. Күрәчәк гел алдан йөгерә икән.

— Тиле белән изгән, тиле белән баскан, ахрысы, дөньясы,— диде ул, «атам» дип янаган иргә туптуры карап. Бусы ике күзле иде, яшь иде… Чәче кыска гына кырылган. Үзенә төбәлгән кыю караштан ир әзрәк каушады: мылтыгын колак төбенә табан күчерде.

— Һы, тиле, янәмәсе! Аның каравы сез акыллылар бергә җыелган монда! Әйдә, ишләрең төркеменә кушыл. Мин бөтенегезне дә подвалга сөрдем, башлыгыгыз Казанда, ди, ул кайтканчы күселәр белән әңгәмә оештырыгыз. Аннан туңкаешып минем басуда кәбестә корты җыярсыз, яме? Язганнар гәзитләрендә көлеп! «Әюповның кәбестәсен корт ашаган, күчәннәре генә тырпаеп калган» дип, ә! Таптырам мин сездән ул кортларны, валлаһи! — дип ярсыган иргә кыз:

— Мин — баш мөхәррир Гөлфия Хантимерова, ә син кем? — диде.

— Кем, дип… Әюпов, рәис Әюпов инде без, Бәкерледән,— диде ир, нигәдер аның баягы ярсуы мизгел эчендә басылды.

— Төшер әле, Әюпов, таягыңны! Син әллә үзеңне урманда дип белдеңме? Халыкны да шулай «атам» дип куркытасыңдыр, әйеме?

Әюпов мылтыгын аска төшерде.

— Юк ла… Ялган сырлагансыз бит. Ачу чыкты шуңа. Йөк ташыган атның башына сукмыйлар бит инде. Эшлибез бит. Авылны кузгатканга өч кенә ай. Укытып ят та бит мәктәптә тыныч кына, китереп тыктылар шул йонсыз, шәрә колхозга. Киңәшмәдә хаким, гәзитәгезне һавада селки-селки: «Әюпов, сиңа «атказанган кәбестә корты» исеме бирдерттерәм, нишләп анда корткычлар үрчетәсең!» — дип мыскыллаганда, редакциягезне танк белән ишәрсең, валлаһи!

— Һәрберегез ишсә-сытса, журналист халкын каян табып җиткерерләр икән? Алар кәбестә түгел, түтәлдә үсми. Озын сүзнең кыскасы, тамагыңны ертса да, тәнкыйтьне чәйнәп йотарга кирәк, Әюпов,— диде Гөлфия, коры гына. Бу битарафлыкка ул үзе дә шаккатты. Моңарчы түрә булып кыланганы юк иде.

Рәис мылтык түтәсе белән дык-дык идән кыйнады.

— Тәнкыйть белән нахак икесе ике нәрсә, кем… Гөлфия Фәләновна апасы!

— Кем, Фәләнович Әюпов абыйсы, өч-дүрт көннән җентекләп тикшербез, зинһар, ишекне ябыгыз! Күрмисезмени, яңгырга эләктем, кипшенәм мин хәзер.

Аңа тизрәк җәнҗалчы рәистән котылырга кирәк иде. Урманнан ияреп кайткан уй күченнән аерылган бал кортлары кебек тузынган, кая төртелергә белмичә быж-быж баш кабыгында гүелдәшә иде.

— Тоз түгел, эремәссең, Гөлфия Фәләновна ханым Хантимерова,— диде рәис, дорфа гына.— Мин сине өч-дүрт көн күз күгәртеп көтәм дә, вәйт! Иртәгә таң зәрәсеннән тикшерү җибәр! Ату… кәгазь пычратучыларыңны атам, валлаһи!

— Куй инде, Әюпов, ир-ат башың белән кәбестә дип вакланма.

— Аңла, апакай бәгырь, миңа дөреслек кыйммәт. Ялганны, ир кеше булсам да, күтәрә алмыйм мин! — Әюпов көрәктән дә дәүрәк кулын Гөлфиянең борын төбендә селки башлады.

— Без эре ир заты дип, үләргә яткан бәләкәй авылда дөньякүләм проблемалар чишмәссең бит инде.

Ир тагын дөрләп кабынды.

— Авылының үз проблемасы хәттин ашкан чөнки дә! Алар бөтенесе дә вак, шуларны хәл итәм диядия, үзең дә вакланасың ул! Мин кәбестәне шәһәр базарында сатып, колхозчы ике ел күрергә тилмергән хезмәт хакын түләргә хыялланам!

— Сабыр, сабыр, Әюпов! Шәп аңлаттың, берсекөнгә көт.

— Юк, иртәгә дигәч иртәгә!

— Кәбестә кыры төтенләп янмыйдыр ич, Әюпов.

— Яна… Берсекөнгә мин өйләнәм.

— Котлыйм, Әюпов.

— Рәхмәт, Гөлфия Хантимерова.

— Килештек, Әюпов. Иртәгә таң атканда басуда күрешербез.

Рәис аңа шикләнеп карап алды.

— Нигә аптырыйсың, Әюпов? Сез генә кояш белән бергә уянмыйсыздыр ла. Киткәндә подвалдагы халыкка азатлык бир. Берүк ата күрмә!

— Ата ди. Эче тутыккан аның, болай гына тоттым, шәбәер өчен генә инде. Әлегә хуш иттек.

Шау-гөр килеп баскычтан мөхәррирләр менә башлады.

Гөлфия, ишектән башын гына тыгып:

— Сәлимә, миңа сугыл,— диде.

Хезмәткәрләр, «баш»ны күргәч, зарланырга дип, дәррәү аның бүлмәсенә ыргылмакчы иде, Гөлфия:

— Беләм, беләм,— дип туктатты.— Әйдәгез, башта эшлик, соңрак сөйләшербез.

— Белгәч, нигә милициягә шылтыратмадың? — Сәлимә түрдәге диванга җәелде.— Хәзер үк шылтырат! Кулын боргычлап, иманын үтүкләсеннәр ул бандитның! Кемне дөпелдәтмәкче диң, Сәлимә Басыйрованы, талантлы каләм иясен! Вәт дүрәк!

— Талант иясе кешеләрне карага буямый, Сәлимә. Нигә Әюповка үчләштең син? Нигә ялган яздың?

— Яздым, вәт яздым! Әзрәк тәнебез матурайсын дип, фотограф белән икәү чишенеп кояшта кызына идек, име! Ат чаптырып килде дә: «Шәрә тәнегезне ялтыратып минем җиремне мыскылламагыз, живо өстегезгә киенегез, хәшәрәтләр! Бу сезгә пляж түгел», — дип җикеренергә тотынды. Псих, үзе чыбыркы шартлата. Аның ни эше бар бездә? Ха-ха! Бабай тетмәсен тетте җыелышта. Зал тәгәрәп көлде.

— Хәзер үк гафу үтен, Сәлимә!

— Кемнән?

— Бәкерле хуҗалыгы рәисе Әюповтан. Югыйсә мин сине редакциядән куам.

Сәлимә, өстәлдәге бәләкәй түгәрәк көзгегә иелеп, чәч бөдрәләрен төзәтте. Юри вакытны суза, юри… Шулай күңелендәге агуын кырып, теленә күчерә.

— Әлә-лә, бөдрәләрем турая, име. Химия ясаттырырга, име. Беренчедән, «куам» дигән сүзеңне бүтән иләктән иләмә, безләр монда таш, безләрне трактор да кузгаталмый, безләрнең өстә…— хатын бармагы белән түшәмгә төртте,— дус түрә әфәндебез корсак симертә. Икенчедән, синең көннәрең санаулы, Бабай урыныңнан очыра, ди. Тәки яратмады сине картлач, име? Өченчедән, районда синең абруйга кырау сукты, бәгырь. Урманнарда тилереп йөрүләрең һәркемгә мәгълүм. Нияз Сафинны син генә үтергән, диләр. Дүртенчедән…

— Авызыңны яп! — диде Гөлфия, нерв җепселләренең шартлап өзелергә җитүен тоеп. Кайда соң ул моңарчы сындырмыйча саклаган әүлия-сабырлык? Соңгы вакытта кызны ташлый да китә, ташлый да китә.

—Үз авызыма үзем хуҗа, белермен кайчан ябасын!

Сәлимә, җилкәсен сикертә-сикертә, ишеккә таба атлады. Һәм бусага төбендә үкчәсе белән идәнне кыра-кыра:

— Кабинетың зерә тузган, әммә нәстә черек, төзәткәләргә кирәк, бәгырь,— диде.— Еврейремонт модада бүген. Эһем, буят, ямат, кактыр, миңа, булачак «баш»ка, калдырма тузан эше. Мин «куам» дип шапырынмам, идән юарсың. Керләнгән дөньяны агартабыз дип көчәнгән һәрбер язучы кисәгенең муенына чиләк белән чүпрәк асар идем. Юыгыз безнең шакшыны! Ха-ха! Дүртенчедән, дидем дә, әйттермәдең, чукынчык, име! Дүртенчедән, Гөлфия Хантимерова исемле классикны Язучылар берлегеннән дә типкәннәр, ди, име!

— Уф, җиз елан, синең телеңнән чәчрәгән агудан гөлләр шиңде, бакчы! — Кабул итү бүлмәсендә утырган сәркәтип Мәйсәрә пырылдамаса, Сәлимә, эчен бушатып, рәхәткә тарачак иде.

— Чык тизрәк, иту, каенсеңел димәм, чәчеңне йолкырмын. Мин синең югарыдагы ышпаналарыңнан өркемим! Ник шуны муеныңа атландырасың, кызым?

Гөлфиянең кымшанырлык та хәле юк, тиктомалдан гына баш әйләнә, бер яндыра, бер туңдыра иде.

— Мәйсәрә апа, бүлмә караңгыланды, утны кабыз әле,— диде ул, үз-үзен кочаклап.

— Чү, кызым, яп-якты ласа. Кояш күзеңне чагылдыра. Абау, син нишләп калтырыйсың, бала? Өстең лычма су икән лә! — Сәркәтип хатын кофтасын аның җилкәсенә салды.— Кая, төрен. Абау, синең тәнең пешерә ләса!

— Үтә ул, Мәйсәрә апа, үтә…

— Сәлимә генә чирләтә сине, кызым. Арын шул бәгыреңә кадалган әрсез тигәнәктән. Сиңа усалланып алу бик килешер иде.

— Минем чирем җәйге яңгыр төсле, сибәли дә китә ул, Мәйсәрә апа.

Сибәләп кенә китмәде шул, сеңдереп-сеңдереп яуды. Машинасын көчкә йөртеп, капкага килеп төртелгән Гөлфияне Мәйсәрә култыклап диярлек өйгә алып керде.

— Көндез үк кайт та ят, дидем, кызым. Харап, эш дисез дә үләсез.

— Рәхмәт, биш ел миңа җылы өеңдә урын бирдең, Мәйсәрә апа. Яхшылыгыңны ни-нәрсә белән түләрмен?

— Нинди түләү, кызым? Минем йорт Ходай ярдәме белән төзелгән. Яшә дә яшә!

…Өн белән төш арасында буталды ул. Күбәләккә әверелеп, урманга очты. Елан сыман бөгәрләнгән сукмак… Нишләп аяк астыннан шуа-а-а… Ә көмеш йөзек кош икән ләбаса! Әнә ул канатларын ничек матур җилпи… Кинәт аны Сыңар күз тәпиеннән эләктерә дә шатыр-шотыр чәйнәргә керешә. Аһ, әрәм итә, явыз! Ат шуңа, Әюпов, ат! Әй, ирләр тутыккан мылтык тотып йөримени?! Күрен әле, күрен, таныш тавыш. Гөлфия сине ничә ел эзли… Әманәт эзләттерә… Озак яуды бу яңгыр… Тәмам җебетте…

…Кыз манма су булган иде. «Туңам» дигәч, хуҗа хатын ике кат юрган япкан икән. Таң ата… Аллага шөкер, төнне исән-имин генә озатты. Дөнья хәсрәтеннән мае сызган йөрәк кайчандыр бер сүнәр инде ул.

— Сусадыңмы, кызым? Торма, ят, хәзер чәй бирәм,— диде сак йокылы Мәйсәрә.— Төнката бәргәләндең, кызым.

— Торам әле, Мәйсәрә апа. Барасы җирем бар.

— Барасы җиреңне урыныннан күчермәсләр. Ят, ят, чирле килеш ниткән йөрү ди тагы!

— Ярамый, Мәйсәрә апа. Мине басуда Әюпов көтә.

— Бабайга җиткерерләр, кызым. Беркая да борын тыкма, редакцияңдә генә утыр, дип акырган ич сиңа.

— Ул мине барыбер кудырта. Ичмасам, тагын бер кешегә изгелегем тисен: бу санда ук, фактлар расланмады дип, Әюповтан гафу үтенербез. Иртәгә аның туе икән. Безгә рәнҗеп башламасын яңа тормышын.

— Үз хатасын Сәлимә үзе төзәтсен!

— И Мәйсәрә апа, хатамыни бу?! Үч белән эшләнгән яманлык инде. Мине сорасалар, кырда димә. Хәер, эш сәгатенә кайтып өлгерәм икән әле.

— Редакциядә күренеп йөрмә, өйдә генә дәвалан, кызым.

Шофер егет капка төбендә, тончыга-тончыга, тәмәке көйрәтә иде.

— Ахык-ахык… Дүрттә тек дүрттә, Гөлфия апа. Без үрә каткан. Ахык-ахык…

— Төтенләмә, җегет, һаваны бозасың.

— И-и, Гөлфия апа, йөрәккә яткырып тартумыни?! Шул исне җен-пәри яратмый, диде дә күрше Чатан Кәриме. Ахык-ахык… Тәмсезлеге, малайгынам! Кичә машина чыгымлагач, гаражга бикләгән идем, син аны ничек кузгаттың, ә, Гөлфия апа?

— Чеметеп, тел бистәсе. Йә, син кабызасыңмы, минме?

— Кәничне, мин, Гөлфия апа. Безнең машина гасыр яшьтәше бит ул, «һайт» дип типсәң дә, гөлт итеп кабына. Татарстанның берәр музее борынгы экспонатка тилмермиме, сораштыр Казанда, Гөлфия апа. Кабынмый, киребеткән! Көненә ун сүтә, ун җыя аны Рамил, диген, тәмам таралып беткәнче алыгыз, диген, һә-һә! Без дә моңардан котылгач, шәп кенә айгыр эзләрбез. Җиктең — киттең! Бензин эчми, запчасть кирәкми, баерак калхузлардан солы китертәсең дә. Һә-һә, кабынмый, Гөлфия апа. Айгырның маңгаена «Күмер Тау районы гәзитәсе» дип язып эләсең. Койрыгына ике лампочка беркетәсең. Фара ролен үти ул, шуңар электр чыбыгы сузасың. Сора инде җүнлерәк машина гылавадан, телең өзелмәс лә, Гөлфия апа. Хакимияттәге малайларның эчеп бәрдергән арбалары да бата безгә, ямарбыз, ялгарбыз. Ура, кабынды! Шөлләде, мине музейга аткаралар, дип.

— Телең булмаса, карга күтәреп китәр иде сине, лыгырдык.

— Хатын да шулай ди. Ярый әле сыерлар очмый, ди. Чум, Гөлфия апа, пока борыны тыгылып төчкермәгәндә, әз-мәз чакрымны узыйк. Әле дә каныгамы сиңа Борчак патшасы?

— Кем, кем, тел бистәсе?

— Безнең гылаваның кушаматы Борчак патшасы бит, ишеткәнең юкмыни, Гөлфия апа? Каныгамы, дим, әле дә?

— Синең эшең — руль бору, энем. Чокырларны тигезләмә.

— Ие инде, рульне кул бора, ә авыздан телне кем бора менә. Гылаваның шофер егетләре белән гәпләшәм мин. «Ялагайлана белми синең чәчбашың…— Әй, телемне бал корты чакты! — Шуңа сезнең арбагыз иске, утыныгыз чи»,— диләр.

— Чәч бит миндә генә түгел, ир-атта да үсә.

— Түрә хатын-кызга чәчбаш диләр инде, Гөлфия апа, үпкәләмә. Как-никак син гәзитә хуҗасы.

Гөлфия, бертуктаусыз такылдаган егетне ишетмәс өчен, тәрәзәгә борылды. Бөтен гәүдәсенә инә кадаганнармыни, әз генә селкенсә дә, тәне авырта. Бу инәләр, дәррәү кузгалып, сул беләкне чәнчә дә, аркага күчеп, кабырга астын чокый. Кичәге хәлләр ничек тетрәндерде сине, и йөрәк!

Олы юлдан төшеп, Бәкерлегә табан җилдергәндә генә машина «төчкерде».

— Вәйт сиңа мә, «томау борын»! Басуга хәтле өч чакрым иде. Син утырып кына тор, Гөлфия апа,— диде шофер егет.— Мин, ике аяклы «джип»ны үрләтеп, Бәкерлегә элдертәм. Безнең таныш ул иптәш Әюпов.

— Чү, чү, энем! Мин җәяү генә барам, ә син сүт тә җый бу тимер өемен.

— Баш өсте, Гөлфия апа!

«Ник йөрәк калтырамасын,— диде ул, яңгырдан кипшенгән юл читеннән әкрен генә атлый-атлый.— Биш елда биш көн ял итмәгән кеше бит мин. Гомер су кебек ага… Теге яра һаман төзәлмәде. Учагында җылынырга гаилә юк, бала-чага юк… Әй газиз Аллам, онытылып гашыйк булырдай ир затым да юу-ук! Кайда ул, кайда-а? Хәлсез йөрәкне дәвалап терелтер дә дөньяның матурлыгын тоеп яшәтер иде бу мәхәббәт…»

Кыз иелеп туфрак учлады. «Шушы балчыктагы тузан бөртекләре кебек, галәмдә дә син яраткан адәм исәпсез-хисапсыз, әй газиз Раббым! Миңа насыйбы гына яралмаган, ахрысы. Ялгыз картаерга язган микән?»

Гөлфиянең иңбашына, йоклаганда бөтәрләнгән канатларын төзәтер өчен, күяз алсу күбәләк кунды. «Җырымны тыңлыйлар» дип, сөенә-сөенә тургай сайрады, чык тамчысы белән битен юган төклетуралар, чырык-чырык күлеп, зәңгәр күзләрен ачты… Яңа туган иртәдән сабый исе аңкый иде… Туу хисен тояр өчен адәм баласына таң атканны күзәтергә кирәк икән. Табигатьтә көннең өр-яңадан тууына ишарә бар, ә кешедә — юк… Аның яшәешендә таң атмый, ул нибарысы йокыдан гына уяна. Кичәге уйлар, кичәге мәшәкатьләр, кичәге авырулар тагын кабатлана.

Кәбестә басуында кызны Әюпов куып тотты.

— Санадыңмы? Ничә данә? — диде ул, җитди генә.

Таң белән әсәрләнеп дөньясын оныткан Гөлфия:

— Нәрсә? — диде.

— Соң… кортларны, дим. Максатың шулдыр бит?!

— Әюпов… Кулыңдагы кәчтүмеңне ябынырга мөмкинме?

— Мә, рәхим ит. Нинди тамаша халык соң болар? Берәүләре анадан тума чишенә, икенче берәүләре кат-кат киенә.

Эчтә боз иде. Менә ул кул-аякларны туңдыра башлады. Кызу җәй уртасында зәмһәрир суыклы кышларга илтеп ташлаган бу зәхмәт чир, күр син, азмакчы була.

— Кәбестәләреңнән салкын бөркелә, Әюпов,— дип көлемсерәде кыз.

— Нинди генә гаепләр такмыйлар безнең басуга. Кәҗә көтүе җибәрәм, валлаһи!

— Син гел шундый дорфамы, Әюпов? Иртәгә өйләнәсе егет, әзрәк елмай!

— Шәп киңәш, валлаһи! Нишләдем мин, ә? Ник бу кадәр чәбәләнәм, ә? Ир башым белән, ә? Чәнчелсен кәбестәләре!

— Үрсәләнмә, шушы санда ук «расланмады» дип бастырырбыз, Әюпов. Кәчтүмең өчен рәхмәт. Мә, үзең ки. Хуш!

— Исән генә яшә, Гөлфия,— диде рәис, елмаеп.— Минем исемем Җәүдәт, яме! Гафу, гафу, анда сезнең «арбагызны» сүткән Рамил, өч көнлек эше бар әле аның.

— Ашыкмасын, мин урман буйларында йөреп килэм,— диде Гөлфия.

— Урман моннан гына якын күренә, яшел төс күзне алдый ул, Гөлфия. Аягыңдагы шәһәр чабатасы чакрымнарга чыдамас шул, әйдә утыр!

Егет үзенә-үзе чокыр казый иде.

— Син Күмер Таудагы хәлләрдән хәбәрдар түгел бугай, Әюпов. Мин баш мөхәррир саналсам да, хокуксыз «баш». Миңа киңәшмәләрдә катнашу, хуҗалык җитәкчеләре белән аралашу, авылларга чыгып әңгәмәләр кору катгый тыелган. Сәлимә Басыйрова йөри безнең андый җирләргә. Минем белән очрашкан рәисләрне шунда ук эшеннән бушаталар.

Җәүдәт ышанмады:

— Син шаян кыз икән, Гөлфия.

— Әйе, елаганда шаяртам мин. Йә, хуш, Әюпов!

— Кузгалма, дим, утыр! Утыр, диләр! — Егет аяк тибеп кычкырды.— Ялындырсаң, алам да ыргытам хәзер машинага. Мин Бабайдан курыкмыйм, без җебегән малайлар түгел! Нигә ирегеңне кыса ул синең, ә?

Чит-ятларга кем түгелә ди. Күңел савытың ташыса да, дәшмә инде. Биш елда беркемгә дә зарланмады Гөлфия. Җыйды да йөрәгенә бикләде, җыйды да бикләде.

— Мин болай да күп сөйләдем, Җәүдәт. Алда сулы чокыр, бата күрмә.

— Алда чокыр, артта чокыр, җаннарда гына такыр... Рифмасы чатанлый, әйеме? Безнең авыл китапханәсендә бер китап бар. Тышы таушалган, битләре теткәләнгән. Язучысы — Гөлфия Хан. Синекеме?

— Минеке, Әюпов.

— Гөлфия Хан... Гөлфия ханбикә. Укымадым әле, гафу. Сиңа минем белән күңелсездер, нindидер пүчтәк кенә хуҗалык рәисе тел тегермәнендә сүз тарттыра, әйеме?

— Әюпов, әгәр син мине урман авызында төшерсәң, бик күңелле булыр иде.

— Без алган әйберебезне урынына кире илтеп куярга гадәтләнгән, Гөлфия. Урманда ни йомыш?

Аллам, бәйләнчек сыңары икән бу егет.

— Йөзегемне югалттым, берәүнең истәлек бүләге иде. Шуны эзлим, Әюпов.

— Чытырман эченнәнме? Монда бабаңның кырык икенче үлчәмле галошы төшеп калса да табалмыйсың. Үзеңнең дә исән-имин чыгуың икеле. Беркөнне урман өстендә вертолет бөтерелде-бөтерелде дә аска чумды. Кайчан күтәрелер дип көтә-көтә муен тамыры зәңгәрләнде. Шоферны сакка бастырдым, ул кояш баеганчы күзләде, юк, вертолетны йотты Салабаш. Җә, шул галәмәттән соң ничек мин хатын-кызны ялгызын гына карурманга кертеп җибәрим ди! Әйдә, икәү кармалыйбыз.

Әнә теге кәкре каен — тамга ул. Сукмак очы шуннан башлана. «Йә, кит инде, Әюпов, Алла хакы өчен кит! Бар, кәбестәләреңне караклардан сакла. Чынлап та, быел син —табышлы хуҗалык».

— Вертолет, дисеңме, Әюпов? Бөркетләр ул, куян аулагандыр.

— Минем күзем очлы, Гөлфия, айдагы тапны да күрә. Әнә күктә нокта кадәр генә кош. Хәзер, хәзер! Бүген мылтык корулы безнең.— Егет машинасыннан мылтыгын тартып алды.

Кыз:

— Атма! — дип, аның беләгенә ябышканда, колакны тондырган гөрселдәү тып-тын урманны сискәндерде. Нәни нокта да зурая-зурая җиргә якынлаша иде.

— Тилгән, чебигә китеп барышы иде,— диде Җәүдәт, авызын ерып.

— Кансыз,— диде Гөлфия.

— Кулың салкын, беләкне туңдырды. Кар кызы, ахрысы, син, — диде егет.— Мә, җылын!

Ул кәчтүмен кызның җилкәсенә япты. Гөлфия дер-дер калтырап түмгәккә утырды. Ә Җәүдәт сызгыра-сызгыра урман кырыеннан китеп барды. Хәерсез иртә! Бер якта — зәхмәт чир, икенче якта — сыланчык Әюпов. Вертолет, диме? Күктә нәрсә генә очмас та, Салабаш нәрсә генә «йотмас». Урманда аланнар әзмени! Ул да анда ята…

Кыштыр-кыштыр үлән ярып, Әюпов әйләнеп килде. Кулында зәңгәр мәтрүшкә бәйләме иде.

— Мә, сөттә кайнатып эч тә юрганга төренеп ят, чиреңне «теле» белән ялый.

— Нигә ялагайланасың, Әюпов? — диде Гөлфия.— «Фактлар расланмады» дип бастырам, дидем бит. Кортсыз синең кәбестәләрең, кортсыз!

Егет аңа озак кына карап торды да:

— Мәшәкатьләнмә, хәзер аның кирәге юк инде,— диде.— Менә синең хәлләр йөзек эзләүдән узган, утыр, озатып куям, иптәш баш мөхәррир.

Авызына йозак элделәрмени, әрсез юлдаш бүтән дәшмәде.

Мәйсәрәләр капка төбендә дә коры гына хушлашты ул. Аңламассың бу ирләрне! Кәбестә кебек җиде катлы икән алар. Кичә, исемен акларга кушып, бөтен редакциягә шаулады, ә бүген «кирәге юк», имеш.

Гөлфия сөт белән үлән төнәтмәсе әзерләде. Җылына төсле... Аркасыннан кемдер кулы белән сыйпый төсле... Абау, Әюпов кәчтүме?! Ул аны бирмәгән ләбаса! Нәрсә җылыта, дисә... Әюпов икән лә... Менә хәерсез!

Кыз аны иңнәреннән кагып кына төшермәкче иде, тәне шәрран ярды: «Тимә-ә-ә!» Рәхәт җылы иде бу, рәхәт җылы. Кыз үзалдына кызарды. Иртәгә берәүсенең хәләле буласы ят ирдән җылы урлаган угры хатынга охшаган иде ул. Андый хурлыклы исемне күтәрүеңә караганда, туңып үлүең мең өлеш артык иде. Соры кәчтүм элгечкә асылынды. Гөлфия, үлән эчеп хәлләнәм дә урманга китәм дип, башын мендәргә төрткән генә иде, тансык йокы, гәүдәсенә уралып, керфекләрен йомдыртты. Көн йоклады кыз, төн йоклады. Кузгалам дисә, буыннар таралган иде. Ул уянганда, яңа таң аткан иде. Гөлфия генә кичәге, Гөлфия генә иске... Әмма йөрәккә укмашкан боз эрегән иде.

— Сөбханалла, елмаясың, кызым,— диде Мәйсәрә.— Мәрхүмә әбием әйтмешли, иштең йокы кибәнен. Мендәр белән юрган да дәва шул.

— Дөньяларданиләр бар икән, Мәйсәрә апа? Бәлки, минем урындыкка Сәлимә җәелгәндер?

— Җәелмәгән, җәелмәгән. Аңа ди синең белән ярышу. Бабайны олактыралар, имеш. Морҗадан утсыз гына төтен ургылмый, дөрес, диләр, кызым.

— Шатлыклы хәбәр түгел, Мәйсәрә апа.

— Ничек? Әллә син аңышмадың инде, кызым?

— Аңладым ла, Мәйсәрә апа. Аңа каныкмасыннар иде. Ул гадел һәм намуслы хаким.

— Әстәгъфирулла, Борчак патшасымы? Синең тормышыңа таяк тыгып бутаган кешеме?

— Анын гаделсезлеге шәхсән миңа гына кагыла, Мәйсәрә апа. Минем хакта аңа урынбасарлары гел ялган ташыды. Ул аларны дөрес фикердә дип уйлады. Кирелегем дә булышкандыр. «Күрдем» диярргә иде миңа. Шул сүз хакимнең иң сөекле бәндәсе чутында йөртәчәк иде. Их! Үкенмим анысы, тамчы да үкенмим.

...Күмер Тауга эшкә билгеләнгән көннәр иде. Ниязның үлеменә әрнеп урман буйларын буйлаганда, ул куе үлән арасында нииндидер җан ияләрен шәйләде. Әллә бүре, әллә кабан дуңгызлары әүмәкләшә иде, ап-ачык күрмәде, чөнки керфекләр яшькә чыланган, гүя тирә-якта куе томан белән өретелеп яңгыр ява иде.

Кич белән хаким кабинетына чакыртты.

— Мин ялда чакта сине Казан безгә сылаган икән инде, бигайбә,— диде хуҗа, каш астыннан гына сөзеп.— Каладагылар киңәшергә яратмый.— Хакимнең пеләш башына чебен кунып аптырата, шуңа ул әледән-әле кулы белән буш һаваны «дөмбәсли» иде.— Безнең танышу матур чыкмады, ай-яй!

— Кәефегез юк бугай, Әмирулла Дәминович, соңрак керермен,— диде Гөлфия.

— Причем кәеф? Урман буендагы танышуны әйтәм мин, Хантимерова. Ай-яй, матур чыкмады. Син чаба идеңме анда, чәчең-башың туздырып?

— Мин. Әйе, мин. Ничек таныдыгыз? Без моңарчы кайдадыр күрешкән идек мәллә?

— Апаң таныды, Хантимерова!

— Ялгышасыз, минем Күмер Тауда туганнарым юк.

— Редакция хезмәткәре Сәлимә апаң, алайса. Син чүт кенә өстебезгә басмадың, Хантимерова. Хәйләләмә, син бит безне күрдең.

— Күрмәдем,— диде Гөлфия, тыныч кына.

— У-у-ух! — Хаким бала башы кадәр йодрыгы белән өстәлгә сукты. — Кире-е! Во-он, чурту матыр!

Иртән телефон шылтырады.

— Кер живо, Хантимерова! — диде хаким, боерып.

Хакимият күршедә генә иде, баскычта әрләнкебек як-якка карана-карана аппарат җитәкчесе Фәлинов таптана.

— Исәнмесез, Фәләнов! — диде Гөлфия.

— Фәлин исемле безнең бабай, Фәлин,— диде бәләкәй түрә, — «и» хәрефенә басым ясагыз, Гөлфия Әнвәровна, ямегез. Сез кичә Әмирулла Дәминовичны нык кына борчыдыгыз шикелле. Бездә тәртип болай: хуҗа нәрсә генә дисә дә, ул — хаклы. Буйсынуның берничә кагыйдәсен дә хәтер дәфтәренә теркәгез, ямегез. Мәсәлән...

— Кагыйдәләрегезне маңгаегызга ябыштырыгыз, Фәләнов!

Акъярдагы яңа вазифасының вак уеннар белән башлануы аның җанын рәнҗетә иде.

— Фәлинов, Гөлфия иптәш, Фәлинов,— диде вак түрә, төзәтеп.

— Уз, уз, Хантимерова,— дип каршы алды хуҗа Бабай, хәтта аппарат җитәкчесеннән чәй дә керттерде.— Татулашыйк әле без, Хантимерова, каләмчеләр белән бозылышу ярамастыр. Миңа илле өч яшь тула. Хатын белән утыз өч ел яшибез. Рауза апагыз балалар бакчасы мөдире. Чиб-бәр хатын, акыллы хатын.— Хаким иренен очлайтып чәй шопырды.— Тамак кибә. Син дә эч, тартынма, эч. Кайда эшләдең син элек? Ә-ә, «Яшьләр»дәмени? «Яшьләр, яшьләр, кыю халык» дип җырлыйлармы әле? Кыюланып, ни пычагым кырырсың икән? Син, пример, үзеңне кыю дисеңдер инде, Хантимерова. Сүз көрәштереп кенә батырайсаң иде! Хатын ишетсә, ничек җайларсың, ну, халык... Халыкның сабынлы теленә эләксәң, юып бауда киптерә инде. Казанга жалу язарлар әле. Үз гомеремдә бер ужым чәйнәдем, шуны да костыралар. Миңа исем-абруем кыйммәт, Хантимерова! Күрдем диген, җә.

Хакимнең йөзе мескен иде.

— «Күрдем» дисәм?

— Вот молодец! Күптән таныргга иде, Хантимерова! Синең дәшмәвең алтынга тиңләнер. Ул алтынга миннән фатир, яңа машина, бинагызга җиһазлар, ремонт... Нинди гозерең бар — туры миңа! Ишек һәрвакыт ачык.

Гөлфиянең кунакханәдә ике көн тараканнар белән сугышып йокысызлыктан күзләре кызарган иде.

Аны сәркәтип хатын:

— Икебезгә дә урын җитә,— дип, үз өенә алып кайтты. Кешегә салынып яшәве кыен инде, берәр куыш бирсәләр, үз оям, дияр идең. Редакциянең «кылдырчасы» да лаеклы ял сорый, тимер дә искерәтуза. Әмма ул боларны хәрәмләшеп җыярга тиешмени? Намусын сатыпмы?

Кыз тирән итеп сулады да:

— Алдаргга яратмыйм, күрмәдем шул, — диде.

Хакимнең чыраена камчы белән сыздылармыни, яңаклары буй-буй кызыл сызыклар белән чуарланды.

— Ханти-ме-рова! Син куеныңдагы шартлаткычны миңа кайда томырырга ниятлисең? Сессиядәме? Президент очрашуларындамы? Күрдең син! Күрдең, күрдең, әшәке кыз!

Хуҗа өстәлдәге яшел төймәгә төрткән иде, йөгереп Фәлинов керде.
— Боерыгыз, Әмирулла Дәминович!
— Кем син, Фәләнов... Тыңла…
— Фәлинов мин, Әмирулла Дәминович! Фәлинов, «и» хәрефе анда.
— Миңа син — Фәләнов, аңгыра!
— Сез хаклы, Әмирулла Дәминович. Мин — Фәләнов.
— Менә моны,— хаким Гөлфиягә ымлады,— хакимият тирәсеннән урам себеркесе белән себерегез!
— Баш өсте, Әмирулла Дәминович!— Фәлиновның йөзенә татлы елмаю җәелде. И-и, кемнедер сук-тырсалар, рәхәт тә инде бу түрә-бәләкәчләргә! Сабый бала кебек сөенәләр.
— Хантимерова утырышларда, очрашуларда катнашмый, хуҗалык, оешма җитәкчеләре белән сөй-ләшми, аның бурычы — гәзитә чыгару, и вәссәлам! Ү-тә!
— Баш өсте, Әмирулла Дәминович!
Фәлинов койрык сыман арттан тагылды.
— Кисәттем бит, Гөлфия Әнвәровна! Тыңламадыгыз. «Без Казаннан» дип борын чөймәгез, ямегез. Күмер Тауның үз тәртипләре монда. «Яшьләр»дәге анархия юк. Безгә яраклашмасагыз, эшегез хөрти.
Шул көннән соң редакциядә бер «баш» икегә «ярылды».
Цирктагы шамакай кебек төрле-төрле төсләргә буянган хатын:
— Кәгазьдә — син, гамәлдә — мин мөхәррир,— диде. Ул хатлар бүлеге мөдире Сәлимә иде.— Ба-бай бөтен чара-маралларда мине йөртәчәк. Чибәрлегем бар, телем бар, хәйләм дә бер капчык, хатын-кыз шуның белән алдыра инде, каләмдәшкәем.
Әмма диңгез белән камалган «утрауда» яшәсә дә, Гөлфия район тормышыннан хәбәрдар иде, ни хикмәттер, Сәлимә редакциягә кайтып та өлгерми, ә өстәлдә бәйнә-бәйнә язылган мәгълүмат ята. Гөл-фия сәркәтип хатыннан:
— Кем эше? — дип сорады.
Мәйсәрә җилкәсен генә сикертте.
— Күктән явадыр, кызым.
— Алайса, түшәмне яматырга икән,— диде кыз.
Беркөнне «хәбәрче» тотылды.
— Мин сине үз кызым күек якын итәм, шуңа булышам да,— диде сәркәтип хатын,— син намуслы бала. Мә, министр киңәшмәсеннән репортаж. Ашыгып язганга хәрефләрем уңга-сулга авышты.
Башта Сәлимә, үзеннән алдан «йөгергән» хәбәрләргә тузынып, Гөлфиянең ишегенә тибә иде:
— Җенле! Җеннәрең сырлыйдыр сиңа! Ник минем ипине ашыйсың?! Урманыңда ят тилереп-сата-шып, яме! Тыгылма хәбәрләргә! Яки язма астына минем фамилиямне куйдыр! Бабайдан йоныңны йол-кыттырам итусә! Мин бит «ярты баш»!
Аңа беркем дә теләктәшлек күрсәтмәгәч, «ярты баш», беләкләрен талдырып, агымга каршы йөзмә-де.
— Әйдә языгыз, яз,— диде.— Мин хәбәрдән гарык. Ниемә ул миңа? Балда-майда йөздерәләр. Ка-заннан фәлән, фәлән абзыйлар килгән иде. Таныштык. Всегда поддержим, диләр. Ул табын, малайлар! Җаның ни тели! Кара уылдык, симез-симез кызыл балык, ит, бәлеш... Күбенгәнче ашадым. Менә ничек кикертә!
Сәлимәгә Бәйрәмбаш дигән кушамат тактылар. Ул бердәнбер сәркәтип хатыннан гына шүрли, кори-дорга Мәйсәрәнең шәүләсе төшсә дә, бүлмәсенә шыла иде.

**3**

Кулы белән утлы күмер тоттымыни, кәчтүмне тиз-тиз генә бөтәрләп, сумкасына тыкты Гөлфия.
— Син ашыкма, ә мин кузгалам, Мәйсәрә апа.
Хуҗабикә борынын җыерып иснәнде.
— Өйдә ирләр исе бар сыман.
Кыз ишетмәмешкә салышты.
— Бер-ике сәгать редакциядә кәгазьләрне караштырам да...
— Тагын урманга теркелдисеңме? — дип бүлдерде Мәйсәрә.— Кызым, балам, зинһарлап үтенәм, ташла, ташла тилерүләреңне! Үлгән артыннан үлмиләр! Ул газапларың ничек чирләтмәсен ди. Озакла-мый, бәлкем, Күмер Тауда блач алышыныр. Бәлкем, яңа хаким синең дәрәҗәң белән санлашыр.
— Соңгы тапкыр, Мәйсәрә апа.
— Кичә дә соңгы иде, бүген дә соңгы. Догаларыңны укып, мәрхүм дустыңның рухына багышла да тынычлан инде син, кызым. Рамилгә нығытып әйтәм, һичьюгы, сине урманга ташымасын.
Баш мөхәррир капканы ачкач та иң беренче: «Урман пошлимы?» — дип шаярткан шофер егет авы-зына су капкан иде.
— Эшкә, җегет,— дигәч кенә, ул җанланды.

— Гөлфия апа, Салабаш урманына сыңар күзле ата шайтан ияләшкән, ди. Ничек, мәйтәм, безне бумаган, каһәр. Әле бит син имән агайлары белән хозурланганда, мин кәкре каен төбендә черем дә иткәли идем. Бүтән анда якын бару юк! Бр-р, бала йоннарым тырпайды.

Гөлфия, тавышының үзгәргәнен сиздермәс өчен, учына йөткерә-йөткерә:

— Тагын кемнең әкиятен чәлдердең, тел бистәсе? — диде.

Егет, кулын рульдән алмаш-тилмәш ычкындыра-ычкындыра, сөйләргә кереште:

— Минем бабайның хатыны...

— Шыттырма, тел бистәсе, синең бабаң үлгән бит.

— Минеке түгел, хатынның әтисенең хатыны.

— Вәт мәзәкче! Бабайның хатыны сиңа әби тиеш лә.

— Әй, бабайның хатыны ни, әби ни, аермасы юк. Менә бабайның шул хатыны, ну әби, кортлы безнең, Гөлфия апа. Үзе зерә яшь, туксан икедә генә.

— Хатыныңа утыз, әбиеңә туксан ике.

— Кара, боларның яшь аермасы зур, әйеме, Гөлфия апа? Кортка беркөнне тирги мине. Себеркеңдә өч кенә яфрак, өч тапкыр чабынсаң, ботаклары гына кала да аркам тырнала, ди. Эссе ләүкәдә ике сәгать чабына бабайның хатынының әнкәсе, вәйт кортлы! Киткән төнә әбиең урманга, имән себеркесенә. Сындырыпмы-сындыра икән агач ботакларын. Каршысына тып итеп килеп басмасынмы сыңар күзле шайтан. Тешләрен шыгырдата, ди. Догаларымны укып өрдем, ди әбинең әнкәсе, кузгалмый, ди, шайтан абзаң. Карчык авылга хәтле йөгергән. Чаба-чаба чалыш аяклары турайган дажы, Гөлфия апа. Өйдәгеләр аны «акылга җиңеләйгән» диләр. Мин ышанам. Намаз карчыгы алдашып гөнаһка батмас. Ни хаҗәтемә ди корткага шыттыру-пыттырулар? Дөресме соң, җен-пәри затлары бармы дөньяда, Гөлфия апа?

— Син бар бит, тел бистәсе, ник алар булмасын ди әле.

— Бәрәч-пәрәмәч! Нишләп минем күземә чалынмый икән пәри җанкисәккәйләр? Кысып-кысып кочаклар идем.

— Җирдә техника үкерә, күктә самолет оча, фатирларыбызда телевизор, музыка акыра. Җеннәр генә түгел, тимер башлы, тимер йөрәкле робот та качар иде. Табигатьтән аерылгач, маңгай күзләребез дә томаланган. Шул-лай, без — дөм сукырлар,— дип көлде Гөлфия, ә үзенең эче поша иде. Әнә туксан ике яшьлек карчык та юлыккан урман ияләренә! Сыңар күз — ышыклаучы пәрдә, ә пәрдә артында — Ул! Ни йөрәгең белән түзеп утырасың, Гөлфия, чытырманны айкап эзлә. — Рамил, бүген синең ялың, яме. Машинаны күләгәгә яшер дә дүрт ягың кыйбла.

— «Арбаның» нормасы тулды, Гөлфия апа. Кабызып та азапланма, төкерек белән генә ямаган идем чыбыгын,— диде шофер егет, хәйләләп.— Урман үтүт. Әлсә, бу карчык бабайның хатынының әнкәсе инде. Сыңар күзле шайтан коточкыч ямьсез, ди бабайның хатынының әнкәсе.

— Эһе, малай.

Ул, каударланып, баскычтан менде. Кулындагы сумкасын ишектән генә ыргытмакчы иде, артта кемдер тамак кырды.

— Таптап узасың, Гөлфия.

— Уф, син икән, Әюпов. Бүген туй дигән идең түгелме соң?

— Әйе, шулайрак иде дә... булмады... Син минем өйләнә торган кәчтүмемне киеп киткәнсең.

— Көлдермә, Әюпов. Иске ич ул.

Җәүдәт ишек ачкычын борды.

— Бүлмәңә рәхим ит, Гөлфия.

— Рәхмәт. Мин сине кисәттем, җегет. Бабайның «кара исемлеге»нә эләгәсең, бел.

— Көлдермә, Гөлфия. Терелдеңме?

— Рәхмәт, үләннәрең шифалы икән.

— Кая, кулың җылынган микән?

— Әрсезләнмә, Әюпов. Инде сиңа ни кирәк?

— Ни кирәк, ни кирәк...— Егет ян тәрәзә кырыена басты да бармагы белән чык-чык пыялага чиертте.— Мин төнлә тилердем... Өйдәгеләр һуштан язып егылды. Ак күлмәкле кәләш кыз атасы йортында елый. Кыңгыраулар чыңламады. Кыскасы, өйләнеп булмады.

Тыштан үткен томшыгы белән кош чукый диярсең, пыяла зеңгелди. Әюповның да кулы зур... Сыңар күзнең дә... Дөнья ирләр учында: теләсәләр — төзиләр, теләмәсәләр — җимерәләр...

Кыз, үзенә төбәлгән күзләрдән оялып, өстәлдәге кәгазьләрне рәтләгәндәй итте.

— Өйләнү-өйләнмәү синең шәхси эшең инде, Әюпов. Кичер, мин ашыгам.

— Мин дә ашыгам, Гөлфия. Без бергә ашыгабыз икән. Әйдә!

— Алдан ук кисәтәм, Әюпов, миңа тагылма.

— Тагылмам, мин койрык түгел, янәшә барырбыз,— диде Җәүдәт, төрттереп.

Гөлфия, ярсый-ярсый, иске «арбаны» кабызырга маташты. Кабынмый хәерсез тимер өеме. Ә ирен читләренә елмаю кунган егет аны читтән генә тамаша кыла.

«Авызыңны яп, чебен керә», — диде кыз, эченнән генә. Һай, ул да тупасланды! Нәзакәтле иркә, ягымлы ханбикә салкында чәчкәсе туңган гөл кебек кадый, чәнчи...

— Йә, җегет, артык елмайма, кояш көнләшер. Кайда тырантасың?

— Салабаш урманынамы, Гөлфия?

— Миңа шунда, ә синең соңгы тукталышың — кәкре каен. Ишеттеңме, Әюпов?

— Безнең бабай колакка катырак иде. Йогышлы чир бугай ул.

— Мин шаярмыйм, Әюпов. Зинһар, үземчә яшәргә ирек бир.

— Икәү эзләсәк, йөзегең тизрәк табылыр иде.

— Җөдәтмә, Әюпов!

— Әюпов та Әюпов! Җәүдәт минем мулла кушкан атым!

Егет юри түмгәкләр өстеннән сикертеп узды. Башы бәрелмәсен өчен, гәүдәсен урталай бөкләде Гөлфия.

— Әнә кәкре каен! Мине төшер дә үзең кире борыл,— диде ул, тәкәббер егеткә рәхмәт тә әйтмичә. Җәүдәт тә хушлашып мәшәкатьләнмәде, машина көпчәгеннән чирәмле балчык кисәкләре сиптереп, кискен генә авыл ягына борылды.

Үпкәләде. Серкәсе су күтәрми икән лә. Әрсез «койрык»ның өзелүенә сөенсә дә, шомлы тынлыкта изрәгән урман өркетә иде. Кыз, бер-берсенә чуалып үскән тәбәнәк куакларны як-якка этәреп, эчкә үтте. Менә-менә кайдадыр поскан Сыңар күз җилкәсенә сөякле бармакларын батырыр кебек иде. Ике адым атлагач, артка чигенде. Юкка йөри, юкка маҗаралар эзли. Әле ул акылына килеп, үз теләге белән кабачак тозактан котыла да ала, кире чыгып, котыра-котыра машина куган Әюповка кул да изәп өлгерә. Йа Ходай, нишләргә соң инде?!

Сыңар күз аны өнәмәде. Бик җенләнсә, ботарлап ыргытырга да күп сорамас. Дөньясы кая табан тәгәри: көпә-көндез кеше үтергәндә, чебен дә безелдәмәгән аулак карурманда көчсез генә хатынны имгәтеп ташлау чүп кенә ул. Күкрәкне ярып, тагын ике йөрәк тексәң инде. Берәү генә түзми монда, түзми. Аяк астында шырт та шырт кипкән ботаклар сына, үз адымыңнан үзең куркасың: кемдер карап-күзәтеп тора сыман. Кемдер эзеңә үк басып килә төсле. Гөлфиянең сизгер борынына ис бәрелде. Черегән яфрак исе аңкыган дымсу һава тәм үзгәрткән: учакта ит көйдерәләр. Кайчакта хуҗалык рәисләре, Бабайдан яшеренеп, аулакта сыйлана. Тик алар Салабаш урманына йөрмиләр иде бугай. Кыз күкрәктә тукран кебек тукылдаган йөрәген учы белән кысты. Сабыр, сабыр, туган, ике тапкыр үлмиләр. Әманәт йөкләмәсәләр, ул бүлмәсендә хәреф хаталары гына чүпләп утырыр иде, аның исә андый сайлау мөмкинлеге юк, тармакланган юлларның барысы да урманга илтә... Нәкъ үлемгә илткән кебек. Анда да мең сукмакка кереп адаш, әҗәлең барыбер сиңа дигәненә китереп чыгара.

Кошлар да ачыклыкта гына сайрый икән. Караңгыда абагалар рәхәт чигә. Серле әйбер гел тирәнрәк яшеренә шул. Әнә Ул да җир астыннан юл салган, ахрысы. Урманда нишли икән, йә?

Гөлфия, йөзек тәгәрәгән урынга җиткәч, чүмәшеп, кулы белән агач төбен капшады. Юк йөзек, юк! Кинәт баш очында әлсерәгән җанвар мышнады, тураерга да курыккан кыз аның зур гәүдәле икәнен чамалады. Кисәк кенә аягына баскан иде, чәч толымыннан эләктереп, артка авыштырдылар һәм, күкрәгеннән бау белән уратып, агачка бәйләп тә куйдылар.

— Сыңар күзле шайтан! Сиңа урман тар мәллә?!

— Тик тор-р,— дип ырылдады «җанвар».

— Хуҗаңны чакыр! — дип инәлде Гөлфия.— Чакыр хуҗаңны! Минем аңа сүзем ба-ар! Китмә, шайтан токымы!

Сыңар күз аның ялваруларын колагына да элмәде, ул урман тынлыгында эрегән иде.

— Шул кирәк сиңа! — диде кыз, үз-үзен камчылап.— Әюповны ияртергә иде.

Койрык, янәсе. Сер чәчми, сер түкми, имеш. Рәхәтме инде хәзер агачка берегеп «үсүләре»! Кайчан ычкындырыр бит Сыңар күз. Тукта әле, нигә Әюпов өйләнмәде икән? «Өйләнә торган кәчтүмне киеп киткәнсең...» Һе, кызык... Бу бауны юкәдән ишкәннәр бугай, чәйнәсәң дә өзелмәс. Күпмегә чыдар икән Гөлфия? Тугыз яшендә ул урманда адашкан иде. Кояш баеды, караңгылык иңде, кычкыра-кычкыра тамак карлыкты, абына-сөртенә чаба-чаба аяклар арыды... Кыз, яктыга чыгам дип, гел эчкә кергән икән. Өч тәүлектән соң таптылар. Олылар: «Кайда йокладың? Нәрсә ашадың?» — дип төпчегәндә, дус кызлары: «Абага төнлә чәчәк ата икән, аны каптыңмы?» — дип тинтерәтте, ә ул берни дә сөйләмәде. Әтисе аучы иде, әгәр, әгәр... бүре балалары белән бергә йокладым, дисә, гайрәтле ата йомры йомгакларның өнен туздыра, ә аналарын үтереп, тиресен туный иде. Гөлфиянең елый-елый йөзе өрелгән иде, тозлы күз яшьләре бит тиресен әчеттерә, ярылган иреннәр әрни. Соры бүре, шуны сизгәндәй, кытыршы теле белән яңакларын ялап юды, төнлә кызчык туңмасын дип, җылы сыртын терәде.

Гөлфия үзалдына йомылгач, әниләре: «Курку башына бәргән»,— диделәр. Бәргәндер, мөгаен, бит кыз шуннан соң язу белән сихерләнде. Геройлары урман да бүре, урман да бүре иде... «Яшьләр»гә дә ул урман турында хикәя тотып килде. Баш мөхәррир Нияз исемле авылдаш егет иде.

— Теге чакта синең миеңә каты суккан икән шул, әле һаман айнымагансың,— диде ул һәм «иҗат җимеше»н шытырдатып ертты да чүп савытына томырды.— Син үзеңне безнең каләмдәш дип сана,

Гөлфия! Хәзер үк эшкә кереш. Бүтән агач-куакларда, төлке-бүреләрдә чокынма, Кыргый дигән даның таралыр. Язардай нәрсәләр буа буарлык безнең илдә: төзелешләр, оешмалар, җыр-биюләр, театрлар... Каләмеңне сәясәт карасына да манма, ул да урман кебек: караңгы һәм куркыныч. Анда кеше атлы «ике аяклы бүреләр» дә дәү корсаклы, казык тешле, кызыл күзле; буып каныңны эчәрләр.

Гөлфиянең кушаматы Киребеткән иде. Ничек инде ул, бу кушаматына хыянәт итеп, җаны карышкан эшкә кул тыксын ди! «Баш»ның киңәшләренә төкереп, нәкъ сәясәт турында яза башлады кыз.

— Ярыйсы гына әвәләгәнсең чи камырны,— диде Нияз.— Урысны черетеп сүккәнсең. Дер калтырар инде Мәскәү, синең язмаңны укыгач. Кеше сүгү көчсез татарның чире, алга табан белеп эш ит, авылдаш.

Иркен далада тояк үткенләгән ярсу атка охшаган иде Гөлфия. Җил белән ярышып әй чаба, әй чаба! Аны берәү дә туктата алмый. Ни пычагыма иде аңа сәясәт?! Ишеккә борынын кыстырсалар — кулын, кулын кыстырсалар, аягын тыккан ахмак иде ул. Ахмак, ахмак! Бәлки, бу язмаларны бастырган кеше аның белән чагыштырганда ун мәртәбә ахмаграк булгандыр? Гөлфиянең маңгаена сугарга иде. «Дөньяны үзгәртергә хыяллансаң, кияүгә чык, бала үстер», — диярге иде. Үзең үзгәрмәсәң, дөнья мәңге үзгәрәсе түгел. Адәм баласы аяк астындагы бозны ватмыйча, кәйләсе белән Җир шарындагы дәү бозга кизәнә, ә бит ул әүвәл үзе басып торган нәни шугалакка таеп егылачак.

Нияз аны күрәләтә очындыра иде. Гашыйк ир көпшәкләнгән язгы кар кебек икән: кояш әз генә елмайса да, җебеп эри. Җыелышларда ул авылдаш кыздан күзен ала алмый, әйтерсең бүлмәдә алар икәүдән-икәү генә, әйтерсең бүтән хезмәткәрләр җансыз сын иде. Ләкин Гөлфия егетнең эчкерсез хисләре белән уйнамады. «Файдаланыйм» дигән явыз ният тә юк иде. Каләме үткен, язмалары мәгънәле, көнчеләрне көнләштереп яз да яз! Нияз тугры дус исәбендә генә йөри иде. И, ул ял көннәрендә Салабаш урманнарына кайтып, аланда учак ягулар, чиләк-чиләк бәрәңге тәгәрәтүләр, күмерләнгән кабыктан авызлар буялып, бер-берсеннән шаркылдап көлүләр... Урман бүген дә Ниязның көлүен саклый төсле... Кайсыдыр агач башында бу көлү, кайсыдыр кош оясында... Нияз, Нияз... Яндырды сине Гөлфия, яндырды!

...Селкенмәгәч, аяк-куллары ойый иде. Баягы көйдергән ит исе дә көчәя. Кемдер сый әзерли. Ә бәрәңге күмгән учакның исе бөтенләй башка иде! Кабыкларын Нияз бер өемгә җыя. «Куян өлеше... Бездән соң озынколаклар мәҗлес кора...» Хыялый Нияз, эчкерсез Нияз! Яндырды сине Гөлфия...

Кызның күзеннән эре-эре яшь тамчылары тәгәрәде. Соңгы тапкыр, имеш. Әле берәүнең дә хатирәләренә җеназа укыганы юк. Хәтер иясе белән бергә үлә...

Куак чытырдап сынды, Гөлфиягә табан киң маңгайлы Сыңар күз якынлаша иде.

— Хуҗаң җибәрдеме? — диде кыз, өмет белән.

Шайтан агай дәшмәде, мыш-мыш сулап, тоткынның урта бармагына... көмеш йөзекне шудырды.

— Тикшермә инде, минеке бит! Күрәсең ич, тап-таман. Хуҗаңның бүләге иде ул. Таныдымы? Мин юри ташладым. Син, тавык төсле, сукмактагы инә очы кадәрле әйберне дә чүпләрсең дигән идем — кара, дөрес булды.

Сыңар күз бауны чиште дә, «р» хәрефен икеләтеп:

— Ир-ртәгә,— диде.— Кит, бар-р!

— Төгәл вакытын әйт! Тәүлектә егерме дүрт сәгать.

— Көн ур-ртасында,— диде Шайтан.

Гөлфия күзе белән генә аның буй-сынын үлчәде. Әюпов чамасы икән. Кәбестә басуы хуҗасы бу Алабайны, бәлки, җилкәсе аша гына чөяр иде. Әй, мәнсез кыз, куян башың белән арысланнарны сугыштыралармыни?! Ул да мәнсез, йөзекне таныган бит инде, очраш та сөйләш, сукмакка Алабаеңны казык итеп кактырма. Тагын нинди шиге калгандыр? Кыргый урманны зиннәтле сарайга әйләндереп, тәхеткә кунаклаган хан кебек кыланмаса, дәрәҗәсе кимер ди. Ә түрәләрнең боерыгын ялчылар төгәл үти. Һәр чорда, һәр дәвердә шулай: борынгылар — тәңкә-алтын, бүгенгеләр доллар белән түли. Шайтанны да акчага коендыралардыр, күр, ничек хуҗасын саклый. Гөлфия дә кыбырсык җан, артык өзгәләнә. Югыйсә әманәтне шушы өтек тә тапшырыр иде. Хуҗасы файдасына ла.

Үртәлде кыз, бик үртәлде, бармагындагы көмеш йөзеген янә сукмакка атып бәрердәй булды. Әй кыланчык түрә халкы. Шуңа күрә Гөлфия кәкре каен төбендә йоклаган Әюповка ачуланмады, эчтәге ярсу көчен дә суырган иде, әкрен генә егетнең каршысына тезләнде. Йоклый... Йөзендә яфрак шәүләсе... Җил искән саен, ул маңгай-яңаклардан шуыша... Җәүдәтнең керфекләре озын икән... Кашлары кара икән... И Раббым, нигә ир-атка йөз матурлыгы? Ир заты ямьсезлеге белән матур, акылы белән матур, көче белән матур... Бәлки әле, ярата белү белән дә матурдыр ул...

Әюпов елмаеп уянды.

— Таптыңмы? — диде.

— Нәрсәне? — диде Гөлфия, сорауны аңламады.

— Бәс, йөзегеңне.

— Ә-ә, сукмакта елый-елый көтә иде.

— Мин дә көттем-көттем дә, күзгә йокы тулгач, аудым.

— Сиңа кем көтәргә кушты, Әюпов?

— Без кушмасалар да көтәбез, без — мөстәкыйль дәүләт вәкиле, Гөлфия.
— Нишләп өйләнмәдең? Кәчтүмең өстеңдә ич.
Нигәдер эчтәге үртәлүнең бер өлешен Әюповка күчерәсе килә иде. Әмма егет төртмәле сүзләргә кадалмады. Ул:
— Хәзер өйләнәбез, ике күбәләкне шаһитлар итәбез дә...— дип сикереп торып машинасыннан зәңгәр ашъяулык алды. Аны чирәмгә җәйгәч, табынга берәм-берәм әйберләр тезде.— Әгәр авырсынмасаң, туракла-кисәклә, Гөлфия. Кыяр-помидор юган, тавык ите пешкән.
Гөлфия карусыз гына пычакка үрелгән иде, кире ташлады.
— Әюпов, син учак яга беләсеңме?
— Бәтәч, коймада икән этәч! Нишләп белмәскә ди.
— Күмердә тәгәрәп пешкән бәрәңге тансыкладым мин, Әюпов.
И хыял, канат очлары белән бәрәңгегә орынган хыял... Нияз тергезгән кайнар учакларны кабатлыйсы иде дә, тик үткәннәрдән берни дә, бернәрсә дә кабатланмый. Син могҗиза иясе түгел шул, Әюпов.
— Хәзер оештырабыз, Гөлфия, урманда корыган ботак-санак җитәрлек,— дип, егет җиңнәрен сызганды.
Баядан бирле кызның аркасына инә белән төртәләр иде. Юк, инә түгел, күз угы бу. Шайтан, явыз, мыштым Шайтан посып кына аларны күзәтә иде.
— Әюпов! — Гөлфия учак урыны сайлаган Җәүдәткә кычкырды.— Мин ашыгам икән, гафу ит.
— Ничек? Бәрәңге ашыйбыз, диден бит.
— Ашыгам, Әюпов. Мин табынны җыям.
Ул ризыкларны ашъяулыкка гына төйнәде. Һәм тиз-тиз генә артка утырды. Умыртка сөяге чемерди... Йөзәрләгән агачның һәрберсендә Сыңар күз...
Җәүдәт машинасын бер кабызып, бер сүндереп юри вакытны суза иде.
— Татарда «Үз башыңа йөрисең» дигән әйтем бар. Син дә, Әюпов, минем белән аралашып, бәлагә тарасың. Бабай гафу итмәс бу башбаштаклыгыңны. Корбан инде син.
— Хуҗалыгы-ние белән дөньяның икенче читенә аткарсыннар, җәл түгел. Миңа хәзер бер генә кеше кирәк...
— Йөгер шуның янына, Әюпов.
— Җүләрмени без! Янымда бит ул.
— Йә, Әюпов, сайрама. Ник өйләнмәдең?
— Өч төрле сәбәп аркасында. Саныйммы?
— Йә, сана, тыңлыйм,— диде кыз. Гадәттә, ир-атлар аңа рәхәтләнеп күңелен бушата, күрәсең, Гөлфиянең маңгаена «сер саклаучы» дигән тамга сугылган иде.
— Беренчесе, Гөлфия: мин сиңа гашыйк...
Кыз колагын томалады.
— Ишетмим, ишетмим!
— Икенчесе, Гөлфия: мин тагын сиңа гашыйк.
— Ишетмим, Әюпов!
— Өченчесе... Мин тагын сиңа гашыйк.
— Бернәрсә дә ишетмәдем, Әюпов! Минем әби дә колакка катырак иде, йогышлы чир икән ул...

**4**

Ишетте... Җанга укмашкан мәңгелек боз кантарының чите әз генә кителде. Яратуның тәмен дә татымыйча туңып үлгән мәхәббәт... Ник алай икән: син яратсаң — битарафлык, сине яратсалар да — битарафлык... Ник алай? Ике учак берьюлы сирәк кабына...
Ишекне тутырып ачып Сәлимә керде.
— Бабайны тәхетеннән өрдерәләр дип гайбәт саталар, име? Синең колакка чалындымы ул пүчтәк хәбәрләр? Хәер, каян чалынсын, син районда өч кенә ноктада буталасың — эш, Мәйсәрә йорты, урман. Шатланма гайбәтләргә, Бабай кәнәфиенә нык береккән. Ә синең сәгатьләрең санаулы. Өч көннән сессия, синең артыңа тибәчәкләр.
— Ярар, Сәлимә, сүз боткасы пешермә, чык,— диде Гөлфия.
— Боткага сары май тамызам да чыгам, Фия гөле. Бәкерле рәисен яклыйсың икән, ә? Әхлаксыз Әюповны өстәп-өстәп хурларга кирәк. Ыстырам, ул бүген җирле үзидарәдә кәләше белән язылышырга тиеш икән дә, язылышмаган. Кәләшенә «өйләнмим» дигән, ди. Авыл гөж итә, ди. Бабай аны дөнья бетереп эзләттерә. Авылдан тайган, ди, «кәбестә корты». Ә кыз-кәләш белән атасы хакимияттә утыра. Көтегез, көт, дидем, рас «өйләнәм» дип вәгъдә биргән икән, үтәсен вәгъдәсен, дидем.
Бу хәл Гөлфиянең башына сыймый иде.
— Сез нишләп кешенең шәхси эшенә тыкшынасыз, Сәлимәләр, Кәлимәләр?! Үз тормышыгызның ертыкларын ямагыз әнә.

— Менә-менә, син һаман затсыз Әюповны яклыйсың, Фия гөле. Киттем, син тозсыз белән сүз көрәштереп ябыгасым юк!

Кыз Бәкерлегә шылтыратты.

— Алло, мин кем белән сөйләшәм икән?

— Мин бу, Гөлфия, мин — Җәүдәт.

— Җәүдәт...— Гөлфия сүз табалмыйча аптырап торды. И Аллам, ул да гайбәт куып Сәлимәләр түбәнлегенә тәгәри бугай.— Син авылдамыни?

— Әйе, конторда мин. Кырларны карап әйләндем дә утырам хәзер уйлап.

— Эшеңнән бүлдем, ахры.

— Һи, нинди эш! Мин бит сине уйлыйм, Гөлфия. Мин яратам...

— Тилермә,— диде Гөлфия, йөрәксенеп. Аңа ялгамас борын ук җепне шартлатып өзәргә кирәк иде.— Мин ярата белмим, җегет, белмим!

Телефонны куйгач та кыз канат очын утта көйдергән күбәләк сыман пыр-пыр итте. Ярата белми, белми, белми! Бәйләнмәгез, зинһар! Хиссез ул, салкын ул, җансыз ул!

Гөлфиянең җавапсыз мәхәббәтеннән газапланган Нияз юкка гына: «Сәясәт турында язма, акылсыз кыз, ул бит сугыш кыры, ә үлем белән янәшә ярату хисе яшәми»,— дип тиргәмәгәндер.

Халыкны җыелышка чакырды ул, ләкин ни «баш», ни бүлекләр иҗат турында бәхәс куертырлык хәлдә түгел, һәммәсе дә, бүген-иртәгә хакимне алмаштыралар икән, дип шаулаша, ә Гөлфия күңеленнән генә һаман кызып-кызып Әюповка үзенең чүл кебек коры икәнен исбатлый иде. Хәтта урмандагы вакыйгалар да төссезләнде. Әй, Сыңар күзнең хуҗасы белән очрашканнан соң ни-нәрсә үзгәрер икән? Әманәт дигәнең — гап-гади бер әләк ләбаса. Ә Нияз өчен ул — намус эше.

Халык шаулады-гөрләде дә бүлмәләренә таралды. Адәм баласының тыныч кына яшисе килми, ул, бертөрлелектән туеп, үзгәрешләр көтә. Гөлфия, өстәл тартмаларын актарып, кәгазьләрен җыештырды. Моннан куылган очракта казынып ятмас. Беркатлы адәм баласына үзгәрешләрнең дә могҗиза кушып изгәне кирәк. Әмма еш кына могҗиза тумый. Чөнки үзгәртми торган «үзгәрешләр» иле бу. Яшь чагында Гөлфия дә беркатлы кыз бала иде. Әнә шул сыйфаты аны упкынга илтте бугай. «Сәясәтчеләр клубы»нда ул калын иренле Эдуард Арсланов белән танышты. Эдуард чыгыш ясамый, фикер алышуларда катнашмый, бер почмакта мыштым гына тыңлап утыра иде.

— Ай-яй, сай сөрәләр,— диде ул беркөнне, ризасызлык белдереп.

— Ә Сез тирән сөреп күрсәтегез,— диде Гөлфия, диктофонын көйләп.— Әйдәгез, яздырам.

— Һы, яздырып нишләтәсез?

— Ташка бастырабыз.

Эдуардның чигәсенә борчак-борчак тир бәрде. Бу тәкъдимнән каушады ул, кулъяулык белән чигәләрен сөрткәч, галстугын ычкындырды. Аннары калын иренле авызын яфрак калынлыгы хәтле генә ачып пышылдады:

— Сез кыю гәҗитме? Минем дуста «шартлаткыч» бар; күп кенә агай-энене дер селкетәчәк ул. Менә дусның кесә телефоны номеры...

— Кем ул? Исеме, фамилиясе?

— Тс-с, шыпырт... Аның белән очрашу билгеләве ансат түгел. Сез — абруйлы язучы, ул Сезгә каршы килмәс. Әлегә исемсез дип атыйк без аны. «Әфәнде» дип кенә эндәшерсез. Тик бер үтенеч...— Калын ирен, сулышы белән колак яфрагын кытыклап: — Мин телефон бирмәдем, мин язма турында әйтмәдем, кыскасы, без сезнең белән бер-беребезне күрмәдек,— диде.

«Шартлаткыч» иясе белән төнге клубта очрашкач, Гөлфиянең күзләре маңгаена менә язды.

— Сез?!

— Әйе, мин,— диде кунак.— Әйдә, күрше өстәлдәгеләр безгә чекерәймәсен өчен, күптәнге дуслар кебек үзебезне иркен тотыйк. Нәрсә эчәсең, Гөлфия Хан? Шәраб? Коньяк?

— Җимешле чәй, Ха...

— Исемне атамагыз, мин — Дускай,— дип кисәтте ул.— Дөресен генә әйткәндә, мин гәзит кешеләрен сөймим. Алардан ераграк йөрим. Сезнең агай-эне ярым сатлык, ярым кол.

Кыз, тавышын кысып:

— Мин дә ялагайланмыйм, Дускай,— диде.— Корсак хакына яшәгән түрәләрдән чирканам. Халык, халык, дисез, ә үзегез халык өчен бармак та селкетмисез. Бөтен максатыгыз — мал туплау, чит илләрдә типтерү сезнең. Югыйсә теге дөньяга берегез дә йортын да, машиналарын да, алтыннары белән сөяркәләрен дә төяп китә алмый.

— Син кыю да, усал да икән, Гөлфия Хан. Килмәсәгез, иртәгә җир тетри, дип чакырган идең, йә, вулканның тишеген кайсы бармак белән томаларга кушасың?

— Йа Ходай.— Гөлфия башына ябышты.— Мин бит чакырган кешемне Сез дип уема да китермәгән идем. Вакытны үтердем. Сез майда чыкылдаган түрә ләбаса!

— Син безне артык каты дөмбәслисең, Гөлфия Хан. Бераз мәрхәмәтеңә кил. Менә сиңа гади генә мисал. Син азган-тузган өйгә кердең ди. Кая карама — пычрак, ди. Әмма әйбәтләбрәк тикшерсәң, шун-

да ару әйберләр дә күренә. Кәнәфидәгеләрне «карак, угры, ришвәтче» дип сүккәндә, син шушы мисалны исеңә төшер, яме! Арада төрлесе очрый.

— Ул «төрлесе» нишләп көрәш мәйданында түгел икән соң, Дускай?

— Казанда пешкән сөтле боткадан бер бөртек тары сикереп чыгалмый, Гөлфия Хан.

— Әгәр сикерсә?

— Сикерсәме? Озаталар. Җир асты патшалыгына. Безнең төнге күрешү тәмам, синең кебек талантлы каләм халкы белән танышу мине дулкынландырды, Гөлфия Хан.

— Нишләп «Ник чакырдың?» дип сорамыйсыз?

— Аңлашылды инде. Мин чит илләр белән икътисади элемтәләр буенча җаваплы иптәш. Кайбер утрауларда җир тетрәсә, безнең үзара мөнәсәбәтләр ничек көйләнер? Син шул хакта гәпләшмәкче идең. Вулкан борынласын әле, сөйләшербез.

«Мине шыр тилегә саный. Түрәләрнең мин-минлеге: артыбызны йомшак урындыкка терәсәк, без шунда ук хикмәт ияләренә әйләнәбез, диләр. Калганнар — аңгыра, калганнар — сарык... Нинди «шартлаткыч» ди бу адәмдә?! Калын ирен шыттырган...»

Иртәгәсен кызны телефон чәрелдәп уятты.

— Хәерле иртә! — диде ир-ат тавышы.— Миңа хатын-кыз ярдәме...

Гөлфия тыңлап та бетермәде:

— Бездә интим хезмәт күрсәтмиләр,— дип, трубканы элде.

Берничә минуттан янә телефон чәрелдәде.

— Гөлфия Хан,— диде тавыш,— кичәге Дускай борчый. Миңа, чынлап та, зәвыклы хатын-кыз ярдәме кирәк. Әнкәй авырый, шуны бүләк-мазар белән шатландырсам, бәлки, терелер дә иде. Көмеш йөзек ярата ул, татар карчыгы бит.

— Ә, Сез икән. Ничәдә очрашабыз? Унда? Килештек. Хушыгыз!— диде Гөлфия.

Сәер үтенеч иде, сәер. Казанда Гөлфиядән башка хатын-кыз юк икән лә. Хәләл җефете кайда? Ниһаять, артыннан көтүе белән чапкан сөяркәләре ник булышмый? Үзе кибетләр буйлап йөрмәсә дә, ун ювелир килеп, тауарын күрсәтеп китә.

Кыз җенләнә-җенләнә киенде дә, кинәт бармагы белән чигәсен боргычлады. Әй аңгыра, аңгыра! Йөзек артында хикмәтләр ятмагае әле, шуны уйла да «җеннәрең»не богаулап куй син.

...«Җәүһәр» кибетендә озак бүләк сайладылар.

— Әнкәй ак көмеш дип үлә,— дия-дия, Дускай аны бүлектән бүлеккә йөртте.

Гөлфия, йөзендәге елмаюын саклап:

— Артыгыздан күзәтмиләрме инде? — диде.— Чын күңелдән йөзек эзлибез, беркемдә дә шик уятмыйбыздыр, шәт.

— Шаулама, Гөлфия Хан. Һәрнәрсәнең тәртибе бар. Менә бу икесен алабыз. Берсе — сиңа. Миннән истәлек. Портфельдә «дары», сибәсезме? Бармагыңа сыя, шәп. Тик минем исем белән түгел, авторы — билгесез. Бармакларың матур икән. Әнкәй белән икегезгә дә бер үк төрле йөзек. Кичә мин сине кафеда күзәттем: син намуслы кыз, сатмаячаксың... «Дары» турында тагын кем белә?

Монысы мәкерле сорау иде. Мыштым Калын ирен белә...

— Йөзек килешә, матур. Эдуард белә. Чын дус, үлсә дә сатмый.

«Табигый сизгерлегем кими микән әллә? Мин ул бәндәдән шикләнәм бит, — дип пошынды кыз. — Бу егетнең кайсыдыр төше ошамый».

Язманы ул бүлмәсенә бикләнеп укыды. Йа Ходай, Калын ирен алдамаган: бу әйберне бастырсаң, фәлән-фәләннәрнең көле күккә оча!

Гөлфия кәгазьләрне Ниязга тоттырды.

— Мә, син дә качып кына күз йөгерт!

— Тагын нинди казылма байлык таптың инде?

— Сорама, кулыңда бит,— диде кыз, җитди генә.

«Баш» укый-укый тирләп пешкән иде.

— «Яшьләр»гә батмый,— диде ул һәм язманы, дүрткә бөкләп, Гөлфиянең кесәсенә тыкты.— Утка як! Безнең ансыз да өстәгеләр каныбызны эчә. Телләшәсез, диләр, акчагызны кисәбез, диләр. Шәхси газитләргә мач бу язма, аларны Мәскәү ашата-киендерә, ябалар дип куркасы юк.

— Үз аягы белән кергән малны кулдан ычкындыралармыни, Нияз?! Моның белән «Яшьләр»дә яшен яшьнәтәбез бит! Халык бездән «бәлеш, коймак пешерергә өйрәтүче аш-су басмасы» дип көлмәс иде.

— Гөлфия, бу әйбердә икенче-өченче эшелондагы кәттә-кәттә абзыйларга төрттерәләр. Алар үчле халык. Кем моның авторы?

— Сер. Язманы бүтән исем белән бастырабыз.

— Куркамыни? Ә-ә, аңа гомере жәл икән. Мин дә куркам, Гөлфия.

— Ул куркак, син куркак, барыгыз да куркак куяннар! Ярар, язма минеке булыр.

— Синекеме, шайтанныкымы — бастырмыйм. «Яшьләр» өчен мин җаваплы, — диде баш мөхәррир, бәхәскә нокта куеп.

Атна буе ләм-мим сөйләшмәделәр. Мәхәббәт савыты тулып ташкан егеткә бу тынлыкта яшәү газап иде.

— Көлүеңне дә ишеткән юк, күзеңнән тамган нурга да коенган юк, — диде ул беркөнне, боегып кына.

— Син мине яратмыйсың! — Гөлфия бу үпкә сүзләрен әйтергә тиеш түгел иде, түгел иде! Ул егетнең бәгырендә йомарланып яткан хисләрен тузгытты.

— Яратам! — диде Нияз, кайнарланып.— Яратуымны ничек исбатлыйм, җә?

— Теге язманы бастыр!

Нияз, башын аска иеп, бармаклары белән «керпе» чәчен тарады.

— Китер! — диде аннары, кулын сузып.— Исемеңне сырлама. «Ике аяклы бүреләр»нең әшәкелеген күргәнең юк әле синең, урман кызы.

— Рәхмәт, Нияз! Син кыю егет.

Әйе, чираттагы сан аяз көнне суккан яшен кебек булды. Әмма иң көчле яшен ташы «Яшьләр»дә дөбердәде: баш мөхәррир Нияз Сафинны эшеннән алдылар.

— Мин берничә айга Күмер Тауга кайтып китәм,— диде ул, Гөлфия белән саубуллашканда.— Кайгыра дип уйлама. Язасыларым байтак, шуларны караштырам. Ирләр җир йөзенә көрәшер өчен туа, безне җиңел генә сындыралмаслар. Сиңа дусларча киңәшем: сәяси темаларны ташла. Барыбер берни дә үзгәрталмыйсың. Кыргый хайваннар турында яз. Их-ма, ник мин сине урман фәлсәфәсеннән биздердем икән!

Гөлфия күз яшьләренә коенып елады да елады.

— Кичер, Нияз, мин яндырдым сине, мин, мин! Кичер, кичер!

— Елама, кадерлем, мин үкенмим. Узган эшкә — салават,— диде егет, аның юеш битеннән сыйпап.— Җан сөйгәнем өчен үләргә дә риза хәтта. «Яшьләр»дән башка дөнья караңгыланыр кебек тә... Ну, түзәргә инде.

Нияз артыннан ук Дускай да эзсез югалды. Кесә телефоны җавап бирми иде. Җиде кат авыз, җиде кат колак аша сораштыра-сораштыра ачыклады Гөлфия: авариягә очрап үлгән, имеш. Калын ирен дә клубта бүтән күренмәде. Әй Аллам, нәрсә үзгәрде, йә, нәрсә?! «Дары мичкәсе» шартласа да, бәгъзе адәмнәр сау-сәламәт, элеккечә урлыйлар, талыйлар. Кыз коточкыч гаделсезлек белән беренче тапкыр бәрелеште һәм менә нәтиҗәсе: маңгай ярылган, иҗат дәрте сүнгән, кешеләрдән гайрәт чиккән. Ә аңа нибарысы егерме җиде яшь иде. Гөлфия белән Нияздагы сүрән ут бергә кушылган вакытта дөнья бөтенләй яктырмый иде. Бер үтәчәк иде бу күңел төшенкелеге, үтәчәк. Ләкин иртәгә үтәме ул, берсекөнгәме, яки бер айданмы, яки ярты елданмы — билгесез, ә аңа хәтле көчәнеп булса да яшәү арбасын тартырга кирәк. Күмер Тауга еш кайтты кыз. «Икәү бәрәңге пешергән карама төбендә көч җыям»,— дигән Нияз алдаша, аңарда салам сындырырлык та көч юк, егетнең канатлары өтелгән иде.

Нияз:

— Их, умыртып «Яшьләр»дә эшлисе иде, Гөлфия! Сагынам газиз гәзитемне, сагынам хәреф буявы исләрен,— дип аһылдаганда, кызның йөрәгенә кан коела иде.

Беркөнне егет ярты төн уртасында Казанга шылтыратты.

— Мине яратасыңмы? — диде.— Мин хәзер упкын читендә, «яратам» дисәң, аска мәтәлмим, шул тылсымлы сүзеңә ябышып калам,— диде.

Яраткан килеш «яратмыйм» дип чытлыкланып була, ә менә яратмаган килеш «яратам» диюләре, һай, тел әйләнмәгән иң төче ялган иде. «Яшьләр»не югалтуына ул барыбер сызлана, миңа да өметен җуеп, «ике сызлануны бергә кичерсен, кат-кат өстәлгән ярадан газапланмасын» дип, кыз «акыл сата» башлады:

— Син миңа туганым кебек якын, Нияз, синең кебек әчкерсез дус сирәк. Күмер Тауда чибәр кызлар күп, күзеңне йомып йөрмә.

Кинәт егет, уйнак, көр тавыш белән:

— Җә инде, телефон чыбыгында сандугач сайратма,— диде.— Тыңла, сиңа бер әманәтем бар, син шуны теге «дары» авторына җиткер. Исән ул, үтермәделәр аны. Мин Салабаш урманында — карама төбендә, ул исә берәр кояшлы утрауда арка кыздырадыр. Балык түгел, су астында яшәмәс, калкыр кайчан да бер. Дуслар сайларга өйрәнсен. Аны дусты сатты. Сатып, өскә үрмәләргә җыенгандыр, майлы калҗа умырырмын, дигәндер. Сатлыкҗаннарга сөяк кенә ташлыйлар...

— Син саташасың! — диде Гөлфия, ачыргаланып.

— Ир-атны хатын-кыз гына саташтыра, Гөлфиякәй. Бит ул язманы, мин яздым дип, үз өстемә алдым. Ә теге дус чагып өлгергән. Безне аның белән күзгә-күз очраштырдылар. Кайсыгыз дөрес, янәсе. Ул «дары»ның кемнеке икәнен бик шәп исбатлады. Мини-кассетаны карама төбенә күмәм, казып алырсың, өстендә билге — чыбык кададым. Тавышыннан таныгач, гайрәтләнеп, аның өстенә ташланма. Ике юлбарыс арасына сандугач кысылмый. Син минем затлы кошым идең. Бәхил бул!

Сызылып таң атканга кадәр тилереп, Күмер Тау номерын җыйды кыз. Дәшмәде телефон, дәшмәде... Машина тәгәрмәчләрен җиргә дә тидермичә очып кайтып төшкәндә, зиратта кабер казыганнар иде инде. Салкын чокырга үзе кереп ятардай булды Гөлфия, эчтән кайнар сулыш бәрелеп яргаланган иреннәре туктаусыз: «Рәнҗемә, кичер, рәнҗемә»,— дип пышылдады. Йа Аллам, бар микән ул кичерүләр?! Ходай кичерсә — бәндә, бәндә кичерсә, Ходай кичерә микән?

Карама төбендәге табылдык аны тагын бер кат үтерде. Кая гына барса да, Нияз кесәсенә уч төбенә сыярлык диктофон сала иде. Тарих битләренә терким, дип юри шаярта, ә ахырдан гел сыздырта иде. Монысын уйнап-көлеп түгел, монысын Гөлфиянең күзен ачам дип яздырган егет. Тасмада Калын ирен тавышы... Менә сиңа: «Чын дус үлсә дә сатмый».

«Яшьләр»нең муенына «яңа баш» «ялгадылар».

— Гөлфия Хан кайчан шартлатыр икән дип, минем дары мичкәсе өстендә утырасым килми, безнең белән хушлашуың хәерлерәк,— диде ул, дәү корсагын кашып.— Син җәнҗалчы хатын, тынычлыкны гел бозып торачаксың.

Аңа «Яшьләр»дән китәргә ярамый иде! Монда Ниязның тормышка ашмаган хыяллары, төенләнмәгән уйлары, басылмаган фәлсәфи язмалары... Гөлфия аларны очлап чыгарга тиеш! Ләкин «яңа баш»ның күзендә мәрхәмәт юк иде. Талантсызлар үчле була, явыз була, мәкерле була. Алар син көчсезләнгән чакта катырак сугып калырга тырыша.

— Миңа сөяркәңнең кулъязмаларын төртмә, ярты юлын да бастырмыйм. Өстән төшкән күрсәтмә,— диде Капкорсак.

Кырмыска өенә кош тоткандай сөенеп кайткан, ди. «Ник авызыңны ерасың?» — дигән ди хатыны. «Анда яралы филне кыйныйлар, мин дә бер типтем әле»,— дигән ди кырмыска. Инә очы кадәрле бөҗәкнең аяк көчен фил сизәмени? Үзен шул яралы хайван дип хис иткән Гөлфия нигәдер авыртуны апачык тойды, чөнки кылдан да нечкә бәгырь җепселенә типтеләр.

Дөнья шигрин тиресе кебек һәрьяктан да кысыла иде...

## 5

...Өстәлгә тау-тау кәгазь өелде. Әгәр аны болытлардан җиргә сипсәң, шыбыр-шыбыр сүз яңгыры явар иде. Биш елда Каләм чакрымнар узды: моңланды, зарланды, елады, кул-аягын сындырды, җанын имгәтте, аның шул хәлендә дә хакыйкать турында сөйлисе килгән иде, ә кешеләр Каләмне ишетмәде: алар тормыш мәйданында чынбарлыкны купшы киемнәргә төреп уен уйныйлар, араларында кемнәр генә юк: ялагайлар, сатлыкҗаннар, комсызлар, йөзләрендә оят пәрдәсе ертылган әхлаксызлар... Каләм, бичара, бер читтән генә шуларга карап тора да, ак кәгазьне тырнап, үкси иде...

Гөлфия кулъязмаларны тураклый башлады.

— Чү, нишлисең?! — Әюпов ишектән үк кычкырып керде.— Ник кәгазьләрне ботарлыйсың?!

— Мин бу шөгылемнән ваз кичәм, Әюпов. Без язып кына кәкреләр тураймады, бөкреләр тигезләнмәде. Миңа башка нәрсәләр белән мавыгырга иде.— Кыз үзе шатыр-шотыр кәгазь ертты, үзе көлә-көлә сөйләде:— Мин булдыксыз түгел. Теләсәм, ике көндә тегү-бәйләү эшенә өйрәнәм, теләсәм, сыер савам, теләсәм, чәчәк үстерәм. Казандагы бер таныш хатыным кул арбасы тартып үзбәк майкалары сатарга тотынган иде, аннан күлмәкләргә күчте, аннан итәк-кофтага. Хәзер инде кибет ачты. Гел чит ил тауарлары гына ташый. Акча күп, көнләп байый танышым.

— Байлык — бер көнлек, ә синең язганнарың — мәңгелек хәзинә, Гөлфия Хан. Авызың гына көлә, күзләрең сагышлы. Тукта, ертма, барыбер күңелеңдә саклана бит ул язганнар. Кабат яңартачаксың син аларны.

— Сез дә хаклы, иптәш хуҗалык рәисе. Ник килдең?

— Сагындым...

— Кәбестә басуыннан өрдерсәләр, кая баш төртерсең икән, Әюпов?

— Дөнья киң вә иркен, Гөлфия.

— Әйдә киттек!

— Кая, Гөлфия?

— Култыклашып үзәк урамнардан йөрибез. Боткаң куерды, аны хәзер бүлеп-бүлеп ашатыргадыр бит.

— Бездән башка да бүләрләр. Гайбәт боткадан да артыграк күпереп авыздан ташый.

— Син зур җинаять кыласың, Әюпов. Гөлфия Хан белән аралашасың. Ничә тапкыр кисәттем инде...

— Чү, җинаятьнең формулировкасы дөрес түгел. Мин синең белән аралашмыйм, мин сине яратам, ханбикә!

Гөлфия комачтай кызарды.

— Әй лә... Мәйсәрә апа кайда икән? Бу кәгазьләрне чүплеккә ташысын иде,— диде ул, тавышы зәгыйфь иде.— Кайда икән инде...

Ишекне ачыйм дисә, кул-аяклары тыңламады. Нишләп йомшарды соң әле? «Яратам, яратам...» Күңелгә тып-тып язгы тамчы тама.

Тып-тып... Тамчы таш тишә, диләр, ә бу — ярату тамчысы... Ай-яй, күңелдәге бозны эретер микән? Ул бит тимердән дә катырак! Алай карама миңа, егет... Сөеп-назлап карама! Синең карашың хисләр дәрьясына салып агыза. Батар Гөлфия, батар, ә син коткармассың да...

— Җәүдәт... Бүлмә азды-тузды. Мәйсәрә апа да юк. Боларны тартмаларга тутырып ыргытасы иде.

— Сез дигәндә аяк түшәмдә, диләрме? Хәзер ялт иттерәбез, Гөлфия.

Тынычланырсың инде, йөрәк. Каләмен бүтән синең каныңа манмас Гөлфия. Сез дә, яза-яза тиресе уелган нәзек бармаклар, төннәр буе сызламассыз. Чиратка тезелгән хәрефләр һәм сүзләр, сез дә, бал кортлары сыман, баш миенә тулып гөжләмәссез. Адәм баласына ял кирәк, ирек кирәк!

Җәүдәт кәгазьләр бәйләменә кыстырган кассетаны кулында әйләндерде-әйләндерде дә:

— Моны да ташларгамы? — диде.

Калын иреннең тавышын сеңдергән тасма! Әманәт! Чүплеккә томырасы да авыр хатирәләрдән котыласы иде.

— Йөзең агарды, монда җыр-фәлән генә түгел, ахры, Гөлфия.— Егет табылдыкны учында сикертте.— Сытыйммы?

— Сытма, Әюпов! Бир!

Җәүдәт кассетага сузылган кызның кулыннан эләктерде:

— Син гел шундыйммы?

— Нинди, Әюпов?

— Инәле керпе төслеме, дим?

Гөлфия кисәк кенә артка тартылып көлеп җибәрде.

— Инәсез керпеләр дә буламыни, Әюп...— Ул Җәүдәтнең фамилиясен яртылаш кисте дә: — Гафу, мин һаман исемеңә ияләшә алмыйм,— диде.

— Алда күпме гомер, үземә дә, исемемә дә ияләшерсең әле, кызый.

— Әйе, гомер озын. Син шәхси бакчаңда кәбестә чәчәрсең. Мин су сибәрмен, без эшләп картаербыз,— диде Гөлфия.

— Куй, мине кат-кат кисәтмә, Гөлфия. Мин Бабайдан курыкмыйм. Аның ялчы малайлары минем башымны идерә алмады, шуңа Фәлинов-Фәләновлар юк-барга да каныга, ә менә сине нигә яратмыйлар? Син бит яратып туймаслык асыл ханбикә!

Кинәт Гөлфиянең ачылып китәсе дә, күңелендә ни бар — шушы егеткә түгәсе килде. Ә бит ул аны нибарысы өч кенә мәртәбә күрде. Кемгәдер сереңне тапшырыр өчен еллар буе сынауның хаҗәте дә юк. Их, нәрсәдер итәктән тота! Тәгам түгелер өчен чеметем генә ышаныч җитми. Бәлки, шикләнү — чирдер, һәм аңардан савыгыр өчен әүвәл хыянәтләрдән сызлаган җанны дәваларга кирәктер. Калын ирен хыянәте... Биш ел буе үзен мәрхүмгә чутлаткан, ә бүген урманда симереп яткан Дускай хыянәте... Ирләрнең һәммәсе дә хыянәтче микән әллә?

— Мине кирелегем өчен күралмыйлар,— диде кыз, моңсу елмаеп.— Ирләр хыянәтче, ә ул алдакчы иде.

— Син түгел, дөньясы кире аның,— дип төзәтте Җәүдәт.

— Менә шул кире дөньядан сине чыра яндырып эзлиләр, ди, Әюпов. Хакимияттә бабаң белән кәләшең зарыгып көтә, ди.

— Көтсеннәр! — Егет кочагына берьюлы ике тартманы сыйдырды.— Ә син ул гайбәткә төкер! Көчләп яраттырмыйлар да, көчләп өйләндермиләр дә.

Җәүдәт ачулы иде, муен тамырлары бүлтәйгән иде. Ишектән чыкканда, ул Сәлимәне бәреп ега язды.

— Бездән нәрсә ташый бу хәсрәт? — диде Сәлимә, күзен шарландырып.— Ник син милициядән аны тукматтырмыйсың һаман?

— Соңрак карарбыз әле, хәзер эш белән мәшгуль бит.

— Ниткән «эш»?

— Кәбестә яфракларын корт челтәрләгән, шуларга кәгазь сорап алды.

— Бәтәч, нәмәгә ди?

— Кортлар да кәгазь ашый икән. Язмаларыңның караламасын мунча миченә якма, Әюповка җибәр.

— О-о, сенсация! О-о, яңалык! Мин моның турында гөрләтеп гәзиткә язам, име! Ну түлке артыкпортык кәгазьләремне дошман Әюповка бирмим. Мине ите, каймагы, эремчеге белән туендырган хуҗалык рәисләрен бәхилләтәм лутчы. Фәрнәс тә кәбестә үстерә, теге өч мыек Фәрнәс, Каргалыдан.— Сәлимә телефонга ябышты.— Әлү, әлү, бу кем? Ничек «Мин кем?» «Күмер Тау таңнары» гәзитенең башы, ә син, атаң башы, аңгыра, кантурда нишлисең? Идән юасың? Юуыңны бел, ник хуҗаңның трубкәсен аласың? Кем-кем? Фәрнәс хатыны?! И-и, җимешем, синмени?! Ул чибәрлегең, ул акылың белән нишләп пычрак әрчисең? Эш юк? Җөре ирең тирәсендә уңлы-суллы әмер яудырып. Хәзер калхузлар белән рәис хатыннары идарә итә, җимешем! Фәрнәскә әйт, иртәгә үк йөк машинасы җиффәрсен, бер са-

рык та салсын әрҗәсенә. Мин аңа күчтәнәчкә кәгазь туплыйм. Нәстәгә-нәстәгә! Кәбестә корткычларына! Вак-вак кисәкләргә ерткалап басуга сибәрсез. Агулый ул бөҗәкләрне, вәт, җимешем. Уф! — Сәлимә, бөдрәләрен өф-өф өреп, маңгаен ышкыды.— Саңгырау! Бигрәк аңгыра хатынга өйләнгән Фәрнәс. Аңгыра дигәннән, Әюпов табылган тәки, име? Бабайның урынбасарлары җир астындагы тычканны да казыттыра, име? Туйлары кайчан ди?

— Кызыксынмадым,— диде Гөлфия, көлү өянәгеннән көчкә тыеп.

— Зерә-ә! Кешеләр белән кызыксынырга өйрән, Фия гөле. Син районда ничә гектар җир сөрелә, ничә баш мөгезле эре терлек үрчетелә — гүпчим бихәбәр. Кемнәр кавыша, кемнәр аерылыша, кемнәр мәхәббәт бакчасында алма өзә — бихәбәр. Идән юарга бик тә лаек үле җан син!

— Сәлимә, син минем бүлмәдә адаштың, әйдә, ишеккә хәтле озатам.

— Үзем дә озаермын. Ни әйтмәктә соң әле без? Ә, иртәгә сессия, сине «ашый» Бабай, нәтиҗәсен миннән ишетерсең, сөенче бүләге әзерлә. Әй, кәгазь, кәгазь!

Сәлимә кычкыра-кычкыра коридорга йөгереп чыкты.

— Җәмәгать балалары, кемдә саргайган кәгазьләр, иске гәзитләр ауный? Миңа, миңа, тиз, сручны!

Идән такталары сыгылмалы басма кебек биеде: халык Сәлимәгә кәгазь ташый иде.

— Китапханәдә үзәк матбугатын актарып ярты көнем узды. Нишлиләр безнекеләр? — дип шаккатты сәркәтип хатын.— Теге Бәйрәмбашның бүлмәсендә олау-олау кәгазь, и аңардан тузан болыты күтәрелә.

— Яп, яп ишекне, Мәйсәрә апа.— Гөлфиянең көлә-көлә ирен читләре авырта иде.— Мин әз генә шаярсам да, ул гел фаҗига белән тәмамлана. Кәбестә кортларын агулый дигән идем, Сәлимә егылып китеп кәгазь җыя.

— Әй-й, наданлык бәласе инде. Баш чүлмәгенең дүрт ягы да тишек: уй тормый, җил себерә. Шуның эше җиңел-җилпене артыннан этеп, өскә үрмәләтәләр тагы. Ирләргә акылсыз хатын-кыз белән эш итүе җайлырак. Каенсеңлемне дә синең урынга куймагайлары. Син хет Әмирулла Дәминович белән тәмле телеңне кызганмыйча сөйләшеп чык. Башыңны тилегә салу — иң әйбәте. Күргәнием Сәлимә белән икегезне үлән арасында, диген. Биш ел элек, диген.

— Күрмәдем шул, күрмәдем, Мәйсәрә апа. Бабайга үпкәм күперми минем. Ниязны рәнҗетүләрем өчен Ходай аның кулы белән җәзалады. Мин ул җәзага разый, бик разый.

— Синең ни гаебең, кызым. Күмер Тауда Нияз эчте. Безгә еш сугыла иде, гел кызмача, мәрхүмкәем.

— Минем бер сүзем аны әлмәктән коткара иде, Мәйсәрә апа. Бер сүзем!

— Әҗәле бугазына терәлгән кешене йөз сүз дә коткармый, Гөлфия Әнвәровна, кызым.

Ишек артында тыела алмыйча төчкерделәр.

— Кайсысы микроб тарата икән? — дип, Мәйсәрә ишеккә төрткән иде, борынын кулъяулыгы белән томалаган Сәлимә:

— Үл-ләм, әптечи! — дип урталай сыгылды.— Үл-ләм, миндә тузанга аллергия. Өч мыек малаена шылтыратыгыз тизрәк, апкитсен кәгазьләрен. Мин аңладым инде моның хикмәтен. Кәбестә кортлары кәгазь тузаны исеннән дөмегә икән. Әптечи!

— Подвалда тычкан тапаган иске гәзит төргәкләре күп,— диде Мәйсәрә. — Алып менимме?

— Тик, кызлар, сарык түшкәсеннән өлеш көтмәгез, Фәрнәснең терлекләре ябык, карга чукырлык итләре юк, шыр сөяк. Әптечи! Исәнлеккә-саулыкка, димисез, ә! Шылтырат инде, Фия гөле, әй, Гөлфия апасы...

Җиңгәсеннән пожымлаган Сәлимә хатасын төзәтсә дә, соң иде инде. Сәркәтип хатын аны беләгеннән боргычлап тотты:

— Нинди гөл дисең? Кайда үсә ул? Кем утыртты?

— У-у, чеметмә, җиңги. Казан утыртты-ы-ы!

— Кемне, кая утыртты?

— Беләгемне кара яндырма, иртәгә утырышка кыска җиңле, ачык изүле күлмәк тектергәнием. Тинтерәтмәсәнә, җиңги! Казан Гөлфия Әнвәр кызын чүлмәккә... Әптечи! Әй, безнең гәзиткә утыртты. Җибә-әр, явыз карчык! Үлдең шушы килмешәкне яклап, әптечи!

— Бичараны алдадык та, кыйнадык та, Мәйсәрә апа,— диде Гөлфия, көлүеннән туктап.

— Улмы бичара? — Сәркәтип хатынның күзләре сагышланды.— Бу зәһәр елан минем бәхетемә чакты. Абыйсы Сәйфихан белән өйләнешкәндә, Сәлимәгә ун яшь иде. Аш пешерсәм, ашыма стаканлап тоз сала, мунча яксам, кайнар суын агыза, самавыр эченә тавык тизәге томыра, бөтен әшәкелеген кеше күзеннән качырып эшли, ә аннан каенанам «уңмаган, ялкау» дип мине битәрли иде. Беркөнне кар базына төштем. Каенсеңел баз капкачын япты да куйды. Өстенә бүкәннәр өйде. Баш түбәсе белән этәм — кузгалмый да капкач, кычкырам — тавыш баздан ары китми! Икенче көнне генә чыгардылар мине. Туры бүлнискә озатасы урынга өй юдырттылар. Авырып егылдым, бөтен тәнемне чуан басты. «Якын бармагыз, чире йогышлы» дип, каенанам су да бирдермәде. Көчкә терелдем, тик балага узарлык сәламәтлек юк иде инде. Сәйфиханны әнкәсе көн-төн: «Аер, аер, ул кысыр», — дип талады. Ирем дә, суктырып-суктырып: «Без кайчан ишәябез?» — дип сорый иде. Кызмача вакытта: «Мине баласыз калдыра-

сың, орлыксыз чәчәк»,— дип рәнҗетте. Без аерылыштык. Авыл кырыенда елга ага, кыш ул сәлә генә туңа, астан кайнар чишмә тибә, диләр, шуңадыр инде. Сәйфиханнан аерылуыма дүрт ел иде, әз-мәз каләм тибрәткәч, үзәккә күчеп, гәзиттә эшләп йөргән чак иде. Яр буйлап әниләргә кайтып барам. Берәү елгадан «Коткарыгыз!» дип кычкыра. Суда хәйран тыпырчынган бугай, тавышы карлыккан. Сумкаларымны ташладым да суга сикердем. Җан иясе төпкә чумган иде, чәч үрмәсеннән сөйрәп чыгардым. Сәлимә! Минем каенсеңел! Миңа аны яңадан суга чумырып алырга иде, шундук тончыга иде. Кер чайкаганда аягы тайган икән моның. Әйдә, яшә, дидем, ярга бәрдем. Мин сине, теләсәм, коры һавада да тончыктырам, дидем. Шуннан бирле койрыгын кысты, елан. Абыйсы ун өйләнде, ун аерды, ахырдан эчеп үлде. Кеше баласының күз яшьләре туфракка сеңми, бигрәк елатты бит Сәйфихан. Мәнсез нәсел инде. Сәлимәсенә утыз яшь, күңелендә эшәкелек тә явызлык кына. Элеккеге мөхәррир итәк колы иде. Сәлимә белән чуалдылар да абзагыз моны хатлар бүлегенә тыкты. Мәхәббәт уты көйрәтеп кенә эшләрен җайлый минем каенсеңел. Әнкәй мәрхүм: «Кемдер фәрман, кемдер дәрман белән»,— дияр иде. Җыен әләм-әтрәк дөньяны бозыклыкка табан борды, кызым.

— Икенче ирең Нәҗип белән бәхетле идеңме соң, Мәйсәрә апа?

— Матур яшәдек болай. Тик яратышмадык. Миннән иде корылык. Сәйфихан сагындыра иде. Нәҗип чирләшкә ир иде, мин аны нык тәрбияләдем, өч ел кашыктан гына ашаттым. Үлгәндә, «бәхил» диде. Сүз йомгагын кая таба тәгәрәткәнне сизәсеңдер, кызым. «Нияз» дип бәгыреңне көйдермә, ул егет белән кушылып яшәсәң, тере мәеткә әйләнер идең. Сөю — бер газап, сөймәү — ун газап.

— Мәхәббәт турында уйларга вакыт тимәде, Мәйсәрә апа.

— Сәгате сукса, вакыты тияр, кызым. Әнә безнең кыекка бер күгәрчен егете оялаган, гөрли дә гөрли. Ник кызарасың, кызым? Ошаса, тилмертмә, диюем.

— И шаян да хатын инде син, Мәйсәрә апа.

Борынын каплаган Сәлимә тагын әйләнеп керде.

— Мин эштә ялт-йолт бит, сенсацион хәбәрем әзер дә инде,— диде ул, Гөлфиянең өстәленә бер бит кәгазь ташлап.

— Җә, җә, укы! Җөмләләрне ничек ваттың-сындырдың икән? — дип, Мәйсәрә язманы Сәлимәгә табан шудырды.

— Кһым... Яңалык өр-яңа хәбәрчедән.

— Хәбәрчесе яңамы, яңалыгымы?

— Бутама, җиңги. Дәвам итәм. Чирлибез кырларны агулаган химик матдәле бодай, арпа, борчак, кишер, суган, кыяр ашаудан, ә шкаф тартмаларында нинди байлык, табигый агу — кыягаз ята, тагы да агулырак ул, саргайса, тузанланса. Вак-вак ертыгыз да сибегез кәбестә бакчагызга, кортлар төчкерүдән тәгәрәп үләчәк. Кыягазга мохтаҗлар гәзиткә — Сәлимә Басыйрова бүлмәсенә мөрәҗәгать итсен. Сату бәясе — ирекле. Шәпме? Әптечи!

— Елга суын күбрәк чөмергәнсең, ахры, каенсеңел. Миең сыегайган,— диде сәркәтип хатын.— Сине юри ирештерәләр, юри! Гаҗәп инде, кеше аңгыра икән — явыз, явыз икән, аңгыра булмый, ә синдә бу сыйфатларның икесе дә бар.

— Минем байлыгымнан көнләшәсең, име, җиңги? Бездә ниләр генә юк шул.

— Әйе, синдәге байлык хисапсыз: син надан, мактанчык, ялагай, гайбәтче. Әйдә, ана каз кебек кагынма, мамыгың оча, чык, мин синең нинди кәмит корбаны икәнеңне һәйбәтләп аңлатам. Иту бөтен миргә рисвай ителәсең. Мәрхүм абыеңның хакын хаклап, бел!

Гөлфиягә дә, шаяруларны онытып, алдагы очрашулар турында уйларга кирәк иде. Кассетаны чүплеккә бәрә, имеш. Ә Дускайны ничек ышандыра? Яттан сөйлиме? Кыз табылдыкны карама агачына сөялеп бер генә тапкыр тыңлады һәм шул җитте: Калын иреннең ясалма тавышы ми күзәнәкләренә үк сеңде. Нигә адәмнең эшәкелеге күлләвек кебек җыела, нигә туфрактан саркымый икән? Ул әнә аякка уралып абындыра-сөрлектерә... Ә изгелек мизгел эчендә парга әйләнә. Юк, бу очрашуны катлауландырырга ярамый: барды, күрде, тасманы тапшырды һәм саубуллашты... Шуның белән, шәт, гомер агачыннан үткәннәрнең бер саргайган яфрагы өзелеп, җир куенына сыеныр... Хатирәләрдә бүтән чокынмаска! Кайчакта адәм баласы сүтелгән җепне эләктерәм дип тотына да тишкәли-тишкәли зур ертык ясый.

Күр син, Әюпов китте дә батты. Бәлки, кәләшен утыртып авылына элдергәндер? Абау, нәрсә бу?! Күңел аның өйләнүен теләми. Җанда көнләшү кебек ят хис яралып маташа...

— Рамил! — Кыз ачык тәрәзәдән генә машина юган шофер егеткә эндәште.— Энем, кер әле.

Көнләшә, көнләшә... Әй, юк ла инде!

— Гөлфия апа, мин монда! «Арба» төзек, аны үз хисабыңнан яматтыра-яматтыра бөлгенлеккә төшмәссең микән, Гөлфия апа?

— Әюпов абыеңны күрдеңме, Рамил?

— Машинасына ниндидер тартмалар куйды да очты ул, Гөлфия апа. Куып тотаргамы? Безнеке дә хәзер канатланды.

— Ачкычларны калдыр да кайт, Рамил.

— Э-э-э, син Салабаш урманынамы, Гөлфия апа? Мине дә бабайның хатынының әнисе аптырата. Мәтрүшкә җыярга аппар, кияү, ди. Юл буеннан гына өзгән идем, юк, ди, сарысы түгел, шәмәхәсе кирәк, ди. Язу карасына манырга гына да бит миңа, башсыз!

Гөлфиягә юлдашлар иярткәнгә ярамый иде. Сыңар күз кабат ярты сукмактан борачак...

— Берсекөнгә «арба» синең карамакта, энем. Туйганчы йөртерсең әбиеңне Салабаш хозурында.

— Бер капчык алтын күмгәннәр, дисәләр дә, анда аяк басасым юк, Гөлфия апа. Безнең әти заманында аланда умарта асрады. Ул бытылдаганнарны тыңласаң, бала йоннарың кабара. Берсендә, ди, кичкырын, кояш биек нарат башыннан туп сыман аска тәгәрәгәч, ди, ятып йокладым, ди. Төнлә текерт-текерт иткән тояк тавышына уяндым, ди. Чыксам, умарталыкка унлап сарык килеп керде, һәммәсенең дә йоны аксыл-зәңгәр, ай яктысында җем-җем итәләр, ди. Бер-берсенең койрыгына терәлеп үк чабалар, ди. Авылныкылар адашкандыр, бүре-фәлән бугазламасын дип, боларны ат абзарына яптым, ди. Ишекне терәү белән терәттем, ди. Иртән, авыл юлына табан куармын дип, абзарны ачсам, ди...

Рамил калтыраган кулларын йозаклады.

— Шуннан, тел бистәсе?

— Әти алдалый димә, Гөлфия апа. Бик дөрес кеше ул безнең, кушаматы да Хак Габделхак аның. Э-э-э, абзарны ачсам — сарыклар үтүт, ди. Качканнар дисәң — ишек терәүле, тишек дисәң — алар сыярлык тишек юк, ди. Мулла абзый: «Җеннәрне япкансың син, Габделхак»,— дигән, э-э-э, Гөлфия апа. Икенче бер очракны да сөйләде әти.

— Син клубтан кызлар озатмадыңмыни, Рамил?

— Э-э, озата идем, аннары үзләре мине киредән озата иде. Бүгенге хатын баскычка ук бастырып китә иде әле. Икенчесендә, ди, әти...

— Үзең сөйлисең, үзең куркасың, энем.

— Монысы кыска, Гөлфия апа. Э-э-э, җигүле ат белән Салабашка менеп барам, ди әти. Каршыма биләсипиткә атланган ике ир җилдерә, ди. Көн кызу, комда тавык йомыркасы пешәрлек, ди, боларның башында бүрек, ди. Әй зыр-зыр әйләнә, ди, тәгәрмәчләре җилдән дә хәтәр, ди, йөрүләре. Тәртәгә бәрелмәсеннәр дип, дилбегәне кырыйгарак тарткан идем, җир йоттымыни, ирләр юкка чыкты, ди. Вәт җеннәр алдады, ди әти. Йөрмә ул Салабашта, Гөлфия апа. Нияз абый дип инде, э-э-э, үлмиләр инде.

— «Ике аяклы шайтаннар»дан сакланыйк без, энем. Алар куркыныч хәзер.

— Әлсә, мин китим, Гөлфия апа. Безнекеләр чатыр чабып туйга әзерләнә. Бабайның хатынының әнкәсе кияүгә чыга, туксан яшьлек егеткә димләттергән иде. Ялгызыма күңелсез, ди. Кияү мунчасына каен утыны ягыгыз, пар чыжламаган газ мунчасында юынмыйм, ди әби-кәләш. Өй артындагы урыс каенын кисәм, барыбер каргалар баш түбәсенә сыек-сыек «сәламнәр» тамызып җәфалый.

И тормыш, тормыш... Уң канатында еласалар, сул канатында көләләр. Сөенеч белән көенеч берберсе белән ярыша. Әмма сөенечнең адымнары кыска, ул килеп җиткәндә, көенеч аягын бөкләп түрдә утыра. Аны тиз генә куып та төшерә алмыйсың. Озакка сузылды-ы... Нияз хәсрәте. Әй-әй-әй! Кешеләр кебек көлеп-шаярып кына яшәп булмады, көенечтән көйгән бәгырь күмерләнеп бетте. Вакыт Гөлфияне дәваламады, вакыт әллә туктады, әллә кызны читләтеп үтте. Әллә ул үзе бу сызлануларыннан арынырга ашыкмый, мәңге вөҗдан газабы кичереп яшәргә уйлыймы?

Арынам, дигән иде бит инде, соңгы тапкыр Салабаш урманы белән саубуллашкан иде, ә тәкъдир «ашыкма» диде һәм менә сиңа, янә үткәннәр белән бер чылбырга бәйләде. Елан-сукмак, һай, елан-сукмак! Ник аяк астында бөгәрләнеп яттың икән син?! Җанга, караңгылык пәрдәсен тишеп, нәни генә яктылык сирпелгәндә, синең урман башында ук кырт итеп киселүең хәерлерәк иде ләбаса. Үткәннәрендә генә торып калалмый кыз, юк, калалмый. Аңа яшәргә кирәк. Тормыш — озын-озын сәфәр, ә адәм баласы — юлчы, үлем генә чакрымнарны кыскарта, үлем генә алга барырга чик куя. Димәк, Аллаһы бүлеп биргән елларга сөенеп яшәргә дә яшәргә әле. «Гашыйк... Тагын гашыйк... Тагын-тагын гашыйк...» Акыл: «Әйтмә, Әюпов, әйтмә!» — дисә дә, йөрәк: «Кабатла»,— ди, чөнки ул кайгыдан кысылып-бөрешеп арыган, бәлки, аның сөенечтән шашып тибәсе киләдер. Чү, йөрәк чынлап та сорый, үтенә, ялвара: «И хатын-кыз, мәхәббәт давылында бөтерелеп бер ярат инде син!»

### 6

Кемдер аяк чалды... Ул, канатларын җәйгән кош кебек, гөлҗимеш куагына егылды. Кызгылт-кара җимешләр белән бизәнгән көяз куак үзен таптаган кешене өнәмичә, йөз дә бер шырпысын тәнгә када-ды. Авыртса да елмайды Гөлфия. Шофер егет сөйләгәннәр уйдырма дип көл менә. Кыз, төртеп еккан затны күрергә дип, як-якка күз ташлады. Тып-тын... Имәннәр үрә каткан, каеннар талгын җилне тарак итеп яфрак-чәчен тарый... Гөлфия күлмәк итәкләрендәге чүп-чарны сыпырырга дип иелде дә турайммыйча торды. Бер җепкә тезелгән кырмыскалар сафы сукмакны аркылы чыга иде. Менә кемнәр еккан икән. Ашыгып барганда, безне үкчәң белән сытма, дигәннәр. Меңләгән бөҗәкнең күченү процессы озакка сузылыр дип, ул «сәяхәтчеләр» өстеннән атлап кына үтте.

Төнлә, уянып: «Шулай-шулай әйтермен»,— дип, күңеленә беркеткән иде, ә хәзер ул сүзләр нигәдер мәгънәсез тоелды. Кичке уй таң атканда суына икән. Әманәтне кулына тоттырыр да дәшмичә генә кире борылыр. Түрәләр белән кем өйрә пешерә! Аларны кешеләрнең аһ-зарын тыңламаска махсус өйрәтәләр бугай. Аңлар ди ул синең биш ел бәгыреңне телгәләгән хәсрәтеңне, көт!

Черт-черт коры ботаклар сынды. Әһә, аны күзәтәләр. И газиз Аллам, үзең сакла да үзең якла. Әнә, әнә теге шайтан кавеме — Сыңар күз кул изи. Елан-сукмакны ят күзләрдән яшергәннәрмени, баш «яфрак төшәме»нә бәреlә. Кызның алдыннан юырткан Сыңар күзнең табаннары гына ялтырый. Яртылаш бөгелеп барды Гөлфия. Дымлы һава болай да йөрәкне кыса, ә ул, җитмәсә, җиргә йөзе белән кадалып, черегән яфрак исе дә сулый иде. Ниһаять, «төшәм» биегәйде, кояш яктыртты, алар түгәрәк аланга килеп чыктылар. Алабай лас-лос атлый, аның артыннан иярер өчен, туктаусыз йөгерергә кирәк иде. Алда — соңгы тукталыш түгел икән, яңадан урман ешлыгына чумдылар. Салабаш — яшел дәрья ул, диләр иде, хак икән. Мөгаен, моның бер очы офыкларга тоташкандыр. Сыңар күз аны адаштырырга уйлый мәллә, Ходаем? Кыз, кире чыгар юлны тамгаларга дип, күккә карады. Күкне дә яфрак болыты томалаган иде. Менә сыек яктылык күзне камаштырган нур белән алмашынды: алда иңләп-буйлап атлар узыштырырлык киң алан җәйрәп ята иде. Монда куна-төнә яшиләр иде бугай, бер читтә тәбәнәк кенә ызба, аның янәшәсендә озынча абзар, ары табан морҗасы корым белән буялган мунча... Кирпечтән өеп ит кыздыру җайланмасы да көйләгәннәр.

Сыңар күз, һаман шулай башын игән килеш, ызба ишеген ачып җибәрде. Эчтә караңгы иде, кыз ирексездән бусага төбендә төртелеп калды. Түр сәкедән:

— Тиз табышкансыз,— диде карлыккан тавышлы берәү. Һәм, тамагына бөялгән ташны этеп төшерергә теләгәндәй, каһ-каһ йөткерде. Алабай тәрәзәне каплаган пәрдәнең читен күтәрде.

Гөлфия, түрдә ят кеше абайлап, уф, дип, ишек яңагына сөялде. Ялгышты. Дускай түгел лә бу адәм. Ниндидер авыру карт белән көрешер өчен күпме көч түгелде дә күпме исәнлек югалды. Аны «үлде» диделәр бит инде, ахмак кыз! Мәетләр ахырзаманда гына кабереннән кубарылачак лабаса!

Йөткерүен баскан карт:

— Тартынма, уз,— диде.— Сырхаулаган идем мин. Җәй көне салкын тисә, тиз узмый. Бер-ике көн кояшка күренмим, эсседә суык күкрәккә үрмәли, аны салкынча ызбада ятып кудырырга кирәк.

Әй Раббым, нинди тамашада катнаша ул бүген?! Тавыш — аныкы, җыерчыкланган маңгай, агарган чәч — бүтәннеке...

— Уз, уз, Гөлфия Хан. Без кичә үк күрешергә тиеш идек тә... чир бит. Йөзегеңнән таныдым мин. Алабай бабайга рәнҗемә, ул мине күз карасыдай саклый. Арттыра да инде әзрәк.

Кыз түргә үк үтәргә базмады, урындыкка төртелде. Җилкәсенә элгән нәни сумкасын итәгенә куйгач, тыштан гына капшады: табылдык исән-имин генә урман кичкән иде. Тик аны «мә» дип кенә бирәсе килми, чөнки Гөлфиянең күз алдында сәер күренеш пәйда булган иде. Биш ел элек Хакыйкать биеклегенә үз юлымны ярам дип гайрәтләнгән мәгърур бөркетнең нишләп канатлары өтелгән дә төтелгән соң?

— Аптырама, Гөлфия Хан,— диде Дускай, аның уйларын сизгән сыман.— Дөнья ул бер алдын, бер артын күрсәтә. Кем син: баймы, ярлымы, хакимме, көтүчеме — аңа һәммәсе дә тигез. Алабай, миңа чишмә суы, кунакка үлән чәе керт.

Сыңар күз бу әмергә теләмичә генә буйсынды.

— Алабайның үз-үзен тотышына шаккатма, Гөлфия Хан. Минем фаҗига тетрәндерде картлачны. Әнкәсеннән дә шикләнер иде бахыр.

Кыз каушый һәм туктаусыз бармагын тыгызлаган көмеш йөзекне әйләндерә иде. Дускай биш ел элек котырынган давыл турында оныткан бугай. Монда хәзер өр-яңа хәлләр, өр-яңа вакыйгалар калыккан, ә Гөлфия үткән белән бүгенгесен ялгарлык җеп табалмыйча йөдәп утыра иде. Ә үткәннәрне, җан белән хәтер никадәр генә карышса да, кузгатырга кирәк иде. Дускай, син алардан качма, яме, качма!

— Хантимер... Фаҗига, дидең. Барысы да шул язмадан башланды бит.

— Тәки хәтерне уятасың, Гөлфия Хан.— Дускайның тавышында ризасызлык чагылды.— Әйе, минем фаҗигам белән ул язма арасында бәйләнеш бар. Без өчебез дә — корбаннар. Син дә, баш мөхәррир дә. Минем җелегемне бер генә сорау киптерде. Кем саткан? Нияз Сафин исемемне ычкындырса, үз-үзенә кул салмас иде. Сатлыкҗаннар яшәүгә чытырдап ябыша, алар, кеше сатып, зур бүләкләргә коена, зур дәрәҗәләргә ирешә. Син акыллы хатын, әйт, кем саткан?

Гөлфия чертләтеп күн сумкасының тимер бигеен ачты. Бәләкәй янчыкның бавын чишеп, көзгә алды.

— Күземә чүп кадалды, ахры,— диде.— Табышмак-сорау бу, белмим, Хантимер, — диде.

«Беләсең, беләсең!» — дип ысылдады сумка. Гөлфия тиз генә аны йомарлап, итәгенә кысты.

Алабай чәй кертте. Сулыштан парланган ызбага үлән исе таралды.

— Кем саткан? — диде иягенә таянган Хантимер.— Кем, кем? Шуны уйласам, башым шар кебек кабара да дөньяга сыймый башлыйм. Язма турында син дә Эдуард кына белә иде. Икегез дә намуслы халык.

— Бәлки... бәлки, Эдуардка сатлыкның исеме мәгълүмдер, ә?

— Юктыр. Ул өч хәрефле бина тирәсендә чуалмады. Фән кешесе сәясәттән ерак.

— Алай да сорашырга иде.

— Чәең суына, эч, «җир асты патшалыгыннан» мин әле генә кайтып барам, Гөлфия Хан. Фани дөнья исемлегеннән сызылган кеше дусларына да, туганнарына да кирәкми әле ул. Һәрхәлдә, мин үземне белгертергә ашыкмыйм.

Хуҗа сәкедән торды.

— Әйдә, бу күңелсез сөйләшүне төгәллик. Синең хәлләр ничек?

— Эшлим.

— Шуннан?

— Ашыйм.

— Шуннан?

— Йоклыйм.

— Миллионлаган кешеләр шөгыле бу. Язасыңмы, дим? Нәрсәләр язасың?

— Язмыйм, Хантимер.

— Нишләп, Гөлфия Хан? Күмер Тауга кудылар дип, борыныңны салындырма син.

— Файдасы юк, Хантимер.

— Ничек файдасы юк? Тукран чүпләмәсә, урмандагы агач-куакларны да, язучы каләмен эшләтмәсә, җәмгыятьне дә сорыкортлар баса. Бүген укымасалар, киләчәктә укырлар. Сез — әхлак сакчылары, Гөлфия Хан.

— Кәнәфиеннән очкан һәрбер түрә шулай акыл сатамы ул? — диде кыз, үчләшеп.

— Чур, Гөлфия Хан! Мин беркайчан да үземне Алланың кашка тәкәсе дип санамадым. Атлар белән аунап үскән авыл малае, зиннәтле сарайдагы алтын белән каймаланган тәхет култыксасына таянса да, ат тизәгенең исен сагына. Ни өчен түрәләр бозык һәм надан? Алар табигый тормыш фәлсәфәсен өйрәнмәгән, алар система колы, ә анда ясалмалык, икейөзлелек... Син акыл ияләре фәйләсуфларны кара, кешелек канунын ничек бозмаганнар, ә? Зирәк фикерләр Югары Аң белән тоташкач кына туган, безнең коммунистлар партиясе кебек бармактан суырып уставлар язмаганнар бит!

— Югары Аң белән тоташыр өчен кеше үзендәге «мин»не табарга тиеш, Хантимер.

— Бәхәсләшмим, Гөлфия Хан. Кеше ялкау, эзләргә иренә шул. Ә эзләнүнең юлы — гыйлем. Ул сиңа көрәк белән матди байлык көрәү түгел инде. Инә белән кое казу, диләр аны. Озын сүзнең кыскасы, син миңа түрә дип нәфрәтләнмә. Әйдә, Сылукай белән таныштырам. Ат ул, хатын-кыз дип уйлама.

Нинди хәйләкәр син, Дускай. Ат белән алдалап, җеп очын яшермәкче буласың! Гөлфия дә чеген арбасыннан төшеп калмаган, синең хәйлә йомгагын тиз сүтәр.

— Иртәгә килсәм, шәт, ачуланмассыңдыр, Хантимер? Сылукай белән шунда серләшербез.

Колагын шомрайткан Сыңар күз ачу белән теш шыгырдатты.

— Әһә, безнең картлач җенләнә. Тынычлан, Алабай, бу безнең кыз, аңардан зыян-зәүрәт күрмәбез. Рөхсәтме?

Әмма Сыңар күз хуҗасына буйсынмый иде.

— Ник килгә-ә-ән? — диде ул, сузып-сузып.

Мәгънәле сорау... Әйе, ник килгән? Казанда нибарысы ике тапкыр очраштылар. Дус та, туган да түгел. Тасманы бирергә туры килер, ахрысы... Бердәнбер сәбәпчесе шул гына иде. Ул чакта урманга юл ябыла, һәм Гөлфия «теге дөньядан кайткан» Хантимер Әхмәтовның сереннән мәхрүм кала. Ул күзен дә йоммыйча алдады:

— Нияз... Нияз вафат димәкче идем, ә сез беләсез икән инде,— диде.

Хантимер яратып картның җилкәсеннән какты:

— Ну, тынычландыңмы, Аллаетдин абзый? Каш җыерма, иртәгә дә чакырабыз Гөлфияне. Синең энекәшең матур хатыннар белән гәп корса, ни гаебе? Йә, кунакны иплэп кенә озат.— Хантимер ике якның да хәтерен сакларга тырыша иде.— Карт инде безнең Аллаетдин абзыебыз, сиксәнгә табан кыяклады. Аякта — җитезлек, башта — акыл, яшьләр көнләшерлек. Хуш, Гөлфия Хан!

Мактаулардан Сыңар күз йомшарган кебек тоелды. Картның үкчәсенә үк бәрелеп барган кыз:

— Нишләп Хантимер Әхмәтов урманда яши? — диде.

Җавап булмады. Ә сораулар бихисап иде. Биш елда ир-ат шулай ук картаямы? «Җир асты патшалыгы» үлеп терелүгә ишарәме? «Минем фаҗига белән ул язма арасында бәйләнеш бар»,— диде. Хантимерне ыбыр-чыбырлар, шау-шу куптармыйча гына «җыештырырга» маташтылар микәнни? Бүрене бүре чәйнәми дип йөр менә! Алар да өерләргә бүленгән шул. «Кем сатты?» — ди. Ахмаклык белән беркатлылык арасында буталган сорау... «Өчәү белә, шуларның берсе, һичшиксез, сатлыкҗан»,— дип шикләнми. Болында аунап үскән самими авыл малае! Ат сыман, дуслар да хыянәтсез җан дип исәпли.

— Син энекәшне күр-рмәдең, ул үлек,— диде Сыңар күз, «р» хәрефен икеләтеп.— Бер-рәр-рсенә сүләсәң, үтер-рәм!

— Вәгъдә — иман,— диде Гөлфия.— Иртәгә мине каршылап мәшәкатьләнмә, Аллаетдин абзый. Хәзер кыргый сукмакка ияләштек инде.

Карт, ярсу ат кебек башын чайкап, аягы белән дык-дык җиргә типте.

— Үзем кар-ршылыйм!

— Ихтыярың, Алялетдин абзый. Сакал-мыегыңны кыр, яме! Син бит чибәр генә кеше,— диде кыз, дустанә елмаеп.

Ул күңеле белән генә урман капкасын ябып, куак ышыгындагы машинасына табан юнәлде.

— Сезне Салабашның баш шүрәлесе сәламли, туташ. Исәнмесез! — диде таныш тавыш.

Гөлфия, борылмыйча гына:

— Олы юлда очрашабыз,— диде.

Сыңар күз уяу иде, ул посып кына дөньяны күзәтә иде. Әгәр аның ышанычын акламасаң, эш харап. «Безнең биләмәдә чит кешеләр чуала» дип, Хантимерне сагайтуы ихтимал.

Җәүдәт, узып китеп, олы юлга менә торган сөзәк урында машинасын аркылы бастырды. Беркая да качмыйсың, янәсе. Качарга җыенмый иде Гөлфия, ул, тәрәзә пыяласын аска шудырып, көлә-көлә:

— Әллә туеңа чакырасыңмы? — диде.

— Чакырам. Янәшәмдә урын буш,— диде егет.— Ник без урманнан табан ялтыраттык соң әле?

— Бүтән мине сагалап йөрмә, Әюпов.

— Ачуланма, сагындым, Гөлфия...— Җәүдәт авыр сулады.— Җитәр, бәлки, сиңа. Болай акылдан шашарсың бит беркөн. Нияз Сафин асылынган җиргә йөрисең икән син. Гайбәт тыңлый димә, әйтте шунда бер тел бистәсе. Ник яраттыңмыни соң шул җегетне?

— Ул минем дустым иде...— Кызның ике күзеннән әчеттереп яшь бәрде.— Дустым иде, чын дустым!

— Дус, дип... Аңа Газраилне син җибәрмәгәнсең бит инде...

— Мин җибәрдем! — Гөлфия балаларча үксеп-үксеп еларга тотынды.— Мин, мин!

Нигәдер менә шушы гап-гади җир кешесе аның Галәмгә дә сыймаган серен сыйдырыр кебек иде. Сүзләрен күз яше белән чылата-чылата сөйләде дә сөйләде кыз. Бүлдермәде Җәүдәт, аның йөзе кырысланган, йодрыгы кысылган иде.

— Вәт тинтәк! Дустының башын ашаган, ә! Нияз Сафин сатлыкның тавышын тасмага яздыртып дөрес эшләгән. Мин ул кабахәт җанны буар идем. Кем ул, ни атлы?

— Хәтерләмим,— диде Гөлфия һәм ашыгып тагын кабатлады:— Хәтерләмим.

Хәтерли иде. Йөз елдан соң да бу исемне онытасы юк. Шуны әйтергә тел генә карыша иде. Әйтеп ни файда?

Дуамал авыл баласы кызып китеп кибән яндырырга мөмкин, ә Калын ирен кебек кызыл чырайларга ул капка аша да төкерә алмаячак.

— Ярар, Әюпов, еладык та, җырладык та, машинаңны ал инде,— диде Гөлфия.

— Ашыкма, безнең ише авыл гыйбадлары сай фикерле дисәгез дә, тирән сөргән чаклар да булгалый. Хәйлә-мәкергә өйрәтмәделәр, табигатьтән бирелгән сизгерлек белән яшибез, Аллага шөкер. Нияз белән язма авторы Хантимер дә мәрхүмнәр. Сатлыкҗан бәндә исән дә, син, минем бәхеткә, исән. Бергәбер, әйеме? Ә-ә, кассета бар. Сез өчәү! Ә көч синең якта, Гөлфиякәем. Казанның иң биек тавына менеп яңгырат аның тавышын. Танысыннар эт җанны!

— Көлдермә, Җәүдәт.

— Их, сай сөрелде. Андый тешләк бөҗәкләр меңәрләп-меңәрләптер ул, һәммәсен дә яңгыратсаң, Җир шарында таулар җитмәстер.

Мөлдерәмә тулы күңелен бөтенләй үк бушатмады Гөлфия. «Сизгерлек белән яшибез» дисәң дә, сизмисең, егет, юк, сизмисең. Калын иреннең исемен дә, урмандагы хикмәтләрне дә синнән яшерде кыз. Кичер, ул артык сүздән нигә сакланганын үзе дә аңламый. Кемдер «сер чәчмә» дип кисәтә... «Үтеррәм» дип янаган Сыңар күз дә сыман ул, чал чәчле Хантимер дә кебек, ялгышлардан арыган йөрәк тә төсле. Югыйсә кыз шушы ихлас ир-егеткә алдар идемени?! Нишли соң Гөлфия, Ходаем? Гомердә ялганны яратмады, аны иң чиркандырган нәрсә алдак бәндәләр иде.

Ул, егетнең гөнаһсыз күзләреннән уңайсызланып:

— Кайтыйк,— диде.— Көпә-көндез юлда сөйләшеп тормыйлар.

— Тагын Бабай эштән куа дип, дер калтыратма инде син. Рәисләргә кытлык юк бездә. Миңа хәтле ун кеше эшләгән, унысы да авылда, ә унберенчесе запаста.

Олы юл белән Салабаш урманы арасында чакрымнар ятса да, Сыңар күзнең теш шыгырдатуы ишетелә кебек иде. Картның ачу ташын кыздырмаска кирәк. Юнмаган агач бит ул: кытыршы һәм тупас. Хатын-кыз дип әдәп сакламый, сугып ега. Дан-дәрәҗә, акча-байлык белән бозылмаган бу беркатлы җир баласын тыңлавы да рәхәт. Йомшак сөйләп катыга утыртмый, ул риясыз, хәйләсез. Көн дә нинди матур. Җиһанга зәңгәр күзләре белән баккан күк ап-ак мамык шәлгә охшаган болытларын иңнәренә бөркәгән. Түгәрәк йөзле ромашкаларның керфегендә шул аклыкның дәвамы... Бу дәвамның дәвамы — җанда. Мәхәббәт тә ак төстә икән. Шуңа күрә күңел аны шик-шөбһәләрсез кабул итә дә каралтмыйм дия-дия яраланып бетә. Ник гашыйк кеше мәхәббәтен югалтмас өчен җан тартыша? Яра лабаса ул, нибарысы әрнүле яра. Аңардан дәваланасы да котыласы бит, ә гашыйк, киресенчә, сызлануларын өсти-өсти, ярасын тирәнәйтә. Алсу томанга уралган тагын бер мәңгелек табышмак-сер!

— Мин синең кулъязмаларыңны чүплеккә ташламадым, Гөлфия. Ертылганнарын ябыштырдым.

— Укыдыңмы?

— Юк, рөхсәтсез ярамас дидем. Башта икәү укырбыз, аннары балалар белән...

— Нинди балалар?

— Һы, безнекеләр. Ике кыз, ике малай үстерербез, иншалла.

Әйтерсең алар ир белән хатын иде. Егетнең күзләре усал ялтырады.

— Мин сине кисәтәм, кызый, каты кисәтәм. Тасманы сыздырт, сатлыкларны оныт, дустың Нияз Сафиннан гафу үтенә-үтенә урман айкауларыңны туктат. Иту, бер җилле көнне бензин сибәм дә Салабашка ут төртәм. Аның эче тулы коры агач, жырлый-жырлый яначак.

Җәүдәт шаярмый иде... Кыз да бу коллыкка риза иде. Иректә иркенәеп, никадәр генә тугарылса да, иртәме-соңмы хатын-кыз ир, бала-чага мәшәкатьләре төягән тормыш арбасына җигелә. Гөлфия, берара үткәннәр белән бәйләгән урманны артка чигереп, иркен өйдә йөрде, аш бүлмәсендә тәмле-тәмле ризыклар пешерде, балаларын үбеп йоклатты, тәрәзәдән күзен дә алмыйча ирен эштән көтте... Акыл исә утырып уйлады: ай-һай, җаның тыныч булыр микән? Башлаган эшеңә соңгы ноктаны төртмичә, өтер белән генә тәмамлау синең табигатеңә яраклы гамәл микән әле ул?

— Миңа боерма, яме, Әюпов,— диде кыз, салкын акыл тарафына авышып.— Мин дә соңгы тапкыр кисәтәм: артымнан шымчылык итсәң, сиңа да бер шырпы табылыр.

Егет учы белән күкрәген уды:

— Йөрәкне болай да ялкын чорнаган, чытыр-чытыр яна,— диде.

— Яна, имеш! Нишләп әле син ике төрле сөйләшәсең? Бая гына тау башына менеп сатлыкҗаннарның тавышын яңгыратырга өндәүче кеше син идең бит!

— Мин идем, мин. Шуннан нәстә? Нинди нәтиҗә? «Сафин, Сафин» дип, урманда саташып йөрүләреңнән кемгә файда?

— Ярсыма, Әюпов!

— Ярсысам ни! Сине бәхетле итәргә минем хакым юкмыни? Яратам мин сине, башсыз кыз!

## 7

Иртән бүлмәгә ясанган-бизәнгән Сәлимә керде.

— Фия гөле, бүген чираттан тыш утырыш, әзерлән, сиңа Бабай кул болгый,— диде җиңү тантанасыннан исергән хатын.— Фәлинов, ул да, ягъни син дә, катнаша, диде. Казаннар кузгаттырмый, дип кәпрәя идең, безнекеләр кузгаталар әнә. Мин дә чакырулы, мине «баш» итеп раслыйлар. Һай-һай, кабинет сәләмә, еврейремонт ясатырмын, ахры.

— Язганда хата җибәрмә: евроремонт, Сәлимә.

— Өстәл-урындыклар да искергән. Вапше чүплек оясы!

— Алла, кай арада минем аша уздың, чебен! — дип дулаган Мәйсәрәгә, кыз:

— Мин түзәм, рәхәтләнеп безелдәсен,— диде.— Дөньяны чебен сырган бит инде.

— Безелдимме, чекердимме, нишләсәм дә тыңларсыз! Чөнки мин — баш! — диде Сәлимә.

— Син — муенсыз баш,— диде сәркәтип хатын һәм чакырылмаган кунакны, кулыннан сөйрәп, бүлмәдән чыгарды.— Алдыңнан артың матур!

«Алалар» хәбәре Гөлфияне аяктан екмады. Горурлыгың өчен кайчандыр бер түлисе була. Һәр гамәлгә түләү бар: яхшыга да, яманга да. Ярар, илдә чыпчык үлми. Нәрсәдер югалтсаң, нәрсәдер табасың. Дөнья бушлыктан гына тормый. Менә ул да авыр чакта таяныр кешесен очратты. Менә ул да яратуы белән китек күңелен түгәрәкләде...

Ләкин хакимияттә дөнья икенче төрле болгана, беркемдә дә Гөлфия Хан кайгысы юк, Казан түрәсе Бабай урынына яңа хуҗа китергән иде. Беренче рәткә елышкан кыз утыргычы белән бергә упкынга тәгәри язды: күз аллары караңгыланып, залдагы тавышлар ерагайгач, чытырдап урындык тоткасына ябышты. Сәхнәгә өч ир-ат менә, шуның уртадагысы... Калын ирен иде. Нәфрәт кызның муеныннан буды. Ник аларның юллары яңадан кисеште икән, йа Ходам! Залда кул чабалар иде. Ул ярдәм сорагандай артына борылды һәм Җәүдәтнең күзләре белән очрашты. Егет аңа елмаеп баш селкеде.

Ә сәхнәдә Казан түрәсе нотык сөйли иде. Халык Бабай китә дип сөенә, халык яңа хаким бәхеткә күмә дип өметләнә. Кайчакта искегә тимәвең хәерлерәк. Моннан соң тормыш бакчагызны аллы-гөлле чәчәкләр бизәр дип уйлыйсызмы, адәм балалары?! Сезнең каршыгызда — тере сатлыкҗан. Ул бу җирдә хакимлек итү түгел, аның изге туфрагына сыңар аягы белән дә басарга тиеш түгел иде!

Озатулар һәм каршы алулар тиз башкарылды. Зал гүелди, берәү дә таралырга ашыкмый иде. «Яңа»ның сәхнәдән төшкәнен күзәтәләр, ә ул Казан түрәсенә бармакларын бөгә-бөгә нәрсәдер саный да саный, котларга дип аның тирәсенә сырышкан ялагайларга кулы буш түгел иде. Ә андый халык чыдам, чиратын көнозын көтәргә дә риза.

Гөлфия чыгып китмәкче иде, «уен»ның икенче өлеше белән мавыгып, ирексездән туктады. Бабай янында кеше юк иде... Чәчәк бәйләмен тотып, сәхнә кырыенда таптанган Борчак патшасы нишләргә дә

белми, ул аптырауда иде. Әле генә патша иде, әле генә... Мизгел эчендә таҗын салдырып, тәхеттән сөрделәр. Ә аңа халык белән бер сафка тезелүе авыр, ул бу халәтенәияләшеп тә өлгермәгән. Менә адәм баласы кайчан кызганыч була икән.

— Әмирулла абый, әйдәгез, мин сезне озатам,— диде кыз.

Тәхеттән мәхрүм ителгән патша, өмет белән уңга-сулга карап:

— Кайда соң бу малайлар? — диде.

— Урынбасарларыгызмы? Алар сезнең алмаш белән исәнләшергә дип чиратка басты, Әмирулла абый. Залда бөркү, ә сез нык тирләгәнсез, әйдәгез урамга, әйдә!

Гөлфия аны култыклап алды. Зал һаман айкала-чайкала иде.

— Сине яшәтмәдем мин, Хантимерова, да-а. Каргыйсыңмы?

— Безгә бер Алла хөкемдар, Әмирулла абый.

— Син артык киребеткән бит, Хантимерова.

Ишегалдында Борчак патшасы, тагын онытылып, шоферына кычкырды:

— Бадыйков, живо!

Кара «джип»ның ишеге бикле иде.

— Монысы да чиратта икән,— диде Патша, айнып, һәм хәзер генә үзенең хәлен аңлап уфырды: — У-у-уф! Шул-лай, Хантимерова. Эшлисең-эшлисең дә, беркөнне сине юынтык су кебек урамга түгәләр. Мин урламадым. Урламагач, кемнәрнедер алтын табактан ашатып та булмады. Алар сараннарны яратмый. Да-а, ы-һым, да-а.

Иске хуҗа яшьләнгән шар күзләрен күк йөзенә төбәде. Ап-ак болытларга канат очын мана-мана, кошлар оча иде.

— Биектән егылганда авыртадыр,— диде Гөлфия.— Күк бит ул кулсыз, озак күтәреп тора алмый, тикмәгә генә кошлар вакыт-вакыт җиргә кунмыйдыр инде.

— Әче телле син, Хантимерова. Кызганып залдан җитәкләп чыктың да, хәзер чагасыңмы?

Машинасын атлатып кына ишегалдына Рамил кереп бара иде. Гөлфия аңа кул изәде.

— Әмирулла абый, утырыгыз. Кәефле чагында безнең музей экспонаты ике-өч чакрым гына үтә. Сезнең өегез ерак түгел бит.

— Рәхмәт, Хантимерова. Чаксаң да, синең угың шифалы.

— Хәтерлисезме, биш ел элек безнең беренче танышу «күрдең-күрмәдең» белән башланган иде. Чын мәгәр, мин сезне урман буенда күрмәдем, Әмирулла абый.

— Да-а, син киребеткәннең дә киребеткәне, Хантимерова,— дип, Борчак патшасы йөз ямаулы машинага үрмәләгәндә генә, ишектән халык ташкыны агылды.

— Гөлфия Хан! Качма, тукта! — диде «ташкын»ны иярткән «эре дулкын».— Син что, дусларны не признаешь? Мин сразу таныдым, беренче рәттә татарның популяр писателе сидит.

Гөлфия шофер егеткә кузгал дип ымлады. Их, Бабай белән озак саубуллашты, югыйсә ул шушы сатлыкның калын иреннәренә ягылган ясалма елмаюын күрмәс өчен әллә кайчан койма артына посарга тиеш иде.

— Исәнмесез, Эдуард әфәнде! — диде кыз, йөзенең җил аударган өй кыегы кебек кыйшайганын тоеп. Нәфрәт ничек үзгәртә!

— Ник котламыйсың, Гөлфия Хан? Бүгеннән мин Күмер Тау главасы,— дип, Калын ирен гөл чүлмәген хәтерләткән йомры башын горур гына өскә чөймәкче иде, муенсыз баш селкенмәде, оясындагы күзләр генә төпкә тәгәрәде.— Рәхмәт коммунистлар партиясенә, то есть хөкүмәткә, ышанып Күмер Тауны поручил. Дамы, Рубин Садыйкович?

Казан түрәсе ым белән генә «әйе» дип җөпләде, сәхнәдә сөйли-сөйли аның сүз запасы саеккан иде бугай.

— Без хөрмәтле Рубин Садыйковичны границага хәтле провожаем, бездән калма, Гөлфия Хан. Син как-никак пресса, хакимиятнең «бишенче тәгәрмәче». Кайда моторың?

— Монда, монда, Эдуард Әминович,— дип, төркемнән Фәлинов атылып чыкты. Аның чабуына Сәлимә дә тагылган иде.

— Ашлы-сулы җирләрдә мине йөртәләр ич, Сабир Сабирович!

— Аяк астында буталма! — диде аңа аппарат җитәкчесе һәм, моңарчы ачмаган караңгы чыраен балкытып, Гөлфияне үз машинасына әйдәде:— Рәхим итегез, ямегез!

«Юк!» дип, аяк терәп карышса, ул үзен көлкегә генә калдыра иде. Утырды кыз. Фәлинов та аның янәшәсенә төртелде.

— Менәтерә, Эдуард Әминович белән дуслар икән сез, Гөлфия Әнвәровна! — диде ул, маңгай тирен җиңе белән генә сөртеп. Кесәсеннән, тыгылып, кулъяулык эзләмәкче иде, кулы калтырады.

Әгәр Гөлфия адәм заты белән сөйләшсә, бу дуслыкның бәясе сукыр бер тиен, дип аңлатыр иде, ә монда ике хуҗага да койрык болгап остарган ялагай утыра. Өстәвенә ул куркак та иде.

— Әйе, без шәп дуслар,— диде кыз һәм колның йөзенә карамыйча да күрде: Фәлинов бөрешкән иде.

— Ни инде, ни... Мин сезне алай кыерсытмадымдыр, ни... Гөлфия Әнвәровна, сез ни... Үчләшмәгез берүк, ямегез. Бозылышып бетмик, дим, ямегез.

— Сез хаклы, Фәләнов.

— Ни... яңа главага, дим, дустыгызга, дим, мине яманламассыз инде, ямегез.

— Баш өсте, Фәләнов.

— Ие, ие, Әмирулла агаебыз ярата иде «сез хаклы» белән «баш өсте»не. Начар бәндә иде инде, холыксыз тиран иде. Хәзер сез аны гәзитегезнең беренче битендә хурлап яза аласыз, сез ирекле, Гөлфия Әнвәровна. Ха-ха, үзенең дә көтмәгәндә генә башына чүкеделәр. Йорты сәләмә, яңасына нигез дә салмаган иде. Шәхси машинасы да юк хәерченең. Элеккеге туры коммунист! Ха-ха!

— Ыржайма, Фәләнов, күп көлсәң, елата, диләр.

Шәбәйгән аппарат җитәкчесе тагын бөреште.

— Мин Эдуард Әминовичка тугры хезмәт итәрмен, сез ни... Миңа начар бәя бирмәгез, ямегез, Гөлфия Әнвәровна.

Фәлинов, теле белән иренен ялагач, кызның кулын үбәргә үрелде.

— Кагылма! — Калын ирен кузгаткан нәфрәт, кайныйкайный, йөрәктән ташый иде, Гөлфия җирәнеп кырыйга күчте.— Ялагай ирләрне җенем сөйми. Сине бигрәк тә, Фәләнов. Әмирулла агаегызның боерыкларын сез ун тапкыр арттырып үтәдегез. Шуңа безнең бинабыз иске, машинабыз җимерек, язмаларыбыз сыек.

И Гөлфия, Гөлфия! Кол бәндәгә кем рәнҗи дә кем үпкәли ди. Син аны үзеңә тиң санап бәхәсләшмә, юкса аның дәрәҗәсенә төшүең ихтимал.

Алдан выжылдап очкан ике машина кискен генә уңга каерды. Казан кунагын каенлыктан озаталар икән. Мәҗлес Сәлимәнең бәхете иде. Ул анда, мөгаен, судагы балык кебек йөзгәндер. Кемгәдер буйсынудан да яманрак хәл юк. Бер Раббысына баш игән кеше генә рухи иркенлекнең ләззәтен тоядыр.

Каршыда, тиеннән дә уздырып, беренче урынбасар сикерә иде.

— Стоп, стоп! Фәлинов, син шофер белән сакта кал, ары табан берсен дә үткәрмә. Ә сез, Гөлфия Әнвәровна, безнең кадерлеләрдән кадерлерәк язучыбыз, рәхим итәсез! — Урамда очраса исәнләшергә дә иренгән тәкәббер урынбасар сабагыннан да өзмичә көнбагыш яра иде.— Табынны мин табигатьтә көйләттердем. Саф һава, кыр чәчәкләре! Эдуард Әминович каен кызларын ярата, диләр.

— Ялгышасыз, ул имән егетләренә мөкиббән,— диде Гөлфия, юри мыскыллап.

Урынбасарның йөзе көл кебек агарды:

— Имә-ә-эн?! Шоферы каен диде!

— Нинди зур хата ясагансыз,— дип өстәде кыз. Бүген ул «төртмә телле» тигәнәк иде. Ике хатын агач өстәлләр тирәсендә әвәрә килә иде. Ак халат итәгендәге тауар ярлыгын да кисмәгәннәр. Яңа хаким ризасыз кыяфәт белән учын шапылдатты:

— Җәтрәк кыймылдагыз, Рубин Садыйковичның һәр минуты санаулы. Барысы да готовый, дидең, кая, кем әле син, иптәш?

Беренче урынбасар, кечерәеп, тезе белән түмгәккә тезләнде:

— Мин Рафис Мәү... Мәүлетов, мин... исемле, мин...

— Болар белән ничек аралаштың син, Гөлфия Хан? — диде башлык, карашы белән Мәүлетовны сытып.— Сине бу тинтәкләр кыерсыттымы? Ну, ладно, соңыннан разберемся. Давай, Рубин Садыйкович, горланы юдырыйк! Каты эшләдек без, ә? Җиңдек тәки, ә? — Мыштымның сүз буасы ерылган иде. Ул авызындагы итен лач-лоч чәйнәп мактанырга тотынды: — Югарыдагылар озатмаганга борчылмыйм мин, Рубин Садыйкович. Вот увидите, өч айдан мин Президент хәтле Президентның үзен Күмер Тауга китертәчәкмен. Әллә юмаммы? Китертү чарасын да найду. Хәйлә бар бездә, тапкырлык та оһо-һо! Әмируллалар ише җебегән карт түгел без. Мин аны бүген в упор не видел, ул Күмер Тауга лутчы маймыл куегыз, ну Эдуард Арслановны ни-ни, дигән. Бетәшкән бабайчик! Күрерсез, безнең республика күгендә Күмер Тау йолдызы — Эдуард кабынып. Дөресме, Гөлфия Хан? — Күркә сыман кабарган хаким юлдашлары очындырып тормаса да канатлана иде.— Смотри син, Кәбировлар, Ивановлар миңа таяк тыкмакчы! Мин аларны Татарстаннан сөрәчәкмен, миңа бу Күмер Тау — күпер, теге ярга сикерергә, мин әле иң югары постка менәчәкмен.

Казан түрәсе бик сак кеше иде, ул ни сүзгә кушылмады, ни табындагы ризыкка кагылмады, гел су гына эчеп утырды. Ул, күрәсең, Ивановларга да, Арслановларга да авышмый, урталыкны сайлаган иде.

Кунакның дәшмәвен һәм ашау-эчү белән мавыкмавын яңа хаким, исерсә дә, мыегына чорнаган һәм үзенчә нәтиҗә дә чыгарган иде: «Каенлыкта черки, тәгам дә затлы түгел...» Ахырдан ул ике урынбасарны да утлы табада биетте.

— Сез — бәрәңге кәлҗемәләре! Мине Әмирулла корсагына төягән сасы кыяр, әчегән кәбестә белән опозорить итмәгез! Немедленно озын ботлы өч кызны Казанга укырга җибәрегез! Кунак сые әзерләргә өйрәнеп кайтсыннар. Яз, кайсыгыз яза белә?!

Урынбасарлар, хаким каршысында өчкә бөгелеп:

— Боерыгыз, Эдуард Әминович! — диделәр.

— Беренчесе — таза гына авылда нәселле сарыклар үрчетү. Табынга кайнар килеш бирелгән сарык ите тәмле. Икенчесе — каз фермасы, өченчесе — тавык фермасы. Тавыкны тутыра белмәсәгез, аңгыра башлар, мишәр Чистае өч йөз чакрымда, шунда барыгыз, үрәтерләр. Дүртенчедән, кунак йорты салдырабыз. Бассейны, саунасы белән. Агач мунчасы аерым. Аулак урын сайлагыз. Бу каеннарны кисеп-турап өярсез, мунчага только каен утыны гына ягасыз. Мин сезне җигеп-җигеп эшләтермен, хөрәсән көтүе! Завтра район белән танышам. Нинди мирас оставил икән Әмирулла дәдәгез, посмотрим. Син, Гөлфия Хан, кәгазь-каләм белән кораллан, язасыларың байтак.

Ниһаять, Гөлфиягә дә сүз төртергә җай чыкты.

— Мин гәзиттән китәм шул, Эдуард әфәнде.

— А ну-ка, каты-котыларыгызны җыештырыгыз да пош-шел! — Хаким каенлыктагы халыкны куа башлады.— Тизрәк, тизрәк сыпыртыгыз! Син беркая да не уйдешь, Гөлфия Хан! Потому что син минем шәүләм.

— Сезгә үз шәүләгез генә җитмиме?

— Зирәк ханнар үз ханлыгында поэтлар асраган. Зря түгел. Син минем хакта үзәк матбугатка статьялар язасың!

— Казаннан чакырырсыз, Эдуард әфәнде.

— Миңа чүп-чар журналистлар не надо! Миңа син кирәк. Кем язган? Гөлфия Хан язган, диячәкләр.

— Безгә Казан матбугаты ишекләрен япты, Эдуард әфәнде. Әгәр сез безнең язмыштан әзме-күпме хәбәрдар икән, беләсез булыр: мине «Яшьләр»дән кудылар, ә Нияз Сафин дөньядан ук китте.

— Ишеген дә, тишеген дә ачтырырбыз. Пресса безнең йодрыкта дип сана. Ник кәҗәләнәсең син, Гөлфия Хан? Мин синең каләмеңә лаек түгел, что ли? Что ли мин ямьсез, әшәке, начар?

Гөлфиянең бөтен килеш-килбәте «син — сатлыкҗан» дип кычкыра иде. Ул, көч-хәл белән нәфрәтен эчкә йотып:

— Сезнеңчә, дуслык нәрсә ул, Эдуард әфәнде? — диде.

— Әфәнде дә әфәнде, тешкә тия, әйтмә алай, пожалыста!

— Сезнең дә урыс сүзләре кыстырып сөйләшүегез күңелемә тия, авыл баласы саф татарча сөйләргә тиеш.

— Не беда, татар теле бодай орлыгы түгел, аны чәчеп, урожай җыялмыйсың. Что, интервьюны бүген үк шапылдатабызмы? Ну давай, отвечать начну. Дуслык — минем өчен изге нәрсә. Вот Хантимер другны һаман юксынам. Ул авариягә очрап үлде, прямо күпер өстендә «КамАЗ» белән бәрелешкәннәр дә моның машинасы дөмберт елгага, гәүдәсен дә тапмаганнар.

«Хәзер мин моңа «дустың исән» дисәм, нишләр иде икән? — дип уйлады Гөлфия.— Шатланыр микән? Әй, җүләр кыз, җүләр кыз! Ул дустын файда өчен саткан лабаса! Хантимер Әхмәтовны эзәрлекләүдә бу бәндәнең дә өлеше бардыр. Әллә «Кем саткан?» дигән уен оештырасыңмы? Чү, кабаланып эшне бозма, башта чуалган йомгакларның беренчесен сүт».

— Дальше икенче вопрос,— диде хаким.

Ул җилбәзәк яшүсмерләр сыман кыланып «фью-фью» сызгыра иде. Ә Гөлфиянең уенда Салабаш урманы иде. Көн кичкә тарта, аны Хантимер көтә, ул исә соңара...

Юк, иртәгә хәтле кичектерергә ярамый!

— Әлегә сораулар бетте, Эдуард әфәнде. Черки талый,— диде ул.

— Ну собакаларны, природа дип, бәбәкләре акайган ведь. Ну, ладно, син әзерлән, без матур гына гәпләшербез кабинетта.

...Аны редакция бинасы янында төшереп калдырдылар. Гөлфия йокы симерткән шофер егетне төрткәләп уятты да:

— Кабыз! — диде. Үзе арткы утыргычка чумып, тәрәзә пәрдәсен тартып куйды.— Рамил энем, «ә» димә, «мә» димә, кәкре каен төбенә хәтле илт.

— Син нәстә, Гөлфия апа?! Тиздән кояш байый, яктылык сүнүгә, урман тирәсен җен баса-а!

— Бабаң әкиятен сөйләмә, җегет.

— «Арбабыз» да пытыр-пытыр итә бит, Гөлфия апа. Гылава Әмирулланы илтергә куштыгыз да, әнә күпердә ватылдык. Төшеп этте тагы. Хе-хе! Әйбәт карт икән үзе. Хе-хе!

— Кабыз, Рамил. Ярты юлдан борылырсың.

— Янмыйдыр ла, Гөлфия апа. Җә, кабыздым, җә, киттек-бардык Салабашка. Э-э-э, бервакыт, ди әти, умарталыкта мунча яктым, ди. Кояш, йөзен алсу сулар белән юып, йокларга җыена, ди. Утын өстим дип, мунчага керсәм, әниең туңкайган да мичкә пүлән тутыра, ди. Карчык, авылдан нәстә белән килдең, дип әйтәм, ди. Ничә чакрым ич, җәяүлегә күпме тәпилисе, дәшми әнкәң, ди. Кичә үпкәләшкән идек, шуңар авызын турсайткандыр кортка дип, ишекне яптым да, тукта, бу артыгын өстәмәсен дип, янә ачкан идем, ди, әнкәң юк, ди. Әй әти атын куалый-куалый авылга чапкан, кайтса, әнкәй күрше хатыны белән ләчтит сата-сата йон эрли, ди. Мин төнлә хатынны гел чеметәм, Гөлфия апа. Куенымда җен назланып ятмыймы дип. Хатын тибенә икән, димәк, тәртип. Җеннәрнең бит аларның җисми тәне юк, диләр.

— Куркаклар өчен приз бирсәләр — ул синеке, энем,— диде Гөлфия.

Егет килешмәде:

— Кирәксә, мин ике аю белән сугышам, биш башкисәрнең муенын борам, Гөлфия апа, ну түлке...

— ...Салабашка якын да килмисең, әйеме? Йә, Камырбатыр, ярты юлга җиттек!

**8**

Алан уртасында учак яна иде. Ялкын чаткылары чәчри дә, күккә атылып, караңгылыкта йотыла.

— Алялетдин абзый иртүк сабын күбеге сылап кырынды-чистарынды. Көнозын сине саклады инде, бара-кайта, бара-кайта,— диде Хантимер, учак кырыена тәгәрәгән утлы кисәүләрне эчкә табан эткәләп.— Арыды карт. Авыру ул. Йөрәк аның. Сылукай да йоклады.

— Гафу итегез, соңга калдым шул.

— Син бик вакытлы йөрисең. Төнгә кара, безне сыендырган өч көнлек дөнья нинди матур, Гөлфия дускай.

— Әгәр сез шушы төнге урман белән серләшер өчен генә монда яшәп ятам дисәгез, мин барыбер ышанмас идем.

— Җиденче классны тәмамлагач, мине Казанга — әтинең олы абыйсына җибәрделәр. Шәһәр мәктәбендә урысча укыталар, янәсе. Абыйлар гаиләсе ял паркы каршындагы йортның дүртенче катында яши иде. Тончыга идем мин ул фатирда. Өч бүлмәсе дә тәрәзәсез, тоташ дивар иде. Заманында парк кыриенда биек коймалар белән әйләндереп алган кунак йорты булган. Мәскәүнең тыйнак партия чиновниклары шунда туктаган. Хрущев та шул исәптән. Ә абыйларның фатир тәрәзәләре яшерен кунак йортына карый икән. Беренче, икенче, өченче катларны койма томалый, ә соңгы кат өчен барысы да уч төбендә. Киләләр дә, «вакытлыча» дип, абыйларның тәрәзәләрен кирпеч белән каплыйлар. Казанда йөргәндә күз сал, бүген дә тәрәзә урыны уелмаган. Анда инде бүтән кешеләр тора. Мин җәйне көтеп саргая идем. Авыл белән урман минем өчен көн-төн ябылмаган зур тәрәзә иде. Менә шылдырап күмер төшә...

— Ит кыздырасызмы?

— Каян беләсең?

— Исе яфракларга сеңгән.

— Хикмәтле кеше син, Гөлфия дускай.

«Мин хикмәтле түгел, мин үткәннәрдән киселә алмыйча җәфаланган бичара җан, сереңне чиш тә коткар мине, зинһар!»

— Хантимер, теге көнне син ниндидер фаҗигаләр белән үлеп терелүләргә ишарәләдең.

— Ташла, дускай. Хәтерне уятма. Әнә табигать җан ияләренә мендәр кабарта. Кош анасы балаларын яфракка төреп йокларга сала, күбәләкләр нәфис гәүдәсенә чәчәк таҗларын яба. Кырмыскалар гына хәрәкәттә, ыгы-зыгылы дөньяның үзе кебек. Тыңла, кара, соклан!

— Мин төнге урманны яратмыйм, Хантимер.

— Һы, үзең курыкмыйча килдеңме?

— Яратмаган нәрсәләрдән курыкмыйсың ул.

Гөлфиянең ачу кибәне ишелә иде. Син бит барыбер сөйлисең, Хантимер иптәш, ник аны сузасың икән? Кыз сер юллап көн саен сукмак иләсә, Җәүдәткә ни дип акланыр? Гөлфия яраткан кешесенең җанын шик белән кыйнарга теләми. Менә кайда ул курку...

— Иң якын дустым — Эдуард, дидегез.

— Нишләгән Эдуард?

— Аралашасызмы?

— Мондый хәлемдә мин беркемгә дә күренмим. Хәтта ризык бүлешкән дусларга да. Әлегә мәет исәбендә йөртсеннәр.

Менә, менә! Үзе һаман сер баткаклыгына сөйри, ә үзе: «Ташла, хәтерне уятма»,— ди.

— Бүген якын дустыгызны Күмер Тау хакиме итеп билгеләделәр.

— Эдуардныммы? Кит аннан! Чынмы?

Хантимер кызарып янган күмер өемен таягы белән бутап тузгытты да өстенә кочагы белән чыбык-чабык томырды. Ут озын теле белән күкне ялмарга кереште. Бу хәбәр Хантимерне шаштырган иде.

— Нишләгән соң бу малай?! Ул беркайчан да җитәкчелек эшенә кызыкмады!

— Кеше син яшәгән карурман кебек, Хантимер. Бәлки, дустың дәрәҗә колыдыр.

— Эдуард фән өлкәсендә үсәргә тиеш, ул тел белгече иде.

— Күрим дисәгез...

— Юк, юк, Гөлфия. Хисләнеп тезгенне бушатмыйк әле. Алялетдин абзый белән синнән кала беркем белән дә очрашмыйм. Сезгә — ташлама, сез кеше түгел. Гафу, сез кеше, әлбәттә, тик алардан бик аерыласыз.— Хантимер, тезенә бәреп, шарт-шорт ботак сындырды.— Шайтан алгыры! Хакимияткә урамнан чакырмыйлар, Эдуард ул даирәгә ничек эләккән, ә? Егет ялгыз бүре иде.

— Ул ниндидер төркемдә бугай. Мәсәлән, бүген аңа Күмер Тауда хан таҗы кидерүчеләрнең берсен, Рубин Садыйкович дигәнен, Эдуард якын дустым дип атады.

— Кемне?! Рубин Ансаровнымы?! Ул бит вак-төяк, болай гына ияргәндер. Гөлфия, әйдәле, монда эссе, йөреп килик, әйдә! — Ир, үкчәсенә ут элдергән сыман, ашыга-ашыга алан буйлап китте.— Ничек шул кабахәт белән дуслашкан ул?!

Урманда анның әрнүле тавышы яңгырады. Тимер йөрәкле ирләр дә чарасыз калып өзгәләнә икән...

— Эдуардка мәгълүм: миңа Рубин Ансаровлар гына һөҗүм оештырды. Мәкерле, хәйләкәр, астыртын, хәшәрәт Рубин! Тыштан карасаң, тәүфыйклы ата песи инде. Нәрсәнеңдер очы очка ялганмый бит. Ә-ә! Эдуардны шулар кыстап Күмер Тауга китергәннәр! — Хантимер үзе белән сөйләшә иде.— Егетне сазлыкка батырырга җыеналар. Чөнки чамалыйлар: Эдуард җитәкчелек мәсьәләсендә тәҗрибәсез, фәнгә якынаеп, зур галим булып танылмасын дип эшлиләр моны. Минем өчен үч алалар, кыскасы. Бер генә корбан әз аларга. Үч бит әле ул физик яктан гына юк итү түгел, хурлыкка төшереп үтерү дә. Соңгысы хәтәррәк аның. Син мине тыңлыйсыңмы, дускай?

— Юк,— диде Гөлфия.— Хантимер белән Хантимер бәхәсләшкәндә өченче кеше артык. Табигать мендәр кабарта, кош анасы балаларын яфракка төреп йокларга сала. Миңа да хушлашырга вакыт.

— Чү, сабыр ит.— Хантимер адымын әкренәйтте.— Кил, янәшәмнән атла. Әйе, мин үлеп терелгән кеше. Сиңа аны җентекләп сөйләүнең ни хаҗәте, ә? Бер тапкыр күпердән мәтәлдерделәр, бер тапкыр тишкәләп бетергәнче аттылар. Дүрт ел чит илдә дәваландым, тәнемне ярып-телеп егерме биш ядрә чүпләделәр. Соңгысы йөрәк турысында иде. Кемдер сатты бит мине. Кем, йә, кем? Хәер, төкерәм мин ул кабахәт җанга! Мин әле күтәреләчәкмен, мин егылып, шыңшып ята торган мескен егетләрдән түгел. Бөтен кеше тауга ыргылганда, без генә түбәндә калмабыз, күрерсең.

— Нинди «тау» ул, Хантимер?

— Менә, усал кыз, берәм-берәм серемне урлыйсың тәки, ә! Хакимият турында әйтәм.

— Ә нигә халкы далада, вәзире урманда соң әле? Әкияткә охшаган.

— Әкият түгел, чынбарлык, Гөлфия. Әлегә мин яшеренергә мәҗбүр. Дамир Салиев исемле талантлы сәясәтчене беләсеңме, Гөлфия?

— Белмим. Беләсем дә килми,— диде кыз, битараф кына. — Ачуланма, Хантимер, биш ел элек булган хәлләрне генә ачыкламакчы идем. Сәясәтегезнең дә, сәясәтчеләрегезнең дә поты бер тиен!

— Туктале, Гөлфия, бу синме соң?!

— Мин. Тәүбәгә килгән Гөлфия Хан үзе!

Алар әйләнеп килгәндә, учак сүнгән иде. Ызба тәрәзәсендә тычкан уты җемелди. Сукыр лампа кабызганнар...

— Төн салкын,— диде Хантимер, учакка сулышын өрә-өрә.— Күмерләр тиз каралган.

— Нигә җылы Мәскәүләрдә генә ятмыйсың, Хантимер?

— Саулыкка туялмыйм. Һава белән тынычлык кирәк, ди табиблар. Минем өчен балачагым үткән Салабаш оҗмах инде. Аулакта уйлар да тизрәк тәртипкә салына, фикерләр дә ишәя.

— Гаҗәп.

— Нәрсә гаҗәп, Гөлфия дускай?

— Адәм баласының, гомере белән дә исәпләшмичә, хакимлеккә омтылуы.

— Мин йомшак кәнәфиләргә кызыкмыйм, миңа дөреслек кыйммәт. Син тәүбәләреңне башыңнан чыгарып ат, яме, дускай! Бәлки, без әллә ни майтара да алмабыз, ләкин һәркем бер тары бөртеге генә салса да, амбар туларга мөмкин.

Хантимернең вәгазе кызның йөрәгенә үтми иде инде. Элек хыялы белән чүлдә хан сарайлары кора иде ул. Гәрчә анда ком бураны уйнап, кояш тереклекне яндырса да, кыз көрәшергә кирәк, бәхет иле шушында төзелер дип өметләнә иде. Бүген Гөлфиянең сәясәт мәйданында көрәшкән каләме тутыккан, күңел буш сүзләрдән бизгән, аның каравы бөтен нәрсәне кысрыклап, җанга ярату атлы Хис килә иде. Табигатьтә язны кышка чигереп, ташуларны туктатырлык кодрәт, ә адәмдә мәхәббәтне кире борып җибәрерлек көч юк. Агарткан, чистарткан, сафландырган хисләрне нигә ул сәясәт дигән пычрак уенга алмаштырсын ди! Әгәр бу ир үз гомерендә берәр мәртәбә гыйшык ятьмәсенә эләксә, кызның чәбәләнүләрен аңлар иде. Хәер, аңлар иде микән? Җанының яртысы белән генә яратучылар да бар. Алар инде ялгышлардан сакланып, акылга буйсынып яши. Нинди бәхетсез халык!

Алан хуҗасы яңадан учак тергезде.

— Сүзгә саран хатын-кыз сирәк очрый,— диде ул.— Ник дәшмисең, Гөлфия Хан? Кинәт кенә мин синең өчен кызыксыз кешегә әйләндем бугай.

— Син таш кебек каткан сәясәтче, Хантимер. Хәзер миңа сезнең шөгыль ятрак шул.

— Ә нәрсә якын?

— Синнән бик ерак нәрсә миңа якын, Хантимер.

— Сиңа якын, миңа ерак... Һы, нинди табышмак соң бу?

Шул чакта ызбадан савыт кочаклаган Алялетдин карт чыкты.

— Яшь бәрән итеннән шашлык авыз иттерәбез сиңа,— диде Хантимер, баягы сүзен өзеп. — Алялетдин абзый, син кер, ят, без Гөлфия белән икәү җайларбыз.

— Мин чир-рләмим,— дип кырт кисте карт. Ул учак янына, килә-китә, әйбер ташыды. Аның киреләнеп кереп ятмавы кызны сөендерә иде. Сәясәт дип, төнге аланның ямен җибәреп бәхәсләшеп утырмаслар, ичмасам.

Хантимер дә бүтән күңелсез әңгәмәне ялгамады, яңгыравык тавыш белән:

— Алялетдин абзый, хәтерлисеңме, беркөнне алан өстеннән вертолет очып үткәндә, син аңа каршы күсәк күтәреп чапкан идең?

Карт «ыр» дигән аваз гына чыгарды.

— Кәефсез безнең бабай, әйтәм бит, чирли,— диде хуҗа.— Шуны сөйләсәм, көлә-көлә эче ката иде. Тимер кош куна дип уйлаган ул. Төшсә, тизрәк канатларын сугып имгәтим, бу әкәмәт нәстәкәй йомырка салып, бала үрчетер дә урманда яшәрлек рәт калмас, дигән.

Керпе кебек инәләрен тырпайткан картның башыннан сыйпыйсы килде кызның. Аның да әтисе дорфа, әмма нечкә күңелле иде. Шушы сыйфатны ни өчендер, дорфалык белән чорнап, эчкә үк яшерергә кирәк бит, ә!

— Безнең Алялетдин абзый хисле җан. Камыш сызгыртып җырлый да аннан күз яшен агызып җылый.

— Аның нервысын бозып, авыруын көчәйтмим, китим, булмаса,— дип кузгалган Гөлфияне Хантимер җибәрмәде.

— Чү, чү, син — кунак! Бәрән итенә төрледән төрле үләннәр кушып, махсус синең өчен җебетте бабакай. Өнәмәгән кешесенә яңгыр суы да эчерми ул. Чын мәгәр, диң, Алялетдин абзый. Сакал-мыегыңны кыруларың да Гөлфия өчен бит синең, әйеме?

Бу юлысы карт йомшак кына ырылдады.

— Чит ил чит ил инде, Гөлфия дускай. Дәвасы да әллә ни килешми. Бетеренеп кайттым мин туган якка. Яртылаш картаеп. Кемгә кайттым дисеңме? Шушы сыңар күзле карт йортына. Үләргә дип менеп яткан иде такта сәкесенә, минем ни хәлдә икәнемне күргәч, могҗиза белән терелде. Теге елларда тәки Казанга күчмәде, мин аңа аерым фатир да җайлый идем, тәрбияләргә кешесен дә билгеләттерә идем. Атларым да атларым, диде. Ат абзары — җәннәтем, диде. Бәлки, аның бәхетедер бу. Кимсенми дә, кителми дә бит. Авылдагы йорт-җиреңне бикләп, вакытлыча урманда яшибез инде, әйеме, Алялетдин абзый? Көзгә кадәр, әйеме? Һавабыз әйбәт, дөньябыз түгәрәк. Заманында бал кортлары үрчетә иде монда абзый. Ызбасын аннан-моннан сипләдек. Инде сине ялгызың гына калдыру юк, картлач. Казанга минем белән очасың! Мин көчле, дип очынма.

Карт тешен шыгырдатты.

— Әһә, Казан дисәң, зәһәрләнә безнең бабай. Мине дә җибәрмәскә әле аның исәбе. Савыккач, колхоз рәисе бул, ди. Хет күмәк хуҗалык атлары туйганчы солы ашар иде, ди. Алялетдин абзый өчен иң зур дәрәҗә — рәис. Озак кына бездә Кәбир исемле председатель эшләде. Бервакыт ул абзыйларга үгез суярга куша. Соңыннан берсе, шаяртып: «Кәбир энем, суюын суйдык та, эченнән бозавы чыкты бит»,— ди. Сүгә икән Кәбир Алялетдин абзыйны эт итеп, ник буаз терлек суйдың, дип. Үгез бит ул, ди икән абзый. «Үгезме, чуртмы, син аның буаз икәнен чамаларга тиеш идең»,— дип, һаман үзенекен сукалый, ди, рәис. Безнең картта мәзәкләр капчык-капчык. Яшь чакта син мут егет булгансың диләр, ә, Алялетдин абзый? Көч-куәт ягыннан да сиңа тиңнәр юк иде. Хәтерлисеңме, Акмаңгай, чокырга егылып, аягын сындыргач, син шул хайванны күтәргән идең. Ат хәтле атны! Рәис синең җилкәңә камчы белән ора, үлгәнче суйыйк, ите булыр, ди. Син, үҗәт, Акмаңгайны тәки бирмәдең.— Учак ялкыны Алялетдин абзыйның йөзен яктырта иде. Сыңар күздән яшь тамчылары коела... Хатирәләре елата микән? «Ходаем, бу бәндәң турында яман уйлар да уйлаганмындыр, берүк кичер! Без колларыңның күңел дөньясын күрмичә генә хөкем итәргә ашыгабыз шул».

— Шуннан соң Акмаңгайны үз өеңдә дәваладың син, әйеме, Алялетдин абзый? Сабантуй ярышында катнашып, беренче урынны яуладык Акмаңгай белән. Мин чаптырдым аны. «Маладис, улым»,— дип, күккә чөйгән идең мине. Болытларга башым белән бәрелеп, күкне тишәм дип торам. Әти коры иде, миңа бер дә «улым» дип дәшми иде, ә син, Алялетдин абзый, чит кеше баласына «улым» дип өзелә идең. Сакалыңа ябышып үскән малайлар инде без. Рәхмәт! Хәзер дә синең тәрбияңдә. Минә янында хатын-кыз йөрсә, күңел кыллары ничек тибрәнә икән. Нечкәрдем, ә? Күптән әйтәсе рәхмәтләр иде бу, абзыкаем.

— Соңарган рәхмәтләр ихласрак ул, Хантимер. Син аны ничәмә-ничә еллар күңелеңдә йөрткәнсең бит,— диде Гөлфия. Бу хатирәләрдән ул да йомшарган иде.

— Мине төрле бәла-казалардан саклар өчен, аланның дүрт почмагына мылтык тоттырып, дүрт әзмәверне бастырырга була,— диде Хантимер.— Юк, Алялетдин абзый ышанычлырак. Тегеләрне кемдер күбрәк акча белән сатып та алырга мөмкин, ә минем абзый тау-тау алтынга да «тфү» дип кенә төкерәчәк. Тугрылык иң зур көч икән, Гөлфия дускай.

— Чөнки табигатьтән аерылмаган кеше хыянәттән азат. Ул җиһанның һәрбер ноктасында — үләнчәчәкләрдә, кош сайрауларында, искән җилдә, ак болытларда, үрмәләгән бөҗәкләрдә, киек-җанварларда, төнлә чәчрәп янган йолдызларда Раббысының барлыгын тоеп, иман белән гомер итә. Ә тугрылык — иманның бер билгесе.

— Колак сал, Алялетдин абзый, кунак сине ничек олылый!

— Ишетәм, Хантимер, Ходай үзен дә олыласын,— диде таякларга кадап-кадап ит тезгән карт.

Хантимер, кулын баш очына күтәреп, дым белән тыгызланган һаваны бутады.

— Их, сулышка иркен Салабашта! Бу рәхәтлектә изрисе иде дә... Баягы хәбәрең очлы ташмыни, бавырны тишә. Син акыллы хатын, киңәш бир, Эдуард дуска ничек ярдәм итим икән? Урманда үзең турында гына кайгыртып яту егетлек түгел. Әллә, мәйтәм, аны аланга чакырасыңмы? Мин бик үтенәм синнән, Гөлфия.

— Синең иртәнге сүзең кичкә искерә икән, Хантимер. «Ризык бүлешкән дусларга да күренмим»,— дигән идең.

— Эдуард — бәгырьдәге дус. Студент чакта кызлар озатып кайтабыз. Караңгы урам тыкрыгыннан шәһәр ышпаналары чыкты. Минем өстә яңа куртка. «Сал» диләр тегеләр. «Салмый» ди Эдуард. «Җаның җәлме, малың җәлме?» диләр, мал да җәл, хәерче студент бит без, соңгы тиеннәрне санап яшибез, куртканы көн саен алмыйсың. Ышпананың берсе пычак белән миңа кизәнгән иде, Эдуард аңа күкрәген куйды...

— Үлмәгән лә дустыгыз, исән-сау, — диде Гөлфия.

— Ике ай хастаханәдә аунады. Терелгәч, мин дуска куртканы бүләк иттем. Мә, мәйтәм, син моңа лаек.

— Алдымы?

— Курткanымы? Әйе, әйе! Ул да акчасыз егет иде. Әтисе — колхозчы, әнисе — идән юучы.

Алялетдин карт алар сөйләшкәндә әллә нишләде: бер ызбага чаба, бер йөгереп килеп, яланкул учактагы күмерләрне тарата...

— Эдуард дисәм, котыра башлыйсың, Алабай бабакай,— диде хуҗа, шелтәләп.— Ник аңа нәфрәтләнәсеңдер.

Карт, үзалдына мыгырданып:

— Киемеңне салдырды, хатыныңны аздырды, үтә дә яман бәндә! — диде.

— Син бигрәк инде, Алялетдин абзый! Бер күрмәгән кешене хурлыйсың. Туктале, карт, тукта, Гөлфия Хан без ирләрдән акыллырак. Ул ни дияр бит?

— Күпме сакланасың инде, Хантимер, тагын әз генә түз,— диде кыз.

Ир, бераз уйланганнан соң:

— Шулаймы, Гөлфия дускай? — диде. Һәм җанланып китте.— Көннәрдән бер көнне мин дә Эдуардка үз күкрәгемне куярмын. Ә анда хәтле...— Ул караңгылык аша кызга текәлде.— Киңәш-табыш итәргә син бар, Гөлфия Хан. Син бар! Ир-атка хатын-кыз нинди терәк инде ул дип көлмә, дөньяның яртысын елак һәм җебегән мыекбайлар басты. Без синең кебек акыллы кызларыбызга таянырга мәҗбүр. Син Эдуард янәшәсендә бул әле, зинһар. Абынмасын иде ул.

Бу ялвару күңелне укшыта иде. Күр моны, шайтанга ялчы итеп кодалый. Хыялында икейөзле, ялагай куштаннан дус әвәләгән дә хәзер шуңа фәрештә сыйфатлары өсти. «Күкрәген куйды...» Әйе, синең курткаңны аның ятларга бирәсе килмәгән, чөнки үзе кызыккан... Пычакка эләгеп булса да алган ул аны... Чын дус «Җылы тәнеңдә тузсын» дияр иде. Ул һаман синнән түләттерә. Гомерең белән дә түләттергән әнә: сине сатып түрә урындыгына оялаган... Әгәр син боларны белсәң иде! Белмичә тор, яме! Әле син көчсез, әле син сынган канатларыңны ныгытып кына маташасың. «Дустыңның» хыянәтеннән өзлегерсең дә Нияз Сафин язмышын кабатларсың. Нәкъ менә имән кебек ирләрнең шартлап сынуыннан курка, һай курка Гөлфия. Каен әрсез, усак әрсез, тамырдан бик тиз терелә, ә имәннәр авыр кузгала...

— Кызганыч, Хантимер, дустыңның әшнәсе булалмам шул, мин язу-сызулардан китәм.

— Кая?

— Бәхетемә китәм.

— Нинди бәхетеңә? Синең бәхетең — сәясәт, Гөлфия Хан!

Ахмак ир! Сезнең юлыгыз — бердәнбер хак юлмыни ул! Сез бит чынлыкта хакыйкать эзләмисез, сез бер-берегездән көнләшеп, бер-берегезгә үчләшеп, «тау»га менәргә ашкынасыз. Ә Гөлфия ул ясалмалыктан азат: Ходай кызның җанын Хис белән сугарды, еллар буе кысыр яткан туфракта бүген гөлләр чәчәк ата, куагында сандугачлар сайрый... Яраткан кешесенең елмаюы күңелне җылыта, назлый, иркәли...

Хантимер, «Сәясәт, сәясәт» дип, учак тирәсендә әйләнде дә инәлеп-инәлеп ялвара башлады:— Гәзиттә кал, яз, Эдуардка булыш, ташлама аны, зинһар, Гөлфия, ташлама, үтенәм!

Ир бәндәсе вакланса, тузан бөртегедәй уала, мескенләнсә, иң кызганыч затка әверелә, ялагайланса, табан астыңа хәтле ялый, алар өчен урталык юк икән. Баядан бирле өермә куптармыйча эченнән генә дулаган Алялетдин карт та, энесенең ялынуын килештермичә:

— Ар-ртык сүз — чүп сүз, ит пешкән, тәмләгез,— диде.

Картка күңеленнән генә рәхмәт укыды кыз. Коткарды...

Хушлашканда, Хантимер кунакның кулын кысты:

— Көтәм, кил,— диде.

Алялетдин абзый Гөлфияне озата барды. Ниндидер үтә күренмәле җепләр бу карт белән икесен әкрен генә бәйли башлаган иде. Алар моны тоя-сизә дә иде. Карт инде бүтән теш шыгырдатмый... Аның хәрәкәтләре дә йомшарды. Хәзер аңа Сыңар күз дип ямьсез кушаматы белән эндәшергә ояла Гөлфия. Абзый Эдуардның кемлеген чамалап сөйләшә, димәк, картта күңел күзе сукыраймаган. Аһ, ни җитми, шул җитми адәм баласына! Маңгайдагы чәчрәп торган ике күз ботак тишеге генә шул... Хантимердә дә ботак тишеге...

Сукмак башында Алялетдин карт, ягымлы тавыш белән:

— Кызым,— диде,— синең язу эшеңдә булып тор-руың Хантимер-ргә файда икән, тор-р,— диде.— Җибәр-рмә анау яман Идуар-ртны аның кыр-рына, башын ашар-р зәхмәт,— диде.

Гөлфия караңгыда йөзе күренмәсә дә елмайды:

— Ярар, Алялетдин абзый. Син тагын нәрсәдер әйтерсең кебек...

— Ие, — диде карт, бик тиз килешеп.— Әйтер-рмен дә инде. Вакыт инде... Үзем белән кабер-ргә күммәсеннәр-р инде... Хуш, кызым, ир-ртәгә кил.

— Хуш, Алялетдин абзый!

...Рамил фарасын Салабаш урманы ягына борган, юл якты иде.

— Йокламадым, күзләрем шар да шар, инәгә кадалып утырдым,— диде егет.— Кайчан җен малайлары машинаны селкетә, мәйтәм. Хатынның әнкәсе, догалар ятла, дигәние, шуңа керешәм, Алла кушса, валлаһи!

— Дөрес эшлисең, энем. Кузгалдык!

Капка төбендәге эскәмиягә «төн кошы» кунган иде. Җәүдәт: «Кайда йөрдең?» — дип төпченмәде. Кыз да: «Нишләп мине сагалыйсың?» — дип ачуланмады, нәкъ шушы мизгелдә яраткан кешең белән күрешү тилмереп көткән бәхетнең үзе иде.

— Җәүдәт,— диде ул, егеткә сыенып.— Хатын-кызның дөньясы төрле-төрле урман: берәүләрнең ул махсус куак ботагы төртеп үстерелгән. Анда иркенлек, агач белән агач арасы киң. Ә икенче берәүләренең кеше кулы орынмаган, кеше аягы басмаган чытырман. Минеке соңгысы. Сиңа чытырманлыкта йөрүе авыр булыр: кырмыска түмгәгенә сөрлегерсең, ботак-чатакларга кадалырсың. Җайлырак итәм дип, бернигә дә тимә син. Өзмә, сындырма, тигезләмә, юкса мин яраланырмын. Һәм без мәңгегә аерылырбыз.

— Әй, газиз җаным, ник мин сине үз рәхәтем өчен үзгәртим ди! Када, чәнчә, тик ярат кына.

— Ул «урман»да серләр дә күп, Җәүдәт.

— Әйе, Нияз Сафин... Кассета... Сатлыкҗан... Миннән чыкмас, ышан, газиз җаным, ышан!

Гөлфия егетнең кочагыннан ычкынды:

— Янам, суыныйм әле. Җәүдәт...

— Әү, җаным?

— Мин бүген алҗыдым, Җәүдәт…

— Яңа хаким белән кунаклар сыйлагансың, диләр. Мине куркыткан «бакча карачкысы»н — Әмируллаunion кыяклаттылар. Искитәрлек хәл Күмер Тауда! Малайлар белән өч сәгать чәйнәдек шуны. Шатлыктан чәй эчтек.

— Мин нәфрәттән алҗыдым, Җәүдәт... Тагын бер серемнең шаһиты булырга ризамы син? Фи, ахмак сорау инде. Син бит хәзер минем бердәнбер якын кешем. Сатлыкҗанның исемен белә идем мин. Гафу ит, сиңа ачылып бетмәдем. Безнең яңа хаким Эдуард Арсланов ул. Инде ары табан...— дип, кыз Салабаштагы хәлләргә күчмәкче иде, егет, ачу белән:

— Кабахәт! — диде.— Мин аны үтерәм! Атам! Сатлыкҗаннар Күмер Тау туфрагын пычратмасын!

— Әкрен, син төнге тынлыкны бозасың,— диде Гөлфия.— Сиңа корал тотып утка ташлан димәделәр, сиңа нибарысы сер генә ачтылар, сабырсыз!

— Уф, кызам шул, газиз җаным. Начар гадәт. Ышан, бу сереңне дә күңелемдә саклармын. Безгә нәрсәгә ул адәм калдыклары?! Безнең дөньябызның капкалары алар өчен бикле, әйеме, Гөлфиям?

— Алайса, ярсу атларыңны баганага бәйлә, җегет. Мин «башсыз кыз»га кичә нәрсә дидең әле, исеңдә микән?

— Исемдә, газиз җаным... Яратам, дидем. Яратам...

Һәй-һәй, ишетәсеңме, шомырт кара күзле төн, ишетәсеңме?! Ярата-а!

9

Рамил өр-яңа машинаның тәрәзәләрен ышкый-ышкый сөртә иде, Гөлфия, уенын-чынын бергә кушып:

— Энем, син бүтән хуҗага ялландың мәллә? — диде.

Егет әйтерсең үрелеп кенә бәхет кошын тәпиеннән эләктергән иде, авызын колак артына хәтле ерып:

— Сөенечеңнән хет бие, хет җырла, Гөлфия апа, безгә заграничный «арба» хутладылар. Фәлән Фәләнов үзе китереп бастырды.

— Бар, кире үзебезнекенә алыштыр, Рамил.

— Нишләп, Гөлфия апа?! Дустың гылава абзый бирдерткән бүләктән кем баш тарта ди. Безнекен мәктәп балалары сүтеп, металлоломга ташысын. Әнә-әнә, бирегә табан Фәлән Фәләнов теркелди.

Фәлиновның аксыл чырае тимгел-тимгел кызыл таплар белән чуарланган иде.

— Гөлфия Ән-вә-ровна, хәерле иртәләр! — диде ул, төчеләнеп. — Минем машина сезнең карамакта, ямегез, Гөлфия Әнвәровна. Ярты сәгатьтән район белән танышырга чыгабыз, ди Эдуард Әминович, ямегез, Гөлфия Әнвәровна.

— Карале, кем, Фәләнов абзый, «арба» безнеке, ямегез.— Аппарат җитәкчесе «минем машина» дигәч, шофер егетнең сөмсере коелган иде.— Сафсим-сафсим безнеке, ямегез. Гөлфия апа гылаваның дусты, вәйт!

— Энем, шаулама,— диде Фәлинов.— Танышу ятим балалар йорты белән төгәлләнә, ямегез, Гөлфия Әнвәровна. Әлегә сау булыгыз, ямегез.

— Моны җеннәр генә башкармас, Гөлфия апа. Фәлән Фәләновны шайтан үзе алмаштыргандыр.— Рамилнең күзеннән зәһәр очкыннар чәчри иде.— Элек «машина тузды» дисәм, «сезгә тирес ташый торган чана да әрәм» дигән Фәлән Фәләнов ничек сиңа койрык болгый, и-и. Үзгәргән, бырат, и-и. Гылава моның йомшак җиренә тибә инде, и-и.

— Типми, энем, типми. Аларга шундыйлар кирәк.

— Мин Фәләновның мыскыллавын беркайчан да онытмам, ахры, Гөлфия апа. Шоферы авыргач, мине дәштерде ялагай койрык. Чистайга җыен, ди. Нәселле таналар карарга бер совхозга бардык. Юл кешеләре бит, ну, чәйгә чакырды инде директор. Кем соң әле исеме? Хәйдәров кебегрәк. Ачык мишәр. Син дә кер, капкала, энем, ди миңа Хәйдәров. Шунда Фәләнов, кукраеп кына: «Аңа кухняда көйләгез, кухняда,— диде.— Барин белән кучер бер табында ашамый»,— диде. И-и, гарьләндем дә соң, Гөлфия апа. Син инде безнең төсле гади халыктан җирәнәсең икән — белгертмә җирәнүеңне. Рамил туган, диген, директор белән икәү генә хәл итәсе мәсьәләләр бар, син аерымрак утыр инде, диген. Мин бит аңгыра түгел, шуны гына аңларлык малай.— Егет баш түбәсен кашып алды. — Гөлфия апа, якты дөньяга бөтен кеше дә ике аяклы, ике куллы, ике күзле, ике колаклы итеп яратыла, ник тигезлек юк соң алай да?

— Ә син бу хакта уйланасыңмыни, энем?

— И-и, Гөлфия апа, шофер гына булсам да, уйлый беләм бит инде мин.

— Бу дөньяда без мәңгелек дип уйлаган кешеләр генә синең кебек гарьләнә, энем. Тегендә бай белән ярлы, түрә белән хезмәтче дигән бүленеш юк. Хөкемдар каршында барысы да тигез. Тик аларны җәннәт белән тәмуг кына аерыр. Догаларыңны мәгънәсенә төшенеп ятла син.

Биш ел тоткынлыкта яткан Гөлфия Күмер Таудан читләшкән икән. Баксаң, Әмирулла Гаязовтан мирас булып көйле генә тормыш калган. Әмма тәкәбберлек чиреннән күперенгән яңа хаким көндәшенең хезмәтен аркылы-торкылы сызды. Ул әле бер генә эшнең дә җаена төшенми, һәм наданлыгын яшерер өчен: «Бу искелек, бу пүчтәк»,— дип йөри иде. Җитмәсә, ком чүлендә ташкала салган патша кебек: «Минем фикерләрне, тәкъдимнәрне тарих өчен теркә»,— дип, Гөлфиягә боера иде. Кыз куен дәфтәренең бер битен «Ахмак» дип язып тутырды. Хәер, ахмакларга да тарихта урын бар. Киләчәктә туасы акыллылар шулардан гыйбрәт алсын өчен, аларның да исемен мәңгеләштерергә кирәк. Әнә амбар кенәгәсе күтәргән Фәлинов бу эшне эшләп тә маташа инде.

Ул:

— Сезнең фикерләрегез алтынга тиң, Эдуард Әминович,— дип, җан тиргә бата.

Соңгы тукталыш Күмер Тау итәгендә шомырт агачларына күмелгән балалар йорты иде. Иске бинадан алтмыш-җитмеш адымда гына зәңгәр гөмбәзле мәһабәт йорт калыккан иде, хаким, эре-эре атлап, шунда юнәлде. Аның күзләре пыялаланган, ул ни баскычка тезелешеп баскан балаларны, ни тәрбиячеләрне күрми иде. Мөдир Гөлфияләрнең ян күршесе иде.

— И Аллам, исәнме юк, саумы юк, нәрсәбезне ошатмады икән? — диде хатын, борчылып.— Нәниләребез дәү абыйларына дип җырлар өйрәнгән иде.

— Сәвия апа, бу зиннәтле сарай кемнеке? — диде кыз.

Мөдир, горурланып:

— Безнеке, ятимнәрнеке,— диде.— Әмирулла Дәминович төзеттерде. Аның энесе Казанда төзелеш идарәсе башлыгы иде. Кызыл кирпечләр шул энесеннән. Абый, үзең эшләгәндә йорт салып куй, дигән ул, ә Әмирулла Дәминович безне кайгыртты, рәхмәт яугыры. Искесенең дивар-түшәмнәре черегән иде.

— Ай-һай,— дип баш чайкады Гөлфия.

— Ерактан гына төзек сыман ул, тузган, хәтәр тузган,— дип исбатларга тотынган хатынга кыз, күңелсез генә:

— Күчерерләр микән соң? — диде.

Хаким, ике катлы бинаны җил-җил әйләнеп, урамга чыкты. Төркемнән Фәлиновка гына эндәшеп:

— Яз! — диде.— Яз, первый этажда сауна и бассейн эшләтәбез. Спортзалны җимереп. Дальше яз, бүлмәләрне нарат тактасы белән тышлатабыз. Тәк, дәлше. Особо да зур кунаклар өчен суперлюкс та кирәгер. Анысына иртәгә үк керешегез!

Гөлфия түзмәде, тамагына бөялгән утлы төер комачауласа да:

— Мин сезгә ике көчсез халык — ятимнәр һәм хатын-кызлар хакын хәрәм кылдым, — диде.

— Стоп! — диде хаким, бармагын шартлатып.— Гөлфия Хан, не понял, әдәби әсәреңнән өзек укыдың, что ли?

— Ә мин боерыкларыгызны бик әйбәт аңладым. Ятимнәргә дип аталган бу йортны кунакханә итәргә ни хакыгыз бар?! Мин сезне пәйгамбәр хәдисе белән оялтам, тимәгез ятимнәр өлешенә!

— Нишләсәм дә, минем воля, Гөлфия Хан. Кая монда мөдир заты?

Фәлинов мөдир хатынның аркасыннан этәрде.

— Күрен, Сәвия Сәмигуллина!

— Апа, синдә ничә бала? — диде хаким.

— Туксан биш.

— Вот что, немедленно списогын төзе дә республикада ничә детдом бар — һәрберсенә ровно бүл. Без әрәмтамаклар үрчетеп яталмыйбыз. Все, я сказал!

Мөдир хатын, «үләм» дип, йөрәген тотып җиргә егылды. Ә хаким иярченнәре белән машинасына ашыкты. Беренче урынбасар баядан бирле «төшке аш суына» дип кыбырсый иде.

Кыз мөдирне күтәреп торгызды.

— Сәвия апа, җебемә әле син. Балалар сиңа әни дип карый бит.

— Үләм, үләм, Гөлфиякәем, ничекләр сабыйларымны читләргә таратасың. Бер ятим иде инде алар, тагын, торган җирләреннән аерылып, икеләтә ятим булсыннармыни?! — дип үкседе хатын.— Нинди миһербансыз башлык билгеләгәннәр безгә, Гөлфиякәем! Ятимнәр өлешенә кул сузган бәндәгә Алланың нәгъләте төшсен!

Аларны ишегалдында уйнаган балалар ураткан иде, хатынның:

— Бәгырь җимешләрем, гөнаһсызларым,— дип, әле бер, әле икенче нарасыйны кочаклап үбә-үбә елавы җир-күкләр тетрәвеннән дә көчлерәк иде. Аңа кушылып чандыр гына кызчык та шыңшый башлады. Гөлфия аны эскәмиягә утыртты һәм кәнфит сузды. Үзенең дә йөрәге елый иде. Сабый ялтыравык кәгазьгә алданып тынычланды. Аның салам хәтле генә нәзек бармаклары хәлсез иде, ул кәнфитне уң кулы белән генә эләктерә алмагач, ике кул белән кысып суыра иде.

— Сәвия апа, кичкырын бездә киңәшербез, син алдан ук чәч агартма, балалар Күмер Таудан таралмас,— диде кыз. Ул Эдуард Арслановның вөҗданын уятырмын дип өметләнә иде әле.

— Сиңа Фәлән Фәләнов Каратау наратлыгына барырга кушты, Гөлфия апа, әбәт ашарга,— диде шофер егет.

— Нинди ашау, энем?! Редакциягә кайтабыз.

Әй, ничек качасы икән бу сансыз Арслановлар тирәсеннән?! Хантимер аңа бигрәк авыр бурыч йөкләде: нинди «көчсез» дустына терәк ясатты. «Көчсез Эдуард» кешеләр башыннан йөри әнә. Каядыр качасы иде... Хантимер сатлыкҗанны урманга чакыра икән — үз ихтыяры, Күмер Тауга килеп яңадан сатыла икән — тагын үз ихтыяры. «Кызым» дия-дия сыңар күзле Алялетдин картның ялваруы менә... «Кызым, җибәр-рмә яман Идуар-ртны аның кыр-рына, җибәр-рмә...» Нечкә дә җептән тукылган син, Гөлфия! Ил-көндә һәммә җан иясен дә кызганып бетереп буламыни?!

...Кабул итү бүлмәсендә Сәлимә таптана иде.

— Җиңги әбәткә чапты,— диде ул, мескен тавыш белән.

— Син аның урындыгын саклыйсыңмы?

— Юк ла, сине көтәм.

— Моңарчы минем түремдә куыклы лампа кебек кукраеп утыра идең, әллә ул гадәтеңне ташладыңмы, Сәлимә?

— Сөйләмә дә, име! Шайтан коткысы инде, малай, име! Үпкәләмә инде. Сине бәхет күмде, име, малай! Гылава хәтле гылава дустың икән, име!

— Сәлимә, сиңа нәрсә кирәк? Минем эшем күп.

— Хәзер, хәзер, малай. Миндә сыздым-боздымга талант юк инде, Гөлфия малай, име. Рәнҗетмичә генә җибәр инде син мине, малай. Үз теләгем белән китәм.

— Гаризаңны яз, кул куям, — диде Гөлфия.

— Гаризасын сырларбыз инде аның да... Безнең күрше йортта тегү фабрикасы иде, аны яптылар. Гылава гаиләсе белән вакытлыча шунда яшисе, ди, каттиж салдырганчы. Хатыны Эльза Васильевна пыр туздырып ремонт ясаттыра. Эчтән диварларны сүттереп, киңәйтә-зурайта, малай. Чая хатын икән. Мине ялламакчы ул. Хезмәт хакын да шәп куям, ди. Аннан зур нәчәлник хатыны ышыгында булам бит инде, Гөлфия малай. Урамда күкрәк киереп йөрермен. Кем-кем дигәндә, гылаваның хезмәтчесе, диячәкләр.

— Җаны теләгән елан ите ашаган, Сәлимә. Гаризаңны бир.

— И малай, синнән тәкъдимнамә сорала шул. Элек байлар, йорт хезмәтчесе алганда, шушы нәстәкәйгә караганнар икән. Эльза Васильевна да, хуҗаң, ягъни син инде хуҗа, име, язсын тәкъдимнамә, ди. Хәзерге байбәтчәләр шулайрак кылана икән, име. Сәлимә Басыйрова тырыш, намуслы, акыллы дигәнрәк формада язасың инде. Син язучы сурәтләү-тасвирлауларга мачтыр, тез дә чык кыягазга кешедәге иң күркәм сыйфатларны.

— Синдәге күркәм сыйфатларны эзләргә вакытым таррак, Сәлимә. Үзең табалсаң, язып керт, кул куярбыз.

— И малай, барыр юлларыңда ак чәчәкләр үссен! Син элгәреләр өчен үчләшмисең, име. Рәхмәт, малай!

Гөлфия уйланып калды. Бәлки, үз вакытында йодрык белән тамызып, исәп-хисап ясаргадыр? Чөнки сабыр итәм дия-дия эчкә җыясың да, көннәрдән бер көнне сабыр буасы ерыла һәм син, «уф, түзәр чамам юк» дип, дөньяның башына орыр өчен авыр чукмар күтәргәндә, артык көчәнеп, умыртка сөягеңне сындырасың. Сабырлык та куркыныч көч бит ул.

— Янабыз, кызым, янабыз!

Мәйсәрә уйларына чумган кызны сискәндереп җибәрде:

— Янабыз! Хуҗа безгә килә! Җиһазларыбыз да иске, идәннәребез дә ярыклы, тараканнарыбыз да ябык дигәндәй.

Баш мөхәррир урыныннан да кымшанмады.

Хаким дә, беренче язмасын китергән яшь малай кебек юаш кына:

— Рөхсәтме, Гөлфия Хан? Сезнең биләмәгез белән дә танышыйк,— диде.

— Рәхим итегез, Эдуард әфәнде.

— Нигә безнең белән чәйләмәдең, иптәш редактор?

— Сезнең хәбәрдән соң мөдир хатын авырды.

— Хәдисләр белән генә яңаклыйсың, ә? Сиңа ул килмешәк балалар кадерле икән, Күмер Тауда калдырырбыз. Ләкин бүтән бинада яшәрләр. Мин кунакларны тирес башында чәй эчертә алмыйм.

— Татарча шома гына сукалыйсыз икән, Эдуард әфәнде.

— Синең кисәтүдән соң телне кайрадым, Гөлфия Хан. Мин башта татар факультетын тәмамладым, аннан авыл хуҗалыгы институтын. Только син аңла: начальство халыкка саф татарча гына сөйләсә, тәэсир көче кими.

— Туган телем рәнҗемәс дисезме?

— Язучы халкының шул инде: рәнҗү, вөҗдан, намус, изгелек һәм башкалар, һәм башкалар. Миңа аларны искә төшереп азапланма. Синең ник усаллануыңны беләм мин, беләм, Гөлфия Хан. Монда кислородны томаладыларммы? Кемне, кемне ботыннан асыйм? Кемне җәзалыйм?

— Мин үзем гаепле, Эдуард әфәнде. Беркемне дә асмагыз да, кисмәгез дә.

— Без үзара килешү төзик, Гөлфия Хан: син миңа каршы телеңнән этләр өстермә. Батырайма, кыскасы. Миңа тәнкыйть пычагымамы! Макта син.

— Халык мактасын, Эдуард әфәнде.

— Фу, иске сүз! — Хаким, ике кулын кесәсенә тыгып, бүлмә буйлап әйләнде.— Тыңла, яңа мәкаль! Язгы бозга таян, халыкка таянма. Сез, язучылар, халык-халык дип авыз суы корытасыз, халык — көтү ул, ә көтүнең эченә артык керергә ярамый, тизәккә буяласың. — Арсланов өстәлгә таянды да тантана белән: — Мин сине уң яктагы вәзирем сыйфатында тотармын. Кигәнең — ефәк, ашаган табагың — көмеш, Гөлфия Хан. Давай, минем данны күтәреш син. Шул! Карале, сиңа нәни генә сорау...

Гөлфия бу сорауны көтә иде инде. Хакимнең олы башын кече итеп редакциягә керүе дә тикмәгә генә түгел, аның күңелен корт кимерә иде. «Нәни сорау»... Булыр сиңа нәни! Синең тәкәбберлегеңне дә бастыра алгач, тау хәтле зур, тау хәтле авыр инде ул.

Әмма Калын ирен пышылдарга гына җыенганда, ишектә Җәүдәт күренде. Мәйсәрә аны уздырмаска тырышкан бугай, ә көнләшүдән борын яфраклары киңәйгән егет киртәне сикереп кенә үткән иде.

— Сездә полная демократия икән, Гөлфия Хан,— диде хаким, бүртенеп.— Шаку-нитү дә юк.

— Мин яраткан кызым бүлмәсенә керәм бит,— диде Җәүдәт һәм, әйдә, көч сынашабыз дигәндәй, аякларын аерып, идән уртасына басты.

— Яраткан кыз... Кызык, очень кызык. Кайда эшлисең, егеткәй?

«Танымый, таныса, әтәчләнмәс, әз генә кикриге шиңәр иде»,— дип борчылган иде Гөлфия, егет:

— Мин Бәкерле хуҗалыгы рәисе, иптәш Арсланов,— диде.— Исемем — Җәүдәт.

Ахырдан кыз егетне борчак кебек кызган табада куырды.

— Нинди «яраткан кыз»! Мин эшемдә Гөлфия Хан — баш мөхәррир! Әдәпсез син! Бар, оялмыйча, дөньяга чәч ягатуыңны! Гайбәтчеләр сагыз итеп чәйнәсен!

— Тукта, тукта! Ник мин яратуымнан оялыйм ди?— Җәүдәт бирешмәде.— Моның ише сатлыкҗаннар колагына киртләп куюың таман гына әле ул. Сиңа нәфесен сузмас, белер Күмер Тауда безнең дә барлыкны. У-у, азгын түрәбашлар!

— Җәүдәт, ичмасам, син дөньяга кырылып йөрмә, нәфрәт җүнле хис түгел, ул күңелне корыта.

— Гөлфиям, иртән үк матур уйлар гына уйлаган идем, бу бәндәңне күргәч кенә дуладым. Селтәп ата идем дә, ярый чыгып тайды. Мин бит сиңа өч-дүрт минутка гына сугылдым, могҗиза күрсәтим дип кенә. Мәйсәрә апа, керт!

— Нәрсә бу?! — диде кыз, сәркәтип кулындагы кәбестәгә шаккатып.

— Яшел «чүлмәк»тә чәчәкләр, кызым. И Ходайның кодрәте!

Кәбестәнең нәкъ уртасында өч зәңгәр чәчәк үскән иде.

— Арыш кыры иде быелгы кәбестә басуы. Чәчәкләр ятсынмаган йомры башлардан. Кызлар, минем хуҗалыкта җыелыш, кич күрешербез.

— Кайнар егет,— диде Мәйсәрә, аның артыннан ишекне ябып.— Хаким, дим, ыргылма, дим, бая. Колагына да элмәде. Гашыйк ир-ат ут халык икән.

— Мин бәхетле, Мәйсәрә апа. Минем дә яраткан кешем бар.

— И-и, сине яратмаслыкмы соң, син нур бит, кызым.

— Нур ул мәхәббәт икән! Без егет белән кыз рәхәтендә озак юанмабыз, Алла кушып, тиздән өйләнешербез. Син мине йортыңнан кызың күреп озатырсың микән, Мәйсәрә апа?

— Йолаларыбызны үтәп, никах укыттырып, бирнә белән озатырмын, балакаем. Миннән кулыңны сорасын ут-егет, яме? Хәзер урманнан бизденң бит инде, кызым?

«Юк» дияргә батырлыгы җитмәде Гөлфиянең, «әйе» дип алдады. Бу ялганнан ул шундый туйган иде. Соңгы тамчысына кадәр сыгып-сыгып, Җәүдәткә сөйләргә кирәк. Хантимер исән, Хантимер аланда көч җыя... Бүген үк сөйләргә, бүген үк! Алар бербөтен җан бит инде хәзер.

Машинага утыргач та, шофер егет кай тарафка, Гөлфия апа? дип сорамый иде. Күрәсең, кызның йөзенә сары сагыш җәеләдер дә, егет, шуның билгеләрен «укып», кая табан кузгалырга икәнен чамалыйдыр.

— Җәүдәт абый миңа синең китапны төртте, Гөлфия апа. Җир шарындагы иң шәп язучының әсәре, ди. Сез анда ни... урманда иркенләп һава сулагыз, мин олы юл читендә китап укый-укый көтәрмен.

— Мин тиз, Рамил, бик тиз!

Урманда кызның йомышы юк иде инде. Дөрес, мәрхүм Ниязның әманәтен үтәмәде. Чү, моңа төзәтмә кертергә кирәк: әлегә үтәмәде, иртәрәк дип санады, һәрхәлдә, акылы «сабыр итәргә» дип боерык язды. Хантимер, үлемне җиңеп, хыяллар белән рухланып яши генә башлаган, аның юлына салам бөртеге дә ташларга ярамый иде.

Бу ирнең хата-кимчелекләре бихисап, әмма Хантимер Әхмәтов намус һәм вөҗдан дигән иң кыйммәтле төшенчәләрне базарга чыгарып сатмас кебек. Әйе, ул — беркатлы. Кырыс тормыш чынбарлыгына маңгаен бәреп канатса да, «мин нишләп һаман бер генә кат күлмәктән соң әле?» дип, үз-үзен мәкерхәйлә белән төрмәгән. Һәм… акылга да утырмаган иде.

...Сукмак очында Алялетдин карт саклый иде.

— Агач-куакларга көз сәлә генә сары буяу сибә,— диде ул, көрсенеп. Картның күзе дымланган иде.

— Хәсрәтләнмә, Алялетдин абзый, аның эше шул,— диде кыз, юатып.— Безнең җәйләр алда әле.

— Иһи-һи, кызым, Газр-раил юлдадыр-р, канатлар-рын җилпидер-р, мин китәр-рмен озакламый. Хантимер-ргә дә бүтәнчәли булышалмам, хәйләкәр-р явызлар-р аны хар-раплар итәр-р. Шуңа хәср-рәттә дә уйда башларым, кызым. Атка атланып үскән ир балага ат бер-ркатлылыгы йога икән, иһи-һи.

— Син аның бердәнбер туганы, ахры, Алялетдин абзый?

Карт имән яфрагы белән сыңар күзен сөртте.

— Бер-рдәнбер,— диде.— Атасы белән анасы мөгаллимнәр-р иде, мәктәптә куна-төнә эшләделәр-р. Малай гел минем култык астында иде. Иһи-һи, төштә күек хәзер ул чаклар-р.

Хантимер аланда киерелеп печән чаба, ә аның янында җигүле ат тора иде.

— Кем бу?! — диде Гөлфия, сокланып. Гүя җиргә ап-ак болыт ишелгән дә ак бахбайга әверелгән иде.

Хантимер чалгысына таянды.

— О-о, кунак кызы! Исәнләш, Сылукай туган.

Ат башын чайкап кешнәп җибәрде:

— Миһа-һа-а-ай...

— Һай, һай-й,— диде кыз, аңа табан йөгереп.— Китмә-ә, бахбай-болыт, ялыңа ябыштырып мине дә күкләргә алып мен!

— Ул, кызым, адәм телен аңлый,— дип кеткелдәде карт.— Җәле, Хантимер-р, ар-рбага бер-рәр сәнәк печән ыр-ргыт. Вәт маладис. Җәле, аяклар-рыңны салындыр-ртып менеп утыр-р, кызым. Дилбегәне ипләп кенә кагып, Сылукай, әйдүк, Тулпар-рга апкайт, дисәң, ул сине бор-рма-бор-рма ур-рман эчләр-рендә дә адаштыр-рмас, туп-тур-ры безнең ызбаның капка төбенә кайтып туктар-р. Киң ишегалдында тояк шомар-рткан колын чаклар-рын сагына, малкай.

— Караңгыда да урман гизәме, Алялетдин абзый?

— Гизә, кызым, гизә.

Кыз, дилбегәне әкрен генә селкеп, картның тылсымлы сүзләрен кабатлаган иде, Сылукай дәртләнеп урыныннан кузгалды. Арба тәгәрмәчләре җыр җырлый. Шыгыр-шыгыр, шыгыр-шыгыр... «Ак болыт» аны әкиятләр иленә алып китеп бара...

— Әй абзый, абзый,— диде аларны елмаеп кына күзәткән Хантимер.— Син үзең дә ат сыңары. Авыл дип үләсең инде. Тулпарың күптән таралды бит, анда җан әсәре юк, нигезләрдә алабута үсә.

Карт авылына ашкынган Сылукайны ияреннән тотып туктатты.

— Тр-р, җанкай. Мона нәстә, Хантимер-р, кычыткан үссен, алабута үссен, миңа бар-рыбер. Мин ахыр-рзаманда үз зияр-ратымнан кубар-рылам. Минем анда ике ар-ршын җир-рем тамгаланган. Тактада җазу: Камалетдин углы Алялетдин. Иншалла, соңгы васыятемне бер-рәр изге бәндәсе үтәр.

— Ә-ә, энкәйнең кабере янәшәсендәме тамгаң! — Хантимер картка бармак янады.— Һаман энкәйне яратасың икән, Алабай. Син әнә язучыга сөйлә мәхәббәтең тарихын, әсәрләрендә файдаланыр. Ә-ә, ояласыңмы? Кара, бит алмалары ничек кызарды.

— Кит, оланшак, көлмә! — Алялетдин карт күңел кылларына кагылганга разый түгел иде.

— Мин көлмим дә,— диде Хантимер, җитдиләнеп.— Ярату гаепмени. Әнкәй кияүгә чыккач та, син бүтән кызга өйләнмәгәнсең. Мең рәхмәт, мине кем ат ярышларында узыштырып чыныктырыр иде. И-и, Алялетдин абзый, атамнан да артык идең инде син. Күзеңне минем аркада югалттың.

— Сездә әллә ниләр бар,— диде кыз, бер картка, бер Хантимергә карап.

— Безнең авылның күле тирән иде, Гөлфия дускай. Төптән ун чишмә кайный, диләр иде олылар. Мин коенганда чишмә турысына эләгәм дә, тәнем салкыннан куырылып, бата башлыйм. Ярда балалар кычкыра. «Хантимерне су пәрие урлады, Хантимер үлде!» Алялетдин абзый шул тавышны ишетеп күлгә сикерә дә... Йөзе белән очлы тимергә кадала. Тамаша, ди, күл буенда. Алялетдин абзыйның күз тишегеннән кан ургыла, ди. Кулында һушсыз Хантимер, ди. Бездә шундыйрак хәлләр бар иде, Гөлфиякәй. Ә син ниләр кыйратасың?

— Минме? — Кыз күл вакыйгасыннан айнымаган иде, исенә килеп:— Мин мәхәббәт утында янам,— диде.

— Чынлапмы, Гөлфия?

— Балачакта без «ике күзем чәчрәсен» дип каргана идек.

Хантимер чалгысын җиргә аударды.

— Менә нинди күңелсез хәбәр,— диде.— Ни галәмәттер, акыл дәрәҗәсе югары үскән хатын-кыз да, сәясәтчеме ул, галимме, патшабикәме, бер тапкыр ялгыша. Бу ялгышу мәхәббәт дип атала, Гөлфия.

— Матур ялгыш, Хантимер.

Ир һаман дәлилләре белән һөҗүм итте:

— Ярату сизгерлекне ала.

— Мин аучы түгел, миңа сизгерлек кирәкми, Хантимер.

— Алайса бел: ирләрнең бик сирәге генә сөйгәне хакына яши. Алялетдин абзый кебекләр җир йөзендә санаулы гына.

— Ул мине ярата! Иртәгә өйләнәм дигәндә генә кызыннан да ваз кичте хәтта.

— Аң-ла-шы-ла,— диде Хантимер, сүзен иҗекләп.— Бер тапкыр хыянәт иткән ир үлгәнче әлеге гадәтен куа.

— Телең зәһәр-р синең, Тимер-р,— диде Алялетдин карт,— аһ, зәһәр-р!

Ә кызның күзенә тыгылган рәнҗү, чык булып, менә-менә үләнгә тамачак иде. Аның аланны дерелдәтеп кычкырасы килде: «Юу-ук, Җәүдәт — хыянәтсез җан!» Ул кычкырмады, иренен тешләп:

— Дустыгыз Күмер Тауны үзгәртә башлады,— диде. Аңа елап тору оят иде.

— Ниләр майтарыр икән, җегеткәй? — дип уфырды Хантимер.— Тәҗрибәсе юк. Шәт, син минем үтенечне аяк астына салып таптамассың, дускай.

— Таптамам,— диде Гөлфия.

— Бүр-регә куян дус түгел,— диде Алялетдин карт. Ул кәкре бармаклары белән Сылукайның ялын тарый иде.

Хантимер бу юлысы аның чеметүенә игътибар итмәде.

— Мин, мөгаен, атна-ун көннән Казанга күчәрмен,— диде һәм, бераз кызга табан янтаеп: — Абзыйны калдырмаска исәп, йөрәге бер генә җепкә эленгән бит,— диде.

— Дөньяга күренүегез хәерлеме соң? Дошманнарыгыз Хантимер Әхмәтовның терелүенә нәрсә дияр?

— Күзләренә чалынмам,— дип көлде ир.— Гөлфия, син Күмер Тау тоткынлыгында яшәп, бәлки, Дамир Салиевның сайлау алды программасын укымагансыңдыр.

— Әйе, укымадым. Әй, миңа ниемә ул Салиевлар! Бездә хәзер көн дә сәясәтче туа.

Хантимер кызның арык җилкәсенә кулын салды.

— Алай димә, Гөлфия Хан! Бүтәннәрнеке белән чагыштырыр идең, бәлки. Син шуңа төшен: без — икенчеләр, «һава торышы»н ничек теләсәк, шулай үзгәртәбез. Беренчеләр берни дә хәл итми.

«Мактанчык»,— диде Гөлфия, эченнән генә.

— Халыкка сездән ярты тиенлек файда юк, Хантимер. Зинһар, башымны әйләндермә. Сезнең хакыйкать дигәнегез дә үзегездән ерак китми бит.

Хантимер аның сүзләренә үпкәләмәде:

— Йә, Салиев белән таныштырыйммы соң? — диде.

Ләкин Гөлфиянең күңелендә әз генә дә кызыксыну уянмады.

— Юк, юк! Сез барыгыз да бериш инде.

— Ә ул сине бик әйбәт белә,— диде ир, хәйләкәр елмаеп. — Искиткеч кеше дип соклана. Хәтта җавапсыз ярату белән ярата!

— Шаярма, Хантимер.— Гөлфия ирнең кулын алып ташлады.— Сәясәт белән авырган ирләрдә мәхәббәт күзәнәкләре үлә.

— Үлмәсә нишләтәбез, Гөлфия дускай?

— Дамир Салиевка кайнар сәлам юллыйбыз. Җәүдәт белән безнең туйга килсен.

— Курыкма, ул сиңа мәхәббәтен аңлатмас. Соңлаган икән, асыл кошка бүтәннәр җим сипкән икән. Йә, бары тик дусларча танышу мәсьәләсендә ничек?

Гөлфия тәбәнәк ызбага күз сирпеп-сирпеп алды. Мөгаен, шәһәр ыгы-зыгысында кайнап арыган дәү сәясәтче салкынча җиләс бүлмәдә йокы симертәдер. Затлы кунакханәләрдән дә затлырак була шул гади агач йорт... Төскә-биткә нинди кеше икән соң? Дамир Салиевның моңарчы йөзен күрсәтеп, тавышын ишеттергәне юк иде. Сәер болар: тараканнар сыман качалардыр, посалардыр... Хәер, Гөлфия алар белән йөз ел күрешмәсә дә, берни дә оттырмый.

— Кыстама, Хантимер. Мин арттагы күперләрне сүттем инде. Хушлашканда нәрсә диим? Күп теләктән мәгънә юк: Ходай сакласын сезне...

Хантимер белән Алялетдин карт бер-берсенә караштылар. Кинәт ир дөрләп кабынды:

— Мин кайдадыр ялгышам төсле,— диде. Кызарта-кызарта киң маңгаен ышкыды.— Аһ, бу баш, чүп тутырган баш, шөрепләре бушаган аның. Син Эдуард дип аһ-вах итмәдең, әйеме? Син аңа битараф, юк, синдә аңа эче нәфрәт! Ник? Ни өчен? Нәрсә яшерәсең, Гөлфия Хан?! Мин, дустымны сиңа сылап, бәлки, мәңге гафу ителмәслек хата ясыймдыр, ә? Син хәзер миңа туган сеңлем кебек тоеласың.

— Хафаланма, Хантимер. Без әле очрашырбыз да.

— Әйдә, безнең белән Казанга кит, Гөлфия. Син — язучы, сүнгән учактагы кисәү кебек пыскырга тиеш түгел.

Кызның йөрәге сулкылдады. Күзен каплаган яшь бөртекләре керфек очын чылатты.

— Мин таш каланы сагынам, бик-бик сагынам... Тик Күмер Таудан киталмам шул, яраткан кешем монда бит. Җәүдәт — җир кешесе… Ул мине өзелеп ярата… Казан да якын… Киталмам шул… Иялэштем үзегезгә.

Әллә офыксыз урман көрсенде, әллә Хантимер...

— Гөлфия, әгәр берәр ярдәм кирәксә, мин барлыгын онытма,— диде ир һәм кесәсеннән куен дәфтәре алып сызды.— Менә бу Идел бистәсенең Текә яр урамы. Менә бу икенче йорт, кызыл кирпечтән, тимер челтәр рәшәткәле. Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында, иртәме, төнләме, капканың төймәсенә басасың. Ике ир-ат каршыңа чыгар. Берни дә сорама, исемеңне генә әйт. Алар син танышудан баш тарткан Дамир Салиев белән күрештерер үзеңне. Ә Дамир ул,— Хантимернең кырыс чырае язылды,— ...без инде, Гөлфия туган. Нишләтәсең, өр-яңадан туган кешегә өр-яңа исем кушалар.

...Сукмакта гына Гөлфия таралган зиһенен туплады:

— Синең серең шул идеме, Алялетдин абзый,— диде ул юлдашына. — Хантимер — Дамир... Кәмит тә соң бу ирләр!

— Кеше сер-рендә минем эшем юк,— диде карт.— Чөнки дә үземнеке куәтле. Синең бөр-ркет Хантимер-р белән ар-раң өзелмәс, шәт.

«И картлачкаем-бәгырькәем, бөркет дигәнең нибарысы чыпчык кына түгел микән?.. Чынлап та, кәмит бу ирләр. Берсе Күмер Тауда кәпрәя, икенчесе урманда… Ә без алар корган черек дөньяга риза-бәхил булып яшәргә тиеш».

— Син аңа тапшыр-р, кызым, минем күңел сер-рләрен, җәме! Үземнең көчем җитми. Авызымны ачсам, телем аңкауга ябыша. Сөйләттер-рми кодрәт иясе.— Алялетдин карт, гыж-гыж сулап, уң кулы белән каен агачына таянды.— Чут кенә хәл алыйм... Һәй, бар-р иде бер-р теш шыгыр-рдатсам, ур-рмандагы бүр-реләр-рне калтыр-раткан гайр-рәтле чаклар-р. Кызым, сер-р төенен кешесенә кар-рата гына

чишәләр-р. Тишексез кешеләр-ргә генә, иту коела ул. Минем мәр-рхүмә анам әйтер-рие: «Мичтә җиде әпәең унса, бер-рсен ир-реңнән яшер»,— дип. Сер мисалы да шулай. Син дә җегет канатыңа бер әпәеңне күр-рсәтмә.

— Сөйлә, Алялетдин абзый.

— Хантимер-р нәстә ди? Һаман әнкәйне яр-ратасыңмы, ди, әһ, җүнсез малай. Улымның анасы белән күрше кабер-рдә ятыр-рлыгым жукмыни? Хәер-рче Камалетдин углы дип Зәйтүнәне миңа бир-рмәде атасы, мөгаллим Әхмәтзәки йор-ртына төшер-рде. Кыз минем куенда чыр-расын кабызган иде инде. Шуның белән шул, кызым: Хантимер-р минем кан улым. Мин үлгәч аңа тапшыр-р, тәр-рбия кылган Әхмәтзәки атасы белән бер-рәттән минем рухыма да догалар укытсын. Э-э-э,— карт ыңгырашкан аваз чыгарды.— Ата йөрәге сизмимени, э-э-э. Дус дигәне кабахәт адәм, бә-әк кабахәт.

Гөлфия дә янәшәдәге агачка сөялде. Нәзек кенә каен авырлыктан бөгелмәде. Имән генә нык, диләр тагы. Әй Раббым, бу сыңар күзле моңсу Алялетдин саташа мәллә? Саташмый, юк, саташмый. Ата гына үз баласына йөрәген ярып бирә. Ник ул үз серен Гөлфиянең җанына бушата. Кыз сер җыя-җыя шартлый бит инде.

— Беренче тапкыр мин синнән шундый курыктым, шундый курыктым, Алялетдин абзый. Йон баскан йөз, сыңар күз, дорфа тавыш... Хәзер тагын да куркынычрак син. Сереӊ белән куркыныч... Бергә чакта, исән чакта үзеӊ әйт, үзеӊ! Илле ел улым дип эндәшергә тилмергәнсеӊ бит инде!

— Жук, кызым, Зәйтүнәмне р-рәнжетмим, жук! Әманәтем сиңа күчте. Ишет!

Кайдан көч иңгәндер, карт, гәүдәсен тиен кебек йомарлап, куак ешлыгына сикерде...

**10**

Кичне суырып китергәндәй булды Гөлфия. Аланнан кайткannан бирле йөрәк елый иде. Аңа юатучысы — Җәүдәт кирәк иде. Ә егет Күмер Тауга эңгер-меңгер иңгәч кенә ишек шакыды.

— Нишләп утсыз интегәсеӊ? — диде Җәүдәт, кабызгычны чертләтеп.— Синнән әллә төнлә дә хәреф чүпләтәләрме?

— Кемдер миңа, фәлән сәгатьтә очрашабыз, диде дә...

— Ачуланма, газиз җаным, мин әле генә кунакларны озаттым.— Егетнең йөзе борчулы иде.— Артымнан ук бастырып килде абзаң. Мин-минлегенә тигәнмен икән.

Урманнан җанын каерып алалмаган кыз:

— Кем турында сөйлисеӊ син? — диде.

— Шул инде... Күмер Тауның яңа патшасы. Хуҗалыгыңны күрсәт, ди. Койрыкта ялагай Фәлинов шуыша. И ярарга тырыша Эдуард Арслановка! Теге күркәсе икегә ярыл дисә, өчкә үк ярыла, валлаһи. Әле Бәкерлене яманлаган итенә. Имеш, без арттан беренче. Ух, сорыкорт, итек үкчәсе белән генә сытасы!

Җанга уралган сагыш йөрәкне чәнчи иде.

— Мин сине сагындым,— диде кыз, пышылдап кына.— Сагындым...

Җәүдәт ярсуыннан чукракланган иде.

— Җыен әләм-әтрәк баш та муен! Ул Фәлиновлар салам селкеткән кеше түгел. Гылавага синең сүзеӊ үтә, Гөлфия, чистартсын хакимиятне шул куштаннардан.

...Ак бахбай аны адаштырмыйча урманнан алып бара... Арыса да туктамасын иде Сылукай. Арба тәгәрмәче шыгыр-шыгыр итә... Әллә Сыңар күз теш шыгырдата микән? Юк, юк, усал түгел лә Хантимернең этисе...

— Гөлфия, Гөлфия, дим! Нигә күзеңне йомдың? Син, ахры, мине тыңламыйсың. Уян! — Җәүдәт өстәлдәге кәгазьләрне кыштырдатты.

— Тыңлыйм,— диде кыз.— Безнең ялгыш беләсеңме кайда? Без егыла-тора бер көнлек дөнья куабыз, Җәүдәт! Без хәтта Ходай биргән ярату хисе белән дә ләззәтләнә алмыйбыз, баштанаяк тормыш мәшәкатенә батканбыз.

— Кем инде ул «без»?

— Мин, син, алар...

— Син, ахрысы, хыялый әсәр язасың, Гөлфия. Мин бит ачынып сөйлим. Күкрәк кыза бит!

— Җәүдәт, мин дә ачынам. Син үчтән кара янып миңа йөгердеӊ, әйеме? Хаким Фәлиновның артына типсә, икенчесе утырачак. Әрсез чүп үләненең сабагын өзсәң дә, тамыры кала.

— Аптыраган, валлаһи! — Егет кәчтүм төймәләрен ычкындырды.— Эссе синең бүлмәдә. Әллә мин янам. Хурландыра, Гөлфия. Ат кебек җигелеп тартканда, ике каш арасына инә кадыйлар. Уф, эссе! — Җәүдәт пыяла савыттан су агызып эчте.— Ярар, Фәлинов белән вакланмыйм дисәң, башлыкка фикерләремне үзем җиткерермен. Атна-ун көннән янә безгә килмәкче әле абзаң. Сарык фермасын күрде дә, шашлык пешереп сыйла, диде. Ике бәрәнне симертергә дип аерым яптырдым. Уф, эсселекләр, май эри.

— Җәүдәт җаным, болай булса, син дә Фәлиновтан кимен куймыйсың бит инде! Чакырма да, сыйлама да, күч мәктәпкә укытырга. Гөнаһсыз сабыйлар янында күңелең дә керләнмәс.

Бу тәкъдим егеткә ошамады.

Ул, үртәлеп:

— Күч, күч, имеш! — диде.— Фәлиновның энесе эшсез әнә, агроном кисәге күптән хуҗалык сорый иде, нишләптер Әмирулла гына хут бирмәде. Минем урынга ул мәнсезне тыгачак абыйсы. Эткә майлы калҗа каптыралармыни!

Гөлфия бүтән бәхәсләшмәде. Үзе юл ярган туры Җәүдәт бүген әз генә читкә тайпылган, иншаллаһ, иртәгә ул Фәлиновлар белән булашып яшәүнең нәфес коткысы икәнен аңлап, хатасын төзәтер. Инде ул аңлады да бугай.

— Әй, нишлисең син, тиле малай! Бердәнбереңә «сагындым» дип йөз кат, мең кат кабатлыйсы иреннәреңдә Фәлинов та Фәлинов!

— Гафу ит, кичер, Гөлфиям. Синнән яшерер нәрсә юк. Шуңар сөйлим бит мин.

— Мин дә шулай, Җәүдәт,— диде кыз.— Синнән берни дә яшермим. Эдуардның теге дусты исән...

— Исә-әң?!

— Хантимер үлмәгән. Исемен үзгәрткән. Дамир Салиев ул хәзер.

— Менә яңалык! Кайдан ишеттең?

Колак төбендә Алялетдин картның кисәтүле тавышы: «Җегетеңә бер әпәеңне күрсәтмә, күрсәтмә, күрсәтмә...»

«Нишлим, йә, нишлим?! Без Җәүдәт белән бербөтен. Бары да уртак, югы да уртак. Ә соңгы җиденче әпәй — хикмәтле картның аланы. Гөлфиянең аны телемнәргә телеп, ятлар табынына куярга хакы бармы соң? Юк бит, бер Аллам, юк!»

— Казандагы танышым шылтыратты, Җәүдәт.

— Сатлыкҗан Эдуардка нинди сюрприз, ә!

— Дамир Салиев әлегә дөньяга күренми икән.

— Куба икән җил-давыл, куба-а! Ә кассета нәрсә, Гөлфиям?

— Аның үз чираты, Җәүдәт. Без бүтән бу хакта сүз куертмыйк, яме! Ул синең белән минем сер.

Егет, ачык тәрәзәдән башын тыгып, кызышкан яңакларын суытты.

— Уф, эссе! Кар базына төшеп уынырсың, валлаһи. Исән дисең, ә! Җил-давыллар куба икән. Теләсәләр нишләсеннәр, безнең читләргә касаниебыз юк, безнең үз җырыбыз, үз көебез. Мин сиңа атап шигырь яздым бит әле, газиз җаным. Бак, колхозчы малае хисләрен энҗе итеп бер җепкә тезде.— Җәүдәт, бөгәрләнгән кәгазь кисәген сыпырып: — Укыйммы? — диде.

— Укы, шагыйрь,— диде Гөлфия.

— Тыңла, ханбикә.

> Яратаммы? Яратамдыр.
> Җәйләрдә синең күзең.
> Янымда да, җанымда да
> Яшисең хәзер үзең.

Кыз чыркылдап көлде.

— Кемнән чәлдердең?

— Китапханәдә шигырьләр җыентыгын актарган идем. Сине нәрсә белән сөендерим, мәйтәм.

— Мин болай да сөенәм, Җәүдәт...

«Ниһаять, мин дә сөю бакчасында йөрим, мин дә сөю алмасының тәмен татыйм»,— диде кызның күзләре, ә теле шуны әйтергә оялды.

— Син гел боек, Гөлфиям. Без кешеләр арасында сиңа читендер ул, әйеме? Без тупас, дорфа, томана. Тагын кемнәр әле без? — Егет колак артын кашыды.— Без — тамак коллары, без — әрсез чүп үләне...

Гөлфия егеткә сокланып һәм яратып карады. Менә кызның кадерле кешесе... Аның бер генә кимчелеге дә юк, ул — әүлия... Ничек моны төчеләнмичә генә аңа белгертергә икән?

— Син кешеләр түгел, Җәүдәт, син...— Кыз үз хисләреннән үзе кайнарланды.— Син... син әллә нинди инде шунда. Кешеләр минем бәгыремә камчы белән сыдырганда, мин сиңа сыенам да... терeләм. Хәзер мин бер дә кыен ашамыйм инде, чөнки... син янымда да, җанымда да. Шигырьдәге кебек...

...Ул бәхет канатларында тирбәлеп кайтканда, фатир хуҗасы белән күрше хатыны чәй эчә иде.

— Нинди яңалыклар бар, Сәвия апа? — диде Гөлфия.

Ятим балалар йорты мөдире тезләренә шап итеп сукты да:

— Бирәннәр һапылдатты яңа өебезне,— диде.— Дөбер-шатыр такта ташыйлар. Әле генә шуннан кайтышым иде, бергә кулга-кул тотынышып, Казаннар аша салдырган бина бит, дим, Әмирулла Дәминовичларга барып карыйм, ни киңәш итәр икән, дим, ә ул йөрәк белән бүлнистә ята, ди. Миңа хәзер йортыннан битәр нарасыйларымның таралуы зур хәсрәт. Искесен төзекләндерсәк, яшәр идек әле.

Балалар хакына баш иргә кирәк иде. Иртәгәсен Гөлфия белән мөдир хатын хакимияткә керделәр.

— Никакой искегә ремонт, кунакханәгә ямьсез вид создавать итә ул,— дип акырды хаким.— Аннан китәсез, центрда ике балалар бакчасы, берсе сезгә. Ике ай срок, живо шунда урнашыгыз! Минем добротам аркасында балаларыгыз Күмер Тауда үсә. Бу изгелек турында газетага статья язарга надо. Апа, иди, шагай, ә син задержись, баш редактор.

Яңа хаким, буш өстәленә яртылаш авышып:

— Миндә пока кәгазь өеме юк, бөтен идеяләрне башымда әйләндерәм,— диде.— Кайчан интервью эшлисең, Гөлфия Хан?

— Бераз сезне өйрәнәм инде, Эдуард Әминович,— диде кыз, хәйләләп.— Күмер Тауда эш тә күрсәтегез.

— Ну, ладно. Өйрән, өйрән, мин сиңа добро бирәм. Үзеңнең фронттагы җиңүләреӊ мактанырлыкмы, Гөлфия Хан?

— Нинди «җиңү», Эдуард әфәнде?

Хаким калын иреннәрен бөрештерде:

— Ну, ну, кыйланма. Мәхәббәт фронтында сугышасың икән син. Шул авыл гыйбадын сөясеңмени? Ха-ха-ха! Тәгәрә дә үл: күктәге йолдыз тирес кортына гашыйк! Ха-ха-ха!

Гөлфия дә, җәясен тартып, агулы ук очырды:

— Ялгышым зур икән, әйе. Миңа сезне сайларга иде, иптәш фән белгече. Сез — җитез, өлгер, әрсез ир-егет, әнә хакимият баскычыннан ничек тиз йөгереп менеп киткәнсез, өстәгеләргә ялагайлану талантын сирәк кешегә бирелә.

Эдуард Арсланов:

— И хатынкай, син минем өчен картайгансың, миңа уналты-унҗиде яшьлекләр тансык,— дип шаярып кына җәядән читкә тайпылмакчы иде, әмма ук аның мин-минлеген тишеп үткән иде инде. Ул, ярсып-бүртенеп: — Син, Гөлфия Хан, мине пычратма, яме! — диде.— Минем тырышлыгымны бәяләделәр, миңа ышандылар, кыскасы. Мин беркемгә дә ярамадым. Ул шик сиңа каян килде, ә?

«Син сатылдың... Синең бөтен тырышлыгың шул иде».

— Карале, теге кем, хыялый Нияз Сафин минем хакта аны-моны әйтмәгәндер, ә?

Гөлфия, гаҗәпләнгән булып:

— Әллә сез танышлар идегезме? — диде.

Хаким корсагы кабарганчы рәхәтләнеп сулады. Гөлфиянең бу соравы эчне кимергән «нәни сорау»-га җавап иде. Әйдә, әлегә тантана ит, Эдуард Арсланов. Ә без капчыкта озак ятар микән соң? Ай-һай!

— Ну, ярар, мәрхүмнәрне каберләреннән куптармыйк. Ә син ничего хатын үзең,— диде кәефе күтәрелгән Калын ирен, күзләрен майландырып.— Бәкерле гыйбадына әрәм син. Минем искиткеч матур тәкъдимем бар: икәү төн кочагында бер ләззәтләник әле без. Бер-беребезне ошатсак, элемтәне тагырак та көчәйтербез. Кайсы төн сиңа кулай: дөм караңгысымы, айлысымы?

Ялгыш юеш бакага орындымыни, Гөлфия җирәнеп куйды.

— Ул төн мәңге җиргә иңмәс шул, Эдуард әфәнде.

— Киреләнеп чиратның койрыгында калмагаең, Гөлфия Хан,— дип шаркылдады хаким.

...Беркөнне ятим балалар йорты мөдире урамда очрады да:

— Яңа өебезне фахешханәгә әйләндерделәр, өч бүлмәсе хуҗаныкы. Хатыны Казанда чакта пәри туе ясый. Фәлиновлар моңа Әлмәттән япь-яшь кызлар ташый. Ак як, пакь як идек, ничек пычраталар безне, Аллам, каһәр суккан килмешәкләр,— дип әрнеп-әрнеп елады.

Ике тәүлек хакимияткә «булышкан» Рамилнең дә теле «чишелде»:

— Сиңа гына әйтәм, Гөлфия апа. Бүтәннәр ишетмәсен, иту, мине Фәлиновлар астыра. Без ике яшь кенә нәстәкәйне Казанга аппардык. Мех кибетенә. «Мелита»га. Фәлинов аларның икесенә дә ике йөзәр меңлек тун апбирде. «Әгәр хуҗага тырышып хезмәт итсәгез, бүләкләрне җәлләмибез»,— диде. Әллә акчасы гылава кесәсеннәнме? Мине дүрәк димәсеннәр, без белгәнне тавык чүпләмәгән. Аннан соң мин ул озын ботлы нәстәкәйләрне балалар йорты ишегалдына илтеп бушаттым. Тәрәзәдә ялангач шәүләләр иде. Безнең авылда халык йөз тәңкәгә тилмерә. Монда акчага утырып шуалар.

## 11

Ак як, пакь як... Төс үзгәртмәгән берәр аймагың калды микән? Күлләреңдә көмеш балыклар йөзә, агач-куакларыңда сары сандугачлар сайрый, бакчаларыңда алмагачлар ак чәчәк ата, басу-кырларыңда алтын башаклар үсә... Табигатьнең яралыш-яратылуында хыянәт юк. Йа Раббым, син адәм затын да аклыкка төреп тудырасың, тик ул син тыйганнардан тыелып яшәми һәм карала башлый. Соңгы вакытта Җәүдәт тә дөнья малына кызыга башлады, нәфес, язгы үлән кебек, борын төртеп маташа иде.

— Һи-и, кем кәбестә сатып баесын инде. Алты мең тонна тапшырдык, табышы — тычкан койрыгы.

— Аның койрыгы озын ич, Җәүдәт.

— Һи-и, үзе озын, үзе нәзек. Урламасаң, яшим димә инде син. Әнә үзәктә гөмбәләр кебек ташпулатлар калка. Фәлинов та йорт төзи, түбәсе — амбар калае. Кумады шул куштанны абзаң. Кай төшләре бе-

лән ярыйлардыр. Иелгән башны кылыч кисми анысы. «Шестерка»ларның бөтен җирдә дә бәясе зур. «Шестерка», ягъни «алтылы» — халык телендә хуҗаның артын ялаучы хезмәтче ул, Гөлфия. Зато балда-майда йөзә. Безнең төсле, борыны белән җир сөреп, тиеннәр чүпләми.

Егет шулай күңелендәгесен актарып сала иде дә аннан, кызның бу аһ-зарларны өнәмәсен сизеп:

— Ни булды соң әле миңа? Ач-ялангачмы мин? Гарип-горабамы? Яраткан кешем янымда да, җанымда да, — дип үкенеп туялмый иде. Тик ул хакимнең Бәкерлегә бик еш кунакка килеп йөрүен Гөлфиядән нигәдер яшерә иде. Аның каруы шофер егет хәбәрләргә бер дә сусатмады.

— Гөлфия апа, безгә туган тиешле Моратхан абзый ни дия. Җәүдәт атна саен сарык суйдырта, без хәзер шашлык ясауда тәмам остардык, грузиннар көнләшерлек, дия. Мишә буендагы таллыкларда гылаваны сыйлыйлар икән.

— Гайбәт ул, энем,— диде кыз.

— Чын, Гөлфия апа, чын, Моратхан абый юк-барны тәтелдәми, намусы чиста аның. Күзе дә зерә очлы. Безнең рәис бик кунакчыл икән, гылаваның авызына чәйнәп кенә каптырмый, дия. Ышанмасаң, Җәүдәт абыйның үзеннән сора.

Сорамады Гөлфия. Ваклыклардан өстен җанга чүп-чар тутырмыйлар. Җәүдәт андый икейөзле ир түгел. Ул бит инде Эдуард Арсланов белән ике арада коры эш мөнәсәбәтләре генә урнаштырырга икәнен аңлый. Бу дөньяга сатлыкҗан кубызында биер өчен тумаганын да белә. Айлы төндәге учак тирәсенә иң якын кешеләр генә җыела.

Әмма башын күпме генә кыркыса да, күңелдә яралган шик үсә-үсә зурая иде. Егетнең үз-үзен тотышы сәерләнде. Ашыга, яна, пешә... Хәзер аңарга тәкәбберлек тә чат ябышты. Җәүдәт, тауларны җир белән тигезләрдәй булып, һаваланып сөйләшә иде. Шундый минутларда Гөлфия урманны сагынды. Аланда бушлыктыр инде... Әтиле-уллы тимер капкалы йортта яшидер. Сыңар күзле карт һаман серен яшереп саклыйдыр һәм, үзе үлгәч, аны Гөлфия иясенә җиткерер дип өметләнәдер...

Беркөнне Җәүдәт шылтыратты.

— Сөеклем минем, күз нурым минем, безнең Казанга — уңыш бәйрәменә китеп ятыш. Өч алдынгы хуҗалык рәисе исемлеккә кертелгән.

Кыз, гаҗәпләнеп:

— Син кайчан алга чыктың соң әле? — диде.

Чыбык очында озын итеп суладылар.

— Тырыштык инде... Әзрәк этсәләр, арттагылар да алдан чаба, Гөлфия. Тырыштык, әйе... Абзыйның хәер-фатихасы белән барыш. Төркемне үзе җитәкли. Сау бул! Сагынып көт!

Гөлфия көч-хәл белән ике генә сүз әйтә алды:

— Хәерле юл.

Бәйләнчек уйлар уптым илаһи тагын җанга ябырылган иде. Аның Җәүдәте нишләп хакимгә сырпалана икән, йә? Тырыштым, ди. Таллыктагы төнге бәйрәмнәр хак микәнни соң? Бер карасаң, моның нәрсәсе бар: рәистә сыйланалар. Ә сыйлау артында ниләр ята? Егет ни тели? Ул да «алтылы» санына әйләнергә җыена микән әллә? Ул да... вак тауар хәлендә калып, сатылырга әзерләнәме? Йа Раббым, нинди куркыныч уй. Гөлфия шуны чирканмыйча күңелендә әвәләп йөртә бит әле!

Якшәмбе көн иде. Көз кара туфракта эре-эре бәрәңгеләр тәгәрәтеп, куаклардан шыбыр-шыбыр тулып пешкән алмалар койдырып шаяра иде. Гөлфия белән Мәйсәрә бакчада кайнаштылар. Кыз корыган бәрәңге сабакларын иске мунча янына өя иде, май кояшы сыман балкып, Җәүдәт килде.

— Кызлар, ачуланмагыз, Казаннан туры сезгә кайттым,— диде ул. — Өч көн бәйрәм иттек. Бии-бии таш каланың асфальты тишелде. Сезгә сумкада күчтәнәчләр, чәй эчәбезме?

Хуҗабикә:

— Эчмәгән кая, хәзер чәйнекне гөжләтәм, энем,— дия-дия, өйгә кереп китте.

Аулакта калгач, егет бәрәңге капчыгы аша үрелеп, Гөлфияне кочаклады.

— Нихәл, күз нурым? Әллә сөенмисеңме кайтуыма, былбылым-сандугачым?

— Сөенәм, — диде кыз, коры гына. Җәүдәтнең төчеләнүе аны сагайта иде. Ни кылана, ә? Андый шикәрле-баллы сүзләрне яратмый бит инде Гөлфия. Төчеләнү — ялагайлар сыйфаты ул.

Егет бәрәңге сабаклары өстенә утырды.

— И туган як көзенең матурлыгы! Шәһәрдә тузан, сөрем, төтен. Безнең бәхет Күмер Тауда, Гөлфиям, былбылым-сандугачым. Ныгытып тамыр җибәрик без шушы туфракта.

— Ерактан урама, — диде сагайган Гөлфия. — Эдуард белән сине сарык халкы тәмам дуслаштырган, ахры. Ул сиңа урынбасар кәнәфиен аткарамы?

— Бигрәк син тагы! Сарык белән генә түрәне бөгәрсең ди! Алар ашаган ризыгын икенче көнне үк оныта. Тавышыңда каһкаһә бар синең, Гөлфиям. Җүнлерәк җирдә эшлим икән, бу начармыни? Миңа да адәмчә яшәргә вакыт.

— Адәмчә яшәү нәрсә соң ул, Җәүдәт?

— Акча, дәрәҗә, байлык-муллык дисәм? Хәерчелек ирләрнең күкрәген тарайта, Гөлфиям. Чөнки дә иркенләп сулый алмыйсың.
— Димәк... димәк, син «алтылы» санына риза?
«Уф» дип аркан ауган Җәүдәт бераз дәшми-тынмый ятты да:
— Минем язмыш синең кулда, Гөлфиям, — диде.
— Ничек минем кулда? — Кызның күз алдында кара таплар уйнаклады. Ул менә-менә аңын җуяр кебек иде. — Саттыңмы әллә? — диде Гөлфия, үз тавышыннан үзе үк куырылып.
Йа! Ул яраткан кешесенә нинди зур гаеп ташлады, хәзер Җәүдәт: «Син шигең белән җанымны мыскылладың»,— дип үпкәләп кайтып китәр. Ләкин егет кутәрелеп бәрелмәде. Тыныч кына:
— Сатмадым,— диде.— Без алыш-биреш кенә ясадык. Мин аңа уртак серебезне тиштем. «Кассетаны кулыма сал да күрше бүлмәдәге беренче урынбасар урындыгына кереп чум», — диде Эдуард Әминович. Сине эзәрлекләргә ант итте. «Район бюджеты хисабыннан өч томлыгыңны чыгарттырам»,— диде. Хәтерлисеңме, Казанда танышым кибет ачып кесәсен калынайтты, дидең. Син дә баерсың, теге кульязмаларыңны хутка җибәрербез, Гөлфиям, алтын балыгым. Фәлиновларның арт сабагын укытабыз әле!
Кызның гәүдәсе тотрыклылыгын югалтты. Ул, әллә ничә кисәккә уалып, җиргә сибелде... Егет аны күрми, бармагын күккә «кадап» дәртләнеп-дәртләнеп сөйли дә сөйли иде:
— Шәп йорт тергезербез, сандугачым-былбылым. Сиңа аерым иҗат бүлмәсе. Яз да яз романнарыңны, бөегем минем! Эдуардка кассетаны тизрәк томырыйк та. Тыгынсын ач бугаз. Әйдә, без ике сәер дус арасына чөй какмыйк. Без лутчы аларның икесен дә файдаланыйк. Хәйләкәр кешеләр шулай эшли. Ә синең ул кассетаң — бомба.
Гөлфияне хуҗабикә хатын гына селкетеп уятты.
— Абау, нишләдең, кызым?!
— Гөлфиям! — дип, Җәүдәт тә атылып торды.— Ни булды сиңа?! Күгәрченнәр кебек гөрләшә идек, ни булды?!
Кызның башы бер генә юнәлештә эшли иде инде: «Казанга китәргә кирәк, Казанга, Казанга, Казанга! Тик кем илтә? Кем илтә, кем, кем?» Ул сәгатенә карады. Утыз минуттан рейс автобусы кузгала иде.
— Мин Казанга барам,— диде Гөлфия.
Ә Җәүдәт, көлемсерәп:
— Арсланов олы юл чатларына кешеләрен бастырды. Сине Күмер Таудан чыгармаска кушты,— диде.— Акылсызланма, җаным, бир кассетаны! Шул пүчтәк әйбер өчен Эдуард белән тәмсезләшмик.
— Чү әле, җегетем, кәсит-мәситләрең белән талкыма, бакчи, агарды-күгәрде балакаем, артык күп казыттым, ахры, бакчаны,— диде берни дә аңламаган Мәйсәрә һәм кызны култыклап өйгә әйдәде.
«Кая, җанкаемны күтәреп кенә кертеп салыйм сиртмә караватка, кичкә хәтле ял итсен, мин өс-башымны алыштыргач килермен» дигән егеткә Гөлфия, чебен куган төсле, кулы белән селтәнде. Тыелган чикне сикереп узган ир затына бәгырь каткан иде. Чәй йотып хәлләнгәч, ул, үзенең фаҗигасен тагын бер кат йөрәгеннән уздырып, сытыла-сытыла елады. Моннан да хыянәтрәк хыянәт бар микән ул, йа Раббым?! Мал белән дәрәҗәгә алданып яраткан хатын-кызын саткан бәндәнең аяк атлауларыннан җир ничек убылмый да, күкләр ничек шартлап ярылмый икән?! Юк, оятсызны оялтырга ярамый. Аңа хәтта сүз дә әрәм! Хәзер Эдуард Арсланов кассетаны кулга төшерү өчен көрәш башлаячак. Ул — имансыз, ул — мәрхәмәтсез, Гөлфияне таптап-изеп бетерәчәк. Бер табактан ашаган дустын дошманнарга корбан итеп биргән җәлладтан рәхим-шәфкать көтәргә дә түгел.
— Мәйсәрә апа, син мине иртәгә хәтле кая яшерәсең? — диде кыз, юл сумкасына тәҗел әйберләрен генә салып.
— Кызым, төпченмим-сорашмыйм, өстеңдә болытлар куера, ахры,— диде хуҗабикә хатын.— Бакча башындагы ташландык мунчага кач, анда этем дә иснәнмәс, түшәменә хәтле чирәм үскән.
— Миңа Рамилнең дә ярдәме кирәгер, Мәйсәрә апа. Иске машина аның ишегалдында. Шуңа арба тагып, таң атар-атмас сезгә килсен иде.
Мәйсәрә апа ярты сүздән аңлады.
— Имеш, ул минем бакчадагы чүпне төяп кырга түгә. Аннан нишләрсез икән? Казанга кадәр чакрымнар да чакрымнар.
— Рамил мине Салабашка «аударыр», Мәйсәрә апа.
— И балам, чытырманлы урмангамы?!
— Апа җаным, коткарса, Салабаш кына коткара хәзер. Әнә бит, сак куйдырткан, ди. Алар кеше аулауның иң нечкә хәйләсенә өйрәтелгән. Ант мәгәр, Казанга барып җиткәч тә, мин сиңа хәбәр итәрмен.
— Бер Аллага тапшырдык инде, кызым. Ахыры хәерле булсын!

**12**

Караңгы мунчада уй чигәләрне тыгызлый-тыгызлый башка тула да, күз алдында гөлт итеп ут көлтәсе чәчри иде. Аһ, бу уйлардан ми ничек кайнарланды! Кайда ялгышты соң Гөлфия, кайда?! Әллә бу артык дөрес яшәүнең нәтиҗәсе микән? Дөрес яшәгәннәр гел кыйнала... Әйе, кыз бөтен халыкны бәхетле итәрлек эш-гамәлләр дә башкармады, мәйданнарда көрәш уты кабызып, дан да яуламады, исемен дә яңгыратмады, әүвәл Гөлфия үзе белән көрәште, ә үзең белән көрәшү ул — иң авыр сугыш. Олы җиһад дип аталган бу сугышта җиңсәң, сиңа Ходай дошманнарың белән көрәшерлек дәрман бирә. Тик Гөлфия үзенә тапшырылган бурычны үтәп чыга алдымы соң? Җәүдәт, Җәүдәт... Ник син нәфесең белән кызны рәнҗеттең? Кәнәфигә үрмәләгәч тә, алар дөньясының курчак уены икәнен белерсең, егет. Кушылырсыңмы икән ул уенга, йә? Карышсаң, түбәңә төя-төя «уйнаттырырлар». Гөлфиягә сатылган вак җанлы түрә ир кирәк дисеңме? Ул хәләл көче белән кәбестә үстергән риясыз авыл малаен яратып, мәхәббәт тәхетенә менгезгән иде. Моннан да зуррак дәрәҗәне кайсы ир-ат күргән?! Бәлки, кыз үзе дә гаепледер. Ул нәни генә уйларында сөйгән кешесен югарыга күтәрде! Аны әүлияга тиңләде. Ник алай эшләдең син, Гөлфия?! Кодрәт иясе бары тик кошларга гына биеклекне кадир кылган, ә син бу канунны боздың: яраткан ир затыңны адәми сыйфатларыннан азат иттең дә фәрештә кебек күккә очырдың...

...Вакыт исәбе югалган иде инде. Төн бу җиһанда мәңгелек кунак иде бугай. Бөгелеп утыра-утыра кул-аяклар оеды. Берара ул йокымсырап та алды, тик өннән аерылмаган йокының тәнгә сихәте юк икән. Мәйсәрә ишек-тәрәзәләргә бәрәңге сабагы өйгән иде, кемдер шуны ишеп таратырга кереште.

— Мәйсәрә апа, синме соң? — диде кыз, кыштырдаган якка үрмәләп.

— Мин, кызым, мин. Таң ата. Чүт кенә түз. Рамил бездә. Төнлә өч адәм кисәге өйне тентеделәр. Андрейка милициясе дип белдем мин аларны. Тап-тазалар. Сине таптыралар. Мәйтәм, кичәгенәк киткән иде, иртәгә әбәттә редакциядә булыр, мәйтәм. Ул хуҗа кеше бит, мәйтәм, кайларда йөргәнен безгә әйтми. Инде дә бик яман хәбәр, кызым. Җәүдәтне каты гына дөмбәсләгәннәр. Кичен килеп әйләнде ул. И угаланды, кассета да кассета, дип. Мин, билгеле, алдадым, Гөлфия соңрак кайта, мәйтәм. Төнлә сугылып үтәрмен, ди, сугылды әнә. Баш сөяге ярылган, үлсәм, Гөлфия кулында үләм, ди. Өсте-башы кан, идән уртасында аңсыз ята. Рамил башын бәйли әле. «Ашыгыч ярдәм» чакыртып, бүлнискә озатырмын, дим.

Гөлфиянең йөрәге жу-у итте. Эдуард Арсланов кулы! Бу аның «тасманы китермәсәң, ахыры күңелсез тәмамланыр» дип беренче кисәтүе. Икенчесе озак көттермәс. Алар шаһитларны тиз йомдыра. Кыз инде Җәүдәтне бәгыреннән үк өзеп аткан иде. Бер усаллык белән, бер нәфрәт белән, бер рәнҗү белән. Монда «нишлим?» дип икеләнү артык иде.

— Мәйсәрә апа, аны юк итәрләр бит.

— Әй, кызым, миндә калса, үлә инде ул бичара.

Ә Гөлфиягә егетнең үлеме кирәкме соң? Яшәсен…

— Апа җаным, Җәүдәтне иске-москыларга төрегез дә «арба» төбенә салыгыз. Өстенә бәрәңге сабакларының корысын гына ташлагыз, тончыкмасын тагы.

— Алланың нинди изге бәндәседер инде син, кызым-балам!

Яшәсен, яшәсен… Егет үзен-үзе җәзалады. Җәза аңа Гөлфия көткәннән дә иртәрәк килде. Ходай һәркемгә дә җавабын юллый: йә соңрак, йә минуты-сәгатен төгәл санап.

…Кояш нурында иркәләнеп кенә йокысыннан уянган Күмер Тау тынлыкта изрәгән иде. Арткы утыргычтагы капчыклар арасына чөмәшкән Гөлфия:

— Рамил, сикертмә, Җәүдәт абыең бәрелеп имгәнмәсен,— диде.

— Аны нык изгәннәр, Гөлфия апа. Син түлке борчылма, таза ул, бирешмәс, терелер. Сезне үтермәк булалармыни? Мәйсәрә түти шулай ди. Мин мылтыкны да алдым, каршыбызга чыгып кына карасыннар, күземне йомам да атам!

— Мин сине бу эшкә кыстырмам, энем. Чүплек башыннан Салабаш ерак түгел, безне шунда бушатырсың, яме!

— Һи, бушатты ди! Кәкре каенга ук китереп терәтәм машинаны. Сезгә кая кирәк, шунда илтешәм дә әле, Гөлфия апа.

— Безгә урман эченә керәсе шул, энем. Син ары табан бармассың инде. Монысы өчен дә Алланың рәхмәте яусын.

— Мин сезне сатмам, Гөлфия апа. Тәгәрәп үлим менә! — дип сөйләнгән егеткә Гөлфия:

— И энем, җен-пәридән шүрлисең ич син,— диде.

— Әй син хаклы ла, Гөлфия апа, ике аяклысы куркыныч икән аның. Тегеләр белән без как-никак килешербез. Хатынның әнкәсенең әнкәсе әйтә: «Ихлас күңелдән укы да укы, кияү, догада гына яклану һәм саклану»,— ди.

Салабаш юлы аулак юл иде, хәвеф-хәтәрсез генә урманга якынлаштылар. Ләкин өзек-өзек ыңгырашкан Җәүдәт аягына да басалмый, ул хәтта кемнәргә ияргәнен дә аңларлык дәрәҗәдә түгел иде. Рамил аны аркасына аударып кына сөйрәде. Тар сукмак тагын да тарайган сыман иде. Кыз чыбык-чабык-

ларны эткәләп-төрткәләп эз ярды. Аланда бер-ике көн хәл җыйгач, Күл-Елга тарафларына китәрләр… Аннан Казанга… Җәүдәтнең организмы яшь, таза, ул тиз савыгыр. Калганын уйлыйсы да килми… Алданиләр булыр? — Юк, уйлыйсы да килми.

Чык белән битен юган аланга җиттеләр. Ул буш иде, ятим иде… Рамил аркасындагы йөген чирәмгә сузып салды:

— Авы-ыр син, Җәүдәт абый. Даром кәбестә генә ашамаган. Әллә…— Егет йодрыгы белән күзен уды.— Әллә… җен, Гөлфия апа? Ак ат кыяфәтендә, әнә, әнә! Алан читендә үк! Арбасын да таккан!

— Кайда, кайда?! — диде кыз, аяк очларына күтәрелеп.— Акмы? Болыт төсleme? Бу бит, бу…— Аның сөенече эченә сыймады.— Бу бит Сылукай! Алялетдин абзый китмәгән, димәк! Энем, син Җәүдәт абыеңны караштыр, мин хәзер картны табам.

Гөлфия ызбага йөгерде. Тик ишек терәү белән терәтелгән иде. Әллә берәр куак төбенә посып, аларны күзәтә микән хәйләкәр Алялетдин? Элекке гадәтен куса…

— Алялетдин абзы-ый-й!

Кайтаваз үчекләгәндәй:

— …ый-ый-й,— диде.

Аңа кушылып Сылукай да кешнәде:

— Миһа-һа-һай…

Дәртсез кешнәү иде бу. «Ат та кеше кебек: шатлана да, кайгыра да», — дия иде карт.

— Нигә син моңсу, Сылукай? — Кыз, сөйләнә-сөйләнә, аңа таба атлады.— Ялларыңны туздырып чапкан яшь чакларыңны сагынасыңмы? Сез дә картаясыз, әйеме? Хуҗаң тәки Казанга китмәдеме? Тамырың белән куптарылу үлем белән бер шул.— Гел атка гына игътибар иткән Гөлфиянең кинәт күзе арбага төште.— Әллә…— диде ул, Рамил кебек тотлыгып.— Әллә… ялгыш күрәм инде…— Алялетдин абзый көпчәккә сөялгән дә йокыга талган иде. Яфрак селкенсә дә, колагын торгызган сизгер «урман бүресе» үлән чыштырдаган тавышка да саңгырау хәтта. Кыз аны төртеп уятмакчы иде, иелгән җиреннән арка сөяге катты. Алялетдин карт, җансыз сыңар күзен гарешкә төбәп, фани дөньядан күчкән, аның әле гәүдәсе дә суынып өлгермәгән иде. Авылына җыенган югыйсә… Арбада төенчеге югыйсә… Дилбегәне генә кагасы югыйсә… Кыз «аһ» диде, йөрәктән бәргән бу авaздан тып-тын урман да иңрәде, куактагы яфраклар җил кузгаткан сыман лепердәшеп алды, кояшка тартылган чәчәкләрнең таҗлары яшьләнде… «Мин нибарысы ун минутка соңардым. Рәнҗемә, Хантимернең этисе»,— диде Гөлфия, һәм бармагы белән сыпырып картның күзен йомдырды…

Аны Рамил белән икәү арбага салдылар. Кыз муенына ураган ак яулыгын мәрхүмнең битенә япты. Җәүдәт инде хәлләнә иде, егет, терсәкләренә таянып, як-ягына каранды, аның хәзер башы түгел, күбрәк җаны авырта иде бугай, ыңгырашуы да әллә ничек — газаплы иде. Арба киң иде, озын иде, анда сырхауга да урын табылды. Җәүдәт карулашмады… Кая барабыз дип тә сорамады, гүя ул котылгысыз билгесезлеккә буйсынган кол иде. Әй адәм, адәм! Түрә кәнәфие, дип сикергән идең, ә Ходай сине тотты да гап-гади көпчәкле арбага менгезеп утыртты…

— Сиңа сулга, безгә уңга, энем,— диде кыз, аландагы тамашалардан исрәйгән шофер егеткә.— Сукмактан кире чыгарга курыкмыйсыңмы?

— Миңа оят, Гөлфия апа. Син әнә нинди батыр. Мин җен-пәри дидем дә… Без, ахры, үтереп җибәргән…

— Синең җаның матур, энем. Рәхмәт сиңа. Хуш, яме!

— Хушыгыз, Гөлфия апа!

Кыз әкрен генә дилбегәне какты:

— Сылукай, әйдүк, кузгал…

*Гыйнвар—май, 2003*

## Югалту һәм табу

Юлда кайтканда сусап авыл читендәге чишмә янына тукталдык. Бер апа чиләкләренә су тутырып маташа иде. Татар гадәте буенча исәнләштек.

— Ташырга бик ерак түгелме соң? Урамыгызда коелар юкмыни? — дидем.

— Аның суы тәмсез шул, балам, — диде ул. — Гөлләргә сипсәң, яфрагы саргая.

Менә чишмә челтерәвенә азан тавышы кушылды. Өйлә намазына чакыралар иде. Без, башыбызны иеп, берара тынып калдык. Дөньяда сагышка күмгән әллә нинди көй-җырлар бар, әмма азан кебек җанга үткән моң беркайда да юк.

Дога кылганнан соң, апа, сөенеп:

— И сөбханалла, оста да әйтә, урыс баласы бит үзе, — диде.

Каләм халкы мондый нәрсәләрне колак яныннан гына уздырып җибәрәмени?

— Ничек, ничек ул? — дип төпченергә керештек.

— Мин укытучы. Ирем-канатым мөәзин иде. Мәрхүм инде. Әнә-ә тегендә ята, — диде апа, урман сыман куерган зиратка ымлап. — Без икебез дә муллалар нәселеннән. Бер кыз, бер җегет үстердек. Балалар башлангыч мәктәпне үзебездә укыдылар, аннан аларны аталары күрше авылга күчерде. Урысча өйрәнсеннәр дип. Кеше арасында югалмаслар дип. Күңелем белән бер дә ризалашмадым инде моңа. Тегеләрдә чиркәү чаңы каксалар, йөрәгем калтырый иде. Анысы үз йолаларын үтәсеннәр, үзләренең диннәрен тотсыннар. Элегрәк: «Сагындык», — дип, ял көннәрендә өйгә чапкан улым белән кызым менә бит кайтмый башлады берзаман. Атасы белән икәүләшеп мәктәпләренә йөгердек. Директор Иванов сөйли, укулары начарланды, ди, соңгы еллары, аттестатларында, мөгаен, өчлеләр генә булыр, ди. Ә безнең атабыз аларны институтларда укытырга хыяллана иде. Соңыннан Иванов, безне кызганып: «Авылга яшь поп килде, сезнекеләр аңа ияләште», — диде. Аталары: «Алайса, күземә күренмәсеннәр», — дип пыр тузып кайтып китте. Икенче мәртәбә, аңга китерергә дип, ныклап әзерләнеп барганда, улым белән кызым попка ияреп, Рязань якларына качкан иде. Ул чакта безнең хәлләрне аңлатырлык сүз юк иде. Тере килеш үлеп йөрдек. Дүрт елдан малай йортыбызның ишеген какты. Йөз-кыяфәте имәнгеч, озын сакал үстергән, өстенә чапанга охшаган кара халат кигән. Ябыгып күзләре эчкә баткан. Өйләнгән, хатыны — марҗа. Ярар, сыкрап кына монысы белән дә килештек. Бер-берсен яраталар икән, нишләтәсең. Заманасы шундый булгач! Аннан, бала бит, кызганыч. Сарык суйдык, мунчалар яктык. Әзрәк тәрбияләп, тәненә ит кундырмакта уебыз. Табын әзер, ашарга чакырам, ә килен белән малай тиз генә абзар артына чыгалар да керәләр, чыгалар да керәләр. Көн саен шул гадәт кабатлана. Берсендә, түзмичә: «Нишлиләр икән анда?» — дип шыпырт кына барып карасам, чукынып яталар! Килен дигәнем, тотылгач, күземә бәреп әйтте: «Кысылмагыз, яме! Сашка — рухани ул», — диде. Сәфәрем Сашкага әйләнгән иде. Улыма, елый-елый: «Атаң сизгәнче китегез», — дидем, үзем кудым. Хәсрәт кисәүләрен озаттык кына, кызыбыз кияве белән кайтып төште. Кияү нәкъ Сәфәрем күчермәсе: озын сакал, кара халат... Яннарында өч яшьләр чамасы малайлары. Кызым абыйсы кебек гел урысча сөйли. «Әни, зинһар, этигә белгертмә, минем ирем без укыган авылда поп иде. Ә мин аны яратам, нәрсә генә дисәгез дә, аңардан аерылмыйм», — ди. «Ирең — поп, ә син кем?» — дим. Дәшми. Попка чыккач, кем икәнлеге аңлашыла инде. Кызыбыз сагынып, хәлебезне белергә кайткан дисәм, җитди йомышы бар икән. «Без миссионерлык белән шөгыльләнәбез, шәһәрдән шәһәргә күчеп, халыкны яңа дингә өндибез, китаплар таратабыз, Илья берничә ай сездә торсын әле», — ди бу. Йә, кем «юк» дип кырт кисәр икән?! Бала бит, адашса да, бала! Йөрәгемә кан сауды, билләһи. Монысыннан да өзелдек, мәйтәм. «Ник җибәрдегез?» — диярсез, мөгаен. Бикләп тотасыңмыни!

Мин белгәннәрнең күбесеннән ирем бихәбәр иде. Улыбыз өйләнгән, кызыбыз кияүдә, икесе дә ят кавем белән кушылган. Аңа шулар гына мәгълүм иде.

Ул онык белән юанды, ни хикмәттер, шушы балага ныклап күңел салды. Чормадан иске әлифба китабын тапкан, кичләрен бәләкәчне татарча өйрәтте. Минем инде тел әче, юк-юк та иремнән үч алам (күрше авылга балаларны ул илттерде бит), аңа татар теле ник кирәгер икән, урысча белгән кеше генә югалмый, дигән идең, безнекеләр әнә «югалмады», мулла кушкан исемнәренә хәтле алмаштырды, дим. Хатамны төзәтәм, диде ул. Әтиләре әлеге хәлләргә миннән дә битәррәк хәсрәтләнә иде. Бабай кеше оныкның татарча телен ачтырды, мәчеткә ияртеп йөрде. Азан әйткәндә, манарага ук алып менә икән. Ай үтте, ел җитте. Тегеләр бала турында онытты, «эшләре» куәтле, ахрысы. Сәлам хаты да язмыйлар. Ильяны Ильяска үзгәрттек. Онык та, шаккатырсың, бабасына чат ябышты. Теттереп татарча сөйләшә, аять-сүрәләр ятлый. Беренче сыйныфка — беренче дәрескә барганда «Әлхәм» догасын укып китте. Онык искиткеч акыллы иде. Без моңа шатланып туялмадык. Ләкин шатлыкны тагын бер кайгы кысрыклады: алты елдан соң тегеләр малайларын юллап кайтты. Ильяс болардан тәмам ятсынды, бабасына сыена, сабыйкаем. Безгә рәхмәт юк инде, кыз өстебезгә кычкыра, кияү кычкыра. Нишләттегез баланы, янәсе. Кем ясадыгыз, татарча өйрәтеп ник телен боздыгыз, янәсе. Ильяс ни этисеннән, ни әнисеннән кочаклаттырмады, куркып, һаман бабасының кочагына сеңде. Кызым аны йолкып алмакчы иде, мин аркылы бастым. «Тиеп кенә кара», — дидем. Өч көн өйдә талаштык-тартыштык. Закон ата-ана ягында шул, сабыйның кул-аягын бәйләп алып китте болар. Шуннан соң ирем чирләп егылды һәм бүтән терелмәде... Йөрәк диделәр. Мин хәсрәтем белән култыклашып ялгыз калдым. И ул түккән күз яшьләре! Чишмә сыман аккандыр, мөгаен. Төнлә уянам да: «Якыннарым ташлады, син ташлама, Аллаһым», — дип ялварам. «Кайда син, улым?» — дип, оныгымның сурәтенә карап сыкранам. Баланың укыган догалары колагыма ишетелгән кебек тоела.

Беркөнне ишектән озын буйлы чибәр егет килеп керде. Кулында дәү генә сумка. «Нихәл, әби? Бабай кайда?» — ди. «Син кем соң, улым?» — дидем. «Танымыйсыңмыни, әби? Мин — Ильяс, кунакка кайттым, без җәйге каникулларда», — ди егет. Ильяс?! Оныгыннан да өмете киселгән хатын ничек моңа ышансын ди! Озак телсез тордым. И дөнья, мин бит, тегеләр Ильясны да үз ягына аударган дип, сигез ел хурланып яшәдем. «Әби, эти белән әнинең үз сукмагы, минем — үземнеке», — диде онык ахырдан. Бабасының үлемен ул бик авыр кичерде. Каберенә барып, рухына догалар кылды... Әй, ир-канатым күрсә икән бу бәхетле көннәрне! Мәдрәсәдә дә гыйлем җыйган, институтта да укырга өлгергән оныгы белән горурланыр иде, мәрхүмкәем. Ул азан әйткәндә, күңелләре хушланыр иде. Бүген

минем дөньям түгәрәк. Дөрес, улым белән кызым каядыр шәһәр-калалар гизә, миндә эшләре юк. Язмышыма шулай язылгандыр, күрәсең. Аллаһы Тәгалә берсен алса, икенчесен бирә, югалтулар һәм табулар чиратлаша икән ул...

## Кызым — иремнең дә баласы...

— Мин җүләр, ахрысы, уйларга да куркыныч серемне сезгә сөйләргә килдем.

Ул башта үз-үзен битәрләп алды. Аныңниләр бәян итәргә җыенганын алдан ук белсәм: «Юк, сез җүләр түгел, сез — таш бәгырь», — дияр идем, бәлки. Хәер, хәсрәтле адәм баласына каты-каты бәрелергә минем ни хакым бар?!

Каршымда утырган Мөслимә ханым (исеме, әлбәттә, үзгәртелә) берара икеләнеп торды.

— Әгәр кыенсынсагыз, серегезне ачмагыз, — дидем, кунакның хәленә керергә тырышып.

— Унбиш ел күңелемә бикләп сакладым инде. Кемгәдер сөйләргә кирәктер, мөгаен. Сез барысын да тәфсилләп языгыз әле, башта иремә шул язмагызны укытырмын. Әй, нинди әшәке хатыннар бар дөньяда, диярмен. Ул, билгеле, ялган, дияр, моны язучы уйлап чыгарган, дияр. Ачудан, бәлки, журналны читкә атып бәрер. Шунда мин аңа, андагылар дөрес, ул әшәке кемсә — мин, диярмен. Тыңлыйсызмы? Рәхмәт.

Уфада педагогия училищесын тәмамлагач, мин авыл мәктәпләренең берсендә балалар укыта башладым. Яшь чак, чибәр чак. Клубтан егетләр өере-өере белән озата. Күзеңне йом да теләсә кайсын яр ит, оттырмассың кебек. Ә мин, исәр, хатынлы иргә гашыйк. Ул химия фәне укыта иде. Дәрестән соң: «Тәҗрибәләр үткәрәбез», — дип, лабораториягә чакыра хезмәттәшем. Пыяла савытларда әллә нинди сыекчалар болгатып яндыра. Дәрестән соң бүтәннәр кебек өенә ашыкмый, чөнки ялгыз, фатирда яши. Уфадан хатыны авылга күчәргә теләми, имеш. Иркә шәһәр бичәсе, имеш. Химик абыебыз: «Биредә хастаханәләр юк, ә минем хатын — табибә», — дип аклана иде. Бүген шаккатам: ул мине кайсы ягы белән сөйдертте икән? Ни бите, ни гәүдәсе. Кыска буйлы, җирән чәчле иде. Тик менә теле телгә йокмый, урмандагы барча сандугачларны алмагач куагы ботагына кундырып сайрата иде инде. Мөгаен, шома теле белән йөрәгемә юл яргандыр. Ә минем әлеге дә баягы адым саен хаталар ясый торган яшь чак, җүләр чак… Ничек аның кочагында эрегәнемне сизмәдем шул. Тик безнең кача-поса «уйнаган» мәхәббәтебезгә кырау сукты: нинди тәҗрибәләр белән мавыкканыбызны белеп алган усал директор: «Хатының янына элдерт», — дип, химикны мәктәптән куып җибәрде. Шушы җирдә соңгы нокта төртелсә икән! Ир шәһәргә тайды да котылды, ә минем өчен чын-чынлап тәмуг казаны асылды. Һәр иртәмдә кара таңнар аттырдым мин. Аны сагынудан, аны юксынудан елый-елый күз кабакларым өрелеп шешә иде. Тамактан ризык үтми, хәтер начар, дәрестә кул калтырый, тавыш калтырый, чөнки уемда гел җирән химик. Ичмасам, хәлләремне сорашып, ярты бит хат сырласа иде! Уйнады да ташлады, кыскасы. Ләкин газапларымның бу баласы гына, анасы алда иде. Әрнү-сыкранулар белән игътибар ителмәгәндер, организмдагы сәер үзгәрешләр соң гына ачыкланды. Мин көмәнле идем! Район хастаханәсенә йөгердем, әмма анда мине эт итеп орыштылар: «Элегрәк хәстәрен күрергә иде, өч айдан соң бала төшертмиләр», — диделәр. Һаман да шул яшьлек җүләрлеге инде: коллективта хезмәттәшләрем сизмәсеннәр дип, зурайган саен зурайган корсагымны кысып бәйләп йөрдем. Ә ул шар сыман түгәрәкләнә. Мине исә, авыл һавасы килеште, тазара, дип мактыйлар. Безнең директорның күзе без кебек очлы, үтәли тишә иде. Беркөнне кабинетына чакырды бу: «Яле, яшь дустым, билеңдәге чүпрәгеңне чиш, — диде ул, кырыс кына. — Яле, чиш! Балаңны буып үтерәсең бит, хәерсез кызый. Көмәнең ничә айлык?»

Кем белгән дигәндәй, җилкә сикерттем. Директор буй-сыныма тагын бер мәртәбә текәлеп карады да: «Ике айдан бәбилисең син, — диде. — Тиз генә әйберләреңне төйнә. Сине күз буяр өчен генә Уфага — курсларга озатам. Миңа коллективымның абруе кыйммәт. Салахова мәктәбендә фахишәләр укыта дигән дан таралмаска тиеш».

Салахова апа чатнатып шулай диде. Аңа рәнҗемим, ул бит мине Уфада үз туганнарына урнаштырды. Нәтиҗәдә, мәктәбенең абруен да саклады. Ә мин якты дөньяларга бер кызчык тудырдым. «Баладан баш тартам» дигән язуны үзем теләп яздым. Директорның туганнан туган сеңлесе Иркәбикә шушы хастаханәдә шәфкать туташы иде. «Кечкенәң өчен кайгырма, аны бик тә мәрхәмәтле терапевт хатын кызлыкка ала. Үзенең баласы юк», — диде ул. «Күрсәт аны», — дип, Иркәбикәгә ялындым. Аның йөзеннән кан качты: «Син нәрсә, аңа үзеңнең кемлегеңне белгертәсең киләме? — диде кыз. — Мине эштән кудыртасың ич, ахмак! Сиңа сер итеп кенә әйттем ич!» — «Тынычлан, ерактан гына карыйм», — дидем. Ул вакытта миндә — унсигез яшьлек аламада — ана хисләре уянмаган иде әле, миңа нибарысы кызык иде. Сабыйның булачак әнисен ишек ярыгыннан гына өч тапкыр күрдем. Иркәбикә гел артымнан сагалый иде. Һәм шуннан соң гомерем буе ул хатынның борын очындагы миңен оныталмадым…

Мәктәпкә кире кайтмадым мин. Укытучылык һөнәреннән бизеп, заводка кердем. Уфа урамнарыннан химикны эзләсәм дә очратмадым. Бу якларда мин бәхетемне югалткан идем. Шәхси дөньямны үзгәртеп, өр-яңадан көйләрмен дип, Казанга юл тоттым. Көйләп булмады. Мине, мөгаен,

Алла каргаган иде. Тора-бара ташлап калдырган кызым, исләремә төшеп, үзәкләремне өзде. Егерме биш яшемдә ахирәтләрем Ислам исемле карт егеткә димләде. Яратмасам да ризалаштым. Миңа ничек тә гаилә корып, яшьлектәге хата-ялгышлардан арынырга кирәк иде. Ләкин Аллаһы Тәгалә гөнаһларымны кичермәде: мин балага узалмадым. Тикшерендем. Табиблар, барысы да тәртиптә, диделәр. Ирем тикшеренде, ул да сау-сәламәт. Ислам мине генә гаепләде һәм, «син — кысыр» дип, башка хатынга өйләнде. Ике елдан ишетәм: малай үстереп яталар.

Тагын бер адәм белән кавыштым, тик аңардан да уңмадым. Ул да: «Син — кысыр», — дип мыскыллый иде.

Өченче тапкыр кияүгә… Менә хәзер сез гаҗәпләнүдән телсез калырсыз инде. Химик белән табыштык бит без! Унбиш елдан соң Казанда очраклы рәвештә генә төзелеш тресты җыелышында урыннарыбыз бергә туры килде. Җирән картайган, чәчләре сирәкләнеп, маңгаена җыерчыклар сызылган. Әмма ул һаман да сөйкемле иде. Минем өчен, билгеле. «Хатын белән өч ел элек аерылыштык, — диде ул, көрсенеп. — Мине яратмады. Горур иде, тәкәббер иде, ир дип санламады. Кирәкми дигән өстенә, миңа үч итеп, ташландык бала алып тәрбияләде. Синең хәлләрең ничек? Кияүдәме?!»

Мин аңа түгелмәдем, мин бикле җан идем. Без көн саен күрештек. «Син дә ялгыз, мин дә ялгыз, парлашыйк», — дип, ул мине үзенә кияүгә чыгарга күндерде. Икәү кылган гөнаһларны икәү төзәтербез дип, бу тәкъдимнән баш тартмадым. Ләкин Сирингә уртак балабыз турында ләм-мим. Ул әйбәт ир. Төзелештә участок башлыгы. Миңа бик игътибарлы. Тик менә… Яшьлектәге мәхәббәт хисләре яңадан терелсә дә, балабыз булмады. Шуны ул тилмереп көтте. Бала аның бердәнбер хыялы иде. Әлбәттә, үз каны, үз кисәге.

Беркөнне ирем, нигәдер уңайсызланып кына: «Уфага барабыз, сине әнкәй белән таныштырырга инде, — диде. — Чибәрем, әгәр әнкәй сиңа караңгы чырай күрсәтсә, борчылма. Теге киленен фәрештәгә саный карчык. Тәрбиягә алган кызыбызны үз оныгыннан артыграк күрә».

Чынлап та, Сириннең әнисе килен дип миңа эреп төшмәде. Ул бусага төбеннән үк малаен әр-битәр белән күмде: «Хатыннан хатынга чабасың, азгын! Гаиләң сандугач оясы иде, шуны туздырдың, мәнсез! Кызыңны да җәлләмәдең, таш багана».

Сирин бертуктаусыз: «Ярар инде, әнкәй, ярар, килененңнән оял», — дип кабатлады. Ә инде карчык тынмагач, йөрәк белән ярсып: «Үземнән туса, ул баланы ташлар идеммени, әнкәй», — диде.

«Алайса, ашагыз-эчегез дә китегез. — Әнисе безне куарга ук киреште. — Китегез, кит! Кичкә табан Алия белән оныгым Мәскәүдән кайтышлый безгә сугыла. Күзенә чалынып, баланы әрнетмәгез. Син аңа — ата. Ул синең кайтуыңны көтә».

Әмма Сирин дә үзсүзле иде. Ул да, өздереп-кистереп: «Мин мәрхүм атам йортында, әнкәй. Күпме җаным тели, шуның хәтле кунам», — диде.

Киленен өнәмәгән каенаналар күп. Тик бу хәтле… Сирин хакына түздем мин. Кич җиткәндә йөрәк кенә чәнчергә тотынды. Әйтерсең ниндидер куркыныч давыл якынлаша иде. Җанымны шик-шөбһә урады. Фәрештә көндәшем миннән ирен дауласа, нишләрмен? Оршыш-талаш мәсьәләсендә мин җебек идем. Каенанам төсле Алия дә пычак теле белән бәгырьне теләр микән? Аллага шөкер, без аның белән йөзгә-йөз бәрелешмәдек. Алар чәй дә эчмәделәр, күчтәнәчләрен калдырып, Уфага ашыктылар. Тукта, мин вакыйгаларны тизләтәм бит. Капка төбендә машина кычкыртканда, ян бакчада карлыган җыя идем. Фәрештә көндәшем белән кызы, «әнкәй, әнкәй» дип гөрләшеп, ишегалдына керделәр. Өйдән кочагын җәеп каенанам чыкты: «Әйдүк, бәгырькәйләрем, әйдүк!»

Койма башыннан гына үрелеп кунакларга караган идем, шул килеш каттым да калдым. Хатынның борын очындагы миңе чүт кенә һушымнан яздыртмады. Күзем бер аңарда, бер әбисенең куенына сеңгән үсмер кызда иде. Йа Ходаем, син кемнәрне алдыма китереп бастырдың?! «Тап, эзлә» дип, ничә ел хатлар белән Иркәбикәнең җанын ашадым мин. Анда ук ул кисәтте бит, кисәтте, алар өч ел элек Башкортстаннан кайсыдыр шәһәргә күченгән икән, диде. Димәк, Мәскәүдә төпләнгәннәр. Табибә эз яшермәгәндер, билгеле. Кемнән яшерсен ди. Миннәнме? Баланы төннәр буе шушы хатын багып үстергән ләбаса. Ләкин… ул минем йөрәк парам, ул, ниһаять, Сирин белән безнең уртак җимешебез!!!

Карлыган куагы төбенә чүмәшеп озак утырдым. Күңелем белән: «Кызым!» — дип, машина артыннан чаптым. Чаптым да сөрлегеп егылдым… Сирин эзләп тапканда, мин яртылаш үлгән идем. Ул Алиядән көнләштем дип уйлады. И иркәләде, и юатты. Аңа чын дөресен әйтергә һич телем әйләнмәде. Иремне дә югалтырмын дип курыктым. Аның: «Үземнән туса, ул баланы ташлар идеммени, әнкәй!» — дигән сүзләре колак төбендә яңгырап тора иде. Сирин миңа кул селтәп, беренче гаиләсенә кайтса — дөньяларында яшәүнең ни кызыгы да ни рәхәте!

Сез, зинһар, язмагызны «укучылар хөкеменә тапшырам» дип тәмамламагыз. Мин чит-ятларның киңәшенә мохтаҗ түгел. Ир-канатым нәрсә дияр? Миңа шунысы мөһим…

**Мәхәббәт**

Бу дөньяда нинди генә хәлләр юк. «Кеше ышанмастай нәрсәләрне чын булса да сөйләмә», — дип әйтүе генә җиңел икән ул. Ә менә шушы кисәтүгә буйсынмасаң, нишләргә икән соң? Галина — марҗа хатыны. Без аның белән хастаханәдә бер палатада яттык. Аның инде гомер җебе өзелеп бара, ул бик нык авырый, ләкин, терелмәслеген белсә дә, терелә́м дигән өмет белән яши иде. Заманында балалар бакчасы мөдире — бары тик түрә, интеллигенция балаларын гына сайлап төркемнәр җыйган Галина тиздән дөнья белән ике арада нокта куелачагын аңласа да, акча эшли, кыскасы, ул бизнес-леди иде. Бу очракта палатадашым белән «җеннәребез килеште» дип әйтергә кирәктер, көнозын әллә ниләр сөйләшеп бетерә идек. Без барыбыз да балаларыбызны яратабыз. Оныкларны — аеруча. «Бала баласы балдан татлы» диләр. Әмма Галина кебек онытына мөкиббән хатын-кызны мин беренче мәртәбә очраттым бугай. Телефоннан сөйләшкәндә, ул унбер яшьлек Коляга нинди генә матур исемнәр белән эндәшми иде. Калмый урмандагы иң сөйкемле җәнлек, калмый кош-корт: «Куянкаем, тиенкәем, очлы күзле бөркетем, куакта сайраган сандугачым…» Малайның да әбисенә мәхәббәте искиткеч көчле. Телефонның теге очында сүз саен: «Моя родная бабулька, моя любимая бабулька…» Әбисенең сәламәтлеге өчен дә иң нык кайгырган кеше шушы бала икән. Галина чире турында иренә дә энесенә генә белгерткән, улы белән оныгына чын дөресен әйтмәгән. «Бәлки, өч-дүрт айдан мин бөтенләйгә китәрмен, бәлки, тагын ярты ел яшәрмен, байлыгым да, ирем дә, улым да кызганыч түгел, — диде ул. — Бердәнберем — оныгым — ялгыз тилмерәчәк. Әле бит Коля бигрәк бәләкәй! Аны кем яратыр да, кем иркәләп-сөеп йокысыннан уятыр». Кызык, ханым оныгын дөм ятим саный кебек. Әтисе бар, әнисе бар, һичьюгы, бабасы ташламас. Галинаның ире — алтмыштан узган ир — бер генә дә бетәшкән, чирләшкә адәмгә охшамаган иде. Ул көн саен хатынының хәлен белергә килә, әлегә бизнес эшләре аның кулында икән. Галина гаиләдә — лидер, иренә күрсәтмәләр бирә. Икәүләшеп керем акчасын саныйлар, киләсе айларга план коралар. Әйе, әйе, бизнес-леди, чирен онытып, һаман дөнья куа. Акча икенче урынга күчмәгән, һәм ул үзен хәерче итеп тоярга күнекмәгән. Әнә табибларны бәхилләтер өчен алтмыш мең тәңкә мендәр астына кыстырылган.

Әлбәттә, мин, бик кытыклансам да, сорау биреп Галинаны йөдәтмәдем. Аның өлгергәнен көттем. Күңелем сизә — ул миңа нидер сөйләргә тиеш иде. Ник дигәндә, без икебез ике кыйтга кешеләре, мин аның даирәсендә буталмыйм, берәүнең дә колагына «теге фәлән икән» дип пышылдап, гайбәт таратмаячак идем. Аннан аның мөселман хатыннарына ихтирамы зур иде. Балалар бакчасында да пешекче итеп гел татарларны гына эшләткән икән Галина.

— Мин синең белән киңәшер идем, — диде бизнес-леди, иртәгә мине хастаханәдән чыгарасы кичтә. — Миңа алтмыш өч яшь. Шуның утыз өч елы ялган белән үтте. Ләкин мин бу ялганым өчен вөҗдан газабы кичермим. Үкенмим дә. Оныгым булмаса, әлбәттә, әллә кайчан якыннарыма ачылыр идем. Шулай туры килде, кияүгә соңлап кына чыктым. Татар егетенә. Ике айдан без аерылыштык. Юк, холыклар килешмәде димим, ул миңа хыянәт итте, дус кызым белән йоклады. Ахырдан үзләре бергә дә яшәмәде. Ир-ат халкыннан гайрәтем чиккән иде, башка беркемгә дә күз салмыйм, дидем, үз эчемә йомылдым. Рәхмәт, эш барысын да онытгыра иде. Ләкин язмыш юлыма Валентинны китереп бастырды. Без аның белән өйләнешкәндә әле чирем үзен сиздерми иде. Бөтенесе дә балага узгач башланды. Миңа табиблар: «Көмәнеңне төшер, барыбер балаң үле туачак», — диде. Ә мин аларны тыңламадым. Мәйтәм, ярамыйга карамыйм, табам дигәч табам! Минем бүтән чарам да юк, әгәр Валентинны бала сөю бәхетеннән мәхрүм итсәм, ул, ике дә уйламыйча, мине аерачак иде. Кайсы иргә кысыр хатын кирәк. Шөкер, корсагым әкрен генә түгәрәкләнә, хәл китүләрне, баш әйләнүләрне, күз аллары караңгылануларны гел пүчтәккә саныйм, әһәмият бирмим инде. Ниһаять, бәбинең дөньяга аваз саласы көннәре якынлашты. Тулгак тота башлагач, Валентин мине бала тудыру йортының ишек төбенә хәтле озатып куйды. Шунда без кем белән очраштык диген! Беренче ирем Хәлил белән! Ул да корсагы борынына терәлгән яшь кенә кызны култыклаган иде, икебезнең дә күзләр шакмакланса да, бер-беребезне күрмәмешкә салыштык. Валентин, әлбәттә, аны танымый иде. «Приемный покой»да киемнәрне алыштырганда, мин теге нәрсәкәйдән:

— Иреңме? — дидем.

Кызый оялып та тормады:

— Сөяркәм, — диде.

— Хатыны бармыни? — дип төпчендем.

— Әйе, — диде ул, күңелсез генә.

— Алайса, балаңны ялгыз гына үстерәсең икән, — дигән идем, кызый кистереп:

— Юк, мин аны монда калдырам, — диде. — Хәлил дә шулай куша, — диде.

Өстемә бозлы су койгандай тоелды. Нинди кансызлык! Ярар, безне бер палатага урнаштырдылар. Соңыннан мин әлеге очрашуны кат-кат хәтеремнән уздырдым. Без тикмәгә генә ул кызый белән бергә туры килмәгән икән шул! Югарыдагы Бөек Көч әмере белән эшләнгән икән ул! Кызый Дамирә исемле иде. Икебез дә бер үк төндә бәбиләдек. Икебезнең дә малай иде. Аны палатага, ә мине, хәлем авыррак булганга күрә, реанимация бүлегенә күчерделәр. Баш табиб әйбәт танышым иде. Иртән ул яныма керде һәм минем өчен үлемгә тиң хәбәр җиткерде. Балам үлгән иде. «Галина, сине табиблар кисәткән иде

бит», — диде ул, үзен гаепләмәсеннәр дигәндәй. Мин һәрвакыт тиз уйлыйм, тиз карар кабул итәм. Ә елап ятудан ни мәгънә? Әйе, миңа коточкыч авыр иде, бала урынына үзем үләр дәрәҗәдә идем. Валентинның күзенә ничек карармын? «Мин авыру икән», — дип, аны үземнән биздеримме хәзер? «Әнә фәлән отказ яза, аның баласын минеке белән алмаштырыгыз, «үлде» дисәгез, ул сөенер генә», — дидем. Баш табиб мине кызгандымы, әллә танышлыгыбыз ярдәм иттеме, ул тиз генә чыгып китте. Кире әйләнеп кергәндә, аның агарган йөзенә елмаю кунган иде. «Кизү табиб белән аңлаштык, ул сер саклый торган кеше. Кыскасы, синең теләгең үтәлде, Галина», — диде «баш». Әмма ул нәрсәнедер әйтеп бетерми, икеләнә иде. «Карале, Галина, — диде табиб. — Син кат-кат үлчәдеңме соң инде? Ул бала татардан бит». — «Безнең барыбызда да татар каны ага», — дидем мин, шаяртырга тырышып.

Кичке якта миңа баламны имезергә бирделәр. Гаҗәпләнмәгез, мин аны үз бәгыремнән өзелгән җимешем дип санадым. Гомуми палатада без теге кыз белән очрашмадык, ул, чынлап та, баласының «үлеме»нә сөенеп, вакытыннан алда чыгып киткән. Әй иремнең шатлыгын күрсәгез! Табибларның һәммәсен дә чәчәк белән күмде. Малай матур, таза. Ни гаҗәп, аңарда Валентин чалымнары шәйләнә иде. Денисның үскән саен аңа охшый төшүе дә әкәмәт. Минем, билгеле, тел йозакка бикләнгән: оябызда кайсы кошның баласы тәрбияләнүе тирән яшеренгән. Денис мәктәптә дә, институтта да әйбәт укыды. Сездән яшермим, мин аны чукындырмадым һәм үзем сайлап татар кызына өйләндердем. Әмма киленем җүнсез иде, оныгым тугач, алты айлык Коляны да, ирен дә ташлап, сөяркәсе белән Израильгә качты. Денис та аптырап утырмады: марҗага өйләнде. Ә марҗа оныгым турында ишетергә дә теләмәде, иренә: «Йә ул, йә мин», — дип ультиматум куйды. Денис бозау инде, шуның капризына буйсынды бит. Ахыр чиктә мин яшьләрне фатирдан кудым, ә оныгымны уллыкка алдым. Хәзер аның әнисе — мин, әтисе бабасы иде. Денис малай турында уйлап та бирмәде, тиздән аларның үзләренеке туды. Тик ул онык миңа якын түгел шул. Ә Колям белән без бер җан идек. Аның кебек йомшак күңелле бала юктыр ул. Әз генә кәефем төшсә дә, янымда бөтерелә, әллә нинди юату сүзләре пышылдап, битемнән сыйпый. Мин булмасам, кемгә сыеныр да, кемгә таяныр икән бөркетем. Дөрес, мин аны матди яктан тәэмин иттем. Аның исеменә саклык кенәгәсенә зур суммада акча күчердем, өч бүлмәле фатир сатып алдым. Валентиннан яшереп кенә коттеджны да аңа яздырдым.

Без Хәлил белән тагын очраштык бит! Колям белән үзәк универмагта йөри идек. Бер-беребезне шунда ук таныдык. Ул минем оныгыма озак кына карап торды да:

— Син бәхетле, Галина, — диде. — Ә минем нәселем корыды. Хәтерлисеңме, сез мин озаткан кыз белән бала тудыру йортына бергә кереп киттегез. Без аның белән шул сабыйдан котылырга исәпләгән идек. Малай үле туды. Кызганыч, исән булса, мин аны бүген эзләп табар идем…

Бу сүзләрдән соң «ашыгабыз» дип аласы әйберләремне дә алмыйча урамга чыгып йөгердем. Мин оныгыма хат та әзерләдем. Унсигез яше тулгач уку шарты белән. Аңа: «Татар кызына өйлән», — дидем… Исемен үзгәртсә үзгәртсен. Рухым тамчы да рәнҗемәс…

## «Алтын» итекләр

Дөньяга адәм баласы бик күп чирләр белән туа. (Сүз тән авырулары турында бармый.) Шуларның берсе — мал чире. Заманында халык, бигрәк тә шәһәр халкы, бәллүр савытлар җыйды. «Стенка» дип аталган әкәмәт шкаф-тартмаларда күргәзмәгә куелгандай пыяла җемелдәп утыра иде. Байлык билгесе санала иде ул һәм кунак чакырганда гына урыныннан кузгатыла иде. Соңрак кеше келәм-паласларга ташланды. Шуның белән идән-диварын тышлады, хәтта ки аны түшәменә кадаклаучылар да булды. Футболчылар кебек озын буйлы суыткычлар, музыкаль үзәкләр, компьютер «бумнары» матур гына узды шикелле. Китап модасы чорын хәтерлисездер әле. Юк, уку буенча димим. Исемлекләргә язылып, чиратлар торып, томнар җыеп киштәләргә дыңгычлап тутырган кешеләр арасында гомерендә сыңар әсәр укымаучылар бихисап иде. Ахырдан ул китапларны (модасы бетте!) ун-егерме тиенгә йә базарда саттылар, йә макулатурага тапшырдылар. Бүген машина белән авырый халык. Ала, сата, алмаштыра, вата, төзәтә. Монысы күбрәк ирләр чире. Хатын-кыз исә бизәнү әйберләре өчен җанын фида кыла. Бу мода бәллүр савыт та, келәм дә түгел, җир йөзендә нәфис зат яшәгәндә үтмәячәк әле. Әлбәттә, кемгәдер энҗе-мәрҗән, асылташлар, алтын-көмеш — бизәк кенә, ә кемгәдер чир дә. Ишеткәннәремнән бер гыйбрәтле хәл. Үзе кызганыч, үзе көлке.

— Мин сәнгать даирәсендә шактый билгеле ханым. Гафу итегез, шуңа күрә чын исемемне әйтмим, үземне шартлы рәвештә Гадилә дип атыйм. Университет тәмамлагач, мине бүтәннәр кебек юллама белән мәктәпкә укытырга җибәрмәделәр. Матур җырлагач, сәхнәләрдән оста сөйләгәч, филармониядәге бригадаларга ияреп төрле шәһәрләр, район-авыллар буйлап чыгышлар ясап йөрергә кыстадылар. Советлар Союзы гөрләгән чак, дөнья иркен, дөнья киң. Зинһар, атаклылар арасыннан Гадиләне эзләмәгез, мин фәлән җырчылар күләгәсендә яшәп танылалмадым инде. Элек без, яшьләр, бик тыйнак идек. Хәзерге «такмакчылар» төсле, кеше башына баса-баса, «йолдыз» титулына дәгъва белдермәдек.

Әмма минем бернинди омтылышым да юк иде дисәм, ялганлармын. Мин ярлы гаиләдә үстем. Без җиде бала идек. Минем бик тә байыйсым килә иде. Кайсыдыр артист: «Акча җыймагыз, яна», — дигән иде, янды. Иртән уянганда халыкның саклык кенәгәсендәге меңнәре тиеннәргә калды. «Алтын табышлы, аны теләсә кайчан акчага әйләндерергә мөмкин», — диделәр. Күпмедер акчам бар иде, шуларга бизәнү әйберләре — алка, йөзек, чылбыр алдым. Бу гамәлем ошады. Кызлар кулына әз генә акча керсә, йә кием бөтәйтә, йә диңгездә ял итә, ә мин, бай киләчәк турында хыяллана-хыяллана, бөтен хезмәт хакымны шуңа туздыра башладым. Көлмәгез, көлмә, бүген ул чат саен, базар саен алтын кибете, ә Советлар Союзы вакытында иң дефицит нәрсә — алтын иде. Район кибетләренә кайтса, аны секретарь хатыннарына шудыралар, ә Казанда бердәнбер «Яхонт» кибете ишеге төбендә әче таңнан чират. Анда итәк астыннан сатучылар очрый, ләкин алар милициядән куркып сак эш йөртә. Миңа гүя алтын җене сукты, көн туса, иң зур хәсрәтем алтын юнәлтү иде. Кемнәр аша гына элемтәләр урнаштырмадым да кемнәр белән генә танышмадым. Хезмәт хакын алтын «ашагач», ашау-эчү каты-коты, өс-баш хәерче иде инде. Рәхмәт коллективка, өлкән җырчының бер бүлмәле хрущевкасы бушагач, миңа бирделәр. Ремонт ясап маташмадым, акча җәл иде. Иңе-буе утыз сантиметрлы чүпрәк капчыгым, күңелне җылытып, яртылаш тула иде. Мал зиһенемне томалагандыр, егетләр күземә күренмәде минем. Кияүгә сорасалар, кире кактым. Без яшь чакта ярлы белән бай юк, һәммәбез дә тигез идек. Ә мин үземне «бай кәләш» дип чутладым. Малымны ниндидер ир белән туздырырга башыма тай типмәгән, янәсе.

Тора-бара хәзинәмне саклавы кыенлашты. «Фәләннәрнең фатирын басканнар» дигән хәбәр колакка чалынса, йөрәк жу-у итә иде. Әгәр мине дә таласалар? Гастрольләргә киткәндә, капчыкны, идән тактасын каерып, аска яшерә идем. Бу да ышанычлы урын түгел иде. Хәйләкәр караклар бер иснәнсә, диварыңа хәтле сүтә икән. Ә алар әллә кайчан иснәнгәндер инде. Чөнки күрше-күлән арасында: «Гадилә, такмаса да, алтын ярата», — дигән чыш-пыш таралган иде.

Бервакыт мин үземчә хәйлә кордым. Өчәр кат йон оекбаш белән кия торган зур башлы киез итегем балконда аунап ята иде. Авылларга чыкканда аяк туңмасын өчен һәр җырчыда булды алар. Иске иде инде ул, әзрәк көя дә тапаган иде. Алтыннарымны ике өлешкә бүлеп, шул итекләрнең эченә тыктым да өстенә басып-басып чүпрәк тутырдым. «Кечерәймәсен» дип әни шулай эшли иде. Әй башлы да инде мин! Йә, кайсы карак сәләмә итек актарсын ди! Ул җәйдә төпчек сеңлем имтихан бирергә килде. «Фатирны бикләп йөр», — дип, ачкычны аңа тапшырып, чираттагы гастрольгә — Ташкентка очтым. Унике көннән әйләнеп кайтсам, сеңлем өч имтиханын да бишле билгеләренә тапшырган һәм шатлыктан бүлмәләрне җыештырган. Бүлмә белән берочтан балконны да…

— Итекләр кайда-а?! — Акырган тавышыма түшәм ишелде бугай.

— Иске бит алар, көя дә төшкән үзләренә, чүплеккә ыргыттым, — диде сеңлем.

…Күземне ачканда, йөземә ак халатлы табиб иелгән иде. Артта мышык-мышык сеңлем елый. Аңымны җуеп егылгач, «ашыгыч ярдәм» чакырткан икән.

Шуннан соң ике ай хастаханәдә дәваландым. Нервыларым какшаган иде. Тик файдасы гына тимәде. Алтыннарым белән саташып, кибеп-саргаеп кабергә табан атлаганда олы апамның киңәше белән мәчеткә өшкертергә кердем. Яшь кенә Әлфинур абыстай: «Намаз укыйсыңмы?» — дип кызыксынды. «Юк» дигәч: «Иртәгә кил әле», — дип, аркамнан сыйпап озатты. Шулай әкрен генә мәчеткә тартылдым, намазга бастым, дини китаплар укырга керештем. Шунда гына үземнең әлегә кадәр дөрес яшәмәгәнемне белдем. Шайтан, алтын белән алдап, мине мал колына әверелдергән икән. Чирем дә мал чире икән. Җан тынычлыгына ирешкәч, сулышларым киңәйде, йокыларым тирәнәйде. Мин бәйсез һәм азат кеше идем.

…Ике ел дини курсларда укыткан остазым Әлфинур белән Лаеш районына — аның туган авылына кунакка кайттык. Кыш иде. Мунча ягарга җыендык.

Әлфинурның әнисе:

— Аягың да өшемәс, тайдырмас та, мә әле, — дип, мич башыннан итекләр алып миңа бирмәкче иде, остазым җирәнгәндәй аларны кире аралыкка ташлады.

— Шушы сәләмәләрне оялмыйча кунакка кидерәләрмени, әни! — диде.

Һай, мин бу «сәләмәләр»не танып өлгердем шу-ул! «Балконнан аякланган» итекләрем иде болар! Әле аларның эчендәге чүпрәге дә алынмаган. Димәк, алтыннарым исән!

— Мәрхүм әткәйнең бер начар гадәте үтерә иде безне. Казан тирәсендәге чүплектән хуҗалыкта ярап куя дип иске галошлар, чиләкләр, комганнар ташый иде, — дип акланды Әлфинур. — Бу итекләрне дә терлек-туар янында кияргә булыр дигәндер инде.

Төне буе йокламадым. Колагымда гел бер тавыш: «Алтыннарыңны ал, алтыннарыңны ал...» Шайтан шулай котырта иде. «Ничек серемне Әлфинурга ачыйм икән?» — дидем. Яшь остазым мине терелтеп аякка бастырды, тормышымны үзгәртеп, юлымны ислам нуры белән яктыртты. «Син — мал колы!» — дип, ул миннән йөз чөерсә, нишләрмен?

Шайтан кыяфәтендәге нәфесне җиңдем дигән идем, ул җиңелмәгән икән. Элеккеге авыруларым тагын көчәйде. Иманым зәгыйфь булганга күрәдер, Аллаһы Тәгалә мине икенче мәртәбә бик каты

сынады. Әлфинур: «Авыл һавасы килешмәсме, әйдә безгә», — дигәч, сөенә-сөенә ризалаштым. Хуҗалар тышта йөргәндә, җаен туры китереп, алтыннарны җәһәт кенә сумкама бушатам, янәсе.

Остазымның әнисе бу юлысы безгә өр-яңа итекләр тоттырды:

— Мәгез, мә, балалар, киегез! Кызым, син гелән-гелән тиргәгәч, төпсез чиләкләрне дә, ертык галошларны да, теге көяле итекне дә капчыкларга тутырып, шофер Илдарга бирдем. Мәйтәм, Казанга барышлый чүплеккә түк. Сәләмәләрдән арындык, Аллага шөкер, — диде карчык.

## Яңа ел төнендә...

Тәрәзәдән урамга карап торам. Һавада бөтерелә-бөтерелә кар бөртекләре оча. Күңелгә моңсулык өстәп, чираттагы ел да узып бара. Тиздән иске белән яңа алмашына. Бернәрсә дә үзгәрмәсә дә, декабрьнең соңгы көнендә һәркем могҗиза көтә. Чир-сырхаулар терелер кебек... Бәхетсезләр бәхеткә юлыгыр төсле... Акчасызлар акчага тиенер шикелле... Кемдә нинди уй да нинди өмет! Ә соңгысыннан башка яшәүләре кыен. Кайчакта өмет адәм баласының тар офыкларын киңәйтә, иңнәренә канатлар үстерә. Мин бу вакытта, гадәттәгечә, үткәндәге хәл-вакыйгаларны хәтердән барларга яратам. Быел нигәдер Гөлүсә исемле ерак танышым күз алдыма килеп басты. Гел бәйрәм белән котлаган ханымнан соңгы елларда ым-хәбәр юк. Үпкәләде дисәм — хәтерен калдырмадым бугай. Хәер, ул: «Берзаман Яңа ел кичендә бабай…» — дип сөйләргә тотынса, мин ирексездән көлемсерәп куя идем. Гөлүсә шушы хикәятен: «Син язучыга Яңа ел бүләгем», — дисә дә, язарга әллә кул тимәде, әллә: «Чын микән?» — дип шикләнелде.

Халык гомере буе матур әкиятләргә чолганып яшәгән, һәм, хыялын чынбарлыкка күчереп, алсу төсләр белән бизәгән. Ләкин дөньяда ачылмаган, ачылса да, аңлатырга адәм акылы җитмәгән серләр күп. Шуларның тагын берсенә — Гөлүсә ханым бүләгенә тукталыйк әле.

— Минем бабай Әхмәтгали исемле була. Гәрчә бай балалары чутланса да, өч ир туган ике катлы йортны үз көче белән тергезә. Асты — таш, өсте — нарат бүрәнәдән. Су буенда тегермән кора агай-эне, кибеттә тауар сата. Кыр-басуларда хәйран гына иген игә. Җыеп кына әйткәндә, ир туганнар тирә-якта бик хәлле кешеләрдән санала. Әмма алар комсызланып мал тупламый. Түшәмгә төкереп ятарга күнекмәгәнгә күрә, эшли дә эшли. Яллаган батракларына хезмәт хакын түли, ярлы-ябагайны кан елатмый, мескеннәргә ярдәм итә. Тик революциядән соң боларны, кулак дип, төбетамыры белән куптарып, Себергә озаталар. Бабайның йогышлы чир эләктергән абыйлары юлда ук гаиләләре белән кырыла, ә ул, Аллаһ кодрәте белән, исән кала. Сөргендә ятимә кызга өйләнә. Бичара, туган якларын сагынган, күрәсең, алты елдан хатынын, өч баласын ияртеп, кире авылга әйләнеп кайта. Аны, билгеле, йортына якын да китермиләр. Икенче катта колхоз рәисе, салам да селкетмәгән ялкау Кәримулла оялаган икән, ә беренче катны складка әйләндергәннәр. Тегермән җимерек, кибетләр ватык, койма-капкаларны Кәримулла сүтеп мичкә яккан. Бабай хуҗалыгын күреп утырып елый. Кәримулла бабайга якты йөз күрсәтмәскә боерса да, Исламия атлы карчык, балаларны кызганып, кара мунчасына «фатир»га урнаштыра. Гаилә зурая, иш янына куш дигәндәй, әби тагын бер-бер артлы өч бала тудыра. Авылда әтиләрне «кара мунча пәриләре» дип үртиләр. Җилкәсендә урманнан агач ташып, бабай мунчага терәп ян корма төзи. Моның өчен колхоз рәисе аңа штраф та чәпи. Бабайга колхозда эш бирү турында сүз дә юк, «кулак калдыгы» халыкка йә самавыр, йә чәйнек ише нәрсәләр төзәтә. Ә кышларын, авылдан авылга йөреп, итек бастыра. Кыскасы, ишле гаиләсен ничек тә ач итмәскә тырыша. Ә ярлы Кәримулла һич тынычлап яшәргә ирек бирми, «сез кулак калдыкларының күмелгән алтыны бар» дип, йорт тирәләрен, бакчаларны, нигез төпләрен казыттыра. Туган җирендә кимсетелгән-тибәрелгән бабай хәзер инде үз ирке белән авылдан китәргә ниятли. Хушлашырга дип зиратка — әтисенең каберенә керә ул. Буранлы көн икән. Тирә-юнь ап-ак икән. Кинәт шул аклык эченнән бер тавыш ишетә бабай.

— Улым, уеңнан кире чиген. Балаларым хәерчелектән арынмас дип борчылма, аларга байлык көтмәгәндә ишелер.

«Әти белән сөйләштем», — дип, өйгә йөгереп кайта ул. Аны, кызганыч ки, акылга җиңеләйгән дип уйлыйлар. Төенчекләр яңадан чишелә, әби үкси, балалар шыңшый.

Тормыш элеккеге эздән дәвам итә: үзәккә үткән ачлык, рәиснең каныгулары, «мунча пәриләре» дип үртәүләр... Бабай терелгән сыман тоела, әмма Яңа ел кичендә ул йокысыннан: «Әти белән гәпләштем, әз генә түзәргә куша, — дип саташып уяна. — Балаларыңның бәхете шушы туфракта, ди, бик ышандырып әйтә, оланнар. Ул хикмәтле карт, юк-барны лыгырдамас».

Бабай арттыра, аның атасы Биккол бер дә хикмәт иясенә охшамый. Авылда кибетләр гөрләтеп, гел Казан юлларын таптаса да, сәүдәгәрнең кесәсендә җилләр уйный. «Сәүдәм табышсыз» дигән, имеш, ул. Биккол яшьләй үлә, өч улына аңардан сәләмә йорт белән иске кибетләр генә кала.

Болай да көчкә-мөчкә нужа арбасы сөйрәгән Әхмәтгали бабай базга егылып аягын сындыра. Гаилә туйдыручысыннан колак кага. Хәзер төп авырлык иң олы балага — әтигә төшә. Ул мәктәптә укуын

ташлый. Бабай бөтенләй авырып түшәккә егылгач, күрше авылларга барып, эшкә яллана. Ундүрт яшьлек үсмер сигез кешелек гаиләне ашата. Ә Кәримулла аларны җәлләгән, бүтән каныкмаган дисезме? Бел, дускай, муеннан байлыкка күмелсә дә, хөсетле ярлының күңелендә ачу бетми, ул үзенең булдыксызлыгын аклар өчен барыбер кемнәндер үч ала. Хуҗалыгы иң артта сөйрәлгән Кәримулла, утыз баш сыеры ачтан тәгәрәгәч: «Теге кулак калдыгы хайваннарга агу эчергән», — дип, авыл халкын бабайга каршы котырта. Нәтиҗәдә, куштаннар төнлә, этиләр изрәп йоклаганда, ян кормага ут төртә. Клубтагы яшьләр Ходай ярдәме белән йортның мунча өлешен сүндереп өлгерә. Югыйсә кышкы салкында урамда катасы икән этиләр. Авыллардан авылларга йөреп дөнья исе иснәгән, буын ныгыткан, тел чарлаган эти: «Утыз чакрымдагы урыс чиласына («село» сүзен татарлар шулай үзгәрткән) чакыралар. Чтапан дәдәй — колхоз рәисе, эш бар, килегез, ди әнә, дип күченү турында сүз кузгаткач, сырхау бабай олы улын янына дәшә дә колагына:

— Биккол бабаң рөхсәтеннән башка ике аягымның берсен дә атламыйм, Мидхәт. Бүген, Яңа ел төнендә, мин аның белән хәбәрләшәм, шуннан соң кая юлыбыз илтә — чилагамы, чурткамы — синең ихтыярда, — дип пышылдый.

Иртәгесен бабай аңа бик сәер төш сөйли. Имеш, Биккол карт: «Минем сәүдәдән җыйган хәзинәмне ташлап кая китәсең, сансыз?! Онықларыма дигән мал ияләрен көтә бит. Әз генә сабыр ит», — дип ачуланган, имеш.

Әлбәттә, бу саташулардан эти бик-бик туя. «Әти, син җүләрләнәсең!» — дип кычкырганы өчен ахырдан үкенә ул. Ә бит хәзинә табыла. Хәйләкәр Биккол сәүдәгәр, киләчәктә дөньяларның үзгәрәчәген алдан ук сизенеп, алтын-көмешен тимер сандыкка сала бара. Менә сиңа «табышсыз сәүдә»! Әти сандыкны дәүләт органнарына илтеп тапшыргач, аңа процентын бүлеп бирәләр. Шул процент белән, ниһаять, Биккол онықлары хәерчелектән котыла. Шуннан соң намуслы егет дип, унҗиде яшьлек этине колхоз рәисе итеп сайлаттыра район түрәләре. Дөнья — куласа, бер әйләнә, бер баса, диләр. Кәримулла икенче каттан җиргә мәтәлә шул. Юк, эти аны рәнҗетми, киресенчә, без яшәгән мунчаны аңа бүләк итә.

Вакыйгаларны тизләтеп, алга сикердем, әйеме? Бабайның фатихасыннан башка эти урыс чиласына күченергә базмый. Элеккечә тирә-як авылларда хезмәткәялланып, ачтан үлмәслек кенә микъдарда он, ипи, май ише әйберләр кайтара. Аның котын очырып тагын Яңа ел килә. Нәкъ менә шул чакта бабайның төшләре белән саташуы көчәя ләбаса.

Бу юлысы сырхау гаиләсе белән мәңгегә бәхилләшә.

— Балалар, мин Биккол бабагыз катына күченәм. Җәсәдемне зиратка күммәгез, тау башындагы ялгыз имән төбенә — уң якка җирләгез. Чит-ятларны катыштырмагыз, каберне, малайлар, үзегез генә казыгыз. Эти шулай куша, — ди ул һәм соңгы мәртәбә сулый да күзләрен йома.

Дүрт ир туган үзара озак бәхәсләшә. Икесе: «Кеше көлдермик, зиратка күмик», — ди. Икесе: «Васыятькә хыянәт итмик, тау башына меник», — дип куәтли.

Төнлә мәет саклаганда йокымсыраган этинең колак төбендә, нәкъ өндәге сыман, бер тавыш яңгырый:

— Син — олы бала, Мидхәт, Биккол бабаң кушканны үтә!

...Дүрт туган көрәк-кәйлә күтәреп тауга юнәлә. Туңган җир катламын вата-чокый азапланганда, этинең көрәге ниндидер тимергә бәрелә. «Бу тауда җирле халык чехлар белән сугышкан, мөгаен, берәр төрле корал-мазардыр», — дип аска иелсәләр... Шунда малайлар телдән яза. Корал дигәнең сандык икән. Эче тулы алтын-көмеш икән... «Биккол бабай без онықларына мирасын улының төшләре аша җибәрде, һай!» — дип шаккатып сөйли дә баш чайкый иде эти...

## «Зинһар, мине дә калдырма...»

Гомер бакый изгелек белән яманлык этешә-төртешә бер сукмактан атлаган. Кайсы җиңгән дә кайсы җиңелгән дип өздереп әйтә алмыйбыз, чөнки дөньяда аларны үлчәп барырлык үлчәүләр юк. Ләкин «Шайтан гына өметсез» диләр. (Ник дигәндә, тәүбәгә килсә дә, Аллаһ тарафыннан аңа кичерү булмаячак.) Без һәрвакыт изгелек өскә калкып чыга дип ышанабыз. Тикмәгә генә борынгылар «Изгелек җирдә ятмый» димәгәндер, күрәсең. Ник мин һәрберебезгә дә таныш мәңгелек төшенчәләр турында сүз куертам соң әле? Без үзебез үк катлауландырырга яраткан шушы гап-гади тормышта чәбәләнеп-чуалып беткән хәл-вакыйгалар очрый, һәм, ни гаҗәп, болар йә изгелек, йә яманлык белән бәйле була.

Рәмзия ханым Казан бистәләренең берсендә яши. Ул тумышы белән Арча кызы икән. Күңелендә бикләп-саклап йөртүе авыр, күрәсең, кунагыбыз үз башыннан кичергәннәрен әрни-әрни сөйләргә тотынды.

— Сүземне әнидән башлыйм. Чөнки бу хикәятемнең төп герое — ул. Алдан ук әйтеп куям, мин аны һич кенә дә яманларга җыенмыйм. Еллар узды, яралар төзәлде, үпкә-сапкалар онытылды инде. Ләкин төзәтеп-матурлап та сөйлисем килми. Алай ул ялган булыр иде. Элек татар авыллары әхлаклы иде дисәк тә, анда да җилбәзәк кызлар, азгын егетләр бар иде. Сирәк иде, әлбәттә. Минем әни яшьлегендә чибәр кызлардан санала. Шуңа күрә, матурлыгыннан масаеп, егет арты егет алыштыра. Хәтта күрше

авыллардан да аны озаткалап йөриләр. Ил-көндә бер яманатың таралса — аны төзәтүе бик авыр икән, әни кияүгә чыгып, балалар тапса да, аңа тагылган Җилбәзәк кушаматы шул килеш кала. Җитмәсә, әтигә барганда ул авырга узып өлгерә. Усал телле каенанасына: «Син фәлән иден», — дип чеметеп торырга җитә бу. «Әти» дидем дә... Бер-бер артлы туган ике малайдан соң, әти саналган бәндә акча эзләп Себергә китә. Ул аннан кире әйләнеп кайтканда, дөньяга мин — бәхетсез җан туам. Ник «бәхетсез» диярсез, чөнки әти гаиләсе өчен мин уйнаштан туган бала саналам. Болай да әнидән көнләшкән әти, күзен дә йоммыйча, Аллаһтан да курыкмыйча: «Син ирең читтә чакта бүтән белән чуалгансың, бу кыз минеке түгел, малайларны калдыр да, балаң белән әниләреңә олак», — ди. Аңа каенана да кушыла: «Җирбит, оятсыз, сөйрәлчек, һаман элеккеләрне куасың, фәлән-фәсмәт». Кыскасы, икәүләшеп әнине эт итеп тиргәп ташлый болар. Абыйларга ни, алар бит әле сабый гына, берсе дә җәберләнгән ананы яклый алмый. Әни нишли? Әлбәттә, үзенең гаепсез икәнен аңлатырга тырыша. «Бала синеке», — дип, әтинең аяк астына ятып-ятып елый. Тегеләрнең барыбер күңеле йомшармый. Нәтиҗәдә, без сукыр әбинең сәләмә йортына кайтып егылабыз. Әни мине җүнләп карамый, сукыр карчыкка ыргытып, киенеп-бизәнеп эшкә йөри. Кибеткә сатучы булып урнаша ул. Моны әтигә үч итеп эшләгәндер инде. Безнең заманнарда авыл ирләре, өчәр-өчәр борынга укмашып, кибеттә эчеп ята иде бит. Әни мут та, чибәр дә, телгә дә оста. Ирләр аның белән сүз уйнатыр өчен генә дә кибеткә сугылып үтә. Әти ара-тирә килеп ком бураннары да кузгатып китә, тик файдасы гына булмый: һәр тавыштан соң кибеттә ирләр отыры күбәя. Ир белән хатын бер-берсеннән көнләшеп арыгач, алга табан ызгышып-талашып яшәү мөмкин хәл түгеллеген аңлый һәм килешү төзеп карый. «Кибетеңне биклә дә өйгә — балалар янына кайт», — ди әти. Куанычыннан әнинең башы түшәмгә тия. «Хәзер Рәмзияне алам да кайтам, бәгырь җимешем», — ди ул. Шунда әтинең күзе-кашы җимерелә. «Сөйрәлчектән туган балаңны күземә күрсәтмә, — дип акыра ир. — Йә син, йә кызың. Сайла!»

Әни, билгеле, ике ут арасында яна. Җитмәсә, аңа гайбәтчеләр: «Ирең өйләнергә хатын эзли», — дигән хәбәр ирештереп торалар. Менә шунда әни миннән котылырга ниятли дә инде. Мине курчак кебек киендереп, Казанга юл тота. Киров урамында без автобустан төшәбез. Анда Нурулла мәчете чаты бар. Әни мине шул чатта утыртып куя да үзе урамның икенче ягында яшеренеп карап тора. Аның уенча, кемдер баланы жәлләп алып китәргә тиеш. Аннан соң ул, котылдым дип, җиңел сулап авылга — ир йортына йөгерәчәк.

...Мин башта кызыксынып тирә-якны күзәтәм. Ят урын, ят кешеләр... Аннан нәни йөрәгемә шом үрмәли. Әни кайда соң? Ул миңа: «Тик кенә утыр, мин сиңа курчак эзлим», — дигән иде. Нишләп озаклады икән? Көтеп-көтеп тә килмәгәч, шыңшый башлыйм. Үткән-сүткән миңа игътибар итә. Мәчеттән әллә ничә тапкыр чалмалы бер карт чыгып, минем тарафларга күз салып ала. Шыңшу зур тизлек белән үкереп елауга әйләнә. Бу юлысы минем каршымда башта бер-ике, соңрак өч-дүрт кеше туктый. Теге чалмалы бабай да тек-тек атлап килеп баса.

Олылар, пошаманга төшеп:

— Кем баласы икән? — диләр. — Адаштыңмы әллә? — диләр.

Чалмалы карт:

— Күптән утыра бит бу нарасый, әллә милисә чакыртыйк микән, җәмәгать? — ди.

Мин тагын да катырак елап җибәрәм. Яныма кешеләр җыела да җыела.

«Бу хәлләрне энәсеннән җебенә кадәр ничек хәтерлисең? Сиңа бит нибарысы ике генә яшь булган!» — дип гаҗәпләнмәгез. Мин әни теле белән бәян кылам. Соңыннан ул барысын да үзе сөйләде.

Әнинең өметләре акланмый. Мине милиционер да култыгына кыстырып китми. Күрәсең, әнинең мәрхәмәте уянгандыр, бәлки, кызгангандыр, ул, ах-вах итенеп, төркем эченә ташлана. «Әй кызым, кибеттә чират иде», — дип, мине кулына күтәрә.

Хәзер мин үз хатирәләремә күчәм. Шаяртып әйткәндә, үз телемә сүз бирәм. Әни белән әти һаман кавышмыйлар. Абыйлар ата йортында, ә мин сукыр әбидә үсәм. Әни көннән-көн явызлана, бер сәбәпсезгә мине кыйный. Үземне белә-белгәндә мин сәгать саен тукмала идем инде. Әни бөтен бәхетсезлеген миннән күрә иде. Ул гел-гел бертөрле такмаклар иде:

— Үлмисең дә, ичмасам! Синең аркаңда мин ирсез тилмерәм. Үлсәң, кабер туфрагыңны таптап-таптап күмәр идем.

Бервакыт ул мине урамнан чәчемнән сөйрәп барды. Әлеге дә баягы әче битәр:

— Үлмисең дә, ичмасам! Суга да батмыйсың, ичмасам!

Шунда безгә авыл абыстае Гайшә әби очрады.

— Кызыңны бик рәнҗетәсең икән дип ишеткән идем, Рауза, хак икән, — диде ул. — Картаймыш көннәреңдә шушы бала кулына калмагаең әле, — диде.

Әни авызыннан төкерекләр чәчрәтә-чәчрәтә җавап кайтарды:

— Калмам, калмам, абыстай! Минем ике малаем бар, алар багыр, — диде.

Сигезенче сыйныфтан соң мин авылдан качтым. Башта педагогия училищесында укыдым. Аннары институт тәмамладым. Авыл турында онытырга тырыштым. Сукыр әби мәрхүмә. Ә әти белән әни

никах яңарткан иде. Кунакка кайтам дисәм дә, газиз нигезем юк иде минем. Әниләрнең тормышы бозылыр дип тә шикләндем. Мәрхәмәтсез әти мине барыбер кызым дип танымас иде.

Аллаһы Тәгалә бәхет капкаларымны бикләмәгән икән, мин әдәпле, тәртипле егет белән гаилә кордым. Өч балабыз туды. Үзем, ана назы тоймыйча үскәнгә күрә, аларны яратып-сөеп туялмадым. Иремдә дә бала ярату хисе бик көчле булды. Ул төзелештә участок башлыгы иде. Акчага беркайчан да кытлык кичермәдек. Фатир да алдык, шәһәр читендәге бистәдә яңа йорт та салдык. Шулай тернәкләнеп яшәп ятканда гына авылдан коточкыч хәбәр китерделәр. Мин элек тә туган яклардан күңелсез хәбәрләр ишетә идем. Ике абый да эчә икән, беркайда да эшләмиләр икән. Монысы адәм ышанмаслык иде: әниләрне өйдән куып чыгарганнар. Карт белән карчык күршеләрнең кара мунчасында тереклек итә, ди. Иремнән берни дә яшерми идем. Ул кинәт кенә әйтеп куймасынмы:

— Әйдә икесен дә үзебезгә алып килик. Йорт иркен, рәхәтләнеп торсыннар.

— Юк, юк! — дип кычкырганымны үзем дә сизмәдем. Йөрәгемдә нәфрәт уты дөрләде. Мине каккан-суккан чит-ят кешеләр нишләп бусагамнан атларга тиеш әле. Яшәсеннәр, мунча төс аларга!

Ун көннәр чамасы янып-көеп йөрдем. Ахырдан сабырландым. «Дөньяда ана хакы дигән нәрсә бар, һичьюгы, шунысын уйларга кирәк, Рәмзия», — дидем.

Ирем белән авылга киттек. Андагы кичерешләремне сөйләсәм елармын дип куркам. Карт белән карчык мунча пәриләренә әверелгән: икесе дә корымга буялган, икесе дә шыр сөяк.

Тамак төбенә төялгән утлы төерне йотып, әнигә эндәштем:

— Әйдә киен, син безгә күченәсең.

Әни йомгак кебек аяк астыма тәгәрәде. Үзе:

— Кызым, җимешем, кайлардан очып кунган фәрештә соң син?! — дип тәкрарлый.

Мин, билгеле, әти дигән кеше тарафларына күз дә салмыйм. Ул аякларын салындырып ләүкәдә утыра. Безнең сүзгә катнашмый. Әнине култыклап машинага илткәндә генә артыбыздан чыкты. Сез инде, бу хатын шулай китеп барган, диярсез. Юк шул, зәгыйфь, мескен тавыш бөтен җанымны айкады:

— Зинһар, мине дә калдырма, мин бит синең әтиең, кызым...

## Акыллыга — уй, җүләргә — туй...

* * *

Сиземләү, ягъни интуиция һәр кешедә дә бер үк дәрәҗәдә булмый. Ул гадәт тә, холык та түгел, аңа югары уку йортларында да өйрәтмиләр. Сиземләү — талант кебек үк Аллаһ бүләге. Чагыштырып карасаң, авылда туып үскән кешедә сиземләү көчлерәк. Чөнки ул табигатькә беретеп яши. Туфрак исе, яшеллек, төтенсез һәм корымсыз саф һава, сулап торган бүрәнә йорт, асфальт түшәлмәгән юл-сукмак, тынлык һ.б. — табигый. Бу нәрсә хайваннарга да хас. Гадәттә, авыл эте Актырнак югалса, йөзәр чакрымнан өенә кайта, ә шәһәрнеке, хуҗасыннан аерылса, үз ишегалдында адаша.

* * *

Иман бик күп төшенчәләрне үз эченә сыйдыра (акыл, тәүфыйк, гыйлем, әдәплелек, миһербанлылык, сабырлык һ.б.). Яңа гына гаилә корган егет белән кыздан: «Иң зур байлык нәрсә ул?» — дип сорадым. Болар: «Коттедж, машина, акча, кием, алтын-көмеш», — дип тезеп киттеләр. Яшь чакта, мөгаен, байлык шушы кыяфәттә күзгә күренеп ымсындырадыр, ә менә балалар үсеп җиткәч, алда санап үтелгән әйберләрнең бер мәгънәсе дә калмый. Иң зур байлык — иманлы бала. Нишләптер бу хакыйкатькә соң гына төшенәләр.

* * *

Бүгенге каләм тибрәтүче яшьләр өлкән буынның иҗатын юкка чыгарып сөйләргә ярата. Яр өстендә, кукраеп: «Диңгезнең суы саек», — дип кычкырудан ни мәгънә! Башта шуңа бер тамчы булса да үзең өстә...

* * *

Үз чорында бер генә даһи да, бөек тә халык тарафыннан танылмый. Гасырлар узгач кына аларның эзен эзләп җиде кат җир астында казына башлыйлар.

* * *

Җитәкче-башлыкларны яки аларның туган-тумачаларын ураткан ялагай-куштаннар иң әшәке җаннар, чөнки алар хуҗаларының абынып егылдырырлык хаталарын күреп торсалар да: «Сез хаклы, сез дөрес эшлисез!» — дип хуплап, тагын да күбрәк ялгышларга этәрәләр. Ә ахырдан, җитәкчеләр «янса», тараканнар кебек ярыкка чумалар. Тирә-ягыгызга күз салыгыз әле, андый мисаллар шактый. Рәис Беляев өлкә комитетында идеология секретаре кәнәфиендә утырганда, аның тирәсендә кемнәр генә бөтерелми иде!

Постыннан төшерелгәч, Рәис абыйның әйткәне бар:

— Кайбер «дуслар», «якын иптәшләр» мине мактап бозгандыр, шуңа күз дә томалангандыр. Җүләр инде без, мактауга эрибез, әзрәк тәнкыйть ишетсәк, кырынаябыз. «Рәис Кыямович, син ялгышасың», — дип кисәтүче-төзәтүче булса, язмыш җиле миңа болай ук каты суктырмас та иде, бәлки. Кичә мине Аллага тиңләүчеләр бүген әнә күрмәмешкә салыша.

…Бер төнне өйдә телефон шылтырый. Безнең Рәис абыйлар күршесендә генә яшәп яткан чак.

— Әйдә, сеңелкәш, җыен! Минем дачага барабыз, Роза апаңны да алабыз (Роза Туфитуллова), Фәһимә апаң (хатыны) кыстыбый пешерде. Иреңә әйт, көнләшмәсен, тынычлап йокласын.

Рәис абый шулай тиз генә сөйләп ыргытты да трубканы куйды. Безнең ише халыкка аның белән аралашу «куркыныч» түгел иде инде, ул мәдәният институтының ректоры иде...

Дача дигәнең бәләкәй генә агач йорт иде. Фәһимә апа безне кайнар кыстыбый белән сыйласа, Рәис абый төне буе гармун уйнап җырлатты. Аңарда көч-дәрт ташып тора иде. «Тәнәфес»тә мин икенче катка мендем. Нүештә зур арыш капчыгы күреп, бавын чиштем. Аклы-каралы фотолар! Идәнгә бушаткан идем, шаккаттым. Рәис абый кемнәр белән генә сурәткә төшмәгән! СССРның бөтен күренекле шәхесләре, сәясәтчеләре, ил башлыклары, политбюро әгъзалары шушы капчыкта «ята» икән. «Мин бит, Нәбирә, истәлекләр язам, беренче бүлеген тәмамладым инде, китабымда ул фоторәсемнәрне дә кулланырмын, шәт», — диде ул.

Кызганыч, истәлек тә юк, үзе дә юк... Рәис абый Аксубай районының Шәрбән авылы егете иде. Чаллы төзелгәндә ярты Шәрбәнне шунда күчереп бетерде ул. Вертолет белән авыл читенә кайтып «куна» икән дә, күпме кеше сыя, төяп китеп, эшкә урнаштыра икән. Киң күңелле, юмарт җан иде инде. Имтиханын икелегә биреп, институт баскычы төбендә елап утырган авыл балаларыннан ун минутта студент ясап куя иде ректор Беляев.

Бервакыт туган ягын Туфан Миңнуллинга күрсәтәсе килде аның. Алар дуслар иде. Без бу сәяхәткә өчәү — Рәис абый, Туфан абый Миңнуллин һәм мин барырга тиеш идек. Казаннан кузгалып китәсе көнебез дә билгеләнде. Шәрбән наратлыгында Рәис Беляевнең яшь дусты Рафаэль Әгъләмиев, туганнан туган энекәше Рөстәм Хафизов табын көйләп, учак ягып (Рәис абый көлдә пешкән бәрәңге яраткан. Колхоз рәисе Рафаэльгә: «Мин кайтам, бернәрсә дә әзерләмә, бәрәңге генә тәгәрәт», — дия торган булган.) көтәчәк иде. Хуш, ул көн җитте. Без Язучылар берлеге янында машинага утырып китәргә тиеш идек. Юлга әзерләнеп йөргәндә, Рәис абый шылтыратты:

— Мин әле институтта, срочно берничә мәсьәлә хәл итәсе бар. Союзга әйләнгеч, син яшь кеше, җитез кеше, Туфан абыеңнар йортына табан атла инде, яме! Шунда көт безне.

Бу безнең соңгы сөйләшү дип кем уйлаган! Дөньяда бернәрсә дә эзсез узмый. Йөрәк — иләк сыман арышка охшаган вак-төякләрнең бөтенесен или, әмма кылчыгын үзендә калдыра. Рәис Беляев тыштан гына теге чактагы вакыйгаларны җиңел кичергән кебек күренгән, ә йөрәгенә кылчыклар кадалган да кадалган... Ул кинәт хәле авыраеп, бүлмәсендәге диванга утырган да... чакрымнары билгесез мәңгелеккә юл тоткан. Югыйсә дәртләнеп-ашкынып җыенган урыны — Кама аръягындагы Шәрбән генә иде...

* * *

Безгә ярдәм кулы сузган олы йөрәкле кешеләргә, хәлбуки алар югары дәрәҗәдәге постлар биләсә дә, табынмыйк. Бердәнбер табынуга лаек зат — Аллаһы Тәгалә барлыгын онытмыйк. Әгәр ярдәм күрсәткән кешегә баш орсак, аны Аллаһыга тиңдәш ясарбыз һәм Галәмнәр хуҗасының ачуына дучар итеп, бәла-казага юлыктырырбыз. Изгелеккә изгелек белән җавап кайтарырга ниятләсәк, намаздан соң, мәрхәмәтле бәндәнең исемен атап, аңа бәхет һәм сәгадәт сорыйк. Төчеләнү яки ялагайлануга караганда Кодрәт иясе аша теләгеңне ирештерү, минемчә, иң дөрес гамәлдер. Аннан, намаз артыннан кылган догалар, теләгән теләкләр бик тиз иясен таба, диләр.

* * *

«Изгелек ит тә суга сал: балык белер, балык белмәсә, халык белер». Илшат Шәех улы Фәрдиевнең («Татэнерго» ААҖ генераль директоры, Татарстан Дәүләт Советы депутаты) бөтен булмышы шушы әйтемдә чагылыр иде. Әдәбият-сәнгать әһелләренә, мәктәпләргә, матбугатка, ятим балалар йортына, авыруларга, мохтаҗ гаиләләргә, янгын чыгып йорт-җирсез калган хәсрәтлеләргә, хәлсез карт-корыларга, студентларга һ.б. (бу исемлекнең иге-чиге юк) даими ярдәм иткән бу шәхеснең сез «мин» дип мактанганын яки «мин» дип шапырынганын күрмәссез дә, ишетмәссез дә. Мин, язучы, аңа барысы исеменнән дә рәхмәт әйтер өчен сүзләр барлыйм, ләкин ул сүзләрнең көч-кодрәтен тапмыйча, гаҗиз булып бетәм һәм, аларны йөрәгемә кысып, дәшмичә калам. Бик сирәк кеше чишмәгә тиң: аңарда мәрхәмәтлелек кипми дә, саекмый да. Бик сирәк кеше бүтәннәр кайгысын үз җаны аша үткәрә. Андыйлар, баксаң, гади генә зат та түгелдер сыман! Ә кем? Бервакыт әни Казанга кунакка килде. Икәү тәрәзәдән кичке шәһәргә карап торабыз. Алтынчы кат, йорт түбәсе болытларга орынган. Мин әнигә Илшат Шәех улы турында сөйлим дә сөйлим, сөйлим дә сөйлим. Аны кем дияргә икән, дим. Ул дәшми, аның зәңгәр күзләре күктәге болытларга текәлгән.

Шунда әни, карашын болытлардан күчермичә генә:

— Кем дә түгел, Җир өстенә җибәрелгән фириштә ул, кызым, — дип куйды.

* * *

Мин — бик зур хәзинә иясе. Миндә серләр сандыгы бар. Әгәр аны дөньяга аударсам, соңгы адәм калдыгы булыр идем. Бит кеше саклар дип үз серен ышанып сиңа тапшыра.

Рәшит Сәет улы Хәмәдиев безнең якташ — Аксубай егете иде. Сәер рәвештә кинәт кенә вафат булды, мәрхүм. (Йөрәк диделәр. Кышкы зәмһәрир суыкларда күл-бәкедә коенган, һәм бер тапкыр да сәламәтлегеннән зарланмаган ир-уланның үлеме, чынлап та, сер томаны белән өретелгән иде.) Шуннан соң аның турында истәлекләр тупларга керештеләр. Кызганыч, ул китап ни сәбәпледер дөнья күрмәде. Күрәсең, спонсор табылмагандыр. Җыентыкны төзүче Рәис Нәҗипов «яз» дип миңа да шылтыратты. Хатирәләр юк иде дисезме? И-и, ничек кенә бар иде әле! Рәшит абый Зәй районын җитәкләгән елларда аның янына еш бара идек. Йомыш белән түгел, тәк кенә. Кунакка. Зәй хакимиятенә бюрократизм чире йокмаган, кайчан гына килсәң дә, ишекләр ачык. (Хәзер дә Зәйдә андый чир белән авырмыйлар.) Язучы халкына хөрмәте зур иде аның, ул кабул итү бүлмәсендә чиратларда издереп, сәгатьләр буе көттерми иде. Заманында Рәшит Хәмәдиев Зәйдә менә дигән иркен коттедж салдырып, язучы Аяз Гыйләҗевне шунда яшәтте. Тик кем котырткандыр, Аяз абый йортны әйтми-нитми генә сатып, кире Казанга кайтып китте. Моңа бик сыкранды Рәшит абый. «Ник алай эшләде икән, ә?! Акча кирәк дисә, бирер идек. Без бит бу коттеджда киләчәктә әдәбият музее ясарга хыяллана идек», — диде. Ул кешегә ышана торган беркатлы, шул ук вакытта чиста күңелле, самими җаннарның берсе иде. Истәлекләр язмавымның сәбәбе гади: мин аны җитәкче-түрә буларак белмәдем, ә болай, шәхесенә кагылып, күңел дөньясындагы хәлләрне җилгә сибәргә теләмәдем. Түрә дигәч тә, без еш кына каты бәгырьле, кырыс, төксе һәм дорфа кешене күз алдына китерәбез. Юк, алар арасында да төрлесе очрый. Аллага шөкер, бүген күп кенә җитәкчеләр тормышның төбеннән күтәрелгән, сыртында нужа агайның каешын татыган урта буын вәкилләре. Аларның йөзендә иман нуры бар. Тиздән боларга алмашка яшьләр, Марсель Галиев әйтмешли, пыяла күзле, җансыз «компьютер малайлары» килер. Дөньяны, тормышны, кешеләрне тимер тартмадан гына өйрәнгән шул милләтсез роботлар кулына калырга Ходай язмасын! Гафу, әзрәк читкә тайпылдым. Рәшит абый Чаллы шәһәре хакимияте башлыгы итеп билгеләнгәч, безнең очрашу-күрешүләр, эчкерсез, дустанә әңгәмә корып утырулар сирәгәйде. Ул күргән саен: «Оныттың, килмисең», — дип битәрли иде. Ә мин Чаллы хакимияте тирәсендә уралырга яратмадым. Аның кабинетына үтәр өчен кемгәдер ялынырга-ялварырга кирәк, ә миңа мескенләнергә горурлыгым комачаулый иде. Рамил Галиуллин кебек бер карашыңнан аңлаган урынбасарларны Зәйдән Чаллыга да күчерсә икән ул! Рәшит абый безнең араларның суынганын сизеп уңайсызланды бугай. Аксубайга җыенса, ничек тә хәбәр итәргә тырышты. «Мин фәлән сәгатьтә чишмәдә, дусларың белән килегез әле». Ул Батыр авылы янындагы чишмә тирәсен төзекләндереп, ике яктан да баскыч түшәтте, өстәл-эскәмияләр куйдыртты. Чишмәнең тарихы кызык: әтисе — Сәет абый — Рәшит тугач кипкән елга төбенә төшә һәм үлән арасында челтерәгән тавыш ишетеп, җиргә иелә. Нәкъ аның аяк астында гына чишмә тибә икән. Яшь ир улы хөрмәтенә аңа Рәшит исеме куша. Соңгы елларда Рәшит Хәмәдиев туган җире — Аксубаена ешлады, әтисе нигезендә тергезгән йортына атна саен кайтып йөрде. Җәй айларында аның бакчасы шау чәчәккә күмелер иде. Нигәдер эре-эре розалар яратты ул. Чаллыда Хәсән Туфанның йөзьеллык бәйрәмен уздырганда, чыгышымнан соң Рәшит абый сәхнәгә розалар букеты тотып менде. Чәчәкләрнең авырлыгыннан чүт кенә сыгылып төшмәдем. Авылда туган кеше — дәүләт эшлеклесеме ул, язучымы, сәясәтчеме, зур түрәме — картая-картая таш каладан бизә.

Рәшит абый дөньяның җиде могҗизасын күрә, диңгезнең төчесендә дә, тозлысында да коена, нинди генә илләрдә сәяхәт итми дә нинди генә утрау комнарында кызынмый, ә нәтиҗәдә Аксубайга берсе дә

җитми, Аксубай иң газиз аймакка әверелә. Без яшьлек юләрлеге белән аңлап бетермибез шул: кичәге сала баласы калада ничек кенә тирән тамыр җәйсә дә, аның биредә чын нигезе юк. Кендек каны тамган туфрак кына нигез санала. Һәм ул берзаман үзенә тарта башлый. Бу тарту шундый көчкә ия ки, аңа һичничек карыша алмыйсың. Йөрәккә сагыш булып төшә ул, бәгырьләрне актарырлык моңлы көй булып җанга сарыла. Әллә нинди хатирәләр уятып, үзәкләрне өзә... Шушы хистән оялмады Рәшит Хәмәдиев, юк, оялмады. Кайсыдыр явызы, үчләшеп, аның Аксубай бистәсендәге йортына ут та төртте. Өй эчендә такта белән тышланган диварларга хәтле янган, диделәр. Сәер хәл, читкә китеп даншөһрәткә ирешкән, ил-көндә танылган дәрәҗәле якташларының («безнеке» дип горурланса да) кайтып үз нигезендә төпләнүен өнәми җирле халык. Рәшит абыйга да эчләре пошты бугай. Бүтән куышын яңартып маташмас, үпкәләп бу якка кул селтәр инде дисәк, юк, киредән эшләтте. Картлыгын ул туган җирендә каршыларга өметләнә иде. «Мин Аксубайда бәләкәй генә мини-ферма оештырдым, терлектуар асрыйм», — диде ул берсендә, горурланып. «Кайтам!» — диде бервакыт, кистереп. Кайчан, тәгаен әйтмәде. Аллаһ тарафыннан төзелгән тәкъдирләр каршында безнең өметләр пылт итеп сүнә икән шул.

Исеме билгеле шәхесләр турында гайбәт тиз тарала. Рәис Беляевне урыныннан алгач: «Мәҗлестә утырганда ул партиянең беренче секретаре Г.Усмановны тәнкыйтьләгән, ә моны Рәшит Хәмәдиев, яшертен генә диктофонга яздыртып, Усмановка тыңлаткан», — дип пышылдаштылар. Имеш, шуннан соң Р.Беляев түбән очкан. Мөгаен, моңарчы беркем дә Рәшит Сәет улына бу сорауны бирергә кыймагандыр, ә мин, боргаламыйча-сыргаламыйча, туп-туры сорадым:

— Шул хәбәр дөресме? — дидем.

Рәшит абыйның төсе үзгәрде.

— Мин сатлыкҗан түгел, Нәбирә, — диде. — Ник син гайбәткә ышандың, ник башта ук үземнән сорамадың? — диде. Шунда аның ике күзенә мөлдерәп яшь тулды... Ахырдан ачыкланды: түрәлеккә омтылган фәлән ханымның кулы уйнаган икән. Итәк астына диктофон кыстырып, гайбәт җыйган андый кемсәләр бүген юк дисез мәллә?

...Төн. Улактан шау-шу су ага. Борынгы болгар ханнарының тирмәсе кебек башы очлайтып ябылган өстәл баганасындагы кадакка фонарь эленгән. Рәшит абый сузып-сузып керәшен халкы җыруын җырлый. Тынлык эченә кереп югалган моңның кайтавазы йөрәкләрне сулкылдата. Без бер генә мизгелгә фанилыктан — ыгы-зыгылардан, гайбәт-әләкләрдән, вак мәшәкатьләрдән ераклашабыз. Ә иртәгесен хакимият башлыгы Чаллыга юл тота. Шәп костюмын киеп, шәп галстугын тагып, җитди кыяфәт белән кабинетына кереп утыра, һәм беркем дә аны чишмә буенда язучы Нәбирәләр, укытучы Вәсиләләр, Равилләр белән керәшен җырлары җырлап төн кунган дип уйламый.

...Аксубайга кайтсам, «Рәшит Сәет» чишмәсенә сугылып үтәм. Хәзер хуҗасы өчен чишмәсе җырлый кебек. Тып-тын калып тыңласаң, су агышына аның моңы сеңгән шикелле.

* * *

«Авызның тәме юк» диләр. Картлар гына түгел, яшьләр дә зарлана. 1981 елларда шагыйрә Асия Минһаҗева белән Мөслим районына — аның туган авылы Мөтрәйгә кайттык. Асиянең әбисе бик карт иде инде. Карчык миңа иске китаплар арасыннан саргайган дәфтәр алып бирде. «Мә, бу Шәйхеләхмәт мөфти васыяте, син аны күчереп илгә тарат», — диде. Тыңладым, күчереп яздым. «Сихерче» әсәремдә васыять тулысынча кертелде. «Кыямәт алды Җәбраил фирештәмез, җир йөзенә ун кат иңәрмен, дигәндер. Тәү иңгәндә, бәрәкәтне алырмын», — дип башлана ул. Анда: «Җиденче кат иңгәндә, авыз ләззәтен алырмын», — дигән җөмлә дә бар. Уйланыйк, җәмәгать. Алдагы җиде кисәтүнең барысы да рас килде. Чиратта — сигезенчесе...

* * *

Актриса, театр училищесы укытучысы Тәслимә Хәләф сөйли:

— Студентлар белән фәлән ханымның пүчтәк кенә әсәрен сәхнәләштердек. Ахырдан бу мине чәй эчәргә чакырды. Килсәм — полный банкет! Табында нинди генә ризык юк! Кемнәр генә җыелмаган! Китте тегене күкләргә чөеп мактау! «Яңа драматург туды» дип, тост арты тост әйтәләр. Мине җүләр диярләр, дөньяда миннән дә җүләррәкләр бар әле.

Нишләтәсең, дустым, нәкъ менә иҗатта сай йөзүчеләр үз исеме тирәсендә шау-шу куптара, мактаулар оештыра. Бу да үзенә күрә талант түгелмени?!

* * *

25 гыйнвар, 2001 ел. Кичке сәгать 10.00. Телефон шылтырый. Трубкада Рашат Низами тавышы:

— Котлыйм! Язучылар берлеге идарәсе сине Фатих Хөсни премиясенә тәкъдим итте. Берәү генә каршы иде.

26 гыйнвар, сәгать иртәнге 8.00. Телефон шылтырый. Трубкада тагын Рашат Низами:

— Әле сине котладылармы?

— Нәрсә белән?

— Сиңа кичә Фатих Хөсни премиясен бирделәр бит!

— Ә-ә, шуны әйтәсезмени? Котладылар, кичә кичке унда.

— Ай өлгер кешеләр бар инде! Кем котлады?

— Рашат Низами үзе! — дидем мин. Икәүләшеп көлештек. Рашат абый белән без «Идел» журналында тугыз ел бергә эшләдек. Аңарда хөсетлек юк. Кайбер язучылар турында мондый сүз әйтүе кыен.

* * *

Гайбәт тегермәнен әйләндергәндә, телебез рәхәткә тара. «Юк, юк», — дисәк тә, гайбәт тыңлыйбыз. Чөнки колак тишек, сүз шул тишектән кереп чума. Аерма шунда гына: ишеткән гайбәтне кем ничек куллана. Берәү үзеннән дә өстәп, тагын да купайтып икенче берәүгә тапшыра. Икенчесе — өченчесенә, өченчесе — дүртенчесенә... Ә берәү исә аны кирәкмәгән кәгазь кебек йомарлап ата. Сүз өчен дә чүп савыты бар.

* * *

29 гыйнвар, 2001 ел. «Ватаным Татарстан» гәзитендә Татарстан Президентына сайлаулар турында язмам басылды. Татарча ярты кәлимә белмәгән һәм белергә дә теләмәгән хәсрәт иптәшләргә һәм президентлык дәрәҗәсен түбән төшереп, үзләрен кандидат итеп күрсәткән шофер, эшче, директор һ.б-га каршы яздым. «Укыдыгызмы?» дип, Туфан Миңнуллинга шылтыраттым. Туфан абый көлде дә болай диде:

— Син молодец инде. Укып кына чыгаммы соң, ятлыйм хәтта!

Мин Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев, Равил Фәйзуллин, Илдар Юзеев, Рөстәм Мингалим, Марсель Галиев, Разил Вәлиев кебек затлы әдипләр белән аралашып үстем. Шулар арасында иң якын күргән кешем, әлбәттә, Туфан абый Миңнуллин. Аңа гына менә шулай шылтыратып һәм аңардан гына менә шундый җавап ишетеп була. Элек, әлеге дә баягы без әдәбият бакчасында борын төрткәндә, өлкән буын, үз тирәсенә яшьләрне җыеп, Язучылар берлегендә чәй эчә-эчә кич утыра иде. Әй тыңлап туялмаслык матур гәпләшү бара иде инде! Ник бер сүгенү, ник бер ямьсез-дорфа сүз ычкынсын, болар әйләнәсендә гүя Матурлык, Пакьлек, Чисталык сакта баскан иде. Ул чакта мин бик яшь идем әле. Аларның иҗатына хөрмәт белән карасам да, аларны кабатламыйча, үз буразнамны үзем сызарга тырыштым. Шуңа күп кыен да ашадым. Өлкән әдипләр «Алай язма, болай яз» дип шытырдатып колактан борсалар да, тыңламадым. Кем хаклы, кем хаксыз икәнен әнә Вакыт галиҗәнаплары күрсәтте. Җиңел генә бүтән салган сукмактан атлап китсәм, бүген мин мин булмас идем. Шунысына рәхмәт: бу язучылар үзләрендәге затлылыктан миңа да өлеш чыгарды...

* * *

«Бу дөньяда мин бик озак яшим. Мең ел чамасы...»

Кайчакта ниндидер сәер тойгылар аша яшәешнең икенче бер үлчәменә күчәм. Күрәселәр күрелгән, йөриселәр йөрелгән, кияселәр киелгән, ашыйсы ризыклар ашалган, эчәсе сулар эчелгән шикелле. Дөнья үзе дә бик борынгы сыман. Андый вакытта һични авыр түгел, гомер буе җыелган акылны күтәреп тору авыр. Аны тизрәк каядыр илтеп түгәсе килә. Бу — табигый халәт. Адәм баласы артык акыл тупласа, эчпошыргыч күңелсез кешегә әйләнә. Шуңа күрә «әзрәк савыты тулып җитмәгән» кешеләр белән аралашып, үлчәүләрне тигезләргә кирәк.

«Бу җиһанга мин әле генә тудым. Мин — сабый бала...»

Андый уй да баш миенә чиертеп уза. Сабый гына ихлас ярата, соклана, сөенә, гаҗәпләнә һәм... елый. Әйтик, табигать минем өчен һаман әкияти почмак. Урман-болыннарда йөрсәм, һәр үләнгә, һәр яфракка, һәр чәчәккә сокланам. Йа кодрәтле Аллаһым! Син нинди бөек рәссам! Синдә бернәрсә дә

кабатланмый, бернәрсә дә ярым-йорты гына ясалмый, бөтен нәрсәдә камиллек, төзеклек, тигезлек һәм тереклек бар. Галәмнең мәңгелек серен үзенә йоткан күк бизәкләре — тулган ай белән эреле-ваклы йолдызлар астында басып торганда гына йөрәкне бер үкенеч көйдереп ала: «Их дөнья, дөнья! Каласың, бездән дә каласың...»

* * *

Бердәнбер Ватаным дип мин Татар иле — Татарстанымны саныйм. Илем турында яманлап сөйләсәләр, йөрәгем әрни, мактасалар, түбәм күккә тия. Бүгенге Президентым да берәү генә. Һәм ул шулай бердәнбер булып калачак та. Киләчәктә аны алмаштырырлык кеше күрмим икән, бу минем гаеп түгел. Табигатьнең үз кануннары: талант иясен кадерсезләп, типкәләп йөртмәсеннәр өчен дөньяга көтү-көтү тудырмый.

## Эчтәлек

### Повестьлар

Җәза.......................................................................................................
Күкчәчәк ..................................................................................................
Мәхәббәттә гөнаһ бар ..............................................................................
Каракош ...................................................................................................
Ак торна каргышы ....................................................................................
Тамга .......................................................................................................
Сер...........................................................................................................

### Галәмәт

Югалту һәм табу ......................................................................................
Кызым — иремнең дә баласы... ..................................................................
Мәхәббәт...................................................................................................
«Алтын» итекләр.......................................................................................
Яңа ел төнендә..........................................................................................
«Зинһар, мине дә калдырма...»...................................................................

Акыллыга — уй, җүләргә — туй... .............................................................

Литературно-художественное издание

***Гиматдинова** (Бикчурова) Набира Минахметовна*

**Любовь грешная**

Казань. Татарское книжное издательство. 2008
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

***Гыйматдинова** (Бикчурова) Нәбирә Минәхмәт кызы*

**Мәхәббәттә гөнаһ бар**

Мөхәррире *Р.В.Сабирҗанов*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *В.А.Савельева*
Корректорлары *Л.З.Шиһапова, Г.Г.Гарифуллина, Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 18.02.2008. Форматы 84х108 1/32.
Офсет кәгазе. «Peterburg» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 20,16.
Шартлы буяу-оттиск 20,58. Нәшер-хисап табагы 22,66. Тиражы 6000 д. Заказ Т-120.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

http://tatkniga.ru
E-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahatтм программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.